РИФКАТЬ ӘХМӘТЬЯНОВ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХИ-ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ

РИФКАТЬ
ӘХМӘТЬЯНОВ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХИ-ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2001

УДК 030 + 802/809
ББК 81.2(2Рос=Тат)-3+92
Ә 86

Китап «Россиянең китап басу Федераль программасы» ярдәмендә нәшер ителә.

Фәнни редакторлары:
Татарстан фәннәр Академиясенең член-корреспонденты, профессор *Ф.Ә.Ганиев*
филология фәннәре докторы, профессор *В.Х.Хаков*

Рецензентлары:
филология фәннәре докторы *Ф.Х.Хәкимҗанов*
филология фәннәре докторы *Ф.С.Сафиуллина*
филология фәннәре докторы *Д.Б.Рамазанова*
филология фәннәре докторы *Г.Ф.Саттаров*

**Әхмәтьянов Р.Г.**

Ә 86 Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. — Казан: Тат.кит.нәшр., 2001. 272 б.

Китап татар тел гыйлемендә беренче тапкыр татар лексикасының төп фондын этимологик җәһәттән яктырту тәҗрибәсен эченә ала.

Справочное издание

*Ахметьянов Рифкать Газиззянович*

**КРАТКИЙ ИСТОРИКО-ЭТИМОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Хәбибуллина М.Р.* Бизәлеш мөхәррире *Шәмсетдинов Р.Г.* Рәссамы *Фомин В.В.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Мусина Н.Н.* Корректорлары *Хәмитова Ә.Г.*, *Сундукова Г.Х.*, *Сабирҗанов Р.В.* Нәшрияткә 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән. Оригинал макеттан басарга кул куелды 3.12.2001. Форматы 60×90 1/16. ВХИ кәгазе. «Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 17,0. Шартлы буяу-оттиск 18,5+ф.0,25. Нәшер-хисап табагы 18,4+ф.0,39. Тиражы 3500. Заказ А−488. Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19. **http://www.tatarstan.ru/books/E-mail: tki@books.kazan.ru.** «Идель-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

ISBN5−298−01004−0
© Татарстан китап нәшрияты, 2001

# КЕРЕШ

Бу хезмәт татар теленең төп сүзлек фондын этимологик яктан яктыртуның беренче тәҗрибәсе булып тора. Материалның бирелеш тәртибе ягыннан ул татар әдәби теленең сүз нигезләре сүзлеге. Һәрбер нигезгә кыскача этимологистик характеристика бирелә. Ул характеристика нигез турында иң ышандырырлык дип хисапланган этимологик аңлатмадан (сирәк очракта бердәй ышандырырлык ике аңлатмадан) яки ышандырырлык аңлатманың юклыгын констатацияләүдән гыйбарәт. Тулы этимологик сүзлекләрдән бу хезмәт тагын түбәндәге үзенчәлекләре белән дә аерылып тора:

а) рус теленнән кергән һәм башлыча «интернациональ» сүзләрдән торган фәнни-техник һәм иҗтимагый-политик терминнар (мәсәлән, **акт**, **база**, **кооператив**, **совет**, **союз** һ.б.) сүзлеккә алынмады; гомумән, рус сүзләренең тик татар телендә көчле фонетик үзгәреш кичергәннәренә генә (**бүрәнә**, **сала**, **ызба** һ.б.) этимологик характеристика биреп үтелде. Гарәп сүзләре дә шул нигездә бирелде;

б) аерым авазларны, торыш һәм хәрәкәтләрне белдерә торган тәкълиди (подражательный) сүзләр, үзләренә аерым бер төркем тәшкил иткәнлектән һәм аларның этимологиясе дә үзенчәлекле булганлыктан, шулай ук бу сүзлеккә алынмадылар; тик бүгенге көндә үзләренең тасвирый яңгырашларын югалтып, башка сүз төркемнәренә күчкән нигезләр генә сүзлеккә кертелделәр;

в) диалекталь һәм периферияль лексика шулай ук алынмады, тик әдәби сүзләрнең чыгышын аңларга ярдәм итә торган яисә яңа термин булырлык диалекталь сүзләр һәм архаизмнар гына аерым аңлатылды;

г) сүзлекнең «фәнни аппараты» — аерым аңлатылган сүзләрнең һәм аерым аңлатмаларның чыганакларын (авторларын һәм аларның хезмәтләренең исемен) күрсәтү, теге яки бу сүзнең этимологиясе турында карашлар төрлелеген аңлату һ.б. минимумга җиткерелде; бәхәс тудырырдай булган аңлатмаларның авторлары һәм моңарчы сүзлекләрдә күренмәгән сүзләрнең чыганаклары гына аерым күрсәтеп кителде; фәндә күптән кабул ителгән һәм болай да җиңел аңлашыла торган этимологияләрнең авторлары (күп очракларда аларның кайсы приоритетка ия икәнлеген билгеләү дә кыен булганлыктан) аерым күрсәтелмәде;

д) аңлатмалар мөмкин кадәр кыска бирелде.

Этимонны ачыкларга ярдәм итә торган сүзләр һәм сүз формаларының бирелгән аңлатманы исбат итәргә яраклы булганнары гына китерелде, ягъни теге яки бу сүзнең татар диалектларында һәм башка төрки телләрдә билгеле булган (гадәттә шактый күпсанлы була торган) вариантларыннан тик сүзнең борынгы нигезен яки

тамырын билгеләргә ярдәм итә торганнары гына мисал сыйфатында алынды. Сүзнең таралу ареалын күрсәтү гомуми характеристика төсендә генә башкарылды. Мәсәлән, төрки телләрнең зур күпчелегендә мәгълүм булган сүз *гом. тк. — гомумтөрки* дигән шартлы кыскартма белән билгеләнде. Аның төп фонетик йөзе исә көнбатыш төрки телләр өчен нигез вариантка — IX—XIV гасырдан калган язма истәлекләргә хас булган яңгырашка тиңләштерелде. Мәсәлән, *баш* сүзе уйгур, азәрбайҗан, төрек, төрекмән, кыргыз, тува, башкорт телләрендә *баш* (теге яки бу үзгәрешләр белән), үзбәкчә *бош* (ачык *о*), казакъ, каракалпак, нугай телләрендә *бас*, алтайча *паш*, хакасча *пас*, чувашча *пуç* булып яңгырый; аңлатмада исә гом. тк. *баш* дип кенә әйтелә, бу сүзнең барлык фонетик вариантлары китерелми, чөнки аерым төрки телләргә хас булган регуляр закончалыклы фонетик үзгәрешләрне генә чагылдыралар.

Белүебезчә, татар язма-әдәби телендә дә, диалекталь лексикада да күпсанлы алынмалар — рус, гарәп, фарсы һәм иске төркичыгтай, уйгур вә төрек теле сүзләре бөтенләй үк үзләштерелмәгән, татар теле калыпларына салынмаган килеш кулланылып йөриләр. Аларның фонетик билгеләре бар һәм шулар буенча гына да алынма сүзләрнең кимендә уннан тугыз өлешен танып була. Алар татар теленең морфологик һәм фонетик законнарына буйсынмыйлар.

Төп татар-төрки сүзләре түбәндәге фонетик законнар илә тәгърифләнә:

1) сүз (иҗек) башында ике тартык аваз бергә килми;
2) сүз башында *л* һәм *р* авазлары кулланылмый;
3) яңгырау тартыклардан *г, ч, д,* һәм *з* чагыштырмача сирәк кулланыча; иҗек азагында *б, ғ, г* һәм *д* авазлары очрамый;
4) иҗек азагында ике тартык бергә килми, бу кагыйдәдән чигенте буларак *-лт, -нт, -рт, -жт, -шт, -ст* чатлашулары гына очрый (*арт, выжт, келт, ант, кышт, аст* һ.б.ш.);
5) төп татар сүзләрендә тугыз сузык аваз гына (а,о,у,ы,ә,е,и,ө,ү) кулланыла;
6) ул авазлар аерым сүздә (сүз нигезендә) арткы (калын) яисә алгы (нечкә) рәт сингармоник чылбырлар буенча гына урын алалар (түбәндә ул чылбырлар компакт шәкелдә бирелгән).

1 иҗек 2 иҗек 3 иҗек
*арткы рәт*




Барлыгы ике иҗекле 9 һәм өч иҗекле 18 чылбыр ( 4 нче һәм ары табангы иҗекләрдә *ы* һәм *а* гына кулланыла), мәсәлән, ы-ы: *кызыл*; ы-ы-а: *кызылча* һ.б.ш.

1 иҗек 2 иҗек 3 иҗек
*алгы рәт*




Барлыгы ике иҗекле 11 һәм өч иҗекле 22 чылбыр (4 нче һәм ары табангы иҗекләрдә *е, ә* генә кулланыла), мәсәлән, ә-е: *әкрен*; и-ә-е: *кирәклек* һ.б.ш.



7) Калын сузыклар белән каты тартыклар, ә нечкә сузыклар белән йомшак тартыклар гына чатлаша.
8) төп татар сүзләрендә *о* (русча басымланган *о* кебек), русча *э, ый* сузыклары һәм *h* авазлары кулланылмый.
9) *ф, х* һәм ['] (*һәмзә*) авазлары күбесенчә алынма сүзләрдә очрый (бу авазлар диалекталь сөйләмдә генә актив кулланылырга мөмкин).

Инде аерым алынма группаларының фонетик билгеләрен карап үтик:

*Рус теленнән* һәм *рус теле аша* Европа телләреннән кергән сүзләрдә

а) сүз (иҗек) башында ике һәм күбрәк тартык бергә килә ала, мәсәлән, *кран, стиль, трактор, фронт, штрек.*
б) сингармонизм законнары ригая ителми (икенче, өченче һ.б. иҗекләрдә дә *и, у, ү,* авазлары була ала; бер үк сүздә йомшак һәм каты тартыклар, калын һәм нечкә сузыклар була һ.б.).
в) *о, э* сузыклары, *в*, урта *г* (мәсәлән, *гармонь-гармун, программа*) һәм урта *к* (мәсәлән, *класс, контора-кантур*) тартыклары киң кулланыла.
г) Иҗек азагында *б, г, д* авазлары кулланыла һәм язылышта да чагылдырыла (гарәп-фарсы сүзләрендә алар саңгыраулаштырыла).

Гарәп вә фарсы алынмаларының уртак фонетик билгеләре һәм аерым билгеләре бар. Уртак билгеләргә түбәндәгеләр керә:

а) сингармоник чылбырлар ригая ителми (мәсәлән, *бичара, китап, мөмкин, тәҗрибә, гомуми һ.б.*).
б) каты тартыклар белән нечкә сузыклар вә йомшак тартыклар белән калын сузыклар чатлаша ала (бигрәк тә *ғ* һәм *ķ* авазларының нечкә сузыклар белән еш килүе күзгә ташлана: (*гамәль, мәлгунь, мәкаль, мөстәкыйль, тәкъдим*).
в) составларында *h* авазы була ала (ярдәмлек билгеләр) һәм *ф, х,* сүз башында *г, ғ, л, р,* авазлары еш очрый (ярдәмлек билгеләр), мәсәлән, *галим, зиһен, лаек, рәхим, кәсәфәт* — гарәп сүзләре, *һәм, һәр, һич, миһербан, гөл, рас, рәвеш — фарсы сүзләре*).

Аерым билгеләр:

Гарәп сүзләрендә йомшак *г*, һәртөрле *п, ч* һәм *җ* авазлары булмый.

Фарсы сүзләрендә *г, п, ч,* һәм *җ* авазлары булала. Әгәр нинди дә булса сүз составында *h* авазы да, *г, п* яисә *ч* авазы да булса — бу тәгаен фарсы сүзе, мәсәлән, *гөнаһ, гөруһ (груһ), гуаһ* шундыйлар.

Бик еш кына бер үк сүздә алынмаларның берничә билгесе берьюлы очрый, мәсәлән, *революция* сүзендә рус алынмаларының барча диярлек билгеләре — сүз башында *р*, ачык *э, в, о, ц* авазлары, сингармонизм законына буйсынмау бар; бары тик иҗек башындагы ике тартык килү мисалы гына юк.

Рус һәм гарәп алынмаларының бик ачык морфологик билгеләре бар. Алар махсус хезмәтләрдә (дәреслекләрдә һ.б.) бәян ителәләр.

Югарыда күрсәтелгән билгеләрдән тыш алынмаларның бүтән фонетик билгеләре дә очрый, тик аларны белгечләр генә күрә ала.

Татар телендә, әйткәнебезчә, күп кенә сүзләр кардәш төрки телләрдән һәм монголчадан кергән. Тик аларның күпчелеге бик тиз үзләштерелгән һәм аерымлык билгеләрен сакламыйлар да.

Фин-угор алынмалары турында да шуны әйтергә мөмкин. Төрки алынмаларның аерым аергыч билгеләре тик язма телдән кергән сүзләрдә генә очрый.

Кушма сүзләрдә (нигездә) сингармонизм билгеләре сакланмаска да мөмкин, мәсәлән, *һичкайда, һәрвакыт, бөтенхалык, илтөзәр, сукояр* һ.б.ш.

Төрки язма телләреннән (чыгтайчадан, уйгурчадан һәм төрекчәдән) алынган сүзләрдә икенче вә өченче иҗекләрдә дә *и* һәм *у, ү* авазлары очрарга, өстәвенә иҗек азагында *ғ, г,* авазлары булырга мөмкин, мәсәлән, *олуг, баглау, матур, тугра, тугры* һ.б; уйгур алынмаларында нечкә сузык белән калын тартык бергә килә ала, мәсәлән, *бәгырь* (татарча *бавыр* сүзе белән тамырдаш).

Әлбәттә, мондый алынмаларның да кайбер морфологик билгеләре бар. Гарәп һәм фарсы телләреннән алынган кайбер сүзләр төп татар сүзләреннән фонетик җәһәттән берничек тә аерылмаска да мөмкин, мәсәлән, *азар, байтар, бәрәкәт, исем, кинә, мәсәл, сәмән, тән* сүзләре шундый. Ләкин андый сүзләр күп түгел, хәтта чагыштырмача (гарәп-фарсы сүзләренең төп массасы белән чагыштырганда) сирәк дип әйтергә дә мөмкин.

Ә менә үзләштерелмәгән рус сүзләренең «татарча» әйтелеш очракларын табу кыен. Рус фонетик системасы татар фонетик системасыннан кискен рәвештә һәм һәр җәһәттән аерылып тора.

Транскрипция билгеләре — махсус аерым билгеләр — шулай ук аз санда алынды. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

тамак *к* авазы — *қ;*
тамак *г* авазы — *ғ;*
иҗек ясамый торган *у* — *ў;*
татар-башкорт *о*сы — *ŏ;*
татар-башкорт *ө*се — *ө*;
гомумтөрки *о* — *ŏ;*
гомумтөрки палаталь *ö* — *ö;*
озынлык билгесе (озын сузыкларда) —;
билгенең очлы ягы яңарак вариантны күрсәтә — > (<).



## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

| | |
|---|---|
| алт. — алтай теле | алтайский язык |
| башк. — башкорт теле | башкирский язык |
| бор. — борынгы | древний (яя) |
| гар. — гарәп теле | арабский язык |
| гом. — гомум, гомуми | обще- |
| госм. — госманлы (төрек) теле | турецкий язык |
| диал. — диалекталь | диалектальное |
| ир. — иран теле (телләре) | иранские языки |
| иск. — иске әдәби тел | старолитературный язык |
| к. — кара! | смотри! |
| кар. — караим | караимский |
| кб. — карачай-балкар теле | карачаево-балкарский язык |
| кк. — казакъ теле | казахский язык |
| ккк. — каракалпак теле | каракалпакский язык |
| калм. — калмык теле | калмыкский язык |
| кум. — кумык теле | кумыкский язык |
| кырг. — кыргыз теле | киргизский язык |
| кырым.— кырым татарлары теле | крымско-татарский язык |
| көнб.тк. — көнбатыш төрки телләр (Якын Шәрык культурасы йогынтысындагы халыкларда) | западные тюркские языки (народов, находящихся под влиянием арабо-персидской культуры) |
| көнч.тк. — көнчыгыш төрки телләр (алтай, тува, хакас, якут һ.б. телләр) | восточные тюркские языки (алтайский, тувинский, хакасский, якутский и т.д.) |
| лат. — латин теле | латинский язык |
| лит. — литва теле | литовский язык |
| мар. — мари теле | марийский язык |
| монг. — монгол теле | монгольский язык |
| морд. — мордва телләре | мордовский язык |
| н. — нугай теле | ногайский язык |
| себ.тат. — себер татарлары диалекты | диалект сибирских татар |
| скр.— санскрит | санскрит |
| тат. — татар теле | татарский язык |
| таҗ. — таҗик теле | таджикский язык |
| тк. — төрки | тюркский |
| ткм. — төрекмән теле | туркменский язык |
| тув. — тува теле | тувинский язык |
| удм. — удмурт теле | удмуртский язык |
| уйг. — уйгур теле | уйгурский язык |
| хәз. — хәзер | сейчас |
| үзб. — үзбәк теле | узбекский язык |
| чаг. — чагыштыр! | сравни! |
| чув. — чуваш теле | чувашский язык |
| чыгт. — чыгтай теле | чагатайский (средневековый среднеазиатский) язык |
| ш. ук — шулай ук | также |
| язм. — язмаларда | в письменных памятниках |
| әд. — әдәби тел | литературный язык |

Сүзлекнең **исем нигезләр** дип бирелүенең хикмәте шунда: бирелә төп игътибар исем һәм сыйфатларга бирелә. Фигыль нигезләрнең этимологиясе бик катлаулы һәм еш кына гади укучыга аңлашылып бетмәскә дә мөмкин. Шуның өчен фигыльләрнең этимологиясе кыскача гына бирелде.

## АЛФАВИТ ТӘРТИБЕ

А, Ә, Б, В, Г, Д, Е, Ж, Җ, З, И, Й, К, Л, М, Н, Ң, О, Ө, П, Р, С, Т, У, Ү, Ф, Х, Һ, Ц, Ч, Ш, Щ, Ъ, Ы, Ь, Э, Ю, Я.

# -А-

**АБАГА** «папоротник, орляк» — мар., удм. *абага, абалгы* «абага» — искечә *абага көпшәсе* ~ чув. *упа (упаха, опака) кĕпçи* «аю көпшәсе» дигән сүздән: Себер төрки телләрендә *абага* > чув. *упака, упа* «аю»: төптә бу сүз гом. тк., гом. монг. *абага, абахай, абагы* «апа, абый, бабай (гомумән, өлкән кардәш)» нигезеннән килә: күп кенә халыклар үзләренең чыгышларын аюдан дип исәпләгәннәр, аюны «бабай» дип йөрткәннәр һ.б. Башкорт диалектларында хәзер дә *бабай* «аю». К.Әхмәтьянов, 1981:11—12.

**АБАЙ** «внимательный» (*абайла* «быть осторожным») — гом. кыпчак сүзе: н., кк. ккк. һ.б. *абай* id.

**АБЗЫЙ** «дядя; старший брат» — диал. *абзый, абызагай* < *абыз агай*- мар., удм. *абзый* id. Тат., н. *Абыз* «ученый мулла, интеллигент, писарь, дьяк (во времена Казанского государства)» — гом. кыпчак сүзе, гар. *хафиз* «(Коръәнне) яттан белүче» сүзеннән үзгәргән: элек гаиләдә иң олы баланы укырга җибәргәннәр, шуннан *абыз-ый, абыз агай* «өлкән ир туган» мәгънәсен алган; тат.диал. *әбзи, әбзә, абза — абзый*дан килеп чыкканнар. К.**Абыстай.**

**АБЗАР**, *диал.* **АЗБАР** «хлев, скотный двор» — мар., удм. *азбар, асбар* «азбар, утар» — н., кб., кар., кырым, чыгт. *азбар, абзар, арбаз* «йорт, утырыш, ихата, урам очы» < гар. *арбад* «юлаучылар яши торган урын, торлак» яисә бор. фарсы. *абичариш* «мал-туар утары» сүзеннән булса кирәк. К.Әхмәтьянов, 1989:127—128.

**АБРАУ** «беречь, спасать от опасностей» — чув. *опра-, упра-, уппăра-*, гом. кыпчак. *абра-*, төрек. *abra-* (*abramak*) ~ бор. монг. *abura-* «коткару» сүзенән дип карала. Ихтимал, бор. тк., аб (к.**Аптырау**) «яклаучы сихер, яклаучы рух» сүзеннәндер. *Абрау* сүзеннән метатезаланып *арба-у* «сихерләү» ясалган.

Борынгы заманнарда вакытлыча тиелми, үзендә ау аулanмый торган территорияләр *абрау җир* (*абрау су*) дип аталган.

Чув. *упраççи* < кыпчак. абрачы «яклаучы фәрештә».

**АБЫЙ** «старший брат» — татар теленең үзендә ясалган сүз, ул инде югалган *абай* вариантыннан килә; к. кырг. аба «ага», хакас., алт. *аба* «ата» *абай* «абый». К. **Апа**.

**АБЫН-У** «споткнуться» — кыпчак телләрендә килеп чыккан; башк., к., кб. *абын-*, кырг. *абун-* «абыну»

Формасы буенча **абын-** нинди дер **абы-** фигыленең кайтым юнәлеше.



**АБЫСТАЙ** «старшая сестра; жена муллы, занимающаяся обучением девочек и мальчиков» — диал. *абыз тутай* сүзеннән татар теленең үзендә ясалган. К.**Абзый**.

**АБЫШКА** «мужчина, потерявший первую жену; старый муж» — мар. *обышка*, чув. *опăшка, упăшка* «муж; жених не первой молодости», тат. диал. *абыш* «ага», *амышка* «карт», алт. *абышка* «тол ир». Бу сүз бор. тк. телләрдә еш очрый: *абучка, авунча, авынчка* «ир, карт ир; карчык». Һәм аның бор. тк. *абынч* «юаныч» (*абын-* «юану») сүзеннән ясалуы ихтимал.

Урта Идел регионында *абышка* «хатынсыз калган ир» булса, *кортка* «ирсез калган хатын» була.

**АВАН** «простой, простодушный, открытый» — тат. диал., башк. *ауан*, себ. тат. *әүән* «надан, укымаган», чув. *аван* «яхшы, әйбәт», Ставрополь төрекмәннәрендә *аван* «саран», гагауз. *аван* «явыз», кар. *аван* «гөнаһлы», кабарда телендә *аван* «мыскыл, явызлык». Бу сүз К.М.Мусаев буенча яһүди телендәге *ғавон* «гөнаһ, җинаять» сүзенә барып тоташа һәм Хәзәр дәүләте чорында төрки телләргә таралган.

**АВЫЗ** «рот» — гом. тк. *аўыз ~ ағыз* << бор. гом. тк.* йағыргь > чув. *çăвăр* «авыз», гом. алт. аң «тишек; авыз; ачыклык» сүзеннән дип хисапланыла (*аңыз — йаңыз* «тишеклек»).

**АВЫК** «момент времени» — тат. диал. *әвек, әүек*, мар. *аук*, чув. *авăк*, кб. *ауык* «авык, берара» борынгы гарәп алынмасы (*вакыт* сүзе белән тамырдаш). Бу сүзнең күплек формасы әүкать «хәл; байлык» мәгънәсендә йөри.

**АВЫЛ** «деревня» — рус теле аша күп телләргә таралган татар-кыпчак сүзе, бор. тк. *ағыл* «киртәләп алынган урын, кура, табыр» сүзеннән — **аг, *аң* «ачык һавада мал-туарны туплап тоту өчен ясалган кура» тамырыннан. К.Севортян, 1: 65—66.

**АВЫР** «тяжелый» — гом.тк. *ағыр* «авыр, салмак; кыен; олы» сүзеннән; к. куман. *аур*, үзб. *оғир*, уйг. *ағыр*, чув. *йăвăр*, якут. *ыар*, тув. *аар* «авыр, кыен; әкрен; салмак». Тамыры бор. тк. *агы* «кәрван йөге; товар; затлы ефәк». Мәгънә үсеше борынгы сиръ төркиләрнең ефәк сәүдәсе юлында күпләп хезмәт итүеннән калган (озын-озак, авыр юл йөрүчеләрнең уй вә күзәтүләрен чагылдыра): «йөк < авыр, салмак > кыен ~ әкрен» (йөкле әкрен хәрәкәтләнә бит).

**АГА** «старший брат, дядя» — гом.тк. *аға, ақа* «олы туган, олы кеше, хөрмәтле кеше» тамырыннан (шуннан ук диал. *әкә* «ага», үзб. *ака* «агай»), көнб. тк. *аға* «хөрмәтле олы кеше», чув. *ака, аки* «олы апа», якут. *аға* «олы яшьтәге кеше, ата», хакас. *аға* «баба». Монгол һәм маньчжур телләрендә дә киң таралган (бурят. *аха* «абый, ага», эвен. *акан* «ага, абый»). Чаг. ш. ук санскрит. *акка* «ана, әни», чув., фин. *акка* «апа, әби». К. Севортян, 1974: 70—71.

**АГАЙ ага** сүзеннән (чаг. **Абый**). Күп телләрдә очрый / кырым. *ақай, ағай* «таныш булмаган ир кеше; туган», чув. *акай* «олы апай», монг. *ахай* «абыстай; хөрмәтле, олы хатын»); ага сүзенең эндәшү формасы. Удм., мар. *агай* — татарчадан.

**АГАЧ** «дерево» — иске тат. *йыгач, җыгач,* чув. *йывăç* — болг. **йуач-*, гом. тк. *агач, йагач, айгач,* «агач; урман». Тамыры — бор. *аңгы* «урман» (аң-*гач* кечерәйтү кушымчасы). К. Әхмәтьянов, 1989:27.

**АГУ** «яд» — мар., удм. *агу-*, гом. тк. *агу*, госм. *агу* «ачы», бурят. *аг* «ачы, агу».

Тат. диал., гом. кыпчак. *у, уы* «агу», уа «яман шеш» сүзләре дә *агу* сүзеннән булса кирәк. К.Севортян, 1:67.

**АДАШ** «тезка» — гом.тк. *адаш* сүзеннән (шул ук мәгънәдә). Ясалышы һәм тамыры мәсьәләсенә килгәндә, эш катлаулы. *Адаш* < *ат-даш* дип кенә аңлатуның җитәрлек булмавын хакас. *адалыс* «адаш» сүзе үк күрсәтеп тора.

**АДАШ-У** «блуждать, заблудиться» — мар., удм. *адаш-* чув. *аташ-*, гом. тк. *адаш-, азаш- аз-у* сүзе белән баглы. К.Севортян, 1:94—95.

**АДӘМ** «человек» — ислам әдәбияты аркылы гарәп-фарсы телләреннән кергән сүз. Коръәндә *Адәм* — «дөньяда иң беренче кеше». *Адәм баласы, адәм заты, адәми зат* сүзләренең ясалышы да шул легендага бәйләнешле. Сүзнең тамыры — семит телләренеке (чаг. яһүди *адамаһ* «адәм, кеше»).

**АДЫМ** «шаг» — кыпчак телләренең тарихи үсешендә ясалган сүз булса кирәк. Бор. тк. *ат-, алт-* «атлау, йөрү» сүзеннән *-ым* аффиксы ярдәмендә ясалган. К.чув. *ут-* «атлау», *утăм (удым)* «адым, йөреш»; калм. *адм* «зур адым, үлчәү адымы», азәрб., төрек. *аддым,* үзб. *одим* «адым» — кыпчак телләреннән. Удм. *адымаиы* «юырту» — бор. татарчадан. К. **Атлау.**

**АЕК** «трезвый» — гом. тк. *айык, айыг* «ачык; аек; сәламәт» сүзеннән. Тамыры — бор. гом. тк. *ай* «сәламәт; ачык» (к. **Айны-у**), госм. *аик-* «ачыклану; аязу; сәламәтләнү», госм., азәрб., алт. *айык* «аек, дикъкатьле, абайлы», госм. *ай-* «айну», чыгт., алт. *ай* «акыл; хис»; чаг. эвенк. *ай* «сәламәт; ачык, сәламәтләндерү, ачыклау». Чаг. **Аеш**.

**АЕЛ** «пряжка, подпруга (*у седла*)» — борынгы кыпчак сүзе булса кирәк: чыгт. *аил* «аел, аел бавы», чув. *уйăл* <**ойыл* ~ башк. диал. *әуел* «аел» һ.б. К. **Аеш**.

**АЕР-У** «отделить, разделить» — мар. *айыр-, ойыр-*, чув. *ойар-, уйар-*, гом.кыпчак. *айыр-*, тув. *адыр-* «аеру», бор. тк. *айы* «аерылган, аерым» нигезеннән, бу нигезнең фигыль мәгънәсе дә булган (к.**Аеш**) һәм аннан бик күп сүзләр ясалган. Мәс., тат.диал. *аер* «җәп», *айран* > *әйрән*. К. **Аел**.

**АЕШ** «суть, толк» — бор. *ай-, айы-* «аерымлану» фигыленнән.

**АЖДАҺА** «дракон» — чув. *аçтаха*, тат. диал., мар., удм. *азьдага* фарсы теленнән күп төрки телләргә таралган сүз; фарсы. *аждар, аждарһа, аждаһа,* бор. фарсы. *ажи даһака* «кыйраткыч елан» (*ажи* «елан», *даһак* «кыйраткыч»). *Аждаһа* образы Фирдәүсинең атаклы «Шаһнамә»сендә бирелә.

**АЗ** «мало» — гом.тк. *аз «аз,* күп түгел» сүзеннән. Тамыры — бор. гом. тк. **аргь* «аз, кечкенә» булса кирәк. К. чув. *ар* «аз», монг. *арай*, эвенк. *аран* «аз гына». Чаг. тат. диал. *аран* «көчкә, көч-хәл белән».



**АЗА** *диал.* «демон» — к. алт., тув., хакас. *аза, ада* «җир рухы», *ада* «явыз рух, әзмәвер» (Рамстедт). Башка кыпчак телләрендә дә бар; монгол, тунгус телләрендә киң таралган сүз. Борынгы һинд телләреннән кергән дигән фикер бар.

Тат. диал. *азат* «бәбиләр чире рухы» < *монг. аза-д «азалар». Аза кубу* беренчел мәгънәдә «җир тетрәү» дигән сүз булган. К. Әхмәтьянов, 1981:12.

**АЗАК** «последний» — борынгы кыпчак җирлегенә кайтып кала торган сүз: башк. *аҙак*, кк. *адак* «азак, азакы, соңгы», телеут. *адак* «соңгы, начар». Куман. *азақ, азаг* > *азау* «елга тамагы» > *Азов.* К. **Аяк**.

**АЗАМАТ** «слуга народа» — гар. *'азамат* (иск.тат. *газамәт*) «көч, ярсу» сүзеннән үзгәргән. Алтын Урда чорында *азамат* «гаскәри хезмәт; гаскәри уеннар», шуннан мар. *азамат* «университет» (!). «Батыр сугышчы» мәгънәсендә *азамат* кырг., кк., ккк., н., кум. һ.б. телләрдә очрый. К. Әхмәтьянов, 1977:49.

**АЗАП** «мучения, тяготы» — гар. *газаб* сүзеннән (к. **Газап**) үзгәргән.

**АЗАР** *диал.* «оскорбление; мучение» — фарсы. *азар* «сүгү».

**АЗАР-БИЗӘР** «всяческие неприятности в отношениях между родными» — ~ кырг., кк., ккк., азәрб. *азар-безер (бәзәр)*, чув. *асар-писер* «явыз рух, дию», алт. *казар-пизер, казар-пазар, эзер-пазар,* монг. *асар-усар* «легендар Гэсэр (Хазар) ханның ике эте». *Азар* һәм *бизәр* сүзләре, асылда, борынгы Иран мифологиясендәге *Асура* һәм *Мизра (Митра)* — җир йөзендә тәртип саклаучы ике фәрештә исемнәренә кайтып кала.

Татар-башкорт җырларындагы *Айзар, гизаем, байзар, гизаем* кушымтасы да борынгы мәҗүсилектән килә. К.Әхмәтьянов 1981:13.

**АЗАУ** (азау теш) «коренной зуб» — гом.тк. *азау, азу, азыг* «азау теш» сүзеннән. Тамыры **ар-*; к. монг. *араа* < *арига* «азау теш», тат. диал. *аз теш* «азау».

**АЗМАН** «трутень» — «соры корт; шөпшә» — күбесенчә ата хайванны билгерә торган гом.тк. сүз (к. кк., кырг. *азбан, азман* «печтерелмәгән яки соң печтерелгән айгыр, үгез», кырым., госм. *азман* «ярым печтерелгән тәкә; соры корт»). Тат. һәм гом. тк. *аз-* «блудить, совращаться» (*аз-у*) тамырыннан булса кирәк.

**АЗЫЙ-КӘРӘМ** «название свадебной песни» — к. гом.тк. «Куруглы» дастаны геройлары *Ауҗикәрәм* һәм *Аслы.*

**АЗЫК** «пища» — гом.тк. *азык, азук* «азык; ашамлык запасы» сүзеннән; алт., кк. *азык*, уйг. *озук*, якут. *йысык*, бор. язм. *азук* «азык, азык-төлек». Тамыры ачык түгел (чаг. фарсы. *азука* «азык»). Чаг. **Асра-у**.

**АЙ** «луна, месяц» — гом.тк. *ай, ой* «ай; ай нуры».

**АЙГЫР** «жеребец» — бор. тк. *адгырага* «ата мал, айгыр» сүзеннән килә (бор. язм. *адгыр, азгыр* «айгыр», *адгырак* «ата киек»). Төрки телләрдән тыш та киң таралган (монг. *ажирга, аҗирга, азрага*, бурят. *азарга* ~ эвен. *адирга* «айгыр», бор. монг. *аҗиргы*, маньчжур. *ажырган* «айгыр») һәм хәтта монгол телләреннән алынма булуы да ихтимал. Алтай телендә *айгыр* «бер

айгыр карамагындагы көтү». Чув. *ăйăр* борынгыдан килә (татарчадан түгел).

**АЙДАР** «чуб» — башк., н., ккк., кырг. *айдар* «какул, кәкел, ир-егет толымы» — монгол телләреннән. К. калм. *алдр, арзар* «шан-шәрәф; ир-егетлек билгесе», рус. диал. *ардар* «какул» (Даль).

**АЙКА-У** «махать (саблей, кнутом); искать с криком» — бор. *һайка-* id. *Һай* дип кычкырудан. Бор *һайык* «оран (боевой клич)».

**АЙМАК** «аймак, округа» — бор. тк. *айы-маг* «җыен, төркем, ил» сүзеннән (к. башк., себ. тат. *айма-у* «җыю, кочакка җыю, учлау»), бор. гом. тк. яки бор. гом. монг. *ай-* «җыю» тамырыннан (к. монг. *айм-маг* «аймак», *айшмаг* «җыен», *ай-* «җыю»).

**АККОШ** «лебедь» — күп кенә төрки телләрдә бар; *ак* һәм *кош* сүзләре кушылып ясалган; борынгы төрки телләрдә аккош — *ку, акку*.

**АКЛАН** *диал.* «маленькая поляна» — к. эвен. эвенк. *аклан, аглан*, удэгэй. *аудан* «болын, алан». Монг. *аглак, агыл* «ерак дала, аулак җир» сүзе белән тамырдаш. К. **Аулак, Алан**.

**АКМАН-ТОКМАН** «название начала весны; февраль и март» — тат. диал. *алықман-толықман, алыкман-толыкман* «тоташ, бөтенләй беткәнче»; бор. тк. *алык-* «(запаслар) бетү» сүзеннән; *толыкман, толык, ток*» «төп, зур кисәк; бозау, башмакның тоташ килеш салдырып алынган тиресе».

**АКСА-У** «хромать» — гом.тк. *акса* — «ару; атта озак йөреп аяк оюы» < *ахт-са-* id., бор. *ахт* «ат» сүзеннән булса кирәк.

**АКТЫК** «последний» — көнч.тк. телләрдән килә: кк. *актык-* «дәвам иттерүче, мөрид, варис», тув. *актык* «актык, ахыргы, соңгы», *аак* «ахыргы, соңгы, нәтиҗә». Мисаллардан күренгәнчә, *аак* «азак» сүзенә кайтып кала; *тык-* кайбер төрки телләрдә *-лык*ның (исем һәм сыйфат ясаучы аффикс фонетик варианты (чаг. *култык, җентек, ертык, бөртек*). Борынгырак мәгънәдә *актык* «төпчек угыл, кинҗә». Чув. диал. *актăк*, мар., удм. *актык* «актыккы, бөтенләй» — татарчадан.

**АКУЛЧА**, *диал.* **ӘКҮЛЧӘ, ҮКӘЛЧӘ** — мар. *угылза* — чув. *укăлча, укалча* < рус. *околица*.

**АКЧА** «деньги» — көнб. тк. *акча* «акча, тиен, монета» сүзеннән, беренчел мәгънәсе «көмеш (ак!) тәңкә» булса кирәк: госм., кырым, *акша* «ак, аксыл; акча». Бу сүз бик борынгыдан килә. «Ак → акча» мәгънә күчеше күп телләргә хас (бу турыда к.: Барбаро и Контарими о России. — М., 1971. — с. 154). Ясалышы буенча чаг. *карача* «кара әйбер; тап; артык гади», *кызылча* «кызамык», *яшелчә*. К. ш.ук **Тиен**.

**АКЧАРЛАК** «чайка» — *ак* һәм *чарлак* сүзләреннән; к. себ. тат. *царлак*, кум чарлак «балык тотучы ерткыч кош» (*кара чарлак* та була). Тамыры *-чар* «чарлау, чарылдау авазы».

**АКШАР** «белая глина; мел» — *ақ* һәм иск. тат. *шар* «буяу» сүзләреннән тора (к. бор. рус. *шарь* «буяу, төс», *шарьчи* «буяучы, маляр; художник»); чаг. тат., бор. тк. *сар, сыр* «буяу; известь».

**АКЫЛ** «ум» — мар., удм. *акыл*, тат. *ғакыл* ~ чув. *хакăл* һ.б. гар. *гақл* «акыл» (гақыйль «акылдар») сүзеннән гом. тк. алынма.



**АКЫН** «акын» — казах теленнән. Казах. *ақын* «халык җырчысы; укымышлы, остаз» фарсы теленнән алынма (к. фарсы. *ахонд* «укымышлы», К.**Ахун**).

**АКЫРЫН** «медленный, тихий» — көнч. тк. телләр җирлегендә *ағыр // ақыр* «авыр, салмак» сүзенә инструменталь килеш аффиксы *-ын* ялганып ясалган сүз. К.**Авыр**.

**АЛ** «алый» — гом. тк. *ал* төрки телләрдән тунгус, монгол, славян һ.б. телләргә кергән: сүзнең төп чыганагы фарсы. *лал* «ләгыль (кызыл рубин)» булса кирәк; шуннан ук иске тат., н., кум., калм. *ал* «асыл, сыйфатлы, фазыллы» (*ал кеш тун, ал патша* һ.б., «Заятүләк» дастанында *ал балдак* «тылсымлы балдак», *ал көзге* «сихри көзге»). *Ләгыль ~ лал > ал* күчеше бор. төрки сүз башында [*л*-] килмәве белән аңлатыла.

**АЛА** «пегий» — гом. тк. *ала* «ала, чуар» сүзеннән. Монгол телләрендә дә очрый (бурят. *алаг* «чуар, ала»). Бор. монг. *агула* «карлы тау» сүзеннән дигән фараз бар.

**АЛАБУГА** «окунь» — көнч.тк. һәм кк., куман. *алабуга* «алабуга» сүзеннән, *ала* һәм *буга* сүзләреннән тора (*буга* бирегә «җәнлек, җанвар» мәгънәсендә); чаг. тув. *көге буга* «(күк буга) күгәрчен». Алабуганы аның алалыгына игътибар итеп атау монгол телләрендә дә очрый: бурят. *алгана, алагана (алаг-ана)* «алабуга».

**АЛАБУТА** «лебеда» — рус. диал. *лобода*, бор. рус. *лабуда* «алабута» сүзеннән (к. диал. *алабата, ылабута, лабута* «алабута», фонетик үсеше *лобода > лабута > ылабута > алабута*); *ыла* — өлешенең *ала-* га әверелүе «халык этимологиясе» буенча, үсемлекнең (җиткән хәлендә) «алалыгына» нисбәтән килеп чыккан күренеш; куптәнге алынма, К. кк. *алабата*, куман. *ала бота* «алабута», үзб. *олабота* «бөдрә алабута (марь)».

**АЛАЙ** «так» — бор. тат. *ан-лай* сүзеннән, *ан (ул)* алмашлыгына *-лай* аффиксы ялганып ясалган сүз (чаг. *болай, тегеләй, бөтенләй*); к. кб. *аллай* «алай».

**АЛАМА** «плохой, худой; неприятный» — гом. диал. *аламак* «чүпрәк-чапрак, ертык нәрсәләр» сүзеннән. Бор.тк. *алай-мак* дигәннән, ягъни «алалану, телгәләнү, начарлану, тузу» фигыленнән булса кирәк (гом. тк. *ала* «ала, ямьсез, иске; ямаулы» сүзеннән (Рясянен); к. якут. *äлäмä* «чүпрәк-чапрак, алама», *äлäй-* «начарлану, тузу» (Пекарский, 1:240 — 241); чаг. тат. диал. *әләмә* «иске-москы», *алам-салам, алама-салама* «иске, начар, чүп-чар», кк. *аламай* «ала тышлы, ямаулы», чыгт. *алама* «чүпрәк-чапрак»; чув., мар., удм. *алама* «начар, әшәке» — татарчадан.

**АЛАН** «поляна» — гом. кыпчак. *алан* «алан, мәйданчык, уйсулык» сүзеннән, гом. тк. һәм гом. фин-угор *ал-* «түбән урын» (к.**Алд**) тамырыннан булса кирәк; к. мар., удм. *алан* «тугай, әрәмәле болын» (<тат.). Чаг. тат. диал. *алан* «йорт алды, лапас, япма», кк. *алан* «мәйдан, алан». К. **Аклан**. К.Әхмәтьянов, 1989:28—30.

**АЛАН-ЙОЛАН** «с оглядкой, оглядываясь» — к. калм. *алн-җилң* «алан-йолан»; *алң, алаң*, кк. *алаң* «шикләнеп», *ал-* «шикләнү».

**АЛАС, АЛАЧ** «слово-пароль; боевой клич» — татар, казакъ,

кыргыз һ.б. халыкларның уртак ораны. Сөрән вакытында карга боткасы уенында кырда-яланда учак аркылы сикергәндә дә «*Алач!*» дип кычкыралар. Шуннан Себердә *алас*, Казан арты сөйләшендә *әләсә, әләш, әләшә* — учак аша сикереп уйнау, җыен килеп чыккан. Гарәпчә *халас* «азат, йөксез, гөнаһсыз» сүзеннән булса кирәк. К.Әхмәтьянов, 1981:67; чаг.ш.ук бор.тк. *ал* «ут; ялкын».

**АЛАЧЫК** «лачуга» — гом.тк. *алачык* < *аланчык* «кечкенә мәйданчык, йорт алды, ишегалды», *алан, алаң* «ябулы мәйданчык» сүзеннән; к. тат. диал. *алан* «япма, лапас»: «Казарма дигәннәре тәбәнәк түшәмле, кечкенә тәрәзәле, озын, караңгы алан иде» (К.Тинчурин); *-чык* аффиксы ялганып ясалган; к. алт. *аланжук, аланчык* «кабыктан ясалган өйчек, лапас, алачык, ихата, ихата киртәсе».

Ләкин чув. *лаçă*, башк. диал. *ылаш*, тув. *алажы* ~ уйг., бор. тк. *алачу*, ткм. *алаҗа*, якут. *аласа* «алачык, тирмә; ышык җир, куыш» *алачык* сүзенең икенче тамыры да булганлыгын күрсәтә.

**АЛАША** «мерин» — тат. диал. *лаша* «ат», бор. тк. *лоша, луша* «атланып йөрелә торган ат; качыр» сүзеннән (тамыры буенча алынма сүз булса кирәк; протетик [-*а*-] ның килеп чыгуы йә *ат* сүзеннән, (к. чыгт. *ат-лоша* «ат, алаша, меңге ат», йә төрки телләрнең фонетик законнарына яраштырудан; чаг. *алабута* < рус. *лобода*). Рус. *лошадь* «ат», *лошак* «ана ишәк айгырдан тапкан кушылгак», украин. *лоша* «колын», поляк. *losza* «бия» сүзләре борынгы төрки телләрдән. К.чув. *лаша* «алаша, ат». К.Әхмәтьянов, 1989:75.

**АЛБАСТЫ** «злой дух, вызывающий кошмары и бред» — гом. тк. *албасты* «бастырылдыра торган өй иясе» сүзеннән; беренчел формасы *албарс-лыг* «албарс-лы, албарсы» булган, фонетик үсеше: *албарслыг* ~ *албарс-тығ* > *албастығ* > *албасты;* чаг.кырг. *албарсты* «албасты». Себ.тат. *албарты* «авыр сөякле», якут. *албастах* «сихерләнгән», *иблис* «сугыш алласы», *албас* «җен, сихер». *Албас* < *албарс* < *ала барс* исә киң таралган сүз; к.тув. *алты көстү ала парс* «алты күзле ала барыс» — явыз рух. К. бор. гом.тк. *ала* «начар, явыз», *парс, пар* «барыс»; к. ш.ук алт. *албыс, алмыс* «авыру рухы, явыз рух, җен, кар кешесе — легендар йонлач тау кешесе», шор. *ылбыс* «өрәк; убыр уты» телеут. (алт. диал.) *алмын* «маймыл; явыз рух», монг. *алмас, аламас, албин* «шүрәле, албасты». Төрки телләрдән бу сүз күп кенә күрше телләргә (фарсы, славян, Кавказ) күчкән; к. мар., удм. *албаста* id.

*Албасты* сүзен шумер-аккад. *ламасту* «бер явыз рух» сүзеннән дип тә уйлыйлар.

**АЛ(Д)** «перед» — гом. тк., алт., *ал-ын* «алгы як; маңгай; аскы як» сүзеннән үзгәргән (фонетик үсеше: алын, тартым кушымчасы [-*ы*] ялганганда *алын-ы* > *алны* > *алды*); к. диал. *алып* «урак урганда алда урылмаган кишәрлек», *алны* «ал як», тув., госм. *алын* «алд; маңгай», бор. язм. *алын* «маңгай, кашлак», алт., як ут. *алын* «түбән, бер як, бер чит (тәге)». Сүзнең тамыры бор. гом. тк. *ал* «аскы як, уйсулык мәйдан» булса кирәк; к. көнч. тк. *ал* «аст, түбән».



**АЛДАК** «ложь» — бор. тк. *алдаг* «алдак, ялган; хәйлә» сүзеннән. Гом.тк. *алда-у* фигыленнән. Бор. *ал* «хәйлә; ялган» тамырыннан.

**АЛДА-У** «лгать» — гом.тк. *ал-да-* «алдау, ялганлау, хәйләләү» сүзеннән, бор. тк. *ал* «начарлык, явызлык, хәйлә-мәкер, хәйлә алымы» (к. бор. мәкаль: «Аучы ничә ал белсә, аю шунча юл белер») тамырыннан, фонетик үсеше: *ал-ла* > *ал-да* (ягъни бу сүз башта *ал* тамырына фигыль ясаучы *-ла* аффиксы ялганып ясалган). К. госм. *аллак* «хәйләкәр, сүзендә тормаучы», чыгт. *алдағчы* «алдакчы, ялганчы».

**АЛҖЫ-У** «обессилить» — гом. тк. *ал-чы-* «ялгышу, юлдан язу, рәтсезләнү, чуалу» сүзеннән; *ал//алығ* «начарлык, ялгышлык, ялган, хәйлә» тамырына фигыль ясаучы аффикс *-чы* кушымчасы ялганып ясалган сүз. К. *диал.* алҗау «аптыраган, хәлдән тайган», себ.тат. *алцы-у* «картаеп тилерү», башк. *алйы-у* «исәрләнү, хәлдән таю, арыганлыктан зиһен чуалу», үзб. *алҗимок* «юкны сөйли башлау, юлдан язу», уйг. алҗы- «адашу, акылдан язу».

**АЛКА** «сережки» — гар. *халқа* «алка; әйләнә; боҗра, түгәрәк; тамак» сүзеннән гом. көнб. тк. алынма.

**АЛКЫН** «полководный; стремительный; стрежень» — бор. тат. *алкыгын* id. *алык-* «ашкыну» фигыленнән сыйфат исем (алык- нигезенә *-ын* аффиксы ялганып ясалган). К. чув. *улăх-* «күтәрелү, шәбәю, алгасу», кырг. *алкын-* «кызулану, ярсу, ярсыну», *алкылда-* «ярсып алга омтылу», бор. тк. *алық-* «ярсыну, кискенләшү», шуннан ук тат. *алгысау, алгасу, алыксу* «ярсынып тору».

**АЛКЫШ** «аплодисменты, овация» — уйг. яки госм. телләреннән кергән сүз. К. госм., бор. уйг. *алқыш, алқаш* «дога кылу, бит сыпыру», кар. *алғыш*, кк., ккк. *алгыс* «алкыш, дога». Бор. тк. уйг., үзб. *алқа* — (*алқамок*) «тәрбияләү, мактау» сүзеннән (*алқаш*); бу сүз исә монгол теленнән булса кирәк. К. монг. *алга* (бор. монг. *алақан*, ккк. *алақан*) «уч», *алага-да-х* «уч белән сугу; тәрбияләү», бурят. *альган* «уч; яңаклау, суккалау».

**АЛЛА** «бог» — гар. *аллаһу* «алла, тәңре» сүзеннән.

**АЛМА** «яблоко» — гом. тк. *алма* «алма» сүзеннән. Тамыры ачык түгел; к. бор. язм. *алма, алмыла* «алма», монг. *альмын* «алма». Чаг. һинд-евр. телләрендә: немец. *apfell*, лат. *abella*, литва. *aboll, abelis, abell* «алма», фин. *otena* «алма». Ихтимал, алма агачы Европадан таралгандыр.

**АЛПАВЫТ** «помещик» — бор. тк. *алпагут* «герой, алпавыт, князь» сүзеннән, бор. язм. *алпагу* «рыцарь, башлык» сүзенең күплек формасыннан (*алпагу-т*) гыйбарәт. К. чыгт. *албагут* «алпавыт, герой», монг. *албагут* «герой». Тамыры — *алып*. Хәрби башлыкның алпавытка әверелүе типологик күренеш. К. Әхмәтьянов, 1977:46.

**АЛПАМЫШ** «великан, богатырь» — гом. көнч. тк. «Алпамыш» эпосының төп герое исеменнән, *Алып Маңаш* «Маңаш батыр» дигәннән кыскарган; к. алт. *Алып Маңаш* — эпос баһадиры (алыбы): *Маңаш*, кырг. *Манас* — шул исемдәге эпос циклының баш каһарманы, монголларның дошманы (шуңа күрә монголча *Маңгас* «чудовище»).

**АЛПАР** «рыцарь» — бор. *алып эр* «алып ир» сүзеннән; чаг. бор. тк. *алпагу, алпак* «рыцарь; рыцарь киеме, шлем».

**АЛТМЫШ** «шестьдесят» — бор. тат. *алты-мыш* «алтмыш» сүзеннән. Чаг. **Җитмеш**. *-мыш // меш* кушымчасы бор. *-ым-ыш, -ым, -ыл* кушымчасыннан.

**АЛТЫ** «шесть» — гом. тк. *алты* «алты» сүзеннән, тамыры ачык түгел; *җиде* саны белән чагыштырып, борынгы бер *-ты // -те / -ды* кушымчасын аерырга мөмкин (ягъни *ал-ты*).

**АЛТЫН** «золото» — мар. *алтын*, удм. *алтын, ултын*, чув. *ылтан* — гом. тк. *алтын*, «алтын акча» сүзеннән, бор. *алт* «алтын» нигезеннән (*алт-ын*). К. монг. *алт* «алтын». Сүзнең тамыры ачык түгел, бор. тк. *ал* «ал, кызгылт» сүзе белән бәйләнгән булуы ихтимал (*ал* + кытай. *тон* «бакыр»?) дип карала.

**АЛУ** «сушеная алыча» — к. **Алча**.

**АЛ-У** «взять, брать» — гом. тк. *ал-*, бор. гом. тк. *āл-* «алу, алыну» сүзеннән. Чаг. монг. *абал-* «алу». Чув. *ил-* < *ыл-* < **айл-* id. К.Севортян, I:127—128.

**АЛЧА** «алыча» — иск. тат. *алуча* «вак чия» сүзеннән, тамыры *әлү, алу* «чия төре» — фарсы теленнән алынма. Чаг. госм., ткм. *алча*, үзб. *олча, олуча* «алча». К. фарсы. *алу* «чия».

**АЛЧАК** «чистосердечный» — гом. тк. *алчаҡ* «шаян, күнелчәк, илгәзәк, сүзчән, хәйләкәр» сүзеннән (кайбер телләрдә бөтенләй башкачарак мәгънәләр алган очраклары да бар). Тамыры *ал* (к. бурят. *аалишаг* «алчак, тыныч, юаш», *аалин* «тын, әкрен»), ләкин *алчак* сүзе төрле телләрдә һәм төрле мәгънәләрендә төрле тамырдан килеп чыккан булуы да ихтимал.

Э.В.Севортян *әлчак* сүзен *ал* «түбән» сүзеннән чыгара. Без моны берсүзсез кабул итмәс идек.

**АЛЫП** «богатырь» — гом. тк. *алып, алп* «батыр, баһадир» сүзеннән (монгол, тунгус, корей телләрендә дә бар). Шуннан ук *алпавыт, алпамыш, алпар*. К.Әхмәтьянов, 1981:17—18.

**АЛЫС** *диал.* «далекий; невидимый отсюда; за горизонтом» — тув., алт. *алыс* «яшерен урын, ышык; тау арты; эчке мәгънә, тамыр, нигез», монгол *алсын* «ерак», тат. диал. *алсын* «иске үлән, каудан; нурлы», себ. тат. *асый*, хакас, *азый* < *алсый* «үткән елгы». Кк. кум., тк., н., кырг. һ.б. *алыс*, үзб. *олис* id.

**АМБАР** «амбар» — бор. фарсы. *анбар* «амбар, келәт» сүзеннән гом. тк. алынма. Төрки телләрдән башка да күп ирани булмаган телләргә таралган (гар. *анбар*, монг. *анбар*, рус. *анбар, амбар*).

**АНА I** «мать» — гом. тк. *ана* «ана, ана хайван» сүзеннән. Дөньядагы барлык телләрдә охшаш яңгырашлы булган типологик ымлык тамырдан; к. чув. *ама* «ана», һинд-евр. ami «ана, әни», элам. *амма* «ана», гар. *амма* «ана; нигез, чыгыш».

**АНА II** «Вот, вон» — башк., кк., ккк., үзб. *ана* «ана, әнә» бор. *ан* «ул» (к. *андый, анда, аңа* < *анга*) тамырыннан ясалган сүз. Диал. *анау* «теге, ул» < *ана ул*.

**АНДЫЗ** «девясил; аир» — чув. *антăс*, мар. *андызь*, удм. *андъс* — бор. тк. *андыз* «андыз үләне» сүзеннән. Кыпчак һәм угыз төрки телләрендә *аңдыз* «аңду, посып каравыллап тору» (урыны). Андыз үләне биек һәм яфракчан була.

**АНСАТ** «легко» — иск. фарсы *асанд* «тыныч, ансат» сүзеннән (*асанд* ~ *асант* ~ *ансат*). Диал. *асат* — ансаттан үзгәргән булырга тиеш; иск. *асан* «ансат, җиңел» шул ук *асанд* сүзеннән татар җирлегендә туган яки фарсыдан алынган (к. хәзерге фарсы *асан* «ансат»). К. Җ.Вәлиди, I:72.

**АНТ** «клятва» — гом. тк. *ант*. Тунгус-маньчжурча *аҥ-ыт* «ике туган» сүзеннән — борынгыча ике ят кабиләнең ике кеше үзара кардәш булып хисапланырга вәгъдәләшү гадәтеннән; шуннан ук бор. *ант* «славян һәм төрки кабиләләр союзы» сүзе дә килә (А.И.Попов); чаг. монг. *ант, анда* «кандаш дус, ахирәт», *андагар*» «ант (дус булырга)»; чув. *антăк*, алт. *антык-* «ант итү». *Ант эчү* сүз тезмәсе ант сүзенең килеп чыгышына түгел, борынгы йолага — ант иткәндә (бармакка һ.б.) яра ясап кан эчү гадәтенә ишарә; чаг. осетин. *ard* хачun «ант ашау», таҗ. *қасам хурдан*, фарсы, *соуганд хурдан* «ант ашау».

**АНЫК** «точный, известный» — гом. тк. *аныҡ* «анык, билгеле; хәзерләнгән, билгеләнеп куелган» сүзеннән, бор. тк. *аны-* «казану, табу, хәзерләп кую, алдан билгеләп кую»; тк. *ан-* «искә алу». К. кырг., уйг. һ.б. *аныҡ, аныг* «анык; әзер», уйг. *анун-* «хәзерләнү», *анут-* «хәзерләү», хакас. *аны-* «казану, табу», бор. тк. *анунды* «хәзерләнде» һ.б. Чаг. мар. *аныҡ* «запас» (иске татарчадан). Мисал: «Анык ипинең кадерен бел».

**АҢ** «сознание» — гом. тк. *аң* «аң, сизгерлек; сизгер, зирәк» сүзеннән. Борынгы мәҗүсилектә *āң* «шаман (камчы) илһамы; илһам, күрәзәлек». Бор. гом. тк. тамыр сүз.

**АҢГЫРА** «тупой, глупый» — бор. тк. *аңғыр-ағ* «ачыгавыз» сүзеннән: сүзнең нигезе бор. *аң-ғар- // аң-ар-* «авыз ачылу, ачылып тору» — гом. тк. *аң* «авыз; ачыклык; тишек» тамырыннан (к. үзб. *аңроу* «аңгыра», кырг., себ.тат. *аңыр-* уйг. *аңкар-* «шаккатып калу, авыз ачып калу», бурят. *ангагар* «ачыгавыз», бор. монг. *анга* «ачык булып тору»). К. **Аңкау, Ахмак.**

Икенче яктан, бор. **анғы-р-у* фигыленнән дә **аңгыр-ағ* килеп чыгырга мөмкин; к. тат. *аңкы, аңгы (аңгы-миңге, аңкы-тиңке)* ~ монг. *аңгуй* «ансыз». Чаг. **Миңгерәү**.

**АҢКАУ** 1) «зев»; 2) «разиня» — бор. кыпчак. *аң-кағ* «ачыгавыз, авыз ачыклыгы» сүзеннән, *аң* «авыз, ачыклык» тамырыннан (к. кк. *аңка* «авыз ачыклыгы», *аңкау* «тиле, ахмак, аңкау», кырг. *аңкоо* «аңнау, тилемсә»). Аңкау сүзенең ике мәгънә алуы (1) «авыз куышлыгының югарыгы өлеше»; 2) «тиле, ахмак, ачыгавыз») кыпчак җирлегенә кайтып калса кирәк.

**АПА** «старшая сестра» — гом. тк. *апа* «олы хатын-кыз туган» сүзеннән, барлык алтай телләрендә охшашрак яңгырашлы булган бер ымлык тамырдан; төрки телләрдә *апа // аба, әпә // әбә* тамырының алган мәгънәләре һәм вариантлары гаять күп, монгол һәм маньчжур телләрендә дә киң таралган (к. монг. *абакай* «принцесса, хатын», *ава* «абзый; ата», эвен. *абака* «олы ата». Алтай телләреннән башка телләрдә дә кардәшлек терминнарын *апа* аваз комплексы белән бирү очрый (к. санскрит. *apa* «апа; ана»). К. **Абага**, **Абый**, **Әби**.

**АПАРА** — рус *опара* «апара» сүзеннән (русчада ул *парить* «парлау, булау» фигыленнән).

**АПАТА** *диал. әбедә, әтәпә, әпәтә* — чув. *опăта, упăте*, мар. *обда, овда, абда*, удм. *обида* «аңгырарак урман иясе»; бор. тк. *абита, амита* «табигать рухы» санскрит. *amithaba* «Будданың табигатьтәге гәүдәләнеше» сүзеннән килә.

Бу сүз татар телендә Тау ягы сөйләшендә һәм Себердә генә очрый һәм, ихтимал, борынгы болгар теленнән килсә кирәк.

**АПТЫРА** «недоумевать» — көнч. тк. *аптыр-ға* «ашыгу, кабалану, нәрсә эшләргә белмәү», н., кк., ккк., кум. *абдыра-*, кб. *абызыра-* «югалып калу», алт., кырг., хакас., бурят., эвен. *апта-, аптар-* «сихерләү, сихерләнү», эвен., бурят. *аб* (як., алт. *ап*) «сихер», *аптирга-* «сихерләү». Чув. *аптара-*, удм. *абдра-*, мар. *аптырга-*, эрзя. *апторга-* «аптырау» — татар теленнән.

**АРА** «расстояние, промежуток» — гом. тк. *ара* «ара, аралык; чик» сүзеннән, килеп чыгышы ачык түгел; чаг. осетин. *äча* «ызан, чик», хетт. *ачһа* «чик», бор. *һинд. ачапа* «ят, чит».

**АРАКЫ** «водка» — Азия илләрендәге бик күп телләргә таралган сүз (тк. *аракы, арак*, монг. *арагы*, эвен. *арги*, фарсы. *арак*, гар. *арак*). Башта гарәп телендә килеп чыккан булса кирәк (гар. *арак* «тир, тирләү; парда утыру»).

**АРАН** «стойло» — бор. кыпчак, куман. *айран* «*аран*; маллар аерым-аерым ябыла торган абзар» сүзеннән. *Аер-у* фигыленнән булса кирәк. К. уйг. диал. *айран* «арата, ике ат арасына куела торган агач». Чаг. себ. тат., кырым., кк., чыгт. *аран* «кура, өйалды; чатлы казык».

**АРБА** «телега» — Көнбатыш Азия илләрендә киң таралган сүз; *арба* варианты башлыча угыз телләрендә һәм монгол телендә; күпчелек очракта киң кулланылган вариант: чув. *урапа, орапа*, мар. *арава, орава, орва*, удм. *уробо*, тат. диал., уйг. *араба* «арба; тәгәрмәч» ~ иске тат. *гарәбә* ~ гар. *гарабат* id. табышмаклы сүз; монгол яисә борынгы төрки телдән таралган дигән фикер бар (Рясянен).

**АРГАМАК** «аргамак, скаковая лошадь» — гом. тк. *арғамак, арғымак* «озын торыклы ат», чыгт. *узун арғамағ* «озын муенлы ат, гарәп аты». Борынгы бер бик үк ачык булмаган *арға-* нигезенә *-мақ* кушымчасы ялганып ясалган; к. уйг. *арғун*, кырг. *арғын*, бурят. *арқан* «аргамак; кушылгак». Борынгы Болгар чорында *арғамак* дип корбанга билгеләнгән атны һәм «ат рухын» атаганнар.

**АРГЫШ** «свадебная процессия» — бор. тк. *арқыш* «кәрван, кәрвандаш иптәш; дус; почтальон». Бу сүз рус, коми һ.б. телләргә дә кергән. Сүзнең тамыры — тат., тк. *аркы-* «күчену (бер ара күчү)»; к. тув. *арғы-* «бер араны туктаусыз үтеп йөрү, киләп сару». К. Әхмәтьянов, 1981:75—76.

**АРДАК** «нега, нежность; каприз» — алт., кк., кырг. *ардақ*, башк. *арҙак*, якут. *атаак, атаах* «кадер; иркәләү; узындыру (мәс., баланы)», монг. *ардаг* «өйрәтелмәгән (*ат турында*); иркә (*бала турында*)», бурят. *ардаг* «тәҗрибәсез; кыргый; шук; әбәләк, нәзберек; кире», калм. *ардаг* «йомшак, тиз аручан; кыргый, холыксыз (*ат турында*)», бор. тк. *ардак, артак* «бозылган»; *арта-*, хакас, *арда-* «бозылу, азу» — мар., морд. *орда-, орта-* «бозылу; көйсезләнү». Чув. *иртэх-* «артык иркә булу», *иртен* — «очыну, тәкәбберләнү» ~ бор. тат. **әртән-*, **иртән-*. Рус. *артачить* «бозылу, артык тупас мөгамәлә итү нәтиҗәсендә чәмәнләнү (*ат турында*)» — бор. татарчадан булса кирәк (Пекарский).

**АРЗАН** «дешевый» — фарсы-тадж. *арзан* «арзан, очсыз» сүзеннән алынма. Күп кенә төрки телләрдә билгеле. Тамыры иск. фарсы. *арз* «хак, бәя» — бор. фарсы. *ачz, ачd* «хак, түләү» (Абаев). Татар телендә шул ук тамырдан *арзы-у* «бәясенә тору, тиешле (югары) сыйфатта булу» сүзе булган.

**АРКА** «спина» — гом. тк. *арка* «арка, арт як» сүзеннән, тамыры **ар* (к. **Арт**).

**АРКАН** «крепкая веревка, канат» — гом. тк. *аркан* «юан бау, кылдан үрелгән бау» сүзеннән, борынгы бер *ар-* «бау үрү» сүзенә *-кан // -ган* кушымчасы ялганып ясалган сүз. Чаг. абазин. *арган* «чыпта», монг. *аргамчы, армакчы* «аркан». К. **Аркау**.

**АРКАУ** «уток» — кыпчак җирлегенә кайтып кала торган сүз. К. башк., кк., ккк. *аркау* «аркау, аркаулык» — бор. язм. *аркағ, арқа-ғу*. Нигезе бор. *арка* — «үрү, туку». К. **Аркан**.

**АРКЫЛЫ** послелог «через» — килеп чыгыш юллары бик үк ачык булмаган сүз. К. башк. *аркыры*, бор. язм. *арқуру* «аркылы»; икенче яктан, к. иск. тат. *арткылы* «аркылы». чаг. хакас. *архы*, якут. *арғы* «аркылы агач, тияк, дар».

**АРМАЙ** «староста» — к. башк., удм. *армай* «полицейский, палач»; бор. монг. *албань* «налог җыючы» сүзеннән. *Армай* сүзе татар телендә XVIII гасырга кадәр актив кулланылган. К.Әхмәтьянов, 1981:76.

**АРПА** «ячмень» — гом. тк. *арпа, арба* «арпа» — бор. ирани. *arbhi* «арпа» сүзеңнән (шуннан ук монг. *арбай*). Гом. һинд- евр. сүзе. К. грек. *alfi* ~ албан. *elpi* «арпа».

**АРТ** «задняя сторона» — гом. тк. *арт* < *арын* — (*арн-ы*) «арт як, арка» сүзеннән, тамыры *ар-* «арка»; к. бурят. *ара* «арт як, төньяк, арткы», монг. *ару* «арт». К. **Арка, Арт-у, Артык.**

**АРТ-У** «увеличиваться; в древности также «нагружать» — гом. тк. *арт-* «асып кую, артып тору, ашу, күбәю» сүзеннән, төпкә *арт-* «йөкләү, аркага төяү» сүзеннән булса кирәк (мәгънә күчешләре: «аркага төяү > төяү, йөкләү > асу, элү, очы артып тору > ашып, башкалардан аерылып тору, күбәю»).

*Арт-* фигыленнән *артмак* «ияр капчыгы, курҗын» сүзе дә ясалган.

**АРТЫК** «лишний» — бор. тк. *артук, артыг* «йөк, балласт, кирәкмәгән йөк» сүзеннән (*арт-* «төяү» фигыль нигезенә *-ыг* кушымчасы ялганып ясалган).

**АРТЫШ** «можжевельник» — бор. тк., бор. монг. *артича* «таптаза; саф, сафландыргыч» («ару иткеч, арыткыч, аруландыргыч») **ар-* «чиста» тамырыннан. К. көнч. *артыш* «артыш», бор. язм. *артуч* «артыш, арча» (М.К). Борынгы йола буенча артыш ботагы белән торакны «шайтаннардан арындырганнар».

**АРУ** «чистый; здоровый» — мар., удм., чув. *ару* гом. кыпчак *ару, ариу* бор. тк. *арыг* «чистартылган» — бор. тк., монг. *ары-, ар-* «чистарту» фигыленнән (чаг. тат. *арын-у, арчы-у*).

Бу сүзнең тат. диал. *әру, иру, ире* ~ мар. *ире* >> чув. *ырӑ* «чиста, саф, матур» варианты болгар теленнән килә.

*Ар* тамыры бор. заманнарда «изге» дигән мәгънәдә дә булган.

**АРЧИ** «свадебный поезд» — монг. *арчи, арти, арчил, артил* ярдәмче гаскәр; хан гаиләсен саклаучы төркем» (хәз. монг. *ардыл*), тат. диал. (Нократ) *артчы* «сакчы». Рус *артель* бор. татарча *артил* «арьергард, сакчы гаскәр» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1981: 76—77.

**АРЧЫ-У** «очищать» — гом. тк. *арча-, арчы-* «чистарту, арчу» *ар-* (к. **Ару**) фигыленә *-чы* аффиксы ялганып ясалган (чаг. *борчы, кыр-чы-, чән-че-*).

**АРШЫН** «аршин» — фарсы-таж. *аршин* «аршын» сүзеннән төрки алынма, бор. ирани. *arasnis, aradna* «беләк, терсәк; аршын» сүзеннән килә (чаг.: *фут* — беренчел мәгънәсе «аяк табаны», *карыш* — беренчел мәгънәсе «кул»).

**АРЫ** «дальше» — бор. тк. *ан-гары* яки *ан-ру,* (Рамстедт) ягъни «аңа, аңа таба» дигәннән кыскарган сүз. Кыпчак төрки телләрендә таралган. Чаг. **Бире**.

**АРЫК I** «арык, канава» — гом. тк. *арыķ* «арык, канау, елгадан тармакланып киткән ерынты», себ. тат. *айыр, айырыķ* «аерылган елга» сүзеннән үзгәргән булса кирәк (Радлов); чаг. тув., кырг. *айры, айрыķ,* «инеш». Икенче яктан, к. төрек. *harк (hарķ)* < гар. *ғарк* «ерынты».

**АРЫК II** «худой» — гом. тк. *арығ, арыķ* «ябыккан, арык» сүзеннән, *ар-* тамырыннан (*ар-ығ;* к. тат. *ары-у* «уставать»).

**АРЫСЛАН** «лев» — гом. тк. *арыслан* «арыслан» сүзеннән, ясалышы буенча ике төрле аңлатма бирергә мөмкин: 1) *арсылаң,* ягъни «саргылт хайван» (гом. тк. *аң* «ау, киек» һәм бор. тк. уйг. *ар-сыл* «саргылт»; чаг. алт. *арсыл айу, арсыл аба* «арыслан»; 2) *арыс-лан,* ягъни «ярсу җанвар» (к. уйг. *арыс* «комсыз, ярсу, ерткыч» һәм бор. гом. тк. *лаң* «җанвар, җәнлек»). Төрки телләрдән башка күп кенә телләргә таралган; к. монг. *арсалаң* «арыслан», венг. *oroszlan* «арыслан» һ.б.

**АРЫШ** «рожь» — бор. рус теленнән XVI гасырга чаклы ук кергән сүз; к. рус. *рожь*, бор. рус. *ръжь* < һинд-евр. *roughi* «арыш». К. Әхмәтьянов, 1989:48.

**АРЫШ АНАСЫ** «дух-хранитель полей» — Борынгы болгар мәҗүсилегеннән килә; к. чув. *ыраш амашше*, мар. *уражава*, морд. *розява*, удм. *ӟеганай, мумыӟег* «арыш анасы (фәрештә — алиһә һәм гөмбәчек)». К. Әхмәтьянов, 1981:9.

**АС** «горностай», **сары ас** «колонок» — бор. *арс, арыс* «усал, ерткыч» сүзеннән К. **Арыслан.**

**АСАБА** «вотчинник, основной владелец (земли); основной наследник» — иске тат. *ғасабә* «төп варис; үзәк; нерв» гарәп телендәге *ғсб* «нерв; үзәк» тамырыннан (шуннан ук *ғасаби* «нервлы, тынгысыз»).



**АСАУ**: **асау айгыр** «племенной жеребец» — бор. *арсау* «кыргый, өйрәтелмәгән (*ат турында*)» сүзеннән.

«Менгегә өйрәтелмәгән» мәгънәсендә *асау* күп төрки телләрдә очрый.

**АСЛАМ** «выгода, барыш» — *асула-м* яки *ас-ыт-ла-ма* (Радлов) сүзеннән кыскарган. К.**Асу**.

Мар. *ӓшлӓм, ашлам, ослам*, чув. *ослам, услам*, удм. *услом*, манси. *ослым* «файда; бурыч проценты» бу сүзнең Идел-Урал даирәсендә киң таралган булуын күрсәтә. Ул рус телендә дә очрый һәм Алтын Урда заманында уйгур теленнән таралган булса кирәк.

**АСМАН** «небо» — төрки телләргә фарсы теленнән кергән һинд-евр. сүзе (к. фарсы-таж. *асман, осман* «күк ~ сorg. *smn* «күк»). Һинд-евр. тикшеренүчеләре фикеренчә, бор. славян *акмень* «таш» белән тамырдаш (Пекарский).

**АС(Т)** «низ» — гом. тк. *аст*, бор. тк. *ас-ун* «ас як» сүзеннән (Исхаков), бор. *ас-* тамырыннан (беренчел мәгънәсе бик үк ачык түгел).

**АСТАР** «подкладка» — төрки телләргә фарсы теленнән кергән санскрит сүзе (скр. *astara* «астар, җәймә, пластырь», һинд-евр. **star-, *stal-* «җәю», шуннан рус. *стелить* «җәю»).

**АСТЫРТЫН** «исподтишка» — кыпчак җирлегендә барлыкка килгән сүз (к. кк., ккк. *астыртын* «яшерен, астыртын»), *аст* сүзенә килеп чыгышы бик үк ачык булмаган *=ыртын* элементы ялганып ясалган (чаг. *шыпыртын, югартын, әкертен*).

**АСУ** «польза, выгода» — бор. тк. *асығ* «файда, асу» сүзеннән; кб., кум. *асу*, чув. *осӑ, усӑ* «файда, асу»; тамыры *аси*, ихтимал, кытайча *ай-си* «йок, кунган тузан» — күчерелмә мәгънәдә «процент, бераз файда» сүзеннәндер. К.Әхмәтьянов, 1989:103.

**Ау-У** «подвешивать; вешать» — гом. тк. *ас-* id.

**АСЫЛ** «благородный; исконный, основной» — гар. *асил* «борынгыдан килгән, нәселле» сүзеннән төрки алынма.

**АТ I** «лошадь» — гом. тк. *ат* «ат, алаша» — бор. тк. *ахта* «печелгән хайван, алаша» сүзеннән (фонетик үсеше *ахта // ағта > ағт аът > ат,* Ф.Исхаков). Чыгышы буенча ирани сүз (Радлов, Мелиоранский). К. монг. *ағыт*, бурят. *ағта* «ат, алаша, яхшы ат, менге ат», тув. *аът* «ат», үзб. *ахтхона* «атлыкса, конюшня». К.**Атан**.

**АТ II** «имя» — гом. тк. *āт* «исем, ат» — бор. тк. *айт* < *ай-ыт* «исем, дан, билгелелек» сүзеннән (Радлов), тамыры *ай-* «күрсәтү, җаваплау». К. **Әйт-ү**.

**АТА** «отец» — гом. тк. *ата* «ата, баба» сүзеннән, күп телләрдә охшаш булган ымлык тамырдан (К. бор. элам. *ata*, бор. хетт. *atta*, *ette* «ата, әттә», гот. *atta* «әти», рус. *от-ец* «ата»).

*Ата* тамырыннан: *аталан-у, аталык* (кеше улын тәрбияләүче), *атач > әтәч* һ.б.

**АТАК** «известность; имя, авторитет» (*атак-лы, атак-лау*, диал. *атагы чыгу*) — бор. тк. *āт-ағ* (*ай-ыт-ағ*) «дан; исем» сүзеннән; к. тк. *атак* «дан». К. **Ат** *II*.

**АТАЛГЫ** «скобель» — кк., ккк., н. *аталгы* «китмән», мар. *аталык* «аталгы», калм., монг. *аталга, атылга*, якут. *адалга* «бәлҗә (аркылы балта)» Бор. *ата-* «болгау, туглау; бораулау» сүзеннән, шуннан ук *атала-, атыла-* «май язу».

**АТАМАН** «атаман» — кыпчак җирлегендә яки соңрак ясалган сүз, иске тат. (диал.) *утаман, урта-ман* (Җ.Вәлиди) сүзен, халык этимологиясенчә, *ата* сүзенә нисбәт итеп әйтүдән килеп чыккан; к.н. *удаман* «өлкән көтүче, көтүчеләр группасының башлыгы», башк. (тат. диал.) *узаман, уҙаман* «уен башлыгы», иске тат. *удаман* «атаман».

Сүзнең беренчел мәгънәсе «урда башчысы, урда башлыгы» булса кирәк; уенда урта «уен түгәрәге, уен мәйданы» ( к. кырг. *ордоо ал-* «урда алу уены», *ордомон* «урда алган уенчы»). *-Ман* сүз ясаучы кушымча, башта ул хәрби терминнар ясауда кулланылган: *узаман* «разведчик, алгы күзәтче», *күзәмән* «күзәтче»; бу терминнар соңрак уенга күчкән, аннан аерым характерлы кешеләр атамасын ясаган: *кабарман* «кабаручан кеше», беләмән «минбеләмлекле кеше».

**АТАН** «самец верблюда» — бор. тк. *атан, актан* «атан, печелгән дөя» сүзеннән. Тамыры бор. *ахта* «печелгән хайван» (к. **Ат I**).

*Атан* сүзенең «беренче приз», «иң зур ярыш», «шедевр» мәгънәләре булган.

**АТАУ** «остров, полустров» — кыпчак җирлегендә (кк. *атау* «утрау») бор. тк. *адағ* «аяк, азак, ахыр, елга азагы — елга тамагы» сүзеннән трансформацияләнеп килеп чыккан (фонетик үсеше: *азағ ~ адаг > адау > атау*, мәгънә үсеше: *аяк → азак → ахыр* елга агымының ахыры, елга тамагы, *дельта → дельта утраулары*, һәрбер утрау). К. госм. *ада*, чыгт. *адақ* «утрау, атау», монг. *адаг* «елга тамагы, елга ахыры; түбән җир, тугай. Бор. кыпчак. *атау* «дельта» сүзеннән үк тат. диал., кк. *атау* «куе үләнле тугай, яшел болын» (шуннан рус. *отава* «куе үләнле көтүлек») һәм иске тат. *атау* «тирән урын, чоңгыл» сүзләре дә килеп чыккан. К. **Аяк**, **Азак**.

**АТА-У** «называть» — гом. тк. ат «исем» сүзеннән.

**АТЛАС** «атлас» — гар. *атлас-ун* «шома киндер, атлас» сүзеннән төрки алынма. Тамыры гар. *таласа* «юу, җую, тигезләү, шомарту».

**АТЛА-У** «шагать» — гом. кыпчак. *атла-*, чув. *от- > ут-*, госм., азәрб. диал. *ад-*, бор. тк. *āт-, ат-* «атлау; адымлау» сүзенең тагын да борынгырак яңгырашы татар сөйләшләрендә сакланган булса кирәк; Әстерхан якларында *awыт* «адым», *awытла-* «атлау-у» (Л.Ш.Арсланов). Чаг.ш. ук монг. *алд* «адым озынлыгы».

**АТЛАН-У** «сесть на коня» — һичшиксез, *ат* сүзеннән.

**АТЛЫГ-У** «устремиться; рвануться» — *ат-ыл-* нигезеннән ясалган (< *атыл-ык-у*).

**АТНА** «неделя» — бор. фарсы. *адина* «атнаның бишенче көне, биш көнлек атна» сүзеннән, гом. тк. алынма. Чув. *ерне* «атна; атна көн, ял көне» (шуннан мар., удм. *арня* «атна, якшәмбе»)



йә чуваш теленең үзендә [*д>р*] күчеше нәтиҗәсендә, яки [*д>р*] күчеше булган ирани диалектлардан (мәс., курд. *арна* «атна; җомга көн») килгән.

**АТ-У** «стрелять; кидать» — гом. тк. *ат-, аат-* < бор. *ағыт-* «югары ыргыту» сүзеннән булса кирәк. *Таң ат-у, чәчәк ат-у* дигәндә мифологик күзаллаулар чагыла. (чаг. монг., тунгус. *гарба-, гарпа-* «ату; таң ату»).

**АУ** «охота» — гом. тк. *ав // аг // аң* «ау, киек, ау коралы» (беренчел янгырашын һәм формасын билгеләү кыен) сүзеннән, бик борынгы тамыр сүз. Чаг. кк. *аба*, монг. *аба* «ау, киртәләп, урталап тоту».

**АУЛАК** «укромный, безлюдный» — гом. тк. *ағлак* «аулак урын, сәхрә» сүзеннән. Килеп чыгышы төрлечә аңлатыла. Чаг. тат. диал. *аулақ* «яшерен», кк. *аулақ* «ерак урын, ерак», үзб. *авлак* «аулак урын, ау ауларга мөмкин булган урын», хакас. *ағлах* «аз санлы, аулак», монг. *аглак* «аулак, саф һавалы урын, буш җир», эвенк. *аглан* «дала». Чаг. **Аклан, Алан.**

**АУНА-У** «валяться» — гом. кыпчак. *ауна-* < бор. тк. *агна-* «аунау, авып, тәгәрәп китү» бор. тк. *аг-* «аву» сүзеннән. Ихтимал, бор. *агын* «аву хәле» дигән нигездәндер (*ағын-а-гу> ауна-у*).

**АФӘТ** «беда» — гар. *афәт-ун* «бәла, авыру, зыян, яра» сүзеннән.

**АХАК** «сердолик» — гар. *ғакыйк-ун* «ахык» сүзеннән төрки алынма.

**АХИРӘТ** «подруга» — гар. *ахирәт-ун* «ахирәт, дөньяның ахыры» сүзеннән (*ахыр* сүзе белән тамырдаш). «Ахирәт» — «якын дус» мәгънәсендә искечә *ахирәт дусты* (дөньяның ахырына кадәр дус) сүзеннән кыскарып килеп чыккан сүз.

**АХМАК** «глупый, бестолковый» — гом. көнб. тк. сүз. Гарәп теленнән алынма дип карау (киң таралган фикер) бөтенләй дөрес түгел: гар. *ахмақ* «ахмак, тиле» үзе төрки телләрдән кергән булса кирәк (*хамуқа* «ахмак булу» фигыле бу очракта икенчел күренеш). Бу сүз бор. тк. *аңга-мақ* «ачыгавыз» дигәннән кыскарган, ягъни бор. тк., монг. *аң-а- // аң-га-* «авыз ачылу, ачык булып тору» фигыленнән (*аң-* «авыз, тишек, ачыклык» тамырыннан) килеп чыккан; к. хакас. *аңмах* «ачыгавыз, ахмак», *аңмай-* «авыз ачу, ачыгавыз булу» (себ. тат. *әңмәй* «ачыгавыз, ангыра», алт. *аамай* «ачыгавыз»), бурят. *аңгай-ха* «авыз ачу, ачыгавыз булу»; чаг. бор. тк. (МК) *уңғамуқ* «ахмак, аңкау», госм. *ахумак* «аңкау», мар. *акмук* «удивление», чув. *камӑк* «ачыгавыз, тиле» К. **Ангыра, Аңкау.**

**АХУН** «ахун» (*духовное лицо у мусульман)* — иск. тат. *ахунд* фарсы. *ахунд, ахонд* «укымышлы кеше, укытучы, остаз» сүзеннән (фарсы. *хондан* «уку» фигыленнән).

**АХШАМ** «определенное время вечернего моления после заката» — госм. теленнән; к. госм. *ахшам, ақшам* «кояш баткан вакыт, кичке намаз вакыты». Гом. тк. *ақ* «ак, якты» һәм фарсы. *шам* «кич, эңгер» сүзләре кушылып ясалган (ягъни беренчел мәгънәсе «якты эңгер» булган).

**АЧ** «голодный» — гом. *ач, ăч* «ач, ачыккан, комсыз; ачыгу, әрнү» сүзеннән (фигыль мәгънәсе татар телендә *тамак ач-ты* тәгъбирендә генә сакланган). Бор. тк. бер фигыль формасыннан килсә кирәк. К. **Ачы**.

**АЧУ** «гнев» — бор. тк. *ач-ыҒ* «ачу, ачы, ачылык» сүзеннән; к. үзб. *оччиғ* «ачу», *оччиғланмоқ* «ачулану».

**АЧ-У** «открывать» — чув. *уç-, оç-*, гом. тк. *ач-*. Шуннан гом. кыпчак *ачкыч* һәм тат. диал. *ача, ачамай, ачатай* «ике аяклы корылма, җайланма» сүзе ясалган.

**АЧЫ** «горький» — гом. тк. *ачыҒ* «ач; әрнүле, ачы» сүзеннән (*ач* сүзе белән тамырдаш), иск. тат. *ачу* «ачы» шул ук *ачыг* сүзенең икенче төрле фонетик үзгәреш нәтиҗәсе.

**АЧЫ-У** «киснуть; горкнуть» — чув. *йӳç-, йӳçе-* < айчы-, бор. **аҒ-чы-*, гом. тк. *ачы-*, бор. тк., монг. *аҒ* «ачы нәрсә; тоз; агу» (к. **Агу**) тамырына *-чы* аффиксы ялганып ясалган (чаг. *ар-чы-, кәр-че-, куп-че-*). Тат. диал. *әче-* < бор.**эгчи-* > тк. eksi- «ачу».

**АШ I** «пища; суп» — гом. тк. *аш* «аш, ашамлык; иген, икмәк, арпа» сүзеннән. Төптә ирани сүз дигән фикерләр бар.

**АШ II** «перевалить: переходить границы дозволенного; претворяться в жизнь» — гом. тк. *аш-* id., бор. гом. тк. *āл-* «ашу». Бу фигыльдән ясалган сүзләрдән тат. *ашыр-у, ашыҒ-у* < *ашык-у* (шуннан *ашкын-у*) сүзләре актив кулланылышта. К. **Аша**.

**АША** «через» к. **Аш-**.

**АШЫК** «бабка альчик» — гом.тк. *ашык, ашук* id. Безнеңчә, бу сүзнең тамыры мар. телендә сакланган *ош-, уш-* «ялгау, төйнәү», шуннан тат. диал. *ашкак* «тез», мар., чув. *ошык, ушык (ушăк)* «ялгау урыны», *ошкын, ушкын (ушкăн)* «берләшмә». Чаг. төрек. *ашы* «ялганма», тат. һәм гом. кыпчак *ашлау* «ялганып ясалган улак».

**АЮ** «медведь» — гом. тк. *айыҒ, адыҒ* «аю» сүзеннән. Күптөрле фонетик вариантларда очрый (алт., кк., ккк., куман. *айу, адыҒ, адық, азыҒ*, тув. *адыҒ*, бор. тк. *адыг* «аю»). Чаг. бор. чыгт. *азыҒ-лык* «азаулы, ерткыч тешле» (Боровков).

**АЯГҮРӘ** «стоя на ногах» — иск. тат. әд. *аяк үзрә* «аяк өстендә» дигәнне *урә тору* дигән сүз белән контаминацияләүдән килеп чыккан булса кирәк. К. **Үрә**.

**АЯЗ** «ведренный» — гом. тк. *айаз* «аяз, салкын, суык» сүзеннән, бор. тк. **айаргь* «аяз, ачык, якты» нигезеннән. Шуннан болгар. **айар* > мар. *айар, ояр* ~ чув. *ойар* > *уйар* «аяз». тамыры-*ай* сүзеннән булса кирәк. К. Әхмәтьянов, 1989:4.

**АЯК** I «нога» — гом. тк. *айак*, бор. тк. *азак* (МК), *адак* (Боровков) «аяк» сүзеннән. Бор. гом. тк. **адак* нигезеннән; к. чув. *ура* «аяк» id. Бор. тк. *адак* «аяк, түбән як, түбәнлек, ахыр, оч, елга тамагы» сүзенең күчмә мәгънәләре аерым төрки телләрдә аерым фонетик яңгырашлар алып дифференциацияләнгәннәр һәм башка төрки телләргә таралганнар, шул нигездә тат. *азақ* һәм *атау* сүзләре килеп чыккан (к. уйг., тув. *азақ* «аяк, ахыр», тув., монг. *адак* «түбәнлек, сай җир», госм. *азак* «түбән җир, астыр», якут. *атак* «аяк, түбән,



түбәнге як, ахыргы, азаккы», бор. язм. *атак* «аяк» һәм башкалар). К. **Азак, Атау.**

**АЯК** II «сосуд» — гом. тк. *айақ* «савыт, чиләк, чүлмәк», бор. гом. тк. *аңақ* «авыз, тишек, куышлык, чүлмәк» сүзеннән килә (бор. гом. тк. *аң* «авыз, тишек» тамырыннан; Рясянен); к. якут. *айақ* «тишек, авыз, ишек, бәке, баз, авыз, зур савыт» (Пекарский), хант. *аң // ан, анәх // анәк* «савыт, җамаяк», манси. *ане* «тәлинкә», монг. *айага* «савыт», мар. *аң, әң* «тишек, савыт бугазы». К. **Аңгыра, Аңкау, Ахмак.**

**АЯКЧУ** «обувь» — *аяк* һәм *чу* < бор. тк. чоҒ «төенчек» сүзеннән. Бу сүз башта аякны төреп бәйләгән тире кисәген белдергән.

**АЯУ** «языческий праздник цветов» — мәҗүси бәйрәм: җәйге чиллә башында үткәрелә торган булган. Бу чорда печән чабу, урман кисү һ.б. рәвештә «табигатьне рәнҗетү» тыелган; аның каравы кырлар-болыннардан «җитмеш җиде төрле чәчәк җыеп, суга салганнар. *Аяу атнасы* «бала тапканнан соңгы ял атнасы». *Аяу* үзе *ая* — «поберечь» фигыленнән; чув. *ояв. уяв*, мар. *оя, уя* бәйрәм; аяу бәйрәме» татар теленнән. К. Әхмәтьянов, 1981:63.

Гом. тк. *айа* — фигыле тунгус. *ай-* «дәва, дәвалау» сүзе белән чагыштырыла (Севортян). К. **Нардуган.**

## -Ә-

**Ә** I *межд.* «а» — барлык телләрдә охшашы булган ымлык тамыр (чаг. рус. *а*, грек., гот. *а* «авырту, сорау, гаҗәпләнү ымлыгы») (Покорный).

**Ә** II *союз* «а» — рус. *а* теркәгеченнән булса кирәк. Чаг. кк., ккк. *а* «ә».

**ӘБӘЛӘК** «обидчивый; мягкотелей» — н., «кырг. *эбелек*, кк., ккк. *ебелек* «кангак (үлән); җилбәзәк» уйг. *әп-, әлп-* — «тиз генә качып, чабып китү» сүзеннән.

**ӘБӘТ** «обед» — рус. *обед* «әбәт, төшке аш» сүзеннән борынгы алынма (чаг. чув. *апат // епет*, венг. *ebet* «әбәт»). Тамыры *ед-* «аш».

**ӘБӘҮ** *межд.* «ой» — гом. тк. характердагы ымлык, к. башк. (тат. диал.) *абау, аба*, тат. диал. *аппа*, үзб. *абба, обба* — нәфрәтләнү ымлыгы, чув. *апав, апап*, бурят. *аппа*, «Әбәү, тьфү», уйг. *аба* — җирәнү яки гаҗәпләнү ымлыгы. *Әбәү* < *абау* < *абаб-* бор. тат *абаба, аба-аба* формасыннан (ягъни *аба* ымлыгының кабатлануыннан) килә.

**ӘБИ** «бабушка» — иск. тат. *әбәй* формасыннан, гом. тк. *әбә* «карчык, әби, хөрмәтле карт хатын» нигезеннән килә (киң таралган уртак тамырдан; к. **Апа**); к. госм., башк., мар., удм. *әби, эбә* «кендек әбисе», якут. *эбә* «әби». Тат. *әби* сүзенең борынгы скиф. *апи* «җир алиһәсе» сүзе белән мәгънәдәш булуы кызыклы (чаг. диал. *әпи* «әби; курчак»). К. Әхмәтьянов, 1981:10—11.

**ӘБРӘКӘЙ** «сточная канава» — мар. диал. *äбрäкäй* id., фарсы. *абраһа* < *аби раһа* «юынтык сулар» сүзеннән.

**ӘВӘРӘ** «занятый, увлеченный (*чем-нибудь нестоящим*) — фарсы. *ауара, awapa* «эшсез, сукбай, тик йөрүче» сүзеннән.

**ӘВӘЛӘ-Ү** «валять, скатывать» — рус. *обвалять* сүзеннән булса кирәк.

**ӘВӘС** «увлекающийся» — гар. *һәвәс* сүзеннән.

**ӘВЕН** «*овин*» — һинд-евр. тамырдан; бор. рус. *евин* «әвен», литва. *iaviena* «ашлыклы» дип хисапланылса да, Идел буе телләрендәге мисаллар бу версияне шик астына куя: чув *ăван* (< *ävin* < *awin*), мар. *awen, äүгүн, äгүн* «әвен, ау базы (западня)» < бор. кыпчак *әвүн* «ау базы», тат. диал. *әү*, бор. тк. *эв, әв, әвү* «өй, көпкә (землянка)» сүзеннән булырга мөмкин. К.Әхмәтьянов, 1991:49.

**ӘВЕРНӘ** «мотовило» — иск. тат. *әүер-* «әйләндерү» фигыленнән (шуннан ук *әверел-ү*) *-нә* аффиксы ялганып ясалган сүз (чаг. **Бирнә**).

**ӘГӘР** «если» — фарсы теленнән борынгы заманнарда ук кергән алынма сүз (к. кк., ккк. *әгәр, йәгәр* «әгәр», үзб., чыгт. *әгәр* «әгәр», венг. *akar* «әгәр»). К. **Гәрчә**.

**ӘГЕРҖЕ** «квашеное тесто; остатки теста; закваска» — монг. *эгәрчин* id. *агарча* сүзенең палаталь варианты; тамыры *әг* < *ағ* әчегән, эчелек»; шул ук тамырдан тат. *әҗекәй* << монг. *эгэҗэгэй* «кызыл эремчек». К. **Игәрче**.

**ӘДӘП** «воспитанность» — гар. *әдәб-ун* «әдәп, йола» сүзеннән, *әдүба* «әдәпле булу» тамырыннан, шуннан ук әдип, әдәби, әдәбият.

**ӘДЕП** «оторочка, кайма по вырезу рубахи; подкладка» — уйг. *әдип* «әдәп».

**ӘДЕРНӘ** «огромный лук, тетиву которой натягивает несколько человек» — н. *аьдирине*, себ. тат. *әтәрнә*, калм. *адарона* id. < борынгы һинд. *айдорона, айндра Дрона* «Дрона дигән батырның утлы ук-җәясе (аңа бу коралны Индра — сугыш алласы биргән)».

**ӘДРӘС** «адрас (*полушелковая ткань*)» — к. уйг. *әдрәс*, таж. *адрас* < һинд. adharsa «ярым ефәк».

**ӘҖӘЛ** «смертный час» — гар. *әҗәл-ун* «срок, аралык, гомер срогы» сүзеннән. Чув. диал. *ичел.* мар. *äзал*, удм. *эзель* «әҗәл» татарчадан.

**ӘҖӘТ** «долг» — гар. *хäҗәт-ун* «хаҗәт» сүзеннән.

**ӘҖЕР** «вознаграждение» — гар. *аҗр-ун* id. Шуңа тамырдаш *иҗарә* «аренда».

**ӘЗЕР** «готовый» — *хәзер* сүзеннән үзгәргән.

**ӘЗМӘВЕР** «великан» — бор. тат. *әзнәвер*, н., кб., бор. кыпчак. *азнаур* «ханны саклаучы зур гәүдәле угланнар» сүзеннән (чаг. тат. диал. *гвардин* «әзмәвер — гвардияче»). Сүзнең чыганагы — фарсы. *азнавар* «сарай әһелләреннән» термины, шуннан ул әрмән, грузин һ.б. Кавказ телләренә дә кергән (бу сүзне әрмәнчә *азнив* «асылзат» сүзеннән дип аңлату да бар (Будагов, I:37—38).

**ӘЙБӘТ** «хороший» — *һәйбәт* сүзеннән үзгәргән.



**ӘЙБЕР** «предмет, вещь» — татар теле җирлегендәге фонетик һәм семантик үзгәрешләр нәтиҗәсе буларак, *әр-бир* тезмәсеннән килеп чыккан борынгы болгар сүзе: *әр* ~ бор. тк. *әд, әҙ* «күн әшьялар», тат. диал. *бир* (чув. *пир*) ~ гом. тк. *бәз* «тукыма»; к. диал. *эрбер, эрбир* «әйбер, мар. *арвер* «өй әйберләре, киемсалым», удм. *арбери* «әйберләр».

**ӘЙЕ**. диал. *ийе, ие, әйге* «да» — кар., *эйги, эййи*, «яхшы», бор. тк. *эй, ай* «яхшы, яхшылык» сүзеннән. К. **Игелек**.

**ӘЙЛӘН-Ү** «крутиться, оборачиваться» — гом. тк. *айлан-* id. бор. тк. *айы* «ярымтүгәрәк, алка» сүзеннән; бу сүзнең үзатар («самострел») мәгънәсе булган.

**ӘЙРӘН** «айран» — гом. тк. *айран* «май язу калдыгы» сүзеннән, тамыры **аҒ* «әче, әчетке»: *аҒра-* «кымыз әчетү»; к. госм. *айран*, чув. *уйран* «май язу калдыгы», монг. *арҒан* «әйрән, май язу калдыгы», *айраҒ* «кымыз». Удм. *арьйан*, мар. *йыран* «май язу калдыгы» татар диалектларыннан. Иске тат. *әйрәтке* «кымыз әчеткесе» (Будагов). К. **Әгерҗе**.

**ӘКИЯТ** «сказка» — *хикәйәт* сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1981:203.

**ӘКӘЛӘ**: **имән әкәләсе** «желудь» — иск. тк. әд. *һәкәләк* «чиклэвек, йомырка» сүзеннән үзгәргән. Асылда — фарсы теленнән.

**ӘКӘМ-ТӨКӘМ** «улитка» — Идел-Урал өлкәсендә борынгы заманнардан бирле таралган бер модель буенча ясалган сүз; к. диал. *акы-токы* «әкәм-төкәм», башк. *укән-тукән*, удм. *окасьтукась* «әкәм-төкәм», мар. *әкән-тукән* «әкәм-төкәм» (*тукән* «мөгезле» дигән сүз); чаг. венг. *csida-bida* «әкәм-төкәм».

**ӘКӘМӘТ** «чудеса; напасти» — гар. *хәкәмәт* (*äкäмäт*) «чокыр-чакыр, тау-чагыл, чытыр-чатыр; төрле хикмәтләр» сүзеннән булса кирәк; Идел-Урал лингвистик өлкәсендә генә таралган сүз (башк., чув., мар.). К.Әхмәтьянов, 1981: 20.

**ӘКРЕН** «медленно» — *акрын* сүзеннән палатальләшеп килеп чыккан. К. **Авыр**.

**ӘЛӘК** «клевета; жалоба» — көнч. тк. һәм монг., маньчжур телләрендә киң таралган бер сүздән (тамыры ачык түгел); к. алт. *әләг*, якут. *әләк* «мыскыллау, көлү, әләк», монг. *әләг* «мыскыллау, яла», эвен. *әләк, үләк* «ялган, хәйлә, әләк, яла». Чыгт. *әлук, әлик* «мыскыл, көлү» көнчыгыш төрки телләрдән кергән булса кирәк. Чув. *элек* «әләк, бәла, яла, гайбәт» — татар теленнән.

Борынгы Болгар мәҗүсилегендә *әләк* «тәңрегә кешенең ни кылганын әйтеп торучы фәрештә»; к. мар., удм. *аляк* id. (И.П.Смирнов, А.Емельянов). К.Әхмәтьянов, 1981:20. Бу сүзне *һәләк* сүзеннән үзгәргән дип аңлату да бар.

**ӘЛӘМ** «знамя» — гар. *Ғаләм* «билге; әләм; галәм (ягъни «Алла кодрәтенең билгесе» сүзеннән. Шуннан ук *галәмәт* «билге; гаять зур».

**ӘЛӘФӘ** «льгота» — иске тат. *аләфә, Ғаләфә* «компенсация; пенсия» < гар. *әгъләфә* «сугышчыларга бирелә торган азык-төлек запасы; фураж, печән»; түбәндә «печәннәр» (*галәф* «үлән, печән» сүзеннән). Бу сүзнең мәгънә үзгәрешләрендә юмор сизелә (пенсия — «печән»).

*Әләфә* сүзеннән иске тат., кк. кум. *алафа*; *алапа* «сугышчы гаиләсенә бирелгән имтиаз, льгота» сүзе, шуннан русча *лафа* «мач килү» сүзе килә.

**ӘЛБӘТТӘ** «конечно, обязательно» — гар. *әлбәт* id сүзенә *-тә* кисәкчәсе ялганып ясалган.

**ӘЛВИДАГЪ** «прощание; прощальный, последний день ежегодного поста; песня — прощание девушки с домом, с родителями» (не плач!) — гар. *әлвидагъ* «аерылышу» сүзеннән. Чаг.- *әлфирак* «бөтенләй аерылу; кызның туган авылы белән хушлашу җыры» < *әл фирак* гар. *фарк* «аерма» > иске тат. *фәрекъ* id.

**ӘЛЕ** частица «теперь; еще; же; пока» — гар. *һалән, халән* «бу хәлдә, хәзер үк» сүзеннән үзгәреп, барча мөселман төркиләренә, татар теленнән күрше фин-угор телләренә дә таралган сүз. Шунсы кызык, чуваш телендә бу сүз гарәпчәгә якынрак яңгырашта: *халь* > *ха* id.

**ӘЛЛӘ** «не то..., не то...» — гар. *äллä* «әллә тагы, әллә, югыйсә» сүзеннән. Чув. *элле*. мар. *äлä*, удм. *ало* «әллә» татарчадан.

**ӘЛЛӘ-ЛӘ** *межд.* ой-ой — гарәп-фарсы телләре йогынтысында активлашкан ымлык булса кирәк; к. фарсы., һинд. *allalana* авырткannan кычкыру ымлыгы, гар. ällälä авырткannan кычкыру, бәләләү ымлыгы; чаг. шулай ук *әлли*.

**ӘЛЛИ-БӘЛЛИ** «баю-баюшки-баю» — типологик ымлык тамырдан; к. немец. *lall, lallen* «әлли-бәли иттерү». Мар. *али-валий*, удм. *алли-балли* id.

**ӘЛСЕРӘҮ** *хәлсерәү* формасыннан: *-сыра // -серә* кушымчасы нәрсәнең булса да житешмәвен белдергән фигыльләр ясый, мәс., *кансыра* — «кан качу». Кырг. *алсыра*, н. *әлсире-* «әлсерәү».

**ӘМАНӘТ** «залог; заложник; страхование» — гар. *амәнәт-ун* «ышаныч, ышанып тапшырылган нәрсә» сүзеннән. *Имин* сүзенә тамырдаш.

**ӘМӘЛ** «средство; выход из положения — чув. *эмел*, мар., *äмäл*, *амал* id.— төрки телләрдә киң таралган сүз; к. кум., хакас., үзб. һ.б. *амал* «юл, ысул, хәйлә». Гар. *гамәл* «эш» сүзеннән.

**ӘМЕР** «приказ, повеление» — гар. *әмр* id. Шуңа тамырдаш— *әмир*.

**ӘНӘ** «вот; тот» — (к.) **Ана II** сүзеннән палатальләшкән.

**ӘНӘЧӘ** «фигурка из теста» — к. **Элә-танак**.

**ӘНИ** «мама» — иск. тат. *анай* (*ана-й*; к. **Ана** *I*) сүзеннән үзгәреп палатальләшкән. К. диал. *анай*, удм. *анай* «әни». Чаг. алт. *эна* «ана», *энкәй* «ана, карчык».

**ӘНИС** «анисовый, анис» — киң таралган сүз (к. рус. *анис*, немец. *anis*, грек. *avicov*, лат. *anisim*). Татар теленә русчадан яки төрекчәдән кергән.

**ӘНЧЕК** «шавка» — бор. тат. *аң-чык // аң-чек* «кечкенә җанвар» сүзеннән, *аң* «ау, җәнлек, киек» тамырыннан (к. **Ау**); чаг. чув. *анчык* «эт-әнчек», алт. *аңчык* «эт, әнчек», *аңычак* «кечкенә җәнлек, кечкенә эт-әнчек», *әң, аң* «җәнлек», госм. *әнүк, әнижик*, якут. *öнүгэс*, тув. *öнöгэс* «көчек, әнчек».

**ӘҢГӘМӘ** «разговор, беседа» — < чыгт. *әңгәмә, һәнгәмә* «жы-



елыш, әңгәмә, шау-шу», кырг., уйг. *әнгимә* id.— фарсы-таж. алынмасы, *һәң, һәңгә* «тавыш» тамырыннан ясалган сүз.

**ӘР** «упрек, укор» — чув. *эр*, мар., удм. *äр, ар*; татар телендә гарәп алынмасы *гарь* нигезендә килеп чыккан. Мар., удм. *äрсыр, арсыр* бу сүзнең болгар телендә дә булганлыгын күрсәтә. *Әр*нең дериватлары бик күп: *әрлә-ү* (диал. *гарьлә-ү*), *әрле* < *гарьле, әрсез, әрләнчек* һәм алар күрше телләргә дә үтеп кергәннәр.

**ӘРӘ** «трутень» — алт., хакас., тув., кк., ккк. *ара*, уйг. *әрә, әре, әррә*, үзб. *арра*, себ. тат. *ары, аргуан* «әрә; шөпшә». Бор. төрки сүз булса кирәк.

**ӘРӘМ** «попусту, зря» — чув. *эрем*, мар., удм. *арам* — гарәп алынмасы *харам* нигезендә татар телендә килеп чыккан сүз: гомумән ул сүздән татар телендә өч сүз килеп чыккан: *харам* «грех», *хәрәм* «жульничество в игре» һәм *әрәм*.

**ӘРӘМӘ** «кустарник на лугу» — мар., удм. *äрäмä, арама*, морд. *урама*, рус. *урёма, урема* «әрәмә; тугай урманы», бор. тат. *әрәмән, урәмән* < бор. тк **ораман* «таң урманы» сүзеннән (шуннан ук *әрем* һәм *имән* < *ирмән* < **әрәмән* сүзләре дә килеп чыккан).

**ӘРДӘНӘ** «поленница» — мар., удм. *ардана, артама-* алт. *эрдине*, монг., уйг. *әрдини, эртини*, бор. тк. *әрдинә, әрдәни* «запас, хәзинә», ткм. ардана «бозауламаган килеш саудыра торган сыер», куман. *әрдән* «кызлык, кызлыклы кыз» һ.б. санскрит телендәге *rathna* «кыйммәтле таш; кыйммәтлек» сүзенә кайтып кала.

**ӘРЕКМӘН** «репейник, репей» — тат. диал. *әрекмән, әтрәкмән, әпертмән, әрәтмән, әрәсмән, әберәкмән, рахман* (бик күп вариант), мар., удм. *äрыкмäн, арыкман* «әрекмән», кырг. диал. *абдрасман* «төтәсләү ырымы өчен кулланыла торган үлән», ахыр чиктә санскрит. *барәсман* «изге эчемлек эчкәндә кулланылган үлән» сүзенә кайтып калса кирәк. К. Әхмәтьянов, 1989:102.

**ӘРЕМ** «полынь» — чув. *эрем, арӑм*, мар., удм. *äрым, арым*, венг. *üröm* бүтән телләрдә *ән* бетеме белән килә; к. себ. тат. *ирмән, әрмән*, кырг. *эрмен*, үзб. *эрман*, уйг. *әрмән*, алт. *әрбән*, бурят. *әрмн.*, кк. *ермене* «әрем, тау әреме»: *әрәмә* сүзе белән бердәй диярлек, К. **Әрәмә, урман.**

**ӘРЕПЛӘШҮ** «спорить; ссориться» — гар. *хәреп* (*хәрб*) «сугыш» сүзеннән үзгәреп татар телендә килеп чыккан. Чаг. тат. әд. *хәрби, хәраба, харап* һ.б. бер тамырдан.

**ӘРЕШ, ИРЕШ I** «охвостье» — чув. *ирեш, аврӑш*, мар. *äвра*, äрва, тат. *әрбә*, тат. диал. *әүрә, әүре, ире*, башк. диал. *әүрә, әүрәү*— Идел-Урал регионына хас агрокультура термины. К.Әхмәтьянов, 1989: 50—51.

**ӘРЕШ, ИРЕШ II** «оглобля; тормозная палка ткацкого станка; основа ткани» — иске тат., гом. кыпчак. *арыш* «тәртә» сүзеннән: төрки-монгол телләрендә киң таралган сүз, монг. *арал* «арба, тәртә» сүзе белән бәйләнеш.

**ӘРҖӘ** «короб, ящик» — мар. *аржа, арзья, öрза*, морд. *арьдзя*, чув. *арча, ырҫа* «ящик, короб», удм. *арӟа* «квадрат в ткани» — Идел-Урал регионына хас термин (кк. *әрже* «орнаментлы тартма» татар теленнән булса кирәк); гадәттә бу сүз хакас. *харачах*,

тув. *хааржак* «әржә, котый» сүзе белән чагыштырыла, ләкин бу чагыштыру фонетик законнар буенча бик үк акланмый. Чаг. ш. ук бор. тк. *әржән, аржан* Манихей динендәгеләрнең китап тартмасы (футляры).

**ӘРЛӘН** «хомяк» — мар., удм., чув. *ăрлан, арлан*, алт. *эрлэн*, кк., бор. тат. *арлан*, тат. диал., башк. *ирлән* «әрлән, ялман (сукыр тычкан); йомран — тамыры ачык түгел; чаг. көнч. тк. *үрге, öрӛ* ~ венг. *ürge* «әрлән».

**ӘРЛҮС** «перекладина» — бу диалекталь сүз болгар телендәге **арлы ивач* «аркылы агач» сүзеннән булуы белән кызыклы. К.чув. *урлаççи* «перекладина, ригель».

**ӘРМӘК** «армяк; неплотный (*о ткани*)» — чув. *әрмек*, тат. диал. *үрмәк*, бор. тк. монг. *öрмеге* «әрмәк, чикмән», чыгт., кк. *үрмек, öрмек* «тукыма, пәрәвез, чыпта» — *öр-* «үрү» сүзеннән. Тат. вариантның килеп чыгышы: *öрмек* > *үәрмәк* > *әрмәк* [ö > үә].

**ӘРНЕ-Ү** «ныть; горькое чувство» — мар. диал. *ăрны-* id. «ругаться, ссориться»; к. алт. *әренеш* «сагыш, кайгы», алт. хакас., кк., ккк., кырг. *арын-* «ару, хәлдән таю; зарлану, сыкрану» — бор. *ары-, агры* — «ачы булу» сүзеннән булса кирәк. К. **Агу**.

**ӘРЧЕ-Ү** — *арчы-у* сүзеннән палатальләшкән. К. **Арчы-у.**

**ӘСӘР** «произведение; впечатление» — һәр ике мәгънәсендә (әдәби әсәр; калдык, билге) гар. *ăсăр* «калдык билге, эшләп калдырылган эш, әсәр» сүзеннән, гар. *ăсăрă* «калдыру, тапшыру, сөйләп бирү» нигезеннән, шул ук нигездән *тәэсир*. Мар. *ăсăр* — татарчадан.

**ӘСИР** «пленный» — гар. *ăсир-ун* «әсир» сүзеннән (*ăсăрă* «плен төшү» нигезеннән).

**ӘТӘМБИ** диал. **әтәмбәй**, **әтәмбай** «хилый, болезненный; отродье, выродок» — мар. удм. *атамбей*, чув. диал. *эттемпи* «падалица; незаконорожденный», башк. *әтәлбәй, әтәрбәй* «типтәр (припущенник)» бор. тк. *артан* «бозылган, нәселсез», *арта* — «бозылу, таркалу» сүзеннән (*артаң бай* «бозык нәсел» > *әртәнбәй* > *әтәмби*). Чаг. ш. ук *әтәм-сәтәм* < *әртәң-сәртәң* «теләсә нинди (кеше)». *Бай* өлеше к. **Байтирәк**.

**ӘТӘЧ** «петух» — бор. тат. *атач* «ата хайван (кош)» сүзеннән; чаг. миш. *әтәч, әтәс* «әтәч чебеш», *әнәч* «тавык-чебеш»; к. тат. диал. *атач, атакач* «атакай; атасына охшаган», бор. тк. (МК) *атач* «атасына охшаган кеше (мал)». *Әтәч* сүзен бор. тк. *öт-*, алт. *öт-*, чув. *авăт-* «җырлау, кычкырып җырлау» сүзе белән бәйләү дөрес түгел. К. Әхмәтьянов, 1989:66.

**ӘТИ** «папа» — сөйл. *әтәй* id. *ата-й* «әти, әткәй» сүзеннән палатальләшеп үзгәргән (к. **Ата**); *әтәй* формасы *ата-кай* яки *әти-кәй* дигәннән, шулай ук бор. тк., чыгт. *әтәкә* «олы ата, абзый» сүзеннән дә килеп чыгарга мөмкин.

**ӘТРӘК**: **әтрәк-әләм** «всякий (*о людях*); сброд» — иске тат. (<гар.) *әтрәк* «төркиләр» һәм *аләм, голәм* «яллы гаскәрләр» сүзләреннән булырга тиеш.

**ӘФӘНДЕ** «господин» — госм. *әфәнди* «әфәнде, галим, дини укымышлы» сүзеннән. Урта Азиядә бу сүз бөтенләй икенче



мәгънәдә (үзб. *афанди* «тилемсә»), шуның өчен тат. *әфәнде* госманлы теленнән дип әйтеп була. Тамыры буенча бу сүз грекчадан (Кононов); грек. *avθevtnç* «мөстәкыйль кеше» яисә *Adnviad* «Афинада укыган кеше» сүзеннән.

**ӘФЛИСУН** «апельсин» — рус. *апельсин* сүзеннән, чыгышы буенча голланд теленнән (голланд. *appelsien* «кытай алмасы», *appel* «алма», *sien* «Кытай, Чин»).

**ӘФСЕН** «наговор» — фарсы. *афсун* «сихер» сүзеннән, чыгышы буенча бор. ирани сүз.

**ӘХЛАКЪ** «нравственность» — гар. *ахләк* «әхлакъ, холыклылык» сүзеннән.

**ӘҺЕЛ** «представитель» — гар. *әһл-ун* «туган, тугандаш халык, әһел» сүзеннән. К. ш. ук тат. *әһале* «әһелләр, илат».

**ӘЧЕ** «кислый, горький» — к. **Ачы**.

**ӘШӘКЕ** «плохой» — мар. *ашака*, удм. *ашаки* id. иск. тат. әд. *хәшәки* «әшәке, былчырак, түбән сортлы» сүзеннән, чыгышы — фарсы-таҗ. *хäшäки, хашаки* «әшәке, нәҗес, түбәнлекле», хашак «чүп, былчырак». К.Әхмәтьянов, 1981:117.

**ӘШНӘ** «друг; собутыльник; приятель» — фарсы. *ашна* «дус, яр, әшнә; ханым; сөяркә» сүзеннән бераз палатальләшеп килеп кергән.

## -Б-

**БАБА** «дед» — гом. тк. *баба* «баба, ата» сүзеннән, типологик ымлык тамырдан; к. бор. скиф-сармат. *Папай* «Зевс», бор. һинд-евр. *баба* «ата, баба», картвел. *баба* «баба», гар. *баба* «ата» һ.б.

**БАБАСЫР** «глисты» — төрки телләрдә гар. *буасир, бауасир* «бөсерләр, һәртөрле бөсер» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; к. үзб. *бобосир*, ткм. *бабасыл* «бабасыр». К. **Бүсер**. Удм. *бабасыр* «явыз рух, чир рухы» татар теленнән кергән сүз.

**БАБҮЛ** «малоземельный крестьянин; бобыль» — фарсы, гарәп. *бабуль* «азгын; сукбай; гаиләсез өлкән ир кеше» — асылда «Бабил (Вавилон) кешесе» дигәннән: мөселманнарда Бабил азгынлык символы булган. Рус. **бобыль** — татарчадан.

**БАВЫР** «печень — гом. тк. *бағыр* «үзәк; йөрәк; бавыр» сүзеннән (к. **Бәгырь**); *бауыр* яңгырашы кыпчак җирлегеннән үк килә (к. кк., ккк. *бауыр* «бавыр, эч, йөрәк; якын кардәш»). Бор. тк. *бағыр* «бавыр, бәгырь» сүзен *бакырдан* (бавыр бакыр төсендә була) дип аңлату да очрый. К. **Бакра**.

**БАВЫРГАЛЫК** «подбрюшник» — һичшиксез, *бавыр* сүзеннән, ләкин нинди семантик нигездә ясалганлыгы ачык түгел (к. ккк. *бауыр* «бавыр; хайван корсагы», *бауырай* < *бауырағ* «тау сырты, сырт»).

**БАВЫРСАК** «баурсак (*сдобные шарики из теста*)» — гом. тк. *баўырсақ, боғурсақ* «бавырсак, вак кына туралган ит» сүзеннән: *бауыр* (*бағыр* сүзенә *-сак* кушымчасы ялганган; к. чув. *пырша* < *пырса* «эчәк; эчәк-бавыр» < **баwырсаh*; к. кар. *бауурсак* «суелган малның эчәк-бавыры»; икенче яктан, монг. *буурцаг* «бавырсак, борчак (!)».

**БАГА**: **илче бага** «дипломат» — бор. тк. *баган* «баш рухани; милли традицияләр белгече һәм саклаучы» (шуннан — авар теленнән) венгр, серб телләрендә *бан*, чех, поляк телләрендә *пан* «кенәз; әфәнде».

**БАГАНА** «столб» — гом. тк. *бағана, бағанак, баған*, якут. *багах* «ат бәйләү өчен багана; табыну баганасы» (чаг. **Баға**). Бу сүздән (бор. фарсы теле аркылы) латин. *паган* «мәҗүсиләрнең табыну урыны; мәҗүси, кяфер» сүзе килә. Шуңа рус. *поганый* «кяфер, әшәке» сүзе тоташа.

**БАГЛА-У** «связывать (*напр., факты*)» — уйгур теле нигезендәге әдәби-язма төрки телдән. Бор. *бағ* «бау, бәй» тамырыннан ясалган (шуннан ук тат. һәм гом. кыпчак, *бау*).

**БАГУ** «ворожба» — гом. тк. *бақ-*, чув. *пых-* «багу, карау, эзләп табу» бор. *баға* «күрәзә, баш рухани» сүзе белән бәйле булса кирәк.

**БАҒЫШЛА-У** «посвятить, уст. дарить» — фарсы. *бахш, бахшиш* «бүләк, корбанлык; ришвәт» нигезеннән.

**БАҖА** «свояк» — гом. тк. *бажа* «бажа, кардәш», калм. *база, баджа* «каената, каенага, биага», алт., якут. *пажа, пәжә* апа, түти, олы кайнигәч», госм. *бажы* «олы түти» < чыгт. *абажы, абажа* «өлкән апа», бурят. *абажы, абазы* «апа, түти» безнеңчә бор. тк. *аба-ача* «апа-түти, апа-сеңел» (ягъни апалы-сеңелләрнең ирләре) сүзеннән (*ача, ажа* «кыз карендәш» сүзе күп төрки телләрдә бар, мәс., үзб. *ача* «түти», башк. *әсә* < уйг. диал. *әчә* «ана»).

Иске тат. *бажанак* > мар. *пасáна, посана*, чув. *поҫана, пуҫана*, удм. *бусенә* «бажа, көндәш» бор. тк. *бачанағ, бәчәнәг* «бер бажа, бажаларның берсе» сүзеннән (шуннан ук рус. *печенег* «борынгы төрки кабиләләрнең берсе»).

**БАЗ** «яма, погреб, углубление» — рус. диал. *баз* «көпкә, землянкә» бор. болгар теленнән, к. чув. *пуҫă, поҫă* (*пузы, позы* дип әйтелә) «баз, казылган җир» — болгар **базы* < *базыг* id., тат. диал. *бас-*, чув. *пос-, пус-* «казу» сүзеннән, ягъни *басу* сүзе белән бердәй. **К. Басу.**

Болгар телендә ике сузык арасындагы [-с-] авазы [-з-]га күчкән.

**БАЗАР** «базар, рынок» — фарсы. *базар*, бор. фарсы. *баһзар* «яшелчә базары, яшелчәлек» сүзеннән (*баһ* «яшелчә», *зар* > тат. диал. *сар* «нәрсә дә булса җыелган урын»). Күп телләргә таралган. Рус теленә татарчадан кергән дигән фикер бар.

**БАЗЫК** «кондовый, крепкий» — чув. *пусăк* «базык», *пысăк* «зур, юан» < гом. кыпчак. *базык* ~ бурят. *базаг* «базык, юан, кабарынкы, симез», бор. тк. *баз-, бад-* (*вад-*) «үсү, зураю, кабару, күперү, симерү», бор. тат., кб. *баз* «батырларның көрәш алдыннан бәхәсләшүе». Чаг. тат. диал., кб., кар. *баз-* «кыючылык итү».

**БАЙ** «бай, богач, богатый» — гом. тк. *бай* «бай, маллы; ир, герой» сүзеннән. Монгол һәм маньчжур телләрендә дә киң таралган сүз; к. якут. *буйаң* «байлык», чув. *һуйан* «бай», мар. *пайан, пойан* «бай; байлык», бурят. *байа-н* «бай, байлык», бор. уйг. *буйан* «бәхет, байлык». Санскрит теленнән кергән дип уйларга нигез бар (Малов); к. скр. *рипуа* «бәхет; байлык».



**БАЙГЫШ** «филин» — кыпчак җирлегендә *бай қуш* (*кош*) тезмәсеннән гыйбарәт; к. иск. тат. *байқуш, байғуш* «байгыш, өке», ккк. *байкус* «төн күгәрчене»; чаг. керәшен. *байгызы, бай кызы* «байгыш, өке», үзб. *бойқуш, бойуғли* «байгыш (бай улы)», чыгт. *бай қуш* «байгыш».

**БАЙРАК** «знамя» — гом. көнб. тк. *байрак* // *байдак* (> тат. диал. *байдак*) «байрак, гаскәр, приз, бәйге» сүзеннән. Бу сүзне Н.К.Дмитриев фарсы. *пийадак* «җәяүле сугышчы» сүзеннән чыгара, ләкин бу ышандырмый; к. уйг. *бодрук* «байрак», тат. диал. *байрак* «биек җир, калкулык», чув. *пуйрак* «тау-чагыл, сыза» (шуннан рус. *буерак-*), төрек. *байыр* «тау-чагыл». *Байрак* сүзенең башта гаскәр тукталган урынны (чаг. үзб. *байрок* «мәхәллә, квартал, полк») белдергән булуы ихтимал. к. **Бай-у**.

**БАЙТАЛ** «молодая неожеребившаяся кобыла» — төрки телләргә (алт., кк., ккк., үзб. *байтал* «колынсыз бия», чыгт. *пайтоқ* «байтал») монгол теленнән кергән сүз; к. монг. *байтал* «бия, байтал», *байта-саг* «ту бия яки сыер, колынлаудан, бозаулаудан туктап торган бия яки сыер — *байлда-, бай-* «туктау, туктап тору» фигыленнән ясалган сүз. Чаг. якут. *байтасын, байтасыр* «җәй буе симертелгән бия яки сыер».

**БАЙТИРӘК** «родовое священное дерево; дерево, посаженное предками, тополь, осокорь» — кырг., кк. *байтерек*, алт. *пай терек, пай қазық* (бай каен), *темир терек* (тимер тирәк) ыруның изге агачы; төрки-монгол халыкларында ыруның гербы дүрт элементтан — *байтирәк*тән, ыру кошыннан — *бай чагал*дан һәм *тамга* белән *оран*нан торган. Халык аңынча, байтирәк — башы Тимер Казык Йолдызы турысында күккә җитә, тамыры Эрлик (Эрклик) хан җир асты патшалыгында булган агач. *Бай* сүзе биредә «өлеш, бәхет» мәгънәсендә; чаг. башк. диал. *байһөйәк* «табында өлешенә тигән сөяк», кырг. *байчечек* «бәхет чәчәге» — язны күргән беренче чәчәк: ул сары булса — җәең кайгылы була, кызыл булса — җәең тук үтә.

**БАЙТАК** «довольно много» — кыпчак телләренә хас сүз. Борынгы кыпчак телләрендә *байтак* «империя, зур ил; масса» фарсы. *пайтахт* «пайтәхет, бөтен ил халкы» тезмәсеннән үзгәртелеп килеп чыккан.

**БАЙ-У** «закат; закатиться» — татар һәм башкорт телләрендә генә актив кулланыла. Төптә *байа-* булса кирәк (к. себ. тат. *пайа-* «әкренәю, тукталу; кырг. *байоо* «тукталыш урыны», иске тат. *баяу* «утрак тормыш». Тамыры бор. тк. монг. (< кытай) *бай* «күчеп килеп утыру урыны; тукталыш».

**БАКА** «лягушка» — гом. тк. *бака* «бака» сүзеннән. Бик катлаулы мәгънә үзгәрешләре кичергән бер төрки сүздән; чаг. диал. *бака* «бака, шеш, такталы чүлпы», башк. *бака* «бака, оры, шеш», тув. *бага* «күпкән корсак, бака авазына охшату сүзе («бак-бак»)», рус. диал. *бака* «ку, мәшкә, энә карагы, чикерткә» ~ коми., удм. *бака* «мәшкә, гөмбә», бор. тк. *бакка* «кырмыска», бурят. *бака* «бака; тояк арасы».

**БАКАЛТАЙ** «гавань, пристань» — к. рус. *бокалда*, эрзя. *ба-*

*калда*, чув. *пакалта*, мар. *паталца*, башк. *бакай*, рус. диал. *бакай* «елга култыгы, күләвек, тоба, камышлы күл» (монг. *бакалтай* «бака күле, култык.).

**БАКРА** «куколь» — к. чув. *пукра, похра*, мар., удм. *покро, пукро*, мукшы. *пакор* «бакра, укра» тат. бакыр (*багрый*) *чәчәк* «бакыр төсендәге чәчәкле үсемлек» сүзеннән (чаг. ш.ук рус. *багровый, багряный*). К. Әхмәтьянов, 1989:52.

**БАКРАЧ** «уполовник» — кыпчак җирлегендә *бакыр* сүзеннән ясалган сүз («*бақыр-ча* яки *бақыр-ғач*» дигәннән); к. тат. диал. *бағырча* «бакыр тас», *бақраж* «(чуен) чүлмәк», башк. *бақырса* «кечкенә чүлмәк, бакыр чәйнек», алт. диал. *пақрас* «чүлмәк», ккк. *бақыраш* «металл таба, бакрач», кк. *пакыр, бакыр*, үзб. *пақир* «металл (бакыр) чүлмәк яки чиләк»; к. шулай ук якут. *бағарак* «сөт кайнату өчен чүлмәк». Чаг. **Чуен** («металл > чүлмәк»). К. **Бакыр**.

**БАКЧА** «сад, садик; огород; бахча» — гом. кыпч. сүзе. Фарсы. *бағ* (иск. тат. әд. *бағ*) «агач бакчасы» сүзенә кечерәйткеч кушымча *-ча* ялганып ясалган сүз (*бақча < бағ + ча*).

**БАКЫР** «медь» — гом. тк. *бақыр* «бакыр, бакыр акча» сүзеннән. Бор. фарсы теленнән кергән дип хисапланыла (Йоки); чаг. монг. *бакар* «бакыр», кетт. *багыр* «бакыр». **К. Бакра**, **Бакрач**.

**БАЛ** I «мед» — төрки һәм монгол телләренә борынгы ирани (скиф) телләрдән яки санскрит теленнән кергән дип хисапланыла (Рясянен); к. кк. *бал*, монг. *бал* «бал, эчемлек бал», кар. *бат* «бал», бор. тк. *бад*; чаг. скр. *madhu* ~ рус *мёд*» бал; эчемлек.

**БАЛА** «дитя» — гом. тк. *бала* «бала, сабый, кыз» сүзеннән, асылда, борынгы һинд-евр. телләреннән алынма булса кирәк. Чаг. скр. *bāla, bālah* «яшь, кечкенә бала, малай, кызчык».

**ВАЛАБАН** «молодой орел или сокол, сокол обученный» — кк., ккк., н., кум., башк. *балабан, балапан* «яшь бөркет, яшь лачын» борынгы *палуан* «ауга өйрәтелгән лачын» сүзеннән. Борынгы кыпчакларда ауга өйрәтелгән кыргый хайваннарны *палуан, пәһлеван* дип атаганнар. Бу сүз башта өйрәтелгән аюга карата кулланылган. К. **Барабан**.

**БАЛАВЫЗ** «воск» — *бал* һәм бор. тат. *уыз* «балавыз» сүзләреннән торган кушма сүз. Бор. болгар. *уыз* /чув. *ăвăс*/< гом. тк. *оғуз* «угыз (аксымлы сөт)» сүзеннән.

**БАЛАК** «штанина» — гом. көнб. тк. *балак* «балак, балакның түбәнге ягы», бор. тк. *бакал-ак* «балтыр, сыйрак» сүзеннән; к. кырг. *бағалак* «балак, балтыр». Чаг. **Балдак**. Тамыры турында к. **Бәкәл**.

**БАЛАН** «калина» — бор. кыпч. *балан* «балан» сүзеннән (к. алт. *балан* «балан», кум., н. *балам* «аю баланы»). Чыгышы ачык түгел. Чаг. **Миләш**.

**БАЛГА** «кувалда» — н., кк., ккк., кырг., уйг., башк. һ.б. *балға, балқа* «зур чүкеч, гөрзи, хәрби балта». Борынгы шумер-аккад. *pelakku* «гөрзи» сүзеннән.

**БАЛДАК** «кольцо» — бор. тат., чыгт. *балдак* «аяк беләзеге, богауның кулга, аякка кидерелә торган боҗрасы» сүзеннән; к.



диал. (казан арты, хвалын) *балдак* «куныч, балак, кунычның иң тар урыны». Сүзнең борынгырак мәгънәсе «сыйрак», шуннан кк., ккк., себ. тат., рус. диал. *балдак, палдак* «култык таягы, таяк, тоткыч», чыгышы бор. *бақал-тақ* «сыйрак, бәкәл сөяге» сүзеннән; к. бор. язм. уйг. *пакалчақ* «сыйрак», кырг. *багалчақ* «бәкәл буыны», бор. чыгт. *багалдақ* «балдак, бәкәл, таяк»; чаг. *балак, балтыр*. Тамыры турында к. **Бәкәл**; *-дак // -так* — билгеле аффикс.

**БАЛДЫЗ** «свояченица» — бор. тат. *балдыз* «үсмер бала» (к. диал. *кыз балдыз* «балдыз», *ир балдыз* «каениш») — бор. тк. *балтар* «житлекмәгән, бала хәлендәге нәрсә» сүзеннән; к. кк., госм., үзб. *балдыз* «балдыз», чув. *пултăр, полтăр* «балдыз, хатынның энесе яки сеңлесе», *пултăр кин* «кече килен», удм. (бор. чув.) *бултыр* «беренчесе үлгәч алынган икенче хатын», бор. тк. (МК) *балдыр оғул* «үгәй ул (угыл)», *балдыр тарығ* «иртә чәчелгән иген, яшь иген», монг. *балчир* «яшь, тәҗрибәсез», бурят. *балтар* «бала», якут. *балҗыр, былчыр* «яшь бала, сабый, күкрәк баласы». Тамыры *бал(а), (к. **Балтырган**); *-тыр* кушымча. Чаг. тат. диал. *балд-, балды* «ана ягыннан кардәш» (*балдыкай, балд әби, балд бабай*).

**БАЛИТӘК** «оборка» — *бала итәк* кечкенә итәк сүзеннән; чаг. *бала елга* «кушылдык елга», *бала каз* «бәбкәлектән чыккан, ләкин үсеп житмәгән каз», *бала кычыткан* «кычытканның кечкенә яфраклы төре».

**БАЛКЫ-У** «сиять; выглядеть полным» — кыпчак җирлегендәге *балқы-* «эреп җәелү, мөлдерәү, балку, ялтырау» сүзеннән; к. кк., кырг., кум., куман. *балкы-* «эреп җәелү, балку, былкылдау», кк. *балкы-у* «эрү (*металл турында*)», ккк. *балкы-* «эрү, балку, мунчада кызыну». Татар телендәге мәгънә контаминацион характерда; чаг. диал. *балк иту* «яктырып китү, яшен яктырту», чув. *пал, палл* ут кабынуга тәкълид сүзе.

**БАЛТА** «топор» — бор. тк. *балту* «балта» сүзеннән, киң таралган тамырдан, к. гом. тк. *балта*, көнч. тк. *балту* (МК), *балду* (Зәмәхшәри); к. ш. ук чув. *порта, пурта* «балта», венг. *balta, baltu* «балта», монг. *бата* «чүкеч», эвенк. *парта* «кылыч, пычак», коми., удм. *пурт*, бор. иран. *parathu* «пычак, балта».

**БАЛТЫР** «голень» — бор. тк. *бақал-тыр* «сыйрак, бәкәл сөяге» сүзеннән (*бақал* тамыр сүзеннән; к. **Бәкәл**); к. башк., кырг., н., кк. *балтыр*, госм., азәрб., тув., ткм. *балдыр* «балтыр, сабак, курай», чыгт. *балдур* «беләзек» (чаг. **Балдак**), госм. *балтырак* «балак» (чаг. *балак*; тат. диал. *балтырат-у* балакны итектән чыгару»), *-тыр* элементы *-ты* һәм *-р* аффиксыннан; чаг. *балдыз, балтырган*.

**БАЛТЫРГАН** «борщевик» — бор. *бал-тар* «житлекмәгән тереклек; яшь үлән, бәбәк» (к. **Балдыз** < *балдыргъ*) сүзенә бор. *-ғана / -қана* кушымчасы ялганып ясалган; к. алт., тув. *палдырған* «үсемлек төбе, бер төптән үскән сабаклар төркеме, балтырган», кк. *балдырған* «яшь үлән, курпы; буыны ныгымаган бала», балдыр «су төбендә үсә торган йомшак үлән, яшь кеше, йом-

шак», бурят. *балтыргана* «балтырган, аксыргак». Төрки телләрдән бу сүз күрше фин-угор, славян, фарсы-таҗ., шулай ук кавказ телләренә дә кергән. Сүзнең тамыры эвенк., эвен. телләрендә сакланган — *балды* «үсү; тармаклану; курпылау». К. **Балдыз**.

**БАЛЧЫК** «глина» — гом. тк. *бал-чык* «сазлы, юеш урын, балчык» сүзеннән, тамыры бор. тк. *бал(а)* «сусыллык, юешлек, сулык»; к. бор. тк. *балчыҡ* «янгыр» (МК), монг. *балчиг* «саз», чув. *пычăк* «былчырак, баткак», кк. *былшыҡ* «ашка төшкән чүп», тув. *былчаҡ* «пычрак, тап, пычранган, буялган». Чаг. кк. *балҡыш* «баткак урын, баткаклык», тув. *балғаш* «баткак, саз», алт. *балкаш* «саз, баткаклык», кк. *балкат* «сазлык», тат. диал. *балката, булата* «былчырак, су катыш», кк. *балғын* «сусыл, сутлы», бор. тк. *балык* «балык, яңгыр» (МК), хакас, *палығ* «читләнеп торган яра, былчырак», алт. *палуу* «яра, чи» (шуннан бор. тк. *баш* «яра»), якут. *былык* «су китергән ләм», бурят. *балшаг* «балчык, күлләвек», эвен. *булэ* «сазлык урын»; чаг. һинд-евр. *вala, вāla* «саз, сазлык». К.**Балык, Былчырак.**

**БАЛЫК** «рыба» — гом. тк. *балык* (көнч. тк. *палык*) «балык сүзеннән, тамыры **бал(а)* «сусыллык, юешлек, сулык» булса кирәк (к.**Балчык**); к. якут. *баллыгы* «яшь шамбы», *балык* «балык, диңгез хайваны» (Пекарский). Бор. тк. *балык* «шәһәр, кала» нигездә, «балчык дивар» дигәнне белдергән.

**БАР** «есть, в наличии» — бор. тк. *ба-//бу-* «булу» фигыленең бер формасы булса кирәк (*ба-р*); к. якут. *бāр* «бар»; чаг. *бул-у*. Чаг. һинд-евр. **вheu-, вhue-, вhu-* «үсү, таралу, булу».

**БАРАБАН** «барабан» — бор. тат. *балабан* «аючылар уйнатып йөргән аю (пәһлеван), шул аюны биеткәндә уйналган быргы яки зур барабан» сүзеннән (Ж.Вәлиди); к. азәрб. *балабан* «быргы»; *Балабан* > *барабан* күчеше [*л* > *р*] татар диалектларында булуы мөмкин (чаг. *гәрәнке* < *голландка*). Сүзнең тамыры — фарсыча *пәһлеван* сүзе. К. **Балабан**.

**БАРЛАС** «крылатый барс; название древнего рода» — бор. монг. *barulas* «хәрби дәрәҗә; герой; бөркет», чыгт. *барлас, бәрләс* «герой; бөркет», якут. диал. *барылас* «канатлы барс *бар* «барс» сүзеннән.

**БАРМАК** «палец» — гом. тк. *бармак, пармак.* бор. тк. *барынак* < *барын-гак* «бармак» сүзеннән; к. тат. диал. *барнак* «бармак» >> мар. *парня*, чув. *пурна, порна* «бармак» > *пӳрне*. Тамыры *барын-, бар-ын-* «тотыну»; чаг. монг. *барих* «тоту, тотып алу, тотып тору». Чаг. ш. ук тат. диал. *барнаска* > мар. *парняш*, чув. *пӳрнеске* уймак» **барнақа* сүзеннән (бор. болгар теленнән).

**БАР-У** «идти, ехать (*направленно*)»— гом. тк. *бар-* > чув. *пыр-* id.

**БАРЧА** «весь, всё» — бор. язм. *барча* «барча, бөтенесе сүзеннән. *Бар* сүзеннән булса кирәк, ясалышы ачык түгел (ихтимал, *барыча, барынча* формаларыннан кыскарып килеп чыккандыр). **К. Бар.**

**БАРЫС** «барс» — көнч. тк. *барс, марс, бар* «барыс, каплан, юлбарыс». Фарсы теленнән бик борынгы заманнарда ук кергән, себ. тат. *илбис*, көнч. тк. *ирбис* «барыс» та шуннан.



**БАСА** «посконь» — тат., чув. уртак сүз (чув. *пусă* «баса, пәже, кысыр чәчәк»). К. **Пәже**.

**БАСА** — к. **Ләбаса**.

**БАСТЫРЫК** «слега» — кк., ккк., н., тув. *бастырык*, хакас. *пастырых*, кырг., ткм., үзб. *басырыҡ* «бастырык, бастырылу».

**БАСУ-У** «ступать, наступить» — гом. тк. *бас-* id.

**БАСУ** «поле» — бор. тк. *бас-ығ* «казылган җир» сүзеннән, *бас-у* «казу, җир эшкәртү» фигыленнән; к. диал. *бас-у* «казу», чув. *пус-* «казу, яру, казып төшү», *пусă* (пузы) «баз, кабер, кое, басуның аерым өлешләре»; чаг. якут. *баз-* «учлап яки көрәп алу». К. **Баз**.

Мар. *пасу, пасо* «басу» татар теленнән, удм. *бусы»* басу» ихтимал, чувашчадан. К.Әхмәтьянов, 1981:52.

**БАТА** «благословение» — чув. *пата*, кырг. кк. *бата* «фатиха, изге теләк». Гарәпчә *фатыйха* сүзеннән (борынгы алынма).

**БАТМАН** «кадка; батман» — гом. көнб. тк. *батман* — авырлык яки күләм үлчәү берәмлеге (ун кадак, дүрт пот һ.б.), ләкин сүзнең беренчел мәгънәсе тат. һәм башк. «бал чиләге, тар һәм биек чиләк»кә якын булса кирәк. К. бор. тк. *бат, бад, баз* «бал» һәм ирани, тк. *ман* «авырлык үлчәве, савыт»; чаг. башк. диал. (Азнагулов) *корман* «ук савыты» (*кор* «ук»); к. чув. *пасман, пасмана* «дүрт потлык авырлык үлчәве, бизмән» << себ. тат. *бәсмән* «батман»; кум. *батман*, бор. монг. *батман* «күләм үлчәме». кб. *батман* «умарта; кәрзин». К. **Бизмән**. К. Әхмәтьянов, 1989:155—157.

**БАТРАК** «батрак» — бор. тат. *батырак* «көчле, егәрле эшче» сүзеннән рус теле аша кергән (рус. *батрак* «ялчы» — татар теленнән); чаг. ккк. *бадырак* «батрак», *бадырай-* «зурлык, көчлелек ягыннан аерылып тору». Калм. *бадараг* «киң җилкәле кеше», *бада-* «юан булу»; чаг. тат. диал. *бәтрәк* «сугышчан кеше», мар. *падра* «тәбәнәк буйлы баһадир».

**БАТЫР** «герой; богатырь» — гом. тк. «*батыр*, пәһлеван» сүзеннән. К. **Баһадир**.

**БАУ** «веревка» — бор. тк. *бағ* «бау, бәй сүзеннән, тамыры бор. тк. *ба-* «бәйләү, урау, бил буу» (Зайончковский).

**БАХБАЙ** «лошадь» — ат чакыру ымлыгына (*бах*) *-бай* элементы ялганып ясалган сүз (чаг. *Сукбай, Алабай*); к. чув. *пах, паххи* «ат чакыру ымлыгы, ат» (Ашмарин). Чаг. бор. рус. *бахмат* «ат, айгыр», Кавказ телләрендә *бах* «ат, алаша». К. Әхмәтьянов, 1989:196.

**БАХЫР** «бедняга» — гар. *фәкир-ун* «фәкыйрь» сүзеннән үзгәргән; к. диал. *факыр, пакыр* «мескен, бахыр», себ.тат. *бағыр* «мескен, бичара».

**БАҺАДИР** «богатырь» — иск. тат. әд. *баһадир, баһадур* сүзе фарсы-чыгт. *баһадур, баһадир* «батыр, пәһлеван» сүзеннән килә (шуннан ук рус. *богатырь* «баһадир»), фарсы һәм чыгтай телләренә бу сүз монгол телләреннән кергән, монг. *баатур, багатур* «бик йөрәкле кеше, юлбашчы, ир-егет» (шуннан ук гом. тк. *батыр* «батыр, йөрәкле кеше»). Монгол телендә бу сүз тибет алынмасы *баһа* «герой» нигезендә ясалган. К. **Матур**.

**БАШ** «голова» — гом. тк. *баш* (*бас, паш*) «баш» сүзеннән. Тамыр бәйләнешләре ачык түгел (Севортян: **balč* > *ваз* тамырын билгели. **К. Башкар-У.**

**БАШАК** «колос» — бор. тк. *баш-ак* «үсемлек башы, башагы, ук башагы» сүзеннән, *баш* сүзенә *-ақ* кушымчасы ялганып ясалган.

**БАШБАШТАК** «самовольный» — тат., башк. сүзе, һичшиксез, *баш* сүзеннән ясалган, ләкин ясалыш нигезе һәм ясалыш юлы ачык түгел; чаг. диал. *баштак* «тәртипсез, шаян, шук», чув. *пуçтах* «җәнҗалчы, башкисәр», хакас. *пастах* «шаян, шук».

**БАШКА** «другой» — гом. көнб.тк., удм. *башқа* «башка, бүтән» сүзеннән, *баш* тамырыннан, ясалышы ачык түгел (бор. фонетик варианты **баш-ың-а* сүзе булса кирәк; к. мар. *пасна, посна*, чув. *пуçне* «башка»). Чаг. **Үзгә. К. Баш.**

**БАШКАР-У** «выполнять» — кыпчак җирлегендә ясалган *башкар-* «идарә итү, башкару» сүзеннән; к. кк., ккк. *баскар-* «идарә итү, юлбашчылык итү», чыгт. *башқар-* «хакимлек итү, идарә итү», чув. *пуçхар-* «башкару, башлау» *баш* < **балч* > *бәҗ* «баш, башлангыч» тамырыннан: чаг. тат. диал., төрек. *бәҗәр-ү* «башкару».

**БАШЛАМ** «начинание» — гом. көнб. тк., бор. язм. *башла-* «башлау, юлбашчылык итү» сүзеннән, *баш* тамырына *-ла* (фигыль ясаучы кушымча) ялганып ясалган. **К. Баш.**

**БАШЛЫЧА** «главным образом» — төрек теленнән булса кирәк; к. госм. *башлы* «иң әһәмиятле, төп», к., ккк. *баслы* «төп, иң әһәмиятле, беренче дәрәҗәдәге», госм. *башлыча, башлыҗа* «башлыча, иң беренче планда».

**БАШМАК I** «башмаки» — көнб. тк. *башмак* «башмак (аяк киеме)» сүзеннән. «Башмак тиресеннән тегелгән аякчу» дигән мәгънәдә; чаг. диал. *башантай* «кыска оек», бор. тк. *башак* «башмак (аяк киеме)», мар. *пошмак*, коми *пошмаки* «оек» (к. **Башмак** II). К. Әхмәтьянов, 1989:66—67.

**БАШМАК II** «телка» — бор. кыпч. *башмақ* «баш мал итеп каралган ике яшьлек бозау» сүзеннән. Башк. *башмақ* «башмак, башмак тиресеннән тегелгән аяк киеме», ккк. *басмақ*, «бер яшьлек бозау; күн капчык». Борынгы заманда *башмақ-* «башлангыч терлек» — кияүгә китәсе кызга бүләк итеп билгеләнгән. К. **Башмак** I.

**БАЯР** «помещик» — к. **Бояр**.

**БӘБИ**, **БӘБӘЙ** «младенец» — барлык телләрдә охшашы булган ымлык тамырдан, типологик яктан *бабай* (к.) сүзе белән тамырдаш, тк. диал. *бабай* «бәбәй, ир бала», *бәббә* «колын», бор. тк. *баббач, бабагай* «ир бала, бала, бәбәк», уйг. *бабак* «бабай, бәбәй», госм. *баба* «бәбкә, күркә, бәбәк», эвенк. *бэбэ* «бәби; бишек», болгар. *бебей* «бәби» ~ чув. *папа* «бәби», *папак, папакка* «бәби, бәбәк, күз бәбәге» (тат. диал. *бәбәгә* «күз бәбәге»), башк. *бәпес* «бәби», якут. *биәбәй, биәбәкә* «бәбкәй; чаг. венг. *вава, веве* «курчак, бәби», санскрит. *вава, вавва* «әти, бабай, бала», *вавв* «пәп» («үбү»), албан. *веве, вевве* «бәби, яңа туган бала», инглиз. *baby* (бэйби) «бәби» һ.б. К. **Бәбәк**.



**БӘБӘК** «*анат.* зрачок» — бор. тк. *бәбә-к, бә-бә-кә* «бәби, бала» сүзеннән (мәгънә күчешләре: *бала, бәби* > *бөре, бәбәк, бала, бәби* > *күз кешесе, күз «бәбие»*); к. чув. *папак* «бөре, бала, «Чиертлек» уенында фигура (таякчык)», тат. диал. *бәбәгә, бәбәнәк* «күз бәбәге, колак йомшагы», *бәбәк* «күз», чыгт., кырым. *бәбәк* «күз бәбәге, керфек», кум. *бебей* «күз бәбәге; бәби». К. **Бәби**.

**БӘБЕШ** «тапочки» — диал. *бәбеч, папыч*; төрки телләргә (кырг., кк., тк., ткм.) фарсыча *папуш* «аяк киеме» сүзеннән (*па, пай* «аяк», *пуш* «кием, каплавыч»). Чаг. **Кәләпүш**.

**БӘБКӘ I** «стропило; вид раскладки снопов» — < рус. *бабка* «әби». К.Әхмәтьянов, 1989:53.

**БӘБКӘ II каз бәбкәсе** «гусенок» — *баба // бәби* (к. **Бәби**) тамырыннан һәртөрле юллар белән килеп чыгарга мөмкин булган сүз (мәс. *бәбкә* < *бәбә-кә; бәбкә* < *бәби-кәй*).

**БӘГЫРЬ** «сердце, душа» — уйгур теленнән — гом. тк. *бағыр* «бавыр, йөрәк, эч, үзәк, күнел» сүзеннән. Киң таралган һәм төрки телләрдән башка телләргә дә күчкән сүз. К. **Бавыр, Бавырсак.** *Бағыр* «бакыр» сүзеннән (бакыр төсендәге орган) дип аңлату бар.

**БӘД** «худо» — фарсы теленнән кергән кушма сүзләрнең беренче компоненты, «начар, әшәке, кире» дигәнне белдерә: *бәдбәхет* «кире бәхетле, әшәке кеше», *бәддога* «кире дога, начарлык теләп кылынган дога», *бәдрәф* «нәҗес урыны». К. **Битәр**.

**БӘЕТ** фольк. «байт» — гар. *бәйт* «өй, оя, куплет, бәет мисрагы» сүзеннән, фонетик яктан бераз үзгәреп килеп чыккан. Татар әдәбият гыйлемендә *бәйт* «куплет, кушык».

*Бәет*нең жанр атамасы булып китүе нәүруз бәйрәмендә шәкертләрнең соңгы ел тәүлегендә авылда, мәхәлләдә булып үткән истәлекле, гыйбрәтле вакыйгаларга багышланган «Нәүруз бәетләре» язып, халыкка укып йөрү гадәтеннән килә: шуна күрә дә бәетләр «фәлән авылда, фәлән сәнәдә, фәлән вакыйгалар заһир булды» дип башлана.

**БӘЗ** «бязь» — Көнчыгыш Европа һәм Көнбатыш Азиядә киң таралган сүз (Урта Азиядә *бәз*, рус. *бязь* һ.б.); чыгышы гарәпчәдән дип хисапланыла, ләкин бор. кытайчадан да булырга мөмкин.

**БӘЙ I** *межд.* «ба» — төрки телләрдә киң таралган *бай // бәй* гаҗәпләнү ымлыгыннан; к. чув. *пай*, башк. *бәй*, кк. *бай, буй* «бәй».

**БӘЙ II** «привязь» — гом. тк. *бағ* «бау, бәй» сүзеннән (к. **Бау**); татар теле җирлегендә үзгәреп килеп чыккан (фонетик үсеше: *бағ* > *бай* > *бәй*; к. кк. *бай* «бәй», *байла-* «бәйләү»).

**БӘЙГЕ** «бега» — гом. тк. *бәйге, бәйгә, байға* «бәйрәм итү, приз, бүләк, бәйге, ярыш» сүзеннән, бор. тк. *бай*, көнч. тк., башк. *пай* «мишень, приз, ярыш» тамыр сүзеннән; к. монг., бурят. *бай* «мишень, приз, бүләк, максат».

**БӘЙНӘ-БӘЙНӘ** «подробно» — к. фарсы. *бәйн-бәйн* «бәйнәбәйнә», гар. *бәйн* «ара, бәйләнеш» (чаг. **бәйнәлмилал** «интернационал»).

**БӘЙРӘМ** «праздник» — гом. тк. *байрам* «бәйрәм, тантана» сүзеннән татар телендә палатальләшеп килеп чыккан, ясалышы буенча борынгы *багар ~ баҙар ~ баһар* «бәйрәм, шатлык» сүзенә һәм *-ам* кушымчасына кайтып кала; к. бор. тк. *баҙрам, бәҙрәм* «бәйрәм» (МК), **баграм* «бәйрәм» (бор. рус. *баграмь, багримъ* «бәйрәм» — бор. кыпчак теленнән; *улубагръ* «зур бәйрәм, олы бәйрәм» — Афанасий Никитин стилендә — билгесез чыганактан). Чаг. көнч. тк. *байыр*, монг. *байар* «бәйрәм, шатлык, тантана». Каюм Насыйри *бәйрәм* сүзен фарсыча *баһрам* «җиңү бәйрәме» сүзеннән дип бара. Чаг. шук фарсы. *бәһар* «яз, яз бәйрәме» (Заратуштра динендә). Харәзми телендә *бәйрәм айы* «бәһрам ае, язгы ай». К. Әхмәтьянов, 1989:105—106.

**БӘК** «бек» — бор. тк. *бәг, бэг* «ия, хуҗа, мирза, князь» сүзеннән, төрле фонетик филиацияләрдә төрки телләрдә һәм төрки телләрдән башка телләргә киң таралган сүз; к. чыгт., кыпч. *бәг*, госм. *бәй*, үзб. *бек* «бәк»; рус. *бек, бей* «бәк, би», гар. *бәк, бәй* «бәк, би» һ.б. төрки телләрдән. К. **Би, Бик, Бикә, Биләү, Бичә**.

**БӘКӘЛ** «щиколотка, лодыжка» — гом. тк. *бакал, бакай, бакан* «сыйрак сөяге, бәкәл сөяге, бәкәл» сүзеннән; к. башк., кк., кырг., чыгт. *бақай* «сарык сыйрагы, бәкәл, тояк»; кк. *бақы* «бәкәл сөяге», үзб. *бақалақ* «бәкәл», бор. тк., уйг. *пақалчақ* «сыйрак», кк. *бакалшақ*, чув. *пакалчак, пакӑлчак*, кум., н. *бақыншақ*, кар. *бағынчақ* «ашык бәкәл; сыйрак, тояк» госм. *бақанақ* «аеры тояк» — сүзнең тамыр бәйләнешләре ачык түгел. К. **Балак, Балдак, Балтыр.**

**БӘКЕ** «прорубь» — болгар-чуваш сүзе, чыгышы буенча бор. тк. *öкү* «бәке, кое» сүзеннән *(окү > үәке > вәке)*; к. чув. *вак, вака* «бәке», тат. диал. (пенза, сергач, касыйм) *вәке, өке, үке,* «бәке»; башк., тат. диал. *мәке* һ.б., венг. *vek* id.

**БӘЛА** «беда» — удм., мар. *бӓлӓ, бала, пяля*, мар. диал., чув. *пеле-*, гар. *бӓла* «бәла» сүзеннән.

**БӘЛӘК** «валёк» — удм. *бальак*, мар. *валяк, бӓлӓк*, чув. *валек*. Идел-Урал даирәсендә татар теленнән таралган.

**БӘЛӘКӘЙ** «маленький» — мар. *бӓлӓкӓй*, чув. диал. *пелеккей* — татар телендә *балакай* сүзеннән палатальләшеп килеп чыккан; к. тат. диал., башк. диал. *бала* «кечкенә, бәләкәй; ике нәрсәнең кечерәге».

**БӘЛҖӘ** «мотыга, тесло» — фарсы-таҗ. *бәлчә, белчә* «кечкенә көрәк, бәлҗә» сүзеннән (фарсы. *бәл, бел* «көрәк») — гом. һинд-евр. тамырыннан; татар теленә күптән кергән булырга кирәк; к. рус. диал. *белеза* «бәлҗә, кечкенә көрәк» — татарчадан(?).

**БӘЛЕШ** «балеш» — удм. *бальыш*, мар. *палыш, бӓлыш, бӓлеш*, чув. *палёш, пелёш*, рус. *беляш* < себ. тат. *бәләш* татар телендә *бәһале* аш тезмәсеннән килеп чыккан дип аңлатыла. Әмма шуңа охшаш сүзләр — ашамлык атамалары фарсы телендә дә бар.

**БӘЛЗӘМ** «бальзам» — рус теле аша грек теленнән, ә грек теленә бор. яһүди теленнән; к. яһүди *balsan, balsam* > гар. *баласан* «бәлзәм».



**БӘЛКИ** «может быть» — фарсы. *бӓлки* «бәлки» сүзеннән (бу сүз гар. *бӓл* һәм фарсы *ки* элементларыннан тора).

**БӘЛШӘЙ-Ү** «расплющиваться» — диал. *бәлчәй-у бәлч ~ балч* «җебегән, эрегән, балчыксыман» тамырыннан булса кирәк, *мәлҗерә-у* сүзе белән тамырдаш.

**БӘНДӘ** «человек; раб, слуга» — фарсы. *бӓндӓ, банда*, бор. фарсы. *банда* «кол, хезмәтче, алла колы, бәндә» сүзеннән; к. әйтем: *бәндәгә бәндә булу* «колга кол булу».

**БӘРАБӘР** «равный» — фарсы. *бӓрӓбӓр* «тигез, бериш» сүзеннән, беренчел мәгънәсе «иңгә-иң (тигез)»: фарсы. *бәр* «иң; киңлек».

**БӘРӘН** «ягненок, барашек» — күп телләрдә таралган нигездән; к. диал. *бәрәк* «бәрән, сарык, сарык бәрәне», фарсы. *бӓрӓһ* «сарык бәрәне», рус. *баран*, литва. *boranas, boran*, «сарык тәкәсе», морд. *боран*, коми. *балә* «бәрән», үзб. *барра*, таҗ. *барра* «сарык бәрәне», айсор. *баррана* «сарык тәкәсе», грекча *барион*, албанча *берр*, итальянча *бера* «сарык».

**БӘРӘҢГЕ** «картофель» — күп кенә тикшеренүчеләр бу сүзне рус теленнән алынма сүз дип карарга тырышалар, ләкин ул тулысынча монгол-төрки лексик чаралар нигезендә ясалган; к. тат. диал. *бәрәңке*, мар. диал. *буренкы*, венг. burgonya ~ бор. болгар. **бүәрәңке* < bö ränki >> чув. *пуранхӑ, паранхӑ*, «бәрәңге алмасы, бәрәңге», бурят. *боорэнхы* «йомры, шарсыман» (*бөөрэ* «бөер, төен», *бөөн* «бәйләм, төргәк»), монг. *бөгүреңкэй* «йомры; йомры бер нәрсә». К. **Бөер, Бөре, Пәрәмәч**.

*Бәрәңге* сүзен К.Насыйри фарсыча *фәрәңги* «Европаныкы (франкларныкы)» сүзеннән дип күрсәтсә, кайберәүләр русча *пареная* репа «пешкән шалкан» сүзеннән дип язалар; бәрәңге культурасы Мари Элдагы татар авылы Бәрәнгедән татарларга таралган дигән караш та бар.

**БӘРДЕ, БӘРТӘС** «язь (*рыба*)» — диал. *пәрде*, чув. *партас*, мар. *пӓрдӓш, пардаш*, фин. *partti* id., күрәсең, фин-угор телләреннән.

**БӘР-Ү** «ударить» — к. **Бир-Ү**.

**БӘРХЕТ** «бархат» — рус теленнән. Русчага немецчадан, немец теленә исә гарәпчәдән: гар.-фарсы. *бәрәгән* >> тат. диал. *бирән* «бәрхет».

**БӘРЧӘ** «мателка (*у растений*)» — чув. *перче* «бөре, үсенте», мар. *парца, парча* «бәрчә, тәлгәш» < фарсы. *барчэ, барча* «сакалчык, бәрчә» (фарсы. *бар* «сакал» ~ немец. *bart*, рус. *борода* id.).

**БӘРЧЕН** «шелковая кисточка; покрывало невесты» — гом. кыпч. барчын, мар. *парсын, порсын* > чув. *пурсӑн*, удм. *буртчин* «ефәк», рус. *брачина, абрешим* — ефәк тукыма төрләре — күп телләргә борынгы заманнарда таралган сүз: *Айбәрчен, Бәрчен сылу* — дастаннарга кергән легендар гүзәл. Сүзнең чыганагы фарсы теле дип исәпләнә, ләкин сүз составы төркичә (*-чын* кушымчасы).

**БӘС I** «иней; плесень» — гом. тк. сүз: госм., чыгт. *пас* «бәс, тут, кунык, юшкын», чув. *пас* «бәс, иртәнге сыкы», кк., ккк. *бәз* «күгәрек, мүк». Тамыр бәйләнешләре ачык түгел.

Татар-башкорт сөйләшләрендәге *бәс* «конгырт, мүк төсендәге» сүзе дә бу *бәскә* бәйле булса кирәк.

**БӘС II** книжн. «значит, следовательно» — фарсы. *бäс, бас, баст* «житәр; туктат; (дәлилләр) житәрлек» сүзеннән (аның борынгы һинд-ирани тамырлары бар).

Бу сүзгә русча *баста*! «житте, житәр!» (шуннан *забастовка*) ~ немец. һ.б. *баста* id. сүзе дә тоташа. К. **Бәсләү-ү**

**БӘСЛӘҮ-Ү** диал. «обслуживать; удовлетворять; накормить; решать спор жребием» — XIX гасыр татар телендә һәм бүтән кыпчак төрки телләрендә киң таралган сүз булган, к. башк. **бәслә-ү** «хөрмәтләү, тиешенчә хөрмәтле мөгамәләдә булу; кием-салымны һ.б. кадерләп тоту», бәсле «тәрбияле, юньле, рәтле». К. **Бәс II**.

**БӘТИ** «ягненок, барашек» — татар теленең үзендә ясалган сүз булса кирәк: беренчел яңгырашы *бәкәй* (*бәъ-кәй*, ягъни «бәәъ итүче»), фонетик үсеше *бәкәй* > *бәки* > *бәти*; к. диал. *бәки, бәкәй, бәкәч* «бәти». Чаг. рус. диал. *бяка* «сарык бәтие».

**БӘТРӘК** «драчливый; несдержанный» — сөйләшләрдә кинчә таралган бу сүзнең фарсыча өч этимоны бар: 1) *бäдраһ* «яман юлда йөрүче; тәүфикъсыз», 2) *бäдрäфт* «тәрбиясез, әдәпсез», 3) *бäдрайг* «затсыз, түбән нәселдән; явыз».

Ихтимал, рус. *батрак* > тат. *батрак* сүзе дә шуңа тоташадыр.

**БӘТЧӘ** «чадо, сын» — фарсы. *бачча* (шартлаулы [ч] ) «бала, үсмер егет» сүзеннән.

**БӘХӘС** «спор» — гар. *бәхс-ун* «бәхәс, тикшерешү» сүзеннән.

**БӘХЕТ** «счастье» — фарсы. *бäхт* «өлеш, бәхет» сүзеннән (Авеста: *вhaga, вhagada* «өлеш, бәхет»; шуннан ук рус. *бог* «алла, бәхет өләшүче алла»).

**БӘЯ** «цена» — фарсы. *бәһа* «бәя, кыйммәт, буй, үлчәм, хак» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан. Чаг. иск. әд. *бәһа* «бәя».

**БӘЯН** «изложение, объяснение» — гар. *бәйан* «ачыкланган нәрсә, аңлатма» сүзеннән.

**БЕЗ** «шило» — бор. тк. **бәгир*, **бегирг* «үткен оч, кисә, тәлә торган нәрсә» сүзеннән; к. диал. *без, биз* «пычак, пәке», себ. тат. *бес* «чалгы, пычак йөзе», алт., уйг. *бис*, госм., ткм., азәрб., кк. *биз*, үзб. *бегиз* «без, энә», чув. *парӑ* «без», монг. *бирим* «без» һ.б.; чаг. **Беләү**.

**БЕЛӘЗЕК** «браслет» — к. тув., хакас. *билзек*, якут. *билсәх*, монг. *билечег*, бор. рус. *белчугъ*, бор. тк. (МК) *билезук*, калм. *билеруг*, кырг. *билерезик* «беләзек». Нигезе *билер* «беләзек, бил-ләнеп торган урын» (к. монг. *биле* «беләзек»): *беләзек* < *биләрзәк* < *биләр-чәк*. Гар. *билезук* «беләзек» төрки телләрдән.

**БЕЛӘК** «рука (от кисти до плеча)» — гом. тк. *биләк* «кул очы, кулның түбәнге ягы» сүзеннән (кулның югарыгы өлеше мәгънәсендә татар-башкорт даирәсендә генә кулланыла), ясалышы буенча гом. тк. *бәл, бел* «гәүдәнең тарайган жире, бил» (к. **Бил**) сүзенә *-әк* кушымчасы ялганып килеп чыккан; чаг. чув. *пилек* «бил, биллек», эвенк., эвен. *билан, биләэн* «терсәк, беләк». К. **Биш**.



**БЕЛӘН** *послелог* «с, вместе» — тат. диал., башк. *ман, мән, менән, бән*, чув. *-па // -пе*, иск. тат. *берлә, берлән* һ.б. бор. тк. *бирлән* «бергә, берләшеп» сүзеннән. Бу сүзнең *илә* варианты икенчерәк мәгънәдә һәм төптә *икелән* «икәүләп» сүзеннән булса кирәк. К.Әхмәтьянов, 1983:122.

**БЕЛӘҮ** «оселок» — бор. тк. *билә-гү* «үткерләгеч, беләү, кайрак» сүзеннән килә; к. диал. *белә-ү* «үткерләү, очлау» (мәкаль: *Үтмәсне белмә, булмасны сөйләмә*), госм., чыгт., кк. һ.б. *билә-*, якут. *булә-*, алт. *пилә-* «үткерләү, кайрау»; бу фигыль, үз чиратында, бор. гом. тк. *би* «үткен оч, кискеч кырый» сүзенә *-лә* (фигыль ясагыч кушымча) ялганып ясалган (Рясянен); к. якут. *бы//би*, уйг. *би* «пычак, пычак йөзе». Чаг. **Пыч-у**.

**БЕЛ-Ү** «знать» — гом. тк. *бил* «белү, аңлау, биләү, берәр нәрсәгә ихтыярлы булу» (чаг. тат. *нишләтергә белү*) тезмәсеннән. К. **Билге**, **Бүләк**.

**БЕР** «один» — гом. тк. *бир* «бер» сүзеннән. к. **Берәм, Белән**.

**БЕРАВЫК** «некоторое время» — *бер* (к.) һәм диал. *awык* «момент, аз гына вакыт» (гарәпчәдән булса кирәк) сүзләреннән торган кушма сүз.

**БЕРӘМ-БЕРӘМ** «по одному» — татар-башкорт сүзе, чыгышы бик үк ачык түгел, *бер-лә-м* дигән сүздән (иск. *бер-лә-фигылен*нән) булса кирәк. Икенче яктан, к. диал. *икәм* «икенче», *өчәм* «өченче».

**БЕРДӘМ** «дружно, все вместе, единогласно» — төрки. *бер* < *бир* һәм фарсы. *дәм* «сулыш; момент» сүзләреннән. Бу сүз борынгыдан килә.

**БЕРЕК-Ү** «соединяться» — бор. тк. *берк-* «ныгу, кату» (*берк, бәрк* «нык, ныклы» сүзеннән; к. **Бик**) фигылен бер тамырына нисбәт итүдән килеп чыккан, К.иск. *берек* «берләшмә».

**БЕТ** «вошь» — гом. тк. бйт «бет» сүзеннән. Тамыр бәйләнешләре ачык түгел.

**БЕТӘШ-Ү** «зарастать (*о ране*)» — иск. *бет-ү, бет-ә-ү* «үсү» фигыленең уртаклык дәрәҗәсе; к. тат диал. *бетә-ү* «төзәлү, *бетәү «яра»*, төзәлүчән яра. К. гом. тк. *бит-, бут-* «үсү, бетәю; тәмамлану».

**БЕТ-Ү** «кончаться» — гом. тк. *бит-, бут-* «бетү, тәмамлану».

**БИ** «князь; вельможа» — бор. гом. тк. *бег, бәг* «ия, хужа» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан (фонетик үсеше: *бәг* > *бәй* > *би*) һәм күп кенә башка сүзләргә нигез булып хезмәт иткән: *бикә, бичә, бикәч* (к. бор. тк. *векаč* «принц»). Диал. *бием* «биана» (каенана), *би* сүзенә хатын-кыз затын белдергән *-ем* кушымчасы ялганып ясалган (чаг. *ханым*, бор. *тарым* «тархан хатыны»; татарларда туй йоласында егет ягы — *би*, кыз ягы — *хан* булып саналган).

**БИБЕК** «чибис» — шушы кошка характерлы булган авазга иярүдән килеп чыккан булса кирәк («пи-пи итүче кош»); к. монг. *бубук*, бор. чыгт. *бубиш* «һөд-һөд» (Зәмәхшәри); чаг. рус. *чибис*, венг. *бибис* «бибек».

**БИГӘНӘЙ** «чужой, чужак» переселенец из другого места» — фарсы. *беганэ, беганәи* ят, чит, «затсыз-нәселсез» сүзеннән.

**БИГӘН-Ү** диал. «ышанып өметләнү; исәп тоту; теләккә ирешү» — гом. кыпчак. *бәгән-*, *бәгин-* id. < уйг. *бәркин-* id. *бәрки* — «ныгу» сүзенең кайтым юнәлеше. Тамыры *бәрк*. К. **Бик**.

**БИДӘР** «вырезной орнамент, рисунок на украшениях» — кк., кырг., монг. *бәдәр, бәдир* ~ маньчжур. *бедери* «бизәк, кавырсын, чук, чуклы бүрек» ~ бор. тк. *бәдиз* id. К.**Бизәк**.

**БИДӘҮ** «бесплодная (женщина); арабская скаковая лошадь (которые в средних широтах оставались бесплодными)» — гом. кыпчак. *бәдәw* id. < гар. *бәдәви* «дала кешесе, күчмән», *дәду* «дала».

**БИЗӘК** «украшение» — гом. кыпчак. *бәзәк* < бор. тк. *бәдизәк* id. К. **Бидәр**.

**БИЕК** «высокий» — бор. *бәд-*, *вед-* «үсү» фигыленнән килеп чыккан (фонетик үсеше: *бәд-ук* > *бәйек* > *бийек*); к. кк., ккк. *бийик* «биек», уйг. *бәдук* «биек», *бәду-* «үсү», тув. *бедик* «биек, югарылык», *беди-* «биек булып тору, үсү», бор. язм. *бәдук, бедук* «биек».

**БИЕ-Ү** «плясать» — бор. тк. *буди-* id. *буд* «бию» (*исем*) сүзеннән.

**БИЗ** «железа» — бор. гом. тк. *берч* «тимрәү, оры, шеш» сүзеннән (фонетик үсеше: *берч* > *бәр* > *бәз* > *биз*); к. госм., чыгт. бор. язм. *бәз* «биз, шеш, сенер».

**БИЗГӘК** «лихорадка» — бор. тк. *без-* «тетрәү, калтырау» фигыленнән ясалган сүз; к. бор. язм. (МК) *без-ди* «тетрәде, калтырады», *бизгәк* «тетрәвек, бизгәк»; к. үзб. *безәңлә-* «калтырап кую», тат. *безгәлдәк* «дүдәкнең бер төре» (кош).

**БИЗМӘН** «безмен» — тат. диал. *бәзмән*, себ. тат. *пәсмән* таумари диалектында *пäсмäн* > улык мари., чув. *пасман* «бизмән»: ун кадак авырлык үлчәме (К. Әхмәтьянов, 1989:155—157). *Бизмән: бәзмән* чиратлашуы иң беренче нәүбәттә татар теленә хас булганлыктан, күрше телләрдәге *безмень, писмен* (чув.) вариантлары да татар теленнән дип уйларга нигез бар. Төньяк Кавказ телләрендә *базман, батман* «бизмән, батман, умарта» сүзе булганлыктан, *бизмән* һәм батман сүзләренең тарихи бердәйлеге шиксез дип әйтеп була. Бу сүзләрнең уртак тамыры *вад «бал» һинд-европа телләреннән булса кирәк.

*Бизмән* сүзе борынгы сәүдә юллары буйлап X—XII гасырларда ук Скандинавия илләренә һәм Германиягә кадәр таралган.

**БИЗ-Ү** «отвыкать; отучиться, отчуждаться» — гот. тк. *бәз-* id. Чаг. эвен. *бәр-* «үзгәрү, таркалу»...

**БИК** «запор, замок» — бор. тк. *бек, бәк* «ныклы» сүзеннән; к. уйг., госм., алт. *пәк, бәк, бәрк* «ныгытылган нәрсә, бик, көчле, ныклы, үтә». Шуннан ук *бик* «очень» (мәгънә күчеше: чаг. рус. *крепко* «ныклы, үтә, бик», немец. *kraftig, zu kraft* «ныклы, үтә»); к. алт., калм., монг. *бек* «ныклы; бик, йозак», н., балкар., кум., кк., ккк. *бек, берк, берик* «ныклы», үзб. *берк* «йозаклы, бикле», бор. тк., госм. *бәрк, берк* «ныклы, бикле, йозаклы», якут. *бәрәкә, бәккә* «ныклы, каты, бик (үтә)», чыгт. *бәрк-и-* «ныгу, ныгытылу».

**БИЛ** «поясница, талия» — гом.тк. *бел, бәл* «тәннең тарайган урыны» сүзеннән; к. алт. *бел* «арка, бил, умыртка», тув. *бел*, хакас. *пил* «бил, арка, тау үткеле», диал. *билдәк* «билле урын», *билдәү* «күлмәк биле», *билдәмә* «билле кабартма» һ.б. К. **Билтер**.



**БИЛГЕ** «метка; знак» — чув. *палă*, мар. *пäлы, палы*, бор. тк. *бәл-, бәйл-* «белү» фигыленнән; к. бор. *бәлгук, билгук* «стела, кабиләнең гербы, тамгасы төшерелгән багана».

**БИЛӘ-Ү** «владеть» — гом. кыпчак. *бийлә-* «биләү, идарә итү» *би* сүзеннән. *Биләм* «хождение» дә *билә* фигыленнән булса кирәк.

**БИЛЕҢ** диал. «болезненная пугливость» — *билеңлә-ү*, башк. *билеңдә-ү* «куркып сискәнү, әсәрләнеп үз-үзеңне югалту», (шуннан рус. *взбелениться* «ярсудан акылын җую» сүзе дә килә) госм. *бäлин*, н. *белең*, алт. *палин* «тәтәшләнү, ихтыярсыз чытлыклану авыруы». Тат., башк. *билтәк билентәк* < бор. тк. *бäлиңдәк* «куркып тотлыгу авыруы»; тат. диал *биләнке* «радикулит» сүзе дә *билең* һәм *бил* сүзләреннән.

**БИЛТЕР** «средняя часть стопы» — гом. тк. *бәлтир* id.; к. себ. тат. *пилтер* «ике күлне тоташтырган елга», тат. диал. *билтер* «аяк табанының асты куышланып торган өлеше, бишек сиртмәсе». К.**Бил**.

**БИЛЧӘН** «осот» — чыгышы ачык түгел; чаг. якут. *бәлчирән* «көтүлек», *бәлчи* — «көтүдә йөрү», монг. *бәлчи-*, бурят. *бәлши* «утлау». Мар. *писан, пелчән* «билчән» татар теленнән.

**БИҢЗӘ-Ү** *книжн.* «походить, быть похожим» — к. **Миң**.

**БИРӘН I** «обжора» — болгар **быйран* > чув. *пыйран* «бик күп ашаучы» сүзеннән; ясалышы буенча борынгы болгар *быйр* (тат. диал. **боғар*) «бугаз» сүзенә *-ан* кушымчасы ялганып ясалган. К.**Бугаз**.

**БИРӘН II** *диал.* «милый, хороший» — *н. берен, бәрән* «матур ат», бор. тк. *бәрән* «бәрхет, иң яхшы ефәк», фарсы. *бäрäнд* «яхшы ефәк».

**БИРГЕ, БИРКӘ** *диал.* «знак отличия, любви» — к. монг. *бирга*, калм. *бирге* «эмблема» — Г.Рамстедт фикеренчә, санскрит теленнән. Рус. *бирка* — төрки телләрдән.

**БИРЕ** «сюда» — гом. тк. *бäри, бири, бäру* «бире, бу якка» сүзеннән; ясалышы *бән-гәру // бән-гәри* (Дени) яки *бән-ру*, (Рамстедт) ягъни «миңа таба» дигәннән.

**БИРНӘ** «приданое» — чув. *парне*, мар. диал. *бирнä* ~ кар., кб. *бäркä, бирнә, берне* «бүләк, бирнә» — *бир-ү* фигыленнән ясалган булса кирәк (*-нә* — борынгы аффикс); к. *әвернә, энә* < *игнә*.

**БИРТ** — «делать зарубку; щербина» — к. **Бирчәй-ү.**

**БИРЧӘЙ-Ү** «выступать наружу» — *бирчә-й*, ягъни «бирчә булу» сүзеннән; к. тат. *бирт*, кырг. *берт*, себ. тат. *бирец*, кум. *берч*, башк. *бирсә* «биз, яра эзе», алт. *мерт-* «*бизләнү, биртелү, биртү*» — бор. тк. **бәр* «биз». К. **Биз**.

**БИР-Ү** «дать» — гом. тк. *бер, бәр*, бор. гом. тк. *бәр-* (к.якут. *биәр-* «бирү») «Бирү, бүләк итү, корбан чалу».

**БИСТӘ I** *тел бистәсе* «бойкий, речистый» — к. С.Е.Малов материалларында тат. диал. *бистә* «купец, продавец». *Тел бистәсе* «продавец слов». Чаг. **Бистә II**.

**БИСТӘ II** «пригород, слобода» — чаг. ш. ук мар. *пэстэ* «киртләнеп алынган урын» << чыгт. *бәст*, фарсы. *бäст* «йорт,

киртәләнгән урын; чит сәүдәгәрләр яши торган урын (Рясянен). К. Әхмәтьянов, 1989:129.

**БИТ I** «лицо» — бор. тк. *бет, бәт* «бит, йөз» сүзеннән. Чыгышы ачык түгел; к. госм., чыгт. *бәт*, телеут. *пәт* «бит, тышкы як, йөзлек», тк. бет «йөз», чув. *пат* ~ тат. диал. *бит* «ян».

**БИТ II** «ведь» — рус. *ведь* «бит, ич» сүзеннән.

**БИТӘР** «хуже» — фарсы. *бäдтäр, бäттäр* «начаррак, битәр» сүзеннән үзгәртелеп килеп чыккан (фарсы *бäд* «начар» *-тар* сыйфатларның артыклык дәрәҗә кушымчасы). К. ш. ук тат. диал. *битлә-ү* «яманлау». К. **Бәд**.

**БИЧӘ** «жена, супруга» — к. *бийче*, н., кк., ккк. *бийше*, башк. *бисә, бичә*. Би (к.) сүзеннән (чаг. *хан — ханча*).

**БИЧУРА** *миф.* — «домовой» диал. *мичура, пичура, мичин, мачин, мәчкәй* шул ук мәгънәдә. Бор. тк., монг. *бэч, бэчин* «маймыл» сүзеннән: *бичура* < *биччура* «маймыл баласы». Бор. *мачин* «Көньяк Кытай сүзеннән (маймыллар шуннан китерелгән). К. Әхмәтьянов, 1981:22.

**БИШ** «пять» — гом. тк. *бэш, бәш* «биш» — бор. гом. тк. **бэл* «биш» сүзеннән (к. чув. *пилĕк, пиллĕк* «биш»). Ихтимал, бор. *бэл* «беләк, кул очы» («биш бармак») сүзенең мәгънә тармаклануы нәтиҗәсе буларак янача янгыраш алгандыр (Җәләй, Баскаков). К. **Беләк**, **Бил**.

**БИШЕК** «колыбель» — гом. көнб. тк. *бәшик, бешик* «бишек» < бор. **бэлчик* > венг. *bölcsö* id. Чаг. тат., башк. *бәллү* «бишек».

**БИШМӘТ** «бешмет» — фарсы. *пешбäнд* «билле бишмәт, алъяпкыч, камзул» (*пеш* «ал як», *бäнд, банд* «бәйләнгән, буылган») сүзеннән; к. кк. *пешмент* «камзул», ккк. *бешмент* «бишмәт», кырг. *бешмант* «билле бишмәт», ткм. *бешпет, бешпәнт* «бишмәт, алъяпкыч».

**БИШТӘР** «заплечный мешок» — фарсы. *бистәр* «дәрвишләрнең һәм солдатларның аркада йөртә торган урын-ятагы» сүзеннән. Татар диалектларында күптөрле мәгънәләр алган («аркага асу җайланмасы; сөлге; тасма; төенчек; арка сумкасы»).

Рус. *пестер* (шуннан тат. диал. *пичтәр*) «биштәр» — бор. болгар теленнән.

**БИЯ** «кобыла» — гом. тк. *бийә, биэ* «бия» сүзеннән. *Бикә* сүзеннән булса кирәк. Чаг. якут. *эбигэ* «балалы хатын, колынлы бия» һәм тат. диал. *бикәч* «бәрәнле сарык, колынлы бия».

**БИЯЛӘЙ** «рукавицы» — фарсы. *бäһлäи, биһлäи* «лачынчының күн бияләе һәм күн күкрәкчәсе, күн янчык» сүзеннән, борынгы заманнарда ук төрки телләргә таралган; к. н., монг. *биэлэй*, алт. *пәләй, мәләй* «бияләй, перчатка», якут. *бәләнҗик* «аучыларның күн күкрәкчәсе яки күн бияләе» (Пекарский), чыгт. *бәһләи* «лачынчы бияләе». К. ш. ук башк., кк., кырг. *биәләй*. К. Әхмәтьянов, 1981:77—78.

**БОГАУ** «кандалы» — бор. тк. *бокағу* «тышау, богау» сүзеннән, *боғ-, буғ-* «буу, муеннан бәйләү» тамырыннан булса кирәк, К. бор.тк. *боқарсық* «богау, камыт» (Малов).

**БОГЫЛ** «стог» — символик янгырашлы *боғ-, буғ-* «түгәрәк, йомарлак» тамырына *-ыл* детерминанты ялганып ясалган булса кирәк; к. көнч. тк. *буғул*, монг. *боғол* «богыл, өем», удм. *быгыл-и* «түгәрәк, йомры, шардай», *быгыл* «богыл», коми. *бугыль* «күз алмасы», венг. *boglyo, bogol* «богыл, чүмәлә». Чаг. чув. *пух-* «җыю, өю». К. **Букча**.

**БОДАЙ** «пшеница» — гом. тк. *буғдай*, монг. *буғудай* «бодай» сүзеннән. Чыгышы ачык түгел (кытайчадан диючеләр бар). Чаг. **Борай**.

**БОЕРЧЫ** «приказной в ханской администрации» — к. чув. **пуруч* «боергы», *пӳр-* «язмышыңны билгеләү, баеклау», мар. *пуйыршо*, остяк, вогул. (ханти-манси) *пойрыхш* «язмыш алласы». *Боеру* сүзеннән.

**БОЕРЫК** «приказ» — гом. тк. *буйурук* сүзе *буйур-* «боеру» фигыленнән; *буйур-* <**буйғур-* исә бор. һәм уйг. диал. *буй-*«йөкләү, йөкләнү» фигыленнән килә. Шул ук фигыльдән башкортча *бойом* «әмер»; йомыш кушу», Башкортстандагы татар сөйләшләрендә *бойыт* «йөкләмә».

**БОҖРА** «кольцо» — килеп чыгышы бик үк ачык булмаган чуваш-татар сүзе (к. чув. *пăчăра, вăлчăра* «божра, чылбыр»). Чаг. калм. *булҗырха* «муенса; муен бизе», монг. *уулзуур* «төен, чылбыр».

**БОҖЫР** «рябчик» — бор. тк., кыпч. *буҗур* «шадра, чуар» сүзеннән булса кирәк (чаг. рус. *рябой* «шадра», *рябчик* «божыр»). К.кк., ккк. *буҗыр, боҗыр* «бик чуар, шадра», башк. *бөзөр* «су шадрасы», *быҗыр* «су өстендә дерелдек дулкыннар, шадра», кырг. *бүчүр* «шадра», тув. *бозур* «шадра», бурят. *будэяр* «тап, мин, сипкел», чаг. чув. *пăч-пăч* «тап-тап, таплы чуар» (Егоров).

**БОЗ-У** «портить» — гом. тк. *буз-* ~ монг. *буруу* «гаеп, хата»?

**БОЗ** «лед» — гом. тк. *буз* (*пуз, муз*) — бор. гом. тк. **пурғь* «боз» сүзеннән; к. чув. *пăр* «боз».

**БОЗАУ** «теленок» — гом. тк. *бузау, бузағу,* бор. гом. тк. **бурғағу* «бозау» сүзеннән; к. чув. *пăру*, монг. *буруу*, бор. монг. *бурагу, бирагу* «бозау», венг. *виги, borju* «бозау» — борынгы төрки телләрдән. Ясалышы һәм тамыр бәйләнешләре ачык түгел (төрлечә аңлатыла).

**БОЛАЙ** «этак» — *бу-лай* (к. **Бу**) дигәннән.

**БОЛАМЫК** «густая мучная болтушка» — гом. тк. *буламақ* < *булға-мақ* «болгатылган нәрсә, боламык» сүзеннән; к. кум. *буламуқ* ~ чыгт. *буламақ, буламач* ( чаг. тат. *буламач-* К.Насыйри) «боламык», кк. диал. *булғамық* «боламык», монг. *буламак* «бутка, өйрә». Чаг. госм., чыгт., уйг. *була-* «болгату» < *булга-* (к. **Болга-у**).

**БОЛАН** «олень» — гом. тк. *булаң, булан* «болан, поши» сүзеннән, ясалышы һәм чыгышы ачык түгел, кытайчадан дигән фикер бар. Чаг. буға (*булан* < *буғу-лаң?*).

**БОЛГА-У** «махать» — гом. тк. *бул-ға-* «болгау, бутау, комачаулау» сүзеннән, символик янгырашлы *бул-* «болгану, кайнау, дулкынлану» тамырыннан. Гом.тк., монг. *булға-* сүзеннән үк тат. диал. *бőла* «фетнә, кузгалыш» (чаг. башк. *бőла*, чыгт. *булғағ*, бор. тк. *булғақ* «фетнә, шау-шу», рус. диал. *булга* «тревога, паника,

шау-шу», бор. чыгт. *булға* «зур сугыш»), *боламык* (к), диал. *болгауыр* «шау-шу, тавыш», *болангыр* «томан» сүзләр килеп чыккан (J. Poppe).

**БОЛДЫР** «крыльцо» — мар. *булдыр, пулдыр, пылдыр* id., фарсы. *пули-дар* «ишегалды күпере» сүзеннән. Чув. *пӑлтӑр*, рус. диал. *булдырь* «болдыр, ишегалды» татар теленнән. К. Әхмәтьянов, 1989: 129—130.

**БОЛЫН** «луг» — бор. тк. *булуң* «елга бөгелеше, дугай» сүзеннән татар телендә аерым мәгънә алып дәвам итә булса кирәк; к. алт., хакас. *пулуң, булуң* «почмак, борын (мыс), елга култыгы»; чаг. бурят. *булың* «почмак, бөгелеш, култык», монг. *булуң* почмак».

**БОЛЫТ** «туча, облако» — гом.тк. *булут, булыт* «болыт, томан», беренчел мәгънәсе «болганган, айкалган нәрсә» сүзеннән, бор. *бул-* «айкалып болгану, болгатылу» фигыленә (*бул-* тамырыннан; к. **Болга-У**) бор. тк. *-(ы)т* фигыльләрдән исем ясагыч) аффиксы ялганып ясалган (Рамстедт); к. монг. *була-* «томанлану, болгану», *булаңыт* «томанлы, караңгы көн», якут. *былыт* «томан», бор. уйг. *булыт* «болганчыклык, караңгылык, томан», *булун-* «болгану». Чув. *пӗлӗт*, мар. *пылыт* «күк, һава» — икенчел мәгънә.

**БОРАЙ** «полба» — бор. болгар сүзе (к. чув. *пыри* «борай»); чыгышы ачык түгел (чаг. бер яктан *бодай*, икенче яктан бор. рус. *пыро* «бодай», латыш. *пури*, литва. *пурай* «көзге бодай», грек. *пурос* «бодай, бөртек», гар. *буррун* «бодай»).

**БОРАУ** «бурав» — гом. кыпч. *бурау* < *бур-гаг* «борып кертә торган нәрсә» сүзеннән (*бур-* тамырыннан; к. **Бор-у**); к. ккк. *бурау*, ткм., н. *бурау, бура*, кырг. *буроо* «бурау» (рус. *бурав* «борау» татар теленнән булса кирәк). Чаг. уйг. *бурға*, үзб. *бурғи*, госм., кырг. *бурғу*, кк. *бурғы* «борау», көнч. тк. *бурға-* «борып кертү, бору, бетерү». К. **Бурау**.

**БОРТАК** *диал.* «нехороший, грязный» — кк., кырг., кум., н. *буртақ*, хакас. *пуртақ*, бор. тк., монг., бурят., калм. *буртаг* «пычрак, әшәке», себ. тат. *пурт-* «искерү, начарлану, бурсу», монг., калм. *буру* «начар, әшәке». Чаг. **Борчы-**.

**БОР-У** «повернуть» — гом. тк. *бур-* «бору, бораулау, бөтерү» сүзеннән, символик яңгырашлы *бур* «бөтерелү, зырылдап әйләнү» тамырыннан булса кирәк. Чаг. **Бурау**.

**БОРЧАК** «горох» — гом. тк. *бурчақ* «борчак, борчак боз» < бор. тк. *буғур-чак* «шарчык, кечкенә шар» сүзеннән булса кирәк; к. монг. буурцаг «борчак, бавырсак». Чаг. **Букча**.

**БОРЧЫ-У** «беспокоить» — төрки телләрдән татар һәм башкорт телләрендә сакланган бор. тк. сүз (< *бурчы-*), бурят телендә дә очрый: *бурша-ха* «баш тарту, кирелөнү, борчылдыру, борчу»; к. шулай ук диал. *борсалан-у, борлык-у* «борчылу, күңелсезләнү», кк. *бӧрсан-, бурсан-* «ачулану, җенләнү», монг. *бори-, бури-* «бозу, борчу». К. **Боз-у**.

**БОРЫН I** «нос» — гом. тк. *бур-ун, мур-ун* «борын, танау, томшык» сүзеннән, нигездер *бур* нигезеннән; к. башк. *борғақ* ~ хакас. *пурғах* «борындык». Килеп чыгышы ачык түгел; чаг. көнч. тк., уйг. *пура-*, кырг. *бура-*, бор. тк. (МК) *бур-* «искәнү, ислөнү», монг. бур «ис, иснәү». Чаг. шулай ук **Борын II.**

**БОРЫН II** «до, прежде» — гом. тк. *бурун* «элекке, элек булган» сүзеннән, килеп чыгышы ачык түгел; чаг. хакас *пурна-* «узып китү», тув. *мурнай* «иң алдын», *мурну* «алгы як», *мурнуу* «көньяк». Чаг. **Борын** I.

**БОРЫНЧЫК** «намордник» — бор.тк. *бурунлык* «борынлык» сүзеннән булса кирәк (сонор тартыклардан соң [*л* > *д*] гадәти күренеш).

**БОРЫЧ** «перец» — төрки телләрдә киң таралган сүз; алт. *пурч, пуруч*, кк. *буруш*, чыгт. *бурч*, госм. *буруҗ* «борыч». Чыгышы буенча һинд-иран телләре сүзе булса кирәк (Абаев). Һәрхәлдә, рус. *перец* «борыч» сүзеннән түгел.

**БОТ** «бедро», ляжка» — гом. тк. *бут* «бот, аяк; бот арасы» сүзеннән, тамыр бәйләнешләре ачык түгел.

**БОТАК** «ветвь» — гом. тк. *бут-ақ* «агач кисентесе, ботак» сүзеннән, бута- «кискәләү, ботау» тамырыннан. Чаг. **Бота**, ш. ук тат. диал. **бун** «пүлән; буханка», *буна-у* «агачны кискәләү», *ботарла-у* «разорвать на части» (тат. диал., гом. тк. *бута-*, *бутар-* «кисү, кискәләү» фигыленнән интенсивлык төсмере бирә торган *-арла* кушма аффиксы ялганып ясалган сүз. Чаг. *бөг-ү* → *бөгәрлә-ү, йом-у* → *йомарла-у*).

**БОЯР** «боярин; барин» — мар. *баяр*, *паяр* «бояр», морд. *баяр* «әфәнде», азәрб. *баяр* «бояр эше» — рус. *бояр* «үз гаскәре булган эре феодал (андыйлар Петр I заманында бетерелгән)» мәгънәсеннән. Бор. рус. *бояр* < *боляр* исә Дунай болгарлары теленнән килә: бор. тк. (Дунай буенда да, ерак Орхон буйларында да булган) *бойла эр* «аерым кабиләләрнең (бор. тк. *бой* «кабилә», *эр* «ир, батыр») үзәк хакимият каршындагы вәкиле, министр».

**БӨГӘЛҖӘ** *диал.* «кольцо (*деревянное*)» — диал. *бөгәлҗә, бөгәрҗә, бөдәҗә*, чув. *пӗкече*, монг. *богэжи, богж* «түгәрәк, божра», кырг. *бӧгӧжү* «богау, тышау». Башта *боғ-, бӧг-* «буу, бәйләү» сүзеннән ясалган.

**БӨГ-Ү** «гнуть» — гом. тк. *бук-* id. Чаг. **Бөк**.

**БӨДРӘ** «кудрявый; кудри» — бор. тк. *будурағ* «бөдрә сүзеннән, тамыр бәйләнешләре һәм ясалыш нигезе ачык түгел (нииндидер *буд-* тамырыннан; чаг. *бөтер-ү*); к. кк., ккк. *буйра* «бөдрә, йон алкалары», монг. *божур, бужиир, будугур* «бөдрә», эвен. *будурука* «бөдрә», венг. *budra, budura* «бөдрә» бор. төрки телләрдән булса кирәк. Чаг. рус. *кудри*.

**БӨЕК** «великий» — госм. *бүйүк* «зур, олуг, бөек» сүзеннән.

**БӨЕР** «почка (*человека*)» — бор. тк. *бүгүр, богур* «йомры нәрсә, йомгак» сүзеннән; к. диал. *бүүер, беүер-*, чув. *пӗвӗр* «бөер», госм. *бӧгүр* «хатын-кыз күкрәге», *бӧйүр* «бөер», монг. *бӧйӧр* «бөер, бот», *бөгүр* «түгәрәк калкулык». К. **Бөерәк**.

**БӨЕРӘК, БӨЙРӘК** «почка (*животных*); пирог» — к. госм. *бӧйүрәк* «бөер», төрек. диал. *бӧврәк, бүбрәк*, ткм. *бӧрәк*, балкар.

*бүйрәк* «бөер, бөре», алт. (шор.) *пүгрек, пүгрүк,* хакас. *пүгүрүк* «бөер» һ.б. Рус *пирог* сүзе бор. төрки *пөйрәг* «бөйрәк (формасындагы) ашамлык» сүзеннән; к. н. *бөрек* «бөер, пирожок», калм. *бөөрг* «вак пәрәмәч». Сүзнең тамыры — *бөг-*. К. **Бөк, Бүрәк, Бөр-, Бөре, Бөрлегән, Бәрәңге.**

**БӨҖӘК** «насекомое» — бор.тк. *буҗгәк* «бөҗәк» (МК) сүзеннән, н. *бөжек* «коңгыз», ткм. *мөжек* «бөҗәк», кырг. *божек* «куян баласы», *божой-* «бөкчәю»; *буж-* < **бөгүч-* тамырына (фигыль?) *-гәк* кушымчасы ялганып ясалган; чаг. тат. диал. *буҗан, божан* «бөҗәк, коңгыз, шөпшә, кигәвен», *бөгәлчән* «ана кигәвен», үзб. *бугалак* «кигәвен», якут. *бүгүйәк* «бөкер, кигәвен», *бүгүләк* «шөпшә, бөҗәк» — кк. *бүгөлүк* «шөпшә». Чаг. удм. *бөчы* «коңгыз».

**БӨК** «выпуклая сторона альчика» — башк. *бөгә,* кк. *бүгө,* ккк. *пүкке,* калм. *бөкө,* рус. *бук,* коми. *пук* «бөк». Киң таралган *бөг // пөг* «йомры, түгәрәк, бүлтәймә» тамырыннан. «Ашык» уены термины буларак, башта төрки халыкларда кулланылган. Рус һәм коми телләренә төрки телләрдән кергән; *бөк-* фигыле белән тамырдаш.

**БӨКЕ** «пробка» — бор. тат. *бөк-ке* «каплавыч, бөке» сүзеннән, *бөк-* «каплау» фигыль нигезенә *-ке* (исем ясагыч кушымча) ялганып ясалган; к. алт. *бөк, пөк* «бөке, каплавыч, төрмә» (Радлов), чув. *пака* «бөке», госм. *букү, бүккү* «бөке, воронка, конус, очлы бүрек», якут. *бүө* «бөке», чыгт. *бүк-* «каплау, бөркәндерү» (Әхмәт Ясәвидә) < **бүрк-*. К. **Бүрек, Бөркү**.

**БӨКРЕ** «горбатый» — чув. *пĕкĕр,* мар. *пугыр, пукыр,* чыгт. *букри, бөгри,* үзб. *пукра* «бөкре» — бор. **букуруг / букурәг* «бөгәрләнгән» сүзеннән, тамыры *бөк-* < *бүк-*. Чаг. **Бөклә-ү, Бөктәр.**

**БӨЛДЕРМӘ, БӨЛДЕРКӘ** «петля на кнутовище» — башк. *бөлдөрмә,* кк., н. *бүлдирге,* чагат. *билдүргә,* чув. *пĕлтĕрме* «бөлдермә», монг. *бөгүлдүргә* «шнур, билбау, беләзек». Сүзнең нигезе *бөгүл* «билләнеп торган урын».

**БӨРКЕТ** «орел» — гом. тк. *бүркүт, мүркүт* «бөркет» сүзеннән; чаг. монг. *бөргүтү* «бөкре» (?)

**БӨРЕ** «почка» — бор.тк. *бүрү* < *бөгүр-үг* «бөре, бөер» сүзеннән (к. **Бөер**; *бөре ~ бөер* күчешенә килгәндә, чаг. рус. *почки* «бөре, бөер»); к. хакас. *пүр,* алт. *бүр* «бөре, чыбык, үсенте, яфрак» (~ тат. диал. *бере, бөре* «чи чыбык-чабык»), тув. *бүрү* «яфрак», алт. *бөрөк* «бөре, бөер», бор. монг. *бөгүрү* «бөре, бөер». Чаг. кырым. *бүрүм* «бөре».

**БӨРЕҖ** «одно из созвездий зодиака» — гар. *бурҗ* «бөреж, зодиак йолдызлыкларының берсе; почмак; кальга башнясы» борынгы герман телләреннән (*бург* «башня, кальга», төбендә «биек яр» — рус. *берег* белән бердәй); бу сүз гарәп теленә хәчтерүшләр (тәре йөртүчеләр) теленнән кергән булса кирәк: алар Ливанда күппочмаклы кальгалар салган булганнар.

**БӨРКҮ** «затхлый; опрыскивать» — бор. тк. *бүрк-э-г(ү)* «капланган, томаланган» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; к. алт.(телеут. шор.), *пүркү, пүркәү* «болытлы, караңгы һавалы, бөркү; одеял, бөркәнчек» (Радлов). *Бөрке-ү* фигыле икенче төрле ясалган.



**БӨРЛЕГӘН** «ежевика, костяника» — бор. тк. *бүр-лү-гән* «бөрлегән, кечкенә шар, җиләк тамыры» сүзеннән, борынгы *бөр-, бүр-* «кечкенә шар» (< *бөгүр*; чаг. **Бәрәңге, Бөер, Бөре**) тамырына төрле аффикслар( *-лү* + *-гән*) ялганып ясалган; к. бор. чыгт. *бүрлүгәч*, бор. монг. *бүрлүгән* «балан»; чаг. кк. *бүртик* «бөре, җиләк», мар. *мөр* «җиләк». К. **Бөртек**.

**БӨРТЕК** «зерно, крупинка» — бор.тк. *бүрт-үг* «кечкенә шар, бөртек» сүзеннән, *бүр-* тамырыннан (*бүр-үт-үг*; чаг. **Бөрлегән**), бор. телдә ниндидер *бүр-үт-* «бөртекләү, бөртеккә әверелдерү» фигыле булса кирәк. К. **Бөрчек**.

**БӨРЧӘ** «блоха» — ниндидер *бүр-* тамырыннан (*борча* варианты соңрак килеп чыккан); к.кк. *бүргә,* үзб. *бурга* «бөрчә, кандала», ихтимал, *бүре* (к.) сүзе белән тамырдаштыр; чаг. *корт* (к.) «бөҗәк; бүре». К.**Бүре**.

**БӨРЧЕК** «капля, крупинка» — *бөртек* (к.) сүзеннән фонетик дифференциация нигезендә аерым мәгънә алып килеп чыккан; к. кк. *бөртек* «бөрчек, бөртек», чув. *пĕрчĕк* «бөртек», тат. диал. *бөрче-ү* «бөртекләү» фигыле бор. *бөрт-е-* фигыленнән булса кирәк.

**БӨТЕН I** «цельный» — к. **Бөтен** II.

**БӨТЕН II** «все» — гом. тк. *бүтүн, бүдүн* «барлык, бөтен, тәмамланган; халык, ил» сүзеннән килә; сүзнең *бөтен* һәм *бөтен* мәгънәләре икесе ике сүздән булуы да ихтимал, ләкин төрки телләрдә аларның мәгънә һәм форма бәйләнешләре чуалган. Чаг. диал. *бөтәй-ү* «бөтенләнү, җыелу, тезелеп бетү».

**БӨТЕР-Ү** «крутить, вертеть» — татар-башкорт һәм шулардан алынып чув. һәм мар. телләрендә генә. Ихтимал, **бөртер-ү.*

**БӨТИ** «амулет, талисман» — тат. диал. бетү, бетек — чыгыш. уйг. *бүтиг. битиг* «язулы кәгазь, язу, хат, документ» бор. тк. *бүти, -бити-, бити-, пити-* «язу язмак». Шуннан ук *бетекче* < бор. уйг. *битикчи* «писер, чиновник». К. **Пичәт**.

**БӨТНЕК** «*мятник*» — «бөтнек» сүзеннән; чаг. диал. *мәте* < рус. *мята* «бөтнек үләне», чыгышы буенча латин сүзе (бөтнекнең латинча атамасы *menta, menta*), удм. *бутник* «бөтнек» — татарчадан.

**БӨЯТ** «подхомутник» — бор. тат. *бөг-әт, бүг-әт* «бөят, буып торган нәрсә, тоткарлык, комачау» бор. *буг-* «буу, комачаулау» фигыленнән, төрки телләрдә *бүг-* һәм *буг-* (к. **Буу**) фигыльләренең мәгънәдәш һәм дериватларының да күп очракта параллель булуы, аларның бер үк сүздән дифференциацияләнеп килеп чыкканлыгы турында фикергә китерә; чаг. тат. диал. *бөйә* «буа», чыгт. *бөкәт, бөкән* «буа», чув. *пӳен,* «буа, бөят», кырг., кк. бөгөт, бөгэт «буа, тоткарлык», *бөгө-, бөгә-* «тоткарлау, буу».

**БУ I** «пар, испарения» — гом. тк. *бу* < *буғу* «бу, пар, томан, төтен» сүзеннән; шул ук тамырдан татар диалектларында *буак, бугак* «бәс, сыкы» сүзе дә бар; к. чыгт., кк., ккк., үзб. *буғ* «бу, пар», алт. *буу* «пар»; чаг. фарсы *буғ, буғар* «төтен, бу, томан».

**БУ II** *мест.* «это; данный» — гом. тк. *бу, бун.* К. Севортян, 1978: 225—228. Башк. *был, бөл* < *бу ол (ул).*

**БУА** «пруд» — гом. тк. *буа* < *буғ-аг* «буа, буып торган нәрсә» сүзеннән. Чаг. **Богау**.

**БУАЗ** «стельная, жеребая» — гом. тк. *буаз, бугаз* «буаз, йөкле» — бор. тк. *буғ-ар, боғ-ар* «кабарып, төен булып торган урын» сүзеннән. К.**Бугаз**.

**БУАТ** «шестидесятилетний цикл; век»— монг. *богут* «буыннар» сүзеннән — *богун* «буын» сүзенең күплек формасы.

**БУҒА** «бугай» — гом. тк. *буға, буқа*, монг. *бука*, эвенк. *бука* «үгез, буга, ата болан яки ата поши» сүзеннән. Рус. *бугай* «буга» төрки телләрдән.

**БУГАЗ** «горло; пролив» — гом. тк. *буғаз, боғаз* «бугаз, тамак» — бор. тк. **буғ-арг, *боғарг* «кабарып, түерләнеп, йомгакланып торган нәрсә» мәгънәсендә символик яңгырашлы *буғ, боғ* «шар кебек кабарып торган нәрсә» тамырыннан; к. себ. тат. *буак, буғак* «ияк асты, бугаз», *буғыр-так, пуғыр-так* «бугаз төере, итек кунычының түбәнге өлеше», башк. *боғак* «бугаз төере», *богардак* «бугаз, сулыш юлы», тат. диал. *боғарлан-у* «бик нык ашау, тамакка тыгу», алт. *боғак* «бугаз төере», үзб., уйг., госм. *боғаз, боғуз* «бугаз, буаз, корсаклы» ~ монг. *боғар* «буаз», чув. *пыр* < **быгар* «бугаз».

Бу сүз гом. тк. *боғ-* «буу, буылдыру» сүзеннән дә ясала ала: бор. *богур-* «будыру, будырту», *богурғь* «буылып бөлтәйгән урын».

**БУГАЙ** «кажется, кажись» — иске тат. *булгай* «булырга кирәк» сүзеннән.

**БУЕНЧА** «по, согласно кому-чему» — гом.тк. *бойунча* > *бойынча* id. *бой* «буй, озынлык» < *бод* «буй; үзе» сүзеннән.

**БУЗА** «буза, хмельной напиток; скандал» — себ. тат. *буса, пуса* «закваска» < гом. тк. *бōза*, тув. *бōжа*, хакас. *пожа* «буза; сыра; тире иләү өчен әчетелгән боламык» > тат. диал. *буча* «тире иләү өчен селте һ.б.ш.» (шуннан рус. *буча* «болганыш», *бучить* «тиренe әчеткедә тоту»). Бор. монг. *бōжу*, хәзерге монг. *боз*, алт. *бōдьо* «буза; барда» бу сүзнең бор. төркилек заманнарыннан калганлыгын күрсәтә.

*Буза* сүзе бор. татар теленнән (*о* > *у* татар теле үзенчәлеге) гарәп һәм рус телләренә дә кергән һәм бөтен дөньяга таралган.

*Буза* сүзен бор. тк. *бōр* «шәраб» сүзе белән чагыштыру акланып бетми.

**БУЗАР-У** «посереть, побледнеть» < гом. тк. *бозар-* id. *Бōз* (> башк. *буз*) «аксыл-соры» ~ гом. тк. *бōр* (тат. *бур*) «бурташ» тамырыннан дип карала (Севортян).

**БУЙ** «рост: длина; основа»; — гом. тк. *бой*, бор. тк. *бод* «буй, озынлык, гәүдә озынлыгы, торык» сүзеннән, шуннан ук *бот, муен*; чаг. көнч. тк. *пой, пос*, уйг., тув. *пот* «буй, корпус, бәдән, яшь житкәнлек, жимеш төше», монг. *бода, бодо* «буй, эре, зур мал, буй, үзе» эвен. *бэй*, эвенк. *бэйэ* «кеше, ир, иркәк, тән, бәдән, үзе».

**БУЙДАК** «холостой» — бор. *буй-лақ* «буйлаган, үскән, житлеккән» сүзеннән; к. тув., уйг. *бот* «буй, үзе, берүзе, буйдак, яшь; житлеккәнлек», кк. *бойдак* «яшь бәрән; буйдак», чыгт. *бойлуқ* «буйдак»; чаг. башк. *буй аш-у*, тат. диал. *буйла-у* «тоттырмый качу» (*ат турында*).

**БУЙСЫН-У** «подчиняться» — гом. тк. *буйун сун-* «муенны (киссәң, кис дип) сону (сузу)» дигәннән; к. Әхмәт Ясәвидә: *Жилкәң ачып, дога әйләп, буйуң сунгыл*. Чаг. ш. ук тат., башк. *бойондырық* < гом. тк. *буйундуруқ* «үгез камыты (иго), буйсыну хәле». К. **Муен.**

**БУКЧА** «сумка, ранец» — бор. гом. тк. *буғ, боғ* «шарсыман кабарып торган нәрсә; төер, төен» (бу тамыр типологик характерга ия булса кирәк) сүзенә *-ча* (исем ясагыч, кечерәйтү) кушымчасы ялганып ясалган сүз; к. үзб. *бухча*, чыгт., госм. *боғча* «төен, пакет, букча», бор. язм. *боғ* «букча, бөктәр» (МК); чаг. хакас. *поғо* «муен шеше, бүтәгә», үзб., таҗ. *буғра* «муен шеше, шешенкелек», эвен. *боқат* «чикләвек», удм. *поғ* «йомарлак», коми. *буга* «тумпаеп торган нәрсә»; чаг. *богыл, бөк, бөкчәй-ү, буғаз, букән, буксә, бүктәр, борчак, бөер* — барысы да бер тамырдан.

**БУЛА** *служ. сл.* «из-за» — бор. тк. *бола-* «маташу, тырышу» сүзенең фигыль формасы. Чув. *пула*, мар. диал. *пула, була* «була, өчен» тат. теленнән. К. **Булаш-у.**

**БУЛАК** «болотный родник» — бор. тк. *булғақ* «кайнап, тынычсызланып торган нәрсә» сүзеннән, *бул-ға-* «кайнау, кайнашу» фигыленнән; к. **Болгау**; к. ккк. *булақа*, кум. *боллақ* «чишмә, булак», монг. *булаг* «булак, чишмә», *булан-* «аралашу, болгану, караңгылану, тынычсызлану».

**БУЛАТ** «сталь, булат» — фарсы. *пулад* < бор. фарсы. *polād* «корыч, булат» сүзеннән, төрки телләргә бик борынгы заманнарда ук кергән (к. якут. *болат* «кылыч), башка күп телләргә дә таралган.

**БУЛАШ-У** «связываться *с кем-л.*, заниматься *чем-л.*» — иске тат. *була-у* «маташу, ыгы-зыгы килү» фигыленнән, бор. тк., монг. *булга-, болға-* «шау-шу кубару» сүзеннән.

**БУЛДЫКЛЫ** «толковый» — сүзе борында *булдык* сүзе булганлыгын күрсәтә, мәгънәсе буенча ул сүз бор. *булдыр-ык* дигән (*бул-у* фигыленең йөкләтү юнәлеше формасына исем ясагыч *-ык* кушымчасы ялганып ясалган) сүздән килә дип уйларга мөмкин, ләкин андый сүз мәгълүм түгел, аның каравы госм. *булдуқ* «тиз табыла торган, әзер» сүзе бар, бу сүзнең тамыры *бул-у* «табу» угыз теленнән. Чаг. **Булыш-у.**

**БУЛ-У** «быть; стать» — гом. тк. *бол-*, угыз. *ол-* (иске тат. *ул-*) — бор. гом. тк. **бо-* (чаг. санскрит. *вhu-*) «булу, эшләү» тамырыннан. Моннан башка гом. тк. *бул-* «табу» фигыле дә бар.

**БУЛЫШ-У** «помогать» — *бул-у* «табу» фигыленең «әзерләү, өлгертү, табышу» мәгънәсеннән. Чув. *пулăш-* һәм *пулыш* id., мар. *полыш* «ярдәм» татар теленнән.

**БУРА** «сруб» — башлыча татар теленә хас сүз, бор. тк. *боғра-* «тиң кисәкләргә турау» сүзеннән булса кирәк. К.Әхмәтьянов, 1989:130. Чув., мар. *пура*, удм. *бугра, бугъро* «бура», рус. диал. *бугра* «көпкә» (бура өйчек, землянка)» бор. тат. теленнән; ш.ук кк. *бура*, кырг. *боро* «кечерәк келәт, бура».

**БУРА** «кружиться в воздухе» — гом.тк. *бора-, бор-* «әйләнү».

**БУРАЗНА** «борозда» рус. диал. *борозна.*

**БУРАН** «метель буран» — бор. тк. *бураган* «бурап яуган явым» сүзеннән (К.Насыйри); чаг. алт. *бураган, борогон* «буран», тув. *боран* «җилле көн», эвен. *буркун*, монг. *бороон* «буран». Тамыры — *бур, бор* «өермә».

**БУРЗАЙ** «борзая собака» — «йөгерек», «чапкыр» (эт) сүзеннән.

**БУРЛАК** «бурлак» — к. кыпч. *бурлак* «парень, холостой, молодой», мар. *пурдак* «артель, товарищество», тат. диал., башк. диал. *борлак*, безнең фикеребезчә (к. Әхмәтьянов, 1989:163), иске тат. *буралгы*, себ. тат., кк., ккк. *буралкы* «сукбай» сүзеннән. Сүзнең тамыры — *бур-* «әйләнү, әйләнеп йөрү».

Тат. *брамат, борамат* сүзе дә шул тамырдан (*боралмат?*).

**БУРСЫ-У** «преть, гнить» — мар. *порса-*, гом. кыпчак. *борсы-* «исләнү», бор. тк., монг. *бор-* «исләнү». К. **Борын.**

**БУРСЫК** «барсук» — гом. тк. *бор-сы-ғ* «исләнә торган, сасык» сүзеннән. К. **Бурсы-.**

**БУРЫЛ** «чалый» — бор.тк., көнч. тк. *бур-ыл* «аксыл-кызыл, көрән» сүзеннән, бор. тк. *бур* (< *бугур?*) «көрән, соры» сүзеннән; к. тув. *буурул* «чал, көрән-соры», монг. *буғурул* «аксыл-соры». Чаг. гом. тк. *бура* (тат. диал. *бура*), *боро* «кызгылт, көрән, аксыл-соры, көрән-соры» ~ монг. *бора, боро* «көрән-соры»; чаг. фарсы. *бур, бор* «кызгылт, чаптар», осетин. *вич, вӣч* «сары, соры».

**БУРЫЧ** «долг» — гом. тк *борч, боруч* «бурыч, бурычлы» сүзеннән; согди теленнән дип уйланыла (Севортян, 1978: 196—197); чаг. көнч. тк. *буро*, монг. *буру* «гаеп; бурыч; җәза».

**БУСАГА** «порог (*двери*)» — гом. тк. *босага*, монг. *босого*, бор. монг. *басурга*; бусага, арата» сүзеннән; сүз составында монгол-төрки морфологик элементлары бар шикелле тоелса да, сүзнең ясалышы һәм тамыры ачык түгел. Чаг. якут. *можого, модого* «бусага, тау киртләче, мич алды киртләче, кучкар».

**БУТАЛУ-У** «путаться, запутаться» — **бут* < **бот* тамырыннан (ул начар сакланган); к. хакас. *путкал, пудал* «буталу»; чаг. рус. диал. *ботать* «бутау», ← *бот* «таяк».

**БУТКА** «каша» — гом. тк. *ботка, бутка* «бутка, ярма», монг. *будаа(н)*, бор. монг. *будаган* «ярма, бутка, кыздырылган ярма, талкан» сүзеннән. Чыгышы бик үк ачык түгел, *бута-у* белән аңлату акланып бетми.

Татар язма телендә еш кына *ботка* дип язу тел культурасы кагыйдәләренә ярашып бетми (*бот-ка* сүзе белән омоним килеп чыга).

**БУШ** «пустой» — гом. тк. *бош, бос* «буш; бушак» сүзеннән, тамыр бәйләнешләре ачык түгел. К. **Бушак**.

**БУШАК** «слабо натянутый» — *буш* (к.) сүзеннән (*буш-ак*).

**БУЫН** «колено, сустав» — гом.тк. *буғ-ун* «буылган урын, буын» сүзеннән; к. бор. язм., кум., үзб. диал. *боғум* «буын», госм. *боғу*, кк. *бууг<буғ-уғ* «буын». К. **Буа**.



**БУЫНТЫК** «сустав, член» — бор. *буын-лык* сүзеннән үзгәргән булса кирәк. Чаг. *култык, юантык* һ.б.ш.

**БУЯУ** «краска» — бор. тк. *бойа-ғ*, көнч. тк. *будуғ, будук*, монг. *будуг, будаг* «буяу» сүзеннән, *буя-у* фигыленнән. Сүзнең тамыры бор. *бой* «буяу». К.Севортян, 1978:179.

**БҮГЕН** «сегодня» — *бу көн* дигәннән; төрки телләрнең күбесендә очрый.

**БҮДӘНӘ** «перепел» — гом. тк. *бодәнә, бүдинә* < *булданағ(?)* «бүдәнә, бытбылдык» сүзеннән, ясалышы ачык түгел; чаг. кк. *булда* «бөҗыр», бүдәнә», госм. *былдырчын, белдерчин* «бүдәнә», мар. (< бор. тат.) *пулдырчо* «бүдәнә, бытбылдык, тартай».

**БҮЗ I** «хлопчатобумажная ткань» — гом. тк. *бөз* «бүз, тупас мамык тукыма» сүзеннән. Тамыр бәйләнешләре ачык түгел; чаг. **Бүз II**. *Бәз* сүзе белән баглау фонетик яктан акланмый.

**БҮЗ II** «пепельный, беловато-серый» — гом. тк. *бүз, бөз* «аксыл-соры, соры, саргылт-яшел» («сары» ~ «яшел» мәгънә күчеше киң таралган) сүзеннән; к. себ. тат. *бүз* «ак, күл сыман», кк., үзб., чыгт., госм., бор. тк. *буз, боз* «соры, күл төсендәге, аксыл», бор. тк. *бор, бур* «көрән, соры» (к. **Бурыл**); чаг. бор. монг. *чаган бора* ~ чыгт. *ак боз* «акбүз» (*ат турында*), бор. тат. *бүз* (*бүз бала* «яшь бала») «яшь» түбәндәге мәгънә күчешләре нәтиҗәсе буларак килеп чыккан: *аксыл-соры > саргылт > ак кылганлы дала > дала > чирәм > болын > яшь үлән > яшь;* к. кк. *боз* «кылган, кылганлы дала», ккк. *боз, бөз* «чирәм; яшь; яшел».

**БҮЗДӘК** «полевой жаворонок» — **Бүз II** сүзеннән. Чаг. *кашкалдак, үрдәк, бизгәлдәк* — кош исемнәре.

**БҮКӘЙ, БҮКИ** «бука» (*в детском языке*) — төрки һәм башка күрше телләрдә киң таралган сүз; к. тат. диал. *мөкәй, мукай* «шайтан», алт. *мокай*, якут. *мохуй* «аю, бүки» («страшилище»); чаг. бор. тк. *букә* «аждаһа» (МК), удм. *моко* «аю, куркыныч нәрсә, бүки», рус. диал. *бука* «бүки».

**БҮКӘН** «чурбан, пенек» — *бүг // бүк* «кабарып, бүлтәеп торган нәрсә, түмгәк» тамырыннан килә (к.**Букча**); к. чув. *пукан, покан* «бүкән, йомгак, гер», *пукане* «курчак, йомгак», удм. *пукыны* «утыру», *пукон* «урындык, бүкән», монг. *богоно, богони* «тәбәнәк кеше», *бөкөн* «бөкре, бурят. *бүхэн* «бөкер». Татар теленә урындык мәгънәсендә фин-угор телләреннән кергән дигән фараз бар.

**БҮКСӘ** «живот» — гом. тк. *бөк-сә* «бүксә, корсакның аскы өлеше яки арт санның кабарынкы өлешләре» сүзеннән, *бөг // бөк* тамырыннан (к.**Букча**); к. кырг. *боқса* «тау итәге, касык, бүксә», бурят. *бухэ* «арткы як», *бүгсэ* «арт сан», монг. *бөксэ* «арт сан». К.**Бүктәр, Бүсел-ү**.

**БҮКТӘР** «узелок» — чыгт. *буктәр, бөктәр*, үзб., кырг. *букчар, боктар*, кк., ккк. *бөктэр* «ияр артына бәйләнгән йөк, төенчек» сүзеннән, *бөк* тамырыннан (к.**Бүксә**), монг., бурят. *бухэтэр* «бөкре», *бухэ* «түмгәк, йомгак», кырг. *бөктөр* «калкулык, курган»; чаг. *бөк* һәм бурят. *-тэр // -тар* — сүз ясагыч кушымча.

**БҮЛӘК I** «подарок» — бор. тк. *бәл-гүг* «бүләк, истәлек, дуслык

билгесе» сүзеннән, *бейл- «белү, истә тоту» тамырыннан (к. **Бел-ү**); к. тув., бурят. *бэлэг, бэлэк* «бүләк, күчтәнәч», алт. *пәләк*, якут. *бәләх* «бүләк, күчтәнәч, билге, корбанлык», бор. тк. (МК) *бәләк* «бүләк, күчтәнәч», *бәлгү* «билге». Фонетик яктан чаг. **Бүтән**.

**БҮЛӘК II** «земельные или охотничьи угодья; административная единица в Золотой Орде и Казанском государстве» — мар., удм. *бөляк, пөляк* «күршеләр союзы», морд. *белек* «өяз» ~ бор. тат. *бүләк* «хәрби бүлек, шуңа бирелгән җир» сүзеннән; к. төрек., кб. *бөләк* «өлеш, группа», бор. тк., монг., бурят. *бүләг, бөлүк* «отряд, рота». Тамыры — гом. тк. *бөл-* «бүлү».

**БҮЛТӘ** «округленно выпяченный» — шуннан *бүлтәй-ү*. *Бүлт* (*мүлт, мелт*) тәкълидн тамырыннан.

**БҮЛТЕРЕК** «летне-осенний ягненок» — кк., кырг. *болтурук* «яшь бүре, бүре баласы», чув. *путек* (< *бүлтәк*) «бәти, бәрән» — гом. тк., монг. *бөлә* (тат. диал. *бүлә*) «әбидәш (двоюродные)» сүзеннән; к. башк. *бүләсәр*; к. кк. *бөлешер*, бор. тат. *бүләчәр* «әбидәшләрнең балалары». *Онык, чулык, юлык* сүзләре ата ягыннан, *бүлә, бүләчәр* сүзләре ана ягыннан килгән буыннарны белдерәләр.

**БҮРӘК** «пирожок» — к. диал. *бәйрәк, бәрәк, пәрәк* «бүрәк» (кушма сүз составында *шешбүрәк, шешбәрәк, шешпәрәк* «шештә пешерелгән бүрәк, бүрәк шешлек»). Борынгы болгар. *бүәрәк, пүәрәк* < *бөөрәг* «терелек бөере» сүзеннән. К.**Бөйрәк**.

**БҮРӘНӘ** «бревно» — рус. *бревно* «бүрәнә» сүзеннән дип уйланыла, әмма бор. **буранак* (к.**Бура**) «бура өчен кисенте» сүзеннән булуы ихтимал.

**БҮРЕ** «волк» — гом. тк. *бөрө, бөрү*, бор. тк. *бөрүг* «бүре» сүзеннән, бор. ирани телләрдән алынма булса кирәк; к. осет. *bärg* ~ сак. *birgg* «бүре» (Абаев); шуннан ук к. мар. *пире* «бүре», *пириге, пирäгү* «бүре баласы», мокша. *виргас* «бүре». Рус. диал. *бирюк* «бүре» төрки телләрдән.

**БҮРЕК** «шапка» — гом. тк. *бөрк, бөрүк* «каплавыч, бүрек» сүзеннән (тамыры ачык түгел); к. алт. *бөрүк* «бүрек, бөкс», бор. тк. *бөрк, пөрүк* «бүрек, ябулык, яулык», алт. *бäргäсä* «бүрек, капкач, ябулык, такыя», *бүрүө* «тышлык, капкач, кыек», монг. *бүрх* «эшләпә», *бүрхээр* «калпак, мичкә, конус».

**БҮРТӘ** «мухортый (о масти лошади) — бор. *бугурта* «бүртә, саргылт-ак» сүзеннән; к. себ. тат. *пөртү, мөртү*, чыгт. *бөртä* «бүртә ат, йөк аты».

**БҮСЕЛ-Ү** «выпячиваться» — бор. *бөс-* «кабарту» фигыленнән.

**БҮСЕР** «геморрой; грыжа» — гар. *бawaсур* «бүсер, шеш, геморрой» сүзеннән, шуннан ук *бабасыр* (к.).

**БҮТӘКӘ** «желудок жевательный (*у птиц*)» — гом. тк. *бөтөгә*, бор. *бөлтә-кә* «кабарынкылык, шешенкелек» сүзеннән, *болт* тамырыннан (к. **Бүлтә**); к. диал. *бүтәгә, бүтәкә* «бүкән, тәбәнәк кеше, түмгәк, куак, бәбәк, яралгы, көмән, бәрән (төрле җирдә төрлечә)», чув. *пӳтек* «бәрән, бәти», *пӗте* «буаз», *пӗсехе, пӳтехе* «бүтәгә, бөер», якут. *бөтөгө* «кендек, бүтәкә», бурят. *бутэгэ* «бармак бите, колак йомшагы», *булдэгэн* «күкәй, хайван күкәе», бор. монг. *бөлдэгэн* «йомырка», *бөтэкэй* «бүтәкә».



**БҮТӘН** «другой, иной» — фарсы-таҗ. *бедун* ~ гар. *бидун* «башка, бүтән, аеруча» сүзеннән.

**БЫЛАГАЙ** «беспокойный; шумный» — монг. *булғa-ғай* «болганчыклы, ыгы-зыгылы» сүзеннән (к. **Болга-у**); к. чув. *пӑлахай*, башк. *былагай* «чытлык; лыгырдык», якут. *булағай* комачау, начарлык.

**БЫЛБЫЛ** «соловей» — гар. *бүлбүл* «былбыл, сандугач».

**БЫЛТЫР** «в прошлом году» — гом. тк. *былтыр* «былтыр» — бор. *бир йыл турур* «бер ел булыр» сүзеннән дип уйланыла (Дени).

**БЫЛЧЫРАК** «грязь» — бор. *балчыр-аг* «балчыраган, чапылдап торган» сүзеннән; к. диал. *балчырак* «балчырак, балчыклы, пычрак», ккк. *булшыра* — «ябышу». Сүзнең нигезе *былчы- / балчы-* «сыек балчык» (*балчы-р-а-к*) кайбер төрки диалектларда очрый. Сүзнең тамыры -был- // бал- «сыеклык». К. **Балдыз**.

**БЫРГЫ** «горн, охотничий рожок» — гом. тк. *бургы*, бор. чыгт. *бургуй* «быргы, труба». Киң таралган сүз: тамил. (Һиндстан) *puriya*, Малайялм. *puri*, гар. *бурийу* «быргы», бор. монг. *büriyel* сыбызгы, быргы» (шуннан рус. *бирюлька* «сыбызгы; төрепкә»). К. Әхмәтьянов, 1991: 111—112.

## -В-

**ВАЗ**: **ваз кичү** «отречение» — фарсы. *waз гузаштан* «яңадан кайту» тәгъбиреннән калькалаштырып алынган сүз (фарсы. *waз* «яңадан, тагы, ачык, шыр», *гузаштан, гаштан* «үтү», кичү»).

**ВАЕМ** «забота, беспокойство» — киң таралган (к. чув. *вай*, үзб. һ.б. *вой*), *уай* «ах, кызганыч» ымлыгыннан булса кирәк; к. диал. *вайга алмау* «гамьсез, ваемсыз булу», ккк. *увайым* «ваем, хәстәр», кырг. *убайым* «курку, хәтер», *убай* «гамь, хәстәр».

**ВАК** «мелкий» — бор. *уак* «уалган» сүзеннән; к.ш.ук *ват-у* < *уату* һ.б.; к. бор. тк. *уғак*, шор. *уфак*, алт. *оок*, бор. чыгт. *ушак*, *уфак* «вак», *ууак-түфәк* «вак-төяк». *У-у* фигыленнән. *Валчык* < *уалчык* — *уал-у* ~ *уыл-у* фигыленнән.

## -Г-

**ГАТЫРША** «духи» — гар. *'атр-ун* «ислемай» сүзе нигезенә -*ша* элементы кушылып барлыкка килгән сүз; к. чыгт., үзб. *'отир* «ислемай, гатырша».

**ГАУГА** «шум, переполох» — к. тат. диал. *гау, кауга*, кырым., кб., кум., н. *кау, кауга* «гауга, тавыш, сугыш, тревога», ткм. *ғовға*, чув. *хавха* «шатлык, дулкынлану, каударлану» (тат. диал., башк. һ.б. *қауға* «кое чиләге, барабан» бүтән сүз), фарсы. тау, гар. *ғауға* «гауга, шау-шу» сүзеннән. Әмма гарәп-фарсы сүзләре үзләре төрки телләрдән булырга мөмкин; к. кум., н. *қавла-* «рухландыру, шау-шу күтәрү», *қавлы* «шат», чув. *халхав, хавхал*

«пожар». Сүзнең тамыры — гом.тк. *қау* «кипкән үлән» (к. **Каудан, Курай**): *қау, қауға* дип элегрәк даладагы кипкән үләнне яндыру эшен атаганнар. Шуннан, бер яктан, «сугыш», икенче яктан «шатлыклы шау-шу» мәгънәләре килеп чыккан. Кипкән үләнне яндыру хәзер дә Африка саванналарында киң кулланыла. Аны төрле максатларда: далага таралган терлекләрне җыю, дошман як терлегенә азык калдырмау яки җирне ашлау һ.б. өчен эшләгәннәр. К.тат. *каулау, каугалау* «ашыктыру, куалау».

**ГӘП** «разговор» — фарсы. *гäп*, «гәп, сүз, әңгәмә» сүзеннән, *гуф-тан* «әйтү, сөйләү» фигыленнән.

**ГӘРӘБӘ** «янтарь» — фарсы. *каһ-руба* «гәрәбә; салам тартучы» (гәрәбәнең ышкылганда электрланып, вак предметларны үзенә тартуыннан чыгып әйтелгән, фарсы. *каһ* «салам», *руба* «тартучан») дип исәпләнелә. Ләкин гәрәбә Урта Азия һәм Иранга Болгарстаннан китерелгән, Болгарстанга исә аны «рус»лар (викинглар) китергәннәр, алар телендә *грива* (түбәндә «Двина тамагы») «гәрәбә» (бу сүз көнчыгыш славяннарда «муенса, анвары «акча бермлеге» мәгънәләрен алган, русча *грива, гривна* сүзләре дә шуннан). *Грива* сүзе *гәрәбәгә* безнең Болгарстанда әверелгән, фарсы-таҗиклар аны халык этимологиясе буенча гына *кәһрүбә* дип әвереләдергәннәр. Чаг. тат. диал. *герәбәнкә, гәрәнкә* «бер кадак (400 грамм)», фарсы. *гирванкә* < бор. рус. *гривенка* id.

**ГӘРӘНКӘ** «брюква» — рус. диал. *голландка* «гәрәнк, Голландия шалканы» сүзеннән (Рясянен).

**ГӘРЧӘ** «хотя» — фарсы. *агарчи, агарчанд* «әгәр, хисаплаганда, гәрчә» сүзеннән. К. иске әд. *әгәрчә* «гәрчә».

**ГӘҮДӘ** «тело, туловище» — фарсы. *гäwда* «тән, гәүдә».

**ГӘҮҺӘР** «жемчуг» — фарсы. *гäwhäр* «эссенция, асыл табигать, кыйммәтле состав өлеш» сүзеннән, шуннан ук к. **Җәүһәр**.

**ГЕЛ** «все, всегда» — гар. *кулл* «тулы, бөтен» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; к. диал. *гөлле, көлле* «барлык, бөтенесе», *гелән, гүллән* «гел, барысы да» (гар. *кулл-ән* формасыннан); к.ш. ук кк., ккк., үзб., уйг., ткм. *күлли* «бөтенесе». Шулай итеп, *гел* сүзе татар телендә ясалган. Чув. *кĕл*, мар., удм. *гыль* «гел» — татарчадан.

**ГЕР** «гиря» — рус. *гиря* «гер» сүзеннән; рус. *гиря* исә фарсы теленнән дип санала. Ләкин себ. тат. *кыйрә* «авырлык, гер» турыдан-туры фарсычадан.

**ГЕРДӘ** «ритуальная маленькая булочка» — фарсыча гирда «түгәрәк» сүзеннән. *Гердә* кырык «күзгә күренмәс изгеләр» өчен кырык данә пешерелгән.

**ГИДАЙ** «бедняк, немущий» — фарсы. *гидаи* «ярлы кеше», *гида* «ярлы».

**ГИЗ-Ү** «изъездить, обходить, побывать (*в определенных местах*)» — төрек теленнән алынган (госм. *гэз, гиз-* id); к. бор. тк. *кэз-* (чув. *кас-*) «гизү; капкыннарны карап чыгу» — якут. *кэрии* id.

**ГОМЕР** «жизнь, жизненный путь»,— диал. «век» < гар. *ғумр* «яшәү» ~ «Яшәеш, яшәү» тамырыннан; шуннан ук *гыймарәт* «зур торак бина; яшәү рәвеше; яшәү кирәге; табигый гомер (ул 120 ел дип исәпләнгән)» — бу сүз төрки телләрдә «гасыр» мәгънәсен алган. Чаг. мар. диал. *ымырет, ӓмырет* «озын гомер», «бөркет (йөзьяшәр кош)».

**ГӨБӘДИЯ** «губадия» — диал. *гөлбәдия*, фарсы. гүли-бәдиһә — роза гөленең бер төре. *Гөбәдия* шуңа охшатып пешерелгән ашамлык. Чаг. диал. *гөлбәнәк* — розага охшашлы ашамлык, фарсы. *гулибäнäк* «букет».

**ГӨБЕ** «маслобойка» — гом. көнб. тк. *көп-үг* «гөбе, цилиндр, көпшә» сүзеннән, *кәб/көб* «эче куыш агач» тамырыннан (к.**Күбәк**); к.диал. *гәбе, гүбе* «гөбе, биек һәм тар агач чиләк», үзб. *гуппи, куппи* «киле, гөбе», венг. *köpü* «гөбе» (бор.тк. телләрдән).

**ГӨБЕРЛЕ**: **гөберле бака** «жаба» — к. башк. *гөбәргәйел*, н. һ.б. *кубурткөйә*, кырг. *күбүргөлүү бака* «ташбака». Сүзнең нигезе *гөбер (гөбәр), гөберкә* «формасыз кабарынкылык»; чаг. диалекталь *гөберле шәл* «кабарынкы бизәкле шәл».

**ГӨЛ** «цветок, цветы» — фарсы. *гул* «гөл, чәчәк» сүзеннән, шул ук тамырдан һәм шулай ук фарсы теленнән *гөләндәм* «гөл гәүдәле», *гөләп* «су гөле», «ак чәчәк», *гөлбадран* «ай гөл» һ.б. сүзләр алынган. К.**Гөбәдия**.

**ГӨМБӘ** «гриб» — Көнчыгыш Европада киң таралган символик янгырашлы тамыр сүз: рус. *губа, гунба* «гөмбә, буа болыты», коми. *гоб* «гөмбә», венг. *gomв* «шар», талыш. *гобалай* «гөмбә»; чаг. монг. *бумба* «шарсыман нәрсә, шар, бомба», санскрит. *витвul* «шарсыман нәрсә».

**ГӨМБӘЗ** «купол» — фарсы. *гунбаз* «гөмбәз, каланча» сүзеннән.

**ГӨНАҺ** «грех» — фарсы. *гунаһ* «бурыч, гаеп, җинаять» сүзеннән. Тамыры бор. иран *nāš* «гаеп, явызлык; хата, ялгыш».

**ГӨРЗИ** «боевая палица» — фарсы. *гурз, гурзи* «гөрзи, чукмар» сүзеннән.

**ГРИФТАР** «обреченный» — фарсы. *гирифтар* «тарыган, очраган, эләктерелгән» сүзеннән, *гриф-тан* «тоту, эләктерү» тамырыннан.

**ГУАҺ** «свидетель» — фар. гуаһ «белүче, шаһит» сүзеннән.

**ГҮЗӘЛ** «прекрасный» — госм. *гузал, күзал* «гүзәл, матур, күркәм» сүзеннән, *күз- // күр-* тамырыннан (к. **Күр-ү**) дип санала.

**ГҮР** «могила» — фарсы. *гур* «гүр, кабер».

# -Д-

**ДА** к. **Та**.

**ДАВЫЛ** «буря» — гом. тк. *тawыл, таб-ул* «давыл, буран, җил, шау-шу, тавыш» сүзеннән, бор. *таб* «җил-буран, ыгызыгы; барабан кагу» тамырыннан; к. алт. *дуул*, куман., кб. *тавул*, якут. *тыал*, чув. *тывӑл* «давыл, буран, җил», тув. *дывыла-* «дулау, шаулау», монг. *дуула-х* «җырлау», бурят. *дуун* «тавыш, җыр»; чаг. **Дула-у.** К.**Тавыш**.

Сүзнең икенче төрле этимологиясе гарәп-фарсы телләрендәге *табл, табул, давул* «дошман явы килгәндә зур сугыш ал-

дыннан кагыла торган гаять зур барабан» сүзе белән бәйләнә. Бу сүз исә борынгы шумер-аккад. телендәге *таббалу* «зур сугыш барабаны» сүзенә кайтып кала.

Тат. диал. *тип*, үзб. диал., ткм. *дәп, дап* һ.б. (бик күп телләрдә бар) «барабан» сүзе дә гарәпчә *табл* сүзеннән кыскарган булса кирәк. К.Әхмәтьянов, 1989:5.

**ДАГА** «подкова» — гом. тк. *тага, така* < *так-каг // таңкаг «дага, олтан, табан, аякча» *так-* «тагу» һәм *таган* (к.) сүзләре белән тамырдаш булса кирәк; к. алт., шор. *такка* «олтанга тегелгән күн», чыгт. *такау, такагу* «дага», хак, *таха* «олтан», якут. *тага* «чүлмәкнең аякчалары, дага» < *та-ка* «дага», чув., мар. *таган, такан* «үкчә, олтан, дага», монг. *тах*, бурят. *таха* «дага, чана табанының алгы өлеше».

**ДАИМ** «всегда, постоянно» — гар. *даим* «даим, озак бер вакыт» сүзеннән, шуннан ук *даими*.

**ДАИРӘ** «круг; круги, общество» — гар. *даирә-т-ун* «даирә, әйләнә-тирә» сүзеннән. Шуннан ук иске тат. *диар* «өлкә».

**ДАЛА** «степь» — гом. тк. *тала, дала* «дала, бер як, бер кырый, яссылык» сүзеннән; чаг. госм., чыгт. *дал* «арка, иң, ялангач, шома, урта», бурят. *дала* «калак сөяге». Чаг. скр. *tala* «яссылык, уч табаны».

**ДАН** «слава» — көнб. тк. *дан, даң* «дан» сүзеннән, чыгышы ачык түгел (төрлечә аңлатыла). Безнеңчә, ул *таң алласы* белән баглы. К. **Таң калу, Тансык**.

**ДАНӘ** «штука» — фарсы. *данә* «бөртек, төш, данә» сүзеннән.

**ДАР** «виселица» — фарсы. *дар* «дар агачы, дар баганасы» сүзеннән (беренчел мәгънәсе «агач, багана», рус. *дерево* «агач» сүзе белән тамырдаш).

**ДАРУ** «лекарство» — фарсы. *дару* «дару, им» сүзеннән.

**ДАРЫ** «порох» — фарсы. *дару* «дару» сүзеннән (Санжеев); к. монг. *дар* «дары»; чаг. ягноб., таҗ. *даруи-мылтык* «дары (мылтык даруы)». Чаг. рус. *ружейное зелье* «мылтык даруы» — дары.

**ДАУ** «скандал» — гар. *дәгъwа* «дәгъва, дау» сүзеннән дип хисапланыла (Радлов, Абаев); к. госм. *дау*, кк. *dawa*.

*Дауның дәгъвадан* килеп чыкканлыгына мар. *тавала* «дәгъвалау, даулау» сүзе дә дәлил.

**ДАЯ** «кормилица» — фарсы. *дайа, дайә* «дая, бала караучы, аристократ хатыннарның баласын имезүче хатын» сүзеннән, тат. диал. *дайә* «бишек сиртмәсе» — күчерелмә мәгънәдә.

**ДӘВЕР** «век, эпоха» — гар. *даур-ун* «дәвер, период» — *даура* «әйләнү» тамырыннан.

**ДӘГЪВА** «претензия» — гар. *дәгwа-т-ун* «дәгъва» сүзеннән, чаг. иск. әд. *дәгъват, дәгъватнамә* «требование (эш кәгазе)», *дәгъвачы* «истец».

**ДӘРЕС** «урок» — гар. *дарс-ун* «дәрес, өйрәнү; бер җәем көлтә» сүзеннән — *дараса* «өйрәнү, агару; чүп-чардан, саламнан котылу» тамырыннан, шуннан ул *мәдрәсә* (к.), *мөдәррис* «преподаватель».

**ДӘРИЯ, ДӨРРИЯ** «парча, тафта» — к. башк. *дәрйә*, чув.



*тарай*, тат. диал. *дарай*, кк., н. *дәри*, кб., кум. *дарий* «затлы ефәк». Фарсы теленнән (фарсы *дуруйа* «ике яклы ефәк яки хәтфә, Шәмәхә шәһәрендә эшләнә», *ду-* «ике», *руйә* «яклы, өсле»).

**ДӘРМАН** «лекарство; способ» — фарсы. *дарман* «дәрман, дәва» (*дару* сүзе белән тамырдаш) сүзеннән, *дар* «агач (кайрысы)» тамырыннан.

**ДӘРРӘҮ** «сразу, с ходу» — фарсы. *даррaw* «дәррәү, йөрештә; шундук» сүзеннән.

**ДӘРТ** «страсть» — фарсы. *дард* «газаплану, йөрәкләнү, газап, авыру, дәрт» сүзеннән; к. иск. әд. *дәрд* «күңел авыруы, авыру».

**ДӘРЬЯ** «большая река, большое озеро» — фарсы. *дарйа* «дәрья, зур елга» сүзеннән.

**ДӘҮ** «огромный, большой» — фарсы. *дәw* «дию пәрие, мәһабәт гәүдәле» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; чаг. госм., кк. *дәү* «дию; зур гәүдәле кеше», ккк. *тәү* «дию, әзмәвер». К. **Дивана, Дию.**

**ДӘХЕЛ** «отношение; касательство» — гар. *gäxл* id. төбендә — «эчке як, үз ягы».

**ДӘФТӘР** «тетрадь» — фарсы. *дәфтәр* «дәфтәр» сүзеннән (барлык төрки һәм монгол телләренә таралган), бу сүзнең борынгы төп чыганагы — грек. *difteros* «тире, пергамент» (чаг. **дифтерит** «кызамык, тире авыруы»). К. **Типтәр.**

**ДЕБЕТ, ТЕБЕТ** «козий пух» — бор. тк. *Түбүт* «Тибет» сүзеннән. *Тебет* башта як мамыгын белдергән һәм ул Тибеттан китерелгән. Чаг. тат. диал. *төбет* «зур гәүдәле көтүче эт» — төптә «Тибет эте».

**ТҮБҮТ** «Тибет» кытайча *тюбод* «бод (тибетларның үзатамасы) халкының башлыгы» дигәннән.

**ДИВАНА** «полоумный, юродивый» — фарсы. *дәwана* «дивана, җенле, дию ияләшкән» — *дәw* «дию» сүзенә *-ана* аффиксы ялганып ясалган (чаг. иск. әд. *галибанә* «җиңүчеләрчә», *дустанә* «дусларча», *шагыйранә* «шигъриятле» һ.б.). Шул ук *дәw* «дию, җен» сүзеннән тагы *ирдәwәй, ирдәwкә* «ирләр сыман хатын-кыз», *дәукәди* «зур һәм ямьсез гәүдәле», *дуамал* < *дәwаман* «җен кебек кыланучан» сүзләре ясалган. К.Ахмәтьянов, 1981:22—23.

**ДИЛБЕГӘ** «вожжи» — гом. тк. сүз, чыгышы ачык түгел, көнч. тк. *дәл* «ат ялы» сүзе нигезендә ясалган булуы ихтимал; чаг. якут. *дәлбәргә*, бурят. *дәлбәргә, дәрбәлгә* «ат ялыннан ишелгән бау, тасма, чачак, чук»; чаг. кк. *дилбе* «дилбегә», алт. *дилбәк* «тасма» һ.б. Монг. *дәл-бә-хә* «атны бору». Чув. *тилхěпе*, удм. *дельбуго* «дилбегә» — татарчадан.

**ДИМ** «уговаривание» — татар-башкорт сүзе; Троянский *дийем* «әйтем, әйтү» (к. **Ди-ү**) дип аңлата, ләкин к. чув. *тим* «теләк», *тимле-* «тырышу, димләү», хакас. *тим* «әзерлек, әзер тору», *тимнә-* «әзерләү, кешеләрне өмәгә җыю» алт. *тәм* «үрнәк, гадәт, осталык, димләү осталыгы», тув. *дәм* «бергәләшеп эшләү», бурят. *дәм* «кеше белән якынлашу осталыгы»; иң башта атның

авышып борылуын аңлаткан булса кирәк — шул мәгънәдә монгол телендә *дэм* киң кулланыла.

**ДИҢГЕЗ** «море» — гом. тк. *дэңгиз, таңиз* «диңгез», бор. гом. тк. **таңгир* «зур су» сүзеннән (к. венг. *tenger* [ч~z] «диңгез» — бор. тк. телләрдән); к. эвен. *тöнгэр* «күл»; төп чыгышы ачык түгел (төрлечә аңлатыла).

**ДИРБИЯ** «необходимые части предмета; сбруя; сервиз» — гар. *тәрбия* сүзеннән булса кирәк. Чаг. тат. диал., чув. *тирке* «дирбия, тәрбия, комплект». Татар теленә ниндидер башка төрки телдән кергән. К.Әхмәтьянов, 1989:82.

**ДИСБЕ** «четки» — *тәсбих* (к.) сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; к. диал. *тисбе* «тәсбих, дисбе».

**ДИСТӘ** «десяток» — рус. диал. *десть* «дистә, берничә, ике дюжина» сүзеннән дип карала; чаг. шулай ук фарсы. *дäстэ* «төтам, учлам, бәйләм, төргәк».

**ДИСТЕР** диал. «сверстник: близкий друг» — фарсы. *дäстгир* «ярдәмче» — төбендә «кул бирүче».

**ДИ-Ү** «сказать» — бор. тк. *тә-* (> тат. диал., башк. *ти-*) иң борынгы төрки сүзләрнең берсе. *Ди* «говорит» формасы мишәрчә *дир-* дән кыскарган (хәзерге заман формасы *диә* сирәк кулланыла). *Диген* формасы бор. *дигел-* дән (боерык фигыль формасы *-гыл // -гел, -кыл // -кел* булган). Татарча *ди* (*дей* дибрәк әйтелә) сүзеннән русча *де, деи* «янәсе, ди, диик» сүзе килә. *Диган, димәк* лексикалашкан формалар.

**ДИХАЙ, ДИХИ** «однообразный, спонтанный; беспричинный; темный, дикий» — фарсы. *диhhаи, диhи* «авылныкы, авылча; натураль (хуҗалык)» сүзеннән (*диh* «авыл, утар», *диhha* «авыллар»). Бу сүз шәкертләр — муллалар теленнән таралган.

**ДИЮ** «див, демон» — фарсы. *Дэв* «дию; гигант». К.**Дәү Дивана**.

**ДОРФА** «грубый» — иск. әд. *турфаи*, фарсы. *турфаги* «сирәк, сәер; сирәк һәм гаҗәп нәрсә» сүзеннән; к. диал. *торпа, төрпә, торбайы* «дорфа, тупас», кк., ккк. *турпайы* «дорфа». Семит сүзе.

**ДОШМАН** «враг» — фарсы. *душман* «дошман» — бор. ирани *duša-man, dowşa man* «начар уйлы, начар ниятле» сүзеннән (Абаев).

**ДӨГЕ** «рис» — бор. тат. *түге* «төелгән ярма» сүзеннән булса кирәк; к. диал. *ту* «тары ярмасы», куман., ткм. *ту, туи* «тары», бор. тк. (МК) *тöги* «тары ярмасы», *тöг-* «төю». Бу сүзнең кытайча тамырлары да бар.

**ДӨЕМ** диал. «общий» — башк. *дөйөм* id., кырг., кк. *дүйүм* һәртөрле», *түркүн-дүйүм* «һәрнинди; теләсә нинди», ккк. *дүйым* «гомуми, тулай; барча» - госм. *дүгүн* «туй сые, туйда халыкны сыйлау» (< *той-күн* «туй-җыен») сүзе белән чагыштырыла. Башкортстандагы Дим < *дөем* (мишәрчә *дейем*) сүзеннән булса кирәк ( бор. рус документларында *Дуйма*, хәзерге русча **Дема** «Дим»; бу елга тамагында барлык башкорт кабиләләренең җыены уздырылган). Чаг. рус. *Юматово* < **Дуйма тавы*.

**ДӨРЕС** «правильно, верно» — фарсы. *дүрүст* «сәламәт, дөрес,



чын, көчле, каты» сүзеннән, һинд-евр. **derv* «агач» тамырыннан (Покорный).

**ДӨЯ** «верблюд» (*дөйә*, диал. *дәүә, төйә*) — гом. тк. *түйә, тәwә* «дөя» сүзеннән; чаг. монг. *тэмэ*, фин. *teme, temen* «дөя» һ.б. бик борынгы сүз.

**ДУ** «подражение шуму» — гом. тк. *ду* «ду»; к. башк. *дыу* «шаушулы» (сыйфат); чаг. *эвен.* дэву «жил-буран, өермә».

**ДУАДАК** «одинокая (гусыня) — бор. *тугадак* «ялгыз, сыңар» сүзеннән (гом. тк. *toγ, tog* «ялгыз» тамырыннан); к. диал. *дыwадак* «өйсез-йортсыз, хуҗасыз мал, дуадак кош», әкиятләрдә *Тугзак батыр* «ялгыз батыр», *игезәк* белән *тугзак* («берәүнең өч баласы була, икесе игезәк, өченчесе тугзак»). К. **Дүдәк; Тугыз.**

**ДУАМАЛ** «безумец; необдуманно» — диал. *дәуамал, даумал* «дуамал», башк. *дәүмәл* «зур, көчле», тат. диал. *дәүмәлек* «зурлык», н. *дәу амал* «дию шикелле», тат. диал. *әмән, әмәл* «кебек, шикелле: гүяки» < фарсы. *häман* «шул ук».

**ДУГА** «дуга» — рус. *дуга* «дуга» сүзеннән хисапланыла; чаг. шулай ук *дугай.*

**ДУГАЙ** «старица» — гом. тк. *тогай* «тугай, елга буе, дугай» сүзеннән; к. тув. *дугай* «бөгелеш, елга алкасы», монг. *токой* «терсәк, бөгелеш; җәя». Шушы сүздән үк Тукай («җәя» мәгънәсендә) исеме дә килә.

**ДУЛКЫН** «волна» — диал. *тулкын; тулкы-* «дулкынлану», гом. тк. *тол-кун, тол-ук-ун* «дулкынлы» бор. *тол-ук* «дулкын» нигезеннән, ниндидер *тöл-, тог-ул-* «дулкынлану» фигыленнән (*тог-* тамырыннан); чаг. *тулган-у*; к. башк. *тулкын-ыу* «дулкынлану», алт. *толку* «дулкын», якут. *долгуо-* «дулкынлану, селкенү, болгану», бурят. *долги-хо* «чайкалу, ярга сугылу, дулкынлану», *долгиин* «дулкын»,; чаг. тув. *дойл-ур-, догул-ур-* «дулкынлану, болгану», шор. *токыл* «дулкын».

**ДУМБРА** «домра» — фарсы. *тунбра, тумра, тамбура* «думбра, барабан» ~ гар. *тамбур, тумбур* «думбра, даирә (тамбурин)» сүзеннән, беренчел формасы фарсы *думи барра* «куй койрыгы, шуңа охшашлы музыкаль инструмент» сүзеннән хисапланыла. Татарларда *думбра* XVI гасырда ук шул исемдә йөргән (документларда *думбрачылар* искә алына), шунлыктан бу сүз рус алынмасы түгел.

**ДУҢГЫЗ** «свинья» — гом. тк. *тоңгуз* «дуңгыз» сүзеннән, чыгышы ачык түгел; чаг. бор. кытай., корей. *tong, ton* «дуңгыз». К. Әхмәтьянов, 1989:68.

**ДУС** «друг» — фарсы. *дуст* «дус» — бор. ир. dauštar «күңелгә ошаган (кеше)» сүзеннән.

**ДҮДӘК** «дрофа» — гом. тк. *тогдук, тогдак* «дүдәк» — бор. *тогадак* «ялгыз, сыңар (кош)» сүзеннән (к. **Дуадак**); к. монг. *тоодаг* «дүдәк». Сүзнең тамыры бор. тк. *тог, тоң* «ялгыз; так»; шуннан ук тат. диал. *тон бала* «беренче ир бала» һәм *тугыз, тугыз-ак* сүзләре килә.

**ДҮЛӘНӘ** «боярышник» — гом. тк. *тöләнә, толана*, борынгырак формасы *толукуна* «дүләнә», к. диал. *дулана*, алт. (телеут.)

*толоно*, якут. *долокуна, долукуна* «дүләнә». Тамыры хак. *тоо* «вак җиләк» (*тоолу* «вак җиләкле», *кана, куна* «куак, курпы»).

**ДҮЛМӘН** «широкая папаха» — к. госм. *дулбәнд, тулбәнд* «чалма», әрмән-кыпчак язм. *дулбант* «зур чалма» — фарсы *дулбәнд* «чалма» (*дул* «түгәрәк, *бәнд* «бәй, бәйләвеч, урама») сүзеннән. Шуннан ук — төрки телләр аша — рус. *тюльпан* һәм тюрбан.

**ДҮН-Ү** «отвернуться; отрекаться» — гом.тк. *дөн-, төн-* «әйләнү, кайту, кирегә юнәлү» сүзеннән; к. диал. *тун* «кире як».

**ДҮҢГӘЛӘК** «перекати-поле; кольцо». бор. язм. *туңгәләк* «бөжра, алка» — бор. *туң-әл* «түгәрәк нәрсә» сүзеннән, *тун, төң* «түгәрәк, йомры» тамырыннан булса кирәк (чаг. **Түмгәк**); к. диал. *дуңгәнәк* «тәгәрәй үләне, комгак»; чаг. эвен. *тонгал, тонгалра* «бөжра, балдак».

**ДҮРТ** «четыре» — гом. тк. *дөрт, төрт* «дүрт» сүзеннән, тамыры ачык түгел (төрлечә аңлатыла); чаг. якут., монг. *дөрбән* «дүрт», чув. *тăват* «дүрт».

**ДЫМ** «сырость» — чыгышы ачык түгел; чаг. н., кк., башк. *дым*, үзб. *дим* «тынчу, бөркү»; икенче яктан, чув. *лăм, лым*, кырг. *ным*, үзб. *нăм* «дым, юешлек».

## -Е-

**ЕГӘР** — к. **Җегәр**.

**ЕГЕРМЕ** «двадцать» — бор. *йәккермә* «егерме, ике ун» — бор. тк. *йәки* «ике» сүзеннән: гом. тк. *йекерме, йәкирми* > якут. *сүрбә* «егерме»; *йәки-р-ми* яки *йәкир-им* сүзенең соңгы өлеше суффиксаль ясалма (*-им* — «-нче») яки монг. *арба(н), арма(н)* «ун» сүзенең төрки варианты булса кирәк. К. **Игез, Ике.**

**ЕГЕТ** «юноша, парень» — гом. тк. *йәгит*, бор. тк. *тәгит* «егет, егетләр, гвардия» *тәгин* «принц, шаһзадә» сүзенең бор. күплек формасы. *Тәгин* сүзе тур. әдәбият бик күпсанлы. Берәүләр бу сүзне бор. ирани *digvina, diga* «шаһзадә» сүзе белән, икенчеләр кидань телендәге *телигунь* «император» гаиләсе әгъзаларының тәнсакчысы» сүзе белән чагыштыралар (татар туендагы «кияү егетләрен» хәтерләсәк, бу фараз дөрескә дә охшый). Рус. *джигит* Кавказ төрки телләреннән. *Егет* сүзе татар теленнән күрше фин-угор телләренә кергән.

**ЕГ-У** «валить» — гом. тк. *йык-* «егу, җиңү, бетерү» сүзеннән; к. алт., куман. *йык-* «егу, бетерү, төшерү», бор. тк. *йык* -«төшерү, кулдан җибәрү», уйг. *йыгың* «һәлакәт», азәрб. *йых-* «төшерү, җимерү», чув. *çăх-* «егылу». Чаг. бор. чыгт. йың- «егу, аудару», *йыңыл-* «аву» (Боровков). Чаг. **Җиң-ү.**

**ЕЛ** «год» — гом. тк. *йыл, җыл*, якут. *җыл, д'ыл, сыл* «ел, җәй» — бор. тк. **йал* «яшеллек» (к. **Яшь**) сүзеннән, чаг. чув. *çул* < *җал* «ел».

**ЕЛА** «плакать» — к.**Ыгы-зыгы**.

**ЕЛАН** «змея» — гом. тк. *йылан, җылан, йулан йыл-, җыл-* «бөгелгәләү, шуу, шуышу, үрмәләү» тамырыннан.

**ЕЛГА** «река» — бор. *йал-ға-ғ // йул-ға-ғ* «елга, үзән, уйсулык» — *йол- // йул-, җал- // җул-* «инеш, чишмә, елга, саз, юеш җир» тамырыннан; к. тат. диал. *йылга* «коры үзән», бурят. *җалга* «үзән, ерынты, тарлавык, уйсулык», кк. диал. *җылауа(н)*, *җулга, җолга*, кк. әд., кырг. *җылга* «үзән, коры елга» (Аманжолов), чув, *йăлка* «юеш үзән». К.**Җылу**.

**ЕЛГЫР** «шустрый, юркий» — бор. *йыл-ыгыр* «случан, житез, шома» гом. тк. *йыл-, йал-* «шуу, шәп бару, очу» тамырыннан.

**ЕЛДАМ** «быстрый; проворный» — бор. *йыл-лам, йыл-да-м* «хәрәкәтчән» — *йыл-ла-* «шәп хәрәкәт иткәләү» сүзеннән, *йыл-, йал-* «шәп хәрәкәт итү» тамырыннан. К. **Елгыр**.

**ЕЛКЫ** «лошадь» — бор. *йал-кы // йал-лык* «яллы (ялын кисмәгән) ат» яки «ял итүче ат» сүзеннән; к. алт. *дылкы* «өйрәтелмәгән ат, бия, госм. *јылкы* «иректә йөрүче атлар», ккк. *җаллык* «ат», чулым. *йалты, йал-тыг ~ йал-лыг* «елкы». К. **Ял** I.

**ЕЛМАЙ-У** «улыбаться» — татар. диал. *йылма* «көләч; якты; ялтырап торган» сыйфатыннан ясалган фигыль (чаг. *кара-, карай-, туры-, турай-* һ.б.ш.), бу сүз исә, үз чиратында *йыл* — «шомарып ялтырау» фигыленнән һәм *йал- // йыл-* «ялтырау» дигән гаять продуктив тамырга (чаг. *ялт, елт, елык-елык, елкылдау* һ.б.) тоташа.

**ЕРАК** «далекий» — гом. тк. *йыра-* «ераклашу» (алт. *ыра-*, уйг. *йыра-* «ераклашу, урманга китү») сүзеннән; төптә *йы-ра-*, ягъни **йы-* «урман» тамырыннан, к. **Агач**.

**ЕР-У** «прорвать, рвать» — гом. тк. *йыр-* id. Шуннан ук *ермак, ерганак, ерт-у, ерткыч* һ.б.

**ЕФӘК** «шелк» — бор. *йип-әк* «ефәк жеп» — *йеп, җип* «җеп» сүзеннән (Рясянен); к. кк. *җибек*, алт. *дибәк, чибәк* һ.б. «ефәк шнур». К. **Җеп**.

**ЕШ** «частый, густой» — бор. *йығ-ыш*, бор. тк. *йы-ғ-* «куеру, ешаю» сүзеннән; к. чув. *йу, йывă, йыв, йăвă, (йывы)* «еш, куе», н., тат. диал. (себ.тат.) *йыйы* «еш, тыгыз», бор. тк. *йыш* «ботаклы агач, еш, куе». Алт. *дыш*, бор. тк. *йыш* > тат. диал. *йеш* «урман, урманлы тау» башка тамырдан булса кирәк.

## -Ж-

**ЖАЛУ** «жалоба» — рус теленнән.

**ЖӘЛ** «жаль» — рус. *жаль* «жәл, кызганыч» сүзеннән.

**ЖИРӘБӘ** «жребий» — рус теленнән.

## -Җ-

**ҖАДУ** «колдовство; колдун» — чаг. диал. *җәт* «заговор, порча» — Азиянең күп телләрендә очрый торган сүз. Бор. тк. — *йат*, тув. *чат*, себ.тат. *чату* «сихер; күрәзәлек; сихерче, күрәзәче».

*Җаду таш* ярдәмендә һава хәлен үзгәртеп була дип ышанганнар; *җадугәр* — һава хәлен үзгәртерлек көче булган сихерче.

*Җаду* сүзен бор. һинд. *җатак* «догалык» (китап) сүзеннән дип уйлыйлар.

**ҖАЙ** «место, лад; удобный момент» — Санжеев буенча бор. монг., тк. *җабу, җагу* «буш ара, буш вакыт» сүзеннән (татар телендә һәр ике мәгънәсе саклана булса кирәк); к. бурят. *зай*, монг. *җай* «буш урын, ара», *җаб, дзаб* «буш вакыт, җай (уңайлы вакыт)», тув. *чай* «иркен, буш вакыт», үзб. *җой*, кк., ккк. *җай* «урын, буш урын», куман. *йай* «уңайлы урын» (к. тат. *җай-ла-у* «уңайлы итеп урнаштыру, уңайлау»). К.**Җайдак**.

**ҖАЙДАК** «всадник» — көнч. тк. *йабыдак*, алт. *д'абыдак*, тув. *чабыдак* «иярсез атка атланган, иярсез, ялангач» сүзеннән, тамыры *д'авыз, д'абыр*, «ялангач, буш, түбән, тәбәнәк» (к. **Җай**); к. башк. *йайҙак* «җайдак», алт., уйг. *йайдак* «җайдак; киң, сөзәк, түбәнгә таба авыш», алт. *д'абызак* «тәбәнәк, түбән», бурят. *зайдан* «җайдак; ачык, ялангач, кола ялан (*зай* «ара, җай, ачык урын»), «буш ~ түбән, тәбәнәк», мәгънә күчеше аңлашылып бетми, ихтимал, бу көньяк Себер тауларының табигый шартлары белән бәйләнгәндер. Чаг. шулай ук **Сыбай**.

**ҖАМАЯК** «полоскательница» — асылда, кушма сүз: *җам* «тәлинкә, савыт, су савыты» һәм *аяк* (к. **Аяк** II) сүзләреннән тора.

**ҖАН** «душа» — фарсы. *җан* «җан, энергия, тын, сулыш» бор. ирани. dah, dayah «тын, сулыш, һава» сүзеннән (гар. *җан* «җан» фарсы теленнән).

**ҖАНВАР** «зверь, существо» — фарсы. *җаноwар* «җан иясе, җан йөртүче». Чаг. **Җәнлек**.

**ҖАН-ФӘРМАН** «во всю мочь» — бор. *җәң фәрманы* «сугыш хәбәре, сугышка мобилизация приказы» сүзеннән (*җәң* «сугыш, бәрелеш» — фарсы теленнән).

**ҖАР** «клич; песня — обращение к силам природы» — бор. *йар* «кычкырып әйтелгән игълан», шуннан ук *йаргы* «суд», *йарлыҡ* һ.б. К. **Ярлык.**

**ҖАУ** «жир» — гом.тк. *йаӯ, җаг, йаг* «май, майлы нәрсә», тат. диал. *җәү* «гомумән май», үзб. *йог*, чув. *çăв, çу* «май, эчмай».

**ҖӘВЕР** «потомство, семья, дети» — к. тат. диал. *җүр, җүрә* «җәнлек-җанвар баласы», себ. тат. *чүри, цүри* «чеби, каз бәбкәсе», чув. *çăвăр, çурă* «бала-чага; куч», төрек., гагауз. *йавру*, бор.тк. *йауры* «кош баласы» һ.б. Бу сүз, ихтимал, *йара- < йагра-* «барлыкка китерү, тудыру» сүзе белән бәйләнгәндер (к. тат. *ярату, яралту* «бар иту»).

**ҖӘЕН** «сом» — бор. **чаг-ын* сүзеннән; к. кырг. *чайын* «җәен», чув. *çĕвĕн, çуйăн* «җәен», н., ткм. *йайын*, кк., ккк. *җайын*, үзб. *җаин* «җәен», бор. тк. *йаган, йагын* «аждаһа; фил».

**ҖӘЗБӘ** «циркуль» — татар теленең үзендә гар. *җәдвәл* «таблица» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан. К. иске татар *җәзбәр* «озынлык нисбәте».



**ҖӘЙ** «лето» — гом. тк. *йай, җай* «җәй» бор. тк. *jaγ id. сүзеннән; чаг. эвен. *д'огни, д'үгэни* «җәй», монг. *җүн, җэг-үн* id.

**ҖӘЙРӘН** «джейран» — бор. тк. *җәгәрән, дәгәр-әң* «җирән киек» сүзеннән булса кирәк; чаг. монг. *җэгэрдэ* «җирән ат; төлке», бурят. *зээрдэ* «җирән», монг. *җэгэрэн*, бурят. *зээрэн* «җәйрән», рус. *джейран, зерен* — төрки телләрдән. К. **Җирән**.

**ҖӘЙ-Ү** «стелить, расстилать» — гом. тк. *йай-* id. К. ш. ук *җәйрә-ү* «расстилаться» < йайра — id.

**ҖӘНЛЕК** «зверь» — бор.тк. *җанлыг* «җанлы нәрсә (кемсә), җан иясе» сүзеннән. Мар. *йанлык* «җәнлек» — татарчадан.

**ҖӘНҖАЛ** «скандал» — фарсы. *җән-җәдал* «сугыш-талаш» сүзеннән; к. иск. тат. *җәң* «зур сугыш», тат. диал. *җәдәл* «ызгыш, талаш». К. **Җан-фәрман.**

**ҖӘРГӘ** *книжн.* «боевой строй» — гом.тк. *йәргә* > чув. *йерке* id. К. **Ниргә.**

**ҖӘРЕН** «на следующий год» (ср. *былтыр*) — бор. *йарын < йар-кын < йар-ык-ын* «яктырту, яктылык» сүзеннән (мәгънә күчешләре «яктылык > яктырту > таң > иртә > иртәгә > киләсе елга»); к. иск. *йарин*, уйг., госм., тк. һ.б. *йарын* «иртәгә», үзб. диал. *йаркын, җаркын* «якты, таң», чув. *çурăн* «таң», алт. *йаргын* «таң», *җаркын, д'аркын* «нур, балку», д'арык «яктылык», себ. тат. *йарык*, бор. тк. *йаруг* «якты», бор. чыгт. *йарын* «иртәгә, иртән» — куман. *йарындасы* «иртәгәсе». Сүзнең тамыры *йар-* «яктыру, балку», бор. тк. *йаг-ыр* «ягылган, яктыртылган» сүзеннән ягъни *якты* сүзе белән тамырдаш булса кирәк (к. **Якты, Ягу**); к. алт., уйг., госм. *йары-*, хакас. *чары-*, якут. *сары-* «яктыру, таң ату».

**ҖӘҮҺӘР** «бриллиант» — фарсы. *гәуһәр* (к.) сүзенең гарәп теленең фонетик законнары буенча [*г > җ*] үзгәргән формасы.

**ҖӘҺӘННӘМ** «геенна» — гар. *җәһәннәм* «җәһәннәм, эссе тәмуг» беренчел мәгънәсе буенча Палестинада үзенең корылыгы һәм эсселеге белән атаклы булган бер үзән. Ул *гә-й-һәннәм* «һәннәм балалары җире» дип аталган; анда «Молох» дигән пот торган һәм шунда балаларны корбанга чалганнар. Чаг. рус. *геенна.*

**ҖӘҺӘТ** I «быстро, живо» — гар. *җăһăд-ун* «тырышлык, ашыгу» сүзеннән — *җăһăдă* «тырышу, көч салу» тамырыннан, шуннан ук *иҗтиһат*. К. ш. ук диал. *йәтрәк // җәтрәк, җәһәтрәк* «тизрәк».

**ҖӘҺӘТ** II «сторона; отношение» — гар. *җăһăт-ун* «як, тараф» сүзеннән (тамыры *җәһ-* «ике якка аерылу; ике якның берсе»).

**ҖӘЯ** «лук (*оружие*)» — гом. тк. *йа, йай, йайа* «җәя» сүзеннән; чаг. ш. ук кк. *җай*, тув. *ча* «җәя»; чаг. фарсы. *зеһ, зәһ*, бор. ирани. *дуа* «җәя, кереш».

**ҖӘЯҮ** «пешком» — бор.тк. *йайаг < йадаг ~ йадан ~ җадан* > чув. *çоран, çуран* (чаг. гагауз. *йайан*) «җәяүләп», монг. *йадагу* «җәяү»; фарсы. *пиадаг* «җәяүле» сүзе белән чагыштырыла.

**ҖЕБЕ** «промокнуть» — гом. тк. *йиби-* «җебү», монг. *д'ебте-* «җебету». Татар телендә *җебе-* бик продуктив нигез: шуннан *җебек, җебен, җебен-у* һәм *юеш* (к.) сүзләре ясалган.

**ҖЕГӘР** «мощь, сила» — тат. диал., башк. *йөгәр*, чув. *йёкер*, мар. *йегар, йыгар, җӹгäр*, удм. *ӟигар-*, фарсы. *җикар* «бавыр, йөрәк» сүзеннән гом. тк. алынма; к. ткм., кырг. *җигер*, гагауз. *җеер* «бавыр», якут. *сэгэр* id.; к. тат. *җөкәр-бәгърем* «җаным, сөеклем»; кыпчак телләрендә *йигер, җигер, җигерли* «гайрәт, гайрәтле».

Бу сүзнең һинд-европа телләрендә параллельләре бик күп.

**ҖЕН I** *миф.* «бес, черт» — гар. *җинн* сүзеннән.

**ҖЕН II** «сухожилие, пищевод» — чув. *чен*, мар. *сун, шӧн*, удм. *сӧн* «сеңер». Төптән фин-угор сүзе.

**ҖЕНЕС** «пол» — гар. *җинс*. Асылда һинд-европа *ghen, gen* «тудыру» тамырыннан (шуннан ук рус. *жена* «хатын», ягъни «тудыручы»).

**ҖЕНТЕКЛӘ-Ү** «дотошно исследовать» — татар теленең үзендә тат. диал. *җентек* «үлчәнгән өлеш, үлчәү берәмлеге» сүзеннән; тамыры бор. тат. *җен, йең* «төгәл үлчәм, субординация» ~ алт. диал. *йин*, бор. чыгт. *җиң, җин* «өлеш, үлчәү, порция» >> тув. *чин*, хакас, *син* «үлчәү, чак, яшь, кимәл, дәрәҗә» (*синниг* «үлчәнгән», *ниндиг* «тентү»). Бу бор. төрки сүздән русча *чин* «дәрәҗә» сүзе килә.

**ҖЕП** «нить» — гом.тк. *йеп, д’ип* «җеп, йон» сүзеннән. К.**Ефәк**.

**ҖЕПСӘ** «шпонка; перекладина» — уйг. *җипсә* ~ чув. *йёп, йёпсе*, мар. (> удм.) *йыпша, йыпса* «иглица, шпона; копье; стержень петли». Борынгы татар теленнән (й-!), тамыры бор. тк. *йэбэ* «тимер оч, сөңге; ук»; к. мар. *йып* «сөңге», чув. *йёп* «ук», алт. д’ебе «ук; тимер оч».

**ҖЕПШЕК** «слякоть; мокрый (*о снеге*)» — иск. *җебе-ш-ек* «җебешкән, җебегән» сүзеннән (к. **Җебү, Юеш**); к. диал. *җепше-ү*, башк. *йеп-ше-ү* «бераз эри башлау (*кар турында*)», чув. *йăпсăк* «вак яңгыр, яңгырлы кар».

**ҖЕТЕ** «ярко (*о цветах*)» — гом. тк. *йит-иг* «үткер, үтә» («үткен → үтә» мәгънә көчеше) сүзеннән, бор. *йит* < **диг-ит-* «үтү, үткер булу» фигыленнән; к. себ. тат. *йетек*, бор. тат. *йете* «үткер, ачык, җете», бор. чыгт. *йете* «бөтенләй», уйг. *йиди*, куман. *йити*, чыгт. *йитик* «үткер», хакас. *четег*, якут. *сыты* «үткер, кискен», чув. *çивĕт, çивĕчĕ* «үткер, җете; пәке йөзе».

**ҖЕФЕТ** «супруг; супруга» — фарсы. *җӳфт* «пар, иш» сүзеннән, шуннан ук *җөп* (к.).

**ҖИБӘР-Ү** «посылать» — бор. тк. *ыда бәр-* «этәреп бирү» (кушма фигыль: *ыд-* «этәрү, җибәрү», *бәр-* «бәрү, бирү») сүзеннән (Рамстедт); к. бор. тк. *ыты-*, чыгт. *ыд-*, тат. диал. (себ., мишәр) *ий-*, н., кб., кум. *ий-* «җибәрү, юнәлдерү»; к. тат. диал. *җиббәр-ү, йепбәр-ү* «җибәрү; шәп чабу» < *ийеп бәр-ү* (*бирү*).

**ҖИДЕ** «семь» — гом.тк. *йете, йэтти* «җиде» сүзеннән, тамыры ачык түгел.

**ҖИДЕГӘН** «Большая Медведица (*созвездие*)» — бор. төрки *җедикан* «җиде хан» сүзеннән (аның риваяте турында к. В а й н ш т е й н С.И. Тувинцы-тоджинцы, 1961:148 һ.б.) Чаг. фарсы. *Һәфт урәң* җиде тәхет, җидегән».



**ҖИГҮ** «запрячь» — к. **ҖИКҮ**.

**ҖИЗ** «латунь» — чув. *йăс, йĕс* «җиз, бакыр», *çăвăç* «җиз калай», мар. *йөз* «җиз», *йеж* «чем»; удм. *ӟез* «бакыр», *ез* «чем (проволока)», рус. *жесть* «калай» — гом. тк. *йэз* «җиз, бакыр» сүзеннән (күп телләргә кергән). Төрки-монг. *jez* < бор.тк. *jerg’ янгырашыннан дип уйларга мөмкин; к. тунгус. *чирик* «точ (бронза)». Чаг. ш. ук һинд. *jast* «калай, кула».

**ҖИЗНИ, ҖИЗНӘЙ, ҖИЗНӘ** «муж старшей сестры» — чув. *йысна* < миш. *йезнә* (> морд. *эзна*) < гом. тк. *йәзнә*, тк. диал., гагауз. *йэништэ* < бор. **йэнизнэ* «чит ырудан килгән абый» сүзеннән; чаг. *җиңги*. Төрки [-з] бор. тк. [-р] дан килгәнлектән, бор. вариант **йэңирңэ* булган булса кирәк.

**ҖИК, ҖЫК** «неприятность» — бор.тк. *йэк*, алт. *д’эк*, хакас. *чек* «шайтан; нәфрәт; нәҗес; яман чир» сүзеннән, шул ук тамырдан *җирән-ү* < *җэгрэн-ү* һәм *җиксен-ү* сүзләре ясалган.

Төрки телләрдә *йәк, йиг* «яхшы, шәп» сүзе дә булган, әмма ул «шайтан» мәгънәсенең «шәп, елгыр» дигән трансформациясеннән килеп чыкмадымы икән? Котби телендә *йәк* «баһадир; батыр сугышчы» мәгънәсендә.

**ҖИКЕР-Ү** «кричать на *кого-*л.» — тат.-башк. телләрендә моны *-кыр // -кер* аффиксы ярдәмендә «һи!» ымлыгыннан ясалган — башта *икер-ү, йе-кер-ү* булган дип була; *шулай ук* «җир!» дип кычкыру да була ала; к. алт. *д’иркирэ-* «җикерү».

**ҖИКҮ** *диал.* «сбруя; хомут» — кырым. *йәкү*, себ тат. *йәк, йәке* id.; шуннан *йәклә-* ~ алт. *йэктэ-* «җигү»; гом.тк. *җик-, йэк-* «җигү» сүзен чув. *çак-*, мар. *с’ăк->*с’ак- «асып кую, элү» белән чагыштырып була. Чаг. ш. ук немец. *joch, jok* «боендырык (үгез камыты)» ~ рус. *иго* id.

**ҖИЛ** «ветер» — гом. тк. *йэл* id., төптә тәкълиди тамырдан; шуннан ук *җилпе-ү, җилт-җилт итү, җилке-ү* (шуннан *җилкен-ү*), бүтән тамырлар кушылып *җилбәгәй, җилбәзәк, җилкән* һ.б. күп сүзләр ясалган. Мифологиядә *җил*нең «күренмәс рух» мәгънәсе дә бар.

*Җил // йэл* тамыры *йал // сал // тал // чал* тамырлары рәтенә керә; чаг. *салкын, селкен-, талпын-, тилпен-, тилкен-, чал-, чәл-*.

**ҖИЛӘК** «ягодка, ягода» — гом. кыпчак. *йэләк, җэлэк*, н. диал. *чигләк*, алт. диал. *йиглэк*, бор. *йигдләк*, ткм. *чигәләк*, кк. диал. *җегелек* «җиләк, кавын»; тамыры ачык түгел, ләкин борынгы формасы *йигер-ләк* булган дип була; ткм. *чигэлэк* «җиләк», кк. *җидэк* «җиләк», үзб., ккк. һ.б. *җидә* «бер төрле җиләк бирә торган агач, җидә», монг. *җигдә* «җир җиләге», чув. *çирле, çырла* «җир җиләге». Чаг. **Җи-ү**.

**ҖИЛӘН** «халат, плащ» — бор. тат. *җәлән* «җилән, бер төрле материя» (К.Насыйри) сүзеннән; к. монг. *дэгэлэй, дэгэлэн* «камзул», чыгт. *дэглэ*, алт. *телен, дьелен* «җилән». Бик күп телләрдә очрый.

**ҖИЛӘС** «прохладный, свежий» — «җил» сүзеннән *-әс, -әз* кушымчасы (диал. *җиләз* «җиләс, җилле») ялганып ясалган.

**ҖИЛБӘГӘЙ** «нараспашку» — монгол теленнән; к. кк. *җэл-*

*бэгэй* «постау башлык», бурят. *далбагар, җалбагар* «киң, киң кырлы (мәс. эшләпә, яка); сөзәк», *далбага* «җилкән», *далбага-наха* «җилфердәү, язылу», якут. *дәлбәгәй* «җилбәгәй»; чув. *елегей* «җилбәгәй» ~ монг. *зэлбэгүй, зэлэгүй* «җилбәгәй, җилесез» — *зэлбэ, зэли* «җиле (изү бавы)» сүзеннән. *Җилбәгәй*, шулай итеп, «изү баусыз» дигән сүз.

**ҖИЛБӘЗӘК** «ветреный, легкомысленный» — бор. тат. *җилбәз* «җилләнеп торган: уенчак, мавыгучан, җиңел акыллы» («җил> тилелек» мәгънә көчеше) сүзенә *-әк* кушымчасы ялганып ясалган; к. алт. *д'элбис* «җиңел холыклы, тыйнаксыз, җилбәзәк», *д'элби* «мавыгу, дәрт» ~ монг. *җилбэрхэх* «кызыгу, кыҗрау, теләү». Икенче яктан к.төрек., фарсы һ.б. *җэлвэ* «җенсән кызыктыру», фарсы, *җэлвегяр, җэлвезан* «җилбәзәк».

**ҖИЛГӘР-Ү** «веять (*зерно*)» — «җилгә бәрү» сүзеннән кыскарган булса кирәк; чаг. диал. *йилгә бәру* «җилгәрү» (элекке заманнарда ашлыкны җилгә каршы көрәк белән чөеп җилгәргәннәр).

**ҖИЛЕ** «петелька из шнура, прошнуровка» — к. кк., кырг. желе, чыгт. җәли «тайлар, бозаулар бәйләү өчен элмәкле аркан; әсирләрне богаулау өчен тимер богау», монг. *җэл, зэл, зэли* «җиле, изү бавы, ялау» — бор. йалагу «элмәк, җиле» сүзеннән, бор. йал — «төйнәү, элмәкләү» тамырыннан; к. чув. *йăлă* «элмәк, төен», *йăлмак* «элмәк», *йăлла-* «элмәккә алу, төймә төймәләү». К. **Ялау**.

**ҖИЛЕК** «костный мозг» — гом. тк. *йәлик, йүлүк, д'әглүк* (*сүңүк*) «эчмайлы (сөяк)» сүзеннән булса кирәк; к. алт. *д'илик, д'үлүк* «җилек, арка җилеге», *д'ү, д'үг* «май, эчмай»; чаг. тув. *чилиг*, чыгт. *йилиг* «җилек», монг. *җилүгэ* «ми, җилек», уйг. *йүлум*, алт. *йүлүн*, шор. *чилин*, кк. себ.тат. *йүлүн* «җилек».

**ҖИЛЕМ** «клей» — бор. тк., гом. тк. *йэлим* «җилем» сүзеннән, чыгышы ачык түгел; чаг. фарсы. *шилим* «җилем», монг. *җилий* «җилем», якут. *силиңнэ-* «җилемләү», *силим* «җилем, койка, балык лайласы».

**ҖИЛЕН** «вымя» — гом. тк. *йэлин* «җилен», бор. **дэл* «җилен, түл, буазлык» сүзеннән; к. алт. *дэлдэ-*, *тэлдэ-* «җиленләү, тулу, юанаю», *тэлбэк* «юан», *тэлди* «җилен, җиленле», якут. *силин, сирин* «җилен», бурят. *дэлэң* «җилен».

**ҖИЛКӘ** «затылок» — бор.тк. **дәл* «җилкә йоны, ял» сүзенә *-кә* (*-кәк*) кушымчасы ялганып ясалган сүз; к. кк. *җелкә* «җилкә», уйг. *йәлкә* «җилкә», гом.тк. *йал* «ял (ат ялы)»; к. чув. *çилке* «ат ялы»; чаг. бурят. *д'элһэн*, монг. *д'эл* «ял», якут. *сиэл* «ял». К. **Ял** I.

**ҖИЛКӘН** «парус» — госм. *йәлкән* сүзеннән дип саныйлар, асылда, *җил* сүзе белән тамырдаш.

**ҖИЛПӘЗӘ** «веер» — госм. *йәлпәзә* «җилпәзә» сүзеннән, *җил* (к.) белән тамырдаш.

**ҖИЛПУЧ** «лоток для муки» — диал. *җилпәүеч, җилпәгеч* сүзеннән, *җилпе-ү* фигыленнән, тасвирый яңгырашлы *җилп-җилп иту* тамырыннан.

**ҖИМ** «корм, пища, еда» — гом. тк. *йэм*, тат. диал. *җий-*, гом. тк. *йэ-, йэй-* «ашау» сүзеннән. Шуннан ук тат. *җимеш* (чув. *çимĕç*, мар. *емыш* һ.б.) сүзе дә ясалган, ә бусыннан татар телендә *җимшән, җимшәү* нигезләре (диал. *җимшә-ү* «җимеш бирү, җимешләнү» фигыленнән) килеп чыккан.

**ҖИҢ** «рукав» — гом. тк. *йэң* «җиң, йөгән». Чаг. иран. *чэң* «кул, канат». Ихтимал, *җиң, йэң* сүзеннән тат. *җиң-ү* < гом. тк. *йэң-* «җиңү» сүзе дә киләдер (элек җиңелгәннәрнең җиңнәрен артка каерып бәйләгәннәр). *Җиң-ү* «победить» тур. фаразлар бик төрлечә.

**ҖИҢГИ, ҖИҢГӘ** «сноха, невестка (*жена старшего брата или родственника*)» — тат. диал. *йеңгә* > чув. *инке*, мар. *енга, енгай-*, гом. тк. *йэнгэ* (төрки телләрдә *җиңгәчи* < *йэңгэчәг* варианты киң таралган) «җиңги, өлкән апа (үз кардәшең түгел)», хакас. *ниге* «җиңгә», *нигеҗи* «җингәчи», якут. *саңас* «җиңгәчи».

*Җиңги* < *җиңгә-й* һәм *җизни* < *җизнә-й* сүзләре бер модельдә һәм бер борынгы *йэң* «чит ыру кешесе» сүзе нигезендә ясалганнар: **йэң әкә* (к. чув. *ака* < болгар. *әкә* «апа») «җиңги, җиңгә, чит ырудан килгән апа», **йэң эрңә* «җизнә», чит ырудан килгән абый».

**ҖИҢЕЛ** «легкий» — чув. *çăмăл*, мар. *сымыл-*, гом.тк. *йэңкил* бор. *йэң* «җиңел» тамырыннан; к. бор. тк., уйг. *йэни-* «җиңеләйтү» (*йэң-и*), *йэник* «җиңел» ~ тув. *чиик*, алт. *дьиик*, хакас. *ниик* «җиңел» ~ тат. *нәни* < *nеniq* < *jeniq* (*j-* > *n-*).

**ҖИР** «земля» — чув. *çĕр-*, гом. тк. *йэр* «җир, урын» (мәгънәләре бик күп). Бу сүзне тат. диал. (мишәр.) *йертец*, куман. *йэртинчи*, уйг., монг. *йиртинчү* ← тибет. jegrten «дөнья, туган ил» сүзе белән чагыштыралар.

**ҖИРӘН** «рыжий» — хакас. *чигрэн*, алт. *дьээрэн* «җирән, җәйрән» (болар төптә икесе бер сүз: җәйрәннәр һәрвакыт җирән булалар), бор. тк. *йэгир* > сагай. *чэгэр*, якут. *сиэр*, чув. *çавăр, çавр* «җирән» (шуннан рус. *саврасый* «аксыл җирән»). Рус. *игрений* һәм *чегравый* дигән ат төсмерләре дә шуннан, төрки шивәләрдән. К.Әхмәтьянов, 1989:78—79.

**ҖИРӘН-Ү** «брезговать, гнушаться» — тат. диал. *игрән-*, чув. *йĕрен-*, мар. *йӹрӹн-, йырын-* < гом. тк. *йирэн-*, кум. *җиргэн-*, якут. *сиргэн-* тат. диал. *җирек-* «ялку» сүзе белән тамырдаш булса кирәк; к. бор. тк., бор. монг. *йэгүр-* «җирәнү» — бор. тк. *йэк* «яман, шайтан» сүзеннән.

**ҖИРЛЕ** «то-то, вот почему» — тулы варианты *әйтәм җирле*: *җирле* монда н., кб., кар. *йэрли* «урынлы» дигәннән һәм тулы дөрес вариант *әйтсәм (дә) җирле (урынлы)* булып чыга.

**ҖИТӘК** «повод, узда, руководство» — гом. тк. *йэтэк, йэдэк* «җитәк, бау, запас, өстәмә, кушымта, савыт булып хезмәт итүче тире» сүзеннән, бор. тк. (МК) *йэт-* «җитәкләү, тарту, күтәреп яки сөйрәп алып киту» фигыленнән. Чаг. **Итәк**.

Электә *җитәк* < бор. тк. *йэтәк* сүзе башлыча «запас ат» мәгънәсендә кулланылган.

**ҖИТЕЗ** «ловкий, расторопный» — бор. тат. *җит-кер-*// *йэт-кир-* «житүчән, тиз җитә торган» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан булса кирәк ([р>з]; к. **Җит-ү**). Башк. *йетез*, чув. *йĕтĕс* «житез» татарчадан. Чаг. бор. тк. *йитик, йитиг* «тиз, җитез».

**ҖИТЕН** «лен» — бор. тат. *йәтән* «җитен, җитен материя» бор. тк. *кәтән* «киткән, җитен тукыма» сүзеннән (Егоров). К. **Китән**.

**ҖИТМЕШ** «семьдесят» — гом.тк. *җитти, йәтти* «җиде» сүзенә *-мēш, -мēл* кушымчасы ялганып ясалган; к. кар. *йәтимес* «җитмеш», *алтымыс* «алтмыш», чув. *çитмēл* «җитмеш», *утмăл* «алтмыш».

**ҖИТ-Ү** «достигнуть» — гом. тк. *йәт-* «җитү, өлгерү, җитәрлек булу».

**ҖИ-Ү** *диал.* «есть». — к. **Җый-у**.

**ҖИЯН** «племянник» — төрки телләрдә киң таралган сүз: *мәс.* башк. *ейән*, үзб. *җиян*, якут. *сиэн*, бор. тк. *йэгән, чыкан* (*-кан // -кән, -ган // -гән* — нәсел-нәсәп терминнарында очрый торган кушымча) id.

**ҖИЯК** «оторочка» — фарсы. *зиһәк* «җияк» сүзеннән.

**ҖОМГА** «пятница» — гар. *җумга-т-ун* «җыен көне (җыелып намаз уку көне)» сүзеннән, *җәмәғә* тамырыннан (→ *җәмгыять*). Мөселманчылыкта җомга — атна ахыры, ял көне. Шуңа күрә татар сөйләшләрендә *йома, җома*, кум, н. телләрендә *җума* «атна».

**ҖОР** «остряк, шутник» — чув. *йăр* ~ тат. диал. *җōр, йōр* < гом. тк. *йур* «антилопа, дала җәйрәне» сүзеннән («шуның кебек елгыр» дигәннән). Чаг. диал. *җōрнай* «этләй (вьюн)».

**ҖОФАР** «выхухоль» — гом. тк. *йыпар, йубар, йаѓар* «мөшек, мөшекле җәнлек», безнеңчә гом. тк. *йы, йыѓ, йыд* «хуш ис» һәм *бар, пар* «барс, циветта (хуш исле бүленте чыгара торган мәчесыман җәнлек)» сүзеннән. К.Әхмәтьянов, 1980.

**ҖӨЙ** «шов» — тат., миш. *йу* (шуннан *йулә-ү* «кушып тегү»), чув. *çēвē, çӳ* < бор.тк. *йиги*, тк. *йив*, кк., ккк. *җик*, хакас. *чик*, алт. *дьик, йик* һ.б.; шуннан ук тат. *җек* «ике такта, ике бүрәнә арасындагы ярык» сүзе дә килә. Монг. *зүй, җүй* «җөй» төрки телләрдән булса кирәк. К.**Энә**.

**ҖӨМЛӘ** «все вместе; предложение» — гар. *җүмлә* id.; тат. әд. *җөмләтән* < гар. *җүмләтән* «бергәләшеп».

**ҖӨП** «четный, парный» — фарсы. *җүфт* «җөп, пар» сүзеннән; шуннан ук *җефет* «супруг»; бу фарсы сүзенең тагы бер чагылышы — *чүпләү, чүп-тар* «парлы буйлык, парлы аркаулык белән киндер сугу». Чаг. **Җөпләү-ү**.

**ҖӨПЛӘ-Ү, ҖҮПЛӘ-Ү** «поддакивать, одобрять чьи-л. слова» — тат. диал. *җүп күр-ү*, чув. *йӳп кур-*, ай., чыгт., көнч. тк. *йӧб*, монг. *цоб, цзуб*, тув. *чөп* (*чӧб*) «дөрес, ярашлы, ярый, әйбәт» сүзеннән. Ихтимал, бу тамыр фарсы теленнән борынгы алынмадыр. К.**Җөп**.

**ҖӨЯ** «система, место в системе» — кк., ккк. *җүйе*, кырг. *җүйө*, үзб. *җуя* id. Бу сүзнең килеп чыгышы безгә мәгълүм түгел.

**ҖҮР, ҖҮРӘ** «детеныш животных» — к. **Җәвер**.

**ҖҮРМӘ, ЮРМӘ** *диал.* «потроха; ливер» — к. кырг., кк. *җүрмӧ, җӧрӧм*, чув. *çӳреме, çӳрме* «ливер», кум. *яверме* «казылык, җүрмә», бор. тк. *йөргемеч* «ливер колбасасы» (МК). Сүзнең тамыры — бор. тк. *йөр-* «урау, чорнау».



**ҖЫЕН** «сход, сходка» — бор. *йыѓын* «җыелган нәрсә» (*йыѓын*) сүзеннән. Бу сүз күп мәгънәле. К.Әхмәтьянов, 1989: 147.

**ҖЫЙ-У** «собирать, собрать» — гом.тк. *йыг-* «җыю; туплау; җирләү, яшерү». Бу сүзнең мәгънә структурасы борынгы иҗтимагый шартлар белән аңлатыла: ул тәүдә, күрәсең, «запас туплап, чокырга яшерү»не, аннары «кардәш-ыруны туплап, ашсый бирү»не белдергән; кешене дәфенләгәндә дә ыру-кабилә җыелган. *Җый* < *йыѓ* тамырының исем мәгънәсе дә бар: тат. диал., башк. *йык* — чув. *йăх* «токым, зат, ыру, җәвер» — кк. *җык* «туплам; күп, масса».

Җый-у сүзенең «туплау-җирләү» мәгънәләренә рус. *хранить* — *хоронить* сүзләре аналогия.

Җый-у сүзенең тат. диал. *җи-ү* < гом. тк. *йэ-* «ашау» сүзе белән мөнәсәбәте ачык түгел; безнеңчә, аларның тамырдашлыгы шикле.

*Җый-* < *йыѓ-* тамырыннан төрки телләрдә бик күп сүзләр ясалган, мәсәлән, тат. *җыену, җыйнау, җыештыру, җыеру, җыерчык*. К. **Җыен**.

**ҖЫЛУ** «полынья» — бор. *йыл, йал* «сулы, юеш җир, күлдәвек» сүзеннән (чаг. **Елга**); к. диал. *җалу, йалу*, башк. *йылыу*, кк. *җылыш, җылым* «җылу, туш», чув. *йăлу* «җылу», *йăлка* «елгада туңмый торган урын, юеш», *йăлкка* «бик сыек баткак», *йăлма* «юеш, баткак», *йăлпаран-* «чиләнү, җебү» (Ашмарин); чаг. кк. *җул*, сагай. *чул*, бор. тк. *йул*, чув. *çол*, монг. *җулай* «чишмә, кизләү».

**ҖЫЛЫ** «теплый» — гом. тк. *йылы, йолу*, кар. *йыллы*, тат. диал. *җыллы* id. бор. *йул, җул* «җылылык; җылы чишмә» (к. **Җылу**) тамырыннан, шуннан ук тат. диал. һ.б. *йылы-, җылы-* «җылыну»; чаг. тунгус. *йулку* «җылу».

**ҖЫЛЫМ** «невод» — бор. тк. *ил- // йыл- // йал-* «бәйләү, үрү, элү, чалу». Эл-ү фигыленнән ясалган исем булса кирәк (Вамбери); к. кум., н. *йылым*, ккк. *җылым*, чув. *çилēм* «җылым», якут. *илим* «җылым, пәрәвез»; чаг. рус. диал. *илым* «җылым» (Даль).

**ҖЫР** «песня» — бор. тк. *йыраѓ, йураѓа* «җырлау» сүзеннән. К. тат. гом. диал. *җыру* «җыр», иск. *җыры-у* «җырлау», үзб. *җиримок* «җырлау», кум., н., иске тат., себ. тат. *йырау* «җырчы»; якут. *ырыа*, ~ чув. *йорă, йурă* < **йар* «җыр», монг., кырг. *җиргал, җаргал* «шатлыклы мәҗлес, концерт». Чаг. бор. ир. *jar, ǰar* «җарлау, җырлау».

## -З-

**ЗАМАН, ЗАМАНА** «время, эпоха, век; пора; период» — к.ш.ук тат. диал. *заман, замат*, чув. *саман, самант*, мар., удм. *замат, самат*, тат. диал. *зәмәт, сәмәт*, чув. *семен* «тиз генә, ашыгыч төстә, тәҗелләп», тат. диал. *замат, заматта* «вакытында», гом. кыпчак, үзб., уйг. *замат* «момент» барсы да фарсы *заман, замана, замат* сүзләреннән.

**ЗАР** «плач; жалоба» — фарсы. *зар* «зар, инәлү, мөшкел, нечкә, зәгыйфь» сүзеннән; шуннан ук *зарыг-у* (*зар-ык-*). Иск. әд. *зарый* фарсы. *зари* «инәлү, ялыну» сүзеннән, *зар-зар елау* фарсы. *зар-зар гирйа кардан* сүзеннән калька.

**ЗАТ** «род, потомство» — фарсы. *зад* «зат» сүзеннән, зан «туу, тумыш, нәсел, ул» тамырыннан (һинд-евр. *ghen «туу, нәсел»), иск. әд. *задә* «улы яки кызы»: *маликзадә* «малик улы (кызы)», *шаһзадә* «шаһ улы (кызы)» шулай ук фарсы теленнән һәм *зат* сүзе белән тамырдаш.

**ЗАЯ** «напрасно» — гар. *зай-а, зайг* «һәлак булган» сүзеннән.

**ЗӘВЫК** «вкус» — гар. *зәуқ-ун* «зәвык, тәм» сүзеннән. К. ш.ук. себ тат. *саук* «һәвәскәр», удм. *заук* «мелодия» — татарчадан.

**ЗӘГЪФРАН** «шафран» — гар. *зәгфәран* «зәгъфран» сүзеннән, шуннан ук рус. *шафран* (төрки телләр аркылы кергән булса кирәк).

**ЗӘЙТҮН** «олива» — гар. *зәйтун-ун* «зәйтүн, майлы агач», *зата* «майлау» тамырына нисбәт ителә, ләкин төптә Кытай порты *Цзяодунь* сүзеннән (зәйтүн элек шуннан китерелгән). *Сатин* сүзе дә шуннан. Чаг. «Бүзегет» дастанында *Зәйтүн* — чит ил егете.

**ЗӘМӘТ** *диал.* «сплошной забор» — гарәпчә *сәмәд* «койма, киртә, чик» сүзеннән үзгәргән.

**ЗӘҢГӘР** «синий, голубой» — гадәттә фарсы. *зәнгари* «зәңгәр буяу» сүзеннән (*зәң* «тутык, карасулык» тамырыннан) дип аңлатыла, ләкин бу сүзне төрки-монгол сүзе *сэнхэр* «аксыл-зәңгәр, күк», бор. тк. *чаңкар* «зәңгәр, аксыл» сүзенә дә кайтарып була (Санжеев); к. бурят. *сэнхир* «зәңгәр диңгез», *сэнхигэр* «зәнгәр», якут. *чаңкир* «зәнгәрсу, зәңгәр», телеут. *чаңкыр* «зәңгәр». К. **Чагыр.**

**ЗӘҢГЕЛӘ** «цинга, скорбут» — к. тат., диал. башк. әд. *зәңге*, чув. *сенкер-сехмет, синкер* «үләт, эпидемия», башк. диал. *сәң, сәнгале, сәнге* «зәңгелә» (рус. *цинга* — төрки телләрдән, мишәр сөйләшләреннән булса кирәк). Сүзнең тамыры — фарсы *зәңги, зәңгәри* «эрен, шеш». *Зәңгелә* янгырашы *зәңгәрәдән* үзгәргән. К. **Зәңгәр.** К.Әхмәтьянов, 1989:96—97.

**ЗӘҺӘР** «яд, отрава» — фарсы. *зәһр* «зәһәр, агу; үт» сүзеннән, шуннан ук к. **Зерә I**.

**ЗЕЛПЕ** «жимолость» — фарсы. *зулф* «толым, бөдрә» сүзеннән (асылда, гарәп сүзе булса кирәк) үзгәреп килеп чыккан; к. диал. *зелеф, зелеп* «зелпе», диал. *җилпе* «зелпе» халык этимологиясе нигезендә килеп чыккан сүз (чаг. **Җилпе-ү**).

**ЗЕРӘ I** «очень, в высшей степени» — фарсы. *зәһрә* «үтлек, үт куыгы, ачу, явызлык, кыюлык, үтә» (*зәһр* «агу, үт») сүзеннән борынгы заманнан ук кереп калган; к. чув. *сехер* «үт, курку, көлке», *сехре* «үт, курку, үтә, зерә». К.**Зәһәр**.

**ЗЕРӘ II** «зря» — рус. *зря* «бушка, юкка» сүзеннән.

**ЗИЛЗИЛӘ** «землетрясение» — гарәпчәдән. Гарәп телендә шундый сүз ясалыш моделе бар: *гаргарә* «өзлексез гырылдау», *каһкаһә* «мыскыллап көлү», *силсилә* «чылбыр, династия», *тантана* «(өзлексез) тантана», сүзләре татар әдәби теленә дә кергән.



**ЗИНДАН** «тюрьма» — борынгы Харәзем телендәге *зәминдан* «җирне казып ясалган төрмә» сүзеннән киң таралган. Ирани телләрдәге *зәмин* «җир, җирлек» (татар әдәби телендә дә очрый) рус. *земля* сүзе белән тамырдаш.

**ЗИНҺАР** «пожалуйста; ради бога» — фарсы. *зинһар* «(каргышымнан) саклан!» сүзеннән.

**ЗИРАТ** «кладбище» — тат. әд. *зыярәт* < гар. *зиарәт* «барып күрү, барып тору; барасы җир» сүзеннән, *зарә* «барып күрү, теге дөньяга бару» тамырыннан. Шуннан ук к. **Мазар**.

**ЗИРӘК** «сообразительный» — гом. тк. *сир-гәк* «зирәк, тиз сизүчән» сүзеннән, бор. гом. тк. *сәр-, сэгэ-эр-* «сизү» тамырыннан; к. тат. диал. *сиргәк* «зирәк», *сиркәк* «сизгер» ~ хакас. *сирэк* «зирәк, үткер күзле, сизгер», монг. *сэргэг* «зирәк, сизгер», *сэрэх* «сизү, уяну, сискәнү», бурят. *зээрэг* «куркак»; чаг. бор. чыгт., кк. диал. *серең* «сак, сизгер», госм. *зәйрәк* «зирәк». Фарсы. *зирәк* «зирәк» — төрки телләрдән. К. **Сәр-мәү**, **Сискән-ү**.

**ЗИРЕК** «ольха» — фарсы. *зирк, зирик* «барбарис талы» сүзеннән.

**ЗИТ** «против; противо-» — уйг., гом. кыпчак. *зит* < фарсы. *зид* id.

**ЗИФА** «стройный, статный» — фарсы. *зиб, зиба* «матурлык, сылулык; орнамент, бизәк» сүзеннән; к. диал. *зиба буй* «зифа буй», бор. тат. әд. *зиба* «матур, чибәр» (б > п > ф уйгур теленә хас).

**ЗУР** «большой, крупный» — бор. ирани. suura «зур, көчле» сүзеннән борынгы заманда ук киң таралган сүз. К. эстон. *суур* «зур», хәзерге фарсы телендә *зур, зор* «көчле».

**ЗУРАТ** «скирда» — рус. диал. *зарод* «озынча эскерт, киртәләп алынган кибәннәр төркеме» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1989:55.

**ЗЫБЫН** «зипун» — гар. *җуббун* «өске кием, плащ» сүзеннән тармакланып килеп чыккан һәм Көнчыгыш Европада киң таралган сүзләр рәтенә кергән: тат. әд. *җөббә*, диал. *чоба*, рус. *шуба, юба* (*юбка*), *зипун, жупан* барысы бер чыганактан.

**ЗЫЯН** «вред» — фарсы. *зиан* «зыян», бор. ирани. ziana (*зиана*) «кыенлык, зыян» сүзеннән.

**ЗЫЯНДАШ** «эпилепсия» — фарсы. *зиан дашт* «зыян иткеч» сүзеннән.

# -И-

**И-** (**и-де, и-сә, и-кән, и-меш**) — бор. тк. *ир-, әр-* «булу, бар булу» фигыленнән; к. иск. әд. *ирде, ирсә, иркән, ирмеш* < бор. тк. *эрди, эрсә, эркән, эрмиш* «иде, исә, икән, имеш». К. **Ит-ү**.

**ИБЛИС** «сатана» — гар. *иблисс-ун* «иблис» < бор. грек. *диаблос* «иблис» сүзеннән килә. Чаг. рус. *дьявол* ~ тат. (Х.Туфан) *явыл* «җен».

**ИГӘР** «охотничья собака» — гом. тк. *әкәр, экәр* «игәр, ау эте» сүзеннән, тамыры ачык түгел; к. диал. *экәр* «ата җәнлек, ата эт яки ата песи», кум., кб. *эгер, акар* «бурзай», уйг. *әңәр* «игәр», тув.

*экер* «шәп, егетләрчә» Көнчыгыш Европада күптән билгеле сүз; осетин. *эгар*, венг. *akar* «игәр».

**ИГӘРЧЕ** «остатки кислого теста» — к. чув. *икерчĕ* ~ мар. *егерче, игерче, эгэрцэ* «игәрче», *аварт'ыла* «әчегән камырдан пешерелгән ипи», хакас. алт., тув. *аарчы, ааржы*, монг. *аарц* «җогырт, кымыз, ачы камыр», якут. *аар* «кымыз» — бор. монг. *агарча* «ачыган камыр», бор. тк. **агартаг* «ачытылган» сүзеннән, *аг* «ачы» тамырыннан. К. ш. ук себ. тат. *арца*, калм. *арза* «молочная водка».

**ИГӘТ** «надел земли в составе приданого» — бор. тк. (МК) *эгәт* «кәләшне хезмәтләндерүче кол хатын-кыз», ләкин хәзерге төрки телләрдә *игәт* «бирнә; бирнә составындагы җир». Чаг. үзб. *эгат* «буразна»: утрак төркиләрдә кәләш кызның агасы аның исеменә берничә буразна җир сөреп чәчкән (бу гадәт мишәрләрдә бүгенгәчә саклана).

**ИГӘҮ** «подпилок, напильник» — бор. тк. *ик-әгү* «игәү» сүзеннән (*ик-, эк-* «кырый, чик»), чыгт. *әгәк*, кум. *эгак*, кум., н. *эгев* «игәү». Тат. *Игә-ү* «подпиливать» гом. тк. *әгә-, әкә-* «игәчләү, пычу» сүзеннән; чаг. кб. *йэйэ* «игәү», мар. *йака* «кыска пычкы» (бор.тк. телләрдән).

**ИГЕЗ** «двойня, близнецы» — бор.тк. *иккиз* < **йэки-рги* «икелек, икеләр» сүзеннән (к. **Ике, Егерме**); к. гом.тк. *иккиз, экиз* «игез», чув. *йĕкĕр* ~ мар. *йӹгӹр, йыгыр,* монг. *игир*, эвен. *игирэ* «игез».

**ИГЕЛЕК** «добро, благодеяние» — диал. *иге*, бор. тат. *әйге*, бор. тк. *эҙгү* «изге, яхшы» сүзеннән килә (к. **Изге**); чаг. диал. *ий* «яхшылык, күндәмлек» (шуннан *игә килү* «күнү»).

**ИГЕН** «хлеб, хлеба» — бор. тк. *экин* «иген», *экинчилик* «игенчелек» тат. *ик-* (~ чув. *ак-* < *äк-*) < гом. тк., бор. тк. *ек-, эк-* «иген игү» тамырыннан. Чаг. шумер. *ака* «иген игү». Мар. *игын* «иген», *игынче* «игенче» — татар теленнән.

**ИДӘН** «пол» — бор.тат. *ырдаң* «тигезләнгән җир, җир идән» сүзеннән (шуннан ук *ындыр*); к. чув. *йĕтем, итем* «ындыр табагы, ындыр», тат. диал. *идәм* «ындыр», *идин, идиң* «идән». К. **Ындыр**.

**ИДЕЛ** «Волга» — бор. тк. *Этил*, **Эртил* «Идел» сүзеннән (беренчел мәгънәсе һәм тамыры ачык түгел); Марко Поло Иделне Herdil дип атый. Ихтимал, *Иртеш* гидронимы белән бердәйдер (л ~ ш күчеше бар). Идел елгасы мари телендә *Юлга* һәм *Биче*, мордва телендә *Рав* дип тә атала.

Төркиләр Иделнең төп тармагы Агыйдел дип белгәннәр: ана Чулман — Кама һәм Күк Идел — Волга кушылдыклар дип каралган.

**ИҖЕК** «слог» — бор. тк. *уҗик* «хәреф, иҗек» сүзеннән, *уй, уҙ* «буын, кисәк, өлеш» нигезеннән; к. бор. язм. (МК) *уҗук* «хәреф, иҗек», монг. *үзэг* «хәреф»; чаг. алт. *үйэ*, якут. *уйэ*, бурят. *үйэ* «буын, иҗек, өлеш, кисәк; период».

**ИЗГЕ** «святой» — бор. тк. *әд-гү* «изге» сүзеннән, *ed/er* «яхшылык, байлык» тамырыннан; чаг. уйг. *әтку*, чыгт. *әзгу* «изге, яхшы», бор. язм. (Урхун) эд' «байлык, яхшылык». К.**Әйбер**.



**ИЗ-Ү** «размять, смять; месить» — гом.тк. *ĕз-* < **эйргь-* id.

**ИЗҮ** «нагрудник, вырез рубашки» — бор. *изег* «изү бавы, ялау» сүзеннән килә; к. башк. *иҙеү*, кум. *эзив* «изү», тат. диал. *изү* «җөй; чабу», *ису* «авызның ике як чите», кк. *из-* «тоташтырып тегү». К. **Ызма**.

**ИКЕ** «два» — гом.тк. *икки, йэки* «ике» сүзеннән, шул ук нигездән *егерме* (к.) һәм *игез* (к.)

**ИКЕНДЕ** «молитва, совершаемая мусульманами; время перед заходом солнца» — бор. тк. *икинди* «икенче; икенде» сүзеннән, *ике* нигезеннән.

**ИЛ** «страна; общество» — гом. тк. *әл, эл* «ил, халык; тынычлык, солых» (соңгы мәгънәсе буенча бор. тк. *элчи* ~ тат. *илче* килеп чыккан) сүзеннән. Чаг. шумер. *el* (эл) «якты, чиста җир».

**ИЛӘК** «сито» — гом. тк. *эл-гәк* «иләк» сүзеннән, *илә-ү* < гом. тк. *элгә-* «иләү, куллау» сүзеннән (*ил, эл, әл* «кул»).

**ИЛӘМ** «красота, благолепие» — чыгышы ачык түгел; чаг. чув. *илем* «иләм». К.**Ямь**.

**ИЛӘС**: **иләс-миләс** «легкомысленный» — бор. тк., кк., ккк., алт. *элес* «ефәк; силуэт», *әле-, элэ-* «булмаганны күрү, аягүрә саташу» сүзеннән. К. н. *элес алган, элесли* «җен алган, җенле, иләс, тиле», якут. *элес* «тиз генә үтеп китүче рух», *элес-батыр* «йорт саклаучы рух», *иләс-бәләс* «таркатылган, бозылган, иләс-миләс», чув. *элес-милес* «җил таркаткан» (*мәс.* чәч яки чүмәлә, салам өеме турында). К. ш. ук тат., башк., чув. *илер-*, кк., ккк. *елир-* «саташу, җен күрү, кинәт кычкырып җибәрү». Сүзнең тамыры — гом. алт. *эле* «очып йөрүче рух» (Поппе).

**ИЛГӘЗӘК** «радушный, приветливый» — диал. *алгазы* «шаян, алгасый торган» сүзеннән булса кирәк; к. диал. *илгәсәк* «илгәзәк, коллективист», *алгасак* «тынычсыз, илгәзәк, тере, чая» (фонетик үсеше *алгазак* > *элгәзәк* > *илгәзәк*). К. ш. ук ккк. *элгесе* «туганнарны сагыну», *элгесек* «туганын яратучан» (← *эл* «ил»).

**ИЛЕР-Ү** «беситься». — К.**Иләс**.

**ИЛЛЕ I** «пятьдесят» — гом. тк. *эллиг* «илле» — гом. тк. *әл, эл* «кул» сүзеннән; чаг. **Илле** II.

**ИЛЛЕ II** «ширина пальца, дюйм» — гом. тк. *элик* «илле, бармак киңлеге» — *эл, әл* «кул» сүзеннән; к. бор. язм. *элик, илик* «кул, бармак», үзб. *илек* «чирек аршин, карыш» бармакның билгеле бер озынлык үлчәве мәгънәсендә йөрүе төрки телләрдә еш очрый; чаг. башк. *иргәйел* «бармак буйлыгы, кечкенә буйлы кеше», бор. тк. *әрңәгел* «бармак буйлы», *эрңәк* «бармак».

**ИЛТЕР** «мерлушка» — бор. *илек тире* «болан баласының тиресе» сүзеннән; к. диал. *илек* «кыр кәҗәсе», алт., якут. *элик* «кыр кәҗәсе», монг. *ил* «болан баласы»; к. чыгт. *илтир* «кызгылт йонлы тун», бор. язм. (МК) *элдири* «углак (ылак) тиресе», куман. *әлтири* «кәҗә бәрәне тиресе»; чаг. башк. *куйтир, куйтыр* «куй (сарык) тиресеннән тегелгән тун».

**ИЛТИБӘР** (**илтабар** түгел!) «премьер-министр у булгар и пр. тюрок» — к. **Тип**.

**ИМ** «лекарство, целительное средство» — гом. тк. *эм* «им,

дару» сүзеннән; к. монг. *эм* «дару», *эмгэг* «авыру; имгәк»; бор. тк., монг. *эмгэ-* «имгә мохтаҗ булу», шуннан *имгән-ү, имгәт-ү*.

**ИМАНА** «надушный надел» — рус. *имена* «(списоктагы) исемнәр» яки *имение* «утар» сүзеннән (бу турыда күп авторлар яза).

**ИМӘН** «дуб» — гом.тк. *имән, эмән* «имән», чув. *йуман* «имән», кар. *әмән* «имән», себ.тат. *имән, ирмән* «тополь». **Әрем** (к.) сүзе белән тамырдаш. К.ш. ук. **Әрәмә, Урман.**

**ИНҖЕ** «приданое, состоящее из недвижимого имущества»— < гом.тк., монг. *энчи, өнчү* «балага атадан калган җир өлеше; *инче* һ.б. кытай. *инь цзы* «киленнең шәхси малы» сүзе белән чагыштырыла.

**ИНЕШ** «речка; ручей» — хакас. *iнiс*, кырым., куман., кум. *эниш* «авышлык, түбәлек, төшү» — тат. *иң-ү*, гом.тк. *эң-, эн-* «төшү, түбәнәю» фигыленнән. Чаг. чув. *анăç* «көнбатыш», *аниш* «түбәнлек». Шул ук *иң-* тамырыннан татар-башкорт телләрендә *иңкү, иңкел, иңкәю.*

**ИНЛЕК** «румяна» — бор. тк. *энлик* «биткә, йөзгә ягыла торган нәрсә» — бор. тк. *эң, эн* «бит, янак» сүзеннән; чаг. монг. *энгискэ* «инлек».

**ИННЕК** «забор (*разборный ряд жердей вместо ворот*)» — мар. *аньык-*, тат., башк. диал. *ин*, болг. **эн, эң* «керү урыны», тк. *in* «өн», тат., башк. *ин-* < тк. *эн-, эң-* «төшү; керү» сүзеннән.

**ИҢ I** «ширина ткани» — гом. тк., монг. *эң*, бор. тк. *эгин* «иң, киңлек» сүзеннән, шуннан ук *иңлә-ү, иңсә.*

Тат. диал. (мишәр) *иң, ин* ~ мар. *äң, аң,* чув., удм. *ан* «тукыма, киндер» Идел-Урал дистинктив сүзе булса кирәк. Мар. диал. *äңа, аңа*, чув., удм. *ана* «дисәтинә җир» — болгар. **әнә* < **әңәг* id. сүзеннән.

**ИҢ II** «самый» — гом. тк. *әң, әңгиң* «иң, бик, үтә» сүзеннән; к. якут. *үгэн*, уйг. *әгин* «иң»; чаг. уйг. *әгис* «камил, бөек».

**ИҢКҮ** «низменный» — бор. *иң-кег, иң-ег* «инкү, иңгән» сүзеннән; тат. *иң-ү* < гом. тк. *эң-* «түбәнәю, басылып керү».

**ИП**: **ипкә килү** «становиться податливым» — бор.тк. *әп*, тат. диал., уйг. *әп*, алт., кум., кк., кырг. *эп* «әдәп, юнь, булдыклылык» сүзеннән, шуннан ук *иплә-ү, иптәш*; ш. ук диал. *япьтәш, ятеш* «булдыклы, сәләтле, уңай» — бор. *йәп* «ип» сүзеннән.

**ИПИ** «хлеб» — татар-башкорт сүзе; чаг. тат. диал. *әппә* «мәми», бор. тк. *эбәк* (*балалар телендә*) «ипи», чыгт. *иби-* «ашау». Чаг. ш. ук аккад-шумер. *ери* «ипи пешерү», сармат. *апи* «Җир-ана».

**ИР** «муж; мужчина» — гом.тк., монг. *эр* «ир, герой» (тат. *ирән* < гом.тк. *эрән* «чын ир-егет, яугир»). Чаг. шумер. eren «яугир (воин)».

*Ир* < *эр* тамыры нигезендә *иркәк, иркәч, ирәмсе-* ясалган.

**ИРӘВЕЛ** «авангард; разведчик» — бор. тк., монг. *эрағул* «бергә-бер сугышырга сайланган сугышчы» — *эрэ-* «бергә-бер (иргә-ир) сугышу» сүзеннән.

**ИРӘК** «ставка, стоянка войск» — н. *ийрэк* «ат араны», бор. тк. *эриг* «тукталу урыны, ирәк». Чаг. **Ирү**.



**ИРЕК** «воля, свобода» — гом.тк. *эрик, эриг* «көч, куәт, ирек, ихтыяр», бор. тк. *әрк* «көч, куәт» сүзеннән; шуннан ук *иркен* < *ирек-ен*; ниндидер бер *ир* ~ *эр* тамырыннан.

**ИРЕН** «губа» — гом. тк. *эрин* id., *эр* «кырый, ирен» тамырыннан; к. тув. *эрик* «яр, кырый». К.**Ирнәү**.

**ИРЕН-Ү** «лениться» — к. **Ирү**.

**ИРКӘ** «ласковый; неженка» — көнч. тк., уйг., кк. *эркә, эркә* (исем һәм фигыль) «иркәлек, артык иркәләү», бор. *эр* тамырыннан (к. **Ирек**); к. чув. *иртех* «иркә булып киткән», *иртен-* «шаяру, иркәләнү».

**ИРКЕН** «просторный» — к. **Ирек**.

**ИРНӘҮ** «край посуды; рубец раны» — бор. тк. *әрнә, әрин-эг* «кырый, яр, чит» сүзеннән, *эр* «кырый, чит, яр» тамырыннан.

**ИРТӘ** «утро; рано» — бор. тк. *ир-тә, эр-тә* «иртәдә» дигәннән, *эр* «эртә (утро, рано)» сүзеннән; к. чув. *ир*, госм., чыгт. *эр* «иртә», эвен. *эрдә* «рано, утро», монг. *эртэ* «рано, в старину» бор. тк. телләрдән. Мар. *эр, ир* «иртә», *эрак, ирак* «иртә үк, иртүк», *эрденысе* «иртәгесе» һ.б. — бор. татарчадан. Тат. диал. *иртәк*, кк. *ертәк* «әкият», н. *эртек, эртеги* «әкият, борынгы хәлләр» сүзе дә *иртә* сүзеннән, к. кб., н. *эртде-эртде* «борын-борын заманда». К.**Иске**.

**ИРҮ** «привал; *диал.* медленно, не торопясь» — бор. тк. *эриг* «тукталыш» *эр-* «тукталу, ял итү» сүзеннән (шуннан ук *ирен-ү*, тат. диал. *ирек-ү* «ялыгу», *ирмәк* «ял итеп күңел ачу»).

**ИС I** «запах; угар» — бор. көнч. тк. *ийес* «ис» сүзеннән; к. ккк., кар. *ийис* «ис», кк. *иес* «ис», чув. *йыс* «ис килү, көю»; ненец. *йас*, коми. *ис* «начар ис; ис сизү» — төрки телләрдән.

**ИС II** «память, сознание» — гом.тк. *эс, э̄с* «ис, хәтер; сау аң» сүзеннән; чув. *ас*, мар. *äш, аш* «хәтер, ис». *Исәнгерә-ү, исер-ү* фигыльләре дә шуннан. К. **Исән**. Чаг. шумер. esig «сау, көчле; исән».

**ИСӘН** «здоровый; живой» — гом. тк. *эсэн* «исән, сау; бәхет», тат. диал. *изән-* «яхшы аңлау», *ис, әс* «аң, сау акыл» сүзеннән булырга мөмкин; к. Әхмәтьянов, 1989:97; к. **Ис** II.

**ИСӘП** «расчет, намерение» — чаг. **Хисап**.

**ИСӘР** «глупый» — *иссә-* «иссез, ахмак булу» сүзеннән, *әс* «ис» (к. **Ис** II) тамырыннан булса кирәк, кк., ккк., кырг. *эсәр* «исәр» һ.б. Чув., мар. *исер* (*исэр*) — татарчадан.

**ИСКЕ** «старый» — гом. тк. *эски* «иске, борынгы» < бор. *эз-ки* < *әр-ки* «борынгы, беренчел» сүзеннән; *эр* «иртә, алдын, элек» тамырыннан булуы ихтимал; к. сагай., тув. *эрги*, хакас. *ирге* «иске, элекке», якут. *эргә* «элекке, карт»; чаг. шор. *әзә* «элекке».

**ИС-Ү** «веять, дуть» — гом. тк. *эс-*, *әс-*, ткм. *өвус-* id. Чаг. **Ис** I.

**ИТ** «мясо» — гом. тк. *эт, э̄т*, «ит, тән» сүзеннән; чаг. тув. *эт* «ит», бор. ирани. *yt, yatta* ~ чув. *ӳт* «ит; тән».

**ИТ-Ү** «сделать, содеять» — гом. тк. *эт-* id. Барлык тикшерүчеләр бу сүзне бор. *эрт-* (*эр-* фигыленең йөкл. юн. формасы) диләр.

**ИТӘК** «подол» — гом. тк. *әтәк, әдәк* «итәк», бор. *әт-ә* «сөйрәү, тартып бару» сүзеннән булса кирәк (Рамстедт); чаг. чув. *арăк, аркă* «итәк», шулай итеп *әдәк // арăк* «итәк» ниндидер бер *äд // äр* тамырыннан. Чаг. **Җитәк**.

**ИТЕК** «сапог» — гом. тк. *этик, ат-ыг* «итек, аяк киеме» сүзеннән, *äт-* «бару, йөрү, басу» (Радлов) яки «киенү» (Рамстедт) мәгънәсендәге тамырдан; к. себ. тат. *ату* «итек», чув. *атă* «итек»; чаг. алт., уйг. *өтүк* «итек», якут. *этәрбәс* «итек».

**ИЧ** частица «ведь, же» — *һич* (к.) сүзеннән дип карала. Ләкин мар. ач «ведь, же», чув. *арче* «иде» < болгар. *эрче* «иде» сүзеннән.

**ИЧМАСА** «хотя бы» — *һич булмаса* тәгъбиреннән кыскарып килеп чыккан. К. Ш.Мөхәммәдевтә: «Харбинда, һич булмаса, чиснук күп иде, чиснук ашап, перцовка эчә торган идек».

**ИШ** «ровня, пара» — гом. тк. *эш, иш* «юлдаш, иптәш» сүзеннән; чаг. алт. *эш-* «иярү» (к. **Ышану**). Чаг. шумер. *eš* (эш) «масса». Чув. *йышши*, мар. *эшеже*, удм. *эшез* «ише, кебек» — татарчадан калька.

**ИШАН** «ишан» — фарсы. *ишан* «алар» (хөрмәтләү йөзеннән кеше турында күплек сандагы өченче зат алмашлыгы белән сөйләшүдән) сүзеннән.

**ИШАРӘ** «знак» — гар. *ишарәт-ун* «ишарә» сүзеннән; к. диал. *ишарәт* «ишарә».

**ИШӘК** «ишак, осел» — бор. тк. *әшйәк, эшгәк* «ишак» (МК) сүзеннән, *элш-* тамырыннан; чаг. алт. *эштәк* ~ тув. *элҗиг-эн* «ишәк».

**ИШЕК** «дверь» — гом. тк. *эшик, әшик* «ишек, капкач, ябу, чыпта, җәймә» — бор. тк. *әл-ик* «ябу (щит)» сүзеннән (*әл-* тамырыннан); к. чув. *алăк* «ишек, капка», *ашăк* «торыпша, кап».

**ИШ-Ү** «плести; грести» — гом. тк. *эш-* id.

**ИЯ** «хозяин» — бор. тк. *эга // эда* «ия, хуҗа» сүзеннән; к. уйг. *әгә*, үзб. *эга* «ия, хуҗа», бор. язм. *эди*, алт. *әзи* «ия».

Борынгы болгар мәҗүсилегендә *ия* сүзе «явыз рух, кеше аңына кереп урнаша торган шайтан» мәгънәсендә йөргән, шуннан тат. диал. *ияле* «җенле», чув. *ийе*, мар., н., удм. *ие, ия* «шайтан».

**ИЯК** «подбородок» — гом. тк. *әгәк, әнәк* «ияк, авыз тирәсе» бор. тк. *әң* «ияк, яңак, авыз» сүзеннән (чаг. **Яңак**); к. азәрб. *эң* «ияк».

**ИЯР-Ү** «следовать за *кем*-л.» — ~ мар. *ияр-*, чув., удм. *ер-* ~ гом. тк. *эйәр-, эдәр-, эгәр-* (тат. диал. *игәр-*). *Эз < из* сүзеннәнме?

**ИЯР** «седло» — бор. тк. *әгәр // эдәр* «ияр», бор. гом. тк. *әңәр* «ияр, яңгырчак» сүзеннән булса кирәк. Чаг. **Ыңгырчак**.

## -Й-

**ЙОДРЫК** «кулак» — бор. тк. *йумдурук* «йодрык» сүзеннән, ниндидер *дум- // нум-* тамырыннан; к. госм. *йумрук*, алт. *д'удрук*, монг. *нудурук, нудурка* «йодрык»; чаг. *йом-у* < гом. тк. *йум-* «йому». К. **Йомры**.



**ЙОЗАК** «замок» — бор. тк. *Д'урғағ «йозак» сүзеннән ниндидер *д'ур-*»тамырыннан»; к. кар. *йузак*, шор. *чодак* «йозак», монг. *цуурга*, мар. *ćура*, чув. *çăра* «йозак», куман. *jusxak* id.

**ЙОКЫ** «сон» — бор. тат. *ойо-кы < уйу-ку* «йокы» сүзеннән, бор. *уйу-* «йоклау, ою» фигыленнән ясалган исем; к. иск. әд. тат. *уйку*, бор. уйг. *удуку* «йокы», чув. *ăйăх, ăйăхă* «йокы».

**ЙОЛА** «обычай» гом. тк. *йула, йола* «йола» сүзеннән, көнч. тк. *йула* «җан, рух, әрвах, үлгәннең җанын чакыру (шайтан йоласы)», себ. тат., чув. *йăла* «төс, кот, чырай», морд. *ила*, мар. *йӱла*, удм. *йула* «йола» — татарчадан.

**ЙОЛДЫЗ** «звезда» — гом. тк. *йулдуз* «йолдыз» — бор. гом. тк. **йул-тургь* «йолдыз, яктырткыч» сүзеннән, *йула* «яктылык» **д'ул* «якты» сүзенә *-нур, -тур // -туз* кушымчасы (чаг. **Бал-дыз, Андыз**) ялганып ясалган сүз; к. чув. *çăлтăр* «йолдыз».

**ЙОМРАН** «суслик» — чув. *йăмран*, мар., удм. *юмыран-* гом. кыпчак. *йумран, йомран, жумран,* алт. һ.б. *йубуран, йувуран* (рус. *еврашка*) ~ бурят. *зумбаран*, маньчжур. *җумарган* «йомран» < бор. монг. *җумбарган* «соргылт җәнлек» (*җум* «соры», *җумбар* «соргылт»).

**ЙОМРЫ** «круглый» — *йом-у* < гом. тк. *йум-* фигыленнән.

**ЙОМША-У** «размягчиться, мякнуть» шуннан *йомшак, йомышак* «мягкий» — гом. тк. *йумуш-а* «йомшау» гом. тк. *йуң-* «йо» сүзеннән.

**ЙОМЫРКА** «яйцо» — бор. *йумур-ут-ка* «йомырка», *йумур // йум-ур* «йомры» сүзеннән, алт. *д'ымыртқа*, башк. *йомортқа*, чув. *çăмарта* «йомырка». Чаг. **Шомырт**.

**ЙОМЫЧКА** «щепка» — **Юн-у** (к.) сүзеннән; к. диал. *йунгы, җунгы, йуңгычка* «йомычка». Н. *йумурчка* «йомычка» сүзендә [*-р*] протетик юл белән килеп чыккан; чаг. чув. *турткăш* «тутый кощ», тат. диал. *кортлау* «котлау».

**ЙОМЫШ** «дело, поручение» — гом. тк. *йумуш* ~ чув. *йăмăл* «йомыш» ~ мар. *сомыл, сомылка* «йомыш, йомышчы» гом. тк. *йум-, д'ум-* «җәмәгать эшенә җыелу» тамырыннан, чаг. тат. *йӧмыл-*, үзб. диал. *йумул-* «бар көчкә чабу, бар көчкә тырышу».

**Йомыш** — **йомыл* бик борынгы (*л-ш* шуны күрсәтә) ижтимагый термин. Чаг. башк. диал. *йоман — юл* «йомыш — юл», *йомша-* «мөһим эш кушу»; *йомыш*, димәк, «дәүләт хезмәте» мәгъ. булган, к.иске тат. *йомышлы* «служилый». Төптә бор. тк. *йум* «күп кабилә-ыруларның бергә җыелып гыйбадәт кылуы» сүзеннән булса кирәк, чаг. удм. (бор. төрки телләрдән) *юмша-* «җыелып күңел ачу», *юмшан* «мәҗүси гыйбадәт һәм сабантуй», бор. кыпчак. *юмшан* «әремнәң бер төре» (аның илә ритуаль тәтәсләү уздырганнар).

**ЙОН** «шерсть» — диал. *җӧн, җөн, йөн*, гом. тк. *йун, йуң* > чув. *çам* id.

**ЙОНЧЫ-У** «утомляться, изумчиться» — диал. *йӧңчы, җӧнчы-, җөнче-, йөнче-* < гом. тк. *йунчы-, йунчу-* «йончу, арыкланып йоны чуалу» — *йуң* «йон» сүзеннән (башта бу сүз бары тик терлек-туарга гына караган).

**ЙОРТ** «дом; двор» — диал. *җорт*, чув. *çурт*, мар. *с'урт*, удм. *ӟурт* < гом. тк. *йурт* «йорт, төп биләмә, кышлау» бор. *йурыт* id. *йуры-* «кайтып йөрү» сүзеннән дип уйланыла. К.Әхмәтьянов, 1981:132.

**ЙОТ I** «голод, голодное время» — диал. *җӧт*, гом. тк. *йут* «ачлык» бор. **йу* «ачлык» сүзеннән: күчмәчелектә, терлекләр утлап көченгәндә, бозлавык булуы терлекләрнең ачлыктан кырылуына китергән.

**ЙОТ- II** «проглотить» — диал. *җӧт-*, гом. тк. *йут-*, *уйут-*, *йувут-*id. бор. *йу-* «эчү, йоту» сүзеннән; к. монг. *у-* «эчү».

**ЙӨГӘН** «повод, узда» — диал. *җөгәң*, гом.тк. *йүгән*, тув. *нүгэн* id. бор. *йүг, дьүг* «йөгән, йөгәнләү» синкретик тамырыннан; к. эвен. *нөг* «йөгән».

**ЙӨГЕН-Ү** «уставать; кланяться» — н., кум. *йүгүң-*, кырг. *җүгүн-*, чув. *çӑкӑн-* «йөгенү» бор. **йүк-* «иелә төшү» >> чув. *çӑк-* «егылу, аву» сүзеннән; *йөк* сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

**ЙӨГЕР-Ү** «бегать, бежать» — диал. *йуыр-у* «бежать рысью» һәм *йөр-ү* «ходить, курсировать, ездить» — барысы да бер нигездән булса кирәк, чөнки төрки телләрдә аларның мәгънәләре керешә. К.**Юырт-у.**

**ЙӨЗ I** «лицо, физиономия» — гом. тк. *йүз, йүзә*, бор. гом. тк. *йүрг, йүргә* < *йүгүргә* «йөз, маска» сүзеннән; к.монг. *нүгүр, нигүр* «йөз».

**ЙӨЗ II** «сто» — гом. тк. *йүз, йүүз* < бор. **йүгүргь* «йөз» > чув. *çӗр* id. сүзенең беренчел мәгънәсе «көтү, өер» булса кирәк; к. якут. *сүӧс* «өер, көтү»; чаг. ш. ук кк. *җүз, җүз* «кабиләләр берегe» К.**Йөзек**.

**ЙӨЗЕК** «кольцо» — гом.тк. *йүзүк* < бор. **йүргүг* >> чув. *çӗрӗ* бор. **йүз ~ *йүр* «буын» тамырыннан ясалган; к. алт. *йүстүк, дүстүк*, тув. *чүстүк* «йөзек» < **йүзлүг* «буынлык», тув. *чүс* «буын, бармак буыны», якут. *сүсүӧк* «буынтык, буынлык». Элек бармаклар һәм буыннар ярдәмендә санаганнар, һәм, шуннан чыгып, *йөз ~ йүз* «көтү, йөз данә» сүзен дә *йүз ~ йүр* тамырыннан килә дип уйларга мөмкин.

Чаг. ш.ук бор. рус. *узгь* «буын». К. **Өзәнге**.

**ЙӨЗЕМ** «изюм» — гом. тк. *йүзүм, үзүм* «йөзем, виноград» сүзеннән, чыгышы ачык түгел.

**ЙӨЗ-Ү** «плавать» — гом. тк. *йүз-* < **йүргь-* id.

**ЙӨК** «воз»— гом. тк. *йүк, д'у-к* «йөк», бор.гом. тк. *йү- // д'ү-* «төяләү, ташу» фигыленнән (Рамстедт); к. калм., бурят *зө-*, монг. *җүгү-*, эвенк. *д'үгу* — «күчерү, ташу»; рус. *тюк* бор. тк. *д'ук* «йөк» сүзеннән.

**ЙӨРӘК** «сердце» — диал. *җөрәк* ~ чув. *çӗре*, гом. тк. *йүрәк*, монг. *җүрүк* «йөрәк» сүзеннән, тамыр бәйләнешләре ачык түгел. Күп этимологлар *йөр-ү* гом. тк. *йүр-* «йөрү, хәрәкәтләнү» сүзеннән «хатыннар телендә» ясалган дип карыйлар; к. бор. монг. *җүрүкэн* «йөрәк, йөргеч».



# -К-

**КАБА** «пряслице» — гомуми мәгънәсе «табанчага утыртылган багана» булган Урта Идел дистинктив сүзе; к. мар. *кава*, удм. *кубо*, рус. диал. *коба* «казык»: беренчел мәгънәсе «уч, кул аясы» булган булса кирәк. К. тат. диал. *каба* «сука төрәне», мар. *коба, копка* «уч», *кова* «бәлҗә». Шул ук нигездән чув. *йопа, юпа* «багана; кабер өстендә кеше кыяфәтле багана» (чуваш телендә күп кенә сүзләр башында [*к*>*й*], мәс. *кар* > *йур* «снег» һ.б.).

**КАБАК I** «веко» — чув. *хупах, хопах-* гом. тк. *қабақ*, тат. диал. (мишәр.) *капкак*, хакас. *хахпаг, хапхах*, бор.тк. *капкаг* «күз кабагы, капкач» — бор. *кап-* «ябу, каплау» тамырыннан. Чаг. **Кабак** III.

**КАБАК II** «тыква» — удм. *кабак*, мар. *кавак*, чув. диал. *капак-*, гом. тк. *кабгак* «кабак, киң яфраклы үсемлек» (МК) — бор. кытай. *ху пах* «варварлар кабагы» сүзеннән дип уйланыла. Ләкин *ташкакбак*ның Урта һәм Үзәк Азиядә савыт буларак киң кулланылуын искә алсак, бу сүз гап-гади *кап-ак*, ягъни *кап* сүзеннән булып чыга; к. абазин. *каб* «кабак».

Рус. диал. *кабак, кабака, кебека* (шуннан *кабачки* «кабакчык, вак кабакның бер төре») төрки телләрдән.

**КАБАК III** «магазин, харчевня; кабак» — чув. *хупах, хопах*, мар. *кавак, кабак* «кабак, сыраханә», тат. диал. *кабак* «йорт, ихата» — татарның үз сүзе; к. бор. тат. *кабак* «шәһәр (кальга) капкасы». Алтын Урда чорында кабакчы «шәһәр капкасын саклаучы» булган. Н., кб. *кабак* «авыл, торлак; зур капка; киртә» бор.тк. *капуг, капаг* «махсус капка» сүзеннән (*кап-* «ябу, каплау» тамырыннан). Бу сүзнең китерелгән мәгънәдә формалашуына *күз кабагы* сүзе дә тәэсир иткән булса кирәк: элекке шәһәр капкалары астан өскә ачылган. К. кар. *қабақ* «шәһәр».

*Кабак* сүзенең хәзерге «мәйханә» мәгънәсе борынгы телебездә булмаган, ул рус теленнән килә.

**КАБАЛӘ** «договор» — гар. *кабалӓт* «кабул ителгән (шартлар)» дигән сүздән. Алтын Урда чорында бу сүз татар теленнән бүтән телләргә таралган; к. рус. *кабала* «гаделсез шартларда яллану», коми. *кабала*, морд. *габала* «кәгазь», удм. *куболо* «расписка». Казан дәүләте заманындагы *хаблә* «җир өчен салым» да шуннан.

**КАБАЛАН-У** «суетиться, торопиться» — диал. *кабала-у* «тегендә-монда сугылу»; татар телендә ясалган булса кирәк, *кабу* фигыленең интенсивлык дәрәҗәсеннән кайтым юнәлеш формасы; к. чув. *кып-* «кабу, тоту», *хыпала-* «кабалау, төрле нәрсәгә тотыну», *хыпалан-* «төрле нәрсәгә тотынгалау, кабалану»; хакас. *хабын-* «тотынгалау, ябышу, ашыгу, кабалану», *хаб-* «кабу» сүзеннән.

**КАБАН** «кабан» — гом. тк. *кабан* яки *кабан дуңгызы* (*доңгуз-у*) «кабан», беренчел мәгънәсе «күл, саз» булган булса кирәк; чаг. тат. *Кабан күле*; мар. *кубан* «сазлы»; Төньяк Кавказда *Кубань* елгасы һ.б.

**КАБАРЧЫК** «опухоль, мозоль, пузырь» — бор. *кабар-ығ-чык* «кечкенә кабарык» сүзеннән; к. тув. *хабарык* «кабарык, кабарчык»; *кабар-у* < *кап-ар-у* «кап булу, каптай булу». К.**Кап**.

**КАБАТ** «повторно; слой» — гом. тк. *кабат* «кат, пласт, ян» сүзеннән, нигидер *кап-, капа-* фигыленнән булса кирәк (*кабат-т*). К. **Кат** (I, II). Икенче яктан, *кабат* көнч.тк. *катап* «кабат, яңадан» сүзеннән метатеза булырга мөмкин.

**КАБ-У** «есть; брать в рот» — гом. тк. *қап-* ~ һинд-евр. *кар-, *кер- тәкълиди тамыр булса кирәк, бу сүзнен «каплау, ябу» мәгънәсе дә киң кулланышлы һәм бу тамырдан бик күп сүзләр ясалган. К. **Кабак, Капка, Капла-у.**

**КАБЫЗ-У** «зажечь, зажигать» — көнч. тк., кум. *кабыз-* «кабызу» — бор. *қап-қыз, қап-қыр* «кабындыру, (ут) каптыру» сүзеннән. К. **Каб-у.**

**КАБЫК** «кора» — к. **Кавык**.

**КАБЫРГА** «ребро» — гом. тк. *қабырқа* «кабырга» монг. телендә *-ка* аффиксы ярдәмендә ясалган; чаг. үзб. *қабыз* «кабырга».

**КАБЫРЧАК** «раковина» — гом. тк. *кабур-чак* «кабырчак; табут, көймә, тат. диал. *кубыр*, бор. *кабур* «тартмачык; сөкә; куыш һәм ябык савыт; кап» (к. **Кап**) сүзеннән булса кирәк; к. ккк. *қабыршақ* «юка тышлык, балык тәңкәсе», чыгт. *қауурчақ* «ташбака кабырчагы»; чаг. көнч.тк. *хааржчақ, харачах* «табут, әржә», монг. *хуурцаг, хайрцаг* «тартма, табут»; к. госм. *кабур, кабура* «кечкенә сумка, тартма» (шуннан рус. *кобура* «револьвер савыты»).

Төрки *кабырчак* «кимә» сүзенә рус. *ковчег* «көймә» сүзе дә тоташа. Төрки әдәбиятта кыпчак этнонимы да *кабырчакка* нисбәт ителә.

**КАВЫЗ** «мельничная канава, коробка мельничного колеса» — чув. *кавус, кавăс* «кавыз», гом. көнб. тк. *хавуз, һавуз* «су саклау өчен баз» — гарәп теленнән (*хаўўуз* «сулык») булса кирәк.

**КАВЫК** «перхоть; кора, чешуя» — гом.тк. *кабык, кабук* «кабык» сүзе белән тамырдаш һәм шуның тәэсирендә булса кирәк, ләкин *кабык* < *каб-уг* бор. *кап, каб* (к. **Кап**) тамырыннан, *қауық* < *қағ-уғ* бор. *қағ сүзеннән дип уйларга нигез бар; к. башк. *қау* «елан кабыгы»; к. чув. *хубы* (*хупă*) «кабык, кайры, кибәк, кавык».

**КАВЫЛ** «ковыль» — чаг. себ.тат., урал. *қау*, башк. *қау, қаулан* «чабылмыйча калган үлән, кылган». *Кау* тамырыннан. К. **Каудан, Каудар.** Рус. *ковыль* — бор. кыпчак теленнән. Борынгы яңгырашы *кауғал* булса кирәк; к. чув. *халхав* «дулкынлану; кауга», мордва телләрендә *кавал* «коры үлән, кавыл» (борынгы төркиләрдә былтыргы коры үләнне яндыру — *кауга* яки *каугал* дип аталган). К.Әхмәтьянов, 1989:30—32. К. **Гауга**.

**КАВЫН** «дыня» — бор. тк. *кағ-ун* «кавын, кыяр» сүзе төптә бор. кытай теленнән дип уйланыла.

**КАВЫРСЫН** «маховое перо птицы» — бор. тат. (диал.) *кағырсун* «кавырсын, каурый» сүзеннән, *қағыр* «каурый» нигездә жыйма күплек кушымчасы *-сун* (чаг. монг. *-сун*) ялганып ясалган сүз; чаг. диал. *қағырчын*, якут. *куорсун*, бурят. *гурагхан*, монг. *гуурагсан* «кавырсын, каурый». К. **Каурый**.



**КАВЫШ-У** «соединяться» — көнч. тк. *қабыш-* «кавышу, ялгану» сүзенә караганда, *кабу* (< *кап-у*) фигыленең уртаклык дәрәҗә формасыннан килеп чыккан, төрки *кауш-*, ккк., н. *кауус* «кавышу, берегү», *кауысар-у* «кул кушыру». К.**Куш-у, Кушыр-у.**

**КАДАК I** «гвоздь» — бор. тк. *када-ғ* «кадатыла торган нәрсә» сүзеннән (к. **Када-у**); к. н., кк., ккк. *қадақ*, чув. *хутах*, тув. *кадағ* «кадак, казык», алт. *қадығ*, тат. диал., кум. *қадау* «кадак».

**КАДАК II** «фунт» — башк., кк., кырг. *қадақ* «фунт» борынгы бизмән таягына кагылган вак кадакларны күз алдында тотып әйтелгән.

**КАДА-У** «колоть, уколоть» — гом. тк. *када-* «кадау» фигыленнән; чаг. бурят. *хада-ха* «кадау, тегеп кую».

**КАДӘР** «столько» — гар. *қăдăр-ун* «чама, үлчәм» сүзеннән, *қăдăрă* «үлчәү, чамалау» фигыленнән, шул ук тамырдан *микъдар* һәм *тәкъдир* сүзләре килә. Бәйлек буларак *кадәр* — *кадәрледән* кыскарган.

**КАЕЗ** «обработанная кора» — бор. тк. *қадыз* < *қадырғъ* «кайры, кабык» сүзеннән (к. **Кайры**); к. иск. тат. *қайыз* «кабык», бор. тк. *кадыз* «агач кабыгы» (МК); чаг. тат. диал., ккк. *қауыз* «балык тәңкәсе, кавык», кк., чыгт. *қауз, қабуз* «кибәк». К. **Каен**.

**КАЕК** «лодка» — гом. тк. *кайык* «каек, көймә» сүзеннән, бу сүз күп телләргә таралган; к. эскимос. *кай-ак* «каек, көймә» (чаг. *каен*) *кай тамырыннан; к. бор. тк. *кай-ғык* «каек» (МК), бурят. *хайба* «кыек».

**КАЕН** «береза» — гом. тк. *кайын* < *кадың* < *кар-г-аң* «каен» сүзеннән, бор. гом. тк. *қарг' тамырыннан булса кирәк; к. көнч. тк. *казың*, уйг., тув. *кадың* «каен, каен тузы», бор.тк. *хазын* «каен» (Әхмәт Ясәви), чув. *хурăн* «каен» < *каргын. Семантик типологиядән чыгып фикер йөрткәндә, *қайыз, қайык* һәм *қайын* нигезләре «туз, төрле әйберләр ясау өчен кулланыла торган кабык» мәгънәсендәге борынгы тамырдан ясалганнар.

**КАЕНСАР** «березняк» — бор. тат. *каензар* «каенлык» сүзеннән: *-сар* ~ *-зар* билгеле бер урынны белдерүче кушымча, ул фарсы-таҗ. теленнән кергән; чаг. диал. *усаксар* «усаклык», иск. әд. *гөлзар* «гөл үскән жир», *чәмәнзар* «чүп үләннәр үскән жир» һ.б., үзб. *пичанзор* «печәнлек».

**КАЕНЕ** «младший брат жены» — к. *каениш* < *каен энекәш* «шурин», диал. кайнә < каен инә «*каенана*» (мать мужа); мишәр. *кань* өлеше бор.тк. *кадың* «өйләнешү буенча кардәшлек» сүзеннән, нигидер *кад тамырыннан; к. хакас. *хазын* «хатын буенча кардәшлек», бор.монг. *кадум* ~ *кад-уң* «хатын ягыннан кардәшләр».

**КАЕР-У** «выдирать; загибать» — бор. гом. тк. *қад* → *қай-* «борып жибәрү, кирегә жибәрү, кайтару» фигыленнән ясалган (*кай-ыр* < *кай-ғар* яки башка шундыйрак нигездән); к. көнч. тк. уйг. *кайыр-* «каеру, кирегә бөгү, кайту, әйләндерү, кайтару». К. бор. тк. *кай-ды* «каерды» (МК). к. **Кайт-у.**

**КАЕШ** «ремень» — бор. тк. *кабыш* «каеш» сүзеннән (тамыр

бәйләнешләре ачык түгел); к. якут. *хатыс* «каеш», хакас. *хаас*, тув. *каас* «каелган билбау» — *кай-у* сүзеннәнме?

**КАЗ** «гусь» — гом. тк. *каз (қас, ғāз)* «каз, аккош» сүзеннән, бор. гом. тк. **карғь* «каз» тамырыннан; к. чув. *хур* «каз».

**КАЗА** «напасть, гибель, беда» — гар. *қаза* «каза, бурыч, үлемле яра» сүзеннән.

**КАЗАК** «бобыль; казак, казах» — гом. тк. *қазақ* «казак халкы», н., кум. *қазақ* «батрак» > мар. *ажак, ожак* id. бор. тк. **қаз-ғақ* «кар казып үлән табучы ат» сүзеннән (башта көтүдән аерылган атны белдергән булса кирәк; к. бор. тк., чыгт. каз- «кыргыйлашу, ялгыз тибендә йөрү (*ат турында*)» < бор. **карғь-* к.**Казан-у.**

Рус. *казак*, коми. *козак* «өйләнмәгән кеше, ирекле, бәйсез кеше» — бор. төрки телләрдән. Рус казакларын алпавытлардан качып киткән крестьяннар тәшкил иткән, шуңа күрә аларны төрки халыклар *казак* дип атаганнар; төрки казак элек-электән үзәкләшкән дәүләтләргә буйсынмыйча далада качып йөргән. Борынгы Казан дәүләтендә *казак* дип ялланган гаскәрине атаганнар (Шпилевский), шуннан *казаки, казакин* — татар солдатларының хәрби формасы. (Н.К.Дмитриев). К. Әхметьянов, 1989:164—166.

**КАЗАН** «котел» — гом. тк. *казан* < **каз-ған* < **қар-ған* «казан, түгәрәк чокыр» сүзеннән, **карғь* тамырыннан (тамыр мәгънәсе ачык түгел); к. бор. тк. *қазған* «казан» (Ибне Муханна), чув. *хуран*, гагауз. *харан* «казан». Чаг. һинд-евр. **cara* «казан». Чаг. ***Казан-у***.

**КАЗАН-У** «приобретать доверие кого-л.» — гом. тк. *казан-* < *казған-* «эшләп табу, запас җыю» сүзеннән, бор. *казға-у* «казып алу» фигыленнән булса кирәк; к. якут. *хасаан-* > эвен. *кахан-* (*каһан-*) «азык табу, азык җыю, кар астыннан казып үлән табу». К. **Казак**.

Тат. һәм гом. тк. *каз-, казы-* «копать» чув. ~ *хур-, хир-*, иске монг. *кару-*, *халха-* монг. *хар-* бор. **карг* тамырыннан *казык* сүзе ясалган булса, димәк, борынгы төркиләр җирне казык кебек корал казып эшкәрткәннәр.

**КАЗНА** «казна, клад основание *чего-л.*» — гар. *хәзинә* һәм бор. тк. *казнак* «казып яшерелгән мөлкәт» сүзләренең контаминациясе; к. диал. *кызана* «мич казнасы». Рус. *казна* — татар теленнән. *Казна*ның «лар, келәт, баз, ләхет (кыргыз телендә)» мәгънәсе борынгы заманнарда мал-мөлкәтне махсус чокырларга яшереп саклау гадәтеннән килә. К. Әхмәтьянов, 1989:111. Чаг. **Кәзәнке**.

**КАЗЫ** «жир, сало» — гом. тк. *казы* «казы, эчмай, казылык» сүзеннән, бор. **кар* тамырыннан; к. чув. *йур* «казы», бурят. *харма* «казылык, колбаса», монг. *карбиң* «корсак мае».

**КАЗЫК** «колышек, кол» — гом. тк. *каз-ык* «казык», бор. гом. тк. *қазынуқ-* id; к. монг. диал. *харху* «казык», венг. *karo* «казык» (бор. тк. телләрдән); чаг. монг. *хадху, кадамбу* «казык», алт. *кастык* «казык» *казан-у* сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

**КАЗ-У** «копать» — гом. тк. *казы-* < бор. гом. тк. **каргы-* чув. *хор-* > *хур-* ~ монг. *хар-, хару-*, ихтимал, *кар* сүзе белән тамырдаштыр, ягъни башта сүз карны казып үлән табу (*атлар турында*) мәгънәсендә булгандыр.



**КАЙ I** «какой, который» — гом. тк. *кай* «кайсы, кай» сүзеннән; бор. *қайу* «ничек, нинди» тат. һ.б. *кая* < *кайга, кайда, кайчан, кайсы*, тат. диал., гом. кыпчак. *калай* < *кайлай* «ничек» сүзләре ясалган. Чаг. фин., бор. ирани. *ки* «кайда?», рус. *когда, какой*. Шул ук тамырдан *кем*.

**КАЙ II** «горловой голос, горловое пение, которым исполняли эпос» — бу сүз татар һәм башкортларда XIX гасырда искә алына һәм күрше телләргә дә кергән: чув. *хай, хайлав*, мар. *ой, хай, ойло, хойло* «хикәя, әкият». *Кай* мәҗүси җеназа догасы мәгънәсендә йөргәнлектән, муллалар аны онытырырга тырышканнар, *Кайгы* сүзе, бәлки, *кай* белән тамырдаштыр.

**КАЙГЫ** «горе, печаль» — бор. тк. **кад* «гаҗәпләнү, аптырау» фигыль нигезенә исем фигыль ясаучы *-ғу // -ғы* аффиксы ялганып ясалган сүз (*кай-ғы*); к. уйг. *кайғу* «кайгы», *катку* «хәстәр», бор. уйг. *кадгу* «кайгы» (МК), госм. диал. *кат калмак* «хәйран калу» (Радлов). К. **Кай II.**

**КАЙГЫР-У** «горевать» — гом. кыпчак. *кайгыр-* id. *кайгы* сүзенең сыйфат мәгънәсеннән булса кирәк, ягъни *кайгы* сүзе бер даирәдә «кайгылы» мәгънәсендә булган һәм *кайгы-р-* «кайгылы булу» сүзе килеп чыккан.

**КАЙМАК** «сметана; сливки» — гом. тк. *каймак* «каймак, өре» сүзеннән, бор. *кай-* «кайнау» фигыленнән (*каймак* сүзенең беренчел төп мәгънәсе — кайнап суынган сөт яки шулпаның өстенә җыелган, яки савыт стеналарына утырган тәмле өресе); к. бор. болгар. *қайақ* «май, каймак» (МК), көнч. тк. *эт каймагы* «ит шулпасы», якут. *хоймох* «сөт төбе (кайнаганда төпкә утырган сөт)», монг. *кайы-мак, хайлмах* «каймак».

**КАЙНА-У** «кипеть» — гом. тк. *кайын-а-у* «кайнап тору» бор. тк. *кай-* «кайнау» тамырыннан.

**КАЙРАК** «точило, брусок» — бор. *кайыр-аг* «кайрак» сүзеннән, *кайра-у* фигыленнән; тамыры *қайыр* «кырчынташ».

**КАЙРЫ** «кора» — гом. тк. *кайыр, кайры* «кайры» — бор. тк. *кадыр-ығ* «кайры, кабык» сүзеннән; к. якут. *хотырык*, көнч.тк. *қазырык* «кайры» (Пекарский); чаг. фин. *kuori, kaarna* «кабык».

*Кайры тун* тәгъбирендә *кайры* «агач (тал, зирәк, имән) кайрысы кайнатмасы илә дупланган» дигән мәгънәдә.

**КАЙТ-У** «вернуться, возвратиться» — гом. тк. *кайт-* < *кайыт-* id.

**КАЙЧЫ** «ножницы, верхние концы стропил, скрепленные крестом» — гом. тк. *кайчы, каучы* «кайчы», бор. тк. *какчыр* «кайчы», **кабыктыр* «аркылы-торкылы нәрсә» сүзеннән, бор. гом. тк. *кап-* «уртага кысу, тешләп алу» (чаг. **Кымыт-у, Кап-**); к. тат. диал. *канчы, қанчы* «кайчы», монг. *кайычы, кайынчы*, фарсы (төрки телләрдән) *кайынчы* «кайчы», көнч. тк. (алт. *капту*, кар. *кыпты* «кайчы», хакас. *хыпла-, хыбыт-ла-* «кыстырып кисү», *хыпты* «кайчы», бор. монг. *кабчур, кабтур, кабтагур* «кайчы», монг. *хавчаар* «келәшчә, кыскыч».

**КАК** «сухой, сушеный; пастила» — гом.тк. *как* «коры, кипкән, каты кипкән жир, киптерелгән җимеш яки җимеш измәсе»

сүзеннән, бу бер бор. тамыр сүз булып, бик күп дериватлар биргән булса кирәк. К.**Какча, Какша-у, Каты, Коры.** Диал. *кагыт* «җимеш кагы» бор. *қақ-ы* «кору, кибү» фигыленнән ясалган исем (*қақы-т*).

**КАКУЛ** «хохол, чуб» — тат. диал. *кәкәл, кәкел*, кк., ккк., н., кырг., кб., кум. *кекил, кекел,* үзб. *кокил*, монг. *көкүл*, эвенк. *кекел*, якут. *көғүл* «маңгай чәче»; беренчел мәгънәсе — малайларның баш түбәсендә калдырыла торган толым: бу гадәт Тибетта, Кытайда, Кореяда һ.б. да бар. Туй вакытында егетнең какулын кызның толымына бәйләгәннәр, кайбер халыкларда (тув.) егет белән кызның толымнарын аралаштырып кисеп алып, гаилә символы итеп саклый торган булганнар («чәчен чәчкә бәйләү» тат. телендә шуннан килә). Рус., украин. *хохол* «баш түбәсе толымы, шундый толым йөртә торган халык (украиннар)» — кыпчак-куман теленнән. К.Әхмәтьянов, 1981:84.

**КАКЧА** «суховатый, жилистый (*о человеке*)» — *как* тамырыннан К.**Как**.

**КАЛА** «город» — чув. *хола > хула-* гар. *қалғä* «крепость, крепость башнясы» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан дип исәпләнә. К. **Каланча**.

**КАЛАЙ** «листовое железо; жесть» — Азия һәм Көнчыгыш Европа телләрендә киң таралган сүз, кк., ккк. *калайы* «бронза, аккургаш», чув., мар., удм. *калай* «металл», гар. *қалғи* «аккургаш», Кавказ телләрендә *калай, қалай* «аккургаш», грек. *калай*, серб. *калай* «аккургаш». Сүзнең чыганагы борынгы заманннардан бирле аккургаш чыгарыла торган Qualah (Малакка ярымутравында) өлкәсе (Абаев). Чаг. **Кула**.

**КАЛАК** «большая ложка; лопатка» — көнч. тк. *калак* «калак, кашык» сүзеннән, бор. гом. тк. **кал* тамырыннан; чаг. монг. *калбаға* ~ алт., тув. *қалбақ*, маньчж. *халба* «калак, кашык, калак сөяге».

**КАЛАНЧА** «каланча, башня» — бор. чыгт. *қалга-ча* «кечкенә крепость, бастион» сүзеннән; к. госм. *қаланча, қäлäнчä* «кечкенә крепость». Чаг. **Кала**.

**КАЛАЧ** «калач» — бор. тк. *кäлäч*, бор. рус. *колач* «калач, түгәрәк ипи», чув. *холач, хулаç*, мар., удм., үзб. *калач, кäлäч*, гом. тк. *калач, калас, калаш*, бор. кыпчак. *қалач* уртасы тишекле (бауга тезмәле) ипи». Төптә төрки сүз булса кирәк; к. алт. *калāч* «төңгер, бер яклы түгәрәк барабан».

**КАЛДЫРЧА** «сучило» — чув. *калтăрмас*, мар. *олдырчо, алдырцы* «блок; скалка». Тәкълиди нигездән (← *калдыр-колдыр килү, калдырдау* — тәгәрмәч турында).

**КАЛҖА** «творог из молозива; кусок мяса» — гом. тк. *калҗа, калйа* гарәп теленнән дип исәпләнә.

**КАЛКАН** «щит» — бор. тк. *калкан* «калкан» (МК), монг. *қағал-ға-ң* «каплавыч» сүзеннән, бор. монг. *қаға-* «ябу, бикләү, каплау» фигыленнән; к. көнч.тк. *калка* «ишек, капкач», монг. *кагалга* «капка», *халха* «ярдәм, яклау; ышык».

**КАЛПАК** «шапка, колпак» — фарсы. *кäллä-пак* «баш капла-



вычы, баш киеме» сүзеннән, борынгы заманнарда ук төрки телләргә кергән; шуннан ук тат., чыгт. *калфак*, диал. *кәлпәк* «түбәтәй», *кәпәч < кәлпәч < кәләпәч*, себ.тат. *кәләбәц* «очлы бүрек», *тәлпәк < кәлпәк* «түбәтәй, колаклы бүрек», үзб., кк., ткм. һ.б. *телпәк, тилпәк* «бүрек» ~ бор. рус. *клобукъ*, рус. *колпак* «калпак, биек бүрек».

**КАЛЫК-У** «подниматься, подняться» — гом.тк. *қалқ-* id. бор. *қāл-* «үсү» сүзеннән. к. **Калын**.

**КАЛЫМ** «калым» — гом.тк. *калың, калаң* «калым» сүзеннән, чыгышы ачык түгел; чаг. эвен. *хулу* «калым». *Калым*ны «кыз өчен кала торган байлык» (*кал-у* сүзеннән) дип аңлату — халык этимологиясе.

**КАЛЫН** «толстый (*о плоских предметах*)» — гом.тк. *калың* «калын, юан, куе, күп, бик, үтә» сүзеннән, бор. гом.тк. **қал* «үсү; ныклы, базык, зур» тамырыннан; к. тув. *қал* «ныклы», монг. *халхгар* «артык зур». К. **Калык-у.** Чаг. шумер. *кал, гал* «зур, биек».

**КАЛЫП** «колодка» — гар. *калап-ун* «калып», грек. *халлор* «калып» сүзеннән, рус. диал. *калыпь,* белорус. *кальпь*, серб. *калуп* «калып» төрки телләрдән булса кирәк.

**КАМА** «выдра, мех выдры или бобра» — бор. кимәкләр теленнән килеп чыккан сүз: удм. *кама*, мар. *ома, кома*, чув. *хăма* «кама»; сүзнең нигезе — гом.тк. *кам* «шаман, төрки рухани»; к. себ. тат. *камнауыц* (*камлавыч*) > хак. *хамнос*, шор. *камнағыс* «кама». Борынгы болгарда *кама* тиресе ярдәмендә *камлаганнар* (бу турыда Ибне-Фазлан язмаларында әйтелә).

**КАМГАК** «перекати-поле» — бор.тк. *каң-мак* «тәгәрмәч, тәгәрәгеч» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан, тамыры *каң-* «тәгәрмәч, арба» булса кирәк; к. кк. *каңбак* «камгак, тәгәрәгеч», *каңы* «арба», кырг. *каңа*, уйг. *каңга, каң* «көпчәкле арба», чыгт. *каңлы* «ике тәгәрмәчле арба» (кабилә исеме буларак та билгеле).

**КАМЗУЛ** «камзол» — рус. *камзол* сүзеннән, беренчел чыганагы — итальян. cammiciuola «кечкенә күлмәк» (Преображенский). Чув. *камсул*, мар. *камчол* «камзул» татарчадан.

**КАМКА** «камка; золоченая ткань» — кк., ккк., кырг. *қамқа*, рус. *камка*, таҗ. *кимхоп* «камка», чув. *канихвә* «камка» һ.б. *Хәтфә* (к). сүзе белән бәйләнгән. К. ш. ук **Камка.**

**КАМЧАТ** «узорчатый (*о ткани*); камчатский бобер» — бор. рус. *камчат, камчатка* «бизәкле тукыма» сүзеннән, бу сүзнең нигезе исә (*камка, камкят > камчат*) рус. теленә татар теленнән кергән. К. **Камка**.

**КАМЧЫ** «плеть» — гом. тк. *камчи, камучу, камчин,* монг. *камчун* «камчы», көнч. тк. *камды*, якут. *кымны* «камчы, кашау» — бор. тк. *кам-* «сугу, сыдыру» (МК) фигыленнән булса кирәк; тув. *камчы* «шаман чыбыркысы» — бу сүзнең гом. тк. *камчы* «шаман» сүзе белән бәйләнешенә ишарәле.

**КАМЫЛ** «стерня» — *камыш* (к.) сүзе белән тамырдаш булса кирәк, кб., н. *камыл* «камыш, камыл».

**КАМЫР** «тесто» — гар. *хәмир-ун* «ачытылган нәрсә, ачы

камыр» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; к. иск. тат. *хамыр* «камыр» — фарсы-таҗ. *хамир* «ачы камыр». К. **Хәмер, Камыр-батыр.** К.Әхмәтьянов, 1981:30—31.

**КАМЫТ** «хомут» — рус. *хомут* сүзеннән дип саналса да, рус сүзе үзе төрки телләрдән булса кирәк; чаг. башк. *кум*, бор. тк. *ком*, монг. *хом* «ияр астына салына торган киез, дөя камыты».

**КАМЫШ** «камыш» — гом. тк. *камыш*, бор. тк. *камуш* «камыш» бор. гом. тк. *камул, камыл* «көпшә-сабак» сүзеннән булса кирәк.

**КАН** «кровь» — гом. тк. *қан*, бор. гом. тк. *қāн* «кан» сүзеннән; к. якут. *хаан* «кан», чув. *йун* < **йан* < **киан* < **каан* «кан».

**КАНАТ** «крыло» — гом. тк. *канат*, бор. гом. тк. *кан-ат* «канат, канатлар» — нииндидер бик борынгы һәм киң таралган сүздән булса кирәк; чаг. чув. *ҫунат* < *җанат* < **йанат* < **кианат* < **каанат* «канат», фарсы. *каң*, гар. *җанак-ун* «канат, ян як; кул».

**КАНАУ** «канава» — бор. рус. *коновь* «канау, улак» сүзеннән, асылда, грек сүзе.

**КАНӘФЕР** «гвоздика» — барлык төрки һәм башка телләрдә киң таралып, төрле яңгырашлар алган сүз: бор.тк. *карамбул*, үзб. *калампур*, фарсы. *кәрәнфол*, бор. рус. *кануфер, калафур*, чув. *каләмпер* «канәфер». Асылда, гарәп теленнән.

**КАНӘТ** «милый друг» — чаг. бор. монг. *кани* «хәрби дус».

**КАНДАЛА** «клоп» — гом.тк. *кандала, кандалай, кандагай* ~чув. *хăнкăла, хăмăтла* ~ мар. *умдыла* «кандала», үзб. диал. *қанығ* «кандала, борча»; чыгышы билгесез сүз (*кан* сүзе белән баглыдыр дип уйланыла). Чаг. ш. ук фарсы *гандä* «кандала», *гандäнä* «кандалалар», *гандäги* «сассы» (чаг. тат. диал. *сассык* «кандала»).

**КАНТАР I** диал. *кәнтәр, кәлүтәр, кәлтәү, кантыр* «глыба, ком» — кум. *қантар*, чув. *катнар, катмар* «кантар, каткан балчык». Чаг. иске тат. *каңылтыр* — гом.тк. *каналтыр* «рудадан эретеп алынган металл; металл каткагы». К. **Кургаш**.

**КАНТАР II** «декабрь, январь» — гом. кыпчак. *күз қантар* «көз уртасы — октябрь», *кыш қантар* «кыш уртасы — январь», *йаз қантар* «яз уртасы — апрель». Чаг. **Кантар III.**

**КАНТАР III** *диал.* «безмен» н., кум., төрек. *қантар*, рус., болгар. *кантар*, азәрб. *ғантар*, гар. *қантар* «бизмән; авырлык берәмлеге (45 кг)» бор. грек *кентарь* «авырлык үлчәме» сүзеннән килә.

**КАҢГЫР-У** «скитаться, блуждать; шататься» — алт., шор. һ.б. *қаңгы* «ачыгавыз» сүзеннән (*кангы-р-*); к. ш.ук тат. диал., гом. кыпчак. *қаңгы-* «читтәрәк йөренү, тирәләү» — *қаң* «тәгәрмәч» сүзеннән булса кирәк. К. **Камгак.**

**КАП** «футляр; крышка» — гом. тк. *қап* «капчык, кап, футляр, сумка» белдерә, шул сүздән: *кабак* (күз кабагы), *кабык, кабырчык, капка, капкач* һ.б. ясалган; чаг. фарсы. *каб* «савыт, кыны». К. **Кабак**.

**КАПКА** «ворота» — бор. тк. *қап- // қап-а* «ябу, каплау» фигыленнән төрлечә ясалырга мөмкин: 1) *қапқағ* < *қапа-қағ* (чаг. тат. диал. *капкак* «капкач, капка»); 2) *қап-уға* (чаг. иск. тат. *қапу, қапуғ* «капка, кабак, күк капусы»). К. **Кап, Капкач.**



**КАПКАЧ** «крышка (*ведра*)» — *капка-ча* «кече капка» яисә *кап-кач* (*-кач* аффиксы да бар!) сүзеннән. К. **Кап.**

**КАПКЫН** «ловушка, капкан» — гом. тк. *капкан, капкун* «капкын» сүзеннән, *кап-* «эләгү, эләктерү, кабу» тамырыннан.

**КАПЛАН** «леопард» — бор. тк. *каплаң* «барс, леопард» *кап-* тамырыннан (*кап-лан*) булса кирәк.

**КАПША-У** «щупать» — монг. *хабша-* «учлау, тотып алу, аңлау» бу фигыльнең *кап-* «кабу» тамырыннан икәнлегенә дәлил. Иске тат. *капса-у* «уратып тоту; камау» сүзе дә шуннан ук.

**КАПЫЛТ** «вдруг, неожиданно» — чув. *хапăлт* «тиз генә», кк. *капылыстан*, ккк. *капылдан* — гар. *гафил* (*гафилдән*) «көтмәгәндә» сүзеннән үзгәреп һәм тәкълиди сүзләр калыбына кереп килеп чыккан.

**КАР** «снег» — гом.тк. *қар*, бор.тк. *қағар* > болгар. **һиар* > чув. *йор* > *йур* «кар». К. **Карт**.

**КАРА** «черный» — чув. *хора* > *хура* ~ гом.тк. *қара* бик күп сүзләргә нигез булган борынгы тамыр; монг. һәм тунгус телләрендә дә киң таралган. К. **Караңгы.**

**КАРАВЫЛ** «караул, стража» — чув. *хорал, хурал*, мар. *орал*, гом.тк. *қараўул, қаравул* < монг. *қарағул* «каравыл» — гом.тк., гом. монг. *кара-* (к. **Кара-у**) фигыленә монг. *-ғул // -кул* кушымчасы ялганып ясалган.

Монгол һәм кыпчак төрки хәрби-административ системасында кулланылган бик күп терминнар шул модельдә *-вул // -ғул* аффиксы ярдәмендә ясала торган була, шуннан татар телендә *багавыл, бөгәвел, иравыл, яртәвел, ясавыл* кебек сүзләр калган. К.Әхмәтьянов, 1989:148.

**КАРАГАЙ** «лиственница; *диал.* сосна» — күп кен төрки телләрдә очрый, ләкин сирәк; *-ғай* аффиксына караганда бу сүз монгол телләрендә бар: тамыры *кара* «черный», ягъни *карагай-* «кара кәүсәле агач» дигән сүз.

Татар телендә кайбер агач исемнәре (*нарат, өрәңге, чаган*) һәм үлән атамалары монгол теленнән килә.

**КАРАГАТ** «черная смородина» — *кара* (к.) һәм *ғат // қат* «җиләк» сүзләреннән ясалган кушма сүз; к. алт. *кат* «җиләк», *қарақат* «карагат», *кызылғат* «кызыл карлыган», бор. тк. *қат* «җиләк, җимеш» (МК).

**КАРАГАЧ** «карагач, ильм» — *кара агач* сүзеннән кыскарган.

**КАРАК** «вор» — гом. тк. *каракчы* «карак, угры, күзәтче» — бор.тк. *кара-ғ-чы* «күзәтүче, караучы» сүзеннән *-чы* аффиксы төшеп калып килеп чыккан, башка төрки телләрдә һәм кайбер татар сөйләшләрендә *қарақ* «күз карасы, күз алмасы». К.**Кара-у.**

**КАРАКУРА** «бурьян» — к. башк. *каракура, карагура*, бор. кыпчак. **каракура*, шуннан (кабарда, абазин телләрендә *кэрэ-курэ, каракура* «каракура» — бор. кыпчак-куманчадан).

**КАРАКҮЛ** «каракуль» — Урта Азиядә Кара Күл дигән күл исеменнән: каракүл мехын бирүче сарыклар (куйлар) башта шул күл тирәсендә яшәгәннәр дигән фараз бар.

**КАРАЛТЫ** «надворные постройки» — чув. *хуралтă*, мар. диал.

*оралты, каралты*, удм. диал. *каралты* — татар тел гыйлемендә кура алды сүзеннән дигән фикер бар, әмма безнеңчә бу сүз себ. тат., н., кум., госм. *каралты* «еракта каралып күренгән нәрсә, силуэт, карачкы» сүзеннән; *карал-* (чув. *хурал-*) «каралу, кара булып күренү» фигыленнән. К. Әхмәтьянов, 1989:133.

**КАРАМА** «вяз; вязки (*саней*)» — чув. *хурама-* тат. диал. *кары-* «ишеп бәйләү» фигыленнән *-ма* аффиксы ярдәмендә ясалган исем, ягъни «бәйләмә, бәйләмәлек» кебегрәк; яшь карама элек-электән төрле җайланмаларда беркеткеч бәй ясау өчен кулланылган: рус телендә дә *вяз* «карама», *вязать* «бәйләү» фигыленнән; мар. *соло* «чирән һ.б. бәе, карамасы; карама агачы».

**КАРАҢГЫ** «темный» — гом.тк. *караңгы, караңгу* id. *кара* сүзеннән яисә монг. *карангуй* «карагысыз, күргесез» дигәннән чыккан.

**КАРА-У** «смотреть, глядеть; пытаться» — гом. кыпч. *кара-* id. Кайбер төрки телләрдә юк. Бу сүзне борынгы монгол алынмасы дип уйлыйлар. Татар телендә *кара-* бик продуктив нигез — шуннан *каралу* (комиссия үтү), *караш, карата* һ.б. сүзләр ясалган. К. **Каравыл.**

**КАРАЧЫ** «один из четырех выборщиков хана, высший сановник» — *кара халык* вәкиле дигәннән булса кирәк, К.Әхмәтьянов, 1977:48—49.

**КАРАЧКЫ** «пугало, чучело» — бор. тат. *карач- кара-ч* нигезенә *-кы* (*-ку*) аффиксы ялганып ясалган сүз. *Карач* — нигезе диал. *карачман* «карасу (*кеше йөзе турында*)» сүзендә дә күренә; к. хакас. *харасгы* «караңгылык, караңгы».

**КАРБЫЗ** «арбуз» — фарсы. *харбуза* «карбыз», беренчел мәгънәсе — «ишәк кыяры» (к. бор. фарсы. *xara* «ишәк» ~ хәз. фарсы-таҗ. *хар* «ишәк» һәм бор. фарсы. bučina «кыяр»).

**КАРГА** «ворона» — гом. тк. *карға* «карга» — карга сыман кошлар чыгара торган авазны белдерә торган тасвирый яңгырашлы сүзләр нигезендә (*кар, карр*) ясалган; к. чув. *корак* «каркар», *курак* «чәүкә, карга»; чаг. эвен. *гурак*, гар. *ғураб*, рус. *грач*, латин. *corvus*, немец. *Krähe, Rābe* «карга».

**КАРГА-У** «проклинать» — удм. *карга-*, чув. *харка-*, гом.тк. *карға-*, гом. монг. *хара-* «каргау», бор. монг. *хрига-, харига-* «сүгү; ант итү» *кара* «черный» сүзе белән тамырдаш булса кирәк. К. бурят. *хара* «кара; явызлык», *харааха* «каралау; каргау».

Татар сөйләшләрендә *карған-у* «ант итү», ягъни «әгәр фәлән эшне эшләсәм, миңа фәлән явызлык булсын» дип, үз-үзенне каргау. *Карга-* нигезен бор.тк. **карығ* «җавап, карау» сүзенә дә баглап була. Гомумән, борынгыларның *каргау* йолаларын без белеп бетермибез, шуңа күрә *карға-у* сүзенең этимологиясен дә билгеләү читен.

Төрки әдәби традициядә *карга-у* һәм *алка-у* — антонимнар.

**КАРГЫШ** «проклятие» — *карга-ш* сүзеннән үзгәреп килеп чыккан яки башка төрки телләрдән алынган (к. уйг. *карғи-*, госм. *карғы-* «каргау» һәм шул ук телләрдән *карғиш, карғыш* «каргыш»); чаг. якут. *карғыс* «каршылык, явыз рух», тув. *харғыс* «тиран».



**КАРДӘШ** «родственник» — *карындаш* (бер карыннан туган) сүзеннән үзгәреп килеп чыккан; к. иск. диал. *кәрендәш*, кк., н. *карындас* «кардәш; кыз туган».

**КАРЛАУ** «лопатка (*для очистки лемеха от глины*)» — бор. *карла-г* «казыгыч, тырнагыч» сүзеннән, бор. *кары-ла* «казыну, тырнау» нигезеннән, *кары-* «казу» фигыленнән (к. **Казы-у**). к. диал. *карлак, карлач* «сабан калагы, шабала», чув. *карлав* «кечкенә көрәк, бәрәңге казыгыч».

**КАРЛЫГАЧ** «ласточка» — *кара* (к.) нигезеннән ясалган бер борынгы сүзгә бор. тк. *чиғай* «кош» сүзе кушылудан килеп чыккан дип әйтергә мөмкин булса да, сүзнең ясалышы ачык түгел, чөнки төрки һәм башка телләрдә бу сүзнең фонетик вариантлары бик күп: кк. *карлығаш*, үзб. *калдиргоч*, төрек. *карлаңғыч*, чыгт. *карачығай*, тув. *хара ачығай* (чыгт. *чығай* «лачын») «карлыгач», якут. *хараңачык*, бурят. *хараасгай*, монг. *хариачай*, эвенк. *карачугай* «карлыгач, чәүкә». Чаг. **Карчыга**.

**КАРЛЫК-У** «охрипнуть» — тамак төбе авазларын белдергән *кар // карк* сүзеннән (чаг. **Какыр-у**; к. алт. *каргырла-* «карлыгу», хакас. *харла-* «какыру, карлыгу», *харлык-* «томанлану, буылу», *харық* «карлыгу» ~ тат. диал. *карык-у* «карлыгу»), якут. *хар-* «томанлану, буылу, чәчәү» һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, *карлык-* сүзе *карыл-* яки *карла-* «карлыгу, чәчәү» фигыльләренең интенсивлык дәрәҗәсе формасы.

**КАРМАК** «крючок, удочка» — бор. *карма-гы* «тотып алу, кармый торган нәрсә» сүзеннән; к. гом. кыпчак. *кармак, карбак* «учлам, кармак» — гом. тк. характерындагы *карма-, карба-* «кармау, тоту, эләктереп алу» фигыленнән, бор. *кары* «кул, кулның бармаклы өлеше» тамырыннан. К. **Карыш**.

**КАРНАША** «плетеное лукошко» — *карна-ча* «кечкенә карна» сүзеннән булса кирәк; к. рус. диал. *карна* «тобра» (ат азыгы салынган капчык). Бу сүз үзе чуваш теленнән булырга мөмкин. Чаг. **Кәрендәс**.

**КАРСАК I** «низкорослый» — башк. *карһак-* тик татар һәм башкорт телләрендә генә: чыгт. (к. Радлов, II:206) *карс-* «түбән төшерү» фигыленнән булса кирәк.

**КАРСАК II** «корсак (*степная лисица*)» — башк. *карһак*, кк., чыгт., госм. *карсак* id., кырг. *карсақ* «чапкыр җәнлек» (>> мар. *карсак* «үр куяны»), хакас. диал. *харсах* «кеш тәпие».

Бу сүзнең этимологик дублеты — бор. тат. *кырса* ~ рус. *харза* << монг. *хярза, хярс* «Себер көзәне». Бу сүзләрнең борынгылыгы аларны тат., башк. *карсак* «тәбәнәк» сүзе белән тәңгәлләштерүгә шик тудыра.

**КАРТ** «старый; старик» — чув., мар., удм. *карт-* гом. кыпчак., тк. диал. *карт* «карт кеше, хөрмәтле олы кеше» бор.тк. *карыт* id., *кары-* «олыгаю, картаю» фигыленнән *-т* кушымчасы ярдәмендә ясалган (чаг. тат. *карый* <**кары-ғ* «бик карт кеше»).

Бор. *кары-* фигыле *кар* сүзеннән ясалган һәм башта «еллау, күп кар кичерү» мәгънәсендә булган (моның аналогиясен мар. *ий* «боз → ел → яшь» мисалында күрергә мөмкин).

**КАРТА** «толстая кишка» — гом. тк. *қарта* «карта, туры эчәк, карын» — бор. *қарнақ* < *қарын-ақ* «карынлык, карынчык» сүзеннән (чаг. *сәрдәк* ~ *сәрәнә*); к. якут. *харына, ханна, карынак* «карта». Чаг. **Карын**.

**КАРУ** «возражение; возмездие» — бор. тк. *кары-ғу* (яки *кар-ығ*) «кире кайтару, үч, җавап» сүзеннән, *кар- // кары-* тамырыннан; к. тат. диал., кырг., кб. һ.б. *қару* «көч, хәл», бор. тк. *қары «үч, җавап, каршылык», хакас. *харығ* «каршылык», бурят. *хари* «чит, ят», *хариха* «кире кайту; үч», бор. монг. *қариғу* «кару» һ.б. К.**Каршы, Карыш-у.** К.Әхмәтьянов, 1989: 111—112.

*Аның каруы* тәгъбире еш кына *аның каравы* дип әйтелә.

**КАРУН** «скряга» — Муса пәйгамбәрнең бабадаш энесе Карун исеменнән (Коръәндә әйтелгәнчә, ул гаять саран кеше булган).

**КАРЧЫГА** «ястреб» — бор. тат. *қарчығай*, бор. тк. *қартал чигай* «бөркет, лачын» (*қартал* «бөркет», *чигай* «кош, ерткыч кош, лачын») сүзеннән; к. тув., кк. *картыға*, көнч. тк. *картаҗағ* «карчыга», госм., чыгт. *карталҗық* «бөркет баласы», *картал* «бөркет, каракош», якут. *хардатчы* «карчыга». Чаг. **Карлыгач**.

**КАРШЫ** «против» — бор. *қар-ыш-ық* «карышучан» сүзеннән, *қары тамырыннан (к. **Кару**); чаг. алт. *қаршу* «дошман, корткыч», шор. *қарча* «кире, тискәре», телеут. *қаршу* «каршы, дошманлыклы», чув. *хирӗҫ* «каршы». Тат. *қарыш-у* — бор. *қары- фигыленнән.

**КАРЫШ** «вершок; пядь» — гом. тк. *кары* «кулның очыннан терсәккә кадәр өлеше» сүзе нигезендә ясалган сүз; к. тат. диал. (мишәр., питрәч) *кара, қәре — киләп* (озынлык берәмлеге) — 1 м, 1,5 м; себ. тат. *қарғын, қары,* алт. *қары* «терсәктән кулбашка кадәр», *қарыш* «карыш, учлам», үзб. *қарич* «карыш», бор. тк. *кары* «карыш, аршын», чыгт. *кары* «кул, терсәк, ике аршынга тигез үлчәм», куман. *кары* «беләк, аршын», якут. *хара,* чув. *хур* «ике беләк озынлыгы», бор. тк. *қарағ* «кул, беләк». Чаг. монг. *гар* «кул».

**КАСМАК** «поскребки (*напр.*, каши)» — бор. тк. *касмак кас-ың-гак* (?) «касмак, кайнау калдыгы» (чаг. **Каймак**) сүзеннән, ниндидер *кас- // кад-* («кайнау»?) тамырыннан; к. чув. *хысма,* кк., ккк. *касмак*, кум. *касмак* «касмак».

**КАСЫК** «пах» — бор. тк. *қас-, қасы-* җыерчыкландыру, бору, киткәләү, тигезсезләү» фигыленнән булса кирәк; чаг. госм., кырым. *қасық* «җыерчыклы урын (*тәндә*)», *қас-* «кыскарту, бәрү, җыеру», *қасы-* «җыерчык ясау» (Радлов), төрек. *кас* «мускул».

**КАТ I** «слой, пласт, этаж» — гом. тк. *кат, кāт, кабат* (к. **Кабат**) «кат, катлам, кырый, ян (ишек каты)» сүзеннән; к. тув. *каът* «кат, рәт, тышлык, кабат», шул ук нигездән тат. диал., гом. тк. *катар* «рәт, рәттән», *катмар* «кат-кат торган». К. **Кат-у II.**

**КАТ II** «раз» — гом. тк. *кат* id. ~ бор. *ката* «рәттән, өзлексез».

**КАТА** «валяные галоши» — чыгышы ачык түгел; чаг. монг. *кутасун* «итек»; рус. *коты*, башк. *ката* «тояк» икенчел булса кирәк.

**КАТАУ** «укрепление, крепость» — бор. *ката-у* «көтү, көтү саклау» ~ тув. *ката-* id, сүзеннән; к. бор. уйг. *катағла-* «корал илә саклау», чув. *хӳте* «койма, дивар» << болгар. *катау id.



**КАТ-У I** «затвердеть; загрязниться» — чув. *хыт-*, гом. тк., гом. алт. *қат-* < *қагт-* id. бор. *қағ* «кипкән, каткан» тамырыннан, шуннан ук *каты* (бор. тк. *каттыг*) «твердый», себ. тат. *катрац* «жесткий» һ.б. К. **Кау.**

**КАТ-У II** «сучить; заправлять» — чув. *хут-* id. бор. синкретик *қат-* тамырыннан; шуннан төрки телләрдә бик күп сүзләр ясалган: тат. *катлау, катна-у, катыш-у, катык.*

**КАТЫК** «катык (*национальный сорт кефира*)» — гом. тк. *катық* < *катығ* «ашка катыла, кушыла торган нәрсә» — гом. тк. *кат-* «кушу» фигыленнән ясалган; аның төрле мәгънәләре дә шуны күрсәтә: бор. уйг. *қатық* «аш серкәсе», гагауз. *қатық* «өстәмә ризык», бор. тк. *қатық* «аш тәмләткеч», тув. *кадығ* «бутка», азәрб. диал. *ғатых* «соус».

**КАУ** «прошлогодняя сухая трава» — бор. тк. *қағ* < *қаға* ~ монг. *хаға* «коры, кипкән» — бор. тамыр сүз. К.Әхмәтьянов, 1989:30—32.

**КАУГА** «кожаное колодезное ведро; *ист.* барабан» — монг. *кобуға, ковға, кōға* ~ кырым. *қопқа*, госм. *қова, қован* «тире чиләк, цилиндр». *Гауга* сүзе белән багланышы халык этимологиясе тәңгәлендә генә.

**КАУДАН** «прошлогодняя трава; стерня» — *-қау* сүзеннән, монг. *-дан* кушымчасы кушылып ясалган. Чаг. тат. диал., бор. чыгт. *қаулан (кавыл-ан)* «каудан». К. **Каудар**.

**КАУДАР** «торопливый, нетерпеливый» — к. диал. *қаудар, каудыр* «каудан, кипкән каракура» ~ кк., ккк. *қаудыр* «коры, кипкән». Бурят., якут. *хагдар-, хагдарыг* «кору, кибү» — *қағ* «коры, кипкән» тамырыннан (к. **Кау, Каудан**). Сүзнең *-дар* өлеше монгол телләреннән дип исәпләргә мөмкинлек бирә. К. ш. ук **Кавыл**.

**КАУРЫЙ** «перо (*птицы*)» — бор. *каур-ығ* «каурый» — *кауыр, кағыр* «каурый сабагы» сүзеннән, ниндидер *кағ* тамырыннан; к. тат. диал. *қауырғый* «каурый», *қауыр* «каурый, кавырсын» — хакас. *каар* «каурый», ихтимал, *каурый-* курай (к.) сүзе белән бер нигездәндер; к. себ. тат. *каурай* «курай», *кауырсын* «камыл, курай» (Тумашева). К. **Кавырсын.**

**КАУША-У** «смущаться, растеряться» — гом. тк. *қағша-, қақса-* «кибеп какшау, каушау, хәлсезләнү» — бор. *қағша-* (МК) «хәлсезләтү» сүзеннән (шуннан ук *қақша-у*); к. кк., ккк. *кауса-* «кибеп какшау, бөлү», чув. *хакша-* «корып кибү, зәгыйфьләнү», *хавшак* (тат. диал. *каушак, какшак*) «муртайган, мәлҗерәгән» сүз тамыры *как* (к.).

**КАЧКЫН** «беглец» — *кач-у* (к.) фигыленнән; кайбер төрки телләрдә *качкын* «качып киткән кеше» түгел, ә «качып бару, паника».

**КАЧ-У** «убегать, избегать» — гом. тк. *қач-* id.

**КАЧЫР** «мул» — гом. тк. *качыр*, монг. *качыр, катыр*, гом. тк. *қат-* «кушу, өстәү» сүзеннән (Рамстедт). К. **Кату II.**

**КАШ** «бровь, возвышенность, крутой склон, бровка» — гом. тк. *қаш, қас* «биегәеп торган кырый, ян, кырый, каршыдагы калкулык, текәлек»; шуннан ук *кашак, кашага, кашка, кашлак.*

**КАШАГА** «бордюр, занавеска» — бор. монг. *касиға* «ихата, кура, тирәсе киртәләнгән урын, киртә, стена» сүзенең *каш* (к.) сүзе белән контаминацияләнүеннән килеп чыккан; к. көнч.тк. (алт., кырг., уйг.) *кажа* // *каша* // *каса* «кура, лапас, абзар», тув. *қастыг* < *қаш-лыг* «кашага». Чув. *кашака, хавшака* «тәрәзә (ишек) яңагы, кашага» татар теленнән булса кирәк.

**КАШАУ** «скребница» — чув. *кашав*-, ткм. *ғашав*, азәрб. *ғашов*, госм. *қашағы*, бор. тк. *қашағу*, якут. *кысыах* бор. тк. *каша*- «ат тәнен кыргычлау» сүзеннән. *Кашау* сүзе күп кенә төрки булмаган телләргә дә үтеп кергән (*мәс.* Кавказ телләрендә *хашав* «кашау»). Чаг. бурят. *хосо*- «кыргычлау».

Себ. тат. *качау, кацау*, мар. *кашаргы* «чөй, очлы таяк, өтерге» сүзе дә, ихтимал, *кашау* сүзе белән бердәйдер.

**КАШБАУ** «кашбау (*женский головной убор*)» — мар. *кашпау, капу, ошпу* ~ чув. *хошпу, хушпу*, удм. *кашпу*, рус. диал. *кошпа*, башк. *кашмау* id. Бу сүзнең аңлатмасы бик гади кебек (*каш* + *бау*) күренсә дә, монда катлаулы моментлар юк түгел: *каш* биредә тән әгъзасы түгел. (чаг. *йөзек кашы*); к. **Кар**. → *кашбағь* «бизәкле билбау» — азәрб. *ғашбәнд*, фарсы. *қашбӓнд* id.; *бау* сүзе дә биредә кытай. *мау* «кәпәч» сүзеннән дилэр.

**КАШКА** «белая отметина на лбу» — гом.тк. *қашқа* — гадәттә, «кашы ак» сүзеннән дип аңлатыла, ләкин сүзнең этимоны тирәнрәк булса кирәк; к. диал. *қашқар* «кашка» («Алланың кашка тәкәсе» — корбан чалуга билгеләнгән кашка тәкә, төрки халыкларда кашка малны Алла үзе тамгалаган дип уйлап, корбанлык сыйфатында симерткәннәр); чаг. шулай ук алт., тув. *калка* «маңлай», *калйак* «пеләш», монг. *калчыгай* «пеләш», *калчак* «кашка». К. **Кашкалак.**

**КАШКАЛАК** «лысуха» — *қашқа* (к.) сүзеннән (кашкалакның маңлае ак була); чаг. диал. *кашкалдак*, госм., азәрб. *кашғалдак* «кашкалак».

**КАШКАРЫЙ** «астра» — к. диал. *кашгарый* «кашкарый, астра, кашгар гөле» (*Кашгар* — Синьцзяньдә бер зур өлкә).

**КАШКЫР** «степной волк» — тат. диал., кырг. *качкыр, карышкыр*, үзб. диал. *қаршқул*, гадәттә, *карыш курт* тезмәсеннән дип аңлатыла: *қарыш* «усал» (к. чув. *хăрушă* «хәтәр, явыз») + иск. тат. *корт* < бор. тк. *курт* «бүре». Чув. *кашкăр* «бүре» — татар теленнән.

**КАШЛАК** «косогор, скат горы» — *каш* (к.) сүзеннән; к. диал. *қаш* «калку җир, үр, текә тау», *кашлык* «кашлак», алт., кк. *кас* «каш, елганың текә яры, калку яр».

**КАШЫ-К** «ложка» — бор. тк., монг. *кал*- тамырыннан, *қалақ* (к.) сүзе белән бердәй нигездән дифференциацияләнеп килеп чыккан булса кирәк (Дмитриев). Чаг. *ишек* ~ чув. *алăк* <*alik.

**КАШЫ-У** «чесать» — гом. тк. *кашы*- // *касы*- «тырнау, тырнак, кыру» сүзеннән; к. ш. ук кк. диал. *каша-у* «казу, сөрү», себ. тат. *качау* «өтерге белән тишү», бурят. *хосо-хо* «кыру». К. **Кашау.**

**КӘБЕН** «брак; бракосочетание» — фарсы-таҗ. *кабин* «калым, хатын малы, никах» сүзеннән.



**КӘБЕСТӘ** «капуста» — рус теленнән, рус теленә исә Көнбатыштан кергән (итальян, *капуцца* «баш, кәбестә башы»).

**КӘВӘРӘ, КӘБӘРӘ** «скатка теста; заготовка детали» — үзб. диал. *кәбәрә*, алт. *кебер* (кәбэр) «сын, сурәт» — бор. тк. *кәп* (> чув. *кап*, себ. тат. *кип*) «сын, сурәт, форма» сүзеннән. Бор яңгырашы *кәбирәң*. К. **Кипрән**.

**КӘВЕШ** «кавуши (*национальные мягкие кожаные калоши*)» — диал. *кәбич*-, үзб. *кавуш*, фарсы. *кафш*, сугди. kvš «кәвеш», беренчел мәгънәсе — «патша кигән алтын ката».

**КӘГАЗЬ** «бумага (*письменная*)» — мар., удм. *кагаз*, морд. *кагод*, чув. *киакас* — киң таралган сүз, татар теленә гарәп-фарсы даирәсеннән кергән: к. фарсы. *кағад*, гар. *кағад-ун*, уйг. *кӓғат, кағат* «кәгазь», тат. диал. *киагаз, кыягаз, йагаз, җәгаз*: [*й-, җ-*] ~ [*ч-*] күп телләрдә күзәтелә; алт. *чагазын*, монг. *чагасун* күп телләрдә уртада [*-р-*] килеп чыга: бор. монг. *чагалсун, чагарсун*, бурят. *сараһоон*, грузин. *кагарди* «кәгазь»; хәзерге *кәғәз* яңгырашы гарәпчәдән булса да, соңгы тикшеренүләр буенча бу сүз төрки *кағыт* (тат. *қақ, қағыт*) «юка гына җәелгән җимеш измәсе» сүзеннән (гарәпләр бу сүзне халык этимологиясе буенча *кғз* «сөзү» тамырына нисбәт иткәннәр); борынгы кытайлар кәгазьне нәкъ кагыт койган шикелле ясаганнар.

**КӘЕФ** «настроение» — гар. *кәйф-ун* «яхшы кәеф», күңеллелек» сүзеннән.

**КӘҖӘ** «коза» — бор. тк. *кәчә, кэчи* «кәҗә» (МК) сүзеннән, киң таралган сүз; к. рус. *коза*, латыш. *каза* (*kaza*), ихтимал, скиф телләреннән таралгандыр, тат. диал. *кәзә* рус. *коза* тәэсирендә килеп чыккан, кәҗәне куу ымлыгы *көҗҗә* — *кәҗә* сүзенең борынгы бер фонетик вариантыннан булса кирәк; тат. диал., үзб. һ.б. *ички, кички* «кәҗә», бор. тк. *кәч-кә* «кәҗә»; к. венг. keszeke ~ keszke (*кэчкә*) ~ чув. *качака* «кәҗә».

**КӘҖҮЛ**: **кәҗүл күн** *разг.* «козловая кожа» — рус. *козел* «кәҗә тәкәсе; кәҗә тиресеннән эшләнгән күн» (Даль) сүзеннән.

**КӘЙ** «плохой; дрянной» — бор. тк. *кәй* (> чув., мар. *кай*) «соңгы, кәй» < гом.тк. *кэй, кэд, кэт, кэз* «соң, арт як» сүзеннән; *кәй, кей* нигезендә тат. диал. *кәйен*, үзб. *кейин* «соңынтын; соң» сүзе һәм *кинҗә* (к.) сүзе дә ясалган; к. Әхмәтьянов, 1989:58—59.

**КӘЙЛӘ** «кайло» — к. кк. *кайла*, фарсы - гарәп. *хәйл* «кәйлә, китмән».

**КӘЙТӘН** «басон (*о шнуре*)» — госм. *кайтан* id. сүзеннән; чыгышы борынгы *Каййета* дигән шәһәр исеменнән (Преображенский), рус. *гайтан* «кәйтән» госманлы теленнән; к. грек. *гайтани*, латин. *caytani* «кәйтән».

**КӘКРЕ** «кривой, согнутый; крюк» — мар. *кагыр*, чув. *какăр* — бор. тк. *кәкру, кәйре*, халыкара *кәк, как* «кәкре» тамырыннан; к. чув. *кукăр, куклек*, мар. *каклэкэ* «кәкере», чув. *куклен*- «бөгелү», *куклет*- «бөгү». Чаг. ш. ук монг. *каҗи* «кәкре», фин. *käurä*, эстон. *käär* «кәкре».

**КӘККҮК, КҮКЕ** «кукушка» — бу кошның тавышын бел-

дергән тәкълиди (ияртем) сүздән, барлык телләрдә дә диярлек охшаш яңгыраш алган; к. рус. *кукушка*, таҗ. *кәккук, какук*, фарсы. *куку*, әрмән. *кәку*, немец. *kuckuck*, грек. *кокку*, латин. *сисu*, венг. *каккик* (*каккук*), бурят. *хухы*, грузин. *гугул* «кәккүк».

**КӘЛӘВӘ** «калеве» — гар. *хәлуә* сүзеннән булса кирәк (Абаев; к. **Хәлвә**), үзб. *калаwа* «калач, күмәч».

**КӘЛӘПҮШ** «тюбетейка» — фарсы-таҗ. *каллапуш* «кәләпүш» сүзеннән, фарсы. *калла* «баш» һәм *пуш* «каплавыч» (*пушидан* «каплау, ябу») сүзләреннән; к. диал. *кәллә* «түбәтәй».

**КӘЛӘШ** «невеста, сговоренная девушка» — иске тат. *кәләш*-ү «сөйләшү, кыз ярәшү» (кырым, кар., кб., кум. телләрендә дә очрый) сүзеннән; к. чув. *калаş*- < **käläč*-, тат. диал. *кәлә-ү* «сөйләү» (шуннан рус. *калякать*); бор. *кәл* «тел» .

**КӘЛҖЕМӘ** «лепешка из картофельного пюре» — *кәрчемә* сүзеннән.

**КӘЛИНКӘ** «калитка» — бу диалекталь сүз рус теленнән түгел; бор. язма төрки ядкарьлекләрдә *калика, калинка*, монг. *кагалинка* «капка» (*калкан* сүзе белән тамырдаш); к. чув. *калинкка, каленкке* «кәлинкә» < тат.? К. **Калкан**.

**КӘЛТӘ** «ящерица» — себ. тат. диал. *кәлтә елан, кәлтә кисәк* (диал. *кәлтә* «кыска», бор. тк. *кэсәк* «елан») сүзенең икенче өлеше төшеп калудан килеп чыккан дип аңлатыла (Егоров); к. ш.ук бор. тк., монг. *кэләс* «кәлтә» (Зәмәхшәри), *кэләр* «елан, чаян» (МК). К. **Кәлшә**.

**КӘЛШӘ** «молодые всходы хлебов» — чув. *келче, калча* «кыска, курпы, шытым, уҗым» сүзеннән, бу сүз исә тат. диал. *кәлтә* (к.) «кыска» сүзеннән; к. кк. *келте*, үзб. *калта*, фарсы. *халтэ* «кыска, кисек, киселгән». К. Әхмәтьянов, 1989:60—61.

**КӘМӘР** «рыцарский пояс» — фарсы. *kämär*, *kamara* ~санскрит. *kmar* «билбау, каеш; бил; җәя» сүзеннән.

**КӘМӘШ** «форма, подобие» — к. чув. *капаш* «форма, охшашы» ← *кап* < бор. тк. *кäр* «форма, тышкы күренеш» сүзеннән.

**КӘМИТ** «балаган; цирк» — рус. диал. *комедь* «спектакль, тамаша» сүзеннән (*комедия* сүзенең бозылган варианты).

**КӘНДИ** «чашка, миска» — тат. диал. *ҡәнди*, фарсы. *ҡанди* «кәнди, шикәр савыты» (фарсы. *ҡанд* «шикәр»).

**КӘНДИЛ** «канделябр, люстра» — госм. *кәндил* «кәндил» сүзеннән булса кирәк, киң таралган сүз, төп чыганагы — грек теле хисаплана; к. рус. диал. *кандило, кандель* «кәндил, шәм», гар. *кандил* «кәндил, лампа», грек. *хандила*, латин. *candilla* «шәм». К. рус. *канделябр* «шәмдәл».

**КӘНИЗӘК** «служанка; одалиска» — фарсы. *кäнизäк* «кәнизәк, хезмәткәр кыз, кол кыз» сүзеннән, к. Авеста. *Kanijak* «кызчык», санскрит. *kanya* «кыз бала».

**КӘНТ** *диал.* «точно, точь-в-точь» — к. төрек., ткм., бор. тк. *кәнду, кәндуси* «үзе», кб. *кеси* < *кендиси* «үзе», якут. *кини* «ул, шул» — бор. **кән* «үзәк» сүзеннән. К. **Кендек**.

**КӘНТӘЙ** «сука» — төп татар сүзе, бор. *кан, кән* «эт, көчек» сүзенә *-тәй* аффиксы ялганып ясалган (ләкин бу аффиксның биредә нинди мәгънәдә икәнлеге ачык түгел); к. үзб. *канчык* «кәнтәй», себ. тат. *канцак* «кәнтәй»; *кан* «эт, кәнтәй, көчек» бик борынгы заманнарда ук киң таралган сүз булса кирәк. К. корей. *кани*, нивх. *кан* «эт», һинд-евр. **кеuon*, **кеnuon* «эт», латин. canis «эт, кәнтәй», самодий. *канак* «эт». Чаг. **Көчек.**



**КӘПӘЧ, КӘЛӘБӘЧ** «тюбетейка, феска» — к. **Калфак.**

**КӘР, КЯР** «действие; инициатива» — фарсы. *кяр* «эш, шөгыль». К. ш. ук тат. *бикәр* < фарсы, *бикяр* «эшсез».

**КӘРАП** «корабль» — бор. кыпчак сүзлекләрендә *кәраб* id.; грекча *карабос* «кәрап» сүзеннән. Шуннан ук рус. *корабль*. Татар язма-әдәби телдәге *кораб* язылышының тарихи акланмасы юк.

**КӘРӘЗ** «соты» — угро-фин. телләреннән алынма дип хисапланыла (Егоров); к. удм. *карас* «чирәм, кәрәз», мар. *кәрәш*, мокша. *караст* «кәрәз». Төптә һинд-европа телләреннән килә дигән фикер бар. К.Әхмәтьянов, 1989:47.

**КӘРӘКӘ** «карась» — чыгышы ачык түгел; чаг. үзб. *карака* «кәрәкә», тат. диал. *кыраша* «кәрәкә», себ.тат. *кәреш* «стерлядь».

**КӘРӘС, КӘРЕШ** *диал.* «цветочный орнамент» — к. мар. *карыз* «бизәк, чиккән чәчәк», фарсы. *гарз* «чәчәк касәсе». Чаг. тат., башк. *кәрешкә* «ромашка, тычкан борчагы».

**КӘРЗИН** «корзина» — бор. рус. *корзать* «үрү, ишү».

**КӘРВАН** «караван» — фарсы. *карауан, кайрауан* «караван» сүзеннән.

**КӘРЛӘ** «карлик, карликовый» — бор. рус. *карло* «кәрлә» сүзеннән (төптә немецчә *kerl, kerle* «кешекәй»).

**КӘРЧӘ** «харчи» — күп телләргә таралган сүз, төптә гарәпчә *харҗ* «хәрәҗәт, расход» сүзеннән.

**КӘРЧЕМӘ** «самогон; медовый шербет» — к. диал. (гәйнә) *кәрсе*- «артык әчу, нык әчу», себ. тат. *каруца* «бик ачы бал», монг., калм. *харза* «бик куәтле исерткеч, өч кат куылган аракы», тамыры — бор. алт. *кäр*- «ачы, әчегән».

**КӘС** «дерн; круглый кирпич» — диал. *кәз* «зур саман кирпеч яки дүрткел киселгән чирәм», кк. диал. *кэз, кәз, кез* «кәз, кантар»; шуннан тат. диал. *тизәк, кәзәк* «ягулык өчен тизәктән сугылган кирпеч», гом.тк. *тизәк* (к.) шуннан ук килеп чыккан (к. рус. *кизяк* «кипкән тизәк»), мар. *кäш, каш* «сөрелгән җир кишәрлеге, бразна; рәт, төркем». К.Әхмәтьянов, 1989:60.

**КӘСӘ** «чаша, бокал» — фарсы. *касә* «зур купы, зур тәлинкә» сүзеннән.

**КӘТТӘ** «лучший, большой» — фарсы-таҗ. *кäттä* «зур, шәп» сүзеннән булса кирәк; к. үзб. *катта* «зур», тат. диал. *кәттә* «яхшы, шәп», башк. *кәттә* «матур», чув. *качча*, мар. *кача* «сөйгән яр, йөргән егет».

**КӘТҮК** «катушка; шпулька» — рус. диал. *каток* «кәтүк, ролик» сүзеннән; чаг. шулай ук фарсы. *галтäк* «кәтүк».

**КӘҮСӘ** «ствол (*дерево*)» — бор. тат. *кәб-сә, күб-сә* «куыш агач» сүзеннән (к. **Күбәк, Көпшә**). К. чув. *кепсе* «кәүсә, куыш агач, көпшә», төрек диал. *kevse* «кәүсә, сабак».

**КӘШ** «состоит из» — фарсы. *кäшт* «төзелгән, оешкан, эченә алган» сүзеннән. Бу сүзне тергезергә кирәк.

**КӘШӘНӘ** «мавзолей; ограждение могилы» — фарсы. *кәшанә* «кечкенә өй, кечкенә корылма» сүзеннән, күп телләргә таралган; к. кырг., кк. *кәсәнә*, куман. *кэсэнә*, кб. *кэшэнэ* «төрбә». Асылда, фарсы. «Кәшан шәһәре керамикасы» дигән сүз.

**КЕБЕК** «как, вроде» — гом. тк. *кэп* «форма, сурәт, чагылыш, чалым, образ» сүзеннән; к. чув. *кап, капă* «форма, фигура, корпус, килбәт» (Егоров), кк., кырг., алт., кум. *кэп, хэб*, бор.тк. *кэп* «калып, охшашлык, килбәт» (МК). Иск. тат. әд. *кеби* «кебек» < **кэбиг* > уйг. *кәби*, үзб. *каби* id.

**КЕЛӘ** «задвижка, запор» — бор. тат. *кел-әк* «телчек» сүзеннән; к. мар. диал. *келэ, кӹлä* «тел, кечкенә тел, келә», *кел // кӹл* «тоткыч», чув. *кĕле* «бик». К. **Тел.**

**КЕЛӘМ** «ковер» — гом. тк. *киләң* «бәрхет, келәм» сүзеннән ниндидер *кил- // кәл-* тамырыннан; к. чыгт. *кәлин* «келәм», бор. чыгт. *кәлим* «одеяло, покрывало» (Боровков), хакас. *килин, келең*, тув. *хилиң*, бурят. *хилэң* «бархат; плис», фарсы. *гиләм* «келәм». *Гилән* өлкәсе исеменнән дигән фикер бар.

**КЕЛӘТ** «амбар» — рус. *клеть* «читлек, кечкенә бүлмә» сүзеннән. Ләкин бу төрки сүз дигән фараз бар. К.**Келәү**.

**КЕЛӘҮ** «языческое моление» — тат. диал., чув. *келә-* «теләү, ялвару» сүзеннән, сүзнең тамыры гом.тк., монг. *кил // тил* «тел» дип хисапланыла (к. **Тел**). *Ни бәйрәм, ни келәү* әйтеме мөселманлык белән мәҗүсилек арасында яшәлгән чордан калган. Керәшеннәрдә келәүнең төрлесе булган: *олы келәү, кече келәү, өй урыны келәү; келәүлек* «пот».

Мишәр диалектындагы *келәү* «теләү» вариантының параллельләре караим, алтай, хакас телләрендә һәм борынгы хазар теле ядкарьлекләрендә табыла. *Келә-ү* сүзенең дериватларына русча *кляуза* < *келәвеч (келәвец), клевета (келә-* сүзенең «әләкләү» мәгънәсе булган), *клянчить* (*келәнче* «теләнче») сүзләре тоташа; борынгы мишәр-хазар *кал, кел* «тел; мәҗүси дога» сүзеннән чувашча *кĕл* «дога», русча *калякать* һәм, ихтимал, *клеть* < *келәт* «гыйбадәт бүлмәсе» (югары үсешкән мәҗүсилектә һәр гаиләнең үз гыйбадәтханәсе булган), *хлястик* (тат. диал. *келәч* «телсыман деталь») сүзләре килә.

**КЕМ** «кто» — гом. тк. *ким, кэм* (>чув. *кам*) id. Шуннан *кемсә* < *кем ирсә*. К. **Нәрсә**.

**КЕНДЕК** «пуп, сердечник; стержень» — чув., мар., удм. *кендек* «кендек»; тамыры — хакас, якут. *киин* ~ монг. *күйн* «кендек»; рус. диал. *киндяк* (үзб. *киндак*) «кендек» — татар диалектларыннан булса кирәк; угро-фин телләрендә бу сүзнең этимологиясен тирәнәйтергә мөмкинлек бирә торган вариантлары да бар; к. венг. *kele* ~ мар. *келемде* «кендек» (төрки телләрдән). Чаг. ш. ук госм., бор. тк. *кәнд-и* «үзе» > тат. *кәнт* «нәкъ».

**КЕР** «грязь (*на теле и белье*); белье, подлежащее стирке» — гом. тк. *кир*, монг. *хир(э)* «кер» сүзеннән; чаг. чув. *кирĕк* «кер, тузан». Бор. монг. *гкир* «кер, балчык».



**КЕРӘН** «хрен» — рус теленнән. Ләкин русчага бу сүз болгар теленнән кергән дип уйлыйлар; к. чув. *хĕрен*, мар. *ӹрӓн* «керән».

**КЕРӘЧ** «известь» — кум., н., төрек. *киреч*, кар. *керәч* «известь». К. **Кирпеч**.

**КЕРӘШӘ** «касатка» — борынгы телебездә *керәшә, көрәшә, көрәчә* махсус ау коралы, ул формасы белән яр карлыгачына охшаш; хәзерге диал. *керәч, көрәч* «тире тарттыру өчен чөй яки киерге» шул ук сүздән. К. мар. *кӱрезе*, чув. *кĕреçе*, монг. *хурзэ* «сәнәк, көрәк».

**КЕРӘШЕН** «крещеный татарин» — ~ чув., мар. *крӓшӹн, кӹрӓшӹн* id., һәм ш.ук «үз керәшеннәре» (татар теле тәэсирендә) — һичшиксез рус. *крещён* (сыйфат) сүзеннән.

Христиан татарлар (төркиләр) VII гасырдан бирле билгеле, ләкин алар *керәшен* дип аталмаган.

Рус. *крещен* «чукындырылган» сүзе *крест* «хач» сүзеннән, ахыр чиктә *Христос* (грекча «коткаручы») исеменә тоташа. Шул ук *крест* сүзенә *крестьян* (түбәндә «христиан») сүзе дә тамырдаш. Шунлыктан татар әдәби-язма телендәге *крестьян* сүзен йә гади сөйләмдәге *керәстиән*, йә *җирбагар* сүзе белән алмаштыру тәкъдим ителә.

**КЕРДЕШ** «примак» — тат. диал. *килдәш* > чув. *килтеш* «өйдәш» сүзеннән (*кер-ү* фигыле тәэсирендә генә *керде-ш* булып киткән): тамыры тат. диал. (мишәрчә), чув. *кил* «өй, йорт» (шуннан *киләк* «умарта саклау бурасы; урманга-кырга чыгарылган умарталык»). К. бор. тк. *кирдәш* «өйдәш», госм. *гил* «гаилә; өйалды; почмак» (чаг. тат. *өч-кел, дүрт-кел*). К.Рясянен, 1969:270.

**КЕРЕШ** «тетива; смычок» — гом. тк. *кириш* «кереш», *кир-, кәйр-, киер-* «киерү, тарттыру» фигылennән булса кирәк; к. хакас. *кирэш* «тарттырылган нәрсә, кереш», тув. *кириш*, якут. *кырыс*, алт. *кырыш* «кереш», чув. *хирлӳ* «кереш».

**КЕРЕШ-Ү** «приниматься, браться» — гом. тк. *кириш-*; *кир-* «керү» сүзеннән.

**КЕРПЕ** «еж» — гом. тк. *кирпи, кирби* «керпе», бор. тк. *кэрпиг* «энәле, энәлек» сүзеннән, бор. гом. тк. *кэрп-, кырп-* «энә, кадагыч» тамырыннан. Чаг. **Керфек**.

**КЕР-Ү** «входить, войти» — гом. тк. *кир-* id.; шуннан ук *кереш-у* < гом. кыпчак. *кириш-* id.

**КЕРФЕК** «ресница» — чув. *хăрпăк*, гом. тк. *кирпик* id.; *керпе* сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

**КЕРШӘН** «белила, крем; пудра» — бор. тк. *киршән* (МК), әрмән-кыпчак. *кыршан*, тк. (госм.) *киришан*, себ. тат. (Будагов, 1:123) *куршән* «кершән». Шәрекъ телләреннән.

**КЕСӘ** «карман» — чув. *кĕссе, кĕсье, кăсийа*, мар. *киса, кышан, кӱсен*, удм. *кисъ* күп телләргә (фарсы, кавказ, славян) гарәп теленнән таралган сүз; к. гар. *кис* «кесә, янчык», *кисäт* «букчай» (шуннан ук төрек, *кисәт* >> рус. *кисет*). Төп чыгышы — бор. грек. *kistis* «букча, пакет» сүзеннән.

**КЕСӘЛ** «кисель» — чув. *кĕсел*, мар. *кӹсал* — рус. *кисель* сүзеннән (тамыры *кис-* «ачы, әче»: *киснуть* «әчү», *кислый* «әче»).

**КЕТӘК** «клетка для кур» — фарсы-тадж. *кätäк, кäдäк* «кечкенә өй, өйчек» (*кäд, кäда* «өй») < бор. иран. *кätä,ката* «өйчек» сүзеннән, халыкара таралган вариантлары бик күп; к. рус., белорус. *котук, куток, закут*, чех. *кот, коток* «кетәк, токын».

**КЕЧЕ** «малый; младший» — гом. тк. *кичиг, кичик* (иске тат. *кечек* «кече»), тк. *күчүк* «кече, кечкенә». Мар. *изи* < болгар. **кижи* < *кичиг* (?) id.; чув. *кĕҫĕн* < **кечкен* (к. тат. **Кечкентәй**).

Этимологлар бу сүзнең тамырын бик күп телләрдән билгеле булган *кич* «кечкенә» сүзендә күрәләр; к. фарсы. *кыч*, әрмән. *кич* һ.б. «бәләкәй». К. **Кечкенә**.

*Кече атна* ~ чув. *кĕҫнерни (кун)*, мар. *изарня* «атнакич» сүзе элек *атна* «җомга көн» мәгънәсендә булуыннан (к. **Атна**).

**КЕЧКЕНӘ** «маленький» — бор. тат. *кечек кенә* тезмәсеннән кыскарып килеп чыккан; чаг. кк. *кишкинә* «кечкенә, кече» гомумән төрки һәм башка телләрдә «кечкенә» сүзен (яки шул мәгънәдәге сүзләрне) һәртөрле кечәйткеч кушымчалар белән әйтү типологик күренеш; к. тат. диал. *кечери, кечкәй, кечкентәй, кечкенәй* һ.б., хакас. *кĕчичек*, монг. диал. *кучукэн, кучүгүкэн* «кечкенә» (чаг. рус. *малый, маленький, малюсенький*).

**КЕШ** «соболь» — гом. тк. *киш // кис* «кеш» сүзеннән, чаг. ханты. *кет* «кеш» (Рясянен); шумер. *kiši* (*киши*) «бер җәнлек».

**КЕШӘН** «путы» — гом. тк. *кишлән // кишән // кизән* «кешән, богау» сүзеннән, бор. тк. *киш-ә-* (МК), уйг. *киз-ә-*, хакас. *күз-ә* «тышаулау, бәйләп кую», сүзеннән; сүзнең беренчел мәгънәсе «малны казыкка бәйләп куя торган озын бау» булган булса кирәк; чаг. монг. *куш-, кöш-* «бәйләү».

**КЕШЕ** «человек, личность» — гом. тк. *киши* «кеше; кунак» сүзеннән. Бор. тк. *киши* «хатын» мәгънәсендә булган. К.**Теше**.

**КЕШЛЕК** «праздничное платье» — диал. *кеше-лек* «кешеләр, ятлар; халык алдына чыкканда кия торган кием» сүзеннән; к. үзб. *кишилик кийим* «кешелек кием».

**КЕШНӘ-Ү** «ржать (*о лошади*)» — гом.тк. *кишнә-, кишнэ-* тат. диал. *кешеннә-, кешенлә-* «кешнәү», нинидер *кешен // кишин* сүзеннән (чаг. **Кешән?**); к. чув. *кĕҫен-*, бор. чыгт. *кишән-* «кешнәү».

**КЕШТӘК** «ластовица» — фарсы. *хиштәк* «кештәк, дүрткел материя кисәге»ннән (фарсы. *хишт* «кирпеч, квадрат»).

**КИ** *союз* «что; как» — фарсы. *ки* «ни, кайсы, кайчан, кем» сүзеннән, чыгышы — бор. ирани телләрдәге *ка, ак(а)* «кайсы, ни» сүзеннән. Чаг. **Кем**.

**КИБӘК** «отруби, мякина» — гом. тк. *кэбәк* (тат. диал. *кәбәк*), *кәпәк* «кибәк, әрбә» тат. диал. (себ.тат.) *кип, кәп* «тышча, сүрү, кабык» < гом. тк. *кэп* id. сүзеннән. Чув. *кипек, кипенкĕ*, мар. диал. *кäбäк, кибек* «кибәк» — татар теленнән.

**КИБӘН** «стог» — бор. тк. **кэбәң* (тат. диал. *кәбән // кәпән*, кб. *кебен* «кибән, чүмәлә, зур өем» сүзеннән; «өем» сүзен белдергән һәм күп телләргә уртак символик яңгыраш *кәп // куп* тамырыннан булса кирәк; к. якут. *кәбис* «кибәнләү, кибән кую», бор. чыгт. *кэбәң* «күпкән корсак», тув. *хöпээн* «кибән» (чаг. **Күбә**),



ханты. *кебан*, венг. *кере*, удм., мар. *кäбан, каван*, рус. диал. *кабан* «кибән» — төрки телләрдән (Егоров); чаг. шулай ук осетин. *губин* «корсак» (Абаев), һинд. *кавandh* «корсак, болыт, болытсыман өем, үркәч». К. Әхмәтьянов, 1989:59.

**КИБЕТ** «лавка; магазин» — бор. тат. *кәбит, кәбәт* «йөреп сатучының көймәле арбасы» (шуннан рус. *кибитка* «көймәле чана; тәрәзәсез өй») — гар. *кубббәт-ун* «чатыр, палатка» сүзеннән; чув. *кипет, типет* «кибет», удм. *кебит* «тимерче алачыгы, лавка, кибет» татар теленнән.

**КИБ-Ү** «высохнуть» — гом. тк. *кэп-* id. Бу сүз бүтән тк. телләрдә сирәк очрый. Чув. *тип-* «кибү» татарчадан.

**КИГӘВЕН** «овод» — тат. диал. *күгәүен*, бор. тк. *кöкэгүн* «кигәвен, күк (яшел башлы) чебен» (МК) сүзеннән, гом. тк. *кöк* «күк» (к. **Күк**) тамырына исем ясагыч кушымчалар өстәлеп (*кöк-әг-үн*) ясалган; чаг. себ. тат. *кигәүен* «яшел башлы кыр үрдәге, күгәл».

**КИГИ** «спицы колеса» — тат. диал. *кигәй*, бор. тк. *кәкәг* «кигн» сүзеннән, нинидер *кәк // как*(?) тамырыннан; к. урум. *кәгәй, тәгәу* «киги», кум. *кöгай*, н. *кэгэй* «киги», монг. *кэгэ* id. бор. кытай теленнән.

**КИЕЗ** «войлок» — гом. тк. *кийиз // кәбиз // кәдис* «киез», бор. гом. тк. **кәдир* «киез, кашма» — нинидер *кәд // кәб* тамырыннан; к. алт. *кэбис* «келәм», *кийис* «киез», монг. *кеwис, кебис*, «киез», бор. монг. *кибез* «мамык» (Зәмәхшәри), тув. *кидис* «киез, келәм», бор. тк. *кидиз* «киез, кидҗе», *кудуз* «киез, мамык» (МК); рус. *ковер* «келәм» сүзе киез белән нигездәш хисапланыла (Рясянен, Абаев); чаг. тув., *хöбэң*, бор. монг. *кэбэн* «киез».

**КИЕК** «дичь» — гом. тк. *кийик, кәйек*, бор. гом. тк. *кәй-иг, кәд-иг* «кыргый» (МК) сүзеннән. Мар. *кäйык, кайык*, чув. *каййк* «кош», удм. *койык* «поши» ~ тат. диал. (Урал) *көйек, кейек* «мөгезсез пошли» ау объекты кайсы якта нинди хайван булганлыгын күрсәтәләр.

**КИҖЕ** «хлопчатобумажная пряжа» — фарсы. *кәҗи* «тупас (эшкәртелеп җиткерелмәгән) ефәктән эшләнгән» (*кәҗ* «тупас ефәк») сүзеннән; к. башк. *кидҗе*, кум. *кеҗи* «тупас ефәк, ефәк кортының курчагы».

**КИЗӘК** «кизяк» — бор. тк. *кәз-әк* «дүрткелләп ишелгән тизәк басымы» сүзеннән, *кәз* тамырыннан (к. **Кәс**). К. **Касәк, Кизү, Тизәк.**

**КИЗӘН-Ү** «замахиваться на *кого-л*». — *кизә-ү* (к.) фигыленең төшем юнәлеше формасыннан; к. көнч. тк. (алт., тув., хакас) *кэзэн-* «кизәнү, мылтык төбәү, янау, каргау». Чаг. **Кисәт-ү.**

**КИЗӘҮ** *устар.* «надрез на луке для стрелы» — бор.тк., бор. уйг. *кез, кэз* «ук койрыгы, ук таягы, әзерләп куйган таякчык», шуннан иске тат. *кәз* «аршын (ук озынлыгы, аралык)», тат. диал., башк. *кизә* «ук төбендәге кирт; ике нокта арасын тоташтырган туры сызык, арата», *кизә-ү* «укны керешкә кую, атарга әзерләнү», шуннан күчерелмә мәгънәдә *кизә-ү, кизәну* «сугарга җилкенү».

**КИЗЛӘҮ** «родник, ключ, источник» — иске тат. *кизләү* «яшерү» фигыленнән булса кирәк; к. тат. диал. *кизләү мәчет* «яшерен мәчет» (Бәетләр, 1963:200), гом. тк. *кизлә-, гизлә-* «яшерү», *гизле* «яшертен», *киз, гиз* «яшерен урын» (к. Севортян, 1980:43), тат. диал., ккк. *кез, кәз* «ике тау арасы».

**КИЗҮ** «дежурство; дежурный; эпидемия» — гом. тк. *кәзик, кәз-иг* «чират, өлеш, тигез бүленгән бурыч, йөкләмә» сүзеннән, бор. гом. тк. *кәз* «бүлемтек, бүлек, өлеш» тамырыннан, *кәзик* һәм *кәз* төрки һәм башка телләрдә бик киң таралган һәм күп мәгънә алган сүзләр; к. бор. уйг. *кәзик* «чират, каравыл, тәртип», кк., кырг. *кәзәк, кезек* «чират, нәүбәт», кырг. *кезүү* «көтү чираты; көтү», монг. *кәзәк, кесик* «хәрби каравыл составы», алт. *кезү, кезим* «эпидемия», чув. *касă* «урам, квартал, группа, өлеш», *касу, касăк* «чират, нәүбәт, ат көтүенең аерым-аерым бүленеше, отряд». Бор. гом. тк. *кәз* ~ **кәрг* тамырына тоташкан сүзләр татар, чуваш, мари телләрендә шактый гына. Мәс. тат. диал. *кизәр-ү* «аерым тигез өлешләргә бүленү», *кизге* «квадрат».

Ихтимал, бор. тамырга чув. *кар* < **кәр* «күп өлештән торган берлек» сүзе якындыр. К. ш.ук **Кәс, Кизәк** // **Тизәк**.

**КИКЕРИК** «гребень» — тат. диал. *кикәләк, кикеләк* «кечкенә кикел, кәкәл» сүзеннән үзгәргән (к. **Какул**).

**КИКЕР-Ү** «рыгнуть» — фигыль ясый торган *-кыр // -кер* кушымчасы ярдәмендә *кик* тәкълиди сүзеннән ясалган (чаг. *а-кыр-у, ба-кыр-у, тө-кер-ү*).

**КИЛ-Ү** «приходить, прийти» — гом. тк. *кәл-* бор. **кә* «өйгә бәйләнешле хәрәкәт итү» сүзеннән; шуннан ук *кит-ү* < гом. тк. *кәт-* фигыле дә ясалган. Чаг. шумер. *ge-* «урау, йөрү».

**Кә* тамырының чыгышына килгәндә, аны Евразия телләрендә киң таралган *кәд* «өй» сүзе белән чагыштырып була.

Бор. болгар (?) **кәй- > чув. кай-* «бару» фигыле дә *кил-* һәм *кит-* сүзләренең уртак тамыры булырга мөмкин.

**КИЛӘК** «омшаник» — чув. *кил, килĕ* «өй, йорт» ~ бор. хазар. *кел* «башня» сүзе белән тамырдаш. Чыгышы ачык түгел (Егоров).

**КИЛӘП** «моток» — фарсы-таҗ. *калоба* «орчыкка уралган тупас җеп, әвернә, кәтүк, киләп, йомгак» сүзеннән; к. башк. *кәләп* «киләп», бор. тк. кәләбә «әвернә» (Зәмәхшәри).

**КИЛБӘТ** «облик, внешность» к. кум., кырг., кк., ккк. *келбет, келпет*, н. *келбак* «фигура, сын, кыяфәт». Фарсы теленнән; к. фарсы *кăлбад* «форма, калып», бор. тк. *кăлбуд, калбод* «сүрү».

**КИЛЕ** «ступа» — гом. тк. *кили // килә* «киле, төйгеч» сүзеннән, («төйгеч → киле» мәгънә күчеше); к. якут. *кәли, кәлии* «киле»; чаг. саян. *һелукә, хәлука* «киле», венг. kölü, köjlü «төйгеч, киле, күсәк», себ. тат. *кейле* «зур агач төйгеч», кк. *киле, кәллә* «төйгеч, киле».

**КИЛЕН** «невестка, сноха» — гом.тк. *кәлин, килин* «килен» киң таралган *кәл // кәл* «сүз; тел; хатын ярәшү» тамырыннан; к. тат., башк. *кәл-әш* «ярәшелгән кыз», удм. *кăли, кали* «килен», алт. *кәлди, келди* «энесенең хатыны». *Кил-ү* сүзе белән бәйләнешле түгел. К. Әхмәтьянов, 1989:112—114.



**КИЛЕШ-Ү** «ладить *с кем-л.*; соглашаться» — чув. *килĕш-*, мар. *келыш- (келшаш)*, удм. *кельыш-* ~ гом.тк. *кәлиш-* id. *кил-ү* < *кәл-* «(якын) килү» сүзеннән. Чаг. төрекчә *барышмак* «ярату».

**КИЛТӘ** «концы недотканной ткани» — чув. *келт, килте* «килтә»; гом. тк. *кәлтә* (к. **Кәлтә**) «кисек, кыскартылган» сүзеннән. Шуннан ук *китәрү* < *килтәрү* «чәч кыскарту», алт. *кăлтăй, келтей*, монг. *кәлтәй*, бурят. *халтагай* «кискәннән калган өлеш; ярты, ярым».

**КИМ** «неполный; меньший» — тат. диал., башк., алт., госм., чыгт. *кәм* > чув., мар. *кăм, кам* «ким, кимчелек», фарсы. *кăм, кам* < бор. фарсы. *кăтă* «кимчелек, җитешсезлек, кечкенә, бәләкәй» сүзеннән. *Киме-* «уменьшаться» << бор. тк. *кәми-* id.

**КИМӘЛ, КӘМӘЛ** «ватерлиния плотины; фундамент; уровень» — башк. *кимәл, кәмәл* «тәңгәл», чув. *камал* «тиң, кордаш» — бор. тк. (якут., уйг., кар., алт.) > удм. *кәм* ~ хак. *ким* «чама, вакыт, чак» сүзеннән (*кимәл* < *кәм-әл*); к. ш. ук бурят. *хэм* «уровень, мера» К. Әхмәтьянов, 1989:158.

**КИМЕК** «мозговая кость; кора березы» — бор. тк. *кәмук, кәмик, кәбиг* «кимерелә торган нәрсә» сүзеннән, бор. *кәб-* «кимерү, чәйнәү». Шуннан ук *кимер-ү* «грызть < *кәмир-* id. Чаг. төрек. *гәм* «авызлык».

**КИНӘ** «злопамятность» — фарсы. *кина* «үч, үчегү» сүзеннән, сүзнең тамыры бор. ирани. *каепа, каупа*, һинд-евр. *коупа* «үч, җәза, хакын кайтару» (шуннан ук рус. *цена* «хак»).

**КИНӘН-Ү** «наслаждаться, получать удовольствие» — бор. тат. *киңәл-, кинәл-* «тынычлану, гамьсезләнү» фигыленнән; бу фигыль исә **кәң-(ә)* «тынычлану, кинәндерү» сүзенең төшем юнәлеше формасы булса кирәк; к. диал. *киңән-ү* (мишәр.), *килән-ү//киңәл-ү* (тау ягы) «кинәнү, рәхәтләнү», чув. *кан- // кән-* (< *каң // *кәң-*) «тынычлану, рәхәтләнү», бор. тк., монг. *кән-* id. (к. **Кинәт**). Чаг. ш. ук төрек. *гөнән-* «кинәнү».

**КИНӘТ** «вдруг, неожиданно» — иске тат. *кинәтәйен* бор. тк. *кинә-, кәнә-* «гамьсезлек, гамьсез рәхәтлек» (бор. гом. тк. *кәң-* «тынычлану» тамырыннан булса кирәк; чаг. *кинән-ү*) сүзенә монг. *тәй -лы //-ле* кушымчасы ялганып ясалган сүз; к. көнч. тк. (алт., хакас.) *кәнәтәйин, кинәтен* «кинәт», бор. чыгт. *кенетә*, бор. монг. *генетә(й)* «кинәт», бор. чыгт. *кенән*, бор. монг. *генән* «гамьсез», бурят. *гэнэ* «көтелмәгән хәл», *гэнэхэн* «беркатлы, ышанучан», *гэнэтэй* «дуамал, хаталы».

**КИНДЕР** «конопля; полотно» — гом. тк. *киндир, кәндир* «киндер (*үсемлек*), киндер тукыма, сүс» сүзеннән, төптә кушма сүз булса кирәк: *киң* — киң таралган сүз; к. фарсы. *кана, кăнаб* «киндер үсемлеге», бор. ирани. *кпв, кипва, китва*, грек. *коннаби*, латин. cannabis, немец. *һanf* ~ бор. немец. *һапа*, әрмән. *канап*, грузин. *канапи-*, бор. славян. *конопла*, фин. *һатрри* (*һамппу*), эстон. *капір* (*канип*), мордва-эрзя. *кант*, зырян. *кэнтус*, мар. *кине, кане*, удм. *кенэм* «киндер» һ.б. бор. шумер. *кипіві* «киндер» сүзеннән булса кирәк; бор. тк. *кәндир* «киндер» сүзенең икенче компоненты бор. *тәри* «тире» (*кэн тәри* «тукыма тире»). К. **Киндерә**.

**КИНДЕРӘ** «бечева, шнур» — мар. *кӓндерӓ*, чув. *кантра* id. *киндер* сүзеннән ясалган яисә шуның бер варианты; к. тат. диал. киндерә «киндер орлыгы», ткм., төрек., азәрб. *кәндир, кэндир* «киндерә, бау». К.**Киндер**.

**КИНҖӘ** «самый младший сын в семье» — кк. *кейинжә* «иң соңгы, кече, кинҗә» — *кейин* «соңынтын» сүзеннән (к. **Кәй**). Чаг. тат. диал. *кинзә* «калдык», *кинчәлек* «такыр (ялга калдырылган) басу», тув. *хэнчэ* ~ монг. *хэнзэ* «көзен туган (бәти)», азәрб., төрек. *гәнж, кәнж* «яшь кеше».

**КИҢ** «широкий — гом. тк. *кә̄ң, кэиң* id. к. **Киңәш**.

**КИҢӘШ** «совет» — гом. тк. *каңаш* > тат. диал., башк. *каңаш* (> мар. *кӓнӓш* > чув. *канаш*, удм. *кенеш*) — болгар-татар дәүләтләрендә иҗтимагый орган булган. Бу сүз бор. тк. *кэңә -, кэйңә* — «киңәш бирү, киңәшләшү, киңәш сорау» фигыленнән; ул фигыль исә бор. *киң, кэйең* «ханның киңәшчесе» сүзеннән.

Бу сүз Ибне-Фазлан теркәгән угыз титулы *күзәркиң < күзәр киң,* Идегәй дастанында *Киң Җанбай* (Туктамыш ханның киңәшчесе) тәгъбирләрендә чагыла; аннары Ә.Мөхәммәди раславынча, Идел-Урал регионында борынгы Харәзем алфавиты белән язылган язулы тәңкә вә касәләрдә укыла; Ә.Мөхәммәди бу сүзне инглизчә *киң < кӓйң* «король», немецча *кӧниг* (> рус. *князь*) сүзләре белән бердәй, борынгы герман халыклары бу сүзне һуннардан алган дип бара (к. аның «Һуннар һәм Туран язмалары», Казан, 2000:86—87). *Киңнең* «корольлеге» себ.тат *кәңгел* «киң күңелле», *кәңлек* «киң күңеллелек, юмартлык», *киңә-, кәйңә* — «кисәтү; куркытып әмер бирү» сүзләрендә дә чагыла.

Борынгы руник язмаларда *кэңгү* — бер титул (булса кирәк); әгәр шулай икән, борынгы табышмаклы *шаньюй* «император» титулы да аңлашыла: кытайлар язуынча һун телендә *шаньюй* «киң» дигән сүз: *кэ̄ңгу > тэ̄нгу > чә̄нгу > шэнйу* «шаньюй». *Кэйң* «киң» һәм «патша» сүзләре бердәй түгелме икән? «Киң» мәгъ. сүзнең «патша, император» мәгънәсен дә бирүе *чыңгыз* (төбендә *чэңгиз* < бор. уйг. *тэңгиз* «дингез»), *далай лама* «буддистларның башлыгы» (*далай* «диңгез, чиксез киңлек; дала») сүзләрендә дә күзәтелә.

**КИПКЕР** «дуршлаг; пробирка» — себ. тат. *кәпкер*, уйг. *кәпкур* id. фарсы. *кӓфкгир* «күбек алгыч» сүзеннән (*кӓфк* «күбек», *гир* «ал!»).

**КИПРӘН** «оболочка» — тат. диал., башк. *кәпрән* ~ н., кк., ккк. *кепирән* id., тат. диал. *кип, кәп* (>чув., мар. *кӓп, кап*) «тышлык, кабык, сурәт, кибәк; күренеш»; тамырыннан. К. **Кәбәрә, Кибәк.**

**КИР** «гнедой» — гом.тк. *кэр, кәр* ~ бор. монг., фарсы. *кэһэр* id. Беренче мәгънәсе «мамонт; мамонт тәсендәге»; к. себ.тат. *киртеш* «мамонт теше (сөяге)», *кир* «мамонт» ~ алт., тув. *кэ̄р, кә̄р* «әкияти рух» << һинд. *kerk* «мөгезборын»; шуннан ук тат. *кәркәдән* (фарсы теле аша) «мөгезборын».

**КИРӘК** «надо; понадобиться» — бор. тк. *кэргәк* һәм *кэргәк-* id. бор. *кэргә-* «кирәк булу, ярау» тамыр сүзеннән. Этимологик тамыры *кэр* булса кирәк, ләкин аның мәгънәсе һәм чыгышы бик үк ачык түгел — бер яктан тув. *кер ~ кэр* «эш, бурыч», икенче яктан фарсы. *кяр* «эш, кирәклек». Чаг. ш. ук монг. *гэр < кэр* «өй, йорт».

**КИРӘМ** «веревочная лестница» — башк. *кәрәм, кирам,* мар. *керем,* иске рус. *кирень, керень, кирюн* «чолыкчы арканы; җир үлчәү өчен махсус бау; борынгы җир үлчәү берәмлеге». Чыгышы ачык түгел.

**КИРӘМӘТ** *миф.* «место языческих молений у чувашей, марийцев, удмуртов, а также у крещеных татар-двоеверцев — обычно священная роща», в тат. также — «вяз мелколистный», «фетиш, идол» (в разных источниках, у разных этнографических групп)» — < гар. «*карамәт* > тат. *кәрәмәт* «мөгъҗиза; тылсым» (төбендә «Аллаһу бүләге, Аллаһу юмартлыгы») сүзеннән. *Кәрәмәт — кирәмәт* вариантлары булу бу сүзнең Идел-Урал ргионына бик иртә — X—XI гасырларда ук кергәнлеге турында сөйли.

Марийларда *кирәмәт* шәхес — явыз рух буларак та күзәтелә һәм аның тур. күптөрле сөйләкләр, легендалар бар.

**КИРЕ** «обратно» — бор. тк. *кэй-ре // кай-ры* «артка, кире, кире якка» сүзеннән, ниндидер *кэй ~ кэд* (чаг. *кинҗә*) яки *кай ~ кад* (чаг. *кайт-у*) тамырыннан; к. тат. диал. *кәйре* «кире», алт. *кайры*, бор. чыгт. *кайра, кадра* «артка, яңадан».

**КИРМӘН** «крепость, укрепление» — чув., мар. *кӓрман, карман,* гом. кыпчак. *кермэн-* бор. тк. *кер-, кэр-* «ныгытма белән урату» сүзеннән булса кирәк. К. **Киртә**.

*Кирмән* сүзеннән рус. *кремль* (болгар. **кәрмәл*) сүзе килә.

**КИРПЕЧ** «кирпич» — гом. тк. *кэрпич*; чыгышы ачык түгел; рус. *кирпич* — татар теленнән булса кирәк [*э>и*].

**КИРТӘ** «ограда; жердь» — Идел-Урал регионына хас сүз: башк. *кәртә*, чув., мар., удм. *кӓртӓ, карта ~ керте* «киртә, кәртә», бор. болгар. **кәрт, *кэрт* «киртәләп алынган җир» сүзеннән.

**КИРТ-Ү** «сделать зарубку» — чув. *карт-*, гом. тк. *кэрт-* id.

**КИСАП** «пест» — диал. *килесап* «кисап» — *киле* һәм *сап* сүзләреннән кушылып ясалган; к. кк. *келсап, килсап,* ккк. *келисап* «кисап».

**КИСӘРТКЕ** «вид ящерицы» — к. башк. *кәсәртке*, тат. диал. *кисеркә, кэлискэн*, төрек. *кэлэс, кэлэр*, калм. *гӧлгр*, монг. *гӧлбүрге* «кәлтә». Сүзнең нигезе монг. *кӧлбэгүр* «сычкан, кәлтә», бор.тк. (Ибн-Муханна) *кэлэнү, кэлэңүр* формасы аркылы *кэлэр // кэлэз // кэрэс* рәте килеп чыккан. Шуннан *кэрэс-кэ > кэсэркэ > кэсэрткэ* (чаг. *себер-т-ке, чыбыр-т-кы*).

**КИСӘТ-Ү** «предупреждать, предупредить» — себ.тат. *кәсәт-* «(җәзаларга) әмер бирү» бор. тк. (якут телендә сакланган) *кэсэ-* «каты сабак алу; үкенү», *кэс* «кагылгысыз, изге; көмәнле» сүзләреннән (бу сүз төнлә хатын-кыз илә якынлык итү кагыйдәләре белән бәйләнгән булса кирәк).

**КИСӘҮ** «кочерга» — бор. тк. *күсәгү, кӧсәгү* «кисәү, учакны бутый торган агач» сүзеннән (шуннан ук к. **Күсәк**); к. ккк. *кесеу*, бор. куман. *кӧсӧw* «кисәү, күсәк», үзб. *кӧсӧ* «кисәү», *кӧсак* «кисәү,

күсәк», алт. *kөсөк* «кисәү, кәкре башлы таяк», тув. *кезек, кэзэк* «кисәүбаш», саян. *көзәгү* «тимер кисәү» гом.тк. *көз // көс* «янып торган күмер» сүзеннән булса кирәк (Йоки); к. алт. *көс,* саян. *көс, көз,* госм. *көз* «янып торган күмер», саян. *көзэ-пәк* «учак болгату (күзэ-мэк)».

**КИС-Ү** «резать» — чув. *кас-*, гом. тк. *кэс-* id.

**КИСМӘК** «кадка, кадушка; бочка» — *кис-у* (к.) сүзеннән булса кирәк.

**КИТАП** «книга» — гар. *китаб-ун* «китап» сүзеннән, гар. *кӓтӓбӓ* «язу» тамырыннан, шуннан ук *мәктәп,* иск. *мәктүб* «хат», *кятиб* «секретарь».

**КИТӘН** «холстина, полотно; шнур» — тат. диал. *кәтән* > чув. *катан, катам,* мар. *кетен, кытан-* гом.тк. *кэтэн-* чыгышы бор. шумер теленнән хисапланган киң таралган сүз; фарсы. *кӓтӓн,* гар. *кӓттӓн* «китән: киҗе-мамык, җитен», ассирия. *китинни,* санскрит. *kettānā* һ.б. «китән, житен, киндер», бор. шумер. *гад // гәд* «тукыма, киндер тукыма». К. Абаев, 1:595.

**КИТМӘН** «мотыга, кетмень» — бор. тк. *кетмен, кэтмэн* «китмән» сүзеннән, *кит-у* II фигыленнән булса кирәк; к. чув. *катак, касман, катмак* «китмән» (Ашмарин), мар. *кӓтмӓн, катман* «китмән», *катмак* «ачкыч балтасы» (төрки телләрдән), үзб., кк., ккк. *кэтмэн, кетмен* «китмән».

**КИТ-Ү I** «уходить» — гом. тк. *кэт-*, угыз. *гит-,* һичшиксез, *кил-* < гом. тк. *кэл-* «килү» сүзе белән тамырдаш, ләкин ничек — моны әйтүе кыен. Чув. *кай-* < болгар. **кәй-* «китү» сүзеннән чыгып, *кит-* < *кэт-* < **кэйт-,* **кәйет-* дип уйларга була.

**КИТ-Ү II** «отломить, отколоть» — чув., мар. *кат-* < болгар. **кәт* ~ гом .тк. *кэт-* < бор. тк. *кэлт-* «китеп алу» сүзеннән; к. монг., эвенк. *кэлтэ-* «китеп алу». *Кирт-* сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

Тат., башк. *китәр-у* < гом. тк. *кэлтәр-* «удалять, устранять» сүзе дә шул тамырдан (*кэлт-әр-*). К. **Кәлтә**.

Идел-Урал телләрендә тат., башк. *китек,* удм. *кетык* ~ чув. *катӑк* ~ мар. *катык, кӓтык* < гом. тк. *кэтик* сүзе киң таралган.

Татар сөйләшләрендә *кәлтәү* > мар. *кӓлтӓу* «китеп алынган торф кирпече» сүзе билгеле.

**КИ-Ү** «одеваться, надевать (*на себя*)» — гом. тк. *кэй-, кий-,* хакас. *киз-* << бор. тк. *кәд-* > уйг. *кәд->* тув. *кет-, кәт-* «кию». Фонетик закончалыклар буенча бу сүзнең чувашча чагылышы *кар-* < болгар. *кӓр- (кәр-)* «тарттыру» булырга тиеш.

**КИЧ** «вечер» — чув. *каç* < болгар. **кәч* ~ гом. тк. *кэч* «кич». Бу сүздән күп кенә бүтән сүзләр ясалган: *кичегу* (*кичек-у*), *кичә* (*генәк*).

Бу сүзнең *кич-у* сүзе белән бәйләнешы булуы ихтимал, ләкин ничек — әйтүе кыен.

**КИЧӘ** «вечер; вчера» — гом. тк. *кечә, кэчә* «кичен, соң, төнлә» сүзеннән, «үткән көн» мәгънәсе татар (башкорт) телендә генә. К. **Кичек-ү.**

**КИЧЕК-Ү** «опоздать, запаздать» — бор. тк., тат. диал. *кэч,* *кич* «соң» (к. үзб. *кеч* «соң, соңга, кич») сүзеннән ясалган, ясалыш нигезләре бик үк ачык түгел; чаг. *үчек-у , ачык-у.* К. **Кич, Кичә.**

**КИЧЕР-Ү** «пережить; переживать; прощать» — *кич-у* (к.) фигыленең йөкләтү юнәлеше формасыннан; чаг. үзб. *кеч-* «кичү, кичерү, гафу итү».

**КИЧ-Ү** «переходить, перейти» — < гом. тк. *кеч-* «кичү, үткәрү» фигыленнән, К. **Кичер-ү.**

**КИЧКЫРЫН** «вечером; к вечеру» — кар. *кечкырын,* чыгт. *кечкурун* «кичкырын» — *кич* һәм тат. диал. *корын,* чыгт. *кур, курун* «вакыт, чак» сүзеннән. Бу *кур, курун* сүзе ыручылык заманындагы яшьтәш һәм женестәш кешеләрнең бергә җыелып ашавы — *кур* белән бердәй. К. **Кордаш, Көрәгә, Корын.**

**КИШӘНКЕ** «плюсна; соплодие (*орехов*)» — диал. *кәшәнкә, кәсәнкә, кишмек, кәшмәк* «кишәнке», чув. *касмак* «кишәнке». Сүзнең тамыры *кэз* «төркем, кантар» (К. **Киштә, Кишәрлек, Кизү, Кәс**). Тат. диал. *кушанкы* «кишәнке» — халык этимологиясе нигезендә ясалган сүз (*куш-у* фигыле тәэсире).

**КИШӘРЛЕК** «полоса жатвы; участок» — бор. тат. *кишәр* ~ *кәшәр, кәчәр,* бор. *кәз-иг-ир* «өлеш, рәт, шеренга, бүлек» сүзеннән, бор. гом. тк. *кэз* «өлеш» нигезеннән (к. **Кизү**); к. мар. *кӓҗар, кӓшар* «тоташ бер басу, урман кварталы» (бор. болгар теленнән), чув. *касалӑк* «кишәрлек», *касӑ, касу* «чират, өлеш», якут. *кәчәңәр, кәчигир* «шеренга, рәт», бор. монг. *кэшик* «өлеш, чират, кизү, смена». К. **Киштә, Кизү.**

**КИШЕР** «морковь» — бор. фарсы. gezer, gäzur «кишер» сүзеннән; к. үзб., таң *кашир,* бор. тк. *кешур* «кишер» > бор. рус. *кезер, кичири* «кишер», гар. *җәзер* «кишер».

**КИШТӘ** «полка; перекладина» — тат. диал., башк. *кәштә* > мар., чув. *кӓштӓ, кашта* «киштә, матча», *кишәрлек* (к.) сүзенә тамырдаш; *кәштә* ~ *киштә* вариантлары булу бу сүзне татар телендә барлыкка килгән дип уйларга урын калдыра. Чаг. ш.ук мар. *кӓштӓлӓн-, кашталан-* «йомгаклану: рәт-рәт тезелү». Нәкъ шуңа охшаш һинд., урду. *кашта* «озынча мәйданчык, юл, киштә, тезмә, рәт» сүзе бар.

**КИЯ** «дух обиды и мести» — гом. кыпчак. *кия, кие, кейе* бор. тк. kïñe «ярдәмче рух» сүзеннән булса кирәк. К. кк. *киели* «изге, тию тыелган», тат. *киялеге килер* дигәндә, «саклаучы рухы килер» мәгънәсе аңлашылса кирәк. Чаг. ш. ук. бор. тк. keg, kege «дошманлык», бор. фарсы. *киа* «чик сакчысы».

**КИЯҮ** «зять; жених» — бор. тк. *куйәгу* «кияү», бор. монг. *курдэ-гүн* «хатын-кыз ягыннан эне» (*кур* «хатын-кыз», *дәгү(ң)* «эне яки сеңел») сүзеннән (Рясянен); к. орхун. язм. *күдәгү,* хакас. *күзээ* «кияү», бор. монг. *күрэкэн* «кияү»,чув. *кęрӳ, кęрęв* «кияү» һ.б.

**КОБА** «бледно-бурый» — гом. тк. *қуба* «аксыл-соры, аксыл-сары» сүзеннән; к. диал. *куа,* алт. *куу, куба* «аксыл», кырг. *куа,* тув. *куба,* кк. *куу* «коба»; шул ук нигездән *кола* (к.) һәм, ихтимал, *кау, ку* (к.) сүзе дә килеп чыккан.

**КОБАГА** «карниз; ступенька карниза» — кум. *кобага*, кк. *кубаға* «улак», монг., чыгт. *кобуға* «тирмә уртасына кагылган багана», кырг. *кобул* (шуннан — *кобулга*) «улак, ырмау; тирмә колгасының аскы ягына төшерелгән бизәк». Беренчел мәгънәсе — «тирмәнең кыегын кору өчен кулланыла торган каркас».

**КОДА** «сват» — гом. тк. *куда* «кода», монг. *худа* «туй; кода» сүзеннән, монгол теленнән булса кирәк; тунгус-маньчжур телләрендә *куда* «хак, бәя; калым». к. **Кодагый**.

**КОДАГЫЙ** «кума, сватья» — монг. *ходогой, худугуй* «кодагый, кодача» сүзеннән. К. **Кода**.

**КОЕ** «колодец» — гом. тк. *кудуқ, кудуғ*, тат. диал. *кыйу, козык, котың* «бәке, кое», бор. тк. *куд, код* «кое» сүзеннән; к. венг. kut, kud «кое» (төрки телләрдән), чыгышы ачык түгел, чаг. тув. *куйу* «кырый, яр кырые», бор. тк. *кудуғ* «кое, чишмә» (МК).

**КОЗАУ** «кузов из бересты, лукошко» — башк. диал. *қузы* «козау», үзб. *қузы* «кузак; тартмачык». Рус. *кузов* < тат. *козау*.

**КОЗГЫН** «ворон» — гом. тк. *қузғун* «козгын» ниндидер *қуз-, қудуз-* < *қудур* (фигыль?) нигезенә *-ғун // -ғын* аффиксы ялганып ясалган; к. бор. тк. *кудургун* «козгын» (МК).

**КОЙГЫРЫШ** «птица (*жеребенок, ягненок*) счастья» — чув. *кайкăрăш* «койгырыш», башк. *койгырыш, койгороч* «икейөзле», морд. *койгорож* «елан кош» (*куй* «елан», *корож* «кош, өке»). Бу материалдан күренгәнчә, сүзнең чыгышы мордва телләреннән булырга тиеш. Әмма мордваларда бу халык этимологиясе булса кирәк; к. бор. тк. *коғу куш, коғу қоруз* «койгырыш» (*коруз* < фарсы. *хораз* «әтәч; таң кошы»).

**КОЙМА** «забор» — мар., удм. *куйма, кульма*, чув. *хӳме* «койма», кк., уйг. һ.б. *қуйма* «ике кыса арасына сыек балчык коеп ясалган койма»; к. тат. *қойма қою*, чув. *хӳме хӳ-* id. К. **Кой-у**.

**КОЙМАК** «маленькие блинчики, оладьи» — удм., мар. *куймак, кульмак*, чув. диал. *кăймак, куймак* — тат. *кой-у* < гом. тк. *куй-* «кою» фигыленнән; күп телләрдә очрый; к. монг. *хуймаг* «коймак».

**КОЙРЫК** «хвост» — гом. тк. *қуйруқ* < *қудуруқ*, чув. *хӳрĕ* һ.б., бор. тк. **куди-* ~ монг. *годи-* «койрык болгау» сүзеннән (*кудурук* «болгагыч»); к. уйг. *куйук* < *кудук* «койрык»; бу варианттан бор. **куйу* «койрык» сүзе килеп чыккан булса кирәк; к. тат. *коешкан* < гом. тк. *қуйушқан* «җигемлекнең койрык асты бавы». К. бурят. *годируу* «borгаланып, болганып торган (койрык)».

**КОЙТЫ** «плохой, дурной» — башк. *който*, кырг., кк., ккк., *куйту*, төрек. *койту, коту, кӧту*, бурят. *хойто*, монг. *хойту* «караңгы, арткы, төньяктагы, күләгәдәге, түбәндәге, киләчәк» — көнч. тк. *куй*, бор. тк. *койы, коды*, үзб. *қўйи* «түбән жир, түбәнлек, үзән» сүзеннән. *Койты* «калдык» мәгънәсе үзе монг. сүзе (*-ты* кушымчасы).

**КОЙ-У** «лить» — гом. тк. *куй-* бор. гом. тк. *куд-* «кою, сибү» сүзеннән; к. якут. *кут-* «кою».

**КОЛ** «раб» — гом. тк. *қул* «кол» сүзеннән; чаг. бор. чыгт. *ғул* < фарсы. *ғул* «богау» (Боровков).

**КОЛА** «буланый, саврасый» — гом. тк. *қула* < *куба-луғ* «коба төскә тартым» сүзеннән; к. тув. *кувала* id. Шуннан ук *қолан* < гом. тк. *қулан* «кыргый ишәк» сүзе дә килә.

**КОЛАК** «ухо, уши» — гом. тк. *қулақ*, бор. тк. *қулғақ*, якут. *қулғах*, чув. *хăлха* «колак», бор. гом. тк. **қул-* «ишетү» фигыленнән булса кирәк; чаг. фин. *kullo-* «ишетү», мар. *кол-*, манси. *кол-*, хант. *хул-* «ишетү».

**КОЛАКЧЫН** «ушанка, малахай» — *колакчан* «колаклы» формасыннан.

**КОЛАЧ** «размах; обхват» — гом. тк. *қулач* «колач» — *қул* (к.) сүзеннән; к. тк. диал. *кōл ачысы* «кул арасы».

**КОЛАША** «лоток; желоб» — мар. *кулаша*, тат. диал. *кулача* «колаша» — Троянский сүзлегендә *колаша* «колаклы улак, җилпуч» *колакча* сүзеннән. Чув. *хăлаш* «корыто» — татарчадан булса кирәк.

**КОЛГА** «шест» — чыгышы бик үк ачык түгел: диал. (себ. тат.) *қолга*, хакас. *хулха* < бор. тк. *колуңа* «кыяк, камыл» сүзенең колга белән мәгънә бәйләнеше сизелми, тат. әд. *колға* — бор. тк. *қобулға* «тирмә таягы» сүзеннән булса кирәк. К. **Кобага.**

**КОЛМАК** «хмель» — киң таралган сүздән; к. тат. диал. *қомлақ, қомалақ, қумалақ* «колмак», рус. *хмель*, чув. *хумла*, мар. *ымыла, ӹмӹлä*, венг. *komlo* h.б., эвен. *коланак* «колмак, сыра». Ахыр чиктә шумер. *huml* «сыра, колмак» сүзеннән.

**КОЛЫН** «жеребенок» — гом. тк. *қулун* — бор. тк., гом. тк. **кулу* тамырыннан, к. тат. диал. *колык, колкай, көлкәй* «колын, колынчак», *көл-көл* — колыннар чакыру ымлыгы, себ. тат. *кōлан*, бор. тк. *кулан* «кыргый ат, кыргый ишәк (кулан)», көнч.тк. *кулука* «колын», кк. *кулук тай* «колын», монг. *кула*, калм. *хулу* «кыргый ат». Чаг. эвен. *кулуна* «бәби», аккад. *кудуну* «качыр, мул».

**КОМ** «песок» — гом. тк. *кум* «ком» сүзеннән, чаг. алт. *кумак*, тат. диал. (себ.тат.) *кōмык*, монг. *кумаки* «ком, комлык».

**КОМАГАЙ** «жадный, ненасытный» — кк., ккк. *комагай* «комагай» монг. *хумгүй, хомхой* «үлгән эт өрәге» сүзеннән. К. **Комсыз**.

**КОМАК** «крыса» — к. башк. *қолмақ*, алт., хакас. *қулуңақ, қулуйақ*, монг. *кулгуна*, эвенк. *холоңго* «күсе, комак, сычкан». Рус. *колонок* — төрки телләрдән. Сүзнең тамыры **кол // қул*.

**КОМАЧ** «кумач, красная ткань» — киң таралган сүз: чув. *хăмач* < болгар. **хомач* ~ бор. тк. **кумат* << гар., фарсы. *кумаш, комаш*, бор. рус. *кумак*, фин. *китакка* «комач» ахыргы чиктә бор. Мисыр телендәге *кмйт* (сузыклары билгеле түгел) «тукыма» сүзенә барып тоташа. Татар әдәби телендә «тукыма» мәгънәсендә *кумаш* сүзе йөргән; шуны белмәү аркасындамы, бүтән сәбәпләр беләндерме, сонрак *тукыма* сүзе активлашкан.

**КОМАЧАУ** «помеха, препятствие» — чув., мар. *кумача, кумачав*, башк. *камасау* «комачау; экзема; бауга тезелгән кармаклар» — Идел-Урал регионында таралган сүз: морд. *комача-* «каплау, өртү» сүзенең *комачау*-га бәйләнеше бәхәсле.

Ихтимал, *комачау* < *камау-чау* парлы сүзеннәндер: *камау* «ябу, бикләү, уратып алу» һәм **чау* (~ чув. *чав-*) «окоп казу».

**КОМГАН** «кумган» — гом. тк. *кумкан* «комган» киң таралган сүздән к. бор. чыгт. *кумка* «кувшин», якут. *хомуос* «чүмеч», фарсы-таж. *хуж, хумб,* бор. ирани *хи ва* (*хумба*) «комган», рус. диал. *кумка* «стакан», грек. *хубба*, рус. *куб* (*кубок*) «комган».

**КОМСЫЗ** «жадный» — ниндидер **ком // кум* тамырыннан; чаг. бурят. *хомкой, хом-гуй* «комсыз», алт. *ком* «иганә, үзең теләп биргән ярдәм». Димәк, *комсыз-* (дөресрәге, *кумсыз*) «җәмгыятькә берни бирмәүчән».

**КОН** «родовая месть; партия» — гом. тк. *кун* «хак, түләү, үч» сүзеннән; шуннан ук *кỏнсыз* «намуссыз, намус хакы алынмаган» (чаг. ккк. *кунсыз* «очсыз, хаксыз, кыйбат, үче алынмаган» (Чаг. ирани, *хун*, бор. ирани. *хип*, *vohuni*, *vos* «кан үче, канга-кан принципы». К.Әхмәтьянов, 1981:115—116.

**КОМЫЧ** *диал.* «крестец; альчик, сделанный из крестца» — к. чув. *кăмăч*, кум. *куймыч*, кк., ккк. *куймыш* «комыч».

**КОҢГЫЗ** «жук» — бор. тк. *коңкуз, куңкуз, коңкур* «коңгыз» сүзеннән, ясалышы ачык түгел (чаг. *коңгырт*); к. бор. монг. *коңнузук*, якут. *хомурдуос*, эвенк. *комордох* «коңгыз», чув. *кăмăр* «бал корты, умарта корты»; гар. *хунгус-ун* «коңгыз» — төрки телләрдән.

**КОҢГЫР(Т)** «темно-коричневый, карий; русый» — гом. тк. *коңгур(т), куңнур(т)* «коңгырт» (бор. монг. *конкур* «карасу, коңгырт») сүзеннән, ясалышы ачык түгел; к. чув. *хамар* «көрәнсу, күксел», монг. *коңгур* «саргылт, соры кыргый каз», эвен. *хаңра, хакарин* «кара, карасу», рус. *каурый* «карасу, коңгырт төстәге (*ат*)» — төрки телләрдән.

**КОНДЫЗ** «бобер» — чув. *хăнтăр*, мар., удм. *кундыр*, мар. *умдыр, ындыр*, манси. *хонтел* < болгар. *кỏндỏр* (шуннан ук Татарстандагы *Кондырча* елгасының исеме килә: *Кондыр+ча* «кондыз елгасы» дигән сүз (~ гом. тк. *кундуз* < бор. тк. **кунгург* id., тат. *кỏны*, гом. тк. *куну* «куница, росомаха» сүзе белән тамырдаш булса кирәк. Гар., фарсы. *кундус* «кондыз, кеш» — төрки телләрдән.

**КОРАЛ** «оружие; инструмент» — чув. *кăрал*, мар. *кырал* ~ гом. кыпчак., үзб., уйг. *курал* «корал», н., кум. *курал* «музыка әсбабы» төрек. *kuval* «кагыйдә» < бор. тк. *курғал* «яклану (оборона)» сүзеннән, *курға-у, корға-у* «тирәләп алу, һәр яктан яклау» фигыле нигезендә ясалган. К. **Курган, Курку.**

**КОРАМА** «составленный, сшитый из лоскутков» — башк., тат. диал. *кора-*, гом. тк. *кура-* «аерым кисәкләрдән җыю» фигыленнән; к. кк., ккк. *кура-* «аерым кисәкләрдән җыю; запаслану» (чаг. ккк. *кур* «запас»), алт. *кура-* «аерым кисәкләрдән тезү, өстеөстенә өю, өстәп кору».

**КОРБАН** «жертва» — гар. *курбан-ун* «корбан» сүзеннән.

**КОРДАШ** «ровесник, сверстник» — гом. тк. *кор, кур* «яшьтәшләр төркеме, вакыт, замана (Боровков); мохит, түгәрәк, табын» сүзеннән, ягъни төрки гадәт буенча, бер чордагы (уникеллык циклдагы) ир-егетләрнең аерым табында бергә ашау күренешеннән (шуннан ук *кор-у* «бергә җыю, бергә җыелу»; тат. *корын*, гом. тк. *курун*, тат. һ.б. *корылтай* < монг. *курултай* «иҗтимагый җыелыш». К. тат. диал., башк. *кỏр* «түгәрәк табын, ирләр табыны», *кỏрга керү, кỏрга инеү* «балигъ ир-ат рәтенә керү», үзб. *кур* «табор, лагерь». Чаг. шумер. gur «әйләндереп алу»; тамырның палаталь варианты *кỏр, күр* дә киң кулланышлы. К. **Көрәгә, Кичкырын, Кушак, Кыршау.**

**КОРСАК** «живот, брюхо» — бор. тк. *куғур-сак* «корсак, ашамлык» сүзеннән, бор. *куруғ* нигезеннән; к. бор. тк. *куруғсак* «карын, корсак» (МК), тат. диал. (себ. тат.) *курык-лык, курук-лык* «үнәч, ашказаны». Сүзнең тамыры — *кỹр-* «ашау». К.**Корт**.

**КОРТ I** «червь, насекомое» — гом. тк. *курт* «корт» бор. тк. *куру-т* «корт» сүзеннән, ягъни *кỹр-, кỏр-* «ашау» фигылениән ясалган исем булса кирәк (к. **Кортка, Корсак**); көнч. тк. (якут., тув. *хорохой, хорагай* «корт, кигәвен; ефәк корты» ~ бурят. *хорхой*, монг. *хорагай, корагай* «эч корты». Иске тат. *корт* < чыгт. *курт* «бүре» сүзе дә шул нигездән («ашаучы») булса кирәк.

**КОРТ II** — **Корыт**

**КОРТКА** «старуха, старушка» — тат. диал. *кỏрт, карт*, куман., чыгт., уйг. *куртка*, алт., тув., хакас. *куртуях* id. бор. *курт* «ашаучы», ягъни «файдасыз тамак» сүзеннән булса кирәк.

**КОР-У** «сооружать, строить» — гом. тк. *кур-* «кору, төзү» id., тат., башк. *кỏр* < гом. тк. *кур* «алка; билбау; түгәрәк табын; период» сүзе белән тамырдаш; чаг. тат., башк. *кора-у* < гом. тк. *кура-* < *кур-а* «аерым кисәкләрдән җыю». К. **Корама, Коршау, Корылтай.**

**КОРЧАҢГЫ** «чесотка» — чув. *кăрчанкă*, мар. *курчанге, кырчангый*, удм. *кырчангы, курчангы, куршангы*, гом. кыпчак. *курчангы* id., тат. диал. *корчы-*, башк. *корсо-~*, бор. монг. *gorčiji* «кычыну, тик торалмау» — бор. тк. *корт-чы-* «кортлану, кортлау» сүзеннән булса кирәк.

**КОРША-У** «обруч; окружать, охватывать» — бор. тк. *курша-*, алт., кырг. *курча-* «коршау, алкалау» бор. тк. *кур* «алка, түгәрәк, боҗра» сүзеннән.

**КОРЫ** «сухой, высохший — гом. тк. *куруғ* id. К. **Коры-у.**

**КОРЫ-У** «засыхать»— гом. тк. *куру-, кур-, кура-* id, бор. *куғру-, куғ-ра-* id. «ку булу, кибеп кору» фигыленнән, *ку, куғ, қағу* «кипкән, корыган үлән» тамырыннан.

**КОРЫК** «крюк, лассо; шест» — тат. диал. *оқырык, уқрук*, якут. *оғурук*, тув. *уруғ* һ.б. id., якут., эвен. *огур* ~ чув. *укăр, ухăр* «корык, элмәкле бау, аркан» сүзеннән. *Аркан* сүзе дә шул нигездән булса кирәк.

Күчмә терлекчелек дәверендә корык һәм аркан иң кирәкле эш коралы булганнар.

**КОРЫЛТАЙ** «съезд, курултай» — гом. тк. *курултай* < монг. *хурултай, хурилтай* «корылтай, җыен» Чыңгыз-хан империясе заманарында таралган сүз (монг. *хурал, хурил* «җыен, утырыш, кор», *-тай* — кушымча). Бу сүзнең төрки эквиваленты карын < *курун, курум. Корылтайда, корында* төрки-монгол. *кур* «түгәрәк табын» тамырыннан; чаг. шумер. *kur* «түгәрәк, әйләнә». К. **Кор-у.**

**КОРЫМ** «сажа» — гом. тк. *курум*, бор. тк. *куруң*, якут. *коруо* «корым». Чаг. кк. *курум* «каралган, көйгән киез», кырг. *курум кан* «куерык, кан». Чаг. маньчж. *куварча, курча* «корым». К. **Корыч.**

**КОРЫТ** «курут, сушеный сыр» — гом. тк. *курут* id., *куру-* «кору, кибү» сүзеннән дип карала. К. ш.ук. бор. монг. *хурууд* «сыр; азык».

**КОРЫЧ** «сталь» — чув. *хурăç, хурçă*, мар. *хурыс, урсо*, удм. *курч, кырч* id. (бу вариантлар корыч коюның Идел-Чулман регионында күптән билгеле булуын күрсәтәләр) — бор. тк. *курч тәмур* «үткен тимер, корыч», алт., госм. *курч*, монг., калм. *хурц* «үткен».

*Курч* «үткен» сүзе күп телләрдә бар, әмма аның тамыр бәйләнешләре ачык түгел. Шуңа күрә бу сүзне маньчж. *курча-ла-* «тимерне корымда чыныктыру» сүзе белән баглы дип уйларга мөмкин. К. **Корым**.

**КОРЫЧАГАЧ** «ясень» — тат. диал. *көреч агачы*, кб. *күрүч*, чув. *кăвăрăч*, венг. *kõrisfa* «көреч» (*fa* «агач»), осетин. *кӧрз*. Сүзнең чыганагы — фарсы. *гүрүнч* > тат. диал., үзб. *гүрүч* «дөге» булса кирәк: корычагач яфрагы дөгенекенә охшый.

Әйтелгәннән аңлашылганча, сүзнең дөрес варианты *көреч*. *Корыч агач* дию халык этимологиясе нигезендә килеп чыккан.

**КОС-У** «блевать» — гом. тк. *кус-* «косу, агару, төссезләнү» (шуннан *башак косу* «башак агара башлау»).

**КОТ** «душа, уют; счастье» — гом. тк. *кут-* үзенә бик күп тикшеренүләр багышланган сүз. К.Әхмәтьянов, 1981:34. Борынгырак варианты тат. диал., башк. *көрт* < *кағурт* «кот сурәте; җан, бәхет рухы; орлык»; чаг. тат. *котлык кою, котлау, кот очу*. Монг., эвен. *хуту, куту*, ханты. *куут* «кот» төрки телләрдән алынган булса кирәк. К. **Коткару, Коткы, Котый.**

**КОТКАР-У** «спасать» — чув. *хăтар-* һәм *хăтăл-*, мар. *ытар-* һәм *ытыл-, утар-* һәм *утыл-* << госм. *куртар-* һәм *куртул-* «коткару» һәм «котылу» аз билгеле *кут-* < *курт-* «котылу, йолыну, кот бирелү (?)» нигезеннән.

Тат. диал. *котказ-* ~ үзб. *кутказ-* варианты бу фигыльнең шактый борынгы булуын күрсәтә.

**КОТКЫ** «подстрекательство; смута» — тат. диал. (мишәр.) *кот-* < *корт-* < *курт-*, *куурт-* «агитацияләү, куркыткыч хәбәр тарату» сүзеннән. Чаг. ш. ук. бор. монг. *qutqu-* «коткы салу». *Кот* сүзе белән баглы булса кирәк. К. **Котыру**.

**КОТЛА-У** «поздравлять» — чув. *хăтла-*, үзб., уйг., госм. һ.б. *кутла-* «котлау», *котлы* «бәхетле» сүзе кебек үк, көнбатыш (ислам тәэсирендә калган) төрки телләрдә барлыкка килгән сүзләр.

Бу төрдәге сүзләрдән борынгы *кутад-* «бәхет бирү» атаклы әдәби ядкарьлек «*Кутадгу билик*» атамасыннан билгеле. Шуннан чыгып *қөтла-у* һ.б.ш. сүзләр IX—X гасырларда формалашкан дип чамалап була. К. **Кот**.

**КОТЫЙ** «ящичек, шкатулка (*из дерева*)» — тат. диал. *котырчык, котолчык* «котыйчык» кк., ккк. *коты*, кырым., кырг. *куту*, кум. *кутук*, госм. *куту, кутук*, азәрб., ткм. *гуты, гуту* «котый, агач банка», үзб. *кутти* «котый», алт. *котты* «дары савыты», эвенк. *хутанан* «вак-төяк өчен кечкенә янчык», якут. *кытыйа* «агач чиләк». Сүзнең беренчел мәгънәсе «кот (тәре, фетиш) салып куя торган савыт», ә борынгы формасы *кутур* (шуннан тат. *которчык*) булса кирәк; к. алт. диал. *кутру* «тәре». Котның татарларда билгеле бер фигура (кеше яки кош, үрмәкүч шикелләрәк) булып күзаллануы *кот кою* йоласында сакланган. Кыргызларда, калмыкларда аучылар, сугышчылар һ.б. үзләре белән йөртә торган фетиш-фигураны *кут* «кот» дип атаганнар. Мәсәлән, кыргыз эпосында «*котын салып куйнына, мылтыгын асып муйнына аучы китә тауларга*» диелә.

Ибне-Фазлан әйтүенчә, X гасырда Идел буе төркиләрендә, Болгарда һәрбер ир кеше шундый тәре-котчыкны асып йөргән. К. **Кот.**

**КОТЫЛ-У** «спасаться» — к. **Коткар-у.**

**КОТЫРТ-У** «подстрекать; соблазнять» — чув. *кăтăрт-*, удм. *кутърт-ънъ*, мар. *ытырт-* (болгар теленнән) һәм *кутырт-* (татар теленнән) Идел-Урал регионында гом. кыпчак. *кутырт-* «үчекләү, котырырга мәҗбүр итү» сүзе нигезендә килеп чыккан.

**КОТЫР-У** «взбеситься» — гом. тк. *кутур-* «котыру» сүзеннән, ихтимал, *кут-тур* (йөкләтү юнәлеше кушымчасы *-тур*) сүзеннәндер; чаг. алт., чыгт. *кут-* «йөгерү, хәлдән таю, туктау»; бурят. *годоор* «котыру (*маллар турында*)», *года-ха* «койрык чәнчү, койрык кәкрәйтү», *годой-хо* «үрә тору». *Котыр-у* сүзен *кот ору* дип аңлату гом. тк. фактлар белән расланмый. К. **Коткы.**

**КОЧ-У** «обнимать» — гом. тк. *куч-* «кочу» сүзеннән, бор. тк. *куч-* «кочу, каплау», бор. тк. *кауч* < *кабуч* < *каб-ут-* «каплап алу» (*кап-ыч-*) сүзеннән булса кирәк; к. якут. *куус*, монг. *кучи* «каплау, камау, чолгау». К. **Кап**.

**КОШ** «птица» — гом. тк. *куш*, тат. диал. *когыш*, бор. тк. *кугуш* «кош» сүзеннән; чаг. тат. диал. *кугу* «аккош», *кош-корт* җыйма сүзендәге *корт-* бор. тк. *курт* «селәүчен, бүре, җәнлек» (МК) сүзеннән. К. **Корт.**

**КОЯШ** «солнце» — гом. тк. *куйаш* «кояш», — бор. гом. тк. *күң-әл* «кояшлы урын», *кун* (*куң*), *кун* (*күң*), «кояш, көн» сүзеннән; к. гом. тк. *кун* «кояш, көн», тат. диал. *кенәш*, уйг. *күнәш* «кояш», ханты. *кунэл*, венг. *hajnal* «таң, яктылык, көн», чув. *хěвел* «кояш». *Көн* һәм *койаш* сүзләре тамырда икесе ике сүздән диган фикерләр дә бар (Рясянен, Егоров).

**КӨБӘ** «кольчуга, панцирь» — бор. кыпч. *күбә // күпә* «көбә, броня» сүзеннән; к. кырг. *күбө*, кб. *күбә*, кум. *гүбә*, чув. *кепе* «көбә, күлмәк», эвенк. *кумо, куму* «шаман костюмы»; чаг. тат. диал., башк. *көпе*, кк. *кепе, кеппе* «сырган фуфайка», бор. тк. *күпик* «ике кат бөз арасына мамык түшәп тегелгән кием» (МК) ~ кырг. *күпү* «дөя йоны белән эчләп сырылган калын сырма көбә». Сүзнең этимологик тамыры — тат. диал. *күп-* «сыру» булса кирәк.

**КӨБӘК** — к. **Күбәк**.

**КӨЗ** «осень» — гом. тк. *куз*, бор. гом. тк. **кургь* «көз» сүзеннән; к. чув. *кӗр* «көз», венг. *köd, köz* «көз, томан» (бор. тк. телләрдән).

**КӨЗӘН I** «хорек» — гом. тк. *көзән, кузән*, көнч. тк. (себ. тат., алт.) *курән* «көзән (хорек, хорь)», венг. *qöreny* (*гөрәң*) «көзән» (бор. тк. телләрдән) *көрән* (к.) сүзе белән бер чыгыштан булса кирәк (Рамстедт). Чаг. **Җирән ~ Җәйрән.**

**КӨЗӘН II** «паралич; судорога» — чыгышы ачык түгел; к. чув. *кӗсен* «кутыр(!)», удм. *кузен* «көзән»; чаг. бурят. *хэрхэ* «ревматизм». К.Әхмәтьянов, 1989:98.

**КӨЗГЕ** «зеркало» — бор. тк. *кузе-гу // кузә-гу* «карый торган нәрсә» сүзеннән, бор. *кузә-* «карау, күрү» фигыленнән (чаг. *кузәт-у*); к. бор. тк. *көзңү, көзүңү*, бор. уйг. *кузэгу* «көзге» (МК), алт. *көрүнгүш*, хакас. *көрендес* «көзге», кк., кырг. *кузгу* «көзге», тув. *көску* «күренеп торган; үткер күзле», чув. *куҫ-кӗски* «күз көзгесе, көзге», сүзнең тамыры — *көз // көр*. К. **Күз**.

**КӨЙ** «мелодия» — гом. тк. *куй*, бор. тк. *көг* «көй, мелодия» сүзеннән; к. чув. *кӗвӗ*, хакас. *көг*, тув. *хөг* «шатлык, яхшы кәеф; көй, мелодия», бор. тк. *көг* «шигырь үлчәме, мелодия, мәзәк» (МК) Чаг. тат. диал. *көйөлте, көгелте* «кулик», хакас. *көгелде* «кулик», *көглэ-* «көйләү, сайрау». *Көг* тамыры бор. кытай. *куöq, куоg* (хәзерге кытайча *цюй*) «кимвал» сүзеннән.

**КӨЙМӘ** «свод, шатер» — чыгышы ачык түгел, *көймә* «каек» һәм *көймә* «свод, шатер» икесе ике тамырдан (Егоров); кк., ккк., н. *куйме*, чув. *хӳмэ*, калм. *кумэ* «арба кыеге, көймә»; чув. *кӗрме* «каплау, ябу» < тат. *көрмә* id.

**КӨЛ** «зола» — гом. тк. *кул* «көл» сүзеннән; чаг. эвен. *хөлтэн*, эвенк. *һулэптэн* «көл».

**КӨЛӘЧ** «улыбающийся, веселый» — бор. тк. *кулугәч* «көләч» сүзеннән; к. якут. *кулугэс* «көләч», хакас. *кулэчи* «мыскыллап көләргә яратучан», *көл-* гом. тк. *кул-* «көлү» сүзеннән.

**КӨЛТӘ** «сноп» — көнч. *кул-тэ* (к. н., кб., кум. *култэ* «көлтә», кк. *култэ* «учлам, толым») «көлтә, бәйләм» сүзеннән, бор. тк. *кул-* «бәйләү» фигыленнән (Егоров); к. бор. монг. *кули-* «бәйләү», мар. *келда-ш* «бәйләү», *келтӓ*, «көлтә», удм., коми. *культо* «көлтә» — төрки телләрдән. К. **Күлек**. К. Әхмәтьянов, 1989:61.

**КӨЛЧӘ** «булочки, лепешки» — кк., ккк. *кулше* «көлчә», уйг. *кулчә*, үзб. ткм. *кулче*, кырг. *кулчӧ*, тат. диал. *көләчә* «көлчә», калм. *кулцу* «көлчә, юл азыгы», кырг. *кул, кул азык* «озак юлга йөргәндә ала торган азык» — рус. *кулич* «көлчә» — төрки телләрдән (Рамстедт); *кул-* «ияргә бәйләү» сүзеннән, шуннан ук *көлчә* < *кулчә* «ияргә тагып юлга алынган азык». К. калм. *кулчихэ, кулmухэ-* «янга бәйләү, тагу». К. **Күлек**.

**КӨМӘЙ** «распорядительница девичьих вечеров» — бор. тк. *куңәй, куңәч, куң* «яндаш хатын» сүзеннән; *куң* (*куң хатын*), асылда, кытай сүзе.

**КӨМӘН** «беременность» — фарсы. *гөман* «шик, фараз; авырлы (корсаклы) булу» сүзеннән.

**КӨМЕРЕ** «горбатый» — к. ш. ук *көмерәй* «көрәшкәндә бөгелү». Башк. *көмөрә*, кырг., кк. *көмөрө, кумуру* «бөкре; күпер». Чаг. **Күпер.**



**КӨМЕШ** «серебро» — гом. тк. *кумуш*, чув. *кӗмӗл* «көмеш» сүзеннән, тамыр бәйләнешләре ачык түгел. Корей. *kim~* кытай. *kin* «көмеш» сүзе белән бәйләнеше (Рамстедт) шикле.

**КӨН** «день, *уст.* солнце» — гом. тк. *кун* «кояш, көн» сүзеннән. К. **Кояш**. *Көн куру* (*иту*) фарсы. *руз дидан* әйтеменнән калька (*руз* «көн; бәхет»).

**КӨНБАГЫШ** «подсолнечник, подсолнух» — *көн* һәм *багыш* «караш» сүзләреннән.

**КӨНДӘШ** «соперница» — бор. тк. *куңдаш* «көндәш» — бор. *куң* «өстәмә хатын» сүзеннән; к. диал. *куң* «хатын». К. **Көмәй**.

**КӨНДЕЗ** «днем; *разг.* обед» — гом. тк. *кундуз* «көндез, көн, кояш», чув. *кӑнтӑр* «көндез, төш, көньяк» сүзеннән, *көн* (к.) нигезеннән; чаг. *балдыз, андыз, йолдыз, кондыз*, диал. *кандыз* (абзар-кура) һ.б.; борынгы фонетик составы **кунуңур*; к. хакас. *кундуз*, кырг. *кундуң*, кб. — *кюнюом* «кояш төшкән урын».

**КӨНҖӘЛӘ** «моток шерсти, изготовленный для пряжи» — чув. *кӗнчеле*, бор. рус. *кондель* «көнҗәлә» сүзеннән исәпләнелә (Егоров); к. рус. диал. *кундель*, украин. *кундель* «көнҗәлә».

**КӨНЧЕ** «ревнивец» — бор. тк. *куни-че* «көнче» *куни* «көнчелек, көнләшү» сүзеннән; к. бор. чыгт. *куни*, уйг. *куни* «көнчелек, көнләшүчәнлек», алт., якут. *куну* «көнчелек» (*кунуләс-* «көнләшү»); сүзнең тамыры ачык түгел. Чаг. чыгт. һ.б. *кундук* < *кун-лук* «хөрмәт, игътибар, дәрәҗә».

**КӨПЧӘК** «колесо; маховик» — диал. *кубчәк* «көпчәк» сүзеннән, *куб-* тамырыннан (к. **Күбәк**). Чаг. **Көпшә**.

**КӨПШӘ** «стебель, труба, ствол ружья» — бор. тат. *куп-чәк* (к. **Көпчәк**) «көпшә, көпчәк» сүзеннән, *куб* тамырыннан. К. **Күбәк**.

**КӨПШӘК** «вялый; рыхлый» — бор. тат. (диал.?) *кубешәк* «күбенгән, күбешкәк» сүзеннән, *куп-у* фигыленнән; к. себ. тат. *кубешкәк*, урал. *купшәк* «көпшәк, кабарынкы», хакас. *көпсэк* «кабарынкы, йомшак, көпшәк», чув. *кӑпӑш, кӑпӑшка* «көпшәк». К. **Күб-ү.**

**КӨР** «здровый; жирный; бодрый» — гом. тк. *кур* «көчле, көр, кыю, усал» сүзеннән; себ. тат. (бараба) *кур* «үзсүзле, усал», хакас. *кур* «кыю, батыр, усал, шау-шулы», алт. *кур* «симез, көр, житез», чув. *кӗр, кӗрӗ* «көр, ныклы, каршы; ботаклы (*агач турында*)».

**КӨРӘГӘ** «маленькая кадка, кадушка (*для кумыса*)» — башк. *көрәгә* «агач чиләк», н. *куреге* «кымыз көрәгәсе». В.Г.Егоров фикеренчә, чув. *кӗреке* бор. тк. *курәгә* «түгәрәк табын, мәҗлес табыны» сүзеннән; к. алт., хакас. *көрээ* «әйләнә; түгәрәк, кырпу, түгәрәк табын, туй урыны», чыгт. *көргэ* «кымыз кую өчен урындык», тат. диал. (керәшен) *корга* «көрәгә».

**КӨРӘК** «лопата» — бор. тк. *кур-гәг* «көри торган нәрсә» сүзеннән (к. **Көрә-ү**); чаг. якут. *курцэх*, монг. *курҗэк* «көрәк», чув. *кӗреҫе* «көрәк».

**КӨРӘН** «бурый; буровато-коричневый» — гом. тк. *курән, курәң* «көрән, кара-көрән» сүзеннән, *кур* тамырыннан (шуннан ук к. *көзән*); к. тув. *курәң* «көрән», *хургул* «коңгырт», якут. *курәң, куруң*,

бурят. *хуруң* «көрән», монг. *курэнэ* «көзән (җәнлек)», *курэң* «көрән», башк. *көртә* «коңгырт, көрәнсу», чув. *кĕрĕ, кĕре* «кара-су, көрәнсу», *кĕрен* «алсу, чия төстәге, җирән», фарсы. *куранд* «көрән» төрки телләрдән үзгәреп кергән булса кирәк.

**КӨРӘ-Ү** «сгребать, выгребать» — гом. тк. *курә-*. К. **Көрт.**

**КӨРӘШ** «борьба» — гом. тк. *курәш, курәш-* id. бор. тк. (госм.) *курә-* «җину» сүзеннән: *курәш-* «җинеш-». Чаг. **Көр**.

**КӨРЕ** «нитченка» — бор. гом. тк. *кур-уг* «көре» сүзеннән, татар теленә бор. болгар яки чуваш теленнән кергән булса кирәк (шул ук чыганактан кк. *куру*, башк. *көрәс* «көре»), чөнки гом. тк. янгыраштан булса *көзе* булырга тиеш иде (алт. *кузуг*, кырг. *кузук, кузуу* «көре»); к. чув. *кĕрĕ* (*көре*); чаг. **Көрмә-ү.**

**КӨРМӘ-Ү** «завязывать узлом» — шуннан *көрмәк* «тыгыз төен», *көрмәл-у* «чуалып бәйләнү» — бор. *көр, кур* «элмәк, төен, төенләнү».

**КӨРПӘ I** «отруби; высевки» — киң таралган һәм ясалышы бик үк ачык булмаган төрки сүз; к. чув. *кĕрпе* «көрпә, ярма», венг. *korpa* «көрпә» ~ монг. *хурпээ*, бурят. *курпэк* «ярма, көрпә» (тат. диал., башк. *көрпәк* «көрпә, вак кар»).

**КӨРПӘ II** «подстилка; покрывало» — үзб., кк., чыгт. *курпә* «көрпә, юрган, җәймә» — чыгт. һ.б. *курпә* «яшь бәрән (тиресе)» сүзеннән.

**КӨРТ** «сугроб» — удм. *кырт, кӱрт,* мар. *кырт,* чув. *кĕрт-*, гом. тк. *курт* «көрт, кар өеме» ~ якут. *курт-* «кар көрәү», тув. *хөр,* бурят. *хур* «көрт». *Көрт, курт* < *курут* «көрәп алына торган нәрсә».

**КӨРТЛЕК** «тетерев; куропатка» — *көрт* (көрттә, кар астында кышлаучы кош) сүзеннән. Кайбер контаминацион йогынтылар да булган; к. алт. *курт*, хакас. *курку*, тув. *курту*, якут. *курткуях* «көртлек», тат., башк. *көртлә-у* «кудахтать, квохтать».

**КӨРЧЕК** «граница, финиш; тупик» — башк. *көрсөк*, кум., кб. *кюрчю* «фундамент» бор. *курт* «нигез ташы» сүзеннән; чаг. чув. *хĕрт* «нигез», кум. *кӧрук* «мич төбе». Бу сүз исә монг. *курчук* «чик билгесе», *курчу-* «терәлү», *кур-* «җитү» сүзләреннән булса кирәк.

**КӨСМӘН** «рулевое весло» — чув., мар. *кусмән, кĕсмен-*, себ. тат. *көрөсмән, курусмән* «ишкәк», алт. һ.б. *курэ-* «ишкәк ишү, көрәү» сүзеннән.

**КӨТЕК** «куцый, кургузый» — чув. *кĕтĕк* «көтек, кисек колаклы», гом. тк. *кутук, кӧтек* «көтек, тупа, үтмәс» сүзеннән, ниндидер *кут-* тамырыннан.

**КӨТ-Ү I** «ждать; пасти» — чув. *кĕт-*, мар. *кыт-, кут-*, удм. диал. *кыт-*, гом. тк. *кут-* «көтү, карап тору», бор. тк. *ку-, куй-* «көтеп карап тору» фигыленнән (шуннан бор. тк. *кур-, куз-* «көтү» вариантлары да ясалган).

**КӨТҮ II** «стадо» — чув. *кĕтӳ,* мар. *кӱтӱ, кыту, кыто*, удм. диал. *кыту,* удм. *кутьы* «көтү (стадо, табун)» фигыленнән килеп чыккан. «Көтеп тору > мал көтү» мәгънә күчеше типологик характерга ия; к. шор., тув. *кадар-* «ждать; караулить; пасти».



*Көт-* татар телендә бик продуктив сүз ясагыч нигез: *көттерү, көтүче, көтүлек* һ.б. сүзләр бүтән телләргә дә кергән.

**КӨЧ** «сила; мощь; усилие» — гом. тк. *куч* «көч, көчле, кыен» сүзеннән; чаг. монг. *кучин, кучун,* маньчж. *кусу(н)*, тув. *кучу* «көч, көчләү; сугыш, гаскәр, утыз кешедән торган команда».

**КӨЧЕК** «щенок» — гаять киң таралган сүз: алт., кк., үзб. *кучук* «көчек, бүре баласы, эт», коми. *кычи* «көчек», болгар. *коче*, серб. *куче* «эт», рус. *кутенок* «көчек», бор. ирани., бор. һинд. *kuutā, kuttȳ* «эт, көчек», венг. *kutja, kutti* «эт», коми. *кути*, удм. *кутья* «эт, көчек»; чаг. шулай ук тат. диал. (мишәр.) *кочык* «эт, көчек» > чув. *кăчăк* «эт», *кăчкă* «тал көчеге, яңа туган җәнлек», тат. диал. *кунчык* «эт, кәнтәй», монг. *качикан* «көчек». Бор. монг. *канчикан*, ягъни «көчек» сүзенең бор. *кан «эт, кәнтәй» (к. **Кәнтәй**) сүзе белән бәйләнеше бар.

**КӨШЕЛ I** «куча намолоченного зерна на току» — рус. *кошель* «капчык, торыпша (ашлык җәяр өчен)» сүзеннән булса кирәк; к. иск. *кушил* «торыпша, торыпша өстенә җәелгән яки өелгән ашлык, көшел» (К. Насыйри), сүзнең тамыры *кӧш, кӱш-* төрки сүз булса кирәк; чаг. рус. диал. *кош* «кәрзин, үрелгән шалаш, кура», *кошель* «камыш җәймә, камыш кәрзин, саллар бәйләмә».

Бу сүз төптә чирмеш-мари теленнән булырга да мөмкин; к. мар. *кӱшӱл, кышыл* «кабык кыса, көшел» — удм. *кусыл* id. К. Әхмәтьянов, 1989:61.

**КӨШЕЛ II** «водяной крот, выхухоль» — *кусе* (к.) сүзе белән тамырдаш; к. кырым. *кушел*, алт., кырг. *кужул*, калм. *кушле* «күсе», тат. диал. *кушмәр, көсмәр* «күсе; көшел».

**КӨЯ** «моль» — гом. тк. *куйә* «көя» сүзеннән, тамыр бәйләнешләре ачык түгел (төрлечә чагыштырырга мөмкин); чаг. госм. *гувә*, азәрб. *кувә*, чув. *кĕве,* кырг. *кубӧ*, бурят. *хибэ* «көя»; монг. *гуур, хуйр* «көя»; себ. тат. *көйә* «корым», чыгт. *куйә*, бор. монг. *кӧйэ* «корым» һәм мар. *кӧгәр* «пешкән, көйгән урын», *кӧгәрше* «көя (ягъни *көйү* сүзеннән)», удм. *кей* ~ фин. *köj* «көя» төрки телләрдән булса кирәк (Рясянен).

**КӨЯЗ** «щегольской, фасонистый» — гом. тк. *куйәз*, бор. гом. тк. *кӧгәрг «горур, мактанчык» сүзеннән, шуннан ук тат. диал. *көйөрек* «җилкенүчән, масаеп китүчән» (Рясянен), чув. *кавăрă* «җилкенүчән», венг. *körö* ~ мар. *кăрă, кагура*, монг. *кэурэг* «көяз, җилкенүчән», уйг. *кәwәз, кәбәз* < *kebgerg' > монг. *кӧгәр* «мактанчык, көяз», бор. уйг. *куфәз* «көяз» (МК).

**КӨЯНТӘ** «коромысло» — бор. *киб-әнтә // киб-әлтә* «кер чайкау өчен махсус таяк» сүзеннән, *киб- // кӧб-* «кер болгату, кер чайкау» фигыленнән булса кирәк (Рясянен), фонетик үсеше: *кибәнтә, киwәнтә ~ көйәнтә*, мәгънә үсеше — «кер чайкау таягы, ике башына юылган керләр асып, су кырыена барганда җилкәгә алына торган таяк яки көянтә»; к. н. *куйэн*, кк. *куйәңтә*, тат. диал. *кеwәнтә*, чув. *кĕвенте* «көянтә», *кив-, кĕв-* «махсус таяк белән кер юу, бәләкләү», монг. *гӧби-, гӧбӧ-х*, эвен. *гив-дэй* «таяк белән тузан кагу».

**КУ** «сухие стебли (*травы*); трут» — гом. тк. *қау*, бор. тк. *қawағу, қабағу* «ку, көл астындагы тере күмер» сүзеннән, нин-дидер *қағу // қабу* тамырыннан, киң таралган сүз; к. тат. диал., кк. *қау, қыу* «кипкән, коры, саргайган, аксыл-сары; хәйләкәр (көл астында яткан күмер шикелле)», *қу* «мәшкә», башк. *қыу* «коры, җиңел холыклы», *қыуа, қыуау* «тора корыган агач»; сүзнең тамыры хакас. *хох*, тув. *қоқ*, бурят. *хуг* «ку, тере күмер» сүзләренә якын булган булса кирәк. К. Әхмәтьянов, 1989:30—32.

**КУАК** «куст, кустарник» — чув. *хăва*, мар. *хуа, уа*, удм. *куак*, башк., н., кк. *қууақ, қыуақ* ~ тув. *хаак* «тал, таллык», госм., ткм. *қавақ, қауақ* «тупыл», себ. тат. *куғу, куғы* «вак наратлык» — ихтимал, *ку* (к.) сүзе белән баглыдыр. Ягъни «утын өчен ярак-лы агач» дигәннәндер.

**КУАН-У** «радоваться, обрадоваться» — мар. *куан, хуан, уан* «шатлык, куаныч», *куан-* «шатлану, өметләнү, ышану», чув. *хăвал, хăван* «күтәренкелек, шатлык», удм. *куан-* «соклану, куа-ну» — гом. кыпчак. *куан-*, кырг., уйг. *кубан-* себ. тат. (Гиганов) *кув*, уйг. *кыв* «шатлык» сүзеннән. Чаг. ш. ук бор. кытай. *куа* «шатлык».

**КУБ-У** «сняться с места; отдираться» — гом. тк. *қоп-* id. К. **Кузгал-у.**

**КУБЫЗ** «комуз; *диал.* скрипка» — чув. *купăс*, удм. *кубыз, кобыз*, мар. *ковыж, комыж* скрипка, кайбер төбәкләрдә «сы-бызгы» — гом. тк. *кобыз* «кубыз», монг. *хуур, хугур, копур* скрипка бор. кытай. *хубули* скрипка сүзеннән дип карала. Ләкин алт. *комур-ғай* «курай» үзе кытай сүзенең чыганагы була ала.

Рус., украин. *кобз, кобза* скрипканың бер төре» бор. төрки телләрдән: *кобзарь* «музыкант» сүзе дә төрки *кобузчы* сүзеннән калька. Чаг. «Зая түләк» дастанында *купсау* «скрипкада уйнау».

**КУБЫЛГЫ** *диал.* «переливающийся» — гом. кыпчак. *кубыл-*, монг. *хубул-* «ялтырап үзгәреп тору» фигыленнән (*куп-* фигыле белән бәйләнгән); к. себ. тат. *куплыма* «ике төсле (бәрхет)», башк. *кǒбылйы-у*, кырг. *кубылжы-* «төсе үзгәреп тору». К. **Купшангы, Купшы**.

**КУВШИН, КУКШИН** «кувшин» — рус. диал. *кукшин* сүзеннән, ләкин рус сүзе үзе төрки-куман теленнән булырга тиеш: ул «күкесыман савыт» дигән сүз.; к. төрек. диал. *гугум* «күке: күке рәвешендәге чүлмәк», бор. **кукучын* — эвенк. *кукучән* «күке». Русча *кувшин* ~ *кукшин* вариантлары кыпчак телләрендәге аваз тәңгәллекләрен хәтерләтә (*к-г-w*).

**КУЕ** «густой; частый» — гом. тк. *койу, койуғ* id. Тат. теллендә бу нигездән күп кенә яңа сүзләр ясалган: *куер-у, куерт-у, куерык* «болганчык».

**КУЕН** «пазуха; объятие» — гом. тк. *кой-ун* (*-ун* — тән әгъза-сын белдерүче кушымча) «куен, күкрәк, култык» — бор. тк. *койун* «куй, сарык» сүзеннән; к. госм. *қой*, бор. тк. *қой* «куен, елга төбе (МК); көнч. тк. *хой* «куен, күкрәк, куй, сарык тире-се». Борынгы киемнең күкрәк турысы куй тиресеннән тегелгән.

**КУЗ** «горящий уголь» — гом. тк. *қуз, қоз* «күз» — бор. гом. тк. *қур* «куз, утлы күмер» сүзеннән; шуннан ук *ут-куз* сүзенең икенче компоненты (чаг. азәрб., төрек. *кӧз* «куз, утлы күмер»). К. **Кур**.

**КУЗАК** «стручок» — гом. тк. сүз; чув. *кусак* «мәк башы», төрек. *қозалақ* «чикләвек, курак (мамык кузагы)», алт. *қузуқ* «чикләвек». Ясалышы ачык түгел. К. **Кузы I.**

**КУЗГАЛАК** «щавель» — бор. *қузы қолақ* «сарык бәрәненең колагы» сүзеннән (Алпаров); чаг. үзб. *откулоқ* (*атколак*) «кузга-лак», кум. *қозуқулақ*, азәрб. *ғузуғулағы* «кузгалак».

**КУЗГАЛ-У** *диал.* «шевелить, двигать» — шуннан ук *кузгал-* < *козгал; кузгат-* < *козгат-*, иск. тат. *кузгалан* «фетнә, восстание» гом. тк. *козга-*, бор. тк. *корга-* «хәрәкәткә китерү, тынычлыктан чыгару» фигыленнән, *қоз-, қор-* тамырыннан; к. ккк. *қоз-* «җан-ландыру, көчәйтү, шәбәйтү», монг. *корга-* «кузгату»; чаг. тат. диал., башк. *қузғы-у, қужғ-у (күңел қузғы-у)* «тынычсызланды-ру, борчылу, тәшвишләнү». Борынгы *коз-, кор-* < *коб-, ур-, коп-* «кубу, утрак тормыштан китү, җәйләүгә чыгу» фигыленнән булса кирәк; к. монг. *хубисга-, хубис-* «алмаштыру, үзгәреш, куз-галу», бурят. *хувисхал* «революция».

**КУЗНА** «альчик, бабка (*для игры*)» — рус. *козон, козонки* сүзеннән. Бу сүз исә бор. тк. *қозун, қозунуқ* «кузы сөяге» сүзеннән.

**КУЗЫ I** «кокон; орех» — гом. тк. сүз, алт., хакас., себ. тат. *қузу, қузуқ* «эрбет чикләвеге, кедр», үзб. *қузи*, госм. *коза* «ефәк корыт курчагы» (тат. әд. *қузы* «ефәк корты курчагы»). К. **Кузак**.

**КУЗЫ II** «ягненок, барашек» — гом. тк. *қозу* «кузы, сарык бәтие» бор. гом. тк. **коро* «кәҗәсыман киек» сүзеннән; к. тув. *қозаға*, монг. *курага* «кузы», башк. *коралай, куралай* «кыр кәҗәсе», якут. *хоро* «яшь болан», бурят. *курай* «кыр кәҗәсе». К. **Кузгалак, Кузна.**

**КУЙ** «курдючная овца» — гом. тк. *кой, кой-ун* «куй, сарык» сүзеннән; чаг. монг. *конин, кон* «куй».

**КУЙ-У** «ставить» — гом. тк. *қой-* id. *Кум-у* белән тамырдаш.

**КУКЫР** «горделивый» — шуннан *кукыр-ай-у*. Бу сүз башк., тат. диал. *кук* «мактанчык» сүзеннән (*кук-ыр*); к. әйтем: *кук булганчы ашау;* мәкаль: *әни дә кук, мин дә кук; тук әтәч кук була.*

**КУЛ I** «рука» — гом. тк. *қул, қол* «кул, алгы аяк» сүзеннән; *кул* үзенең төп мәгънәсендә төрки телләрдә яңарак сүз, бор. төрки телләрдә *әл // эл* сүзе актив булган.

**КУЛ II** «долина между горами; ущелье» — чыгышы бик үк ачык түгел: бор. тк. *қол* «елга, үзән», монг., тк. *қол, кул* «колон-на; дивизия» > иске тат. *кул* — гаскәрнең өчтән бер бүлеге: *уң кул урар, сул кул турар, урта кул ук атар* (мәкаль). *Урта кулга* картрак сугышчылар куелган, шуннан *урта кул* (рус. *средней руки* татарчадан калька) «бик шәптән түгел».

**КУЛА** «бронза; сплав меди» — гом. тк. *кола* (киң таралган сүз) id. тибет. *гулиң* «җиз» сүзеннән.

**КУЛАВЫЗ** «проводник; пророк, учитель» — бор. тк. *кулawyз, кулғуғуз* «пәйгамбәр; юл күрсәтүче». Кайбер телләрдә бу сүз

«шпион» мәгънәсендә. К. бор. дунай болгар. *колоур* «гаскәргә юл күрсәтүче», «командир», аварларда *бо колабур* «баш рухани», якут. *холобур* «үрнәк»; *кулаwыз (-з)* янгырашы тәүләп Ибне-Фазланда очрый; А.Нәвоидә *колауз* «башняда утырган каравылчы». Чаг. монг. *хола, қола* «ераклык; ерактан күрүче; алдан күрүчән» (тат. диал. *қола ялан* «ялангач тигезлек»).

**КУЛАЙ** «удобный, выгодный» — башк. *қулай*, кк., ккк., н., кб. *қолай, қолағай* «кулай». Бор. формасы *қолағай* булса кирәк. *Кул I* сүзеннән ясалган (*кол-ағай: -ағай* сыйфат һәм рәвеш ясагыч кушымча). *Кулай < куллай < куллагай* булуы да ихтимал.

**КУЛТЫК** «подмышка; залив» — *кул.* (к.) сүзеннән, ләкин ясалыш юлы ачык түгел (*култык < куллык?*), ихтимал, *куентык ~ куенлык* сүзе тәэсирендә барлыкка килгәндер.

**КУМЫШКА** «самогон» — чув. *кумӑшка*, удм. *кумышка, кумыска,* мар. *кумышка, кумыш* h.б. «кумышка» («көмешкә» дә диелә) *кымыз* (к.) сүзеннән булса кирәк.

**КУНА I** «щит; доска, на которой месят тесто» — бор. болгар. **куна*, бор. кыпчак., куман. *канга* «такта», башк. *қуна*, кб. *кана, каңа,* чув. *хӑма* «такта, тәрәк, каба, куна» (мар. *оңа, хана* «такта» — болгар теленнән). Фонетик үсеше *қаңга > қагна > қауна > куна.*

**КУНА II** *диал.* «молодая поросль» — бор. гом. тк. **қон-а* «үрчү; балалау» сүзеннән. К. себ. тат., урта диал. *қуна* «курпы, агач төбеннән чыкан яшь үсентеләр», чув. *кунав* «курпы», куна, *хона* «үрчү, курпылау», мар. *кана* «бер яшьлек ботак», бор. тк. *қан-* «көчәеп үсү», кк. *қуна-* «куәтләнү».

**КУНАК** «гость» — гом. тк. *қунак, қоңак* «кунак», гом. тк. *қон-* «кун-у» фигыленнән.

**КУНАКЛА-У** «сесть на насест» — бор. тат. *қунақ* «куна торган урын (утыргыч яки кунача)» сүзеннән.

**КУНАЧА** «насест» — диал. *кунықча* (*-ча* кечерәйтү кушымчасы) «кунача» сүзеннән, бор. *қуныҡ* «куна торган урын» нигезеннән.

**КУН-У** «сесть с лёта (*о птицах*); осесть (*о пыли*)» — гом. тк. *қон-* «куну» сүзеннән; *кунуның* «өйдән читтә төн уздыру» мәгънәсе борынгы аучыларның урманга киек ауларга барып, агачка менеп төн үткәрүеннән. К. **Куй-у.**

**КУНЫЧ** «голенище; краги» — гом. тк. *қоныч, қончу* «куныч, балак», азәрб. *гунчу* «куныч», чув. *кунча* «савыт аягы» (к.ш. ук. удм. *кунчи*, мар. *кемзы* «куныч») — бор. тк. *коң* «хайванның аяк тиресе» сүзеннән: *коң чу* «тире чолгау». К. себ. тат. *кың* «куныч, сыйрак», бор. монг. *каңчун* «жиң».

**КУПШАНГЫ** «мокрица; навозный жук» — чув. *купшанкӑ* «купшангы: купшы кеше» сүзеннән. К. тат. диал. *капшангы*, рус. диал. *ковшак, капшак* (Даль), мар. *кавшангы* «селәүчән, коңгыз» чуваш теленнән; чаг. рус. *кивсяк* «кыргаяк, меңаяк» < төрки **кэбсэк, *кабсак*; к. шулай ук чув. *хупшанкӑ* «капланган, ябылган».

**КУПШЫ** «франт; элегантный» — бор. тк. **кубызыг, *кубаз-ыг* < бор. гом. тк. **кубар-ыг* «купшы, горур» сүзеннән (чаг. **Көяз**); к.



иск. әд. *купыз* «купшы» (Троянский), диал. *қупай* (урал), *қупық, қубры* (Идел буе) «купшы, көяз», алт. *қубаз* «купшы», чув. *кӑвар* «купшы, көяз».

**КУПЫ** «деревянная чаша» — киң таралган сүз: удм. *копар*, венг. *kupa, kupak* (*купа, купак*) «кубок, бокал, тәлинкә», латин. *cuppa* (*куппа*) «тәлинкә», фин. *kupp* «купы, тәлинкә», осетин. *kopp* (копп) «купы, кап» (Абаев), эстон *kopp* (копп) «купы», санскрит. *kubua, kubba* «табак». Чаг. **Комган**.

**КУР** «уголья для сохранения огня» — гом. тк. *қур, қор* «утлы күмер». В.Г.Егоров буенча бор. ирани. *хвар* «кояш, ут» сүзеннән. Диал. *қурлық* «ачыткы», *қурмал* «үрчемгә калдырылган терлек» сүзләрендә *қур* тамыры күчерелмә мәгънәдә. К. **Куз.**

**КУРА** «огражденный скотный двор; стебель высохшего растения» — гом. тк. *қора* «кура; койма, читән» сүзеннән; чаг. якут. *күрүө, күрә*, бурят. *хүрэ* «кура, мал ябу өчен читән белән уратылган урын».

**КУРАЙ** «сухие стебли растений; дудка, курай» — бор. тк. *қағурай* «корыган сабак» сүзеннән, *қақ* «коры, кипкән» тамырыннан булса кирәк (к. **Как**); алт., чулым. *каурай* «коры камыш», монг. *хуурай*, бор. монг. *кагурай* «курай, коры сабак». Чаг. себ. тат. *кура-у* «корып кибү (*үсемлек сабаклары турында*)», мар. *қағура, каура* «корыган, тиз сына торган» (татар теленнән), венг. *koro* «корыган сабак» бор. тк. телләрдән. К. **Кура.**

**КУРАЧ** «короткий; тесноватый (*об одежде*)» — бор. тк. *қур-*, кырг. *коро-* «кечерәю, азаю» фигыленнән. Бор. формасы *қур-ғач;* к. төрек. *курғаз* «ябык, кечкенә» > рус. *кургузый* (?), башк. *кураңыс* «курач»; калм. *хор* «бик кечкенә әйбер; вак-төяк», *хора-* «курачлану».

**КУРГАН** «курган; крепость» — гом. тк. *қурган* «курган, крепость», гом. тк. *қурға-, қору-ға-* «яклау, саклау, саклап тору» фигыленнән (Ж.Киекбаев)», бор. гом. тк. *қору* «сак, барьер, киртә» сүзеннән; к. алт. *қору* «саклану чарасы, киртә», чыгт., кк., ккк. *қору-* «саклау, хәвефсезләү», *қорға-* «яклау», тат. диал., башк. *қурға-у* «әйләндереп алып саклау», *қургаучы* «гали затларны яки туйда кәләшне саклаучы», якут. *хорга*, монг. *корга* «хәвефсез урын, сак», рус. *курган* — төрки телләрдән.

**КУРГАШ, КУРГАШЫН** «свинец (каракургаш), олово (аккургаш) — гом. тк. *коргашын, коргашун, коргалҗын, коргаршун* h.б. id. монгол телендә ясалган сүз. Нигезе — тат. диал. *курга-*, бор. тк. *корга- < каурга-, каңурга-* «металл эретеп ямау», алт., хакас., кырг., кытай. *қаң* «металл беркетеп ямау материалы, кургаш» тамырыннан (Йоки).

**КУРГЫ** «кузнечный горн» — бор. *курға-, корға-* «металл эретү» сүзе белән баглы булса кирәк; чаг. эвен., монг. *хорхо, хорху* «кургы».

**КУРЫК-** «бояться, пугаться» — гом. тк. *корк-* id. бор. **қор-, қору-* «саклану, үзеңне саклау» фигыленең интенсивлык формасыннан; к. төрек. *қору-* «саклау, саклану», чув. *хӑра-* «курку». К. **Корал, Курган.**

**КУРПЫ** «отава; отавный» — гом. тк. сүз; алт. *қорба*, хакас. *қурбы* «курпы чыбык». Ясалышы ачык түгел. К. Әхмәтьянов, 1989:33.

**КУРЧАК** «кукла» — көнб. тк. сүз, үзб. *қўғирчақ*, бор. чыгт. *қаурчақ, қорчақ* «курчак; сын, рәсем», чыгт. *қағур, кавур, қағурт* «күләгә; сын, кот» сүзенә *-чак* кушымчасы кушылып ясалган.

**КУРЫС** «лыко» — угро-фин телләреннән; чув. *курӑс* «курыс», мар. *корш*, коми. *кырсь* «курыс», удм. *кур* «кабык, курыс», *курьес* «кабыклар, курыс». К. Әхмәтьянов, 1989:33.

**КУСАР** «косарь, большой нож» — русчадан булса кирәк.

**КУТАЗ** «колокольчик на шее скота» — к. урс. *кутас* «шнур с кистями, подвески на шнуре, бахромчатое украшение, аксельбанты; подвесной колокольчик, ошейник на рогатом скоте» (Даль), тк. *кутас, кутаз, кутаис* «муенча, чук, ялау» — гом. тк. *кағут, кут* «кот» сүзеннән; к. ш. ук чув. *хутаҫ* «кот, өрәк салып йөртү өчен бизәкле янчык яки котыйчык»: туй вакытында *хутас (кутаз)*ны туй атының дугасына, кыңгырау янына асып куя торган булганнар. Шуннан ул «кыңгырау» мәгънәсен алган.

Чаг. бор. *қотаз, қотуз* «як» (якның койрыгы батырларга бүләк итеп бирелгән).

**КУТАН** «загородка, хлев» — гом. тк. *котан*, чув. *хӳте*, монг., бурят. *хото(н)*, эвен., эвенк. *котон, котан* «кутан, абзар, ныгытма, шәһәр». К. **Катау.**

**КУТЫР** «короста, струп; болячка» — гом. тк. *қотур* «кутыр, кытыршылык» сүзеннән; чаг. чыгт. *қот-ур-* «кутырлау». Чаг. **Кытыршы.**

**КУЧКАР** I «самец мелкого рогатого скота» — гом. тк. *қучқар, қочқар* «кучкар, сарык яки кәҗәләрнең нәсел тәкәсе», бор. тк. *қочуңар* «кучкар» (МК) формасыннан, төрек. чыгт., бор. тк. *қоч, қоча*, бор. гом. тк. *қоча* «тәкә» сүзеннән (*-қар, -ңар* бередә кечерәйтү һәм кимсетү кушымчасы булса кирәк); к. үзб. *қоччақ*, кк. *қошшақ*, тат. диал. *куччак* «тәкә», кырг., көнч. тк. *қут'а, куча* «сарык, сарык тәкәсе», госм., чыгт. *қоч* «сугыш тәкәсе»; чаг. бурят. *хуса* «сарык яки кәҗә тәкәсе». *Кучкар, куччак* сүзләре кайбер төрки телләрдә (кырг., үзб.) «батыр егет, башлык» мәгънәсендә дә йөри, әмма монысы — күчерелмә мәгънә. Тат. диал. *кучкар-* «әкәм-төкәм», «чөнки аның тәкә мөгезе кебек уралган кечкенә кабырчыклары бар» (Г.Алпаров).

**КУЧКАР** II «карниз, ниша (печи)» — тат. диал., башк. *кусқар* «әвернә, кыса, кирәгә, козырек, такыя»; элегрәк *кыса, әвернә, чыра кыстыргыч* һ.б.лар кучкар яки кәҗә мөгезеннән ясалган булган. Чыракчыларның (төнлә ут яндырып көймәдән балык аулаучыларның) чыра кыстыргычлары да «кәҗә» яки «кучкар» дип атала. Чыра куя торган урынны «кучкар» дип атау мич кашагасына да күчерелгән.

**КУЧКЫЛ** «темный, черноватый» — кырг. *қочқул*, кк., ккк. *қошқул* «кучкыл». Сүзнең тамыры *куч, қоч* — төс исеме, *-кыл(т)* — кушымча.

**КУШ** «двойной, парный» — гом. тк. *қош* «бергә, куш,



җәмәгать, бергәлек, гаскәр» сүзеннән, ниндидер **қо-* фигыле нигезеннән *(қо-ш)*. Чал. **Куш-у.**

**КУШАК** «кушак, пояс» — гом. тк. *курша-* «әйләндереп алу, бил буу» фигыленнән (к.**Кырша-у**) ясалган *курша-қ* «билбау, кыршау» сүзеннән үзгәргән; к. бор. тк. *қур, куршағ* «билбау, кәмәр» (МК), алт. *қурчақ* «кушак, билбау, кыршау», чаг. иск. тат. әд. (диал.) *қуша-у* «бил буу» < *курша-у*.

**КУШТАН** «кокетка; льстец, подхалим» — Идел-Урал даирәсендә таралган сүз; чув. *куштан* «мироед; щеголь» (Ашмарин), мар. *коштан* «своенравный; злой», *костан* «эре (строгий)», удм. *куштан* «эре (гордый; щеголь)», рус. диал. *коштан, коштанник* «мироед, ходатай по мирским делам» (Даль). Чаг. тат. диал. *куштанчык* «куштан, мактанчык, ярамсак», бор. уйг., чыгт. *коштан* «купшы», *кошнан, кошнанчы* «күрәзә, күрәзә хатын, ханның күрәзәсе». Бу сүз башта яучы, димче дигәнне белдергән (*куштан итәк* — яучылар кия торган кием итәге), сонрак «гаскәр җыючы агитатор» мәгънәсендә йөргән. Төптә фарсыча *хош даһан* «татлы авыз (тел)» сүзеннән булса кирәк.

**КУЫК** «пузырь; легкомысленный человек» — гом. тк. *қоwоқ, коwук* «эче куыш нәрсә» бор. тк. *куб-уг // коп-уг* «куышлык» сүзеннән, *коб // коғ* «куыш, буш» тамырыннан; к. уйг. *кағук*, якут. *хабах*, бор. уйг. *кавук* «сидек куыгы, куык», үзб. *қовоқ*, госм. *қоғуқ* «куыш, куышлык, агач куышы», куман. *ку, коғ* «буш, куыш», якут. *хобо*, уйг. *кобы* «куыш, куыш шар». К.**Куыш.**

**КУЫР-У** «жарить, поджарить» — гом. кыпчак. *қуыр-, қыуыр-, қуур-*, гом. тк. *қавур-, кағур-* «куыру», *қау, қагу* «нык кипкән, коры» сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

Бу фигыльдән гом. тк. *қурмач, куырмач, куурмач, куғырмач* һәм *қуырдак, куурдак* (> рус. кавардак) дигән ашамлык исемнәре ясалган.

**КУЫШ** «дупло; полость; шалаш» — гом. тк. *коwуш, қоғуш* «куыш» — бор. гом. тк. *коғол* (к. **Куык-**, *-л* — исем ясагыч кушымча) «куыш нәрсә, куышлык» сүзеннән; к. себ. тат. *куғыз (с)* «эче буш» ([-з-]ның килеп чыгышы ачык түгел), бор. чыгт. *қоғус*, азәрб. *қоғуш* «буш», н. диал. *кушыс*, куман. *коwуш*, кум. *кушуш* «куыш, бушлык», чув. *хӑвӑл* «агач куышы», хакас. *хоол*, тув. *коңгул*, монг. *хонгил* «агач куышы, куыш, буш».

**КУЯН** «заяц» — гом. тк. *қуйан, қойан*, бор. гом. тк. *корған // қор-ғун* «куян» сүзеннән, ихтимал, бор. *қор-* «курку» (к. **Курык-у**) сүзеннәндер; к. хакас. *козан*, тув., саян. *кодан*, бор. чув. *хуран* «куян»; тув. *қойғун* «куян», *кой-* «курку».

**КҮБӘ** «копна, ворох сена; дуло *(ружья)* кин» — таралган *күб* тамырыннан: чув. *купа* < *копа* «күбә», рус. *копа, купа* «өем», *копна* «күбә», осет. *купп* «кабарынкылык», фарсы. диал. *куп* «тау, түбә», литва. *каира-п* «өем». Татар телендәге *күбә* турыдан-туры бурят. *губөө* «түбә, тау, өем», тув. *хөпээн* «күбә, өем, кибән» сүзләре белән бәйләнгән булса кирәк.

**КҮБӘК** «ствол оружия, рукоять» — бор. тк., фин. *кәб // күб* «үзәге куыш агач, куыш сабак» сүзеннән *(күб-әк)*; к. тат.

диал. *кәбе, кабе* «биек агач чиләк, гөбе», алт. *кyп* «биек агач чиләк», үзб. *гуппи* «гөбе, киле», удм. *гумы* «куыш цилиндр, куыш сабак», коми. *гум,* фин. *kääti* «цилиндр, кәтүк, соса», чув. *кӳпчек* «көпчәк, ияр артлыгы», *кĕпчек* «агач йозак», *кĕпçе* «көпшә, куыш сабак, кәүсә, тәгәрмәч көпчәге». К.**Кәүсә, Көпчәк, Көпшә, Гөбе** (эче куыш агач яки сабактан бик күптөрле әйберләр: торба, кәтүк, шүре, төрле савытлар, тәгәрмәчләр, киле һ.б. ясала торган булган); чаг. ш. ук төрек. *гөбәк* «кендек, шланг».

**КҮБӘЛӘК** «бабочка» — гом. тк. *көбәләк, кәбәләк* «күбәләк» сүзенең фонетик вариантлары бик күп һәм бу сүз төрки булмаган телләргә дә үтеп кергән; к. венг. *köröпуеg* «күбәләк», осетин. *гәләбу, гәбәлу,* кум. *гөбәлу* «күбәләк»; чаг. чув. *кӳпе* «күбәләк», удм. *бубыли* «күбәләк» [*б* ~ *к*] аваз күчешләре күп телләрдә очрый.

**КҮБЕК** «пена, пенка» — гом. тк. *көпук, көбук* «күбек», гом. тк. *көп-*«күбү» **(к. Күп-ү)** фигыленнән *(күб-ек < күп-ек).*

**КҮГӘН I** «дверная петля, шарнир» — к. башк. *күгән* «күгән», чув. *кăкан* «чиләк колагы», мар. *көган* «күгән», *көгөн* «йозак, ишек биге», госм. *көкэн,* кырг., кк., ккк. *күген, көгэн-* «бозау һ.б. бәйләп кую өчен бер очында казык, икенче очында элмәге булган озын бау, тышау». Сүзнең тамыры борынгы шом. тк. *көк* «тамыр, төп, казык».

**КҮГӘН II** «терн, плод терновника» — бор. тк. *көгу* «чәнечке, кармак» сүзеннән; к. чув. *кăкан* «ыргак» ~ якут. *көҕ,* монг. *хөхө* «ыргак, кармак, чәнечке» бурят. *гөхө* «тимер очлы колга, сөнге»; чаг. якут. *күөгу* «кыргыч».

**КҮГӘРЧЕН** «голубь» — гом. тк. *көкөрчун, көгурчкэн* «күгәрчен» сүзеннән, фонетик вариантлары бик күп, ясалышы ачык түгел, гом. тк. *көк* «күк, зәңгәр» сүзеннән дип санала (чаг. рус. *голубь, голубой,* фарсы. *кабуд* «зәңгәрсу» — *кабутар* «күгәрчен», осетин. *әхсин* «зәңгәр» — *әхсинәг* «кыр күгәрчене, алабута»). Ясалышы буенча чаг. диал. *әверчен* «урман күгәрчене», *селәучен.*

**КҮГӘЛ** «кряква, селезень» — к. чув. *кăвакал* «үрдәк, күгәл» кырг. *көгөл* «күгәл», кк. *көгал* «ачык-яшел», якут. *көҕөн* «кыр үрдәге» — барысы да *көк-* «күк, зәңгәрсу, яшел» сүзеннән. Рус., украин. *гоголь* id. төрки телләрдән.

**КҮЗ** «глаз» — гом. тк. *көз,* чув. *куç < курç < *көрчү* бор. тк. *көр-* «күрү» тамырыннан.

**КҮЗӘНӘК** «клетка; глазок (*картофеля*)» — *күз.* (к.) сүзеннән; чаг. диал. *күз* «элмәк тишеге (*бәйләмдә*), бөжра яки төен уртасы, тув. (кызыл.) *көзөнөк* «тәрәзә».

**КҮЗӘТ-Ү** «следить, наблюдать» — гом. тк. *күзәт-, көзәт-* «күзәтү, саклау, максат итү», бор. тк. *көзә* — «карау, күзәтү» (чаг. тат. *күзлә-ү*) фигыленең йөкләтү юнәлеше формасы; к. башк. *күзә-ү* «прицелга алу, максат итү», уйг. *көзә-* «максат итү, теләү». К. **Күз.**

**КҮҖӘ** «кашица» — тат. диал. *күзә,* башк., кк., ккк. *көже,* кырг. *көҗө* «күжә, бутка». Бу сүзнең параллельләре тува, мон-



гол һ.б. телләрдә дә бар. Чаг. кытай. *ку цзу* «тары сорты». Күчмә терлекчелек чорында *күҗә* ит-сөттән кала төп ашамлык булган. Шуңа күрә утрак халыкларда ул ритуаль ризыкка әверелгән: аны Нәүрүз бәйрәмендә пешерәләр.

**КҮК** «небо; голубой; синий» — гом. тк. *көк,* бор. гом. тк. *көку* «күк (небо)» сүзеннән, төрки телләрдә күптөрле мәгънәләр алган һәм продуктив нигез булган; к. тат. диал. *күк* «яшькелт, (аксыл) зәңгәр; чирәм, чирәмлек», *күкләм* «язгы беренче яшеллек», *кумгәк* «тәндә күгәргән урын», *күкен* «күк төстәге балык» һ.б. (к. **Кигәүен, Күгәрчен**). Чаг. бурят. *хухэ,* монг. *көкэ* «күк; күк, зәңгәрсу, яшел, яшькелт, саргылт, күгелҗем».

**КҮКӘЙ** «яйцо» — символик яңгырашлы тамырдан; чаг. хакас. *кока,* рус. диал. *кока,* лезгин. *кака,* поляк. *кока,* француз. *коко* «күкәй», грузин. *какали,* әрмән. *какай,* грек. *коккос* «чикләвек, чикләвек төше».

**КҮКЕРТ** «сера; спички; сернистая мазь» — чув. *кӳкĕрт,* гом. тк. *күкурт,* үзб. *гугирд,* фарсы. *гугард.* куман., тк., гар. *кибрит* «күкерт, шырпы» гарәп-фарсы даирәсеннән дип санала, ләкин тат. диал. *күкерт, күгерт,* хакас. *күгурт* һ.б. «күкрәү» сүзеннән түгелме икән (шырпы кечкенә күкрәүгә охшатыла ала. К. Әхмәтьянов, 1989:70)? Чаг. **Күкрә-ү.**

**КҮКЛӘ-Ү** «обметывать, наметывать» — алт., кк., кырг. *көктө- < көклэ-* «күкләү» — алт., тк., чыгт. *көк,* тат. диал. *күк* «тишек, җөй, кадак» сүзеннән. К. **Күгән.**

**КҮКРӘК** «грудь» — гом. тк. *көкур-әк* «күкрәк», гом. тк. *көкур* // *көкүз* «күкрәк, йөрәк» сүзеннән, бор. гом. тк. *кө-* «күр» формасыннан булса кирәк; к. чув. *кăкăр* (<**көгөр*) «күкрәк», алт. *көгүс,* бор. *көкүс,* госм. *көгуз, көңүз* «күкрәк»; чаг. калм. *көкүр* «имчәк, ана күкрәге», бор. монг. *көкэн* «имчәк, ими», *көкэ-* «имү». Сүзнең тамыры **көк, *көң.* К. **Күңел.**

**КҮКРӘ-Ү** «греметь (*о громе*)» — бор. тк. *күркүр-ә-* «күкрәү, гөр-гөр итү» сүзеннән, *күр (күр-күр)* «гөр-гөр» тәкълиди сүзеннән; к. алт. *күркүрэ-,* уйг. *күр- күрә-,* бор. монг. *күркирэ-* «күк күкрәү, гөрелдәү».

**КҮКШӘ** «сойка» — чув. *кукша, кокша* «таз, пеләш» сүзеннән булса кирәк, бу сүз исә *кашка* сүзеннән үзгәргән. Рус. *кукша* «күкшә», мар. *кокша* «таз, күкшә» — чувашчадан. Чаг. ш. ук эвен. *кокшичан* «күкшә».

**КҮЛ** «озеро» — гом. тк. *көл, күл* «күл» сүзеннән.

**КҮЛӘ** «мешок для рыбы» — бор. *күлә* «олау» сүзеннән. К. **Күлек.**

**КҮЛӘГӘ** «тень; тенистое место» — гом. тк. *көлөгө, көлөнкә, көлөткә* «күләгә», көнч. тк. *көлө-* «күләгәләү, каплау» фигыленнән; к. тат. диал. *күләнкә* «күләгәле урын, куак асты», *күләткә* «күләгә, силуэт, скелет» *(күләткәсе генә калган, ябыккан),* чув. *кĕлетке* «тән, тышкы кыяфәт, өрәк, портрет», алт. *көлөтку, көлөткө,* уйг. *көләнкә,* бор. уйг. *көлигә* (МК) «күләгә».

**КҮЛӘМ** «объем» — ачык түгел; к. чув. *кӳлем, кӳлепе* «тышкы форма, күләм», тув. *көл* «үлчәм», уйг. *күләм* «күләм» үзе татар теленнән булуы да ихтимал; чаг. бор. тк. *көл-* «йөкләү».

**КҮЛЕК** «рабочий скот на пашне» — (к. М.Гафури: «Иртән таң саргаюга, күлек җигәр вакытка килеп җит!). К. кк., ккк. *күлүк* «игенче аты», бор. тк. *көлүк, күлүк,* ткм. *гөлүк,* н. *көлик;* кк., ккк. *көлек, көлик* «җигү аты, олау аты», монг. *хөлөг,* бурят. *хүлэг* «олауга җигелгән ат, олау, кәрван», хакас. *хөлег* «җигү, җигелгән атлар», тув. *хүлүг* «бәйләм», якут. *көлө* «жигем, олау, ат», тув. *хөл* «җигелә торган терлек» — барысы да бор. тк.., монг. *көл-, кул-* «бәйләү, тезү, җигү, олау төзү» сүзеннән; к. иске кк., ккк. *күлүк* «озын юл, сәфәр, олау» (Л.Будагов), кырг. *күл* «озын юл», бор. чыгт. *көлэ* «ат» (Зәмәхшәри), төрек. *көлэ* «коллар төркеме», казакъ, башк., тат. диал. *көлэ, күлә, көлөк* «озын аркан, терлек бәйләү өчен бау, капчык» шул ук борынгы сүздән. К. **Күлем.** К.Әхмәтьянов, 1989:83—84.

**КҮЛЕМ** «отдых на поле во время сельскохозяйственных работ» — чув. *кӳлӗм* «күлем, төшке ял», *кӳл-* «җигү» сүзеннән (ягъни атларны ялга туарып яңадан җигү белән бәйләнгән; к. **Күлек**); к. тат. диал. *күләм* «сукачыларның ял вакыты», *күләнү* «эштә тамак туйдырып алу»; к. көнч. тк. *көл-*, бор. тк. *көл-*, монг. *хөллә-х* «җигү».

Күтәр-ү < себ. тат. *күлтәр-ү* дә шуннан (төүге мәгънәсе «йөкләү»).

**КҮЛМӘК** «рубашка» — гом. тк. *көлмәк, көңләк,* башк., тат. диал. *күлдәк,* «күлмәк, өске күлмәк, күкрәкчә» — бор. *көңүлмәк, көңүлдәк-* бор. *көң, көк* «күкрәк» тамырыннан килә.

**КҮМӘК** «коллективный, общий» — гом. тк. *көмак* «ярдәм, ярдәмче гаскәр, тыл» сүзеннән мәгънәсе үзгәреп килеп чыккан, сүзнең тамыры (*көм-*) ачык түгел; к. үзб. *кӯмак* «ярдәм, күпләп», чыгт., госм. *көмәк* «ярдәм», бор. госм. *көмәг* «арка(!), тыл, ярдәмче гаскәр», якут. *көмө* «ярдәм».

**КҮМӘЧ** «булка; белый хлеб» — Г.Алпаров буенча «күммә аш» сүзеннән; к. чыгт. *көмәч* «көлчә, көләчә»; *күммәч* < *коммэч* id. *күм-* < *көм-* «күмү» фигыленә *-мач // -мәч* аффиксы ялганып ясалган (чаг. *умач, токмач, болгамач*) дисәк, дөресрәк булыр.

**КҮМЕР** «уголь» — гом. тк. көмүр «күмер» *көм-* «күмү» сүзеннән; к. чув. *кăмрăк, кăммăркă* «күмер» (<**көмүр-үг*) бер. *комүр-* «күмү» фигыленнән; күмерне ут саклау өчен күмеп калдыралар.

**КҮМ-Ү** «зарывать» — гом. тк. *кум-, көм-* «күмү».

**КҮН** «кожа (*выделанная*)» — гом. тк. *көн, көң* «күн, тире» сүзеннән, н. *көн*, тув. *хөм* ~ бурят. *хум* «күн», монг. *көм* «йоны коелган тире» һ.б. К. **Күңел**. Бор. гом. тк. *көң, көң* башта тиренең йонсыз өлешләрен, мәсәлән, боланның аягын, дөянең муенын белдергән. Шуңа күрә бу тамыр сүз ике мәгънәдә йөри: «муфтасыман тире» (шуннан *куныч, кунчек*) һәм «йонсыз тире». Чаг. тат. *күнәк* «күн чиләк».

**КҮНТЕ, КҮНТӘЙ** *уст.* «судья низшего ранга, понятой, свидетель (*на свадьбе*)» — ~ чув. *кӗнтелен,* иске чув. *кӳнтелен, кюнделеген,* удм. *канделем* id., чув. *кӗнтеле-* «гуаһ булу», *кенте, хунтă* «судта яклаучы» — төрки-монголларда киң таралган *кунду, кунтәй* «хөрмәт, сый; хөрмәтле кеше» бор. кытай. кйн taj «сарай агасы (гофмейстер)» сүзеннән.



**КҮН-Ү** «согласиться» — гом. тк. *көн-* id., асылда, «тураю, төзәю»; чаг. ш. ук чув., тат. диал. *куне* < гом. тк. *көну* «туры, төз»; чаг. тат. *кундәм* «покладистый». *Күнег-ү* «привыкать» *күн-ү*-нең интенсив формасы.

**КҮНЧЕК** «обшивка прореза рубахи; кусок выделанной кожи» — к. чув. *кӳнчек,* ткм. *гөнҗүк,* кырг. *көнчөк* «бизәк, кайма, маң, чулпы», бор. тк. *көнчүк* «киемнең күкрәк өлеше, изү, куен, култык», кб. *көнчэк,* куман. *копсек* «ыштан, чалбар» (к. тат. **Күлмәк-Күнчек**). Элек тире киемнәрнең изүе күннән эшләнгән. К. **Күн**.

**КҮҢЕЛ** «душа, душевное состояние; настроение» — гом. тк. *көнгул, көңүл* «күңел, кәеф; күкрәк» — бор. гом. тк. *көң* «җан; күкрәк» тамырыннан (*көң-үл: -ул // -үл* — сүз ясагыч кушымча); к. алт. *көңүл-* «яратып әсәрләнү», хакас. *көнни* «теләк, ихтыяр, кәеф» < **көң-лиг* һ.б.; *күңел* сүзенең «күкрәк» мәгънәсе татар фразеологиясендә *күңелсезгә күлмәк киертмиләр; күңел ачу; күңел биреп сөю* тәгъбирләрендә чагыла; к. ш. ук бор. тат. *күкелдәш* «сөттәш».

Бор. *көңүл* «бер күкрәк» булса, *көкүз* (иске тат. *күкез*) < **көкүрг* (шуннан **көкүрг-әк* >> *күкрәк*) ике имине белдергән; чаг. бор. *көкүзмәк* «күлмәк»; к. тунгус. *кунку* ~ якут. *күңкүләми* «күн кием, жилет» > рус. *кухлянка*.

**КҮП** «много» — гом. тк. *көп, коп* «күп, барысы да» сүзеннән (Радлов алынма сүз дип карый); чаг. ирани. *куп,* рус. *куп, коп* «өсм, күп».

**КҮПЕР** «мост» — гом. тк. *көп-үр, көпрүк* «күпер» — бор. *көгүр* «тире капчык» сүзеннән; к. хакас. *көбертке* «басма, киштә» — бор. монг. *күwүрге* «күпер», тув. *көбүрүг,* кырг. *көпүрөө* «күпер, басма», куман., төрек., азәрб. *көрпү, көрпүг* «күпер, каба», якут. *күрэ, күргэ* «күпер», кырг. *көмүрүг, көмүркөй* «күпер, дөя тиресеннән эшләнгән сандык. Борынгы төркиләрдә тире капчык (*көвүр, көгүр*) киң кулланыш тапкан: аны капчык, сандык итеп файдаланганнар (к. кб. *кюбюр, көмүр* «сандык»), аның эченә һава тутырып һәм күп капчыкларны бер-берсенә бәйләп йөзмә күпер ясаганнар (алт. *көгэр* «тире капчык, күпер»), ниһаять, аны күрек итеп файдаланганнар (к. **Күрек**) һәм тун итеп тә кигәннәр (к. чув. *кĕрĕк* «тун, толып»). Чаг. **Күпер-ү**.

**КҮПЕР-Ү** «всходить; взбиваться» — гом. тк. *көпүр-* id. бор. тк. *көп* яисә *көпү* «күпкән» сүзеннән (*көп-үр-* яисә *көпү-р-*). К. **Күп-ү.**

**КҮП-Ү (Күбү)** «вспучиваться» — гом. тк. *көп-* id. тасвирый яңгырашлы *көп* «кабарынкы, кабарык, кабару, өрелү» (шуннан ук *көп* «много» сүзе дә килсә кирәк) тамырыннан. Чаг. **Күпер**.

**КҮРӘ I** «смотря; по» — гом. тк. *көрэ* id. — *күр-ү* < *көр-* фигыленнән.

**КҮРӘ II: күрә карау** «близорукость» — фарсы-таж. *кури, куре* «сукыр» сүзеннән. Керәшеннәрдәге *тачик, таҗик* «күрә караучан» сүзе дә шуңа бәйләнгән булса кирәк.

**КҮРӘЗӘ** «гадальщик» — ясалышы ачык булмаган сүз, *күр-ү*

фигыленнән булса кирәк; чаг. диал. *күремче* «күрәзә», иск. *күрәм* «күрәзәләү, ырым» (Троянский).

**КҮРӘН** «осока» — себ. тат. *курәң* «күрән, камыш» — гом. тк. характердагы сүз; якут. *хөрөн* «күрән, кура», *хөрөй-* «тупаслану, кату»; шуннан ук себ. тат., иск. тат. *курәң, көрәң* «камыш читән» >> рус. *курень* «хәрби лагерь».

**КҮРЕК I** «мех (*напр., кузнечный*)» — гом. тк. *көрүк*, бор. гом. тк. *көр-үг* «күрек» сүзеннән, *көр* < *көбүр* «өрдерү» сүзеннән булса кирәк; к. кырг. *көөрүк* «күрек», якут. *күөрт* «күрек», эвен. *куrгэ* «тимерче күреге» h.б.; чаг. хакас. *көбир, көбер* «күрек»; В.Г.Егоров буенча чув. *кӗрӗк* «күрек», бор. тк., чыгт., азәрб. *күрк* «тун, толып», кб. *көрүк*, калм. *көрк* «мех» сүзләре дә күрек белән бәйләнгән (чаг. рус. *меха* «кыйммәтле тиреләр», мехи «күрек», күрекне элегрәк тиредән эшләгәннәр). Бор. тк. *көөрүк*, монг. *көгүрүг, көгэргэ, көwэргэ* «күрек, күпер» сүзе *курек*нең этимологик тамыры *ковур* икәнен күрсәтә. К. **Күпер**. К. Әхмәтьянов, 1989:134—135. Чаг. **Күпер-ү**.

**КҮРЕК II** «красота, краса» — гом. тк. *көрүк, көрку* «матурлык, күрек» — гом. тк. *көр-* «күрү» сүзеннән.

**КҮРКӘ** «индейка» — рус. диал. *курка* «тавык, күркә» сүзеннән булса кирәк (Рясянен); к. чув. *кырка* «күркә»; чаг. шулай ук себ. тат. *қурық тавық* «чеби чыгарырга йөрүче тавык», үзб. *курка товук*, таж. *курк* «чебиле тавык», удм. *курег* «тавык». Ләкин бу сүзләр күркәне түгел, тавыкны белдерәләр.

**КҮРКӘМ** «видный, представительный» — чыгт. *көркәм* «күркәм, матур» сүзеннән, гом. тк. *көр* «күрү» фигыленнән.

**КҮРСӘТ-Ү** «показывать» — бор. тк., чыгт. *көстәр-* «күрсәтү» сүзеннән (метатеза: *күстәр-* > *күрсәт*).

**КҮР-Ү I** «видеть» — гом. тк. *көр* «күрү» сүзеннән; шуннан ук к. **Күрә, Күрек II, Күркәм, Күрше, Күрәзә;** тамырдашлар: **Күз, Көзге, Гүзәл.**

**КҮР-Ү II** «только в отдельных выражениях и в функции вспомогательного глагола (*чара күрү* «принимать меры», *килә күр* «пожалуйста, приходи», *укый күр* «пожалуйста, будь добр, почитай)» — ~ чув. *кӳр-* < бор. тк. *кигүр-, киргүр-* «башкару, алып бару» бор. **кир-* «төзү, ясау» фигыленнән «башкару, эшләп чыгу» мәгънәсендә булган борынгы сүздән. Шулай итеп, бу сүзнең дөрес язылышы татарчада *кувер* (*куәр*) булырга тиеш кебек.

Татар әдәби теленә бу сүзне *кувер-* вариантында «вести (собрание, дело)» мәгънәсендә куллану мәслихәт.

**КҮРШЕ** «сосед; соседний» — *күр-ү* (к.) фигыленнән, ясалыш юлы бик үк ачык түгел; к. чув. *күреш, күрше* «күрше», кк. *көрши* «күрше», бурят. *курш-э* «күрше», алт. *көрүш* «таныш, күренеп йөри торган кеше». К. Әхмәтьянов, 1989:115.

**КҮСӘ** «безбородый; человек с редкой бородой» — көнб. тк. *көсә, кусә* «күсә» фарсы теленнән (фарсы-таж. *куса, кусэ* «сакалмыегы начар үсә торган»).

**КҮСӘК** «дубина; рычаг; болван» — бор. тк. *көсэгү* «кисәү, күсәк, ут болгата торган агач» сүзеннән (к. **Кисәү**); чаг. диал. *күсәбә* «зур кисәк, күсәк», *күсәү* «кисәү».

**КҮСЕ** «крыса» — бор. тк. *куску* «күсе, сычкан *-кус* тамырыннан; к. себ. тат. *куску*, тув. *кускэ*, бор. уйг. *куску* «тычкан», алт. *кускә*, сагай. *кускә* «күсе», якут. *кутуйах, кутүйәх* «күсе», кютэр, күтэр «су күсесе, көшел». Чаг. **Көшел**.

**КҮТӘР-Ү** «поднимать, поднять» — себ. тат. *күлтәр-у*, кб. *көлтүр-* id. бу сүзнең тамыры *күл-, көл-* «ат (хайван) аркасына йөкләү» икәнлегенә дәлил (чаг. **Ау-дар-, Куп-тар-**) Гом. *көтур* — «күтәрү; күчерү, үлчәү» икенчерәк мәгънәви юнәлештә. чув. *кӑлар-* «чыгару» < ***көләр-** («күтәр» сүзенең борынгы фонетик варианты).

**КҮТӘМӘ** «пескарь» (?) — к. чув. *котан, котама*, мар. *кадама*, чув. диал. кӳтеме «пескарь». Фин-угор теленнән.

**КҮТЕР, КҮТЕРГӘК** «топь; илистое место в водоеме» — к. көнч. тк. *көтүр, кутүр*, монг. *кужир, кудыр, куду-гур* «тозлак, тозлы саз», эвенк. *куду, кудук*, бурят. *хэдүк* «тозлак», коми. *гудыр* «муть, осадок» — төрки телләрдән. К. Әхмәтьянов, 1989:34.

**КҮЧ** «рой; табор» — гом. тк. *көч* «күчеп йөрү, күчмәлек, күч» сүзеннән; к. үзб. *куч* «гаилә»; тат. *күч-*, чув. *куҫ-*, мар., гом. тк. *көч-* «күчү, күченү» дә шуннан; бу фигыльдән тагын күп кенә сүзләр ясалган. К. **Күчер-ү, Күчмән**.

**КҮЧӘН** «кочан» — бор. тк. *көчән* «күчән, үсенте, казык» сүзеннән булса кирәк, бор. тк. *коч, көч* тамырыннан, шуннан үк рус кочан, *кочень, кочерыжка* «күчән», *кочет* «күгән», *кочерга* «кисәү, күчән»; к. бор. монг. *көси, көсир* «агач, таяк». К. **Күчәр**.

**КҮЧӘР** «ось» — бор. *көчәр* «күчәр» сүзеннән; к. кырым. *кочар*, н., кк., ккк. *көшәр*, калм. *көшүр* «күчәр, үзәк», н. *көшерге*, морд. *коцькарга* «кисәү», башк. диал. *кусәр* «күчән». Рамстедт буенча бор. монг. *көсигүр* «агач үзәк» сүзеннән, бор. монг. *көси*, *көсир* «агач», «агач кисәге». К. **Күчән**.

**КҮЧӘТ** «рассада» — уйгур теленнән; к. уйг. *көчәт* «күчәт, үсенте». Тамыры — *күч-* (күчереп утыртылучы?).

**КҮЧТӘНӘЧ** «гостинец» — рус. теленнән; к. диал. (мишәр.) *гуснич, гочнич*, чув. *кӳчченеч* «күчтәнәч».

**КҮШ** «сиденье со спинкой (*у саней*)» — бор. тат. *көш* «чана арты»; к. рус. *кошевые сани* «артлы чана». К. **Күшек**.

**КҮШЕК** «бойница; павильон; ниша» — бор. тат., куман. *көшк, көшук* «күшек, чыбылдыклы почмак»; к. фарсы. *көш, күшк* «күшек».

**КҮШӘГӘ** «покрывало; покров» — ~ башк. диал. *кушәгә*, көнч. тк. *көшөгө, көшигэ* «чыбылдык, пәрдә» < бор. гом. тк. **көшүгә; көш-, көл-* «ябу».

**КЫЕК** «косой; скат крыши; крыша» — гом. тк. *қый-* «аркылыга кыеклап кисү» сүзеннән; к. диал. *кыйыкча* «косынка», себ. тат. *кыйык, кыйынты* «кисенте, корама кисәге, кештәк», чув. *кӑйӑ* «күлмәктә өчпочмаклы кештәк». Чаг. ш. ук **Кый-пык, Кыйпыл-у**.

**КЫЕН** «трудно; трудность» — гом. тк. кыйын «җәза, җәфа, кыен» сүзеннән, ясалышы ачык түгел; к. хакас. *хыйал* «җәфа, газап», *хыйалла* «газаплау». Чаг. **Кыерсыт-у, Кыйна-у**.

**КЫЕРЧЫК** «краюшка (хлеба)» — тат. диал. *кыйыр*, көнч. тк. *қыйыр* «кыек, кыеш, кәкре» сүзеннән, гом. тк. *кый-у* фигыленнән.

**КЫЕШ** «кривой, косой» — *кый-у* фигыленнән. Чаг. диал. *кыйшык* «кыеш, кыен», *кыйшаңла-у* «эзлеклелектән чыгу, көйсезләнү».

**КЫЖРА-** «стремиться *к чему-л. (заранее подготавливая себя внутренне)*» — к. кк., ккк., кырг. *қыжҗыр* «ачу, ярсу», *қыжҗы* «шау-шу, тавыш, ызгыш», *қыжҗырай-, қыжҗылда-*, кыжыңда- «ачуланып тору, теш кайрау». Тәкълиди сүз. Тат. диал. *кыдрач, кыжрач* «ачучан».

**КЫЗ** «девочка; девушка; дочь» — гом. тк. *қыз* «кыз» < бор. гом. тк. **қиргь* «кыз» сүзеннән; к. чув. *хӗр* «кыз»; бор. тк. *қырнақ* «кол кыз» (МК), тат., башк., бор. уйг. *қыз-қырқын* «хатын-кыз», себ.тат. *қырқын*, бор. болгар. *гирхум* «хатын-кыз», чыгт. *қырқын* «кол кыз» һ.б.

Бор. тк. телләрдә *қыз* «кыйммәтле, бәяле» дигән сүз бар һәм ул *қыз* «девушка» белән бердәй булса кирәк. Семантик параллельләре бар: бор. тк., куман. һ.б. *эрдәң* «кыйммәтле таш, кызлыклы кыз» (к. **Әрдәнә**). Бор. текстларда еш кына *қыз уғлан* «кыз бала» тәгъбире очрый һәм ул, күрәсең, төп мәгънәсендә «кыйммәтле, кадерле бала» булган (*кызым* «кадерлем» дигән сүз). *Кыз* һәм *кызым* мәгънәсендә бор. төп төрки сүз булдымы икән — әйтүе кыен. К. **Кызган-у, Кызыг-у, Кызыл.**

**КЫЗА, КЫЗАН** «ястреб-мышелов» — диал. *кӧзан* ~ чув. *хӗрән* (*хӗрен*) id.; чув. варианты булу бу сүзнең борынгылыгын сөйли. Чаг. **Козгын**.

**КЫЗАМЫК** «корь» — чув. *кӑсамак*, удм. *кызамык*, мар. *кызамык, кыжамык* «кызамык» бор. *қызығ амуқ* «кызыл чир» сүзеннән булса кирәк; к. чув. *амук* «чир, хаста», бор. уйг. *қызламуқ* < *қызыл амуқ* «кызамык». *Амук* ~ *амык* элементы тат. *карамык* «кара кызамык», *сарымык* «сары хастасы» сүзләрендә дә күренә.

Бу сүзнең икенче варианты чув. *хӗрлӗхен* ~ мар. *ӹрлӹган, ырлыган* < болгар. **хырлыган, һырлаган* сүзеннән. К. **Кызыл**.

**КЫЗАР-У** «покраснеть» — гом. кыпчак. *қызар-*, бор. *кызгар-*, бор. *кызығ* «кызган, кызыл» нигезеннән; чаг. ш. ук *кызгылт*, тат. диал. *кызанкы* «тәндәге кызыл тап», *кызалак* «кызыл чәчәк, тюльпан».

**КЫЗГАН-У** «жалеть, пожалеть *кого-л.*; щадить» — гом. тк. *қызған-* < бор. гом. тк. **қырған-* > чув. *хӗрхен-* id., бор. *қызга-* < **кырга-* > чув. *хӗрхе-* (*хӗрхев* «жалость») «кызгану, кыйммәтле дип исәпләү» фигыленең кайтым юнәлеше формасыннан; чаг. бор. *қызғақ* «саран». К. **Кыз**.

«Кызгану, сараплану → җәлләү, миһербанлык күрсәтү» мәгънә күчеше якут. *харысый-, харыһый-* ~ монг. *харас-* фигылендә дә күзәтелә.



**КЫЗ-У** «накаливаться; преть (*напр., о зерне*); жаркий» — гом. тк. *қыз-, қыыз-* < бор. гом. тк. **кыырг-* > чув. *хӗр-* ~ мар. *хӹр-, ӹр-* id. иң борынгы төрки тамырларның берсе булса кирәк: аннан бик күп тамырлар, нигезләр ясалган. К. **Кызамык, Кызар-у, Кызыл**. Чаг. бор. тк. *кырғу* ~ *кызғу* «алсу, алсулык».

Идел-Урал регионына аеруча хас сүзләрнең берсе — тат. *қызу* «горячий; быстрый» > удм. *кӧжу*, мар. *кызу* ~ чув. *хӗрӳ*.

**КЫЗЫГ-У** «интересоваться, увлекаться» — себ. тат., алт., уйг. һ.б. *кызык-* «кызып китү» (*кыз-у* фигыленең интенсивлык формасы) сүзеннән. К. **Кызык**.

**КЫЗЫК** «интересный, забавный» — чув. *кӑсӑк*, мар., удм. *кызык, кыжык* id., алт., кк. *кызык* «кызу күренеше, кызганлык, эсселек» сүзеннән (*кыз-у* фигыленнән).

**КЫЗЫЛ** «красный» — гом. тк. *кызыл* < *кызғыл*, бор. гом. тк. **кырғлығ* «кызган, кызарган» сүзеннән, гом. тк. *қыз-у* фигыленнән; к. чув. *хӗрлӗ* < **кыр-лыг* «кызыл», *хӗр-* «кызу».

Бор. *қыз* < *қырг* «кыйммәтле, кадерле» һәм *қыз-* < *қырг-* «кызу» тамырларының бәйләнешы ачык түгел. Ихтимал, *қыз* < *қыргь* «кыйммәтле» сүзе «алтын, кызыл металл» сүзеннәндер; к. якут. *кыһыл кӧмүс* «алтын, кызыл көмеш» (димәк, *кыз* «алтын» дигән сүз булган).

**КЫЙБАТ** «дорого» — *кыйммәт* (гар.) сүзеннән үзгәргән.

**КЫЙБЛА** *рел.* «кибла; направление» — гар. *қибла-т-ун* «кыйбла» сүзеннән, *қабала* «очрау, кабул итү, килешүгә бару» тамырыннан; шуннан ук *кабул*, иск. тат. *мәкъбул* «кабул ителерлек», иск. тат. *кабил* «сәләтле», *кабәлә* «килешү, договор» (шуннан рус. *кабала* «гадел булмаган договор»).

**КЫЙГАЧ** «косой; наклонный» — *кыек* (к.) сүзеннән (*кыйык-гач*).

**КЫЙГЫР** «сокол» — тат., башк., чув., кырг. *кыйғыр* id. гом. тк. *қыйғыр-* «кычкырып җибәрү» сүзенә ялгыш нисбәт ителә, дөресе — тат. диал. *кырғуй, кырғай*.

**КЫЙССА** «рассказ; поэма» — гар. *қисса* id. (*қасс* «ни булганны судта сөйләү») асылда латин. *casus* «казус; суд; очрак» сүзеннән килә.

**КЫЛ** «волос (*лошадиный*); щетина» — гом. тк. *қыл* «кыл». К. **Кылга, Кылган, Кылчык.**

**КЫЛАУ** «дужка ведра» — к. диал. *кыл, кылы*, алт., кк., башк. *кылы, кылйы*, мар. *кыл* «кылау». Сүзнең нигезе *кыл* булса кирәк. Чаг. ш. ук диал. *кың* «ирнәү».

**КЫЛГА, Кылка** «ость; усики (*колосьев*)» — *кыл* (к.) сүзеннән (*кыл-ка*); к. алт. *кылға* «кылга». К. **Кылган**.

**КЫЛГАН** «ковыль» — *кыл* (к.) сүзеннән (*кыл-ган*). Параллельләре башк., кк., чуваш телләрендә. Алт., кырг. *қылқан* «кылчык (ость)».

**КЫЛЧЫК** «ость (*у злаков*); косточки (*рыбы*) — *кыл*(к.) сүзеннән (*кыл-чық*); к. госм. *қылчық*, кк. *қылшық*, үзб. *қилтиқ* «кылчык».

**КЫЛЫЙ** «кривой; косой» — *кый-у*(к.) фигыль нигезеннән

булса кирәк (*кылый* < *кыйыл-ый* < *кый-ыл-ыг?*); чаг. *кыек күз белән карау,* алт. *кылыр* «кылый (күзле)».

**КЫЛЫЧ I** «сабля; меч» — гом. тк. *қылыч* «кылыч, пычак», якут. *қылыс* «кылыч, пычак, нечкә кереш»; азәрб. *ғылынч* < бор. тк. *қылынч* «корал» — гом. тк. *кыл-* «кылу, эш итү» сүзеннән. К. **Кылыч II**.

**КЫЛЫЧ II** «бердо (*часть ткацкого оборудования*)» — **Кылыч I** сүзеннән: элек, күчмә тормышта, аркалыкны кысу өчен сугыш кылычы сыман калак кулланылган. Соңыннан «кылыч» сүзе сугыш кылычына бөтенләй охшамаган туку коралы буларак кулланыла башлаган.

**КЫМЫЗ** «кумыс» — гом. көнб. тк. *қумыз, қымыз* гар. *хамизун* «кымыз, сөт кислотасы» сүзеннән дип уйланыла. М.Рясянен бу сүзне иске тат., кк., госм. *қымран* «сөт квасы» сүзе белән бәйли һәм гом. тк. *қым-, қымыр-* «кымыржу» сүзеннән чыгара. К. **Кырмыска.**

**КЫНА** «*бот.* хна; хинна» — фарсы-таж. *хина, хинна* «кына» сүзеннән, асылда, гарәп сүзе.

**КЫНЫ** «ножны, футляр» — гом. тк. *қын, қыны* «кыны» — бор. гом. тк. *қиыны «кыны» сүзеннән; к. чув. *йӑнӑ, йӗнӗ* «кыны», якут., ткм. *кыын* «кыны», бор. монг. *куи, куни* «кыны».

**КЫҢГЫР** «кривой; неправый» — бор. *қыйын-қыр* «кыек, кәкре» сүзеннән (*-қыр* элементы бик үк ачык түгел); к. алт. диал. *қыйын, кыйың,* «кыек, кыңгыр», кб. *кыңңыр* «кыңгыр», якут. *хиаңғар* «кәкре кылыч».

**КЫҢГЫРАУ** «колокольчик» — бор. тк. *коңкырау ~ кыңнырағ* «кыңгырау» сүзеннән, ясалыш нигезе — гом. тк., монг. *каңғыр* «кангырау авазы турында» тасвирый яңгырашлы сүз (*каң-* тамырыннан); к. диал. *қоңғырау,* көнч. тк. *қоңгураа,* бор. чыгт., монг. *қоңкару* «кыңгырау», алт. *каңыра, коңыр* «шылтырау», тув., алт. *коңга* «шылтырау, звонок», бурят. *хонхо* «звонок», *ханхар* «яңгыравыклы», *хон* «яңгыравык», якут. *хоң* «кыңгырау тавышы», маньчж. *қаңғир-қиңғыр* «кыңгырау авазлары турында».

**КЫР I** «поле, нива» — гом. тк. *қыр* «кырый, чик» һәм гом. тк. *қыра* «таучык, калкулык, түтәл» сүзләренең контаминациясеннән булса кирәк (бу ике сүз үзара кардәш булырга мөмкин); к. гом. тк. *қыр* «тау сырты, тау, биек яр, дала», алт., хакас. *қыра*, тат. диал. *қырач* «басу җир, түтәл», тат. диал., башк. *кыраҙ* «саз эчендәге калку, коры җир».

**КЫР II** «край, граница» — гом. тк. *қыр, қыры* «кыр, чик» сүзеннән; чаг. ккк. *кыйыр*, якут. *кыйыа, кыжар*, бор. монг. *кыжар* «кыр, кырый, яр». К. **Кырый**.

**КЫРАУ** «заморозки» — бор. тк. *қырағу* «кырау» сүзеннән, тамыры ачык түгел; к. якут. *кырыа*, монг. *кируу, хируу* «кырау»; чаг. тат. диал. *кырлач* «иң суык айлар (*агам кырлач* «январь», *энем кырлач* «февраль»), *қырпақ* «күзге беренче кар, күзге тун, якут. *қырас, қырамах* «вак кар, кырау», *қырпақ* «вак кар»; чаг. фин. kuura (куура) «кырау», рус. диал. *куржак* «вак кар» (төрки телләрдән?).



**КЫРГЫЙ** «дикий; полевой» — гом. тк. *қыр, қырағ* «кыр, вак таулык, дала, кеше яшәми торган җир» сүзеннән (*кыргый* < *кырығ-ый* < *кырағ-ай* < *кырағ-ағ* «кырдагы, даладагы»); чаг. башк. *қырағай* «кыргый». К. **Кырый**.

**КЫРКУ** «острый; кислый» — бор. *кырк-ыр* «киселгән, кисә торган» (гом. кыпчак. *қырқ-* «кисү») ~ чув. *хӗрхӳ*, мар. *кырку* «артык әчегән, әче; кискен; тупас».

**КЫРМЫСКА** «муравей» — диал. бор. алт. *қырмысқа, қомурсқа* «кырмыска» *кымырда-у* (гом. тк. *қыбыр* «вак хәрәкәт») фигыленнән, ягъни «кымырдап, кымыржып йөри торган нәрсә» сүзеннән; к. якут. *кымы, кымырдагас,* шор. (алт. диал.) *кымырташ* «кырмыска» («кымырдагыч»).

**КЫРПУ** «опушка, оторочка» — бор. тк. *қур* «түгәрәк, билбау» сүзеннән булуы ихтимал (к. **Кыршау**); к. диал. *қырпуқ,* башк. *қырбу,* чув. *хӑрпу, кӑрпу* «кырпу, кайма», якут. *қурбу* «билбау, аркылы бау», алт. диал. (телеут.) *курбу* «түтәл, покос, тау чыгынтысы, тәндәге яра эзе. Чаг. **Керфек, Курпы**.

**КЫРТЫШ** «горбыль; целина» — гом. тк. *қыр* «кыр, дала, тау» сүзеннән булса кирәк (к. **Кыр**), ләкин ясалышы бик үк ачык түгел (*-тыш* элементы аңлашылмый); к. себ. тат. *кыртыш* «кыртыш, тире эчендәге май катламы; кул тимәгән чирәм җир», уйг., башк. *кыртыш* «югарыгы катлам, кабык», якут. *кырыс, кырысыш* «өске як, өслек, чирәм»; чаг. себ. тат. *кырчын*, башк. *кырсын* «сөзәк битләү, куаклык, чирәм җир».

**КЫРЫЙ** «край; берег, побережье» — гом. тк. *қырығ, қырағ* «кырый, яр» сүзеннән, *кыр*(к.) нигезеннән; к. чув. *хӗрӗ*, якут. *кыры*, чыгт. *қырық*, хакас. *хырых*, тув. *қыдыг, қызығ* (< кырығ) «яр, кырый», бор. тат. *қыра*, чыгт. *қырақ*, госм. *ғыра*, азәрб. *ғырағ* «кырый, яр кырые», тат. диал. *қырғак*, үзб. *қирғоқ* «яр буе».

**КЫРЫК** «сорок» — гом. тк. *қырқ, қырық* «кырык» сүзеннән, чыгышы ачык түгел, шунысы игътибарга лаек: кайбер төрки телләрдә гом. тк. *қырық* урынына *дӧртун* «дүрт ун» кулланыла.

**КЫРЫС** «суровый; горячий (*о лошади*)» — чув. *кӑрӑс*, н. *кырыс*, кырг. *кырс*, кк. *курус*, үзб. *курс* id.; чаг. башк. диал. *кырыҙ* «кыргый», тат. диал. *кырс* «карак; урлау» ~ төрек. *һырсыз* «карак».

**КЫСА** «оправа; обечайка; рама» — диал. һәм иске әд. *кыбса* «кыны, кыса» сүзеннән, диал. (себ. тат.) *кып* «тышлык, тышча» нигезеннән (*кып-са // кып-ча*). Чаг. **Кап**.

**КЫСЛА** «рак» — мар. *кысла*, чув. диал. *кӑсла ~* башк. *қысала, кысалаң* id. Төрки телләрдә (тат. диал. һ.б.) *қысқыч, қысқач* вариантлы ешрак очрый. Ясалу нигезе *қыс-*.

**КЫС-У** «сжимать; нажимать» — чув. *хӗс-*, гом. тк. *қыс-* бик күп сүзләргә нигез булган фигыль, шуннан гом. тк. *кыска* (*кыскак*), *кысык, кысла, кысмыр, кыста-у, кыскыч* сүзләре, тат. *кыстыбый* һ.б. ясалган.

**КЫСРЫК** «тесный; тугой» — иске тат. *қысыр* < *кысғыр* < *қысығыр* «кысу, басым ясау» сүзеннән (*қысыр-ық*); чаг. госм. *қысрық* «паника; куркак».

**КЫСТЫБЫЙ** «разновидность пирога» — диал. *кыстымбый*, башк. *кыстымбый*, чув. *кăстăмпи* «кыстыбый» — гом. тк. *кыс-* «кыс-у» сүзеннән булса кирәк, ләкин ясалышы ачык түгел: диал. *кәтемби* (ашамлык) сүзе белән чагыштырып, нииндидер *-мбый // -мби* аффиксы ярдәмендә ясалган дип уйларга мөмкин.

**КЫСЫР** «яловая, нестельная» — чув. *хĕсĕр* < болгар. **hисер* > мар., удм. *исыр* ~ гом. тк. *кысыр* id.; шуннан ук тат. диал., гом. тк. *қысрак* «кысыр бия»; *кысыр* сүзенең ясалышы төрлечә аңлатыла, монг. *кэгү-сер* «баласыз» (монг. *кэгу* «ул, бала»), бор. тк. **кыр-сыр* «кызсыз» яки бор. тк. *йык-сыр* «нәселсез» һ.б. Ләкин һәр очракта да ахыргы *-сыр* гом. тк. *-сыз // -сез*, бор. гом. тк. (чув., монг.) *-сыр // -сер* аффиксы белән бердәй дип карала.

**КЫТАТ** «парча; китайский шелк» — бор. тк. *кыта-т* «кытайлар, китаңлар» (*китаң* — төньяк Кытайны яулап алган маньчжур-монгол кабиләсе) сүзеннән; к. алт. *кыдат* «кытай (Кытай кешесе)»; чаг. чув. *кăтат* «кытат, клеенка», *кăтай, катай* «ак материя, тасма» (электә күптөрле тукымалар Кытайдан кителгән).

**КЫТЛЫК** «нужда; нехватка *чего-л.*; голод» — бор. әд. *қаһтлық* «кытлык, ачлык» сүзеннән, *қаһт* «ачлык» < гар. *каһт-ун* «корылык, ачлык» нигезеннән; к. чыгт. *қаһтлық* «ачлыкка дучар булган», *қаһт* «ачлык» > чув. *кахăтлăх* «ачлык; кризис», *кахăт* «ачлык» (Ашмарин, VI: 177), *хытлăх* «иген уңмый торган җир», *хытлан-* ~ тат. *хыйтлан-у* «интегү», *кыйхытлык* «кытлык, ачлык».

**КЫТЫК** «щекотка» — бор. *кыт-ығ* «кытык» — нииндидер *қыт-* тамырыннан; к. диал. *қытқылық* «кытык», кк. *қытық*, чув. *кăтăк*, госм. *қыдық* «кытык». Чаг. **Кычы-у.**

**КЫТЫРШЫ** «шероховатый, шершавый» — бор. тк. *кат // кут* тамырыннан булса кирәк; к. чув. *катраш, катрашка* «кытыршы», якут. *хаты* «чәнечкеле, шырпылы, тигәнәкле»; *хатыр-* «кытыршылану» ~ тат. диал. (мишәр) *кытыр* «кытыршы, тигезсез (шуннан *кытыр-а-ш-* «кытыршылану», **кытыр-аш-ығ* «кытыршы»). Чаг. **Кутыр**.

**КЫЧЫТКАН** «крапива» — диал. (мишәр.) *кецер-, кыцыр-, кычыр-* «кычыттыру, чагу» фигыленнән (*кычыткан* < *кычырткан*; к. тат. диал. *кече-у* «кычу», *кечерткән, кечергән* «кычыткан»); сүзнең нигезе *қычы-* «кычу, кычытып авырту» (*«кычы булу»; «кычыткан кычырту»*).

**КЫШ** «зима» — гом. тк. *кыш* «кыш» < бор. гом. тк. **қыл* «кыш, суык» (> чув. *хĕл* «кыш») сүзеннән; чаг. эрзя. *кельме*, мар. *кылме, келме*, фин. *кылма* «суык; туңган»; чаг. монг. *колдуу* «туңган».

**КЫЮ** «смелый; отсекать с краю» — бор. *кыйығ* «кыя торган, кыю» сүзеннән, *кый-у* фигыле дә шуннан.

**КЫЯ** «скала» — гом. тк. *кыйа, кайа* «кыя», бор. монг. *хада*, маньчж. *хада*, эвен., эвенк. *кадар* «кыя».

**КЫЯК** «осока; лист злака» — гом. тк. *кыйак* «күрән, кыяк» *кый-у* (к.) фигыленнән (*қый-ғақ* «кыя, кисә торган»); к. алт. *қыйғақ* «кыяк, күрән», тув. *қыйақ сигэн* «күрән» (*қыйар* «кыя торган», *сигэн* «үлән, җикән, камыш»).

**КЫЯР** «огурец» — башк. *кыйар*, чув., н. диал., кум., госм. *хыйар, хийар* «кыяр» фарсы. *хийар* «кыяр» сүзеннән (шуннан ук гар. *хиар-ун* «кыяр»).

## -Л-

**ЛАЕК** «достойно» — гар. *лаик* «лаек, ярашлы» сүзеннән (шуннан ук чув. *лайăх* «яхшы, житәрлек, уңышлы, мөмкин»).

**ЛАЙ** «раствор глины; грязь; тина» — гом. тк. *лай // ылай* «лай, ләм», фарсы. *лай* «лай» сүзеннән хисаплана (шуннан ук монг., бурят. *лай* «лай, ләм»). К. ***Лайла.***

**ЛАЙЛА** «слизь» — *лай* (к.) сүзеннән, ләкин ясалыш юлы ачык түгел; к. чув. *лайма, лыйма* «лайла»; чаг. уйг. *лайла-* «лайга бату», үзб. *лойқа* «лайлы, лайла».

**ЛАК** «лак» — рус. *лак* яки фарсы. *лак* «лак» сүзеннән, асылда, ирани тамырдан.

**ЛАЛӘ** «лилия». — к. **Ләлә**.

**ЛАПАС** «лабаз, сарай наподобие хлева» — чув. *лапас* (*лак*) «кыексыз абзар, тәбәнәк сайгау» сүзеннән (чув. *лап*, тат. диал. *ләпәш, ләпәк, лапак* «тәбәнәк, җәенке», чув. *ас, аслăк* «япма, сайгау»); к. тат. диал. *лат асты* «лапас», рус. *лабаз* татар яки чуваш теленнән. Асылда, мари-удмурт сүзе. К. Әхмәтьянов, 1989: 136—137.

**ЛАФ: лаф ору** «хвастаться, бахвалиться» — фарсы. *лаф* «мактану» сүзеннән, тат. әд. *лаф ор-у*, чыгт. *лаф ур-* «мактану» — фарсы. *лаф задан* (*задан* «ору, сугу») тәгъбиреннән калька; чаг. монг. әд. *лаф дәлэт* «лаф сугу (ору); мактану, лыгырдау».

**ЛАЧЫН** «сокол» — гом. тк. *лачын, ылачын* «лачын, козгын (сирәк очрый)» сүзеннән, көнч. тк. *ыл-* «югарыдан киеккә ташлану (*ерткыч кошлар турында*)» сүзеннән булса кирәк (к. **Эл-ү**); к. тув. *ылғасын* «киеккә югарыдан ташланучан (*ау кошлары турында*)», кырг. *ылаачын* «лачын». Бу сүзне борынгы бер телдән алынма диючеләр дә бар.

**ЛАЯКЫЛ** «совершенно пьяный» — гар. *лә йағқул* «акылы юк дәрәҗәдә» дигән сүздән.

**ЛӘБАСА** «же, ведь; небось; увы» — чув. диал. *лапасса*, мар., удм. *лăваса, лаваса*, тат. диал. *ләсә, ласа* — татар теленнән таралган дистинктив Идел-Урал сүзе: *-ла // -лә* һәм *баса* (гом. тк.) кисәкчекләреннән дип хисапланыла; М.Рясянен гарәп теленнән дип аңлата; Х.Максуди *-ла // -лә баксаң* тәгъбиреннән, ди.

**ЛӘГӘН** «лохань; таз» — киң таралган сүз: рус. *лохань, лагун* «ләгән, таз», тат. диал. *лакан, лагун* «зур тимер чиләк», *ләгән* «зур таз», чув. *лагăм* «ләгән», *лагам* «юлдагы батынкылар», коми. *лагун* «мичкә», бор. тк. *лағун* «уелган савыт» (МК), фарсы-таж. *лăганд* «бакыр таз», грек. *лаххос* «чокыр; бассейн», лакане «чәшке, чынаяк», латин. *laci* «күл, баз» (шуннан ук рус. *лагуна* «диңгез буе күле»).

**ЛӘГЪНӘТ** «проклятие» — к.**Нәләт**.
**ЛӘЗЗӘТ** «наслаждение» — гар. *ләззәт-ун* «ләззәт» сүзеннән.
**ЛӘКИН** *союз* «но» — фарсы-таҗ. теле аркылы гар. *ләкин* (*на*) «ләкин, юкса» сүзеннән; к. фарсы-таҗ. *лек, лекин* «ләкин» > тат. диал. *ликин* id.
**ЛӘКЛӘК** «аист» — фарсы-таҗ. *лаклак, ләгләг* «ләкләк» сүзеннән, тасвирый яңгырашлы тәкълиди тамырдан; к. гар. *лаклака* «кайгылы кычкыру», грек. *лелехи* «ләкләк», гар. *ләкләк-ун* «ләкләк», үзб. *лайлак* «ләк-ләк» — *ләгләк // лаглак* формасыннан.
**ЛӘКШӘ** диал. «лапша, вермишель» — к.н. *ылакса*, уйгур., бор. тк. *лакш, лакша* «токмач, бодай оны». Асылда, тибет-кытай сүзе. Рус. *лапша* — төрки телләрдән. К. Әхмәтьянов, 1981:87.
**ЛӘЛӘ** «тюльпан» — фарсы. *лала* «ләлә, якты, нурлы» *-лал, ләгыль* «ал, кызыл» сүзеннән (шуннан иске әд. *җәүһәри-ләгыль* «рубин»).
**ЛӘМ** «ил; глина» — киң таралган символик яңгырашлы тамырдан булса кирәк; к. диал. *ләпек, ләпәк* «ләм», ккк. *ләм* «дым, ләм», удм. *лем* «җилем», мар. *лем* «шурпа», якут. *ләби* «ләм, кар катыш су»; чаг. фин. liim, liime «ләм», немец. leim «ләм, җилем», чув. *лым* «дым, чык: ләм», кырг. *ным*, үзб. *нам*, уйг. *нәм* «дым, юешлек» (В.Г.Егоров буенча тат. *дым* сүзе дә шуннан), фин., мар. *лум*, коми. *лым*, удм. *лымы* «кар, җепшек кар».
**ЛӘМ-МИМ: ләм-мим белми** «круглый невежда» — гар. *лам* юклык кисәкчәсе (рус. *не*) өстәвенә «авыз» мәгънәсендәге *мим* сүзен кушып әйтүдән, мәдрәсә жаргонынннан: *лам* бер үк вакытта гарәпчә (л) хәрефен дә белдерә, *мим* исә дан соң килә торган (м) хәрефенең исеме.
**ЛӘПӘК** «мошкара» — фин-угор телләреннән кергән сүз булса кирәк; к. мар. *лемэ* «ләпәк», *лепе, лепене* «күбәләк»; чаг. чув. *лепеш* «күбәләк», манси. *лаопх*, якут. *лыах* «ләпәк; күбәләк».
**ЛӘТЧӘ** *зоол.* «ласка» — рус. диал. *ласица* «ләтчә» сүзеннән. Диал. *йәтчә* варианты мари теленнән булса кирәк.
**ЛӘҮ** «дракон; дух мертвеца» — бор. тк. *луй*, якут. *луо* «аждаһа, гөнаһлы кеше җаны», шуннан кум. *элив* «мәет, аждаһа, дию». Бор. кытайчадан (к. **Юха**). Борынгы мәҗүсиләр дине буенча мәет рухына аш уздырып, аңа корбан биргәннәр. Бу ашка пешерелгән махсус күмәч *ләү ашы* дип аталган, шуннан тат. диал., кум., кб. *ләвеш* (*элив ашы*) «лаваш» дигән күмәч исеме килә. Күп телләргә таралган.
**ЛӘҮКӘ** «полок в бане» — рус. *лавка* «ләүкә, кибет өстәле» сүзеннән; чаг. тат. диал. *лафкы* «кибет», чув. *лавка* «кибет, ләүкә, сәндерә».
**ЛЕПКӘ** «темя (*у детей*)» — фин-угор теленнән хисапланыла (Рясянен); к. мар. *лепкэ* «маңлай», *леплу* «лепкә» (*лу* «сөяк»); к. иске тат. *әлфкә* «лепкә, таҗ», чув. *лёпке* «лепкә, баш түбәсе».
**ЛЫГРЫМ** «совершенно; полный» — фин-угор телләреннән кергән *лак, лап, лык, лып* тәкълиди сүзе нигезендә ясалган; к. диал. *лық тулы, лықма тулы, лыгыр булу, лығырдау, лыбыр булу, лыбырдау, лабырдау, леперд*ә*ү* «тәмам юешләнү». Параллельләре чуваш, мари, удмурт телләрендә. Тат. башк. *лыгырдау* «юкны сөйләү, кирәкмәгәнне сөйләү» шушы ук нигездән (күчмә образлы мәгънә).

# -М-

**МАВЫК-У** «увлечься, увлекаться *кем-чем-л.*» — *мау-* тамырыннан (*мауык-*); к. кк., ккк. *мауық-* «бик нык теләү, омтылу, язгы көннәрдә җанланып киту» (*башлыча хайваннар турында*), үзб. *мов бўлмоқ*, кк. *мау бол-, мауқ-* язга чыккач, шатланып йөгереп йөрү, чыгт. *моу* «мыяу», кк. *мауык* «омтылыш, сагыш», тат. диал. *маwық* «юаныч, кызык»; чаг. себ. тат., алт., хакас., кк., уйг. *маң-* «чабыш, омтылыш, буш вакыт; чабу, буш вакыт үткәрү» (шуннан *маң-ык, мағык- // мауык-* «мавыгу» сүзе килеп чыгуы ихтимал).
**МАҖАРА** «приключение» — гар. *мәҗәра* «маҗара, дөнья күрү» *-җәра* «сөйрәлү, ышкылу» тамырыннан.
**МАЗА** «покой, спокойствие» — гом. көнб. тк. *маза*, чув. *маса* «маза, тынычлык, тәм, ләззәт» — фарсы. *маза*, бор. ирани. mazza «тәм, рәхәтләнү» сүзеннән; чаг. ш. ук гар. *маззат-ун* «тәм, тәмләү», *мазза* «суыру, иму».
**МАЗАР** «обозначает приблизительность, неопределенность, *напр., кеше-мазар* «какой-то человек» — фарсы. *мазар* «каберлек, кабер» < гар. *мäзар-ун* «кабер, зыярәт итә торган урын (к. **Зират**) сүзеннән (к. тат. диал. *мазар* «каберлек»); бу сүзнең кирәксез нәрсәләрне белдерүче тагылмага әверелүе татар-чуваш даирәсендә килеп чыккан; к. чув. *таçта-масарда çӳр-* «теләсә нинди кирәкмәгән урыннарда (тышта һәм каберлектә) йөрү», *чул-масар* «ташлык һәм каберлек, җимереклекләр, файдасыз (кешесез) урын (Г.Әхмәров). *Мазарда*, ягъни мәҗүси каберлегендә элек корбанга китерелгән киндерләр, күлмәкләр, тиреяры һ.б. агачларда эленеп торган, шуңа ул чүплек башына охшап калган.
**МАЙ** «масло, жир» — гом. кыпчак., алт. һ.б. (күп кенә төрки телләрдә юк) *май* id.; тат. диал. *май-* «майлау», *маем* «җаным»; *бәби мае* «бәби туе», *килен мае* «килен күрү (май каптыру) мәҗлесе» — мәҗүси алиһә *Умай* (алт. *Май*) — «бәбиләр һәм аналар химаячесе» сүзеннән. Яна туган бәби өстендә *Умай* белән *Аза* көрәшә: Умай — бәбине саклап калырга, Аза үтерергә тырыша. Умайга куәт бирер өчен ритуаль майлы ашамлык пешергәннәр.
**МАЙМЫЛ** «обезьяна» — көнб. кыпчак. *маймыл*, госм., куман., уйг. *маймун* (тат. диал. *мәймун*) id. гар. *мәймун* «бәхетле» яисә «Йәмәннән килгән, йөмәнле» сүзеннән. Чаг. тат. хатын-кыз исеме *Мәймунә* «бәхетле кыз» яисә «Йәмән кызы»; *Йәмән* «бәхетле ил» дип исәпләнгән.
**МАЙМЫЧ** «малёк; малявка» — гом. тк., монг. *май // бай, бал*

// *бар* «йомшак, кабарынкы» мәгънәле тамырдан; к. якут. *майба // байба*, тунгус. *майма, малма* «корсаклы балык, маймыч», бурят. *байбагар* «корсаклы, кабарынкы, йомшак». Тат. диал. *мармыч* «маймыч» сүзеннән рус. *мормыш* «балык җиме, җимбалык» сүзе килә.

**МАЙТАР-У** «исполнять, исполнить, наломать дров» — гом. тк. (хәзер сирәк очрый торган) *май-* «кирегә бөгү, бөгелү, каерылу» фигыленнән; татар сөйләшләрендә шуннан чыккан сүзләр бар: *майтояк* «атның тоягы каерылу авыруы, тояк шешү», *майык, майырык* «кыйшык, каерылган», *майыш* «кыеш», *маймак* «чалшайган», *майткы, мәйтке* «җаваплашу уены; кискен яки җор җавап».

**МАКСЫМА** «домашнее пиво; свадебный квас» — чув. *максăма*, кк., кырг. *максым*, абазин. *бахсыма* «квас, куәтсез сыра», гар. *мәгъсум, мәгъсума* «гөнаһсыз (ягъни эчсәң ярый, искерткечкә саналмый)» дигән сүздән булса кирәк. Чаг. мар. *максымтрай* «камка (гөнаһсыз сыер)»; иске тат. *мәгъсум* (*мәгъсума*) «мулла малае (кызы)».

**МАКТА-У** «хвалить» — чув. *мухта-, мохта-*, мар. *мокта-*, удм. *макта-* ~ гом. кыпчак. *мақта-*, бор. монг. *магта-* «мактау, данлау» бор. тк. *мак, маг, магу* < сугди. *m'γ'* дан, мактау» сүзеннән. К. иске тат. *макчы* (Утыз Имәни) «мактанчык».

**МАЛ** «скот; имущество; богатство; товар» — чув. *мол, мул*, хантый. *мол*, гом. тк., гом. монг., фарсы., гар. *māл* «мал; терлек; байлык» — киң таралган сүз. Чаг. бор. кытай., монг. диал. *мар* «ат, мал».

**МАЛАЙ** «мальчик» — рус. диал. *малой* «егет, хезмәтче малай» сүзеннән; чаг. үзб. *малай* «лакей» (рус сәүдәгәрләре теленнән).

**МАМЫК** «вата, хлопок» — киң таралган сүз: госм. *памук, памбук*, куман., чыгт. *мамук* «мамык», осетин. *бамбаг, бәмбәг* грек. *памбах*, рус. *бумага* «кәгазь, мамык, материя», *бумазея* «мамык тукыма», итальян. *bambag* «мамык» фарсы. *памба, пумбах* «мамык» сүзеннән дип исәпләнә, ләкин фарсы теленең үзенә төрки телләрдән кергән булуы мөмкин; к. тат. диал., башк. *бакмык* «чалмабаш; ябага; кәҗә мамыгы», үзб. *пахмак* «мамыклы ялбыр, бумази». Һәрхәлдә, бу сүз символик яңгырашлы - *бам // бум* «йомшак һәм кабарынкы нәрсә» тамырыннан; чаг. бурят. *бамбагар* «ялбыр, йонлач, мамыклы», *пумпэгэр* «йомшак, йонлач».

**МАНАРА** «башня, минарет» — гар. *мăнара-т-ун* «маяк, манара» сүзеннән, *нара* «яктырту» тамырыннан. *Нур* сүзе дә шуннан.

**МАН-У** «обмакнуть; окрасить» — бор. тк. (чыгт., куман.) *ман-*. Шуннан ук тат. *манчы-*, кар. *манч-*, госм., гагауз. *банч* > чув. *поç-, пуç-* «ману, манчу». Төптә бор. кытай. mak (*мак*) «тушь, буяу» сүзеннән.

**МАҢ** «шитье вокруг переднего выреза платья» — көнч. тк. *маң* «чигүле, ефәк, ука, парча» сүзеннән, асылда, кытай теленнән; к. хакас., тув. *маңыс* «ефәк», алт., тув. *мандык, маңнык, маңлык* «кытай ефәге, чигүле ефәк». Л.Лигети фикеренчә, алт., монг. *маңныг, маңлук* «халык этимологиясе»: кытайча *mang lung* «чигеп төшерелгән аждаһа (изображение дракона на шелковой материи)». Монголиядә һәм Себер төркиләрендә традицион бизәк шундый.

**МАҢКА** «сопля» — гом. тк. *маңка* «маңка, эрен» сүзеннән, ясалышы ачык түгел; чаг. эвен. *муңгие* «эрен, маңка», *мун-дэй* «черү, эрендәү».

**МАҢЛАЙ** «лоб» — гом. тк. *маңлай, маңгай* «маңлай, йөз, алгы як» сүзеннән, ясалышы ачык түгел, бор. тк., монг. *маң // ман* «алгы як, чик, максат» сүзеннән (*mag-agay*) булса кирәк; к. якут. *маңнай* «башлангыч; алгы як; начальник» < монг., бурят. *маңлай* «авангард». Чаг. **Маң**.

**МАР** «курган» — к. чув., морд., рус. *мар* «курган». Бор. санскрит. *мару* «кабер, кабер өстендәге сын-таш» сүзеннән (Т.Н.Кондратьева).

**МАРҖА** «русская» — от имени Мария, рус. *Мария* — хатынкыз исеменнән гомумиләштереп әйтелгән сүз.

**МАСАЙ-У** «возгордиться» — мар. диал., удм. диал. *масай-*, тат., башк. диал. *мастану, масыгу*, тат. диал. *мас*, үзб. *маст* < фарсы. *маст* «шат күңелле, исерек, куанган хәлдәге кеше» сүзеннән; шуннан ук тат. диал. *мәз бету* «эйфория» сүзе килә.

**МАТАШ-У** «возиться; пытаться» — мар. *маташ-, моташ-*, чув. *муташ-*, удм. *маташ-* «маташу: көрәштә аяк чалу» ~ тат. диал. (мишәр., себ. тат.) *мата-у*, кк. *мата-* «атның алгы аякларын арткы аягына бәйләп тышаулау; бик каты комачаулау, авыр хәлгә дучар итү» мәгънәсеннән; к. ш. ук тат., башк. *матавыч* «комачаулы», *матавык* «тоткар», *маталан-у* «бер урында азаплану», *маталау* «комачаулау». К. **Мәтәл-ү**.

*Мата-у* фигыле гом. тк. (тат. диал.), фарсы., гар. *māт* «паралич; камалып тотылу; үлем; шахматта мат» сүзеннән. Еш кына бу сүзне гарәп сүзе дип аңлаталар, ләкин алт. *маат* «тышау, хайваннын аякларына (аны егу өчен) ыргытыла торган герле бау» сүзе *māт-* тамыры киң таралган мәдәни термин икәнен күрсәтә. К. ш. ук эвен. *маут* «аркан; лассо».

**МАТУР** «красивый, хороший; *диал.* молодецкий» — чув. *матур, маттур*, мар., удм., хант. *матор, мотор, матур* id. Идел-Чулман регионына хас сүз — тув. *маадыр, маатыр*, алт. *маттыр*, хакас. диал. *матур* «батыр, герой, баһадир, яугир» сүзеннән. К. **Баһадир**.

Бу сүз Идел регионына татар теленнән таралган. Татар теленә исә ул Себердән XV—XVI гасырларда гына килгән. К. Әхмәтьянов, 1981.

**МАТЫ** *диал.* «грубая ткань; циновка» — рус. *мат, маты* «чыпта, спортив ястык» сүзеннән түгел, ә фарсы. *мата* «гади тукыма» сүзеннән.

**МАТЧА** «балка, матица» — диал. *матича-* рус теленнән (русчада бу сүз *мать* «ана» сүзеннән ясалган).

**МАХМЫР** «пьяный; хмельной» — мар., удм. *макмыр, мок-*

*мыр*, чув. *мохмăр, мухмăр*, морд. *махмара*, рус. диал. *бахмур* id. гар. *мәхмур* «исергән, хәмер эчкән» сүзеннән. Күп телләрдә очрый.

**МАЧ** «везение, удача» (*мач килү* «везти») — чув., мар. *мач*, н., кум., кк., уйг. *мас*, үзб. *мос* < фарсы. *мас* «уңайлы шартлар» сүзеннән. Сүзнең мәгънәсенә рус. *масть* «әйбәт кәрт» сүзе тәэсир иткән.

**МАШ** «наклонная вышка; башня» — чув. *маш*. Безнеңчә рус. *мачта* сүзеннән түгел, ә үзб., кырг. *маш, машқ* һ.б. «хәрби-физик күнегүләр» < гар. *мәшқ* «махсус җәяүләү, гимнастика» сүзеннән (*маш* «гимнастика җайланмасы»). К. **Мәш**.

**МАЭМАЙ** «собака» — этне чакыру ымлыгы *маһ-маһтан*. Чаг. **Бахбай**.

**МАЯ** «запас; капитал; подкладыш» — гом. тк., монг., эвен. *майа* бор. заманнарда ук ирани телләрдән таралган сүз; үзб. *майақ*, фарсы. *майә*, бор. ирани. *madak* «мая, капитал» сүзеннән.

**МАЯК** «маяк» — чыгышы ачык түгел; рус. *маяк* сүзе татар теленнән булырга мөмкин (әгәр тат. *майак* русчадан булса, *май-ак* яки *мәйәк* булырга тиеш иде); чаг. бурят. *майаг* «үрнәк; күренеш». К. Әхмәтьянов, 1989:36.

**МӘГӘЛДӘК** *диал.* **мәгәдәк, мөгәдәк, мүгүрдәк, мөгәртәк, мәдәк** «свадебный экипаж для невесты, ритуальная колесница» — татар теленнән тыш үзбәк теленең Хива сөйләшләрендә генә очрый — бор. монг. *мөгер тәрг* «ике тәгәрмәчле арба» (*мөгер* «тәгәрмәч», *тәрг* «арба») сүзеннән. Алтын Урда чорында мондый арбада хан, хәрби чиннар, түрәләр йөргәннәр. Чаг. морд, мар. *он орва, онова* < *хан арбасы* — «мәгәлдәк» (кәләш исә «хан кызы»). *Мәгәлдәк* — махсус бизәкле туй арбасы — татар халкының югары матди вә рухи мәдәниятен күрсәткән элемент. *Килен төшерү* тәгъбире киленне мәгәлдәктән төшерү (һәм «Хан кызы» җырын җырлау) гадәтеннән калган.

Хәзерге көндә *мәгәлдәк* дип җиңел машинаны да атыйлар.

**МӘЕЛ** «настроение; желание; склонность» — фарсы теленнән кергән гарәп сүзе: Урта Иделдә бу сүз күптәннән килә: тат. диал. *бәел, пәел*, морд. *мяль*, удм. *мыл*, мар. *пиал, пиал*, чув. *пил* «мәел», тат. *мәйлең* «теләгәнчә булсын, ярый, хуш».

**МӘҖҮСИ** «язычник; языческий» — гар. *мәҗүси* < грек. *магос* «маг» бор. фарсы. *магу* «Заратуштра динендәге рухани» сүзеннән.

**МӘЗӘК** «потеха, анекдот» — гар. *мәзах* id. сүзеннән таралган.

**МӘЗИН** «муэдзин» — гар. *мөәзин* «азанчы» сүзеннән, *азан* сүзенә тамырдаш.

**МӘЙДАН** «площадь, майдан» — фарсы теленнән киң таралган сүз; рус теленә татар теленнән кергән булса кирәк.

**МӘЙХАНӘ** «питейное заведение» — фарсы. *мәйханә* «кабак» сүзеннән; к. тат. әд. *мәй* «шәраб».

**МӘК** «мак» — рус теленә грек теленнән (грек. *мах-ас* «мәк») кергән булса кирәк.

**МӘЛ I** «способность» — чув. *мел* «мәл, мән, хәйлә» сүзеннән,



Егоров буенча *әмәл* (к.) сүзеннән; чаг. тат. диал. *мәләкә* «булдыклылык».

**МӘЛ II** «время, пора» — бор. әдәби *мәһәл* «вакыт, чак, ситуация» сүзеннән (асылда, гарәп теленнән, *хәл* сүзе белән тамырдаш); к. чув. *мәхәл* (*мәһәл*) «мәл, чак», чыгыт. *мәһәл*, үзб. *маҳал*, кк. *маал* «хәл, очрак, чак, момент» бор. чыгтай яки госманлы әдәби теленнән таралган. К. Әхмәтьянов, 1989:20.

**МӘН** «толк; понятливость» — диал. *мәне* id. гар. *мәгънә* сүзеннән.

**МӘҢГЕ** «вечный, вечно» — гом. тк. *мәңгү, мөңгү*, бор. тк. *бәңгү* «мәңге, мәңгелек». Г.Рамстедт буенча бор. кытай. mankö (хәз. кытай. *вань цуй* ~ япон. *банзай*) «ун мең еллык» сүзеннән. Икенче яктан к. монг. *мәнгүй* «чиксез» (*мән, мөн* «чик, ахыр, максат», *-гүй* юклык кушымчасы, төрки *-сыз // (сиз)* сүзеннән дә була ала); чаг. хәз. монг. *мөнкә*, бурят. *мунхэ* «мәңге».

**МӘРӘЙ** «игровой круг при играх; мишень» — диал. *мәрә, мәрәү* ~ чув. *мере*, кк., ккк., кырг. *мерей, мәрәй*, алт. *мөрөй* «мәрәй, уңу, уңыш; бәхет» бор. *мәр, мәр* «ук ату мәрәе» тамырыннан; к. тув., хакас. *мәргә-* «төз ату; атуда ярышу мәйданы», кб. *мара-* «төзәү, атып алу». К. **Мизгел**.

**МӘРӘКӘ** «потеха» — чув., мар., удм. *мерекке, марака, мереке* << гар. *мәәрәкә, мәғрәкә* «түгәрәк, халык җыены, сабантуй» сүзеннән таралган сүз.

Гар. *сахир-мәрәкә* «сихерче һәм мәрәкә» сүзеннән русча *скоморох* «мәрәкәче-мәзәкче» сүзе дә килә дигән фикер бар.

**МӘРТ** «летаргия» — фарсы. *мӓрд* «үлем» сүзеннән.

**МӘСХӘРӘ** «издевательство; посмешище» — гар. *масхара* id. (*сихер* сүзе белән тамырдаш) > угыз-кыпчак. *маскара* > тат. диал. (мишәр.), себ. тат., чув., мар., удм. *маскар, мыскар* id. К. **Мыскыл**.

**МӘТӘЛ-Ү** «кувыркаться, кувыркнуться» — диал. *матал-у* «аягы бауга эләгеп егылу» *мата-у* «лассо атып мәтәлдерү» сүзеннән. К. **Маташу**.

**МӘТЕ** «сырая глина; глинозем» — фин-угор сүзе; к. морд. *мода* id.

**МӘТРҮШКӘ** «душица» — рус. *матрешка* id. *Матрёшка* төптә «күп балалы ана». Бер ана шул үсемлеккә әверелгән дигән риваять бар.

**МӘЧЕ** «кот, кошка» — диал. *мачы*, мар., удм. *маче*, кар. *мацы*, фарсы. *мачы* «ана эт яки мәче; ишәк колыны» < бор. грек. *matsa* id.

**МӘЧЕТ** «мечеть» — гар. *мәсҗид* «сәҗдә урыны» сүзеннән.

**МӘЧКӘЙ** «старуха ведьма (*в сказках*)» — иске *мичен, мәчин* «маймыл» сүзеннән. К. **Бичура**.

**МӘШ: мәш килү** «копошиться» — диал. *мәшлән-ү, мәшеклән-ү* «мәшгуль булу» — фарсы. (< гар.) *мӓш, мӓшк* «тренировка» сүзеннән.

**МӘШКӘ** «гриб трутовик» — тат. диал., башк. *мәшкәк* «гөмбә, бөке», алт. *мәшкә* «гөмбә, каен орысы», саян. *бәшкә* «гөмбә, күгәрек», калм. *бәшкә* «мөшкә, ку»; чаг. мар. *мәкш(э)* «черек агач».

**МЕНДӘР** «подушка» — чув. *минтер*, мар. *мындер*, удм. *миндәр-* < кыпчак. *миндәр* «мендәр» *мен-, мин-* «(атка) менү» сүзеннән хисаплана (тәүге кулланышта ияр функциясендә булган дип уйланыла), ләкин фарсы. *бәндәр* «мат, камыш ястык» сүзеннән дә булырга мөмкин.

**МЕН-Ү** «подниматься; взобраться» — гом. тк. *мин-, бин-* id.

**МЕСКЕН** «несчастный; забитый» — чув. *мескен*, мар., удм. *мыскынь* гар. *мискин* «мескен, юаш, өнсез; тавышсыз» *өнсез булу* тамырыннан (шуннан ук *Сәкинә* «тыныч холыклы кыз» исеме килә).

**МЕҢ** «тысяча» — өч вариант бар: гом. кыпчак., үзб. *миң*, кк., ккк. *мың*; тув., хакас., якут., ткм. *муң, муң;* чув. *пин* ~ төрек. *бин*, бор. тк., уйг. *бың, пың*; монгол һәм тунгус телләрендә *минга(н)* «күп яфраклы бер үсемлек төре», бор. тк. язмасында *миң* < **миниң*. Гадәттә «мең», «миллион» мәгънәсендәге сүзләр күпләп пайда булган хайван яки үсемлек исеменнән чыга.

**МИ** «мозг» — бор. тк. *бәңи // мәңи* «ми» сүзеннән; к. тат. диал. *мие, мийә-*, үзб. *мийә*, бор. чыгт. *мийе*, алт. *мее*, кырг., тув. *мээ*, кк., н. *мый*, ккк., кб. *мийе*, якут. *мэйи*, госм., азәрб., ткм. *бәйин, бәйни*, чув. *миме*, уйг. *мәйә*, бор. уйг. *мәңи, миңи*, чыгт. *миңгә* «ми, баш, акыл»; чаг. санскрит. *tayya'* бор. ирани. *tazga* >> үзб. һәм иске тат. *мәгызь* «җилек, төш». К. **Миңке**.

**МИЗГЕЛ** «время; сезон» — башк. *мизгел*, уйг. *мәзгил*, кырг., кк., ккк., кум. *мезгил* «мизгел» — ике төрле аңлатыла ала: 1) кырым. мэзги << алт. диал. *мерги* «мәрәй, максат, барып җитәсе пункт» сүзеннән; 2) гар. *мәскил* «үлчәм» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1989: 149—151. К. **Мәрәй**.

**МИЛӘҮШӘ** «фиалка» — фарсы-таҗ. *бинафша, бӓнафше* «миләүшә» сүзеннән.

**МИЛӘШ** «рябина» — тат. диал. *мәләш, мулиш*, чув. *милеш, пилеш, пулеш*, удм. *палэз*, коми. *пелыс-*, мар. *пизел, пезел* ~ тат. диал. (мишәр.) *пизел* < морд. *пизел, пизол* ~ фин. *pihlaya* «миләш», күрәсең, фин-угор телләреннән (*миләш, мәләш* < *пэлэз* < *пэзэл*).

**МИНӘЗ** «образ» — к. **Миң**.

**МИҢ** «родинка, родимое пятно» — чув. *миң*, мар., удм., гом. тк. *мәң*, угыз. *бәң, бэң* «миң, йөз төсе, янак» — киң таралган сүз.

Тк. *мәң*, монг., тунгус. *мәңгә* «мин, бәхет, тәңре тамгасы» буенча катлаулы юраулар юраганнар (к. Жуковская Н.Л. Категории и символика традиционный культуры монголов. — М., 1988: 94—95). Тат. исемнәрендәге *Миңле-* компоненты «тәңре тамгалаган, бәхетле» дигән мәгънәдә килә.

Бор. тат. *биңзә-* < чыгт., госм. *бәңзә-* «охшаш булу, охшау» сүзе угыз. *бәңиз* «йөз, бит, ике янак» сүзеннән ясалган (*бәң - из-ә-*). Шуннан тат. диал. *минәз, менәз* «образ» сүзе килә.

**МИҢКЕ, МИҢКЕ-Ү** «без памяти; терять память» — (шуннан *миңгерә-ү* > чув. *минкӗре-, минӗре-* «һуштан язырга якынлашу») монг. *мәңигүй, мәңкүй* «мисез» сүзеннән булса кирәк.



**МӘРГӘН** «меткий стрелок, снайпер» — гом. тк. *мәргән, мерген* > мар. *мӓрган, марган, мардан*, чув. *меркен, мерккен, миркен* «мәргән», монг., тунгус. *мәргэн* «мәргән, акыллы, батыр, уйчан, уйчанлык, намус», тат., башк. *мәрәй* «мишень», алт., тув. *мерге* «сага-мәрәйгә бәрә торган таяк», кк. диал., үзб. диал. *мәр* «максат, мәрәй, финиш; шарт» тамырыннан булса кирәк. К. Әхмәтьянов, 1989: 149—151.

*Мәргән* сүзе белән борынгы Себер тарихында зур роль уйнаган *мәркит* (монголча «мәркиләр») кабиләсе исеме баглы: бу кабиләнең калдыклары башкортлар составына да кергән.

**МИС** «миска» — фарсы. *мис, месс* «бакыр, җиз» сүзеннән (рус. *миска* — татарчадан). Металл атамасы савыт исеменә әверелүенә мисаллар: чуен, бакрач.

**МИСЛЕ** «вроде, словно, подобно» — төрки телләрдә гар. *мәсел* «охшашлык» сүзенә III зат тартым кушымчасы *-и* (тат. *=е*) ялганып ясалган сүз (язм. тк. *мәсл-и* > тат. *мисле*); тамырдаш сүзләр: *мисал, мәсәл, мәсәлән, тәмсил* (сөйләм сәнгатендә мисал китерү, охшату).

**МИХНӘТ** «страдание; нужда» — кайбер төрки телләрдә «хезмәт, эш» гар. *михнәт* «сынау, сыналу, чыныгу» сүзеннән.

Шуннан ук **Имтихан**.

**МИЧ** «печь» — башк. *мейес*, тат. диал. *пийәч, пийәш-* рус теле диалектларыннан. К. Әхмәтьянов, 1989: 137.

Мичнең борынгы атамалары *чувал, супа, уша* диалекталь лексикада саклана.

**МИЧӘҮ** «постромки; пристяжка» — *мичә-у* «мичәүләп җигү» фигыленең исемләшкән формасы: бу сүзнең «ярдәм итү, булышу» мәгънәсе дә бар (*өйдә кеше ничәү — бер-беренә мичәү* дигән мәкаль бар). Диал. *мичәп* «янга җигелгән ат» *мичә-п җигу* тәгъбиреннән (*мичә-у* фигыле үзе онытыла төшкән).

Бүтән төрки телләрдә дә бу сүз сирәк очрый: ткм. *мечев* «ярдәм», кум. *минчав* ~ абазин. (куман теленнән) *бачу* «буксирга алу», бор. тк. *бэчэку, бэ-чэ-гу* «аркан, бау» — шуннан рус. *бечев, бечва, бечева* «бурлаклар куллана торган озын аркан»; тат. диал. *бичәвәй* < рус. *бечевой* «бау буйлап тезелеп» сүзләре дә шуннан. Гомумән, *мичә-* фигыле татар һәм башкорт телләрендә генә сакланган булса кирәк. Сүз ясалу моделеннән чыгып, бу сүзнең тамыры *мәч // мэч, бәч // бэч* «элмәкле бау» дип әйтеп була. Шул ук тамырдан тат. диал. *мәчкәй, мәчкәү*, башк. *мәскәү* «элмәкле тозак» сүзе дә ясалган.

**МИЧКӘ** «бочка» — рус. *бочка*, бор. рус. *бъчка* «мичкә» сүзеннән; чув. *пичке* һ.б. татарчадан булырга мөмкин.

**МОГОЛ** «шишка, нарост, желвак» — чув. *мӑкӑль*, мар. *мыгыл, мыгыль*, удм. диал. *мугыл* «могыл, тупа» күп алтай-урал телләренә хас тасвирый яңгырашлы сүз; к. якут. *моғол* «кабарынкы, юан», маньчж. *моголо* «мүкләк», монг. *моколчок* «түгәрәк, юантык». К. **Мокыт, Мүкләк**.

**МОКЫТ** «тупой; тупица» — чув. диал. *мӑкӑт*, удм. *могыт*, мар. *могыт, мокыт, мокай* «мокыт», якут. *моготох*, монг. *моготак*

«мокыт, сүлпән» күп урал-алтай телләрендәге *моко* «тупа, үтмәс» сүзеннән (*мок-ыт*); к. себ. тат. *мӧқ*, алт. *мӧкӧ* «үтмәс (пычак), мокыт, аңгыра», *моко-* «үтмәсләнү», уйг. (таранчи), кк. *моқа-* «үтмәсләнү, хәлсезләнү». Пекарский бу сүзне якут. *муң-а* «ахырга житү, бетү» (*муң* «ахыр» тамырыннан; к. **Матур, Мәңге**) сүзе белән тәңгәлләштерә. К. **Мүкләк**.

**МОҢ** «уныние; печаль» — гом. тк. *муң* «михнәт, кайгы, уй, хәсрәт, акыл» сүзеннән.

**МОНДЫЙ** «такой, подобный этому» — бор. тк. *бун-дай, бу-н-даг* «бу (моның) кебек» сүзеннән; чаг. якут. *манныҕ* «мондый» (*ман* ~ тат. *моң*).

**МОРАТ** «желание, цель» — гар. *мурад-ун* «морат» сүзеннән, *рада* «әзләү, өйрәнү» тамырыннан, шуннан ук *мөрит* «өйрәнүче, өйрәнчек, шәкерт».

**МОРҖА** «труба» — гом. көнб. тк. *мурҗа, мури* «морҗа; мичтәге төтен юлы», фарсы. *мурича* «морҗа, төтен юлы, төрле торбалар» (*мури* «водопровод торбасы») сүзеннән, бу сүз исә гар. *мәррә* «үтү, агып үтү» тамырыннан булса кирәк; к. тат. диал., башк. *мөрилә, мөридә* «морҗалы мич (ак өй мичe)», *мәмер, мәмерйә* «тау тишеге», *мира, мийәрә* «морҗа», рус. диал. *мурья* «морҗа», чув. *мăрйе* «төтен юлы», *мăриле* «морҗа», бор. тк., чыгт. *мури* «улак, су торбасы, мич торбасы». Чаг. монг. *бурича* «морҗа» — турыдан-туры фарсы теленнән. К. Әхмәтьянов, 1989:137—138.

**МОРЗА** «мурза; дворянин» — гом. көнб. тк. *мирза* «морза», фарсы. *мирзад* < *әмир-задә* «әмир затыннан» дигән сүз.

Татар телендә *мирза*, гади сөйләмдә *мырза* һәм (ирен-ирен тартыгы м — тәэсирендә) *мӧрза* булып әверелгән; һәм русча язмаларда XV гасырдан бирле *мырза* һәм *мурза* дип языла. Ләкин императрица Екатерина II 1773 һәм 1783 елгы карарлары буенча Казан ханлыгындагы мирзалар токымына дворянлык хокукы бирелә башлагач, татарча документларда *мирза* дип язылган. Берара *мирза* «укымышлы кеше; писер», ә *морза* «асылзат, дворян» булып китә, ягъни бу сүзләр мәгънә җәһәтеннән аерымлана. Кайбер башкорт сөйләшләрендә *мырзам* «каениш; иреңнең энесе; кечеләргә эндәшү сүзе».

К.Р.Х а й р у т д и н о в. Татарская феодальная знать и Российское дворянство (Ислам в татарском мире. К. 1997: 83—101. Ф.И с л а е в. Чабаталы морзаллар). «Идел», №20—23.

**МӨГАЕН** «наверно; вероятно» — < гар. *мугаййан* «билгеле ки; күренеп тора».

**МӨГЕЗ** «рог» — гом. тк. *мүгүз, мӧңүз* «мөгез» — бор. гом. тк. **мүңүр // *бӧңүрь* «мөгез, кимерчәк» тамырыннан (Рясянен); к. госм. *бойнуз*, чыгт. *буңуз* «мөгез» һ.б. ~ чув. *мыйрга, мăйрака* «мөгез», монг. *мӧрге* «мөгез», *мӧрэң* «кимерчәк», самодий телләрендә *мӧкӧр* «мөгез».

**МӨЕШ** «внутренний угол» — тат. диал. *мөгөш*, себ. тат. *мүәшә*, бор. тк. *мүңүш* id. — гомумән шактый кин таралган сүз — бор. тк., монг. *bulun* (к. **Болын**) «бөгелеш, почмак» белән чагыштырыла. Чаг. ш. ук якут. *муңнук* «почмак, мөеш». Ләкин себ. тат. *мөйәш, мүгәшә* формалары фарсы. (псевдогар.) *мүгүшэ* (*гушэ* «почмак») «һәртөрле чыгынты һәм почмаклар» сүзенә ишарә итә.

**МӨҖӘЛ** «двенадцатилетний цикл» — к. кырг., кк. *мүчол, мүшәл*, тат. *булҗәл* «срок», кырг., гом. тк. *бӧлҗәл, болҗар* «срок», монг. *болҗар, болҗагар* «срок, билгеләнгән урын, гаскәрнең җыелу урыны», кырг. *мүчо-*, монг. *болҗа-* «аныклау, төгәлләү, мөҗәлгә җитү» гом. тк., монг. *бол-* «булу» тамырыннан (Рамстедт). Бу сүз төрки телләрдә бик актив кулланылган; к. ш. ук кк., кырг. *мөлшер, молчар* «чама, үлчәм, срок», бор. тат. *мурчил* «гаскәри тәртип».

**МӨФ:** мөф бәя «бросовая цена, демпинг» — фарсы. *муфт* «бушлай. тиген».

**МӨЧӘ** «часть тела» — гом. тк. *мүчэ, мүшэ, мӧчү* «әгъза, мөчә». Борынгы йола буенча аучының үз табышының бер өлешен беренче очраган кешегә бирү. К. **Оча**.

**МӨШКЕЛ** «трудность; затруднительный» — гар. *мушкил-* «мөшкел» сүзеннән, *шăкалă* «шикле, буталчык булу» тамырыннан.

**МУЕЛ** «черемуха» — бор. тк. сүз, ясалышы ачык түгел; к. башк. *муйыл*, кк. *мойыл* «муел», якут. *мойнйозон, мойногон* «безкойрык (*урдәкнең бер төре*); карлыган», бурят. *мойһон* «шомырт; карлыган». Чаг. ш. ук чув., тат. диал. *мыйыр*, кб. *маяр* «чикләвек».

**МУЕН** «шея» — гом. тк. *бойун // мойун* «муен; буй озынлыгы» сүзеннән, гом. тк. *бой* «буй, гәүдә» нигезеннән (*бой-ун*) дип хисапланыла; к. чув. *мăй, муй,* госм. *бой*, якут. *мой* «муен», үзб. *буйин, бойын* «муен; сөрелә торган җир озынлыгы (буе)»; чаг. ш. ук эвенк. *мойе, моңон*, маньчж. *монгон*, удэгей. *моңоли*, орок. *муйрэ* «муен, иңсә». К. **Буйсын-у**.

**МУЛ** «обильный» — чыгышы ачык түгел; к. азәрб., госм. *бол* «зур, киң, мул», чыгт., тк. *бол* «батыр».

**МУЛЛА** «мулла» — Урта Азия (үзб., таж.) телләрендәге *мулла* сүзеннән, гар. *мәула* «күп укыган, күкрәге гыйлем белән тулы» сүзеннән килә дип санала.

**МУНЧА** «баня» — бор. рус. *мовьница* «юына торган урын, мунча» (*мовь* «юыну») сүзеннән; к. тат. диал. *муйынца, мунича*, чув. *мулча, молча*, мар., удм. *момоца* «мунча». Башка төрки телләрдә татарчадан. К. Әхмәтьянов, 1989: 138—139.

**МУНЧАЛА** «мочало» — рус теленнән. Русча шартлаулы *-ч(тч)* — татар телендә *-нч-* булып әверелгән; башк. *мунсала, мӧнсала*, чув., мар. *мончала* татар теленнән булса кирәк. Тамыры — русча *мок* (*мокнуть, мочить* һ.б.).

**МУРДА** «морда (*рыболовная снасть*)» — рус теленнән, рус теленә исә фин-угор теленнән кергән; к. чув. *мурда, морда, мурада*, рус. *морда, мереда, нерета* (тат. диал. *нәрәтә*), удм. *мерда*, мор. *мерата, нерота*, мар. *мурда, мурза* «мурда».

**МУРТ** «прогнивший; трухлявый (*о дереве*) — гом. тк. *морт* id. сүзеннән; к. тат. диал. *муртык*, чув. *мăртăк, мăртăх,* алт. (телеут.) *портың* «мурт, тиз тузучан», хакас. *порт*, алт. *борт(ың)* «мурт»;

к. шор. *порд-* «зәгыйфьләнү; картаю»; тат. диал. муры- < бор. тк. **мору-* «черү» (димәк, *мурт* < *мор-ыт* һәм *порд* < *бор-ы-т*). Чаг. **Борчы-у**.

**МУТ** «шельма; плутоватый» — тат., башк., чув. *мут* «мут, хәйләкәр», рус. *мот* «акча туздыручы байбәтчә» сүзеннән.

**МҮК** «мох» — рус теленнән.

**МҮКЛӘК** «комолый; безрогий» — гом. тк., гом. монг. *мок // мөк* «очлы булмаган чыгынты, тупыйк оч, үтмәс без» сүзеннән (шул ук тамырдан к. **Мокыт**); к. чув. *мока, мука* «үтмәс, тупа», *мокка, мӑкла* «мүкләк», *мӑклак* «тупак очлы», *мӑкӑл* «оры, чыгынты (*мәсәлән,* мөгез чыгасы төштә)», якут. *муҕуруса* «мүкләк», *мүгүр, муңур* «тупыйк оч», бурят. *мухар* «мүкләк», *муха-муха* «мүкләк баш белән айкау турында», *мохоо* «үтмәс, мокыт», *могсо* «китеп алу, очны үтмәсләү», эвен. *мукты, моңты* «мүкләк». Рус. диал. *моклокъ* «чыгып торган сөяк», коми. *моклок*, удм. *моклок, мучло* «мүкләк, чыгынты, оры» (төрки телләрдән?). Чаг. ш. ук чув. *муклака, муклашка* «оры, чыгынты, түгәрәк кисәк, киселгән төп», тат. диал. *муклашка* «йодрык».

**МҮКӘЙ-, МҮКӘЙЛӘ-Ү** «стоять или ходить на четвереньках» — диал. *бүкәй-, бүкәйлә-* id. ~ алт. *бөкөй-, пүкей-,* якут. *бөкөй-, бүгүй-,* бор. монг. *bökey-* «иелү, тункаю, чүгәләү» гомумалт. *бөк, бүк* «бөк, бөкре, бөкреле» тамырыннан (*бөк-эй-*). Чаг. тат. диал. *бөкчә* «иенке, бөкрәйгән», *бөкчәй-ү* «бөкрәеп төшү». К. **Букча, Бүксә**.

**МҮН** *диал.* (себ. тат.) «большой, великий» — чув. *мӑн, мун* < **мөн, мун* ~ мар. *мын, мӱн* «зур, олы, олпат» — бор. тк. *мун, муң* «зур акча, капитал» сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

**МЫЕК** «усы, усики (*у насекомых*)» — гом. кыпчак. *мыйык, быйык,* бор. тк. *бытык, бутук* «мыек, сакал» — бор. тк. *бут* ~ фарсы. *муй, муд* «төк» сүзеннән.

**МЫЛТЫК** «ружье» — гом. тк. *мултук, мылтык* «филтә белән кабызыла торган борынгы мылтык» көнч. тк. *милтә, мылта* «филтә, мылтык филтәсе» сүзеннән (бу сүз исә гарәп теленнән; к. **Филтә**); к. телеут. *мулта, мылта* «мылтык филтәсе» ~ тат. диал. (себ. тат.) кк. *милтә* «филтә», монг. *билта* «мылтык» (Йоки). К. Әмәтьянов, 1989:151.

**МЫСКАЛ** «золотник» (4,68 грамма)» — гар. *мискал-ун* «мыскал» сүзеннән, *сакәлә* «үлчәү, авыр булу» тамырыннан.

**МЫСКЫЛ** «издевательство» — гар. *мәсхар-ун* «мыскыллау, мәсхәрә, авыр тәэсир итү, жанга тию» сүзеннән булса кирәк, көнб. төрки телләрдән киң таралган сүз: чув. *мӑшкӑл,* кырг., кк., ккк. *мыскыл,* башк. *мыҫҡыл* «мыскыл». К. **Мәсхәрә**.

**МЫШТЫМ** «тихий; тихоня» — башк. *мөштөм,* чув. *пӑштӑм* «мыштым кеше, пассив; кая кусалар, шунда баручы». Әдәби язма телебездәге *муштум* «күсәк» сүзеннән: «күсәк > ангыра, надан» мәгънә күчеше типологик характерга ия; к. фарсыча *муштум* «йодрык, күсәк». Чаг. **Хартум**.

**МЫШЬЯК** «мышьяк» — рус теленнән дип санала, киресенчә дә булырга мөмкин, һәрхәлдә, йә рус. *мышь,* йә фарсы. *муш* «тычкан» сүзеннән. Татар сөйләшләрендә *мышайак* диелә.



# -Н-

**НАБАТ** «набат» — рус. *набат* сүзеннән, бу сүз исә госманлы төрек теле аркылы гарәп теленнән кергән. К.**Нәүбәт**.

**НАДАН** «неграмотный; бездарный» — фарсы. *надан* «надан, ахмак» сүзеннән (*на-* юклык префиксы — рус. *не, дан* исә *данистан* «белү, акыллы булу» фигыленең нигезе).

**НАҖАГАЙ** «зарница» — тат. диал., каз. *найзагай* — кк., чыгт. һ.б. *найза* > тат. *нәйзә* «кыска сөңге; сәгать угы» сүзеннән; к. каз. диал. *нәйзагай* «яшен, яшен чаткысы».

Бу сүзнең *аҗаган, җайнагай, җалагай* һ.б. вариантлары да бар.

**НАЗ** «нега, ласка» — фарсы. *наз* «наз, нечкәлек» сүзеннән. К. **Нәзек**.

**НАКЫС** *диал.* «недостаточный; недостаточно, скупо» — гар. *накыйс* «ким, кыска» сүзеннән; шул ук тамырдан *ноксан* «кимлек, житешсезлек».

**НАМАЗ** «намаз, молитва» — фарсы. *намаз* «намаз» сүзеннән; к. бор. фарсы. *namazh* < авеста. *nemanh* (*неманh*) «намаз; баш иеп сәламләү». Намаз гамәле ислам диненә ирани халыклардан кергән.

**НАМӘ** «письмо; письменный документ» — фарсы. *намә* «хат; язу» сүзеннән. К. **Намус**.

**НАМУС** «честь, совесть» — чув., мар., удм. *намус, намыс-,* фарсы. *намус-* грек. *номос* «закон, йола» (беренчел борынгы мәгънәсендә «гадел бүлеп бирелгән көтүлек жире») сүзеннән, гарәп теле аркылы татар әдәби телендә (һәм барлык көнб. тк. телләрдә) урнашкан. Бор. рус. *номось* «закон», бор. тк., көнч. тк. монг., согд. *ном* «законнар китабы» грек теленең үзеннән Искәндәр Зөлкарнәйн чорында таралган сүзләр.

**НАРАСЫЙ** «младенец» — гом. көнб. тк. *нараси, нарасида* > чув. *нараста,* мар. *нӓрӓштӓ* «сабый, нарасый», фарсы-тадж. *нарасида* «житлекмәгән, өлгермәгән» (*на-* юклык префиксы — рус. *не, расида* «житкән, өлгергән») сүзеннән.

**НАРАТ** «сосна» — монг. теленнән булса кирәк; тат. чув., башк., кб., кум., н. *нарат,* якут. *нурат* «нарат, чыршы» күпчелек төрки телләргә билгеле түгел, аның каравы монгол телләрендә киң таралган. К. бурят. *нархум, нарассун, нарахунь,* монг. *нарас-сун, нара-т-сун* «нарат, чыршы». Чаг. монг. *нара-н* «кояш; алсу, кызыл».

**НАРДУГАН** «святки, святочные игры» — тат. диал. *нардуан,* чув., мар., морд. *нардыван, нартуган, нардава* «нардуган». Бор. *нар, нард* «шакмак, кубик атып уйнау һәм күрәзәләү» (асылда, фарсы сүзе, төрки-монгол халыкларына да таратылган) һәм *фал* сүзләреннән; к. төрек сөйләшләрендә *мартуфал, мартавал, мантувар* «нардуган; бер чәчәк исеме; әкият» очрый. Нардуган бәйрәме (чиллә башы) фарсыларның «елның соңгы чәршәмбесе» бәйрәменнән күчерелгән. (K. Çay A. M. Nevruz. Istambul, 1993.) К. Әхмәтьянов, 1981: 61—66.

Нардуган тәүдә җәйге чиллә башында (25 июнь — 5 июль) уздырылган һәм *аяу көннәре, аяу атнасы* дип тә аталган. Җәйге нардуган руслардагы *русалия, троицын* бәйрәмнәренә охшаш булган. Ләкин җәйге нардуган ~ аяу бәйрәме тормыш шартлары начарланган гасырларда онытылган. Кышкы нардуган Казан дәүләтендә ярминкә вакытында бәйрәм ителгән һәм ярминкәгә килгән бүтән халык әһелләре аша күршеләргә таралган.

**НАХАК** «напрасно; несправедливо» — ~ чув. *нехек-* фарсы. *нахакк* «хак түгел» сүзеннән.

**НАЧАР** «плохо, неважно; плохой; неважный» — чув., мар., удм. *начар*, башк. *насар*, башк. диал. *нәсәр*, мар. диал. *нәзәр* (палаталь вариантлар болгар теленнән булса кирәк) — фарсы. *начар* «чарасыз» сүзеннән.

**НАШМАК** «покрывало невесты» — чув., мар. *нашмак, насмак, масмак,* хакас. *наспах*, бор. тк. (> кар., ткм.) *йашмак* «вуаль, пәрдә, зур яулык» сүзеннән ([*й* > *н*] күчеше бер төркем сүзләрдә күзәтелә; к. **Наян, Ни, Нирге**). Тамыры — гом. тк. *йаш-* «яшерену, качу» К. **Яшеру**.

**НАЯН** «лукавый, хитрый» — чув., мар., морд., рус., коми. *наян* id., якут. *найан* «бәйләнчек», тат. диал. *наянла-у* «кыланчыклану», алт. диал. *найан*, алт. *й'айан, дьайан,* монг. *җайан, дзайан,* бурят. *зайан* «үз үлеме белән үлмәгәннәрнең тынычсыз рухы, өрәге» сүзеннән (бу рухлар турында Көньяк Себер һәм Монголия халыкларында бик күп риваятьләр бар).

Төп төрки вариант *җайаган* < *йайаган* булган; бу сүз *-аган // -әгән* кушымчасы ялганып (чаг. тат. *качаган* «кача торган», *тибәгән* «тибә торган») борынгы *йай-* «корбан булу; корбан итү; шәһит булу, шәһит итү» фигыленнән ясалган. Шунысы кызык, шул ук фигыль борынгы һиндстан телләрендә дә булган: бу факт төркиләрнең төп ватаны шунда булмадымы икән дигән фаразга китерә.

**НӘБИРӘ** «внучка» — бу сүз күп кенә татар сөйләшләрендә очрый: Әстерханда *нәвәрә, нәүбәрә, нәбирә,* Себердә *нәбәрә, нәүәрә,* башк. диал. *нимәрә* гарәп теленнән (*Нәбирә* исеме дә шуннан).

**НӘГӘР** «дружки жениха; *ист.* дружинник» — тат. диал. *нөгәр, нүгәр,* чув. *нӗкер,* кар. *нәгәр,* кб., кум. *негер* «нәгәр, хәрби дус, кучты» монг. *ногур* id. сүзеннән күп телләргә таралган.

**НӘЗЕК** «тонкий» — гом. кыпчак. *нәзук* «тәкәллефле, ыспай, сылу» фарсы-таҗ. *назук* «назлы, нечкә» сүзеннән.

Тат. *нәзберек* «төрләнчек, назланучан» сүзе дә фарсы. *назуварак* «назланучан, сырланучан» сүзеннән.

*Нәзек* һәм *нечкә* сүзләрендә абстрактлыктан конкрет мәгънәгә күчү күзәтелә.

**НӘЙЗӘ** «небольшое копье; стрелка часов» — гом. кыпчак. *найза, нәйзә* id. фарсы теленнән булса кирәк.

**НӘКӘС** «неблагородный; неповоротливый» — чув. *накас, нахас, неккес,* мар., удм. *накас* («ленивый, развратный» дип тә бирелә). Фарсы. *накәс* «кеше түгел» сүзеннән.

**НӘК** «точно; именно» — чыгышы ачык түгел; к. кк., кырг. *нак, накай* «нәкъ, нәкъ үзе»; ихтимал, фарсы-таҗ. *наһ, нәһах* «шул үзе, нәкъ» сүзеннәндер (ләкин бу сүз фарсы телендә дә, таҗик телендә дә актив түгел).



**НӘЛӘТ** «проклятие» — әд. *ләгънәт*, гар. *ләғн-әт-ун* «ләгънәт, нәләт, каргыш» сүзеннән (гар. *ләғәнә* «каргау» тамырыннан); шуннан ук бор. әд. *ләгыйнь* «ләгънәтләнгән», *мәлгунь* «ләгънәтләнерлек»; к. диал. *нәғләт, нәғәләт* «нәләт, ләгънәт», *нәғләт* ~ *ләгънәт* күчеше бер татар теленә генә хас түгел; к. фарсы-таҗ. *наләт, нә'аләт, лә'анәт* «нәләт».

**НӘНӘЙ** «бабушка, мать отца моей матери» — балалар телендә барлык халыкларга уртак булган сүз (*ба, па, ма, на* иҗекләренең кабатлануы яки сүз башындагы *а- // ә-* авазыннан соң килүе буенча ясалган сүз; к. госм., кырым. *нәнә* «нәнәй, әни», үзб., таҗ. *нанай* «әби, нәнәй». Төрки булмаган телләрдә: удм. *нәнә*, грузин. *нана* «әни». Чаг. **Нәни**.

**НӘНИ** «маленький, крохотный; малыш» — диал. *нанай, наный* id. балалар телендә типологик модель буенча (к. **Нәнәй**) ясалган; чаг. чув. *нани, нене* «нәни бала, сөйкемле, нәни», удм. *ненеге* «нәни, чирләшкә». Чаг. ш. ук бор. тк. *jeniq* «нәни», **jen* «кечкенә». К. **Җиңел**.

**НӘРЕН** «ряска; *диал.* суп с зеленью» — себ. тат., кырг., кк., үзб., азәрб. һ.б. *нарын, нарин* «яшелчәле итле аш» фарсы. *нарин* «яшь җимеш» сүзеннән булса кирәк (суда куерып үскән нәрен яшелчәле ашка охшатылган). К. **Нарын**.

**НӘРКИС** «нарцисс» — фарсы. *наргиз, наркәс,* гар. *наркас-ун* «нарцисс» сүзеннән (беренчел чыганагы — грек теле).

**НӘРСӘ** *мест. вопр.* «что» — бор. тк., чыгт. *нә ирсә, нә әрсә, нәң әрсә* «ни булса (шул)» сүзеннән (к. **Ни** һәм **И-**); к. тат. диал. *ниәрсә* > *ниәссә, ни әстә* > *нәстә* «нәрсә, ни», *нәмәрсә* «нәрсәдер (игътибарсызлык яки кимсетү аһәңе белән)» <<**нәңәрсә*; чаг. ш. ук бор. әд. *кемсә* «кемдер бирәү» < бор. әд. *кем ирсә, кем әрсә* «кем булса (шул)»; госм., иск. тат. әд. *нәснә* «нәрсә».

**НӘСЕЛ** «потомок; род» — гар. *нәсл-ун* «нәсел» сүзеннән.

**НӘҮБӘТ** «очередь; отпуск» — гар. *нәубәт-ун* «чират, кизү, дежурлык, вакыт-вакыт килә торган бәла, авыру (чаг. тат. диал. *кизү* «чират; эпидемия»)», дежурга чакырып яки каравыл торуны белдереп музыка коралларында уйнау яки барабан кагу (шуннан ук *набат*) сүзеннән *набә* «өлеш туры килү, язмышка (чиратка) очрау, урынбасар булу» тамырыннан (шуннан ук әд. *наиб* «урынбасар, наместник»).

**НЕЧКӘ** «тонкий, деликатный» — гом. тк. *иңичкә, йиничкә,* ккк. *җиңичке* >> болгар. **җиңиҗә* > чув. *çиңçе*, мар. *синзя* «нечкә»; мар. *нечкы, нӹжга* «иркә, чирләшкә» татар теленнән; *ничкә* варианты кыпчак телләрендә, *нескә* хакас телендә дә бар.

Барлык төрки телләрдә булган бу сүзнең этимологиясе авыр, ихтимал, ул уйг. *йинчкә* (кытайчадан булса кирәк) «Конфуций тәгълиматы» сүзеннәндер.

**НИ, НӘ** *мест. вопр.* «что» — гом. тк. *нәң, нән* < бор. тк. **йәң* > тув. *чә, чү* «ни, нәрсә» (*чүге, чиге* «нигә», *чеже* «ничә» якут. *си*

«ни»; бу сүзләр [*й > н*] күчешенең борынгылыгына мисал була ала (К. Ахметьянов Р. Г. Об особенностях этимологии служебных слов // Проблемы этимологии тюркских языков. — Алма-Ата, 1990:76—81).

**НИГЕЗ** «фундамент; основа, базис» — бор. кыпч., чув. **нигер, *нэгир'* «нигез, төп, рәт, тәртип» сүзеннән, **йэгиргъ* вариантыннан булса кирәк (**к. Ниргә, Эргә**); к. чув. *никĕс*, уйг., үзб., кырг., кк., ккк., н. һ.б. *негиз* «нигез».

**НИРГӘ** «венец сруба» — чув. *нирке*, башк. *нергә* «ниргә, бура, нигез» бор. тк. *нәгир-рә* «рәт; тәртип; рәтләп салынган нәрсә» сүзеннән; к. тат. диал. *нергә, ниргә* «ниргә, нигез, рәт, йола, йола буенча бирелә торган бүләк», *сүз ниргәсе* «сүз тәртибе», *эргә, өргә* «нигез, фундамент (мишәр.); рәт, кырый, ян, күрше» ~ чув., мар., удм. *нерге, ниркэ, ниргэ* «ниргә, рәт, рәтле бизәк», *йөркэ, йәркә* «рәт, кагыйдә; гадәт, йола, ниргә, юл, сәбәп» (бу нигезнең ерак фин һәм эстон телләрендә охшаш параллельләре бар); к. кар. *йәркә* «рәт; нур». Бу сүзне Радлов, гом. тк. *йәр* «җир, урын; бик тә; мәртәбә» сүзеннән, ди.

К. ш. ук бор. тат. *җәргә* < уйг. *җәргә, йәргә* «хәрби тезем, строй, рәт» > чув. *çерке* «арата, рәт»; һәрхәлдә, *нигез* белән *нәргә ~ йәргә*нең бәйләнеше бәхәссез; *нигез* формасы исә бор. *нәгиргә, нәгерә, нәргә* формаларыннан килеп чыга ала. К. Әхмәтьянов, 1981:89.

**НОГЫТ** «бобы» — уйг. диал. *нокут*, госм. *нохуд*, бор. чыгт. *нохуд* «ногыт» фарсы. *нохуд, нохут* «борчак, ногыт» сүзеннән хисаплана; чаг. бор. рус. *нохоть* «борчак»; элегрәк ногыт борчагы белән күрәзәләү киң таралган булган, шуннан чув. *нухăт* «күрәзәләү», коми., мар. *ногыт* «күрәзәләү өчен вак шакмаклар».

**НОКРАТ** «серебряная монета; река Вятка» — чув. *нухрат, нăхрат* ~ үзб. *нуқра* «көмеш акча» — гар. *накәр* «көмеш» сүзеннән. Нократ буйларында кайчандыр «көмеш болгарлар» кавеме яшәгән, диләр.

**НОКТА** «точка» — фарсы. *нукта, нуктә* «нокта, тап» сүзеннән, асылда, гарәп теленнән (гар. *нукта-т-ун* «нокта; пост; очко», *наката* «нокта кую; чәчрәтү, таплау»). К. **Нөктә**.

**НӨКТӘ** «недомолвка; затаенный смысл, намёк» — гар. *нуктә* «тапкыр сүз; ирония; тел төере, төерле тел (күп мәгъ.) сүзеннән, *нокта* белән тамырдаш түгел, ләкин ул сүз белән контаминациягә кергән.

**НУКТА** «недоуздок» — мар. *нукта*, удм. *нюкто*, чув. *нăхта*, морд. *новта*, манси. *нохта* < гом. тк. *ногта*, монг. *ногт, ноңту* «нукта», эвен. *нёг* һ.б., кытай. *луңту* «йөгән, нукта» сүзеннән таралган.

**НЫК** «крепко; крепкий; *диал.* туго, тугой; частый» — чув. *нăх*, удм. *ныгыт* «нык, ныклы», мар. *нык* «көчле», монг. *ниг, нях* «ныклы»; охшаш тамырлар нивх һәм бор. ирани телләрдә дә бар.

Тат. диал. *ныкта-* «тыгызлау», *ныкы-* «кат-кат әйтү», *ныкыш-* «үз дигәнендә нык тору» сүзләренең параллельләре Себер төрки телләрендә очрый; *ныгы-* фигыле татар-башкорт телләрендә генә.



# -О-

**ОЕК** «чулок, носок» — чув. *йăлăх, ала*, кк., чыгт., бор. тк. *уйуқ* «оек», кайбер телләрдә «киез оек, пима» ~ бор. тк. *уйуқ* «киез оек», *уй-* «киезсыман әйбер басу, шуны бизәү» ~ себ. тат. *уйучигү*», тув., якут. *уй-* «берләштереп тегү» сүзеннән. Чаг. **Ою**.

**ОҖМАХ** «рай» — чув. *аçмах*, мар. *узьмак*, удм. *узмак*, гом. тк. *уҗмак, учмах* «оҗмах»; бу сүзнең борынгырак вариантлары Идел буенда сакланган: тат. диал. *җомак, очтомак*, чув. *çăтмах, çатмалăх, ăстăмах* — бор. чыгт. *уштимах* сугди. (согд.) wštmx «оҗмах» сүзеннән булса кирәк, ләкин *сугди* сүзе үзе бор. тк. *уҗалтмаг* «биеклек, биек урын» (*уҗа* «биек») сүзеннән булырга мөмкин.

**ОЗАК** «долго, долгий» — гом. кыпчак *узак* < *уз-ак*. Сүзнең тамыры *оз-* «длина, рост» шул көенчә сакланмаган диярлек, тик гагауз һәм хакас телләрендә *аның узы* «аның буе, озынлыгы» дип сөйлиләр. Әмма татар телендә һәм диалектларында бу тамыр ачык күренә: *көнозын* «көн буена» (*оз-* тамырыннан инструменталь килеш), *оза-, озай-* «оз булу», *киндергә җеп озату* «сузу», *озак* < гом тк. *узак* «ерак». К. **Озын**.

Чув. *вăрăм* «озын», *вăрах* «озак» һәм монг. *урту* «озын» сүзләренә караганда, сүзнең борынгы тамыры **ургъ* булган.

**ОЗАН** «тетерев» — чув. *ăсан*, башк. *ӧзан*, иске тат. *усан* «ата көртлек» төрек һ.б. угыз телләрендәге *узан* «җырчы, шигырьче» (бор. тк. *ўз-* «мактап җырлау») сүзе белән бердәй булса кирәк.

**ОЗЫН** «долгий, длинный, высокий» — гом. тк. *узун* «озын, озынлык; буй», гагауз., бор. тк. *уз* << **ургъ* «буй» тамырыннан; к. чув. *вăрăм* << **ургын* «озын». К. **Озак**.

**ОЙЫ-У** «свернуться (*о молоке*); задремать; онеметь» — бу тамырда бер яисә ике сүзме иканлеген әйтү кыен; гом. *уйы-* «ою, оешу, охшашлану, беришле булып киту» бор. тк. *уйу-* ~ *уду-* «йоклау» мәгънә җәһәтеннән дә, фонетик яктан да бер. Бор. *ойы-у* «бергә берләшү» мәгънәсенә дә ия булган: бу нәтиҗә *оерша (ойорша)* «укмашкан нәрсә, төер» һәм *оеш-у (ойош-у)* сүзләреннән чыга. Төрек., чыгт., кк. *уй-* «ярашу» сүзе дә шул нигездән булса кирәк.

**ОЛАГУ** «пропасть бесследно; исчезать» — татар-башкорт даирәсеннән тыш тик үзбәк сөйләшләрендә теркәлгән (*улақмак*); тамырдаш сүзләр: кк. *лак-* «арттыру», кум. *улагыв* «азыну», хак. *ула-*, алт. *уула-*, тув. *угла-* «юнәлтү, бармак төртеп күрсәтү» ~ монг. *ууғла-, ағула-* id.; *ағу* «ерак» > тув. *уғ* id. К. **Олау**.

**ОЛАН** «ребенок; сын; дочь; расплод (*пчел*)» — гом. кыпчак. *улан* «олан, өйләнмәгән егет» — бор. тат. [*ō>у*] *оглан, углан* «асылзат егет, гвардия солдаты» сүзеннән; бу сүз төрек һәм Европа телләренә дә күчеп, француз, немец телләре аша рус теленә дә кергән: *улан* «атлы гаскәринең бер төре», бор. тк. *оғлан* «углан, олан» *оғул* «угыл» сүзеннән; чаг. *ирән* < *эрән* < *эр-ән*.

Татар-башкорт сөйләшләрендәге *олан, ылан* — сабый балаларга, бигрәк тә малайларга, эндәшү сүзе «булачак батыр егет» мәгънәсендә булып чыга. Чаг. **Апай**.

**ОЛАУ** «обоз; подвода» — чув. *ăлав*, мар. *ула* «олау», венг. *ló* «ат», гом.тк. *улау ~ улаҕ*, бор. тк., монг. *улага* «олау, почта, курьер», тат. диал. *ола-*, гом. тк. *ула-* «тоташу, ялгау, юнәлтү» тув., бор. тк. *уҕла-*, тув. *уҕ* «ераклык», ерак юл» сүзеннән. *Олау* сүзе турында әдәбият шактый зур.

**Олау** сүзеннән рус (казак) сөйләшләрендәге *лава* «гаскәри колонна, атака ясаучы колонна, *күч*, тоташ агым» сүзе килеп чыккан. Чаг. ш.ук тат. диал. *олашу* «бер-берсенә ялгану, терәлеп тору», *олаштыру* «ялгау, теркәү, теркәтү».

**ОЛПАТ** «солидный; серьезный» — бу сүз, беренче карашта, *олы* сүзенә ниндидер *-пат* кушымчасы ялганып ясалган кебек булса да, чынлыкта кк., ккк., кырг. *улпат*, үзб. диал., уйг. *улпәт* «җитди әңгәмә, дусларча сөйләшү, дуслык» < гар. *улфәт* > тат. *өлфәт* «дуслык, әңгәмәдәшлек» сүзеннән килсә кирәк; к. башк. *олпатты* < *олпатлы* «җитди әңгәмәдәш булырлык, өлфәтле».

**ОЛТАН** «подошва обуви» (*олтырак* «стелька») — төрки, монгол, тунгус телләрендә киң таралган сүзләр: көнч. тк. *улт* «табанча, табанлык» нигезеннән ясалган; *олтан* < *улт-а-н* (*улта-* «олтан салу»), *олтырак* < *олтарык* исә тат. диал. *олтару*, гом. тк. *ултар-* «олтанлы итү (булу)» дигәннән. Мар. *утрак*, удм. *ултырак* татарчадан.

**ОЛЫ** «старший; большой» (*олуҕ* «великий») — гом. кыпчак. *улу, уллу,* гом. тк. *улуг, уллуг* «олы, зур» сүзе бор. тк. һәм бор. монг. *ул* «дәрәҗәле кешеләр утырган махсус ястык» сүзеннән килә (*ул* тамырыннан тагы күп кенә сүзләр ясалган), ягъни *улда утыручы (утырырлык)* дигән сүз.

*Олы* сүзе тат. *олыс* «дәүләт, ил» төптә «югары совет» мәгънәсен белдерә; бор. *улус* < *уллу ус* дигәндә *уллу, улда утыручы, ус* борынгыча «акыл, киңәш» (тат. *истә-оста* дигән сүз барлыкка килгән). Кк. *улу кун*, тат. диал. *оло көн*, чув. *ман кун*, мар. *мун күн* (бор. тк. мүн «зур»), удм. *бадзым нунал*, морд. *ине чи, оцю ши* — барлык бу телләрдә «зур көн» Пасха бәйрәмен белдерә.

**ОМСЫН-У** «соблазняться *чем-л.*» — гом. тк. *умсун-, умсан-* «омсыну, теләү», бор. тк. *ум-са-* «теләү, теләктә тору» һәм монг. *ам-са-* «тәмен тату, татырга теләү» фигыльләренең контаминациясеннән; к. алт., якут., монг., маньчж. *амтан* «тәм», якут. *амсай-, амтан-*, монг. *амса-х* «татып карау», алт. *амза-* «татып карау»; чаг. ш. ук кк. *аң-са* «теләү, сусау». Гом. тк. *ум-та-* «теләү» турында. К. **Омтыл-у**.

**ОМТЫЛ-У** «стремиться» — кк., ккк. *умтул-*, үзб. *интил-*, тат. диал. *ынтыл-* «омтылу, нык теләү» — бор. тк. *умут-* «өметләндерү» фигыленең (бор. тк., төрек. *ум-* «өмет итү, көтү, теләү» сүзеннән, төшем юнәлеше формасы булса кирәк; к. уйг., госм. *умыт-* «өметләндерү, омсындыру», *умун-* «өметләнү»).

**ОН** «мука» — гом. тк. *ун, уун,* ткм. *увын* «он», ихтимал, *у-у* фигыленнән ясалгандыр; к. тат. *ӧнты* «он, тузан» < *увынты* (?). Чув. *ҫăнăх* < *җӧнӧҡ* < *йӧнӧҡ* [*о*] авазы алдыннан протетик [*й*] килеп чыкканнан барлыкка килгән вариант.



*Он* тамырыннан татар телендә тагын *онта, онтак, онтау* сүзләре дә ясалган һәм *онаш, ончыл* кебек неологизмнар бар.

**ОНЫК** «внук» — рус теленнән булса да, төптә төрки сүз булса кирәк; к. мишәр. диал. *нук, нука* «онык, онык кыз» (чаг. мишәр. диал. *тудык-, тудыка;* огуз. *чочук-, чочука* «ир бала, кыз бала»), тув. *унук* «яшь буын», ткм. *овнук* «өлеш», монг. *нуган, унуг*, тунгус. *нуку, нэкун* «онык».

**ОНЫТУ** «забыть» — гом. кыпчак. *унут-*, гом. тк. *умут-* бор. тк. *умунт-* нигезеннән; сүзнең тамыры — бор. гом. тк. *ом-, ум-* (тунгус. *оммо-*) «оныту»; мар. *мунт-* «оныту» ~ тат. диал. *мыт-* id. чув. **ман-* << *ӑман-* «оныту» бор. бер төрки чыганактан.

**ОРАН** «боевой клич, призыв к походу» — башк. *оран*, алт., кк., чыгт., бор. тк. *'ран, уран* «оран, пароль». Чаг. калм. *ориго*, монг. *оруңго*, тибет. *rongo* «байрак, флаг». Рамстедт фикеренчә, рус. *хоругвь* «байрак, флаг» сүзе дә бор. тк. *һоруңго, оруңго* «байрак» сүзеннән. К. **Өленге**.

**ОРЛЫК** «семя» — бор. тк. *уруҕ-лык* «орлык, ыруга калдырылган нәрсә» (МК) сүзеннән (*уруҕ* «ыру, нәсел» нигезеннән); к. чув. *вăрă* «орлык, ыру», *вăрăлăк* «орлык, нәсел, зат» (к. **Ыру**). К. ш. ук диал. *оргачы* «нәселгә калдырылган хайван». К. **Үрге-, Үрче-**.

**ОР-У** «ударять, ударить» — гом. тк. *ур-* < *owур-* id. Шуннан ук: *орын-у, орыш-у, иск. орыш* «сугыш» һ.б.

**ОРЧЫК** «веретено» — бор. тк. *агыр-чык* «орчык, каба» сүзеннән (*агыр-* «әйләнү», бөтерелү» нигезеннән булса кирәк; чаг. *әвер-ү, әверел-ү*); к. себ. тат. *аурҗык* «орчык» (Радлов), госм. *аҕыршаҡ* «җеп эрләгеч», бор. тк. *агуршак, агырсак* «орчык, эрләгеч» (МК), бор. монг. *агурчук* «орчык» (Зәмәхшәри); к. монг. *орчи-х* «әйләнү, бөтерелү», бор. монг. *һор-чи-х* «бөтерелү». Үзб. *урчуқ*, кк. *уршук* «орчык», венг. *orsó* «орчык». Бу сүзнең бик борынгы заманнардан ук хәзерге фонетик төсмерне алганлыгын күрсәтә.

**ОРЫ** «нарост, шишка; желвак» — гом. тк. *ур* «оры, агач орысы», тув. *ору* «ачылган шеш», *уру* «оры, агач орысы»; к. чув. *вар* «оры, үзәк (?)».

**ОС** «внимание; внимательность» (в парном выр. *ис-ос* «память и внимание») — к. чув. *ăс* «акыл, фикер», *ăстай* «фикерле, дикъкатьле» (монг. *устай* «ослы»), бор. тк. *ус, уз* «тәҗрибәле, акыллы». К. **Усал**.

**ОСТА** «мастер; ловкий, умелый» — гом. көнб. тк. *уста* «оста» *остаз* (к.) сүзеннән үзгәреп килеп чыккан.

**ОСТАЗ** «наставник, учитель» — гар. *устад-ун* «остаз, укытучы» сүзеннән; чаг. тат. *остабикә, остадбикә* «мулла хатыны» (*остаз бикә* яки *остазның бикәсе* дигәннән).

**ОТ-У I** «выиграть, победить» — гом. тк. *ут- // йут-* «оту, отып кулга төшерү» сүзеннән. Чаг. **От-у II**.

**ОТ-У II** «запомнить; уловить (*смысл*)» — бор. тк. *ут-, ӱт-* «оту, отып алу, иярү» сүзеннән; к. башк. *ӧт-* «оту» (*ӧткы* «подражание»), уйг. *ут-* «охшату, иярү», бор. *уҕут-* «тыңлап оту» *ук-* (иске тат. *ӧк-*) «игътибар илә тыңлау, аңлау» сүзеннән (бу

очракта, бүтән кайбер мисаллардагы кебек, йөкләтү юнәлеше төп юнәлеш мәгънәсен алган).

**ОТЫРЫ** «все более и более» — мар. *утыр, утыр-утыр,* удм. *утыр, ытыр, ытыры* — гом. тк. *удур, утру, утуру* бор. *утур-* «каршыга чыгу» фигыленнән рәвеш фигыль формасы (к.: Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. — Казань, 1983. Ф.Фасеев, Р.Әхмәтьянов мәкаләләре).

**ОЧ** «конец, острие» — гом. тк. *уч* «оч» сүзеннән, бу сүз монгол һәм тунгус-маньчж. телләрендә дә бар; шуннан ук *уч* (к.) үзе дә килеп чыккан дип санала (Алпаров). К. **Өчен**.

**ОЧА** «ягодица» — гом. тк. *уча* «оча, арка», бор. гом. тк. *ууча, угуча, һугута* «оча» сүзеннән (тамыры ачык түгел); к. якут. *уса*, монг. *ууча, угуча* «оча», эвенк. *оса*, эвен. *осал*, орок. *хосо*, маньчж. *ошо* «хайванның бот яки тиресе» (төрки халыкларда *уча, уса* йоласы бар: киекне атып алган аучы үзенә очраган беренче кешегә киекнең очасын яки оча тиресен бирергә тиеш).

**ОЧРА-У** «встречать, встретить; попасть, угодить» — < гом. тк. *учра-, учура-* бор. тк. *учур, учыр* «очрак, момент» сүзеннән; тамыры **уч*; к. эвенк. *учиқ* «очрак; өлеш, язмыш». Ихтимал, *оча* белән тамырдаштыр. К. **Чор**.

**ОЧСЫЗ** «дешевый» — гом. тк., тат. диал. *учуз* «әчтәлексез, арзан» сүзеннән, ясалышы һәм чыгышы ачык түгел, һәрхәлдә, *оч-сыз* дип таркатуның дөрес булмавы мөмкин (татарчада *-сыз* халык этимологиясе буенча гына килеп чыккан булса кирәк).

**ОЧ-У** «летать, лететь» — гом. тк. *уч-* «очу; төшү».

**ОЧЫК** «болезнь, которая лечится путем жертвоприношения земле (*напр., путем закапывания вещей больного*)» — гом. кыпчак., ткм., үзб. *учук*, н., кк., ккк. *ушык*, башк. *очсок* id.; чуваш этнографлары бу сүзне (чув. *учук*) *уй чӳк*, ягъни «басу чүге» (к. **Чүк, Чөк**) дип аңлаталар (татарларда шуңа охшаш *кыр келәве* бар), ләкин н. *ушын-* «тәнгә чабырткы чыгу» бор. *уш-, уч-* «чабырткы чыгып чирләү» фигыле булганлыгына ишарә итә шикелле. *Учук* сүзен бор. тк. *уч ыдук* «өч ыйык (өч мәҗүси корбан)» сүзеннән дип аңлату да бар. *Үч ыдук*ны исә христиан троицасы белән бәйлиләр.

**ОШАК** *диал.* «клевета, сплетня» — себ. тат. *ушак*, кк. *усак* «әләк», бор. тк. *ушак соз* «вакчыл әләк сүзе, вакчыллык», кырг. *ушак* «вак», төрек., азәрб. *ушак, ушағ* «вак, кечкенә; яшь бала», *ушал-* «ваклану»; бор. *уша-* < *уғша-* «уылып ваклану» сүзеннән (Севортян, 1:617). *Ошак* «бала» сүзе мишәр диалектында да булган: шуннан *ланшак, ӑланшак, ӑланчак* (*олан* сүзе белән контаминация), *углан-ушак, олан-ушак* «яшь-җилкенчәк, бала-чага; колын» (> рус. диал. *лончак* id.) сүзе килә. К. **У-у**.

**ОША-У** «нравиться; быть подобным» — гом. тк. *ухша-, укша-* «охшау; ошау»; шуннан ук тат. *охшаш* ~ гом. тк. *ухшаш, укшаш* «подобный»; «охшау» > «ошау» мәгънә күчеше типологик характерга ия (күп телләрдә очрый).

*Охша-* нигезе төрлечә аңлатыла. Безнеңчә сүзнең тамыры



тув., якут., монг. *уғ, уқ,* бор. тк. *уқ, оқ* «нәсел, токым, җәвер; кабилә, ыру»; шуннан **уғуш, *оғуш* (< *уқу уш, оқу уш* «нәселе шул»; к. бор. тк. *ош, уш* «шул, менә») «охшашлык» сүзе, аннары *уғуш-а-, оғуш-а-* «охшау» фигыле ясалган.

**ОШБУ** «этот, эта, это; настоящий» — бор. тк. *ушбу, ушабу* — бор. *уш, уша* (башк. *ошо*) *шушы* һәм *бу* сүзләреннән кәш.

*Ошбу* сүзенең «дөрес» язылышы *ушбу* дип раслауның рациональ нигезләре юк. Шулай ук *ошбу* урынына *әлеге* сүзен куллану да уңышлы түгел, чөнки *әлеге*, асылда, «бая, әле генә искә алынган» дигән сүз.

**ОЮ** — к. **ОЙЫ-у**.

**ОЯ** «гнездо» — гом. тк. *уйа,* чув. *йӑва* ~ угыз. *йува* «оя» сүзенең татар сөйләшләрендә фигыль варианты да сакланган: *ойа-у* «оялау, оя кору»: шуннан кар. *уйал-* «оялау» формасы ясалган; чаг. ш. ук монг. *уйага* «лагерь».

**ОЯТ, ОЯЛ-У** «стыд; стыдиться» — себ. тат. *ойан* «оялчан» — барысы да **ойа-* дигән фигыль тамырына ишарә ясыйлар; ш. ук уйг. *обут*, бор. тк. *увут, уғат, уғиат* «оят», чув. *вӑтан-* «оялу» << **увутан-* id. Сүзнең тамыры — **уй* ~ **уғ* ~ **ув* «оят». Чаг. **Уфтану (Офтану)**.

## -Ө-

**ӨЕГ-Ү** «сбегаться (*о собаках*); толпиться, стоять кучей (*об овцах*)» — кк., кырг. *үйүк-* id. гом. тк. *үй-* «өю» фигыленең интенсивлык формасыннан булса кирәк. К. **Өер**.

**ӨЕР** «толпа; свора; куча» — гом. тк. *үйүр өй-* < *үй-* фигыленнән, әмма ничек ясалганлыгы бигүк ачык түгел: бәлки, **үйгүр* формасы булгандыр; чаг. монг. *үгүр* «иптәшлек, компания». К. **Өер-ү**.

**ӨЕР-Ү** «клубить; скучивать; ругать» — гом. тк. характердагы *үйүр-* id. *өй-* < *үй-* фигыленең йөкләтү юнәлеше формасы.

Бу нигездән татар телендә *өерел-ү, өерелмә, өермә* сүзләре ясалган. К. ш. ук диал. *өерт-ү* «өерү, өере белән куу».

**ӨЗӘҢГЕ** «стремя; стремянка» — гом. тк. *үзәңгү, үзәңги* «өзәңге, баскыч» сүзеннән, бор. гом. тк. **йүрән-кү д'үрәң-кү* «өзәңге» сүзеннән; к. чув. *йӑрана,* монг. *'дӧрүгә,* эвенк. *д'өрэңки* (Рясяне) «өзәңге»; чаг. чув. *йӑра, йӗре* «түгәрәк, дүңгәләк».

Тарихта өзәңге куллану мөһим казанышларның берсе булып исәпләнә: шуның нәтиҗәсендә кавалерия килеп чыккан (өзәңгесез ат өстендә сугышу мөшкел). Тарихчылар (мәсәлән, И.Л.Кызласов) өзәңгене төрки халыклар уйлап чыгарган дип исәплиләр. Аларча *өзәңге* < *үзәңги* бор. тк. **үзән-* «өскә менү» фигыленнән (*үзә, үзрә, үзәрә* «өстендә; турында; ярдәмендә» кебек иске тат. әдәби-язма тел сүзләре белән тамырдаш). Тат. диал. *йөзәңге* «өзәңге; тишекле күмәч» бу сүзнең тәүдә *й*-гә башланганлыгын күрсәтсә кирәк. Чаг. **Йөз-ү**.

**ӨЗЕЛ-Ү, ӨЗӘЛӘН-Ү** «страдание, переживание; страдать,

переживать» — бу сүз *өз-ү* сүзе белән баглы түгел; к. төрек. *үзүл-* «өзәләнү», бор. тк. *үдүк* «көчле мәхәббәт», *үз ~ үд* «көчле хис». Чаг. ш. ук тат. диал. *өзлә-ү* «авыз ачмыйча көйләү, хәтта җырлау (рус. «чревовещание»)» — Себер төркиләрендә *үз* «тавышсыз җырлауның бер төре».

**ӨЗЛЕГ-Ү** (*өзлек-*) «повторно заболеть» — *өз-ү* фигыленең интенсивлык формасыннан дип уйларга нигезләр бар; чаг. *җиту — җитлегү, йоту — йотлыгу, сөрү — сөрлегү* һ.б.ш. Ләкин бор. тк. *үзүл-, үзәл- ~* чув. *верел-* «өзлегү» бөтән фикерләр уята; к. бор. тк. *үз* (күплек формасы *үзүт*) «явыз рух; дошманчылык», *үзлүк* «явызлык, шайтан шәрре» ~ тат. диал. *өзлек* «чир, кайгы калдыгы».

**ӨЗЛЕКСЕЗ** «беспрерывно» — *өзел-ү* (к. **Өз-ү**) нигезендә татар телендә ясалган булса кирәк.

**ӨЗ-Ү** «прервать, оборвать, рвать (*нить, веревку*); *диал.* окончить, покончить» — гом. тк. *үз-*, ткм. *үйз-* «өзү». Юнәлеш формаларыннан тик *өзел-ү* < гом. тк. *үзүл-* генә актив. Аның каравы татар телендә бу нигездән *өздер-ү* «шәп эшләү», өзек «ачыклык; кытлык» һ.б. ясала.

**ӨЙ** «дом; изба» — тат., башк. диал. *ев, әү* > чув. *ав.* (себ. тат. *әүлән- ~* чув. *авлан-* «өйләнү»), гом. тк. *үй, эв, ив,* иске тат. *өйү ~* бор. тк. *эйү*, якут., эвен. *ийү*, кар. *йү* «өй». Бу сүзне *өй-ү* фигыле белән чагыштыралар. Икенче яктан, бор. кытай *иң* «квадрат; башня» сүзе нигезендә ясалган дигән фикер бар.

**ӨЙЛӘ** «полдень; полуденная молитва у мусульман» — чыгт., госм. *үйлә* «өйлә, төш вакыты» сүзеннән; к. бор. тк. *өглә//өдлә* «өйлә» (МК), тамыры *өд: монг., алт. *үдэ* «өйлә», үдәлә- «төшкә тукталу», уйг. *өдләк* «өйлә», *өд* «төш вакыты» (чаг. шумер. *od, ud, üd* «көн уртасы»). Ясалышы буенча чаг. *төнлә* (төн-лә).

**ӨЙРӘ** «суп из крупы» — гом. тк. *үгрә* «өйрә, вак токмач» сүзеннән. Чаг. бор. тк. *öгүр*, чув. *вир* «тары».

**ӨКЕ** «филин, сыч» — гом. тк. *үкү, үки* «өке, байгыш» — Егоров буенча «звукоподражательное слово» (ягъни өкенең «у-у» дип кычкыруыннан). Чаг. немец. *uhu* «өке, ябалак».

**ӨЛӘШ-Ү** «раздавать; распределять» — < бор. *үлә-* «өлешләү» фигыленең уртаклык юнәлеше. К. **Өлеш**.

**ӨЛГӘШҮ** «достигать (успеха), успевать (в учебе)» — бор. *өлгә — фигыленең уртаклык юнәлеше; к. тув. *үүлге-* «инициатива күрсәтү, яңа эш башлау; майтару»; *үүлгет-* «маташу», якут. *үлүһүй-* (<*үлгүс-*) «өлгәшү» *үлүһүт-* (< *үлгүт-*) «ылыктыру, коткы салу, мавыктыру, *өлгәтү» *-үүл* тамырыннан. К.**Өлгер**.

**ӨЛГЕ** «выкройка; часть оконного переплета; шаблон, образец» — к. **Өленге**.

**ӨЛГЕР** «быстрый в действии, хваткий» — гом. *үлгүр-* id. бор. тк. *үүл- ~* бор. монг. *үйл-* «иҗади эш эшләү; инициатива күрсәтү» фигыленнән. Шуннан ук алт., хакас. *үлгән* «иҗатчы тәңре». К. **Өлгер-ү**.

**ӨЛГЕР-Ү** «успевать, успеть; преуспеть; поспеть» — гом. кыпчак. *үлгүр-* id. Бор. *үүл, үйл-* «иҗади эш башкару» тамырыннан (ясалышы ачык түгел). К. **Өлгәш-ү, Өлгер.**



**ӨЛЕҢГЕ** «занавес снаружи (который вывешивался в случае наличия в доме покойного)», в устарелом знач. также «банный передник» — бор. *үлүңгү* < *үрүңгү* «рәсемле байрак» сүзеннән, бор. тибет. һронго «рәсемле ритуаль байрак» сүзенә кайтып кала (к. бор. тк. *үрүңү, үрүңгү* «байрак» > рус. **хоругвь, хорунга** «сурәтле байрак, чиркәү байрагы», шуннан **хорунжий** хәрби чин, «байракчы»). Ибне Фазлан болгарларда мәетле өй ишегенә байрак элү, аннары шул байракны мәет салынган арба алдыннан алып бару турында яза: ул «байрак» өленге булган. Өлеңгене бала туган өй тәрәзәсенә дә элгәннәр — ул явыз рухлардан саклаган! Химаяче рәсем ролендә өлеңге соңрак төрле билгеләр, корама һ.б. кулланылган. Шуннан ткм. *үлңци, үлүңңү* «тәрәзә өлгелеге, трафарет, шаблон» — гом. тк. *үлгү* > тат. *өлге* «үрнәк, шаблон; күкрәкчә корамасы» килә.

Бор. *үрүңгү* сүзе «байрак күтәрүче, батыр, герой» мәгънәсендә дә кулланылган, шуннан бу сүзнең фольклористик мәгънәләре килә: якут. *олонхо* «эпос, дастан» < бор. *үлүңгү* «батырлар турында җыр» > кк., тат., башк. *үләң, өләң* «эпик җыр», хакас *үлгү* «оран, ялкынлы чакыру» К. т. ук алт. *үлгер*, тув. *үлегер*, бурят. *ульгэр*, монг. *үлигэр* «өлге, үрнәк, чагыштыру; батырлар турында дастан (яшь буынга үрнәк!)». К. **Оран**.

**ӨЛЕШ** «часть, доля» — гом. тк. *үлүш* «өлеш» сүзеннән, бор. тк. *öл- // öле-* фигыленнән (*öл-үш*); чаг. көнч. тк. *үлү, öлү* «өлеш, кисәк», уйг., тув., бор. тк. *үлүк, үлүг* «өлеш», чув. валĕ «өлеш». К. **Өләш-ү, Өлкә, Үлчә-ү**.

**ӨЛКӘ** «область» — уйг., госм. *өлкә, үлкә* «өлкә, край, биләмә, ил» сүзеннән булса кирәк; к. ш. ук уйг., бор. тк. *үлүк*, якут. *үлүк*, тув. *үлүг* «өлеш». Чаг. башк. *бүлкә, бүлкәй* «бүлек, өлкә». К. **Өләшү, Өлеш**.

**ӨЛКӘН** «старший; взрослый» — н., кк. *үйкән, үлкән,* ккк., ткм. *үлукан, үлуккан,* якут. *улаххан* «гаять зур, бөек» бор. тк. *улуғ кань* «олуг ата, патриарх» сүзеннән; мишәр. диал. бор. тк. *кань*, чув. *хонь, хунь* «ыру атасы, гаиләдә иң олы кеше».

**ӨМӘ** «коллективная помощь; субботник» — кк., н., уйг. *үме* «өмә», алт. *омо* «киңәш» — мәгънәсе бик үк ачык түгел. Җ.Вәлиди кар. *ума*, уйг., чыгт. *умак* «халык, кабилә, ыру, зат» сүзе белән чагыштыра; к. ш. ук себ. тат. *ом, ум-йум* «кардәшыру», тат. диал. (мишәр.) *бемә* «өмә» ~ мар. *вима, вуме* «өмә» — чуваш теленнән (чув. *вĕме* < *үмә*).

**ӨМЕТ** «надежда» — гар. *үмид* «өмет» сүзеннән иске алынма; төрки телләрдә бу сүзнең *умут, мут* кебек вариантлары бар.

**ӨН I** «явь» — мәгънәсе ачык түгел. Чаг. **Өн II.**

**ӨН II** «голос; звук» — гом. тк. *үн* «өн, тавыш; дан» сүзеннән; шуннан ук *өн-дә-ү* «взывать». К. **Эндәш-ү.**

**ӨН III** «нора» — гом. тк. *үң, ин* «өн» сүзеннән; к. ш. ук башк., тат. диал. *өң-, үң-* «су җибетеп ишелү яки убылу, казып керү» көнч. тк. *үңгү* «агач куышы», кк. *үнүр, үңүр* «өн, куыш», бор. тк. *үң-* «үтәли тишеп чыгару» (МК).

**ӨНГӘЛ** «холка (*лошади*)» — к. **Умрау.**

**ӨРӘК** «призрак; привидение» — тат., башк. *өрәк*, чув. *ĕрех*

«өрәк, җан» — тат. диал. (себ. тат.) *әүрәк, аурак* «өрәк, әрвах» сүзеннән булса кирәк (гар. *әруах-ун* «рухлар» дигәннән); к. ш. ук диал. *арбак* (*әрвах* «убыр, өрәк». Чаг. якут. *үөр* «тәннән чыккан җан».

**ӨРӘҢГЕ** «клен» — уйг. *үрәңги*, чув. *вӗренӗ* «өрәңге» ~ бор. тк. *үрәң, үрүң* «ак» (МК) сүзеннән булса кирәк; чаг. диал. *чаган* «өрәңге» < монг. *чаган* «ак, ак агач, өрәңге»; госм. *акча агач* «өрәңге».

**ӨРЕ** «навар, жир на бульоне» — алт. *өрү, өрө* «өске өлеш, өст» сүзеннән булса кирәк; к. хакас., тув., алт. *өрүмә, өрүңмә*, якут. *үрүмә* «өре, күбек, каймак; өске юка боз, элпә», монг. *өрүмә*, бурят. *өрмә* «өйрә өстендәге элпә, өре». Чаг. ш. ук чув. *вӗрӗ-* «кайнау».

**ӨРЕК** «урюк; абрикос» — гом. тк. *өрүк, өкрүк* бор. тк. *әрүг, әриг* «өрек, чия» сүзеннән, ясалышы ачык түгел; чаг. себ. тат. *өрән*, алт. *үрән*, тув. *үрүң* «бөртек, чикләвек, чикләвек төше, төш» (*үр* «орлык») сүзеннән.

**ӨРЛЕК** «балка, перекладина» — кыпчак телләрендә һәм алтай өлкәсендә таралган сүз, башк. *өрлек*, кк. диал. *үрлик*, ккк. *үрлик, өрлик* «матча, өрлек; мачта, терәү», чув. *вӗрлӗк* «өрлек, колга», алт. *өрлөө* «киртәлек». Тамыры ачык түгел.

**ӨСТ** «поверхность, верх» — гом. тк. *үст-* бор. тк. *үсүн* > тув. *үзүн* «өст, өске як» сүзеннән дип уйланыла (*үсңү* > *үстү* > *үст*). Чаг. **Аст**.

**ӨСТУАН** *уст.* «павильон, беседка» — иске әд. (Г.Кандалый) *ӧстӧхан* < уйг. *устухан* «изге кабер, каркас, сөякләр», бор. «мәҗүси табыну урыны, пот» (> *рус истукан*) < фарсы. *усту-хуан* «сөякләр; кабер» сүзеннән.

**ӨТЕР** «запятая» — гом. тк. *өтрә, өтүрү* id. — гарәпчәдән.

**ӨТЕРГЕ** «долото» — иске тат. *өтер-ү* «төртеп тишү» сүзеннән; к. бор. тк. *өтүр-* «тишү, телү», *өт* (> тув., хакас. *үт*) «тишек»; чаг. якут. *үтүрүй-* «төртү, төртеп чыгу», тат. диал. *өтә-ү* «этеп шудыру».

**ӨЧ** «три» — гом. тк. *үч* id.

**ӨЯЗ** «уезд» — рус теленнән (*уездить* «атта әйләнеп чыгу» сүзеннән).

**ӨЯК** «подбрюшница, пышный мех» — мар., чув. *вӑйӑ, вайа* «өрпәк», чыгт. *үйәк*, алт. *үйөк* «өяк, өрпәк, чук», төптә «почкак, тиренең бер почмагы» бор. тк. *үкәк, үвәк* «почмак башнясы, зодиак йолдызлыгы» сүзеннән, шуннан ук Идел буе шәһәрләренең берсе *Үкәк/Үвәк* исеме.

**ӨЯНӘК** «эпилепсия» — ниндидер *өйә* нигезеннән; чаг. башк. *өйә-лә-ү*, себ. тат. *өйәтә-ү* «тора алмыйча яту».

**ӨЯНКЕ** «ива» — тат. диал. *үйәнке, эвәнке, бәнке* ~ чув. *эвенкӗ* ~ башк. *өйәнке* id., кк. *үйәңки* «өрәңге»; тат. диал. *үәк* id. Чыгышы ачык түгел. Дистинктив Идел-Урал сүзе булса кирәк.

# -П-

**ПАЙ** «пай; доля» — гом. тк. *пай* «пай, өлеш» сүзеннән; к. тат. диал. *бай* «өлеш» (*ата бае* — атадан өлешкә тигән мирас). Асылда, ирани (фарсы). *бәһ, беһ* «өлеш, пай» сүзеннән булса кирәк. Рус. *пай, паёк* — төрекчәдән. Чаг. **Баек**.



**ПАКЬ** «чистый» — фарсы. *пак'* «пакь, саф, таза» сүзеннән.

**ПАЛАС** «ковер; половик» — фарсы. *палас* «палас, чыпта» сүзеннән; к. чув., үзб. *палас, полос* «палас».

**ПАЛАЧ** «палач» — рус теленнән; рус теленә исә госм. *пала-чы* «пычакчы» (*пала* «кеше үтерә торган зур пычак») сүзеннән.

**ПАҢГЫ** «вид гриба» — мар., морд. һ.б. фин-угор. *панга* id. Бу сүз еш кына һинд. *банг* «наркотик үсемлек (киндераш, махсус гөмбә)» белән чагыштырыла. Ихтимал, борынгы атаклы сома наркотигы шулдыр.

**ПАПАДИЯ** «большая ромашка» — госм. *пападия* «пападия» сүзеннән (асылда, грекча *пападия* «поп хатыны; ромашка»).

**ПАРЛАК** «блестящий (*успех*)» — госм. *парлак* «бик шәп, парлак» (*парла-* «ялтырау, очкынлану») сүзеннән. Чаг. тат. *па-рылдау* «җилфердәү».

**ПАРЧА** «парча; узор; отрывок; фрагмент» — фарсы-таҗ. *пара-ча* «кечкенә кисәкчә» сүзеннән, *пара, парә* «кисәк, өлеш» нигезеннән; к. иск. тат. әд. *парә-парә* булу. К. **Чәлпәрәмә**.

**ПАТША** «царь, падишах» — фарсы. *падшаһ* «тәхеттәге шаһ» (*пад, пати* «тәхет», *шаһ* «шаһ») сүзеннән.

**ПӘЖЕ, ПӘҖИ** «пенька; кудель» — к. тат. диал. *пәче, пәце* «пәҗе, баса», тат. *баса*, диал. *маса* (себ. тат.), *паса* (мишәр.) «аксыл киндераш» диал. (мишәр.) *пучы, пуцы*, чув. *пучӑ* «шнур, киндерә»; боларның тамыры төрки һәм фин-угор телләре өчен уртак булган *пач, поч* «сүс, киндераш» сүзе булса кирәк; к. мар. *поч* «аркан, киндерә, бау», *пач* «киндер кисәге, киндер тукыма», удм. *пыш, пуч, поч* «киндераш, сүс», морд. *паця* «яулык» — төрки телләрдән? К. **Баса, Мичәү**.

**ПӘҖМӘ, ПАҖМА** «усадьба, участок земли с домом» — диал. *пазьма, пажум*, чув. *паҫма*, рус. *пазьмо, позём* «тирес, тиресле җир» сүзеннән дип уйланыла, ләкин мар. *паз* «чабынлык кишәрә» бүтән фаразларга да урын калдыра.

**ПӘЙГАМБӘР** «пророк» — фарсы. *пәйгамбәр* «пәйгамбәр» сүзеннән (*пайгам* «хәбәр, вәхи», *бәр- // бар- бардан* «китерү» фигыленең нигезе).

**ПӘЙДА пәйда булу** «появляться, обнаруживаться» — фарсы. *пайда* «барлыкка килү, туу күренеше» сүзеннән.

**ПӘКЕ** «перочинный ножик» — фарсы-таҗ. *паки, паку* «пәке» сүзеннән.

**ПӘКРӘ** «вид осетровых» — калм. *бекре*, чыгт. *бекре*, кк. *бекрә* «чуар чөгә».

**ПӘРӘВЕЗ** «паутина» — фарсы. *паровоза* «һавада очып йөрүче нәрсә» сүзеннән; к. тат. диал. *пәрвәзә* «пәрәвез», иск. тат. *пәрваз кылу* «очу, очышта булу».

**ПӘРӘМӘЧ** «перемяч; ватрушка» — чув. диал. *перемеҫ* «пәрәмәч», удм. *перемеч*, мар. *перемец, бöремеч* < тат. диал. *бүрәмәч* < *бүгүрәмәч* «пәрәмәч, түгәрәк күмәч»; к. гом. тк. *бүгрә//буғра* «йомарлак» сүзеннән; к. чыгт. *буғрамач* «кабартма, пәрәмәч», тат. диал. *пәрәпәч, пирипис, пирамәч, пәрамәчә*, чув. *пӳремес* «пәрәмәч». К. **Бавырсак, Букча, Бәрәңге.**

**ПӘРДӘ** «занавес» — фарсы-таж. *парда* «пәрдә; канат».

**ПӘРИ** «черт; бес» — мар. *парий*, удм. *пери*, тат. диал. *фәри* > чув. *хĕвери* «пәри» — фарсы. *пари* «пәри» сүзеннән.

**ПӘҺЛЕВАН** «богатырь; силач» — фарсы. *pəhləwan, pəлhawan* «пәһлүан, батыр» бор. фарсы. *parthava(n)* (> таж. *партавон*) «парфянин» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1989: 40. К. **Балабан, Барабан.**

**ПЕЛӘШ** «плешь, лысина» — рус теленнән.

**ПЕСИ** «киска, кошка» — гом. тк. *печек//пешек, пишәк//писәк* «песи» сүзеннән — асылда, песиләрне чакыру ымлыгы (тат. *пес-пес*, рус. *кис-кис*, һинд. *бис-бис*, инглиз. *puss-puss, bis-bis*) нигезендә ясалган; к. тат. диал. *пешәк, печәк, печәй, мечәй* «песи» (шундый формалардан үзгәреп *мәче* сүзе дә килеп чыккан), кк. *пишик, мышык*, үзб. диал. *мышак, пшәк*, монг. *биисэй* «мәче». Чаг. гар. *баси*, инглиз. *pussy* «песи, песекәй».

**ПЕСНӘК** «синица, синичка» — рус. диал. *мясник* «песнәк» сүзеннән (беренчел мәгънәсе «итче» — песнәкнең итчеләр янында йөрергә яратуыннанмы яки итчеләрнең киеме песнәккә охшаганлыктан әйтелгәнме, билгесез. к. диал. *песник, песлик* «песнәк». Мар., удм. *пислэг, писник* «песнәк» — татарчадан.

**ПЕЧӘН** «сено» — көнч. тк. *пичән* «печән», кар., кум. *бичән* «печән», бор. тк. *пичән* «үрмә үсемлек» (Радлов), н., кк., ккк. *пишен*, алт. диал., кырг. *пычан, пыжан* «печән», мар. *пилчэн, пилсэн* «печән, билчән», чув. *пиҫен* «билчән, чәнечкеле куак», себ. тат. *пищан* «утлык, печәнлек». **Печ-ү** (к.) фигыленнән.

**ПЕЧМӘН** «весенний праздник с выходом на поля» — рус. *веснянка* сүзеннән, к. ш. ук удм. *бисмянь*, мар. *пӹсман* «ызан, җир очы».

**ПЕЧТЕК** «мизерный» — гом. тк. *пичик* «бик кечкенә» сүзеннән, ниндидер *пич // бич* тамырыннан; к. диал. *печек, печеки, печтеки* «кечкенә» — чув. *пеҫек*, госм. *бечук*, якут. *бичикән, бычыкан, бычыкай*, тув. *бича*.

**ПЕЧТӘЛ, ПЕЧТӘН** *диал.* «незванный помощник» — русча *фискал* — XVIII гасырда крестьяннарга акыл биреп йөрергә билгеләнгән мәгърифәтле «салым җыючы» дигән сүз (салым регуляр рәвештә килеп торсын өчен хуҗалык эшләре нормаль барырга тиеш. Шуна күрә фискал бер уңайдан хуҗалык инструкторы ролен дә үтәргә тиеш булган); соңрак рус телендә *фискал* (латинча *фискалис* «кәҗүнни») «хөкүмәтнең яшерен агенты» мәгънәсен алган.

Татар сөйләм телендәге *печтәнләну* «кирәкмәгәнгә яисә риялы рәвештә кеше хәленә кергән булу, ярдәм тәкъдим итү» һ.б. ш. Екатерина II «фискалларының» реаль ярдәм итә алмаганлыгын күрсәтә.

**ПЕЧ-Ү** «обмануть; ограбить» *диал.* кроить одежду» — уйг., үзү. *бич*-id. < гом. тк. *быч-, пыч-* «аркылыга кисү» фигыленең палаталь вариантыннан.

**ПЕШЕ** «гибкий, неломкий; удалой, опытный» — мар. *пысы*, кк. *пысык*, алт., телеут. *пыжык*, шор. *пышыҒ*, хакас. *пызыҒ*, кырг. *бышык*, тув. *быжыҒ* «пеше, өлгер, өлгергән», тат. (сирәк кулланыла) *пеше-* «өлгертү, кондициягә житкерү» фигыленнән; к. кк. *пысы*-id.; бу фигыль исә, үз чиратында, гом. тк. (тат.) *пеш-, пиш-, биш-, быш-* «ут эссесендә пешү» фигыленең варианты шикелле.

**ПЕШ-Ү** «вариться; печься» — чув. *пиҫ-*. гом. тк. *пиш-*, алт. *пыш-*, кырг. *быш-*, якут. *буш-, бус-* «пешү» варианты бу сүзне согд. *pwγš* ~ бор. иран. *pixs, pač*, скр. *pač pakva* «пешү, пешерү» сүзе белән чагыштырырга юл калдыра (ягъни һинд-евр. **рек*- тамыры белән баглана); моңа охшаш сүзләр бүтән телләрдә дә күзәтелә; к. коми. *пузь-, пожь-* «пешерү».

**ПИМА** «пимы, валенки» — рус., ненец. *пема*, коми. *пими* «пима».

**ПИРӘШ** «крепкое пиво» — иске тат. *пыйраш* чув. *пыраш* сүзеннән булса кирәк: хәзерге чуваш сүзлекләрендә бу сүз юк, ләкин мар. *пуйыр, пуро*, морд. *пуре*, венгр. *bor* «сыра» сүзеннән чув. *пуйраш, пыраш* нигезе ясала ала. Бүтән төрки телләрдән к. төрек. *bira*, сыра».

**Пичәт** «печать (на документе); обои» — беренче мәгънәдә рус теленнән. Рус печать — немец. *Petschajt* «мөһер» сүзләре исә борынгы төрки *пути-, пити-, пичи-* < борынгы кытай **пиэт* — «кисть белән язу, кисть» сүзенә тоташа. И.Г.Добродомов фикеренчә, рус. *печатлять* (впечатлять) «мөһер салу, пичәтле итү» болгарча **пэчәтле* «пичәтләнгән, кисть белән бизәлгән» сүзеннән; димәк печать < болгарча *пэчәт* (**-т** борынгы төрки сүз ясагыч кушымча) «кисть, чук белән төшерелгән бизәк, мөһер» (к. Тукайда «Ашый пичәтле перәннек кенә»).

**Пичәт** сүзен татар телен шул язылышта куллану хәерле. **бастыру** сүзенең артына күп мәгънәлелеген искә алып, шунын урынына **пичәтләү** сүзен кулланырга мөмкин. К. ш. ук **Бөти**.

**ПОЛЫН** «плен, пленный» — рус теленнән, рус теленә исә бор. тк. телләрдән; к. бор. тк. *болон, болуң* «качкын, плен» (МК), уйг. *полун, пулун* «паника, плен» төрки сүз дип исәпләнә.

**Полын** сүзен төрки телләрдә борынгы славян алынмасы дигән фикер дә бар (K.H.Menges Zn einigen Siawisch-turkischen Beziehungen. Tatarica. Finnland, 1987, с.233—239) — бу сүз күпсанлы славян әсирләр теленнән таралган, диләр.

**ПОРАК: порак оны** «плата натурой (мукой) за помол в мельнице» — тат. диал. *борак*, удм. *бурак*, ар. *урак, пырак*, чув. *парах* — «житен талкыганда, йон теткәндә һ.б.ш. чыккан тузан», башк. **порак** «иген серкәсе» — бор. *бор, бур* — бор. рус. *бърь* «учактан күтәрелгән көл, корым» тамырыннан. Чаг. рус. прах, **порох** (шуннан — **порошок**) — фарсы. тк. **барут, барук** «дары»: дары селитра ярдәмендә ясалган, селитра исә мәете череп беткән каберләрнең эстинасына ак онтак булып утыра һәм шуннан җыеп алына. **Порак оны** — тегермән диварларындагы куның он — күчерелмә мәгъ. «ашлык тарттырган өчен түләү» булып киткән.

**ПОС** «испарение; туман с дымом» — гом. тк. *пус* «пос»

(МК), чув. *пăс, поас* «пос, ис, бәс». Коми. *пуш* «ис, пар», *бус* «тузан», удм. *бус* «томан», төтен, пар» төрки теллəрдəн булса кирәк. Чаг. тат. *посқақ* «вак кына яңгыр сибәләү».

**ПОС** — «прятаться и наблюдать» — удм. *пыс-*, азәрб., кк., чыгт. *бус-*, бор. тк. *пус-* «поскында утыру» — борынгы хәрби термин.

**ПОСТАУ** «тонкое сукно» — башк. *бустау, пустау*, чув. *пустав, постав* «сукно, плис», удм. *пустал*, венг. *poszto, postal, postav* «сукно», госм. *пастав* «сукно кисәге» һ.б. рус. *полстина, полсть* «постау, юка келәм, сукно кисәге» яки немец. *Polster* «келәм» сүзеннән булса кирәк. В.Г.Егоров тув. *пос-даавы* «тукыма товары» сүзе белән чагыштыра, бу сүз исә төрки һәм монгол сүзләреннән дип фараз ителәә.

**ПОТ I** «пуд» — рус теленнән.

**ПОТ II** «идол, кумир» — төрки телләргә санскрит теленнән бор. фарсы теле аша кергән; к. бор. тк. *бут* «Будда, Будда статуясы» — фарсы. *бут* «Будда».

**ПОЧМАК** «угол» — морфологик структурасы ачык кебек булса да (*поч-мак*), сүзнең ясалышы ачык түгел; к. көнч. тк., чыгт. *бучмак* «почмак», чыгт., куман. *бучкак* «почмак», госм. *буҗак*, кырым, *буҗук* «почмак; ярты», үзб. *бурчак* «почмак», *бурч* «почмак, оч, кырый»; шулай итеп, баштан ук бер мәгънәдәге ике сүз *бурч-мак* һәм *бурч-как* ясалган дип фаразларга мөмкин. К. **Почык**.

**ПОЧЫК** «половина; курносый» — кк. *пушык* «почык», бор. тк. bučug «ярык, почмак», госм. *буҗак; буҗук* «ярты; почмак», бор. тк. *булуңчук* «өлеш, ярты» (*булуң* «почмак, кырый, үлчәү») сүзеннән. Кайбер татар сүзлекләрендә *почык*ны *потчык* дип аңлату дөрес түгел.

**ПОШИ** «лось» — тат. диал., башк. *мышы, мышый, пышый, пеше*, чув. *пăши* «пошый, болан» фин-угор телләреннән; к. мар. *пучо*, удм. *пужей*, коми. *пэж*, манси. *пааши* «пошый, яшь болан», рус. *пыж* «боланчык» (шуннан *пыжик* «болан бозавы тиресе»); тат. диал. *пышым* «пошый яисә болан тиресеннән ясалган ыштыр», *пыштыр* «тире аякчау, чарык» сүзләре дә шуннан.

**ПУЛ I** *диал.* «отмостки; полати в бане» — к. фарсы. *пул, пол* «ләүкә, киштә, күпер». Рус теленнән түгел.

**ПУЛ II** *диал.* «кон (*в игре*)» — бор. тат. *пул, пӯл* «монета» сүзеннән. Бөтен Шәрыктә билгеле бу сүз бор. грек. *обол*дан килә.

**ПУЛАТ** «дворец, каменное здание» — рус. *полати, полата, палата* «сарай, пулат» сүзеннән.

**ПУМАЛА** «помело» — рус теленнән.

**ПУТА** «широкий ремень, пояс» — фарсы. *пота, фото* «пута, капчык, янчык» сүзеннән. Рус *фата* «киң бөркәнчек» тә шуннан.

**ПУТАЛ** «поталь» — гар. *мөталла, моталла* «алтынланган» сүзеннән (гар., фарсы. *тәлла, тилла* «алтын»). Рус. *поталь* — төрки телләрдән.

**ПУТЕМАР** «перевязь с сумочкой для хранения амулета» — диал. *бутмар, бутумар, муйтымар*, чув. *путмар*, удм. *бутьмар*, морд. *потмар* «сандык; шкаф» — татарча (борынгы болгарча) *буй томар* «гәүдәгә, буйга киелә торган томар» сүзеннән. К. мишәрдә *буй бөтү* «путемар»; чыгт., тк. *тумар* «бөти савыты». *Путемар* (п!) яңгырашы чуваш теленнән.

**ПЫЛАУ** «плов» — төптә һинд сүзе булып, шуннан киң таралган сүз (рус. *плов*). Татар теленә Урта Азия телләреннән кергән.

**ПЫЧАК** «нож» — гом. тк. *пычак // бычак* «пычак», бор. тк. *быч-чак* «кисә торган нәрсә» сүзеннән. К. **Пычкы**.

**ПЫЧРАК** «грязный» — *былчырак* (к.) сүзеннән кыскарган, *пычра-у* исә *былчыра-*удан.

**ПЫЧКЫ** «пила» — *пыч-у* «аркылы кисү» фигыленнән («пычкы»). Гом. тк. *пычкы, бычгы;* удм. *бызгы* < болгар. **быжгы* id.

**ПЫЯЛА** «стекло» — фарсы. *пиала* «фарфор; фарфор яки пыяла савыт» сүзеннән.

## -Р-

**РАС** «верно, правильно» — фарсы. *раст* «рас, төгәл, туры» сүзеннән (чаг. латин. *recto*, немец. *richtig* «туры, дөрес, уң»).

**РӘВЕШ** «образ, облик, вид» — фарсы. *равиш* «рәвеш, хәрәкәт рәвеше, агыш, барыш» сүзеннән (*равидан* «бару, китү» фигыль нигезеннән).

**РӘЕШ** «наряд» — фарсы. *араиш* «бизәк, бизәү», *арастан* «бизәү, ясау, төзәтү» (тамыры *рас-* «дөрес, төзек»). К. чув. *эреш* ~ мар. *ӹрӹш* «рәешле» < болгар. ~ тат. **әрәйеш*. К. Әхмәтьянов, 1981: 116—117.

**РӘНҖЕ-Ү** «обижаться; страдать; -кк., ккк. *ренжи-* фарсы. *ранҗидан* «рәнҗү» сүзеннән ярымкалька; сүзнең тамыры фарсы. *рäнҗ* «азап, яра».

**РӘТ** «ряд; порядок; толк» — сүзлекләрдә бер сүз итеп бирелә, әмма анын артында ике аерым сүз торса кирәк: беренчесе — русча *ряд*, икенчесе нугай һәм Добруҗа татарлары телендәге *рәт, рәәт, рәһәт* «җинел»; **рәтлә-ү, рәтле** сүзләренең тамыры — соңгы *рәт* булуы ихтимал. К. **Рәхәт**.

Чув. *ĕрет* < тат. *эрәт;* удм. *рад, рат*, мар. *радэ* id. рус теленнән.

**РӘХӘТ** «удовольствие, блаженство < гар. *рәхәт* «җиләс», *рух* «җил исү; тын алу, ял итү» тамырыннан.

**РӘШӘ** «марево; мираж» — рус. *ржа, рьдя* «кызгылт томан, рәшә» сүзеннән; к. диал. *әрәшә, ыржа* (мишәр.) «рәшә»; чув. *ырша*, мар. *эрежа* «рәшә». К. Әхмәтьянов, 1989: 9.

**РЫСКАЛ** «счастье» — чув. *ăрăскал, ĕрĕскел*, мар. *рыскал* «бәхет; өлеш» — кк. *ырыскал* id., фарсы. *рузгар* «көндәлек ризык» сүзеннән үзгәргән булса кирәк; к. кырг. *оразгар* «байлык». К. **Ураз**.

## -С-

**САБА** «кожаный бурдюк для кумыса» — башк., кк. **саба** «тире капчык, тырыс», монг., бурят. *саба*, хакас. *сабан, шабан* «мичкә», алт. *сабаш* «чиләк, тырыс», тув. *сава* «савыт; аналык»

һ.б., ясалышы һәм чыгышы ачык түгел; чаг. кырым., кәнч. тк. *саба* «өлеш», фарсы. *сабу, саба* «чүлмәк, чиләк, тәлинкә».

**САБАК I** «урок» — гар. *сабақ-ун* «сабак, дәрес, укып күрсәтү» сүзеннән.

**САБАК II** «стебель» — *сап* (к) сүзеннән (*сап- ақ > сабак*).

**САБАН** «плуг; пахота» — гом. тк. *сабан* «сабан, сука; игеннәр, иген кыры, басу» сүзеннән, удм., чув. *сабан* «агач сабан, кәкре агач, агач кисү өчен җайланма («козлы», шул ук мәгънәдә рус. диал. *сабан*)», мар. *саван* «козлы» һ.б., рус. *сабан* «сабан, бүрәнә ташу өчен зур чана» — бу сүзнең гом. тк., тат. *сарман, сарпан, сапан, сакпан, сапкан,* фарсы. *сапанд* «арбалет; катапульта» сүзе белән бәйләнешенә ишарә итә. Элекке төрки гаскәрләрдә авыр чана сыман станлы мәнҗәникъларны еш кына җирдән сөйрәтеп күчереп йөрткәннәр. К. төрек. sapan (*сапан*) «мәнҗәникъ; мичәү арканы» (сабанны, димәк, мичәүләп тартканнар). Чаг. ш. ук тадж. диал. *сапун, сәпән* «тәрән», бор. ирани. *spana* «тимер, тәрән», шумер. *sabati* «иген игү, сөрү».

**САБЫН** «мыло» — фарсы. *сабун* сүзеннән булса кирәк, бик күп телләргә таралган сүз; к. гом. тк. *сабын,* монг. *сабаң,* гар. *сабун,* латин. *sapo(n),* немец. *Seife* «сабын». Урта Азиядә, Иранда, Һиндстанда элек-электән сабын урынына шундагы бер үсемлекнең күбекләнүчән тамырын кулланганнар. Бу тамыр фарсыча *соибун* «югыч тамыр» дип атала. Үсемлекнең латинча исеме — saponaria.

Тат. диал. *сабынӳ* ~ чув. *супăнь, сопăнь,* мар. *шовынь, шавынь,* морд. *сапонь* (азакта йомшак *-нь*) варианты игътибарга лаек.

**САБЫР** «терпеливый, спокойный» — гар. *сабр-ун* «сабырлык» сүзеннән (татар телендә башта *сабырлы* «сабыр» сүзе таралган булган, соңыннан ул *сабыр* белән алмаштырылган).

**САВЫМ** «счет ниток в пряже» — > чув. *сум,* бор. тат. *саум* «сигез ярым грамм көмеш; туй бүләге» (себ. тат. *сауым* id. — бор. болгар **сау- >* чув. *су-*) «санау» сүзеннән. Борынгы Болгар һәм Казан дәүләтләре чорында *савым,* гомумән, жеп исәбендә төп берәмлек була; *өч бөртек — 1 савым, 10 савым — 1 басма, 10 басма — 1 каре* (4 аршин). Шундый ук исәп мариларда да саклана: *3 пӹрцы* (бөртек) — *1 лыдма* (*лыд-* «санау»), *10 лыдма — 1 пашма, 10 пашма — 1 кынер* (*кынер-* каре, «терсәк» дигән сүз).

**САВЫР** «круп лошади» — том. тк. *сагыр, сагыры* «ат кабыргасы, ат янбашы, шуннан эшләнгән кун» сүзеннән. К. **Саурый**.

**САВЫТ** «посуда» — гом. тк. *сагыт* «савыт, кием, кипрән (оболочка)» сүзеннән. Бор. *саҒ* «металлдан коелган нәрсә» сүзенең күплек формасы (*саҒыт*); к. үзб. *совут,* бор. чыгт., куман. *саҒыт* «панцирь, көбә кулмәк». Бор. Идел буе төркиләре шәһәре *Саксин* исеме дә *саҒчын* «савытчы, көбәче» сүзеннән; к. бор. тк. *сақсық, саҒулга,* чыгт. *сақсық, саҒу* «савыт-саба» (Зәмәхшәри). Чаг. кум. *сагъ* «мера сыпучих тел».

**САГА** «биток; мяч, полотно скатанное из шерсти коровы» — гом. тк. *сақа* (*шақа* «сыйрак сөяге, бәкәл сөяге» сүзеннән) к. **Шака**); к. кәнч. тк. *саҒай,* бурят. *шаҒай,* монг. *сигай* «тубык яки бәкәл сөяге», якут. *сыаҒай* «сака, шака» һ.б.; к. рус. диал. *сақ* «Кала» уенында аткы (бита)». К. **Шәмәй**.

**САГЫЗ** «сера (*жевательная*)» — гом. тк. *саҒыз, саңыз, сақыз* «сагыз, чәер, сумала» — бор. гом. тк. *саккырь* «сагыз, чәер» сүзеннән (к. **Чәер**); к. бор. тк. *сақыр* «сагыз, чәер» (МК), чув. *сухăр* «чәер, сагыз».

**САГЫЗАК** «крупный вид шмеля» — бор. *сагыз -Ғак* «чагучы» сүзеннән, *сагыз- // сагыд-* «чагу, кадау» фигыленнән, гом. тк. *сак- // чак-* «чагу, кадау» тамырыннан; к. диал. *саҒадак* ~ башк. *саҒыдақ* «шөпшә, сагызак», тув. *шаашкак* «сагызак, чуар кигәвен», хакас. *сасхақ* «сагызак», *сас-* «кадау, тишү, чагу».

**Сагызак** сүзен **сагыз** «чәер» белән бәйләп аңлату да игътибагар лаеклы.

**САГЫМ** «мираж; фантазия» — кк., ккк. *сагым,* н., кум. *сагын-* id. — бор. *сақ-, саҒ-* «уйлау, күзаллау, фикерләү» сүзеннән. К. **Сагыш**.

**САГЫШ** «тоска, печаль» — гом. тк. *саҒыш, сақыш* «уй, фикер, ният» ~ бор. тк. *сақ- // саҒы-* «уйлау» (шуннан ук *саҒы-н-у*); чаг. ш. ук бор. тк. *сакынч* «кайгы» (МК), бор. чыгт. *сансыз-сақышсыз* «исәпсез-сансыз» (Боровков), Чаг. **Сан**.

**САЕН** *послелог* «еже-; каждый» — гом. тк. *сайын,* чув. *сайран* «саен», уйг., бор. тк. *сайу* «саен, санап» — бор. тк. *са-, саҒы-* «санау» фигыленең адвербиаль формасыннан (*сай-у, сай-ун* «санап, санаярак») дип хисапланыла (Рамстедт, Гобэйн).

**САЕСКАН** «сорока» — тат. диал. *сашысқан, сәwескән, саурыскан,* гом. тк. *саҒысқан, сақсаган, саҒызган, саҒырткан* һ.б. саескан авазын белдергән *саҒыр, сақыр* тәкълиди сүзеннән. Мар. *шогертем* «саескан» бор. болгар. **саҒырткан* «саескан» сүзеннән булса кирәк [*а > о*], [*с > ш*]. К. чыгт., кырг. *саҒызҒан,* алт. *саҒысқан* «саескан», кб. *чаканжиқ,* осетин. *зәҒәнзәҒ* «саескан», монг. *сагаҗигай* (бор. тк., чыгт. *чиҒай, җиҒай* «кош»), бурят. *шаазгай, шагагай,* якут. *саҗагай* «саескан»; удм. *сезь,* эрзя. *сезьган* «саескан» төрки телләрдән.

**САЗ** «болото» — гом. тк. *саз,* бор. тк. *саргъ* «саз, былчырак» сүзеннән; к. чув. *шур,* башк. *шар* «камышлы сазлык» ~ госм. *саз* «камыш курай»; венг. *scar* (сар) «саз» — бор. тк. телләрдән. К. **Сарут, Сазан**. К. Әхмәтьянов, 1991: 113.

**САЗАН** «сазан» — бор. тк. **сарҒаң* «сазан» сүзеннән (к. украин. *шаран* «сазан» бор. тк. телләрдән), тамыры *саз, сар* (к. **Саз**) яки *саз-а- < *сар-Ға-* «агару, сазау» (Рамстедт); тув. *сазан* «тапталган, таушалган», тат. диал. *саза-* «озак вакыт яшәү; саргаю», чув. *сара-* «сазау».

**САЙ** «мелкий, неглубокий» — гом. тк. *сай* «сай, сайлык, сай елга, коры елга, коры елга үзәне, вак ташлык» сүзеннән; к. ш. ук азәрб. *чай* «елга», чыгт., кк., тув. *сайыр,* монг. *сайир* «коры үзәндәге вак ташлык» ~ тат. *саез* «сай җир».

**САЙГАК** «сайгак». Тат. диал (мишәр) *сайгак, сайак* «азгын, ялгыз йөрүче», кк., кырг., кум., ткм. *сайак,* мāр. (төрки телләрдән) *сайак, шайак* «сукбай, качак; таркалган, көтүчесез;

ялгыз, көтүдән читтә; ят, чит», алт. *сайаң* «сирәк», кырг. *сай* «тиз йөрүчән; шәп, чарыс». Сүзнең нигезе бор. *сай-*, *сайак-* «таркалу, таралып качу; сизгер булу».

**САЙГАУ** «настил, накат, жерди, положенные или прибитые рядами» — бор. тат., тув. *сайға-* «төзү, сайгау салу» фигыленнән (гом. тк. *сай* «рәт, тезем»); к. диал. *сайғак* «идән, түшәм, түшәмә, ихата», иске тат. *сайғак* «идән тактасы», алт., тат. диал. (тау ягы) *сай* «рәт, тезмә, чабата шакмаклары», *сай-* «тезү», чув. *сай* «сайгау, терәк», *сайхах, сайхалăх* «сайгауга ярарлык агач» (бу сүзнең көнч. тк. сай- «чәнчү» сүзе белән бәйләнеше шикле.) К. Әхмәтьянов, 1989:139.

**САДАК** «колчан» — гом. тк. *саадак, сағадак, сағайдак,* монг. *саадағ,* «сайдак, ук» — Ж.Ш.Дондуков фикеренчә, монг. *саа-, сағa-* «ук ату» фигыленнән. Н.Гумилев фикеренчә, бор. һунн телендә *сагайдақ* «итек» (< *сағай атақ* «уң итек»?) — чөнки элек укны итек кунычына тыгып йөрткәннәр.

**САЙЛА-У** «выбирать» — мар. *сайла-*, чув. *суйла-*, гом. кыпчак. *сайла-* «сайлау», алт. *сайла-* «чикләвек чистарту», чыгт. *сайла-* «санау, санга-исәпкә кертү, сайлау» — тат. диал., гом. тк. *сай* «сан, исәп» сүзеннән, аның «аз санлы, яхшы сыйфатлы» мәгънәсеннән; к. кар. *сайла-* «яхшыга исәпләү», *сайлы* «исәпле, сайланган», гагауз. *сайгы* «хөрмәт» һ.б. *Сай, сайы* «сан, хөрмәт» тамыры бор. тк. *са-* «санау, санлау, исәпләү» фигыленнән килә, шуннан ук тат. *саен, сан. сана-у, сагын-у,* сагыш сүзләре дә ясалган. К. **Сайра-у**.

**САЙРА-У** «петь (*о птицах*); говорить, словно петь (*о человеке*)» — гом. тк. (күп телләрдә сирәк кенә очрый) *сайра-* «сайрау, шыкырдау, чөкердәү» бор. тк. *сайыр* «мактау жыры» сүзеннән (ихтимал, *сай йыры* тәгъбиреннәндер, ягъни «мактау жыры» була). Бор. тк. *сайра, сайру* «сандугач», монг. *сайр-ха* «мактану». К. **Сайла-у.**

**САК** «осторожный; охрана» — гом. тк. *сак, саг* «сак, акыллы, айнык, сау, исән» — бор. гом. тк. *са-ғ* «саклана торган» сүзеннән, шуннан ук *сау* (к.).

**САКА** «мыт (*болезнь лошадей*)» — гом. тк. *сақа, саңа* «сакал, сакал сыман нәрсә» сүзеннән, шул ук нигездән к. **Сакал, Сакау, Саңак, Талак;** к. тат. диал. *сақал* «ияк, ияк астына киелә торган бизәнү әйбере», *сақа* «агачның түбәнге ботагы», башк. *һағак* «агачның иң түбәнге ботагы, балта сакалы», чыгт. *сақа* «балта сакалы», кк., ккк. *сағa* «елга тамагы. күл бугазы, сөңгенең сапка кидертелә торган урыны», чув. *саха, сака* «сака», кк., куман. *сакау* «телсез, сакау (бугазы шешкән), колыннарның муен астындагы шеш — сака», башк. *һақау* «сака, сакау», чыгт., госм. *саңақ* «икеле ияк», бор. тк. *сақақ* «яңак, ияк» (МК), алт. *саңат, саңый* «икеле ияк, саңак, муен шеше, колак төбе бизе»; болар барысы да, безнеңчә, сака шешен, саңакны, ике катлы иякне, агач гөмбәсен, рәт-рәт торган чыршы ботакларын борынгы календарь тактасына һәм муенса календарьга охшатудан килеп чыккан. Ул календарь *саңка* яки *сағақ* һәм *саңкал* (к. **Сакал**) дип аталган (*сан.* «сан, хәтер») сүзеннән. Борынгылар календаре турында.

**САКАЛ** «борода» — гом. тк., монг. *сакал, саккал* «сакал» сүзеннән, гом. тк. *саңа // саңа* нигезеннән (к. **Саңа**) монг. аффиксы *-кал, -гал* кушылып ясалган. Ләкин нәкъ менә монголларда сакалбайлар сирәк. Ихтимал, тат. һ.б. сакал «кат-кат муенса, әмәйлек» беренчел мәгънәдәдер. К. **Сака, Саңак.**

**САКАУ** «косноязычный; шепелявый» — кк., куман., чыгт. һ.б. *сакау* «телсез, сакау, сака» сүзеннән, *сака // саңа* нигезеннән (к. **Сака**); чаг. тув. *саңга* «ачыгавыз, сантый».

**САКСАВЫЛ** «саксаул» — бор. тк. (чыгт.) *саксагыл, саксагул* «саксавыл», бор. *сакса-* «коргаксу» сүзеннән; к. чыгт. *сахса*, якут. *сакса* «корыган, коргаксыган, кытыршы, чытыр», тат. диал. *суксаул* «коры чытырлык». Чаг. **Чагыл**.

**САЛ** «плот» — гом. тк. *сал* «сал, түшәмә, сайгау, күпер, паром» — бор. гом. тк. *сала, сал-аг, сай-ла-г* «тезмә, бүрәнәләр тезмәсе» сүзеннән (*сай-* «төзү» фигыленнән булса кирәк, к. **Сайгау**); к. тат. диал. *сала* «тезмә, чабата тезмәсе», себ. тат., кк., кырг., алт., хакас., уйг. (диал.) *сала* «бармаклар теземе, елга кушылдыклары», иск. тат. *сала* «тау сыртыннан рәт-рәт тармакланып киткән кечерәк сыртлар», башк. *һала* «сал, тезмә», бурят. *һала* «идән, тезмә, сайгау, сал», якут. *ал* < *сал* «карап, сал», алт. *салтым* «такта күпер, идән». К. **Салдау**.

**САЛ-У** «класть, положить, кидать» — гом. тк. *сал-* «салу, кую, селкетү», тат. диал. *сал-, сәл-*, чув. *сул-* «селкетү, тирбәтү; янтаю» һ.б. Гомумән, бу фигыль күп мәгънәлелегe белән аерылып тора. Тамыры — тасвирый яңгырашлы *сал // тал // дал // дйал // йал // җал // чал* теземе. Бу тамырдан төрки телләрдә һәм татар телендә бик күп сүзләр ясалган. К. **Җил**.

**САЛА I** «деревня, село» — рус. *сёла* «авыллар» сүзеннән булса кирәк (Радлов), Кыпчак телләрендә бу сүз XIV гасырдан бирле билгеле.

**САЛА II** «отроги гор; ряд; что-нибудь, положенное рядом» — к. гом. тк. *сала, салаға,* чув. *сула* «тармак, бармак арасы, бармаклар, ботаклар, тезмә, балык саңагы» һ.б. Шуннан ук тат. диал. *сала, салаң* «суга батырылган кайрылар теземе». К. **Сал, Салабаш, Шалаш.**

**САЛАБАШ** «хмель, собранный вместе со стеблем» — диал. *саламбаш* «салабаш» < *салаң башы* «бер тезем». К. **Сала**.

**САЛАМ** «солома» — рус теленнән.

**САЛДАУ** «мостки у берега, дебаркадер» — *саллау* (сал кебек нәрсә ясау) сүзеннән.

**САЛКЫН** «холодно; морозно» — гом. тк. *салкын*, монг. *салхи(н)* «җилле, җиләс, салкын, суык» сүзеннән, бор. тк. *салкы-* «көчле җилләү» фигыленнән; сүзнең тамыры төрки һәм монгол телләрендә киң таралган *сал // тал // дал // йал* «җил, җилләнү» тасвирый яңгырашлы сүз (к. **Җил**); к. якут. *салгый-*, кырг. *шалкы-* «җилдә дулкынлану, җилпенү, җил исү».

**САЛМАК** «неторопливый; увесистый» — гом. тк. *сал-* «салу,

кую, йөкләү» сүзеннән (*сак-мак*); к. кк. *салмақ* «авырлык, терәк, салым».

**САЛПЫ** «обвислый; вялый; медленный» — гом. тк. *салп-, салб-* «салпы», гом. тк., монг. *сал // тал // дал // йал* тамырыннан (к. **Җил**): *сал* тармагына **п** детерминанты ялганып ясалган нигез (*сал-п-*, чаг. *тал-п, йал-п, җил-п*); шуннан ук *салпай-у, салбыра-у, сәлберә-ү, шәлперә-ү;* к. госм. *салпа* «салпы, шәлперәйгән, шиңгән», кк. *салпы* «асылынып торган», хакас. *салбаңда* «сәлберәү»; чаг. бурят. *салбуу* «развязный», монг. *салбақ* «ялкау, салпы», *салпай-х* «салпаю». Чаг. тат. диал. *салқы,* үзб. *салқа* «салпы, җилфердәп торган». К. **Салкын**.

**САМАН** «саман» — ясалышы ачык түгел, кк. *сабан,* үзб. *саман* «салам» сүзеннән булса кирәк (саман — кирпеч алу өчен балчыкка салам катыштырып изелгән измә.

**САН I** «число, численность; имя числительное; уважение» — гом. тк. *сан*, бор. гом. тк. *саң* «сан» — бор. гом. тк. *са-, сағы-* «санау, хисаплау, уйлау, фикер йөртү» тамырыннан, шуннан ук к. *сағын-у, сағыш, саен, сайла-у, сан-у;* к. ккк., ткм. *са̄н* «сан», чув. *сум,* венг. *szam* «сан», чув. *су-* «санау, сану, хөрмәт итү, сихерләү» (Ашмарин), якут. *а-х-, са-х-* «санау»; чаг. көнч. тк., госм., чыгт. *сай-* «санау, уйлау, сөйләү».

*Сан* сүзеннән *сан-у, сана-у* сүзләре, соңгысыннан *санак* «исәп-хисап, хисаплау; исәп-хисап язылган язу» сүзләре ясалган.

**САН II** «часть тела» — гом. тк. *сан,* себ. тат., алт. *саң* «бот, оча», чаг. *сын.* **Сан** I сүзе белән баглы булуы ихтимал.

**САНА, СӘНӘ** «частица вежливой просьбы» — (*карасана*! «смотри-ка!»), тк. *сана, сәнә* id. — бор. тк. (тат. диал. *сәңа, саңа* «сиңа» сүзеннән килә (к. **Син**); *сиңа* сүзенең кисәкчә функциясендә кулланылу очраклары татар телендә хәзер дә очрый. *Мәс.*, «бармый ни — барды ди сиңа; шулай ди сиңа, түгел шул» һ.б. К. кк. *саңа, саңан* «сиңа».

**САНАТ** «сенат, вельможа» — рус. *сенат* «сенат, патшаның киңәшчеләр советы» сүзеннән; к. чув. санат «сенат, санат».

**САНДАЛ** «наковальня» гом. көнб. тк. сандал «сандал, утыргыч; өстәл» (тат. диал. *саңдал* «диван») — фарсы. *сандал* «сандал бүкәне, сандал беркетелә торган өстәл, сандал агачы» (санскрит телендә candana дигән агач, бор. тк. *чиндан*) сүзеннән; к. үзб. *сандан* «сандал», чыгт. *санд* «сандал», гар. *синдал* «сандал» (төрек иленнән китерелә торган һәм сандал агачыннан эшләнгән кызыл буяу). Шуннан *сандар* «иләнгән тирене буяу өчен кулланылган состав».

**САНДУГАЧ** «соловей» — башк. *һандуғас,* чув. *сантукасҫ, шантукасҫ,* мар., удм. *сандугас*, уйгур. *сандугач, сандувач,* алт. диал. *сандык* һ.б., бор. сугди. *зант воч* «татлы аваз» сүзеннән килә; төрки телләрдә бу сүз *-ғач* кечерәйтү кушымчасы белән ясалган сүз дип аңлатыла.

**САНДЫК** «сундук» — көнб. тк. *сандук, сандык,* фарсы. *сандук* «сандык» сүзеннән, асылда, һинд телләреннән килә.

**САНТЫЙ** «дурачок; болван» — бор. *сант-ыг, санту-г* сантый, тилергән» сүзеннән, нindидер *сант-, санты-* «исәрләнү, саташу, һуштан язу» фигыленнән. К. кб. *сант* «сантый», кум. сант «апатия», башк. *һандыр, һандырак* «сантый», тат., кк. һ.б. *сандыра-* «саташу».

**САҢАК** «жабры» — бор. *санғақ* «такта календарь, шуңа охшаш нәрсә» сүзеннән; к. чув. *сухал*» сакал, саңак, муенсалар теземе», ккк., куман *сағак* «саңак, колак тирәсе бизләре», тат. диал. *саңак,* «көтүченең календарь һәм чут таягы (яисә тактасы)». К. **Сака**.

**САҢГЫРАУ** «глухой» — *саң-гырау* (чаг. *аңгырау, миңгерәү*) id. сүзеннән, *саңғыр-а-* «саңгыраулану» фигыленнән, нindидер *саңк // сак* тамырыннан; к. бор. тк. *саңрағу, саңғыраг* «саңгырау», госм., кырг. *сағыр,* чыгт. *сақыр* «саңгырау»; к. тат. диал. (Урал) *сақ, сақбай* «саңгырау».

**САП** «ручка, рукоятка» — гом. тк. *сап* «сап, сабак» сүзеннән (шул ук нигездән *сабак* < *сап-ақ*); к. башк. *һабак* «сап», ккк. *сабақ* «сабак, җеп (*сап-лам*)», чув., алт. *сапак* «тәлгәш, сабак, чачак» ~ чув. *сапака,* хакас. *сабаға* id.

**САРАВЫЧ** «женский головной убор» — тат. диал. *салаус, сараус,* удм. *сарауц* ~ н. *сылауш,* бор. тк. *сарағуч* (> фарсы, гар. *сарағуж*), бор. монг. *сарабчин,* эвенк. *сарапчу* «төрки һәм монгол хатын-кызларының борынгы баш киеме» монг. *сараба-, сарба-* «тузгу, җилфердәү» фигыленнән булса кирәк.

**САРАЙ** «дворец; сарай» — фарсы. *сарай., сараи* «өй, сарай», бор. фарсы. *sarai* < *drai* < *thraiti* «өй, корылма» сүзеннән. Русча *строй* сүзе белән тамырдаш.

**САРАН** «скупой, скряга» — ясалышы һәм тамыры ачык түгел; к. чув. *саран* (татар теленнән булса кирәк), алт., уйг., кк., бор. язм. *саран* «саран; сантый», *саран, сараң* «авыру (душевнобольной), сырхау (аз ашый торган)». Чаг. госм. *сайры, сайран* «авыру, зәгыйфь».

**САРАНА** «саранка» — чув. *сарана*, башк. *һарына, зәрәнә,* тат. диал. *сәрәнә* «сарана» — монгол теленнән: монг. *сараана* «сарана, суганча», *сараанаг* «күкәй капчыгы (мошонка)».

**САРАНЧА** «саранча» — куман. *сарынчка*, бор. тк. *сарынча* «чикерткә», *сарыг* «сары» сүзеннән булса кирәк.

**САРПАТ** «воспитанность (*девушки*)» — бор. болгар телендәге *сарпат* «кызлар яулыгы, кызлар такыясы» сүзеннән. Ул торабара «кызлык намусы» мәгънәсен алган, төптә бу сүз фарсыча *сәрбанд* «башбау, кашбау», *сәр* «баш», *банд, бәнд* «бәйләвеч» сүзеннән, шуннан ук тат. диал. *сарпан*, чув. *сурпан*, мар. *шарпан* «кызлар яулыгы, кызлар алъяпкычы»; рус. *сарафан* сүзе дә болгар теленнән.

**САРУ: сару кайнау** «изжога» — бор. тк. *сар-ығ* «сару» сүзеннән, тамыры *сар-*; к. алт. диал. *саруу,* тув. *сарыг* «сару», бурят. *шара* «сару».

**САР-У** «обступать; мотать; облепить; окружать» — гом. тк. *сар-* «сару, урау» сүзеннән; к. госм., кырым. *сар-* «сару, урау», хак.. *сары-* «сару».

**САРУТ** «пырей» — бор. болгар. **сар уты* «саз үләне» сүзеннән булса кирәк (к. чув. *шур ути* «сарут, саз үләне»: *шур* «саз», *ут* «үлән, ут»). Икенче яктан, *сары (тамырлы) ут* (?).

**САРЫ** «желтый» — гом. тк. *сары, сарығ* «сары, аксыл».

Бу сүз кайбер төркиләрдә озын сузык белән әйтелә: *саары*, шуннан чыгып аны монг. *сар* < *сағар* «ай; якты; сары» сүзе белән чагыштыралар. Моны *сары (сар)* сүзенең татар сөйләшләрендә һәм чуваш телендә «матур, нурлы» мәгънәсе булуы да куәтли.

**САРЫК** «овца» — чув. *сурах, сорăх*, мар. *шорык, шарык*, башк. *һарык* «сарык», тат. диал. *сарык* «саулык бәрән» — бор. *сағрық* «савым сарык» сүзеннән (савылмый торган сарык — *куй* сүзеннән аеру өчен әйтелгән). Сүзнең тамыры *сағ-* «саву».

**САРЫМСАК** «чеснок» — удм., мар. *сарымсак*, гом. тк. *сарымсақ*, бор. тк. *сармусак, самурсак*, кб. *сарсмак* id., тк. *сарсы-* «көчле ис аңкыту» сүзеннән булса кирәк. К. **Сассы.**

**САСЫ, САССЫ** «вонючий» — гом. тк. *сасы, сассы, сассык*, көнч. тк. *сарсыг* >> чув. *шăршă* «сассы, күңел кайтаргыч» ~ тат. *сассы-* < уйг. һ.б. *сарсы-*, кырг. *саңырсы-* «сассу (сасу)» фигыленнән. Сүзнең тамыры тат. диал. *сар* << кырг. «үләксә»; шуннан ук тат. *сарыч* < *сарычы, сарчы* > рус. *сарыч* «үләксә карчыгасы (стервятник)».

**САТАШ-У** «бредить» — мар., удм., *саташ-* id.; күп тк. телләрдә бу сүз үзгә мәгънәдә очрый: н. *сатас-* «буталу», тк., азәрб. *саташ-* «очрашу; адашу; һуштан язу», бор. тк. *сатғаш-* «чатлашу, буталу» (*сата-, сатга-* «чатмашу» сүзеннән).

**САТ-У** «продавать; торговать» — гом. тк. *сат-* id. ~ скр. *sartha* «сәүдәгәр».

**САУ** «здоровый; невредимый» — чув. **сувă, сывă*, мар. *шу*, гом. кыпчак. *сау* < гом. тк. *сағу* «сау, бөтен» > тат. һ.б. *сақ*, чув. *сыхă* «сак». Сүзнең тамыры *са-* фигыле дигән фикер бар.

**САУЛЫК** «ягненок; ярка» — бор. *сағлык* «савыла торган» сүзеннән. Чаг. **Сарык.** К. Әхмәтьянов, 1989:70.

**САУРЫЙ** «шагрень» — тат. диал. *сауры*, гом. тк. *сағыр, сағыры*, монг. *сагари* «ат янбашы, ат савыры» сүзеннән; к. рус. *сары* «ат тиресеннән тегелгән итек», *саврьі* «ияр күне» (Даль). Рус. *шагрень* < француз. *chagrin* < төрек., бор. тк. *сағрын, сағырын* > иске тат. *савырын*, тат. диал. *сбран*, чув. *сăран*, мар. *сурон*, удм. *суран, сърон, сӱрон*, кк. диал. *шегирен*, мар. диал. *шарга* id., ихтимал, бор. болгар җирлегеннән таралгандыр.

**САУСЫЗ** «нездоровый» — кум. *савсуз*; мар. *сосыр, сӧсыр*, удм. *сӱсӱр-гэм*, чув. *сусăр* id. *Сау* сүзеннән регуляр булмаган ясалма бор. тат. (кыпчак) теленнән болгар теленә ярымкалька булып кергән.

**САУ-У** «доить» — чув. *су-* < гом. кыпчак. *сау-*, гом. тк., бор. тк. *сағ-*, монг. *сағa-, саах* «саву». К. **Саулык, Сарык.**

**САХРА, СӘХРӘ** «простор; поле; степь» — гар. *сахәрә-т-үн* «кыя, таулар урыны» сүзеннән (шуннан ук *Сахара*).

**САЯК** «редкий; неожиданный» (в парных словах *сирәк-саяк* «изредка», *саяк-сандырак* «неожиданно») — алт., ткм., кырг., кк., ккк., н., кум. уйг. *сайақ* «ялгыз кеше, сукбай; буш, сирәк; ялгыз айгыр», *саян* «сирәк», алт. *сайа-* «сирәкләнү», бор. тк. *сай* «сирәк, аз санлы» сүзеннән. Мар. *сайак* «таркалган, көтүчесез, ят» — төрки телләрдән. К. **Сайгак.**

**СӘБӘЛӘЙ** «ряженый» — тат. диал. *сепел, сәбәләй, сәбәләү, сәбалдәй* «озын кием; шундый кием кигән кеше» — алт. *сәбәлдәй* «көбә кигән шаман». Себ. тат. *сәуал* «сәвәләй», кб. *зибил тон* «кешене күренмәс итә торган тун, шаман туны», бор. тк. *сәбил* «панцирь, сугыш киеме» һ.б. гом. тк. *сәп* «сип, кыз тарафыннан егет ягына бирелгән корал-ярак» сүзеннән булса кирәк. К. **Сип.**

**СӘБӘТ** *диал.* «большая клетка; ларь» — чув. *семет* «ашлык тутыру өчен агач бүрәнкә» — кырг. *себет*, гагауз., кырым. *сепет*, тк. sepet «камыш кәрзин» < фарсы. сăпад «зур кәрзин» сүзеннән. Рус. диал. *сапет, сапетка* «кукуруз саклау өчен кәрзин» — төрки телләрдән.

**СӘВӘТ** «грамотность» (*сәвәтле* «грамотный») — гар. *сăвад* «укый-яза белү; кара (чернила); текст; каралама» сүзеннән; *сӯд* «кара булу» тамырыннан. К. **Сәүдә.**

**СӘГАТЬ** «время; часы» — чув. *сехет*, мар. *шăгăт, шагат* н., кар. кум. *сагат*, бүтән күп төрки телләрдә *саат* id. < гар. *саат* «сәгать», төптә «казык» дигән сүз: вакыт багана күләгәсенә карап үлчәнә торган кояш сәгатендә сәгать — унөч казыкның берсе һәм ике казык арасы.

Элегрәк *сәгать* сүзе Урта Идел регионында тик вакыт бәрәмлеген генә белдергән, вакыт үлчәгеч исә тат. *сәгатьләмә* > чув. *сехетлеме*, мар. *сăгăтлăмă, сагатлама* дип аталган. К. ш. ук тат. диал., кк., ккк. *сәт*, мар. *сат, сады* «момент; бәхет; мач килү», тат. диал. *сәтләмә* «уңайлы момент», *сәтлек* «пульс; момент; шундук», *сәтлексез* «тынсыз».

**СӘДӘП** «пуговица» — гар. *сăдăф* «диңгез кабырчыгы; перламутр» сүзеннән. Татарча *сәдәф* варианты «перламутр» мәгънәсендәрәк кулланыла.

**СӘЕР** «странный, чудной; *диал.* экскурсия» — гар. *сăйр-ун* «тамаша итеп йөрү» сүзенә кайтып кала; *сәйяра* «планета», *сәйяр* «күчмә, күчкен», *сәйран* «һава сулап йөрү» сүзләре белән нигездәш.

Бу сүздән бераз үзгәреп себ. тат. *сәел*, үзб. *сайил* «сабан туе, һавага чыгып күңел ачу; язгы бәйрәм; матур көн» мәгънәсе дә килеп чыккан.

**СӘЙЛӘН** «мелкий бисер» — Цейлон утравы исеменнән (бу утрауны Һиндстаннан аерып торган Полк бугазында энҗе табыла).

**СӘКӘЛ** «пежина» — *сакал* сүзе белән бердәй булса кирәк; к. чув. *сакал*, башк. *һәкәл*, госм. *секи, секил*, монг. *сагаларга, сагалак* «бәкәл», тув. *сэгэл* «аяк».

**СӘКЕ** «нары» — тат. диал. *сике*, башк. *һике*, чув. *сикĕ*, мар. *шăгы, шагы* «сәке, сайгаулык, кибән астына куелган күтәртмә; өстәл», кк. *сәкі*, кырг. *сәки*, бор. тк. *секу* «сәке; алачык», *сәки*

«пьедестал», тк. sekä, seki «колонна нигезен утырту өчен таш; балчык сәке», *sekten* «урындык, киртләч». Ихтимал, ин борынгы вариантта тат. диал. *сәйке* «сәке» якындыр; ул вакытта сүзнең тамыры *сәй-* < *сәр-* ~ мар. *сар-, шäр-* (чув. *сар-*), кар. *сäр-*, тк. ser- «җәю» була. Чаг. ш. ук алт. *сäк* «куна тактасы, якут. (тунгус, монг. параллельләре белән) *сэксэ* «утыру өчен аска җәелгән нәрсә».

**СӘЛ** «маленько; тихонько» — мра. *шäгал, шäхал,* чув. *сахал* ~ иске тат., фарсы. *сәһел, сәһәл* > кк., ккк., уйг. *сәл* «әз генә». Икенче яктан к. (Рясянен) якут. *сэл, сәл* «жинелчә», бор. монг. *selde-, selle-* «бераз ял итү».

**СӘЛӘМӘ** «лохмотья» — татар телендә барлыкка килгән сүз: тат. диал. *зәләмә, салама, шалама* «сәләмә, ялбыр», чув. *селеме* id.; элек *сәлә-, сала-* «ертылу, таралу» фигыле булган булса кирәк; к. мар. *шала* «таркалу, пыран-заран», *шалан-* «таркалып яту», *шалат-* «таркату, туздыру» ~ чув. *салан-* «тузгылу, сәләмәләнү», *салат* — «пыр туздыру». Чаг. **Сәлену.**

**СӘЛӘТ** «способность» — гар. *сәляхият* «сәләт, ярарлык булу».

**СӘЛЕН-Ү** *диал.* «качаться, покачиваться» — шуннан *сәленгеч, сәленчәк* «бишек», *сәнгелдәк, сәлгелдәк* «атыну өчен таган». Татар телендә палатальләшү нигезендә ясалган; к. гагауз. *салын-* «таган атыну», кар. *салла-* «селкетү, *чайкау*», кырг. *салаңда-* «селкенү, тирбәнү», чув. *сол-, сул-* «селкү, таган атындыру», кар., төрек., үзб. диал. *саллан-* «селкенеп тору».

Бу сүз, күрәсең, төрки телләрдә бик күп сүзләр ясауга нигез булган: *сал- сәл-, сел-* «чайкалу, тибрәнү, тирбәлү, селкенү» тамырыннан. К. **Салкын, Салпы, Сәлкәү, Селкену.**

**СӘЛКӘҮ** «вялый, слабый (*о человеке*)» — мар. *сäлкау,* башк. *һәлкәү* «сәлкәү» — гом. тк., монг. *сал // тал // дал // йал* («җилләнү» мәгънәсендәге) символик яңгырашлы тамырның *сал* тармагына [-к-] детерминанты ялганып ясалган нигездән (*сал-к,* чаг. *ялк, елк-*): диал. *сәлге* (мишәр.), *салкы. шалкы* «сәләмә, җыйнаксыз», үзб. *салқа,* госм., кк. *салқы* «зәгыйфь, талгын, салынкы, салпы», чув. *салху* «күнелсез, сәлкәү», госм. *сулку* «зәгыйфь; йомшак». Чаг. диал. *сәлпән, сәлбәгәй, сәлперәк* «салынкы, зәгыйфь».

**СӘМӘН** «денежные средства; капитал» — чув. *семен,* мар. *саман* «байлык, тормыш шартлары» — гар. *сәмән* «хак, бәя, кыйммәт» сүзеннән (төптә бор. мисыр. *смн* «көмеш»).

**СӘМИХ** «янтарь; прозрачный» — фарсы. *сәмғ,* гар. *самғ* «сәмих, үтә күренмәле сумала» (шуннан төрек. *замк* «келәй, җилем») сүзеннән. Удм. *сюмык* «пыяла савыт» < болгар. **самык* «сәмих».

**СӘМРӘҮ** «Симург» (*сказочная птица*) — фарсы. *Сенмург* «Сәмрәү» сүзеннән (асылда *сиәһмург* «кара кош» дигәннән); к. иск. әд. *сәмруғ,* диал. *сәмер* «сәмрәү». Бор. рус. *семарглъ* «сәмрәү» — бор. скифчадан (Абаев).

**СӘНГАТЬ** «искусство» — гар. *сәнга-т-ун* «сәнгать» сүзеннән, *санага* «эшләү, ясау» тамырыннан; шуннан ук әд. *санәга(ть), санигать* «промышленность».



**СӘНӘК** «вилы» — диал. *саник,* кк. *сәнек,* кум., кырг., кб. *сәнэк* «сәнәк» — бор. тк. *сән- // сан-* «чәнчү» сүзеннән, к. чув. *сенкĕ,* морд. (төрки телләрдән) *сянго* «сәнәк». К. **Чәнеч-ү.**

**СӘНДЕРӘ** «полати» — М.Рясянен буенча рус. диал. *середа, средник, середина* «сәндерә, сәндерә киштәсе» сүзеннән. Ләкин Урта Идел сүзе чагылышлары моны бигүк расламый: тат. диал. *сүндери* < *сүндерик,* чув. *сентĕре, сентрей,* мар. *сандра, салдыра, шӧлдравал,* удм. *сэндра, шэндра* «сәндерә; баскыч». Чаг. **Сәрдек.**

**СӘРДӘ** «анчоус; сныть; дягиль» — диал. *зәрдә, сәрәтә, сәрәнә, сәрдәнә* (Идел буе, Пермь), *чәрнә* (Урал), *сәрдәк* id. < фарсы. *зäрде, зäрдена,* (зäрдäк) «алтын-сары буяу; шундый буяу бирә торган үсемлек (зәгъфыран, имбир, рәваж, сәрдә)» күнчеләр теленнән таралган. Тамыры фарсы *зäрд* «алтын». Чаг. себ. тат. *сәртәк* «кишер».

**СӘРДЕК** «полати; настил» — тат. диал. *сәрлек* ~ чув. *сарлык, сарлäк* id., *сар-* ~ мар. *сар-* < *сäр-, сер-* < гом. тк. *сәр-, сәр-* > тат. диал. *сир-* «җәеп салу» (томанны) тарату» сүзеннән.

**СӘРЕНҖЕ** «ткань радужных цветов» — уйг. *сәринҗи,* иске тат. *сарынҗы,* себ. тат., ткм. *сәринди,* чыгт. *саринчә* һ.б. «аллыгөлле, буй-буй тукыма», фарсы. *сарии-н һинди* «һинд сарисе (күлмәге)» сүзеннән.

**СӘРИН, СӘРЕН** «свежий» — төрек, фарсы. *сäрин* id., тув. *сергин* «бодрость», ткм. *сергин* «салкынча» — монг. *сэригун* «сиздерерлек (салкын)» сүзеннән; *сэр-* «сизү» фигыленнән (Рясянен). К. **Сәрмә-ү.**

**СӘРМӘ-Ү, СИРМӘ-Ү** «ощупывать; *перен.* стянуть, красть» — гом. кыпчак. *сәрмә-* id., бор. тк. *сэр-,* монг. *сэри-* «капшап сизү» һ.б. *сиз-ү* сүзе белән тамырдаш.

**СӘҮДӘ** «торговля» — фарсы. «*сäwда* «дәрт, комар; сәүдәакча дәрте» (к. иске тат. *гыйшык сәүдәсе* «гыйшык дәрте»), гар. *сӯд (суғуд)* «көнчелектән кара көю» тамырыннан; *сәүдәгәр* «торговец» — фарсы сүзе (*сäwдакяр* «сәүдә итүче»).

**СЕЗ** «вы» — гом. тк. *сиз, сез* «сез» — бор. гом. тк. **си-рг* «синләр» (*си* «син», *-р* күплек кушымчасы) формасыннан дип хисапланыла; к. чув. *эсир* «сез», бор. хорэзм, *сäр* «сез».

**СЕЛӘГӘЙ** «слюна» — гом. тк. *сүз;* хакас. *силегей,* кк. *силекәй,* алт. *чиләкәй, силәкә* «селәгәй, төкерек», якут., чыгт. *сүләгәй* «селәгәй, сүл», уйг. *шӧлгәй* «селәгәй», азәрб. *селик* «селәгәй, сүл» — бор. гом. тк. *сул // сил* «сүл, селәгәй, сут» тамырыннан (к. **Сүл**); к. ш. ук монг. *шилүсүн,* бурят. *шүлүсү* «селәгәй», эвенк. *силәксә,* маньчж, *силэнги* «чык, селәгәй» ~ удм. *сялзем,* морд. *селгэ,* фин. *sülhe,* рус. *слю-на,* бор. рус. *сли-на* «селәгәй, лайла» грек. *салион* «селәгәй».

**СЕЛӘҮСЕН** «рысь» — гом. тк. *силәусен, сүләусен,* кырг. *сүлӧӧсүн* «селәүчән» сүзеннән; асылда, монгол сүзе булса кирәк (*-сүн* кушымчасы!); к. монг. *сүлӧсүн, шүлүсүн, шилүүс* (>чув. *сӳлевеҫ*) «селәүчен». К. ш. ук атт. диал. *сүлән* «селәүсен».

**СЕЛ: Селке-ү, Селек-ү** «взмахивать *чем-л*». -чув. *селте-,* гом. кыпчак. *силтә-,* кум. *силлә-* төрлечә селкенүне белдергән *сил //*

*сәл // сал* тамырыннан. Тат. диал. (мишәр.) *селдә-* ~ кб. *силдэ-* «ташлау, ыргыту».

**СЕЛТЕ** «щелочь» — кк., ккк., н. *силти*, башк. *һелтә* «селте», чыгт. *силти* «карабарак дигән дәва үләненең көле һәм селтесе» (Радлов), алт. *шылты* «селте калдыгы» — гом. тк. *сүүл-, сөөл* «сөзелү» фигыленнән ясалган исем булса кирәк (ягъни селте < *сөлте* < *сүүлти;* чаг. *сөзенте, юынтык, калдык*); к. монг. *шүлт*, бурят. *шүлтэ* «селте, ылыс суы». Чаг. чув. *сĕлте, сĕлкĕш* «селте».

**СЕМ, СӨМ** «чувство; ощущение» — тат. диал., башк., кк. *шым* «тып-тын» сүзе белән тамырдаш булса кирәк; к. хакас. диал. *сым* «тын, тынлык» ~ тунгус. *сим* «тын гына», *сим-сим* «тып-тын». Чаг. ш. ук монг. *сэм* «тын гына».

**СЕМӘК, СӨМӘК** «наконечник стрелы, штырь; острая верхушка шапки» — бор. тк. *сӧби*, госм., тув. *сүбү* «очлы нәрсә, ук очы» сүзеннән булса кирәк. Чаг. мар. *цымак* «ук очы», алт. *сумун* «ук очы», монг. *сумун* «ук; ук очы».

**СЕҢӘЛ** «жидкий (*напр., о тесте, супе*)» — мар. *шеңал* ~ чув. *шăнкал, шăнкан* ~ себ. тат. *шенкән*, бор. монг., бор. тк. *синкэн* «сыек, сыекча, сеңәл», иске тат. (Будагов) *шиңәлмәк, шинкәлмәк* сыеклану». *Шиңэн* «сыек, сирәк» сүзе тунгус-маньчж. телләрендә дә очрый, димәк, ул шактый борынгы сүз. К. **Сең-ү.**

**СЕҢГЕР-Ү** «сморкаться» — госм. *сүмкүр-*, тув. *сиңмир-*, кк. *сиңбир-* «сеңгерү». Төрки сүзлекләрнең күпчелегендә бу сүз юк. *Сеңгер-* тәкълиди сүзләрдән фигыль ясый торган *-гыр // -гер, -кыр//-кер* аффиксы ярдәмендә ясалган. Нигезе бор. тк. *сӧмүк, сүмүк* «маңка».

**СЕҢЕЛ** «младшая сестра» — гом. тк. *сиңил, сиңли* «сеңел», чув. *шăнкăл, шăллă* ~ мар. *шольо, шоля* «энекәш», Себер төркиләрендә *сиң, сыйың* «сеңел, балдыз, кече кардәш», удм. *шыднар* ~ *шыгнар* «ирнең энесе», якут. диал. *һиңил* «яшь, бала гына». Бор. төп сүз *сиң угыл* «яшь бала» булса кирәк. Чаг. кар. *силли* «кыз бала».

**СЕҢЕР** «сухожилие» — мар. *сыңыр*, удм. *синыр*, чув. *шанар*, гом. тк. *сиңир*, госм., бор. тк. *сүңүр*, себ. тат., кар., азәрб. *сыңыр* «сеңер, сыйрак» (к. **Сыйрак**). Бу сүзне М.Рясянен *сең-ү* фигыле белән бәглый. К. **Сең-ү.**

**СЕҢ-Ү** «впитываться; усваиваться» — гом. тк. *сиң-*, Себер төркиләрендә *сүң-*, бор. монг. *сингэ-*, монг. *шиңгэ*, бурят. *шэңгэ-* «сеңү, бату, кереп югалу» ~ мар. *шыӈ-, шың-* «сеңү, сыешу, сыеп бетү». Төрки телләрдә *сиңир-* ~ азәрб. *сыңыр-* «сеңдерү» сүзе очрый. Шул ук *сиң* тамырыннан чув. *шăн-* «сеңү, югалу, туну» һәм *шăн* «туң, суык» сүзе дә ясалган булса кирәк. Тармакланган бу тамырдан *сеңәл* (к.), *сеңер* (к.) сүзләре дә ясалган дип уйларга нигезләр бар. К. **Сый-у.**

**СЕРӘЙ-** «столбенеть, остолбенеть» — к. кырг. *серей-, сырай-*, тув., хакас. *сырай* «серәю», кк. сырай-, сырый- «ялангач йөрү, серәю», тув. *сырга-* «ялангачлау» — бор. тк. *сыр* (тат. шыр) «ялангач» сүзеннән. К. **Сырган, Сырғавыл, Сызғавыл, Сызған-у.**

**СЕРКӘ I** «уксус» — гом. тк. *сиркә/серкә* — фарсы. *сирка* «серкә» сүзеннән.

**СЕРКӘ II** «гнида; пыльца» — гом. тк. *сиркә*, бор. язм. *сиркэ* «серкә» — беренчел мәгънәсе татар телендә сакланган «башак чәчәге» булса кирәк; к. чув. диал. *шырга*, мар. *сырка* «башак серкәсе», бурят. *шэрхэ* «мал бете, талпан», *шэрхы-хэ* «тырпаеп тору». Чаг. **Сырга, Сиб-ү.** К. **Сипкел.**

**СИГЕЗ** «восемь» — гом. тк. *сегиз, сәкиз, сәккиз* «сигез» — бор. тк. **сәккиргь* «сигез» сүзеннән (к. чув. *сахăр* «сигез»); чаг. **Тугыз.** К. **Сиксән.** К. Әхмәтьянов, 1988: 108—117.

**СИДЕК** «моча» — бор. тк. *сидек* «сидек» — бор. *сид-, сиҙ-* «сию» сүзеннән. Чаг. чув. *шар-, шăр-* «сию» ~ монг. *сари-, шээ-.*

**СИКӘЛТӘ** «ухаб, выбоина» — диал. *сикәлте* сүзеннән үзгәргән — диал. *сикалә-* «сикергәләү, тирбәлү» фигыленнән, бусы исә *сикә-* «тирбәлеп сикерү» фигыленең интенсивлык формасы; к. чув. *сикеле-* «сикеренү», *сакăлта, сикелте* «сикәлтә, сиртмә», *сик-* «сикер-ү» ~ төрек. sek- (*сәк-*) id.

**СИКСӘН** «восемьдесят» — бор. *секиз он* «сигез ун» сүзеннән (Мәхмүт Кашгарый шулай аңлата); к. тат. диал. *сигезән* «сиксән», көнч. тк. *секиз он* «сиксән».

**СИЛӘ, СИЛЛӘ** «пружина; рессора» — к. чув. *силе*, мар. *сила* «силә, аса», кум. *силлев* «селкү, бишек тирбәтү», тат. диал. *сәллә-, сәл-*, чув. *сул-, сол-*, гагауз. *сал-* «тирбәлү» фигыленнән.

**СИМЕЗ** «жирный, тучный (*о человеке*)» — гом. тк. *семиз, сэмиз* «симез» — бор. гом. тк. **сәмиргъ* «симез, симерү» сүзеннән. Сүзнең тамыры монгол телләрендә сакланган *сэм* «эчмай». К. **Симер-ү.**

**СИМЕР-Ү** «жиреть» — чув. *самăр-* < болгар. **сәмер* ~ гом. тк. *семир* «жиреть» — ниндидер бор. гом. тк. *сэм* «май» сүзеннән; к. бор. монг. *семеҗи* «эчмай» (Зәмәхшәри), эвен. *хэмэх-эк* «май» < тк. **сэмэгэк* id. К. **Симез.**

**СИН** «ты» — гом. тк. *сен, син, сэн* «син» < бор. гом. тк. *си* «син» сүзенә аныклагыч *-н* кушылып ясалган сүз булса кирәк; к. монг., тунгус-маньчжур. *си* «син». К. **Сез.**

**СИНГӘР** «небольшой, крутой хребет; укрепленная граница» — башк. *һингәр*, чув. *синкер* ~ чыгт. *сәңир*, фарсы. *сăнгар*, н. *сенкер*, кум. *сянгер* — бор. тк. seӊir «тау борыны, махсус өелгән сырт» төрки телләрдә киң таралган сүз. Бу сүзне борынгы Урта Азия (Бактрия) греклары телендәге *синор* «ныгытылган чик» сүзеннән дип уйлыйлар: шундый чикләр куллануны (атаклы «Сәдди-Искәндәр»не) төркиләр шулардан өйрәнгәннәр. Соңрак әлеге грек сүзе төрки телләргә кабаттан кергән: кырым. *сыныр*, кар. *синор, сынор*, төрек. *синир* «чик, чигәрә».

**СИП** «помощь в проведении свадьбы; ремонт» — гом. тк. *сеп, сәп* «кушымта; кияү бүләге, бирнә» сүзеннән. К. диал. (себ. тат.) *сип* «кызга кияү бүләге», чув. *сип* «файда», алт., кк., кум. *сәп, сэп* «өстәмә, кушымта, бирнә, кием-салым», бор. тк. *сэп* «килен малы, җиһаз» (МК). Бу сүзнең нигезе гом. алт. *сэб* «кызның, кәләшнең егеткә биргән сугыш коралы» сүзеннән (шундый корал бирү йоласы булган). К. Әхмәтьянов, 1981:92.

**СИПКЕЛ** «веснушки» — гом. тк. *сепкил, сэпкил* «сипкел» *сип-, сэп-* «сиб-ү» сүзеннән; к. монг. *сэбэх* «сипкел».

**СИРАТ: сират күпере** «мост над адом» — гар. *сирад-ун* «җир асты юлы, сират» — латинча strata «таш юл» сүзеннән (шуннан ук рус. *стратег, эстрада, трасса*) кергән.

**СИРӘК** «редкий» — гом. тк. *сайрак, сейрәк* «сирәк», госм. *сәйрәк,* чув. *сайра* «сирәк» — бор. гом. тк. *сидрә-, сәд-ир-ә-* «сирәгәю, сирәкләнү» фигыленнән, нининдер **сәд* сүзеннән; к. бор. тк. *сәдрә-* «сирәкләнү», *сәдрәк* «сирәк» (МК), азәрб. *сийрәл-*, чув. *ситрел-* «сизрәү, сирәгәю, сирәкләнү».

**СИРЕЛ-Ү** «раздвигаться; рассеяться» — диал. *сир-* ~ чув. *сар* << госм. *сәр-* бор. тк. *сәд-, сәр-* «җәеп тарату, сирәкләтү» сүзеннән.

**СИРТМӘ** «коромысло (*у колодца*); рессоры» — диал. *сикертмә* «сиртмә», чув. *сиктерме, сике* «рессор, сиртмә».

**СИСКӘН-Ү** «вздрогнуть (*от испуга*) — ~ гом. тк. *сэз-* бор. гом. тк. *сәр-* «сизеп алу, тою» фигыленнән (шуннан тат. диал. *сәрмә-ү*).

**СОК-** «жадный взор; боязнь сглаза» — башк. *һок,* чув. *сăхă,* кк., ккк. *суқ,* н. *сук, сык,* куман. *сух,* бор. тк., уйг. *соқ* «комсыз, күнләшүчән» — бор. гом. тк. *соқ* «комсыз караш» сүзеннән булса кирәк; к. үзб., таҗ. *сук* «күз тию», кк. диал. *суқ* «караш, күз», бор. язм. *сук бармак* «имән бармак» (ягъни күрсәтә торган бармак). К. **Сукбай.**

**СОЛЫ** «овес» — алт., хакас., тув. *сула,* кк., саян. *сулу, суул,* кырг. *сулду,* чув. *сĕлĕ (сөлә)* «солы» — киң таралган сүз булса кирәк; к. мар. *соло* «кыяк», ханты. *сол,* бор. кет телендә *сулу, шули* «солы», калм. *сул, сули* «солы», монг. *сули* «кылган».

**СОЛТАН** «султан» — гарәп сүзе. Борынгы төрки дәүләтләрдә *солтан* дип хан балаларын атаганнар. Соңрак *солтан* титулы Төркия императорына гына караган.

**СОҢ** *послелог* «после; *частица* же» — гом. тк. *суң, соң* «арткы як»; шуннан ук *суң-ра* > *соңра* «потом»: *-ра-* бор. урын-вакыт килеше аффиксы.

*Соң* < *суң* тамыры белән *сул* < *сол* сүзе баглы.

**СОРАУ** «вопрос» — гом. тк. *сура-, сур-* «сорау», этимологиясе ачык түгел; чаг. тув., бурят. *сураг,* фарсы. *сурақ* «билге, хәбәр», чув. *сăрав* «игълан».

**СОРНАЙ** «сорнай; зурна» — фарсы. *сурнай* «туй быргысы» сүзеннән (*сур* «туй, җыен», *най* «көпшә, курай»); шуннан ук азәрб. *зурна.* Күп телләрдә очрый.

**СОРЫ** «серый» — удм., мар. *сур,* гом. тк. *сур, суур, суwру,* чув. *сăрă;* чаг., ткм. *сур* — каракүл тиресенең бер төре; рус. *серый* белән бәйле түгел.

**СОРЫКОРТ** «трутень» — к. чув. *сара,* мар. *шури, сури,* удм. диал. *зыры, узыри* «сорыкорт, әрә»; *соры* төс белән түгел.

**СОСА** «челнок» — башк. *һоса,* чув. *ăса, сăса* фин-угор телләреннән булса кирәк; к. мар. *шуша,* удм. *суса, сусо,* коми. *суса,* хант. *супса, супыс* «соса».

**СОСЛАН** «суслон (*копна из нескольких снопов*)» — чув. *ăслан, сăслан* — рус теленнән (< *су-слон* «терәтелмеш»).



**СОС-У** «черпать» — башк. *һоҫ-,* алт., хакас., ткм., бор. тк. *сус-* id.; шуннан тат. диал., ткм. *сусак* «соскыч».

**СӨБӘ** «нижнее (*ложное*) ребро» — диал. *зөбә, зебә, сүмә,* башк. *һебә* — гом. тк. монг. *сүбө, сүмө,* кырг. *сүбөө,* бурят. *һүбөө* «сөбә; көрәштә җинеп чыккан батырга бирелә торган бүләк».

**СӨЕНЧЕ** «подарок; радостное сообщение» — тат. диал. *севенче,* башк. *һөйөнсө,* мар. диал. *сунзы* (болгар теленнән булса кирәк), кум. *сююнчю,* кк. *суюнши,* ткм. *сөвүнҗи* — *сөенече* < *сүйүнүчү* формасыннан, ягъни *сөенеч* < *сүйүнүч* сүзенең III зат тартым формасыннан булса кирәк.

**СӨЕН-Ү** «радоваться, обрадоваться» — тат. диал. *сәвен-,* чув. *савăн-,* гом. тк. *сүйүн-* (угыз телләре линиясендә *сәвен-*), асылда, «шатлыктан үз-үзеңне чәбәкләп сөю» дигән сүз.

**СӨЙ-Ү** «любить; ласкать» — диал. *сәү-ү, сү-* ~ чув. *сав-,* гом. тк. *сүй-* id. угыз линиясендә *сәв-, сәб-, сев-* ~ монг., тунгус. *сэб* «иминлек; шатлык; бүләк; өстәмә (к. **Сип**)» бик күп яңа сүзләр биргән тамыр сүз; тат. телендә шуннан *сөекле (сөек < сөй-ек), сөендекләнү, сөенеч, сөенче < сөенече, сөйдергеч, сөеш-ү* һ.б. сүзләр ясалган. Аларның ясалышы аңлашылып тора, әмма *сөйкем* сүзе ничек ясалганлыгы бик үк ачык түгел.

**СӨЙКӘ-Ү** «прислонять, привалить» — ихтимал, *сөй-ү* белән тамырдаштыр.

**СӨЗӘК** «пологий, отлогий» — бор. *сүвсәк* (к. диал. *сүзәк*) бор. *сүвсә-* фигыленнән, *сүв* «кискенлексез, таманча» сүзеннән; к. чув. *сӳвек, сĕвек, сĕврек* «сөзәк, сүренке», тат. *сүр-ү* < *сүвер-ү* «кызулык белән уйланган нәрсәдән баш тарту» сүзләре дә шуннан. Бу сүзләр бүтән төрки телләрдә сирәк очрыйлар.

**СӨЗ-Ү** «цедить, ловить рыбу; бодать» — бу ике мәгънә борынгы бер «каршылыкны җиңү; кысырыклау» сүзеннән килеп чыккан булса кирәк: бор. тк. *сүз-, сүгүз-, сүк-* «сөзү (цедить, бодать)» ~ чув. *сĕк-* id.; к. ш. ук тат. диал. *сөр-,* чув. *сĕр-,* мар. *шӱр-* «балык сөзү», шуннан *сөрәкә* «бредень» һ.б.

**СӨЙРӘ-Ү** «тащить волоком *что-л.* за собой» — гом. тк. *сүйрә-* id. < бор. тк. *сүзрә-, сүтрә-* id. тат. *өстерәү* сүзе белән тамырдаш.

**СӨЙРЕ** «остроконечный; севрюга» — ~ чув. *сĕврек* «очлы; сөйрек», *шӱреке* «очлы башлы» һ.б. татар телендә сирәк очраса да, төрки телләрдә киң таралган *сүйри, сиври-* тунгус. *сувурэ* «очлы башлы, очлайган» сүзеннән; рус. *севрюга* мишәрчә *сөүрегә* «сүрек» сүзеннән булса кирәк. К. **Черки.**

**СӨКӘ** «верша (*рыболовная снасть из прутьев*)» — бор. *сүкәк, сүг-кәк, сүй-кәк* «сөзгеч» сүзеннән, *сүк-, сүг-* «сөзү» (к. **Сөз-ү**) тамырыннан; к. чув. *сĕке,* себ. тат., кк. *сүйкә,* алт. *сүгән,* хакас. *сүгэн,* бор. монг. *сигуку* «сөзгеч» (Зәмәхшәри).

**СӨЛГЕ** «полотенце» — диал. *сөл-ү* (чув. *шăл-,* тунгус. *сил-*) «сөртү» тамырыннан; к. ш. ук үзб. *сулги,* ткм. *сүлги,* кк. *сулук, сүлүк,* рус. диал. *сулок,* мар. *сӧлык, солык,* коми. *сулок,* чув. *шăллă* «сөлге, сөрткеч».

**СӨЛЕК** «пиявка» — гом. тк. *сүлүк;* ихтимал, бор. тк. *сүлүк* «гаскәри» сүзеннәндер (бор. тк. *сү* «гаскәр»); чаг. ш. ук фарсы.

*залу,* азәрб. *зәли* «сөлек». Чув. *сĕлĕк, сĕлкĕ,* мар. *сӳлык,* удм. *сулук* «сөлек» — татар теленнән.

**СӨЛТӘР: сөлдә, сөлдер** диал. «скелет» — ~ кк. *сулде, сулдер,* кырг. *сүлдөр* «сөяк-санак, скелет, калдыклар», кум. *сюлдюр* «силуэт, контур», монг. *сулдэр, сулдэ* «символ, як койрыгыннан ясалган байрак, хан рухы» — *суль, сегуль* «койрык; калдык» сүзеннән. Удм. *сульдэр* «картина» татар теленнән дигән фараз бар.

**СӨМ** «чувство; ощущение» — бор. тк. *сӧм, сум* «сөм, тойгы». К. **Сөмсер.**

**СӨМБЕЛ, СӨМБЕЛӘ** «гиацинт; созвездие девы: дева с золотистыми волосами, *диал.* праздник девушек в день осеннего равноденствия (22 сентября); праздник урожая» — фарсы., гар. *сумбуль* «сөмбел», *сумбуляh* «сөмбелә» һ.б., шумер. *шумбултум* «башак» сүзенә кайтып кала.

**СӨМСЕР: сөмсере коелу** «быть не в духе» — *сөм* (к.) һәм *сер* < гом. тк. *сур* «үзеңне гайрәтле итеп тоту, бүтәннәргә тәэсир көче» сүзеннән; к. диал. *сөре-сөме коелу,* чув. *сĕр* «рух» һ.б.

**СӨҢГЕ** «копье; пика» — бор. тк. *суңгу* «сугыш коралы, сөңге»; *су-, суң* «сугышу» (*су* «гаскәр, яу»); к. кк. диал. *сунги* «кылыч», бор. уйгур. сүңүк «сөңге», бор. тк. *суңгушмак* «чәнчешү» һ.б.

**СӨР: сөрит, сөр ит** «вяленое мясо» — гом. тк. *сур* «какланган ит; төтендә тотылган тире» (тирене махсус ыслакларда ыслаганнар). К. **Сөрем.**

**СӨРӘН: сөрән салу** «кричать истошным голосом, взывая о помощи») — башк. *hөрән,* удм. *сурян,* мар. *сурем,* чув. *сĕрен* «сөрән, язгы бәйрәм», кк. *сурен,* үзб. *суран,* чыгт. *сүрән, сурун* «сөрән». Язын явыз рухларны торaклардан «*сөру*» йоласы нигезендә ясалган. К. Әхмәтьянов, 1989: 68—69.

**СӨРЕМ** «угар, чад» — бор. тат. *сөр-* «ислəнеп череп чыгу (*тире турында*)» сүзеннән; к. диал. *сөрсе-ү* «сасу, нык ислəнү», башк. *hөрөм,* чув. *сĕрĕм* «сөрем, корым», удм. *сурым* «ис» (татар теленнән). Кырг. *сурсу-* «(*ит*) ыслану, каклану». К. **Сөр.**

**СӨРЛЕК-Ү** «споткнуться» — *сөр-ү* < гом. тк. *сур-* «пахать; гнать» нигезендә ясалган сүз, чаг. диал. *сөртен-ү* «сөрлегү». *Сөрт-ү* < *сөрет-ү* һ.б.

**СӨРМӘ** «сурьма; сурьмило» — *сөр-ү* сүзеннән; к. чыгт., госм. *сурмә* «сөрмә тарту»; чаг. *сөрт-ү;* хакас. *суркү, сурткү* «сөрмә». Рус. *сурьма* — төрки телләрдән.

**СӨРТ-Ү** «вытирать, вытереть» — чув. *сĕрт-,* гом. кыпчак *сурт-* id.; *сөр-ү* ~ *сур-* сүзенең йөкләтү юнәлеше формасы.

**СӨР-Ү** «пахать; гнать» — гом. тк. *сур-* «куу, җир сөрү, мал көтү, сөртү, этәрү» сүзеннән; шуннан ук *сөрлег-ү (сөр-ел-ек-ү), сөрмә, сөрт-ү* һ.б. Чаг. монг. *сөрӧ-х* «җилгә каршы бару, каршылык күрсәтү».

**СӨТ** «молоко» — гом. тк. *сут,* бор. гом. тк. *сүүт* «сөт» сүзеннән (асылда *су* фигыленнән ясалган исем булса кирәк); к. ткм. *сүйт,* самодий. (саян.) *сиут* «сөт», монг. *сун* «сөт». К. **Сөчек, Төче.**

**СӨЧЕК** «слащавый» — к. **Төче.**

**СӨЯК** «кость» — гом. тк. сүз; госм. *сӧйук,* уйг. *суңук, сӧңук,*



чыгт. *сӧңәк* һ.б. (фонетик вариантлары күп) «сөяк, нәсел» (тат. *үз сөягем* «үз нәселем»); к. ш. ук якут. *унуох, аңуох,* чув. *шăна, шăма* «сөяк». Тамыры — **суң-* «җилек суыру» (?) булса кирәк.

**СӨЯЛ** «мозоль» — гом. тк. *суйəл, сугəл* «сөял» сүзеннән.

**СӨЯМ** «пядь, четверть аршина» — гом. тк. сүз; тат. диал. *суәм,* чув. *сĕвем* «сөям», *сĕвем* «киләп», кырг., алт., тув. *сӧӧм* «чирек, каршы», якут. *суом,* монг. *сугем, сугум* «сөям, карыш», бурят. *hөөм* «сөям, үкчә».

**СӨЯН** «липа, с которой снято лыко» — диал. *сөйям* «сөян», бор. тат. *суим, сөйем* — чув. *сĕвен, сĕвем* «суелган агач» сүзенннән үзгәреп килеп чыккан булса кирәк (чув. *сӳ-, сĕв-* «агач сую»); к. мар. *сӳйем,* удм. *суем* «сөян» (татар яки чуваш теленнән); чаг. бор. *sögün (күплектә sögit) «үзагач (древесина); тал».

**СУ** «вода» — гом. тк. *су, суб, суң, суг* «су» сүзеннән; чаг. монг. *усу(н),* кытай. *шуй; суғар-у* < **су-ғар-ығ* яисә **су-ғар-ғу.*

**СУАЛЧАН** «глиста; червь (дождевой) — диал. *селәүчән, селәү* «суалчан, корт, бабасыр» — гом. тк. сүз, ләкин бик нык буталган; к. кырг. *жыбылжын* «суалчан», *жыбылжы-* «суалчан кебек хәрәкәтләнү», госм. *соғул* «җиргә керү», *согулҗан* «җир суалчаны»; тат. диал. *чуалчан* «суалчан» *чуал-у* (к.) сүзе белән контаминацияләнә; чаг. ш. ук чув. *сăрăлчан* «бабасыр; сары кырмыска» (*сăрка* «соры, сары»), алт. *чойлошкан* «корт, суалчан», якут. *сулу-сун, сулума,* монг. *сӧлсун* «сару». К. тат. диал. *селәүчән сию* «сару».

**СУБАЙ, СУБАГАЙ I** «красивый; статный (*о лошади и о девушке*)» — кк., ккк., кырг., алт. *субагай* «озын буйлы», *субай* «кысыр», кб., кум. *субай* «озын буйлы; сылу; кысыр; кадерле», калм. *сваға,* тув. *сувай* «кысыр» — монг. *субагай* «кысыр» сүзеннән.

**СУБАЙ II** «свая» — рус теленнән.

**СУГАН** «лук» — удм. *суган, сугон,* мар. *шоган,* чув. *сухан,* гом., кыпчак., чыгт. *соған, сойған,* алт. *согоно, сокино,* тув. *согуна, сонгуна* ~ монг. *сонкино* «суган; ук». Бу сүзне кытайча tsuŋ «суган» сүзеннән дип тә уйлыйлар.

**СУГЫМ** «скот, предназначенный на убой» — мар., удм. *сугым,* чув. *сăхăм* «сугым, сугымлык» — гом. тк. *согум, сокум-, сок-* «сугу, сую» фигыленнән.

**СУЕР** «глухарь» — башк. *hуйыр,* себ. тат. *сойр;* бу сүзнең параллельләрен без монгол телендә генә таптык: *сойр* «суер».

**СУЗ-У** «протянуть, протягивать; затягивать» — кк., куман. *соз-,* чыгт., уйг. диал. *сӧз-* «сузу» — бор. **сойз-,* **сой-уз-* «сузу» сүзеннән. Шуннан ук башк. *hуйзан,* тат. диал. *сузан* «озын буйлы һәм нечкә гәүдәле кеше».

**СУЙ-У** «резать, зарезать (*скот*)» — гом. тк. *сой-* «кыйнату, сугу (көнч. тк.), сую, кабык (тире) сую» сүзеннән. Мәгънә үсеше: «сугу, сугып үтерү > пычак белән сугу > сую > суелган малны тунау > һәртөрле тире, кабык кебек нәрсәләрне сую». К. **Сөян, Сук-у.**

**СУКА** «соха» — башк. *hука,* чув. *сука,* кк., ккк. *соқ* «сука» — чыгышы ачык түгел, русчадан дип расларга нигез юк (рус сүзе

үзе төрки теллләрдән булырга мөмкин); к. мордва, эрзя. *соки* «сука». К. Әхмәтьянов, 1989: 63—64.

**СУКБАЙ** «бродяга; босяк» — кк. диал. *сукпай (сукбай)* «азган эт» сүзеннән; *-бай* этләргә бирелгән атамаларга характерлы элемент: *алабай, сарбай.* К. **Сок.**

**СУКМАК** «тропа» — гом. тк. *сокмак, сокма* «сукмак, тау битләрендәге сырлар», кк. *сокпа* «сикәлтәле юл», тув. *сыкпак, сукпак* «тау битләрендәге сыр, уенты, яр, култык ярындагы уйсу җир», якут. *ахпа* < *сахпа* «ерынты, тау битендәге сырлар», хакас. *сыңмак* «җыерчык, җыерылма» — гом. тк. *сок-, сук-* «сугу» сүзеннән дип хисапланыла (чаг. рус., украин. *шлях* «юл» < немец. schlag «сугу (удар); юл», поляк. bita droga «сугылган юл — сукмак»; чаг. алт. *согынты* «тау битендәге сыр», башк. *сугышмак* «юлдагы базлык».

**СУКЫР** «слепой» — гом. тк. *сукыр, сокур,* алт., бор. монг. *соңкар,* якут. *соххор* «бер күзе сукыр», *сохлох* «сукырайту», *соххатча-х* «бер күзен чыгару», *сох* «сыңар, так, житешсез».

**СУЛ-У** «вянуть» — башк. *һулы-,* гом. тк. *сол-* < *соғул-* id.; к. чув. *сывăл-* id.

**СУЛ** «левый» — гом. тк. *сол* «сул», бор. гом. тк. *сол, соңул-* «арт як» — *суң, соң* «арт» сүзеннән булса кирәк; к. тат. диал. *суң* «сул», мар. *шала* «сул; арт», *шалахай* «сул, сулагай» (төрки телләрдән), гар. *шул* «сулагай» шулай ук төрки телләрдән. К. **Сулагай.**

**СУЛАГАЙ** *диал.* «левша; левый» — гом. тк. *солагай, солакай* «сулагай, сул» бор. монг. *солугай* «сул; хата» сүзеннән таралган дип хисапланыла (тамыры, әлбәттә, гом. тк. *сол* «сул»); к. ш. ук чыгт., госм. *солак* «сулагай; бәхетсез».

**СУЛЫШ** «дыхание» — диал. *сулы-у* «сулау» сүзеннән ясалган исем (*сулы-ш*); к. диал. *сулу (сулу алу)* «сулыш». Чув. *сывла-,* мар. *шӱлә-* < тат. *сула- // сыу-ла-*; чаг. калм. *суғ* «авыр сулыш».

**СУМ I** «рубль» — гом. тк. *сум, сом* «сум, тоташ кисәк» сүзеннән (беренчел мәгънәсе «тоташ кисәк алтын»); к. алт., кырг., чыгт. *сом* «брус; кисәк», госм., кк., кырг. *сом* «тоташ; авыр, саллы; сум», *сомун* «түгәрәк металл кисәге», бор. тк. *сон* «тоташ кисәк», *сон алтун* «бармак чаклы алтын» (МК), кырг., кум. *сом алтын* «самородок». К. **Сум II, Савым I.** Элегрәк мөһерле акча урынына гади алтын яки көмеш кисәге йөргән, аны «ваклау» да конкрет мәгънәдә эшләнгән.

**СУМ II: сум ит** «мякоть» — к. кум., ккк., кырг. *сом эт* «сум ите», башк. *һум* «тоташ ит, тоташ шеш», көнч. тк. *сом* «форма, нигез; төп (остов), буй-сын». К. **Сум I.**

**СУМАЛА** «смола, вар» — рус теленнән.

**СУМСА** «пирожок» — фарсы. *самуса, саңбуса* «сумса, өчпочмак» сүзеннән (*саң, си-әң* «өчле», *буса* «кырый, почмак»); к. ш. ук госм. *самса, сомса* «өчпочмаклы кәтермәч».

**СУНАР** «охота» — бор. тат., кк. *сунар, сонар* «яңа яуган кар» сүзеннән: кк. *сонаршы* «сунарчы, яңа яуган кар өстендәге эзләр буйлап ау аулаучы»; к. ш. ук кк. *сону* «яңа яуган кар; кеше аягы басмаган үлән», бурят. *сунга* «кул тимәгән, таза».



**СУСАР** «куница» — гом. тк. *сувсар,* үзб., куман. *саусар, сосар,* госм. *саңсар, самсар* «сусар» — монгол теленнән булуы ихтимал; к. монг. *суусар, саусар* «сусар», *сон* «кама».

**СУТ** «сок» — башк. *һут* «сут» — монг. *усут* «сулар» дигәннән булса кирәк.

**СУФЫЙ** «отшельник» — гар. *суфи-йун* «суфый, аскет» сүзеннән, беренчел чыганагы — грек теле *софиа* «укымышлы», икенче бер аңлату буенча, гар. *суфи-йун* «суфый» гар. *суф-ун* «йон, йон кием» сүзеннән, ягъни «йон кием киеп йөрүче аскет» дигән сүз булган.

**СУЫК** «холодный» — гом. тк. *суук, соwук* «суык», уйг. *соғук* «суык, салкын, суынган», бор. тк. *соғу-* «суыну» фигыленнән; к. тат. диал. *су-у* «суын-у», алт., тув. *соо-,* госм. *соу-, соғу-* «суыклану»; к. ш. ук монг. *сойи-,* маньчж. *сойо-* «суыну».

**СУЫР** «сурок» — гом. тк. *суур, суғур* «суыр, әрлән», бор. тк. *соғур* «куян» (МК) — ясалышы һәм тамыры ачык түгел. Рус. *сурок* татар теленнән (бор. рус. *сур*).

**СҮЗ** «слово» — гом. тк. *сöс, сöз* «сүз, нотык» сүзеннән; шуннан ук *сөйлә-ү* < *сöз-лә-ү.*

**СҮЛ** «сок (*в тканях животных организмов*)» — ачык түгел: диал. *сул* «сүл», үзб. *сулак* «селәгәй, сүл», алт. *шулу* «агач сүле».

**СҮЛПӘН** «вялый» — гом. тк. *сал // тал // дал // йал* (к. **Җил**) символик яңгырашлы тамыр белән бәйләнгән булса кирәк; к. госм. *сулпу* «йомшару, сәлперәю», *сулпук* «сүлпән», тат. диал. *сылпан, салпан,* якут. *сылба* «сүлпән, салпы». К. **Салпы.**

**СҮН-Ү** «гаснуть» — гом. тк. *сöн-* «сүнү, төшү», монг. *сöнö-* «сүнү, үлү, дөмегү» — бор. гом. тк. *сöн-* «сүнү», гом. тк. *сö-* «сүнү, юк булу, төшү» фигыленең кайтым юнәлеше. Венг. *сүну,* ткм. *сөөн-* «сүндерү», калм. *сöö* < бор. монг. söni «төн; караңгылык», шумер. si-, sa-, su- «караңгы булу».

**СҮРӘН** «плохо истопленный; холодный (*об отношениях людей*)» — к. **Сүр-ү.**

**СҮРЕК** «штырь; стержень» — гом. тк. сүз: каз. *сүрек, сүрик* «сүрек», тат. диал. *сөйре* (себ. тат.), *сөйрек* (Идел буе) «чәнечке, балык аулый торган сөңге», алт. *сүүрү,* уйг. *сөври,* госм., чыгт. *сиври,* кк. *сукри* «очлы, очланган, конус, чәнечке, озын, кадаксыман нәрсә», бор. тк. *субу-р-үг* «очлы» — бор. *суб-у* «оч» сүзеннән (к. **Семәк**); к. чув. *сӳре* «тырма теше, шүре, сүрә (арба кендеге)», *шĕвĕр* «очлы, үткер», тат. диал. *сүрек, сүрәгә* «чөгә (стерлядь), осетр». К. **Чөгә, Шүре, Черки.**

**СҮРҮ** «наволочка; оболочка» — ачык түгел: чув. *сӳрӳ* «астар», диал. (керәшен) *сөр-ү* «мендәргә сүрү кидерү».

**СҮРЕЛ-Ү** «затухать; остывать» — чув. *сӳр-, сĕвĕр-,* мар. диал. *шöр-*; шуннан тат. *сүрел-,* чув. *сӳрĕл-, сĕверел-,* мар. *шöрлаш* «сүрелү; салкынаю; дәрте, гайрәте бетү», *сүрән* (к.) сүзләре ясалган. Бу сүз бүтән төрки телләрдә очрамый, шунлыктан аны фин-угор телләреннән дип уйларга мөмкин; чаг. удм. *сöр-* «вату, сүтү, бозу». Шул ук мәгънәдә гом. тк. *сöк-* фигыле бар.

**СЫБАЙ** «верховой; всадник» — бор. тат. *спай* < фарсы. *си-*

*паhи* «солдат, гаскәри», бор. ирани spahi, spah «атлы сугышчы» сүзеннән (шуннан ук рус. *сипай* «Һиндстанда яллы гаскәри»). К. **Ыспай.**

**СЫБЫЗГЫ** «свисток» — көнч. тк. *сывыргы ~ сыгыргы* «сыбызгы» — тат. диал. *сыгыр-*, алт. *сығыр-, сырғыр-* «сызгыру» фигыленнән.

**СЫЕК** «жидкий» — гом. тк. *суйук, сувыг*, бурят. *шииг* «сыек, сусыл», бор. *сыйы-, сыгы- ~* чув. *шĕвĕ-* «сыеклану» фигыленнән, бор. *суг* «су» тамырыннан булса кирәк.

**СЫЕР** «корова» — гом. кыпчак. *сыер*, чыгт. *сыгыр* «сыер». Күп кенә төрки телләрдә «сыер» мәгънәсендә бүтән сүзләр йөри: тат. диал. *инәк ~* чув. *ĕне;* кырг. *уй* < бор. тк. *уд* һ.б. *Сыер* сүзенең чыгышы бик үк ачык түгел: бор. *саг-* «саву» сүзеннән дип әйтү ышандырып бетми.

**СЫЕРЧЫК** «скворец» — мар. *шынгырчык, шырчык,* чув. *шăнкрщă,* удм. *шырчик, сырчик,* тат. диал., кырг. *чыйырчык,* бор. *сыгырчык* «сыерчык, чикерткә, купшыл» — *сыгыр-* «сызгыру» сүзеннән.

**СЫЗ-У** «удрать; уменьшаться в объеме; худеть» — ткм. *сызы-*, алт. диал. *сыс-* һ.б., тунгус. *сир-* «сызлау» белән чагыштырыла; к. ш. ук чув. *сăр-, сур-* id. Сүзнең фигыль мәгънәсеннән гом. кыпчак. *сызык, сызыл* «куырмач; көрпә» сүзе, исем мәгънәсеннән *сызла-у* ясалган. Фигыльнең исем пары бар — себ. тат. *сыз* «сызлау».

**СЫЗГАН-У** «засучивать (*рукава*)» — тат. диал. *сыган-*, чув. *шахран-* < *шăхан-* «сызгану» ~ тув. *сырган-*, алт. *сырқан-* «ялангачлану» сүзе белән бер булса кирәк: сүзнең нигезе — *сызга-* < *сырга-* «сыдырып ялангачлау» бор. *сыр* «ялангач» тамырыннан; шуннан ук тат. *сыдыр-у* < *сырдыр-у* «кул белән сөреп яисә сугып ялангачлау» сүзе дә килсә кирәк.

**СЫЗГЫР-У** «свистеть» — диал. *сыгыр-у-* «сыс, сырыс, с-с «тәкълиди сүзенә авазларны белдергән фигыль ясагыч *-кыр // -кер, -гыр // -гер* кушымчасы ялганып ясалган.

**СЫЙ** «угощение» — гом. тк. *сый*, бор. тк., монг. *суй* «бүләк, хөрмәт» сүзе белән тамырдаш булса кирәк.

**СЫЙ-У** «вмещаться» — гом. тк. *сый-, сыг-* id. Татар телендә бор. *сыгын-* (*сыг*-ның кайтым юнәлеше) ике сүз биргән: *сыгын-у (Аллага сыгыну)* һәм *сыен-у. Сый-* тамыры *сең-* белән дә чагыштырыла.

**СЫЙРАК** «голень» — бор. *сыңырак* id. гом. тк. *сеңер, сыңыр* «сеңер» сүзе белән тамырдаш (чаг. *бөер ~ бөйрәк*); к. азәрб. *сыңыр* «сыйрак». К. **Сеңер.**

**СЫКТА-У** «плакать, всхлипывая» — гом. тк. тат. диал. *сыгыт, сыгы* «кеше үлгәндә елау» сүзенннән. К. **Ыгы-зыгы.** Шул ук *сыгы* тамырыннан тат. *сыкрау* «хныкать» сүзе дә килә.

**СЫКЫ** «изморозь, иней (*на деревьях*)» — диал. *зыкы*, мар. диал. *зыке*, чув. *сăк, сăкă, сăхă*, башк. *һыкыу, зәһеү* «сыкы» Идел-Урал регионына хас сүз: фарсы. *зах, заhи, заhу* «сыкы» сүзеннән булса кирәк. К. Әхмәтьянов, 1989: 11.



**СЫЛА** «судак» — кк., ккк. *сыла*, башк. *һыла*, чув. *шăла*, венгр. süllo-, бор. болгар. **сыллак* «тешләч балык, сыла» — **сыл* ~ чув. *шăл* «теш» сүзеннән дип уйланыла.

**СЫЛТА-У** «ссылаться на *кого-л.*» — чув. *сăлтав*, мар. *шылтык* «сылтау» — гом. кыпчак. *сылта-* һәм *сылтау,* кырг. *шылтоо,* хакас. *сылтаг,* монг. телләрендә *шылтак, шалтак,* бор. тк. *тылдаг* «сылтау, сылтану», үзб. *силтав* «тезген тарту, менелгән атны бер якка бору» — гом. тк., гом. монг. *сал // сэл* «селкү, селкетү» (к. **Жил**) тамырыннан булса кирәк. Әмма бу сүзнең үзенчәлекле абстракт мәгънәсе һәм киң таралыш алган булуы монда нидидер хикмәт барлыгын күрсәтә: ихтимал, төп мәгънә фарсы-таҗ. *силтав* «сылтау» — *силк тавидан* «ефәк җептән тарту — йомшак кинайә» сүзеннәндер. *Сылтау* сүзенә *шелтә* сүзе дә тоташа.

**СЫЛУ** «красивый; красавица» — гом. кыпчак. *сылу, сылыу,* бор. уйг., алт. *сылыг-*, хакас. *cilig* id. Палаталь вариантлар булуы *сылу* < *сылыг* < *сынлыг* (к. **Сын**) дип аңлатуга киртә булып тора. Ихтимал, нидидер *сыл* «чисталык; матурлык» тамыры булгандыр. Аннан *сыллыг* > *сылу* һ.б.

**СЫМАН, СЫМАК** *послелог* «подобный, подобно» — гом. кыпчак., үзб., уйг. *сыман, сымак -су (алсу), -сыл (аксыл, күксел), -сым (төксем)* аффикслары белән тамырдаш. Чаг. ш. ук **Сыңар**.

**СЫН** «фигура, телосложение» — гом. тк. *сын* id.

**СЫНА-У** «испытывать» — гом. тк. *сына-* id. *сын* сүзеннән (тышкы күренеш, кыяфәт буенча эчке сыйфатны белү дигән сүз).

**СЫН-У** «ломаться» — гом. тк. *сын-* бор. тк. *сы-* «ватылу» сүзеннән. К. **Сыт-у.**

**СЫҢАР** «один из парных предметов» — гом. тк. *сыңар, саңар* id. бәхәсле сүз: *сынгары* «үзенең сынына (сурәтенә) таба» дигәннән булырга мөмкин. Чаг. тат. диал. *сыңары* «охшаш; шикелле».

**СЫР** «грань; резьба; резной узор» — гом. тк. *сыр, сар* булган булса кирәк; к. тат. диал. *сыр* «буяу», алт. *сыр* «буяу, лаклау», уйг., үзб. *сир* «кызыл буяу» (чаг. фарсы-таж. *сурх* «кызыл») ~ монг. *шир*, бурят. *шэрэ* «буяу». К. **Шар II.**

**СЫРА** «пиво» — алт., кк., кб., чув. *сыра* «сыра», балкар. *сыра* «арпа сырасы» — фарсы теленнән булса кирәк, ләкин төрлечә аңлатыла: к. кк. диал. *сыраб* «сыра (пиво)», фарсы. *сэраб* «куе эретмә, спирт эремәсе, куе хәмер, тондырылган катнашма»; икенче яктан, фарсы-таж. *ширэ* «сироп, виноград суы»; өченче яктан, бор. ирани sura, санскрит. sura «исерткеч» (к. коми., удм. *сур* «сыра» бор. ирани телләрдән).

**СЫРГА** «серьги» — бор. тк. *исирга* «сырга» сүзеннән (тамыры ачык түгел), бик борынгы заманнарда ук сәүдә предметын белдергәнгә күрә, киң таралган сүз; к. чыгт. *асирга, ызырга,* үзб. *исирга* «алка, сырга», коми. *исерга*, бор. рус. *усерегу, усерязь* «сырга», бор. немец. *üseregü* «алка» һ.б.; к. ш. ук якут. *ытарга* «сырга». Удм. *сырга* «тузганак», мар. *сыраг*, чув. *шăрка* «сырга, серкә» — татарчадан. К. **Серкә.**

**СЫРГАВЫЛ** «наблюдательная вышка; высокая жердь; мач-

та» — кк. *сыргауыл* «каралты түбәсенә куелган биек багана», бор. тк. *сыргауыл* «серәеп торган нәрсә». К. **Сырган.**

**СЫРГАН** «крепость на горе» — диал. *шыған, шыйған,* кк. *шыған* «биек ялангач тау; биек багана», бор. тк. *сырға-, шырға-* «яланганлау» фигыленнән. К. **Серәй-, Сыргавыл, Сызган-.** Мәгънә үсеше: «ялангач > ялангач тау, серәеп торган нәрсә > биек корылма, күзәтү пункты, каланча > ныгытма». К.**Чуан.**

**СЫРПА** «виляющий хвостом» — тунгус. *сирпе* «юка»; к. бор. тк. *сырпа-* «койрык болгау, бөтерелү, килеп ышкылу» (чаг. ш. ук *сырп-ан-у, сыпыр-у*); к. диал. *сырпа-л-у, сырпа-н-у* «сырпалану, көйсезләнү, юри көйсезләнү», якут. *сырбай-*, монг. *сирбе-*, бурят. *ширба-* «койрык болгау, сырпалану».

**СЫРТ** «хребет» — гом. тк. *сырт* «тышкы як, өске як, арка, арт» сүзеннән. Төрки телләрдән күп телләргә кергән (мәс., абазин. *сырт*). *Сыр* тамырыннан булса кирәк (*сырыт* > *сырт*).

**СЫРТЛАН** «гиена» — Рамстедт буенча, бор. тк. *сыртлан* «сырты буй-буйлы хайван» сүзеннән (*сырт* «сырт, арка», *лаң* «хайван, җәнлек» — кытай теленнән хисапланыла; чаг. *арыслан, каплан* һ.б.), башк. *һыртак, сыртак* «аркасы тасмалы (хайван)».

**СЫРХАУ** «больной; болезнь» — кк., кырг. *сырқа-* «авыру, сырхау», фарсы. *сәрхау* «баш авырту, баш сызлау», *сәрхабад* «баш авыруы, чир»; шуннан тат. диал. *сырхаwат*, чув. *сăрхават* «сызлавык, яман шеш». Халык этимологиясе буенча, фарсы. *сәрхау* сүзе төрки фигыль *сырха-* булып киткән.

**СЫТ-У** «давить; сломать» — бор. тк. *сы-* «ватылу» сүзеннән (сы-т-); шуннан ук *сы-н-у.*

**СЫЯ, СЫЯУ** «струя; следы потоков; осыпь» — соңгы елларда әдәби телдә активлашкан һәм күп сөйләшләрдә очрый торган бу сүз фарсы. (XIX — XX гасыр башы татар әдәби телендә еш очрый) *сиаһ* «кара (черный; чернила)» сүзеннән килә.

## -Т-

**ТА** *предлог* «до; *частица* да; еще» — к. **Тагы.**

**ТАБА** «сковорода» — башк., кк., ккк., госм. һ.б. *таба, тапа* «таба» — фарсы. *таба* «куырып пешерү өчен савыт, таба, табак» сүзеннән, бор. ирани. tab (таб) «утта кыздыру, эсселек, кызулык» нигезеннән. Чаг. **Табак.**

**ТАБА(Н)** *послелог* «по направлению ... к» — гом. тк. *табан* «таба, юнәлештә» — ике төрле аңлатыла: а) гом. тк. *тап-* «табу» фигыленең адвербиаль формасыннан (*тап-а*, ягъни «табып, эзләп»); б) гом. тк. *тап* «урын, төш, нокта» сүзеннән (*таба* < *тап-ка* «урынга, төшкә»); к. бор. тк. (МК), уйг. *табару, тап-гару* «таба, юнәлештә», кайбер төрки телләрдә *таба* иялек килеш белән кулланыла (*минем таба*). Чаг. ш. ук тат. диал. *табантын* «таба».

**ТАБАК** «чаша (*большая металлическая*); лист (*бумаги, жести*) — гом. тк. *табак*, госм. *табака* «табак» гарәп-фарсы теленнән чыккан сүз; к. фарсы. *табака* «табак, катлам, капкач»; к. ш. ук монг. *табага* «табак (савыт)». Чаг. **Таба, Табан.**

**ТАБАЛА-У** «попрекать» — кырг., ккк., кк. *табала-*, чув. *тупала-* «табалау, кинаялэп әйтү» — ниндидер *таба* сүзеннән; к. уйг., кк., ккк. *таба* «усал шатлык; әр», монг. *табиха* «кеше казасына шатлану».

**ТАБАН** «ступня, подошва» — гом. тк. *табан, тапан* «олтан, аяк (уч) табаны, тигезләнгән, тапталган урын, нигез (базис)» — бор. тк. *тап* «аяк басу» сүзеннән булса кирәк (чаг. *тапта-у*); к. ткм. *дāбан*, тат. диал. *табач* «уч, кул яссуы».

**ТАБ-У** «находить, найти» — гом. тк. тап «табу» — гом. тк. тап «нокта, төп» сүзе белән тамырдаш булса кирәк; к. тат. диал. (мишәр) *табыл-у* «очрак, тап килү». К. **Тапшыр-у.**

**ТАБЫН** «накрытый стол с угощением; застольная компания» — кк. *табыл, табын* «табын йөри торган көтүлек», бор. тк., чыгт. *табун* «табын, өер» — ниндидер *тап* тамырыннан; чаг. *табыр. Табын* сүзен монг. *табун* «биш» сүзенә дә бәйлиләр («бишәрләп утыру»).

**ТАБЫР** «полевой стан; место отдыха и водопоя скота» — бор. тк. *табур* «атлар өере, олау, арбалар белән уратылган хәрби лагерь» сүзеннән, ниндидер *тап* тамырыннан булса кирәк (чаг. *табын*). К. **Товар, Туар.** К. Әхмәтьянов, 1989: 85—86.

**ТАВИС** «павлин» — фарсы., гар. *таус, тауис* «тавис» сүзеннән, беренчел чыганагы грек теле булса кирәк.

**ТАВЫК** «курица» — гом. тк. сүз: чыгт., үзб. *таwуқ,* бор. уйг. *тагык, такыгу,* алт. *тақаа* (монг. *тақига*), хакас. *таңах* һ.б. (фонетик вариантлары күп) «тавык». Ясалышы, тамыры ачык түгел.

**ТАВЫШ** «голос; звук; шум» — гом. тк. сүз, чыгт. *тауыш* «тавыш, шау-шу, дөбердәү», алт. *табыш* «шау-шу, хәбәр», хакас. *табыс* «тавыш, аваз», бор. тк. *таwуш* «хәрәкәт, ыгы-зыгы, тавыш, давыл» (МК) — бор. гом. тк. *табыл // тагыл* «тавыш, шау-шу, давыл» сүзеннән булса кирәк (к. **Давыл**); к. тув. *дагжа* «тавышлану», бор. монг. *дагун, духун* «тавыш, өн», *дагула* «җырлау». Чаг. ш. ук, **Давыл.**

**ТАГАН** «таган, таганец; качели» — бор. тк. *таган, такан,* монг. *тагаан* «таган», *такан* «казан», бурят. *тогоон* «казан» — гом. тк. *так-* (к. **Таг-у**) «асу, тагу» фигыленнән булса кирәк (Рясянен).

**ТАГАРАК** «корыто; кормушка» — кк. *дагара*, башк. *тагарак*, үзб. тадж. *тагара* «зур балчык табак; тагарак» — бор. тк., госм., уйг. *тағар* «зур савыт, зур кап», фарсы. *тағар* (рус. диал. *тагар*) «бадья, әрҗә» һ.б. бор. тк. *тағар* «тире капчык; тире кап» сүзеннән. К. бор. тат. *тāр, тағар* «арбага салып йөртелә торган әрҗә». К. **Туар, Товар.**

**ТАГ-У** «привязать; присоединять» — гом. тк. *так-*, *тагақ-* id., *такы-* «кабаталу, тезү» сүзе дә шуның белән тамырдаш булса кирәк. К. **Таган, Тагы, Такым, Дага.**

**ТАЗ** «лысина, плешь; плешивый» — гом. тк. *таз*, бор. гом. тк. **тар* «таз, пеләш, ялангач» сүзеннән; к. башк. *тарагай* (татар.

*тарагай)* «чәче кырылган», якут., монг. *тарагай, таракай,* эвенк. *тарака* «таз».

**ТАЗА** «здоровый; чистый, опрятный; зажиточный» — гом. тк. *таза, тәзә,* чув. *таса,* фарсы. *таза* «таза, саф», бор. ирани. tač-, tax-, tagh- «чабу, йөгерү; агу, агым су булу» сүзеннән килә; шул ук тамырдан иск. әд. *тази* «гарәп аты, шәп чабучы ау эте, гепард (җәйрәннәрне дә куып җитә ала торган озын аяклы зур мәче ау хайваны сыйфатында кулга ияләштерелә).

**ТАЙ** «годовалый жеребенок» — гом. тк. *тай, тӑй,* «тай, колын», чув. *тиха* < *тӑйха* «тай, колын» — монгол теленнән кергән сүз булса кирәк; к. монг. **дааган* < **дагаган, *тарка-ган* (?) «икенче яшьлек ат, тай», тат. диал. (себ. тат.) *тӑйынча* «икенче яше белән барган бозау», кк. *тайлак* «ике яшьлек дөя». Чаг. ш. ук венг. tịxa «тай», монг. *тахь* «кыргый ат» К. Әхмәтьянов, 1989: 87.

**ТАЙГА** — «тайга» — рус. «тайга» сүзеннән, бу сүз исә көнч. тк. (алт.) *тайга, тайыга* «тайга, тау урманы» сүзеннән; к. иск. диал. *тайгы* «урманны егып салган хәрби киртә» (Троянский).

**ТАЙ-У** «поскользнуться» — гом. тк. *тай-* «таю» сүзеннән.

**ТАЙЧАН-У** «уклоняться» — *тай-у* (к.) сүзе нигезенә бор. *чы-, ча-* аффиксы ялганып ясалган *тайча- (тай-сы-)* фигыленең кайтым юнәлеше формасыннан; к. диал. *тайчын-у* «тайчану, тайпылу», кк. *тайсал-да-, тайсаң-да-* «тайчану».

**ТАК I** «нечетный» — гом. тк. *тақ* «так, сыңар» сүзеннән; чаг. тат. диал. *тақа* «ялгыз», үзб., таҗ. *тоқа* «ялгыз, берүзе» ~ фарсы. *так* id.

**ТАК II** «пустое место; бедность; нищета» — көнч. тк. *так* «бик нык тапталган, үләне ашалып беткән көтүлек һәм бор. тк. *так* «мохтаҗлык» сүзләре белән тамырдаш булса кирәк; к. диал. *так булу* «бетү», *таксык* «бетә язган». К. **Такыр.**

**ТАКМАЗА** «прибаутка» — *такмак* (к.) нигезеннән ясалган сүз, ясалышы ачык түгел (*такмакча > такмача > такмаза* булса кирәк). Чаг. кырым., үзб. *тапмача, тапмаҗа* «табышмак».

**ТАКМАК** «частушка» — гом. тк. *такмак,* кк., көнч. тк. *такпак* «такмак, такмаза» — гом. тк. *такы* «кабатлау, кабат-кабат әйтү, такылдау» фигыленнән булса кирәк (*такы-мак*); к. ш. ук алт. *тапкак* «табышмак»; к. *тагы, так-у; такмак* «җәяүле юлчы токчае». К. Әхмәтьянов, 1981: 110.

**ТАКТА** «доска» — гом. тк. *такта, тахта* «такта, озын утыргыч, сәке, күпер (*төрле телләрдә төрле мәгънәдә*)» — фарсы. тахта «такта, сәке» сүзеннән, бор. ирани. tax- «кисү, чапкалау, кырлау» нигезеннән хисапланыла. К. **Тәхет.**

**ТАКЫР** «гладкий; ровный; оголенный» — чув. *такӑр,* мар. *тагыр-,* гом. тк., удм. *тақыр* «такыр, тигез» гом. тк. (себ. тат., алт. һ.б.) *тақ* «буш, үләнсез, тапталган» сүзенә бор. тк. сыйфат ясагыч *-ыр* кушымчасы ялганып ясалган (*так-ыр*). К. Әхмәтьянов, 1989: 38.

**ТАКЫЯ** «венок» — фарсы. *тақйа* «такыя, түбәтәй» сүзеннән киң таралган сүз (к. тат. диал., мар. *такыя, тайка,* чув. *тухья* «кызлар бүреге» һ.б.).



**ТАЛ I** «точно половина» — к. алт., башк., кырг., тув. *тал* «нәкъ ярты».

**ТАЛ II** «тонкий стебель; перо на женской шапочке» — к. **Тал III.**

**ТАЛ III** «ива» — гом. тк. *тал* «тал, таллык, чыбык, яңа үсеп чыккан тармак» сүзеннән; к. тат. диал. (себ. тат.) *тал* «төк, бөртек», уйг., чыгт. *тал* «бөртек, кыл», госм. *тал,* бор. уйг. (МК) *тал* «яшь ботак, үсенте», чув. *тал* «учлам (пучок)»; чаг. санскрит. tala «үсенте, яфрак; тәлгәш; учлам».

**ТАЛАЙ** «изрядно, много» — к. башк., кк., ккк., кум., н., кырг., чыгт. *талай* «байтак, беркадәр», кырг. *таалай* «өлеш, пай», бор. тк. *талаң* «өлеш, муллык, бәхет» > бор. гом. тк. *таала-ң* «өлеш, байлык» сүзеннән (чаг. кырг. *таан* «өлеш»). Шуннан тат. диал. *тәләй,* чув. *талан, *талаң* «муллык, бәхет» > рус. *талан,* чув. *чылай (чалай < *талаң),* тат. диал. *чәләй, чәли* «күп; муллык» (к. **Тәләй**); чаг. монг., калм. *дала, далага, далай,* бор. тибет. *талуй* «диңгез, океан, киңлек, муллык, бөек» (тибет. *далай-лама* «бөектән бөек лама»).

**ТАЛАК I** «селезенка» — гом. көнб. тк. *талак, далак,* бор. тк. *талак, сулак* «талак» (МК) — бор. тк. *сагалак* «сакалсыман үсенте» сүзеннән булса кирәк; к. чув. *сула, салак* «талак, сака, санак» (к. **Сака**) [с > п] *(сагалак > саалак > талак).*

**ТАЛАК II** «развод, расторжение брака» — гар. *талак-ун* «талак, ирекка җибәрү» сүзеннән.

**ТАЛАУ** «вид болезни лошадей» — башк., кк. *талау* «талау» < бор. тк. *тал-гаг* «талау, егылучанлык» гом. тк. *тал-* «арып егылу» сүзеннән; к. алт. *талгақ* «талау авыруы».

**ТАЛА-У** «грабить; терзать» — гом. тк. *тала-* «талку, җимерү, өзгәләү, ерткалау» сүзеннән; к. ш. ук монг. *тала-* «талау», чыгт. *талга* «талау күренеше». Чаг. *Талкы-у.*

**ТАЛГЫН** «теплый; спокойно» — гом. тк. *тал-* < **тага-л* «талу, хәлсезләнү» сүзеннән *(тал-гын).*

**ТАЛКАН** «толокно» — гом. тк. *талкан, талган* «талкан, он, онтак», бурят. *талхан* «он, талкан» — гом. тк. *талкы-у* «ваклау, онтау» сүзеннән.

**ТАЛКЫ-У** «мять, измельчать» — көнч. тк. *талқы-* «тире иләү, сүс талку», монг., бурят. *талхи-* «талку, тире иләү» көнч. тк. бор. гом. тк. *тал* «кыл, сүс, сүсәрү» сүзеннән булса кирәк (*талкы-, тал-ык-* «сүсәртү»).

**ТАЛКЫ** «мялка» — иң борынгы сүзләрнең берсе (чөнки ул башта тире иләү коралы булган); к. мар. *туле, толэ,* чув. *тӑла, тыла,* болг. **тиле* > венгр. *tilo* «талкы» < бор. монг. *talγiku, talγon* «тире иләгеч». К. **Талкы-у.**

**ТАЛПА** «часть стада; толпа» — бу сүзнс рус теленнән дию бик үк нигезле түгел, чөнки рус телендә ул 1627 елдан гына билгеле. Аннары бу русча китаби сүз татар (мишәр) сөйләшләренә ничек керде икән? Татарча еш кына *талпа-талпа* дип әйтү дә рус алынмасы өчен сәеррәк. Безнеңчә, бу сүз кк., ккк. *далба, далбай,* азәрб. *далва,* кырг. *талба* «аулаганда киекне чакырып

китерү җайланмасы (махсус сыбызгы, муляж, чүпрәк кисәге һ.б.ш.)» сүзеннән килә һәм дошманны алдау өчен гаскәр кебек тезелгән карт-коры, хатын-кыз яисә әсирләр төркемен белдергән; мондый алымны, мәсәлән, монголлар (монг. *талба* «кавем; маска») кулланган.

**ТАЛПАН** «клещ» — гом. тк. сүз: чув., башк., кк. *талпан* «талпан, кандала», хакас. *табылга(н)* «талпан», ясалышы ачык түгел; к. чув. *талпам* «таза, симез». Чаг. *тарпан* «кыргый ат» — *тарпы-у* «алгы аягы белән тибү» сүзеннән.

**ТАЛТА, ТАЛДА** «утешение; опора» — к. чыгт., кырым., кырг., ткм., азәрб. *далда* «арткы як; ярдәм, таяныч» ~ якут. диал. *далда* «җилгә караган ягы гына капланган шалаш», төрек., чыгт., азәрб. *дал*, монг., бурят. *дала*, бор. тк. *тал* «арка, җилкә, савыр», күчерелмә мәгънәдә «ярдәмче гаскәр»; шуннан бор. тк. (болгар) > рус. *тыл*.

**ТАЛ-У: ару-талу** «уставать; изнуряться» — гом. тк. *тал-* «талу; ватылу». К. **Талкы-у.**

**ТАЛЫМ** «разборчивость в пище» — якут., бор. тк. *тал-* «сайлау» фигыленнән (*тал-ым*); к. кырг. *талым* «иң яхшы, сайланган», кк., бурят. *талга-* «талымлау, сайлау, хөрмәт итү».

**ТАМ** «глиняная стена» — тат. диал. *там*, чув. *тăм* «балчык, балчык кисәге, йомарлак балчык, зур тамчы», тат. диал. *там* «балчык кирпеч, стена кору өчен салам катыш балчык йомарлагы».

**ТАМАК** «горло; еда, рот» — гом. тк. *таңак, тамак* «тамак, бугаз; анкау; ашау-эчү» < бор. тк. *тамгак* «тамак, бугаз» сүзеннән; формасы буенча бу сүз нигидер *там (ы)-* фигыленнән шикелле; чаг. көнч. тк. *там* «азык, тәм», к. ш. ук тув. *таңмак* «танау, саңак», эвен. *там-* «йоту, эчү, суыру».

**ТАНСЫК** «желанный; интересный» — кк. *таңсык*, бор. тк. *таңсык* «тансык, гаҗәеп нәрсә» (МК) бор. *таңсы-* көтеп алу, таң калу» фигыленнән, *таң* (к. **Таң II**) нигезеннән.

**ТАНТАНА** «торжество» — фарсы. *тантана* «тантана» id.

**ТАН-У** «отрицать, не признавать» — асылда, *таң-* «хәйран калу, таң калу, гаҗәпләнгән булып кылану» дигәннән. К. **Таң II.**

**ТАНЫ-У** «узнать; признать» — гом. тк. *таны-, тāны-* id. *Таб-у* белән тамырдаш.

**ТАҢ I** «заря, рассвет» — гом. тк. *таң* «таң» сүзеннән; ихтимал, электә «кояш» мәгънәсендә йөргәндер (чаг. эвенк. *гарпа* «кояш чыгу; мылтык ату» һәм гом. тк. *таң ат-*).

**ТАҢ II: таң(га) калу** «изумляться; удивляться *чему-л.*» — тат. диал. *таң- (таңу)* «гаҗәпләнү» (С.Сүнчәләйдә), чув. *та, тем, там,* мар. *та*, гом. тк. *таң, тāң* «гаҗәп, могҗиза» сүзеннән; к. алт. *таң* «белмим, хәйранмын» ~ тув. *таң* «белмибез; юк»; бор. тк. *таңағ* «курку»; ихтимал, *таң алласы* белән баглыдыр; *таң калу* — тәгъбире гом. тк. һәм монг. *(таң кочар-)* телләрендә бертөрле. Чаг. **Тан-у, Тансык.** К. Әхмәтьянов, 1989: 121—122.

**ТАП I** «пятно, точка; точь-в-точь» — гом. тк. *тап* «нокта, тап, эз, билге, тамга» һәм тат. диал., башк., кк., алт., чыгт., куман. *тап-* «очрау (моменты), туры килү» икесе бердәй булырга тиеш; чаг. ш. ук чув. *лап* «нәкъ, тап». К. **Таба II.**

**ТАП II** *диал.* «щепка; деревяшка» — к. башк., алт. *тап, тапчык,* монг. *тапхай* «йомычка». Шуннан ук тат. *тәп* «өй нигезләгәндә бәйләгеч нокта (точка отсчета)».

**ТАПКЫР** «раз» — кк., башк. *тапкыр*, чув. *тапхыр*, госм. *тапкур*, ткм. *тапгыр* «тапкыр, рәт, чират, отряд» — монгол теленнән булса кирәк; к. монг. *дабкур* «тапкыр, рәт», бор. монг. daƀxaɣar «кизү, чират; налог, салым», бурят. *дабхар, дабхагар* «кат, рәт, икеле, кабатланган, катланган», *дабхаса* «ике катлы» — бор. *даб* «кабатлау» фигыленнән, ягъни гом. төрки *тапта-у* (к.) сүзе белән тамырдаш.

**ТАПТА-У** «топтать; ковать; отбивать» — гом. тк. *тапта-, тапла-* «таптау, чүкү, тукылдау, тыпырдау» гом. тк., монг. күп һәм каты-каты итеп аяк басуны белдерә торган тасвирый яңгырашлы *тап (тап-тап)* сүзеннән (*тапылдау, тапырдау, тапыр-тапыр* һ.б.); к. ш.ук монг., бурят. *дабта-* «чүкү, тапау, кабатлау (к. **Тапкыр**)», эвен. *тапто-, тават-* «чүкү, кабатлау» һ.б.

**ТАПШЫР-У** «поручать, возлагать» — гом. тк. *тапшыр-* < *табыш-тыр-*.

**ТАПЧАН** «топчан, лежанка» — бор. тк., кб., н. *тапчаң* «тапчан, караватъ» < кытай. *тао чаң* «яту урыны».

**ТАР** «узкий, тесный» — гом. тк. *тар* «тар, кысынкы» сүзеннән; шуннан ук *тарлавык* «ущелье», *тарлык-у* «чувствовать себя в тесноте».

**ТАРАК** «гребень; расческа» — гом. тк. *тарак*, бор. тк. *тарғақ* (МК) «тарак» — бор. тк. *тарка-* (к.) фигыленнән.

**ТАРАКАН** «таракан» — гом. тк. *тараакан* «таракан». Егоров буенча, бор. тк. *тара-* «таркату, таралдыру» фигыленнән. Шулай ук чув. *таракан* «качаган, кача торган» сүздән дә булырга мөмкин. К. **Тара-у.**

**ТАРАМЫШ** «сухая жила» — гом. тк. *тара-у* сүзеннән, алт. *тарам, тарамаш* «жила, жилка», себ. тат. *тарамак*, кк., ккк. *тарамыс*, кырг. *тарамыш* «тарамыш», бор. тк. *тарам* «дельта; көнҗәлә».

**ТАРАНТАС** «тарантас» — рус теленнән, рус теленә исә бор. чув. *карантас* «тарантас» сүзеннән; сүзнең ясалыш нигезе — чув. *кар-, карă-* < **кăр-* «чыбыктан үрү» сүзе; к. чув. *кармак, карман* «читән алап (кошель), юкәдән үрелгән сумка» (шуннан ук рус. *карман* «кесә»); к. мар., тат. диал. *кәрәндәс, кырандас* «тарантас», *карнаша* «юкәдән үрелгән сумка», *кәркеш* «киндерә (чабатада)», морд.-мокша. *карандаз* «арба», коми. *карандыс* «алап (короб)».

**ТАРАФ** «сторона; направление» — гар. *тăраф-ун* «ахыр, чик, юнәлеш» сүзеннән.

**ТАРАФДАР** «сторонник» — фарсы. *тарафдар* «тарафлы, яклы» сүзеннән, сүзнең нигезе гарәп теленнән. К. **Тараф.**

**ТАРКАУ** «разбросанный; рассеянный» — бор. тк. *таркағ* «тар-

кау, таркалган», якут., чыгт., монг., бор. тк. *тарқа-* «тарау, тарату» фигыленнән; шуннан ук *тарак* (< **таркак*), *тарка-л-у, тарка-т-у.* К. диал. *тарка-у* «таратып җибәрү».

**ТАРМА** «коробка; дикая конопля» — бор. тат. *тарма* < тарыма «ташландык басу» сүзеннән булса кирәк (тарма шундый урыннарда үсә). К. **Тары.**

**ТАРМАК** «ветвь, ветка; отрасль» — кк., чыгт., бор. язм. әд. *тармак* «тармак, тешчә, ботак» — көнч. тк. *тарба-, тарпа-* «тырпаеп тору», бор. тк. *тар-* «бүлеп тору» фигыленнән.

**ТАРПАН** «тарпан; дикая лошадь» — к. **Тарпы.**

**ТАРПЫ-** «бить передними ногами (*о лошади*)» — *тарп* — имитатив сүз.

**ТАР-МАР** «разгром» — фарсы. *тар-у-мар* «тар-мар» (төгәл тәрҗемәсе: «җеп һәм чырымта» сүзеннән.

**ТАРТАР** «коростель» — бу кошның чыгара торган авазына охшатып ясалган атама *(тартай тартылдый)*; чаг. алт. *талтар, тартал,* хакас. *таарт* «тартай».

**ТАРТМА** «ящик (*выдвижной*)» — гом. тк. *тарт-у* фигыленнән (ягъни тартып чыгарыла торган әрҗә).

**ТАРТ-У** «тянуть; привлекать; весить; курить» — гом. тк. *тарт-* «тарту, үлчәү», гаять күп мәгънә биргән сүз; шулардан: «суыру (тәмәке тарту); качу (тартыну)» һ.б. үзләренә дә күпсанлы дериватлар тудырганнар; к. хакас. *тарт-* «тарту, бетү, кимү, азазлап тотыну», якут. *тарт-* «тарту, иснәү, иген сугу», тув. *тырт-* «тарту, суыру, фотога төшерү».

**ТАРУ** «пашня; зерновые» — уйг., бор. тк. *тары-ғ* «басу, иген, тары» сүзеннән, шул ук нигездән диал. *тарма, тарлау, тарнау* «бөртекле ашлык кыры, бөртекле ашлык чәчелгән яңа басу». К. **Тары.**

**ТАРЫ** «просо» — гом. тк. *тары, тарыг* «тары, иген» бор. гом. тк. *тар-, тары-* «сөреп чәчү» сүзеннән булса кирәк, борынгы заманнарда иң киң таралган ашлык тары булган; к. кк., ккк. *тары,* кырг. *тaруу,* үзб. *тары,* уйг. *тарық,* угыз. *дары* «тары», алт. *тарāн,* тув. *тараа* «иген, ашлык», бор. уйг. *тарығ* «бодай» (МК), уйг., алт., тув., хакас. *тары-* «чәчү», монг. *тари-* «чәчү», *тарма* «бөртекле ашлык» ~ тат., башк. *тарма* «конопля, растущая без света»; к. ш. ук диал. *тырлау, тарлау* «бүлеп алынган җир, көтүлек», кк., куман. *тарлау* «басу; янадан сөрелгән җир». К. Әхмәтьянов, 1989: 39—40.

**ТАРХАН** «тархан; свободный, никому не подчиняющийся» — бор. тк. *тархан, таркан* «тархан, салым җыючы — бор. ирани. tarxun «тархан», кытай. *tadxan «үзе идарә итүче хан» сүзеннән (С.Шапшал); к. ш. ук тат. диал. *тархан* («тархан яту, тарханда йөрү») «ирек, иркенлек, эшсезлек», монг. *дархан* «тимерче» (тимерчеләр салымнан азат булганнар). Борынгы документларда тагын *тарка, таркачы* дигән титул очрый. Бу сүз *тархан* сүзе белән бәйләнмәгән: бор. тат. *таркачы,* монг. *дарукачы* «өлкә белән идарә итүче».

**ТАС I** «тазик» — фарсы. *таст* «җиз табак» < бор. ирани. tast,



tašt, täšt «табак» сүзеннән таралган (күп телләрдә очрый). Тат. диал. *тач* «тас», *тасаяк* (*тас + аяк*) «блюдце».

**ТАС II: тас булу** «отставать, замешкаться» — кум., кб. *тас бол-* «адашу, артта калу», *тас эт-* «ташлау», калм., башк., азәрб. *тас* «югалган, аерылган» ~ монг. *тасу* «бөтенләй юкка чыккан». Шуннан ук *тас кол* «үлемгә хөкем ителгән кол» аны һәркем үтерә алган; хакас. *тас кізі* «кол», *тас аң* «атылырга билгеләнгән киек», тув. *дас* «иркәк поши» — аны атырга яраган.

Үлемгә хөкем ителгән колларны яшь сугышчыны кеше үтерергә өйрәтү өчен файдаланганнар. Әгәр тас кол кораллы кешегә каршы коралсыз көе каршылык күрсәтә алса, аның үзен сугышчы иткәннәр. Тас колларга үзләрен саклау өчен күп елгырлык, хәйлә, ярамсаклык һ.б. кирәк булган. *Тас* һәм *таз* сүзләрен буташтыру нәтиҗәсендә «алдар таз» образы килеп чыккан.

**ТАСКАК** «плоский навес на столбах, строительные леса» — мар., удм., алт., хакас. *таскак* «таскак, тире элү өчен махсус корылма, шүрлек, киштә»; ясалышы ачык түгел; чаг. алт. *такчак, тактачак* «такта урындык» (к. **Такта**); к. ш. ук себ. тат. *тазак, таскак, таткак* «таскак, шалаш».

**ТАСЛА-У** «стругать; разглаживать» — к. чув. *тасла-*; балкан төрекләрендә *тасла-* «таш таслау» — славян телләреннән (рус. *тёс* «тасланган агач»).

**ТАСМА** «тесьма» — гом. тк. *тасма,* монг. *тасама* «тар гына каеш, лента, тасма» бор. *тамса, тамыса* «тамны (тирмә түбәсен) тартып-кысып тора торган киң тасма» сүзеннән булса кирәк.

**ТАСТАР** «тастар (*старинный головной платок, напоминающий шарф*)» — башк., н., кк., кырг., чув. *тастар,* бор. тк. *дестар* «тастар» — фарсы. *дестар* «чалма» сүзеннән.

**ТАСТЫМАЛ** «полотенце» — фарсы. *дäстмал* «тастымал, кул сөрткеч» сүзеннән (*дäст* «кул», *мал* — *малидан* «сөрү» фигыленең нигезе); к. иск. әд. *дастымал,* диал. (мишәр.) *тасмал* «тастымал».

**ТАСЫЛ** «умение, смекалка в деле». К. башк. *тасыл,* алт. *тазыл,* тув. *дазыл* «тасыл, тамыр, таш тамыры» (к. мәкаль: *Тасылын белгән таш кискән*). Гарәпчәдән (*ысулга* тамырдаш) булуы шикле.

**ТАТАР** «татарин» — бу сүз турында бик күп фикерләр әйтелгән булуга карамастан, аның килеп чыгышы ачыкланмыйча кала бирә. *Татар* сүзен *тат* «ят кабилә (халык, ыру) кешесе» дигән (этноним буларак та кулланылган) сүздән дип аңлату (*татар* < *тат-эр*) безне канәгатьләндерми. Чөнки *тат* сүзе фарсыларга караган.

**ТАТЛЫ** «сладкий» — башк., кк., ккк., госм. *татлы,* чув. *тутлă* < алт., бор. тк. *татлығ, татлуқ* «татлы, тәмле» — тат. диал., гом. тк. *тат* < *тағат* «тәм» сүзеннән. К. **Таты-у.**

**ТАТУ** «согласно, мирно, дружно» — чув., мар., удм., гом. тк. *тату,* кырг. *татуу* «тату» — гом. тк. *татлыг* «татлы» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан булса кирәк; к. алт. *тату* «татлы, рәхәт» (< *татту* < *тат-луғ*), бор. тк., чыгт. *татыг, татун* «рәхәт, ләззәтле» (МК). К. тат. *таты-у, тат-у* «тәмен белеп алу».

**ТАТЫР** «осадок; ржавчина» — бор. тк. *татыр* «тутыккан» (Зәмәхшәри) сүзеннән, гом. тк., бор. тк. *тат* «тутык» (тат. диал. *тат* «тап, тут») нигезеннән.

**ТАУ I** «гора» — гом. тк. *тау, тағ*, бор. гом. тк. *тағ* «тау», угыз телләрендә *дағ;* чаг. монг. *дабаг* «тау, тарлавык, үткел» (Котвич).

**ТАУ II** «поздравление» — чув. *тав*, удм., мар. *тагу, тау* «рәхмәт булсын», кар. *табуу* «рәхмәт», кк. *тау* «энергия, сәламәтлек» — фарсы. *тап* «сәламәтлек, гайрәт, түземлелек, көч» һәм гар. *дәгъва* «теләк, чакыру» сүзләреннән контаминация булса кирәк; к. алт. *тап* «теләк, дәрт, ихтыяр», чыгт., госм., азәрб. *тап* «көч, түзем», *дау* «сәламәтлеккә атап шәраб эчү, отышлы уенда акчаны арттырып банкка салу», үзб. *тоб* «сәламәтлек, хәзерлек; теләк, түзем». К. Әхмәтьянов, 1981: 92—93.

**ТАУШАЛ-У** «измяться» — бор. *тауша-, тау-са-* «сәламәтлеккә туймау, сырхаулану» фигыленең төшем-юнәлеш формасы; к. тат. диал. *тауша-* «таушалу», госм., чыгт. *таушал-* «таушалу, ябыгу, зәгыйфьләнү», *тауса-, tawса-* «көчен югалту, хәлсезләнү». Сүзнең тамыры нининдидер *taү < *taaү ~ *taq «бик аз, зәгыйфь» сүзе булса кирәк; чаг. тат. *таксы-, такса-* «бетүгә йөз тоту, аз калу»; к. чыгт. *тавуш* «хәлсез, юка», кк., кб. *таус-*, хакас. *тоос-* «бетерү».

**ТАЧ** «точь-в-точь» — чаг. чув. *лач*, монг. *тас-* көчәйткеч кисәкчә «бөтенләй, тәмам».

**ТАЧКА** «сырой (*о хлебе*)» — чув. *тачка, тачăка, лачка* «пешеп житмәгән» — Урал-Идел даирәсендә — башлыча төрки телләрдә таралган һәм сыек баткакта атлаганда чыккан авазын белдерә торган *лач // лыч* тасвирый яңгырашлы сүзеннән; чаг. тат. диал. *лачка* «тачка», *тач киту, лач киту* «былчыракка егылу», *тач ит (май)* «беришле масса рәвешендәге ит (май)», *тачкыл-у* «үзлеләнү». Чаг. **Туч.**

**ТАШ** «камень» — гом. тк. *таш*, бор. гом. тк. **тал* «таш» сүзеннән; к. чув. *чул* «таш» ~ эвен. *дол*, монг. *тулун* «таш». Шуннан ук *ташла-у* (чаг. *таяк-ла-у*). К. **Чыг-у.**

**ТАШБАКА** «черепаха» — ташбаканың «таш» булуы очраклы түгел, борынгы гадәт буенча, мәңгелек символы итеп, кабер өстенә таштан ташбака сыны ясап куя торган булганнар (С.В.Киселев, P.Zieme һ.б.). Борынгы кыпчак-куман телендә ташбаканы *чирәп бака* дип атаганнар, шуннан русча *черепаха* «ташбака».

**ТАЯК** «палка» — гом. тк. *тайак*, бор. гом. тк. *тад-ак* «таяк» — тат. *тая-у* фигылennән; к. алт., шор. *тазақ* «таяк».

**ТӘБӘ** «яичница» — башк. диал. *тәбийә*, иске әд. *тәбәйи* «тәбә» — фарсы. *табәги* «табада пешерелгән ашамлык» сүзеннән; к. тат. диал., башк. *тәбейә* «тәбә». К. **Таба.**

**ТӘБӘЛДЕРЕК** «педаль ткацкого станка» — тат. диал. *табандырык*, кк., ккк. *табалдырык* «тәбәлдерек, бусага», хакас. *табалдырык* «олтырак» — гом. тк. *табан* (к.) сүзенә *-лдырык* аффиксы ялганып ясалган. Чаг. **Чөелдерек.**

**ТӘБӘНӘК** «низкий» — тат. диал, удм. *табанак, табан, тәбәш, тәбәшәк, тәбәк, тәбән* (Урал) «тәбәнәк» — жәенкелекне белдерә торган *лап* тәкълиди сүзеннән, к. диал. *ләпәшәк, ләпәк* (Урал) «тәбәнәк», *лапак, лапанак* «тәбәнәк юан (*кеше турында*), жәенке» (чаг. *тәпән*)» ~ чув. *лапан, лапака* «тәбәнәк, жәенке» һ.б. Сүзнең фонетик үсеше *лапанак > табанак > тәбәнәк.*

Бу сүзнең формалашуына *түбә* сүзенең гом. тк. *тәбә, тәппә* варианты да тәэсир иткән: к. себ. тат. *тәбән* «түбән», *тәбәчәк* «япма», кар. *тәбэнги* «түбәнге».

**ТӘБЕ** «мышеловка» — диал. *тәпе* «капкын, тәбе», чув. *табы* «тозак, капкын», *тапкычы* «тәбе» — тиз генә китереп сугуны белдерә торган *тап!* тәкълиди сүзеннән (Егоров); к. чув. *тап-* «сугу», гом. тк. *тап*, бурят. *таб* «хлоп!»; чаг. алт. *чапкы* «капкын, тәбе», *чап-* «китереп сугу (захлопнуть)».

**ТӘГӘРМӘЧ** «колесо» — тат. диал., гом. тк. *тәгәр, тәкәр* «тәгәрмәч, түгәрәк нәрсә, көпчәк» сүзенә *-мәч* аффиксы ялганып ясалган (чаг. *пәрәмәч, тукмач*); к. госм., азәрб. *тәкәр, тәкәрләк*, алт. (телеут.) *тәгәрәк*, чыгт. *тәкәрлек* ~ себ. тат. *тигәрчек, түгәрчәк* «тәгәрмәч»; к. ш. ук башк. *тәкмәк* «кечкенә тәгәрмәч». Сүзнең тамыры бор. *тәк* «түгәрәк». Шуннан ук тат. *тәгәрлә-ү, тәгәрә-ү, тегермән, тәүлек, тәкмәч, түгәрәк.*

**ТӘҖЕЛ** «срочный, скорый» — гар. *тәгъҗил* «ашыгыч».

**ТӘКӘ** «козел; баран» — гом. тк. *тәкә, тәккә* «тәкә, кыр кәҗәсе» сүзеннән; киң таралган сүз (монг., фарсы., угро-фин телләрендә дә бар). К. Әхмәтьянов, 1989: 71.

**ТӘКӘРЛЕК** «пигалица; чибис» — башк. *тәкәрлек*, чув. *текерлу, текерлек*, мар. *тăгарлă* «тәкәрлек, әкәм-төкәм, гомумән түгәрәкле хайван» — тат. диал., төрек. *тәкәрләк* «тешле тәгәрмәч, көпчәк» — гом. тк. *тәгәр, тәкәр* «түгәрәк, тәгәрмәч» сүзеннән булса кирәк; чаг. ш. ук госм. *тәкәрлән-* «тәгәрәп төшү, бөтерелү». К. **Тәкмәч.**

**ТӘКМӘЧ** «кувырок» — башк. *тәкмәс, тәкмәр*, төрек. *тәкәр мәкәр* id., *тәкмә-* «тәкмәчләү» гом. тк. *тәк* «әйләнә, түгәрәк» сүзеннән.

**ТӘЛӘЙ** «счастье; удача» — чув. *телей*, уйг., ткм. *тәләй, теләй* < бор. *талай ~ талань* «бәхет, өлеш» сүзеннән. К. **Талай.**

**ТӘЛӘКӘ** «валек; вертушка; поплавок» — кырым. тат., госм. *тәлигә*, чыгт. *тәлгән* «туп арбасы», монг. *тэлэгэн < тэрэгэн* «арба, тәгәрмәч, элмәк, алка» (> рус. *телега* «арба; ухват») гом. тк., монг. *тәк* «түгәрәк» тамырыннан. К. **Тәкмәч, Түгәрәк.**

**ТӘЛГӘШ** «гроздь» — < бор. *тәлкәч-*, гагуз., төрек. *тәл* «чук, бизәнү каурые; чыбык» сүзенең кечерәйтү формасы.

**ТӘМ** «вкус» — иске әд. *тәгымь* > чув. *техĕм* <гар. *тәғм* «тәм, яхшы ашамлык» сүзеннән. *Тәгамь* «аш-су» белән тамырдаш.

**ТӘМӘКЕ** «табак» — татарчага Урта Азиядән кергән булса кирәк; к. ткм. *тамәкә*, фарсы. *тамаку* id., русчага — Европа телләреннән. Бу сүз Американың жирле телләренең берсендә таралган.

**ТӘМИЗ** «аккуратный; чистый» — төрек. *тәмиз* (< гар. *тәмйиз*) «чиста» сүзеннән алынма.

**ТӘН** «тело» — фарсы. *тäн, тан* «тән, буй» < бор. ирани. tanu «тән, гәүдә» сүзеннән килә.

**ТӘНӘ-Ү** диал. *тенә-ү* «восстановить силы после родов (*у лошади*), после длительного бега» — башк. *тана-у, танат-у* id. Чаг. монг., тунгус. *тэний-* «тураю»; тат. диал. *тен (тын) басу* «берничә ел иген игелмәгән, ял иткән басу».

**ТӘНӘКӘ** «принцесса» — иске тат. *кәнәкә, кәникә*, әдәби телдә *ханәкә* id. < монг. *ханкэн* «хан кызы, ханча» сүзеннән Алтын Урда чорында кергән. Чаг. **Тутай.**

**ТӘҢГӘЛ** «тождественный; соответствующий» — башк. *тәңгәл,* чув. *тенкел, тенкĕл,* мар., удм. *тäнгäл, тäнгыл,* кырг. *денгел (дэнгэл)* ~ тув. *деңнел* id.; тунгус-маньчж. *тэңкә, тәңку, тәңки* «тигез тугай, терраса», *тәңкәл, тәңкил* «тиңләр, тигезләр» (чаг. тат. диал. *тиңгел* «кимәл»). Сүзнең тамыры — гом. тк., монг., тунгус. *тәң* «тиң, тигез».

**ТӘҢКӘ** «монета; рубль; чешуя» — гом. тк., монг. *тэнкэ, теңкэ* «тәңкә», бор. тат. *дәңге* > чув. *тенкĕ,* мар. *танка, танкы,* удм. *танка, тэнкы* — киң таралган сүз (шуннан ук рус *деньга* «акча»), чыгышы — фарсы теленнән (бор. фарсы. danik, danika «көмеш тәңкә, соңрак tangga «дирһәмнең дүрттән бер, динарның сигездән бер өлеше); чаг. ш. ук **Тиен.**

**ТӘҢРЕ** «всевышний, бог» — гом. тк. *тәңри, тәңири,* көнч. тк. *тәңәрә, таңара,* монг. *тәңгэр, тэңэри,* эвен. *тангара* «тәңре, күк императоры» — чыгышы ачык түгел; чаг. шумер. *диңир* «күк; алла; тәңре»; к. ш. ук бор. монг., тк. *чыңгыз* < **тыңыр* < **таңыр* «күк алласы».

**ТӘПӘН** «кадка, бочонок для меда» — мар. *тапан, тäпан* id. *тәбәнәк* сүзе белән бәйле Идел-Урал сүзе.

**ТӘП** «точка отсчета при планировке участка, заложении дома» ~ тат. диал., башк. *тап* «нокта, билге итеп куелган йомычка, казык» ~ монг. *таб* «ашыкның тигез ягы (ашык шул ягы белән төшсә, уен яңадан башлана)» К. **Тап.**

**ТӘПӘЧ** «молотило, било цепи» — диал. *тәпәүче* «тәпәч» — *тәпә-ү* (< *тапа-у*) сүзеннән; чаг. ш. ук мар. *топец,* рус. *дубец* «тәпәч».

**ТӘПИ** «лапка (*животных, ножка ребенка*) — диал. *тәпәй,* алт. *табаш,* хакас. *табаң,* якут. *табагай* «яланаяк (*табаны*), тәпи», монг. *тавхай* «тәпи» — гом. тк. яланаяк белән йөрүне яки йөгерүне белдерә торган тасвирый яңгырашлы *тап // лап* сүзеннән; чаг. рус. *лапка,* бор. немец. tappe, итальян. zampa «тәпи», эвен. *таба-н-* «тәпиләү, тәпи-тәпи йөрү, йөгерү». Чаг. **Тапта-у.**

**ТӘПКЕ** «пятка» — *тәпә-ү* сүзенә нисбәт ителергә тиеш; һәрхәлдә, бу сүзне рус алынмасы дип карау дөрес түгел.

**ТӘРБӘЙ, ТИРБӘЙ** *диал.* **тырпай, тырбай** «экономически оправданный, хозрасчетный» — ~ чув. *тирпей* id. < гар. *тәрбигъ* «дүрткә бүлү» сүзеннән: ислам икътисади тәгълиматы буенча, керем дүрткә бүленергә тиеш — бер өлеше маяга, икенчесе — түләүләргә, өченчесе — кулланышка, дүртенчесе — житештерүне дәвам итүгә.



**ТӘРӘЗӘ** «окно» — башк. *тәзрә,* н., кк., ккк., кум., кар. *терезе, тэрээз,* уйг. *деризе, дәризә,* көнч. тк. *дәричә, тэррэчэ,* фарсы-таж. *дәричә* «кечкенә ишек; тәрәзә» (*дәр, дар* «ишек») сүзеннән. Чув. *чӳрече, тӳрече, тӧрече* ~ мар. *тӧрезе, тӧрзэ* < болгар **тӧрәжә.* К. Әхмәтьянов, 1989: 141.

**ТӘРӘШ** «чесаный лен» — *тарау* сүзеннән ясалган кебек күренсә дә, чынлыкта фарсы. *тäрäш* «тетелгән йон» сүзеннән булса кирәк.

**ТӘРЕ** «христианский крест» — тат. диал. *тәйре,* кб. *тейри* «мәжүси алла, *тәңре*» сүзеннән: бу сүзнең татар телендә тискәре мәгънә алуы кыпчакларның бер өлеше христиан булуына бәйләп аңлатыла. К. **Тәңре.**

**ТӘРЖЕМӘ** «перевод» — гар. *тәрҗимә-т-үн* «тәрҗемә» сүзеннән, *рҗм — рәҗәмә* «кайтып яңгырау (эхо)» тамырыннан.

**ТӘРСӘНӘ** «арсенал; мастерская оружия» (XIX гасыр татар сүзлекләрендә очрый) < фарсы. < гар. *дәр әс-синага* «остаханә» (*дәр* «ханә», *синага* «сәнәгать»); рус. (французчадан) *арсенал* сүзе дә шул ук сүзгә кайтып кала: французлар *дәрәссинагада д* авазын үзләренең *д'* кушымчасы дип кабул иткәннәр.

**ТӘРТӘ** «оглобля» — кк. *тәрте,* кк. диал., кырг., иск. тат. *тарта* > чув. *турта* «тәртә» — *тарт-у* (к.) сүзеннән дип хисапланыла; чаг. башк., себ. тат. *тәртнә* «кечкенә чана».

**ТӘТӘЙ** «тетя» — к. мар., чув. *тетей,* морд. тядяй, *тядякай* «тәтәй» — татарчадан. Чаг. **Түтәй.**

**ТӘТЕ** «собачка ружья; курок» фарсы. *дәсти* «тәте, кулса» сүзеннән булса кирәк, чаг. ш. ук себ. тат. *тәсе* < *дәсти* «руль; соса».

**ТӘТИ** «красивые игрушки; красивый» (*в детском языке*) — соклану ымлыгы *әттә-тә* сүзеннән килеп чыккан; к. диал. *тәтәй, тәтәкәй* «чәчәк; тәти»; *тәтәй* «әти, апа, әни, түти һ.б.» (төрле жирдә төрлечә әйтелә), *титек* «кечкенә» ~ кк. *теттей* «кечкенә», чув. *тетте* «тәти».

**ТӘҮ** «начало; происхождение» — уйг. *тәк,* кырг. *тэк* «нәсел, чыгыш, раса» — бор. тк. (Орхон язм.), үзб. *тәг* «чыгыш тамыры, төп. башлангыч» сүзеннән. Чаг. **Ти-ү.**

**ТӘҮБӘ** «раскаяние, покаяние» — гар. *тәуба-т-үн* «тәүбә» сүзеннән. Шуннан ук чув. *тупа,* удм. *тубо* «тәүбә, ант».

**ТӘҮГЕ** — к. **Тәү.**

**ТӘҮЛЕК** «сутки; период времени» — башк. *тәүлек,* кк. *тәулик,* чув. *тавлăк, талăк* «тәүлек», тат. диал., башк. *йыл тәүлеге* «ел буе», бор. *тәглик* «период, тәүлек» — бор. гом. тк. *тәг, тәк* «түгәрәк, әйләнә» сүзеннән (Ашмарин), к. хакас. *тэглек,* ткм. *тегелек* «түгәрәк, әйләнә» (чаг. тат. *ел әйләнәсе* — тулы ел буена), чыгт. *тәвлүк* «тәүлек, тулылык» (Боровков чагыштыруы); к. ш. ук бор. тат. сүзлекләрендә *таулык* «ел (год)», мар. (бор. чув. теленнән — ?) *тавык* «период, вакыт аралыгы»; чув. *çанталăх* < бор. болгар. **җандалык* < *җиһан-тәүлек* «дөнья, жиһан, галәм, һава торышы». К. Әхмәтьянов, 1989: 22—23.

**ТӘХЕТ** «трон, престол» — фарсы. *тахт* «тәхет, диван, утыргыч, тахта» сүзеннән таралган (к. гар. *тухт-ун* «тәхет»); рус. *тахта* сүзе белән бер. К. **Такта.**

**ТЕГЕРМӘН** «мельница» — гом. тк. *тәгирмән, тигәрмән, тегүрмән* «тегермән, тегермән ташы» — гом. тк. *тәгир, тигәр* «тәгәрмәч, көпчәк» сүзенә *-мән* кушымчасы ялганып ясалган (ягъни «әйләнә торган нәрсә, зур түгәрәк» дигән сүз булган). Тат. диал., башк. *тирмән*, кб. *тирмен*, монг. *тэрмэн* «тегермән, тирмә» — *тегермән* һәм *тирмә* сүзләренең контаминациясе ясалган булуына ишарә; к. бор.тк. (МК) *дегирме* «түгәрәк». К. **Тәгәрә-ү.**

**ТЕГ-Ү** «шить» — гом. тк. *тик-*. К. **Текә.**

**ТЕЗ** «колено» — гом. тк. *тиз, тизә* «тез, калкып чыгып торган урын» сүзеннән, бор. гом. тк. **тирғь, *тәрғь* «тәндә калкып чыгып торган төш» тамырыннан; к. чув. *чӗр* < **тӗр* «тез». К. **Терсәк.**

**ТЕЗГЕН** «повод» — гом. тк. *тизгин, дизгин* «тезген, йөгән» гом. тк. *тез-ү* (к.) сүзеннән (ягъни «аллы-артлы тезелеп барган атларны бер-берсенә бәйли торган бау» мәгънәсендә).

**ТЕК (басу)** «вертикально (*стоять*)» — к. *текә, текә-ү, тик.*

**ТЕКӘ** «крутой; круто» — бор. әд. *текәк*, үзб. *тиккә*, кк. *тикә*, алт. *чикэ*, монг. *чикэ*, эвенк. *тики* «текә, туры» — гом. тат. (бор. әд.) *тек, дек*, гом. тк. *тик* «туры, текә, вертикаль, тигез» сүзеннән (чаг. ш. ук кытай. *чик* «туры басып торучы, тигез»). Шуннан ук *тек-ү* «кадату; җөйләү».

**ТЕКМӘ** «тын, плетень» — *тек-ү* фигыле нигезендә ясалган сүз (*тек-мә* «колгалар кадатып ясалган киртә»).

**ТЕЛ** «язык» — гом. тк. *тил, тыл* «тел» сүзеннән; к. тат. диал. *телдәр, телмәр* «үткен телле», *телә-ү* < гом. тк. *тилә-* «тел белән әйтү»; к. ш. ук бор. тк. *кал, кил,* удм. *кил, кыл,* фин. kiel ~ монг. *хил, хэл* «тел, сүз». К. **Келә, Кәләш, Тылмач.** К. Әхмәтьянов, 1989: 112—114.

**ТЕЛӘК** «желание» — гом. тк. *тиләк* «теләк» — *тилә-* нигезендә ясалган. К. ш. ук тат. *теләү, келәү* «мәҗүси дога» (тат. диал. *кел* > чув. *кӗл* id.). К. Әхмәтьянов, 1989: 112—114.

**ТЕЛМӘР** «речь; человек, могущий долго говорить» — к. бурят. *хэлмэри* «тәрҗемә» — *хэлэ-* «сөйләү» сүзеннән (Дондуков), бор. монг. *кэлмэрчин*, калм. *келмерчи* «әкиятче, тәрҗемәче, кош телен белүче» > башк. *тәлмәрйен*, тат. диал. *тәлмәрҗен* «бака» (дастан әйтүче кебек сайрый торган җәнлек), алт., кырг. *тилмерчи* «кошлар телен белүче кеше, күрәзә, тылмач». К. **Тылмач**.

**ТЕҢКӘ: теңкә корыткыч** «надоедливый» — кк., ккк. *диңгә*, үзб. *тинкә*, чув. *тинкә, тӗнкә* «теңкә, нерв; көч, гайрәт» (үзб., н. *тиңкә куру-* ~ кырг. *диңге кур-* «хәл бетү»), бор. тк. (Орхон язм.) *тәң* «көч, гайрәт» сүзеннән булса кирәк (Егоров). К. калм. *теңкен, теңкеген* «саулык, көч», алт. *тэңки-* «сәламәтләнү, көчәю».

**ТЕРЕ (К)** «живой» — гом. тк. *тири, тириг* «тере; үлмәгән» бор. тк. *тир-* «яшәү, даимән бар булу» сүзеннән. Чаг. бор. *ти* «даим».

**ТЕРЛЕК** «домашний скот» — *терелек* сүзеннән (чаг. *кешлек* < *кешелек*). *Терлек* сүзе татар теленең үзендә ясалган.



**ТЕРСӘК** «локоть» — тат. диал. (себ. тат.) *терескәк* «хайваннарның арт аяк терсәге; күздәге арпа», чыгт. *терсәк* «терсәк, тез бөгелеше», бор. тк. *тирсгәк* «терсәк, күздәге арпа» (МК), тув. *дис, дискэк,* хакас. *тизэк* «терсәк; күздәге арпа», кк. *тиләрсәк, тирәлсәк* «терсәк» — бор. тк. *терс-, тәрсә-* «очлаеп чыгу, очлаеп кабару» фигыленнән, тамыры *тәр* «очлы чыгынты» булса кирәк. К. **Тез.**

**ТЕТРӘ-Ү** «дрожать» — гом. тк. *титирә-* < *тиртирә-* «дердер итү».

**ТЕШ** «зуб» — гом. тк. *тиш, диш* «теш»; чув. *шӑл, шӗл* «теш, оч» < бор. гом. тк. **сил* «очлы сөяк, теш» сүзе белән бәйләнеше шикле.

**ТЕШЕ** «самка» — диал. (себ. тат., урал) *тише*, гом. тк. *тиши*, якут. *тысы* «теше; нечкә, озын». *Кеше* сүзе белән тамырдаш [к < т].

**ТИГӘНӘ** «большая деревянная чаша; колода» — гом. тк. *тәгәнә, тәкәнә* «зур агач табак, тигәнә, улак», эвенк., эвен. *такэт, такан,* удэг. *тиа* «улак, тигәнә, түмәр, кискә». К. **Тигәч.**

**ТИГӘЧ, ТӘГӘЧ** «деревянная чаша» — диал. *тәгәц, тәwәч,* башк. *тәгәс*, кк. *тегеш*, үзб. диал. *тәкәш* id., ихтимал, *тәк* «түгәрәк» сүзеннәндер. К. **Тәүлек.**

**ТИГӘНӘК** «репейник; терновник» — бор. тк. *тикән-әк* «чәнечкеле нәрсә», *тикән* «чәнечке, шырпы» — гом. тк. *тик-* «чәнчү, кадау, тек утырту» фигыленнән (к. **Тек-ү**); к. диал. *ак тикән* «крыжовник», алт. *тэгэн* «ылыс, чыршы», *тэгэнэк* «шиповник», үзб., бор. тк. *тикэн, тиккэн* «чәнечке» (МКда *тикди* «кадады» сүзеннән дип аерым әйтелә), алт., хакас. *тегәнәк, тәгәнәк* «тырнак, тырнак авыруы», н., кум. *тегенек* «тигәнәк».

**ТИГЕЗ** «ровный; равный» — гом. тк. *тегиз, тәкиз,* бор. гом. тк. *тәң-из* «тиңнәр, үзара тиң нәрсәләр» сүзеннән булса кирәк.

**ТИГЕН** «даром» — *тик* (к. **Тик I**) сүзенең инструменталь килеше.

**ТИЕН I** «белка» — гом. тк. *тейин, тәйиң* «тиен» — Себердә киң таралган сүз; к. эвен. *деңкэ* «тиен, кеш», манси. *лэин*, ханты. *таңгэ* «тиен; бер тиен акча». К. **Тиен II.**

**ТИЕН II** «копейка» — тат. диал., башк., үзб., таҗ. *тин*, уйг., кк. *тиин* — **Тиен I** сүзе белән бердәй (борынгы заманнарда тиен тиресе вак акча функциясен үтәгән; чаг. мар., морд. *ур*, удм. *коньы* «белка; копейка»). Рус. *белка* сүзе башта вак акчаны белдергән һәм татарча *акча* сүзенең калькасы булып тора (төрки *ак* ~ рус. *бел*). К. **Акча.**

**ТИЕШ** «должен» — *ти-ү* фигыленнән.

**ТИЗ** «быстро, скоро» — госм. *тиз*, уйг. *тиз*, гом. көнб. тк. *тәз, тез* «ашыгыч; тере, тиз, җәһәт» — фарсы. *тез*, бор. ирани. *tez, tez* «тиз, үткер, кызу, ашыгыч» сүзеннән.

**ТИЗӘК** «кизяк; навоз» — гом. тк. *тәзәк, тэзэк,* балкар. *тезгек* «кәс; тизәк». Бор. тк. *кэзэк, кэзгэк* «тизәк» сүзеннән; к. тат. *кизәк* «коры тизәк». Бор. гом. тк. *кэз-* «тезем, төркем; тезү» сүзеннән булса кирәк. К. **Кәс.**

**ТИК I** «без дела, без движения; *союз* только, лишь» — тат.

диал., башк. *тәк* «эшсез, бушка, тиген», алт., куман. *тәк* «тиккә, юкка, тыныч, тавышсыз», чыгт., госм., азәрб. *тәк, тек* «тик; эшсез; тыныч», чув. *тек* «тыныч, хәрәкәтсез, тавыш-тынсыз», бор. тк., госм., чыгт. *тәк* «тавышсызлык, тигез, тыныч, берүзе», тув. *тик* «ноль, буш», хакас. *тик* «бушлай, тиген» *тиң* (к.) сүзе белән нисбәт ителергә тиеш, к. Робгузида *тәк* «тиндәш, ялгыз, тик, сынар», кар. *тәк* «фәкать, тик»; к. ш. ук госм. *тәкин* «ялгыз; эшсез; тыныч», бор. язм., уйг., алт. *тәгин* «сәбәпсез, тиген». К. **Тиген.**

**ТИК II** «как, подобно» — бор. тк. *тәк, тәг* «кебек, шикелле» сүзеннән; шуннан ук *-тай, -тәй // -дай, -дәй* охшату кушымчасы килеп чыккан. Чаг. **Тиң.**

**ТИКЛЕ** «до *кого-чего-л.*» — диал. *тәкле, тиклем, тиңенте, тиңле, тиңлек* «тикле, чаклы» — бор. тк. *тәк, тәң* «билгеле бер сызык, чик» сүзеннән, *тиң* (к.) сүзе белән бердәй булса кирәк; к. ш. ук алт., уйг. *тәги*, чыгт. *тәгру* «тикле, чаклы».

**ТИКШЕР-Ү** «проверять; исследовать» — уйг. *текшур-*, үзб. *текшир-*, кк., ккк. *тексир-*, кырг. *текшер-* «тикшерү», чув. *тишкĕр-*, н., кырым. *тикшер-, тәшкер-* «тикшерү, сынау, аңлау», бор. тк., кырг. *тәкши* < кытай. *тәңси* «үзара тигез, гадел» сүзеннән.

**ТИЛЕ** «глупый, дурной» — алт., куман., кар. *тәли(г)*, госм., кырым., чыгт. *дәли*, кк. *дели*, бор. тк. *тәлү, дәлү* «тиле, дуамал, мавыгучан, җилбәзәк», алт. диал. *тали* «бер тирәдә әйләнү» — җилләнүне белдерә торган гом. тк. *сал // тал // дал // йал* тамырыннан (к. **Җил**) булса кирәк; чаг. тат. диал. *тиле* «шаян», *тиләскәү* «тилерәк», *тилбер* «тиз йөри торган, җилбәзәк», үзб. *телба*, бор. тк. *тәлwә*, уйг. *тәлбә* «тиле», кк. *делбе*, башк. *тилбә* «котыру авыруы», алт. *тилби* «көчле теләк, омтылыш», *тәлби-* «шаяру», *йилби* «дәрт, гыйшык дәрте». Чаг. удм. *тӧлӧ* «тиле, җилбәзәк», *тӧл* «җил» яки рус. ветер «җил», *ветреный* «җилбәзәк, тиле».

**ТИЛЕБӘРӘН: тилебәрән орлыгы** «белена» — *тиле* (к.) нигезендә ясалган, ләкин *тиле бәрән* дип карасак, мәгънәсе аңлашылып бетми, дөресе, диал. *тиле бәлән* (*бәлән* «балан») булса кирәк.

**ТИЛЕГӘН** «коршун» — алт. *тәйләгән*, хакас. *тигелгән*, чыгт. *түйләгән*, бор. тк. *таңгәлгүч, тәнгәлгүн* (МК) «тилгән» — сүзнең беренчел формасына татар диал. *түрләгән, түгерләгән* «тилегән» сүзе якын: бор. *тәкүр-лә-гүн* «әйләнгеч, һавада әйләнеп, түгәрәк ясап очып йөрүче» (*тәкүр-* «түгәрәк, әйләнә»); к. *тәгәрмәч, тегермән-, тәкүрлә-* «әйләнә ясау, әйләнү» — *гүн* исем ясагыч кушымча булган булса кирәк; к. бор. язм. *тилгән* «тәгәрмәч, көпчәк» (Габәин); к. ш. ук алт. *тәәр-* «һавада әйләнеп очып йөрү» < **тәгәр-* id.

**ТИЛМЕР-Ү** «умолять *кого-л.*; нуждаться в помощи» — удм. диал. *тәлмыр-*, мар. *телмыр-*, чув. *тĕлмĕр-*, гом. тк. *тәлмир-* бор. **тәлим иер-* «күп елау» сүзеннән булса кирәк (к. бор. *тәлим* «күп», чув. *йĕр-, иер-* «елау»).

**ТИЛҮ** *диал.* «допущенный к корове без ограничений (*о те-*



*ленке)*» — н. *тәлү* id., себ. тат., башк. *тил-* «бозауны сыерга җибәрү», кырг. *эки энеге тел* «ике инәгә тил ике сыерны имүче», алт. *телкин* «балалы болан». Рус. *теля* «бозау» сүзе дә төрки телләрдән булса кирәк.

**ТИЛЧӘ** «ящур; золотуха» — чув. *тилче, тилçе*, башк. *тилсә, силсә* «тилчә; сөяк туберкулезы» — фарсы. *селчә, селл* «тилчә; сөяк туберкулезы» сүзеннән. Мар. *телеза* «тилчә» — болгар теленнән.

**ТИЛПЕН-Ү** «вспархивать; махать» — җилләнүне белдерә торган гом. тк. *сал // тал // дал // йал* тамырыннан (к. **Җил**); к. диал. башк. *тилп иту* «талпыну, тилпенү», якут. *талыбыра-, тәлибирә-, тәлибрә-* «калтырау, тибрәнү». К. **Талпын-у.**

**ТИМГЕЛ** «пятно; сыпь» — диал., башк. *тимкел* «сипкел; тап», кырг. *темгек*, монг. *тәмдәг* «билге, тамга», алт., бор. тк. *тәм* «тап, билге, миң» сүзеннән (*тим-гел <тәм-кил*). К. **Тимрәү.**

**ТИМЕР** «железо» — чув. *тимĕр*, гом. тк. *тәмир, темур*, бурят. *тумар* «тимер, тимер деталь», бор. кытай. te, ter «тимер» + mur «әйбер» сүзеннән дип уйлыйлар. К. Севортян, 1980: 188—190.

**ТИМРӘҮ** «лишай; экзема» — гом. тк. *тәмирәү, тәмирәткү* id., бор. *тәмир-, тәмирә-* «тимгелләнү» сүзеннән. К. **Тимгел.**

**ТИНТӘК** «глупый, бестолковый» — чыгт., кырым., кар., кк. *тәнтәк, тентәк* «тинтәк, тиле; чая, шаян, үткер» — алт., бор. тк. *тәнтә-, тинти-* «аяксып тору, тиккә йөренү» фигыленнән (Дыренкова), ниндидер *тән* тамырыннан; к. алт., уйг. *тәнә-* «бушка кангырап йөрү, тилелек эшләү», алт.,. тув., бурят. *тәнәк, тәнәг* «тинтәк, тилелек», якут. *тәник, тәнтик* «тиле», тат. диал. (себ. тат.) *тинәк* «бума тоту», хакас. *тин* «исерек, бераз башы әйләнгән», калм. *денд* «таркалган», *денде* «тинтерәү». К. ш. ук тат. диал. *тинтерә-ү* «аптырау, юкка селкенеп йөрү», тув. *тәндири*, якут. *тәмтәри-*, хакас., кырг. *тинтрә-*, алт. *тәнтир-* «тинтерәү, бушка йөрү, абыну, сөртенү, калтырау» — *тәнти* «аптыраган» сүзеннән; тат. диал. *тимен-у* < *тинтен-у* «авырлык белән яшәү».

**ТИҢ** «равный; равенство» — гом. тк. *тең, тәң*, угыз. *дең, дәң*, монг. *тәң*, маньчж. *тәң, таң* «тиң, дөрес, таман, анык, нык» — төрки телләрдә бик күп дериватлар биргән һәм бик күп сүзләр белән контаминацион мөнәсәбәткә кергән тамыр сүз, к. **Тәңгәл, Тигез, Тик** (I, II), **Тикле**. К. ш. ук көнч. тк. (алт.) *тәң, тäң*, «хак, үз хакы, үлчәм», кытай. *тәң* «үлчәү; тигез, тиң». К. Әхмәтьянов, 1981:93.

**ТИП** «большой бубен» — гом. тк. *тәп*, фарсы. *даф, таф, табыл* (бик күп телләрдә очрый) id., ахыр чиктә шумер телендәге *дабаллу* «зур барабан» сүзенә кайтып кала. Шуннан ук иске тат. *дабылбаз, давылбаз* «гаять зур сөрән (гау) барабаны» сүзе дә килә. К. **Давыл, Тибрә-ү.**

**ТИП-Ү** «пнуть, пинать, ударить ногой» — гом. тк. *тәп-, тәп*, чув. *тап-* «тибү, таптау» — һәртөрле тибүне, суккалауны белдерә торган *тап // лап* тәкълиди сүзеннән; шуннан ук *тиберчену, тыпырчын-у, тыпыр-тыпыр килү*. К. **Тапта-у, Тапа-у, Тәпке, Тип-че-ү.**

**ТИПТӘР** «тептярь» — Г.А.Әхмәров бу сүзне «дәфтәр» сүзеннән чыгара (А х м а р о в Г.Н. Тептяри и их происхождение. Казань, 1908: 301, 363 — 364). Бу фикерне А.И.Тәфкилев (Тәфтиләү) язмалары да раслый: «Татары, чуваши, черемиса живут на башкирских землях без письменных обязательств, те наз. бобылями, а прочие из вышеупомянутых живут на башкирских землях по записям (*дәфтәр*), а те называются тептери» (К и р и л л о в И.К. Материалы по истории России. — Оренбург, 1900: 105). *Типтәр* сүзенең *дәфтәрдән* килеп чыгуы хакында бүтән чыганакларда да күп тапкырлар әйтелә һәм тел фактлары да шуны раслый; к. мар. *тептер* «закон, тәртип, акыл», чув. *типтер* «исемлек, бирка, тәртип, чират», кк. диал. *типтәрь* «дәфтәр, рулон, язу» (Будагов). Шундый дәлилләр булуга да карамастан, татар-башкорт публицистлары арасында берничек тә нигезләнмәгән версия — *типтәр* сүзен *тип-* фигыленнән чыгару таралган. К. Әхмәтьянов, 1989: 167 — 169.

**ТИР** «пот» — гом. тк. *тәр, тар*, мар., чув. *тăр, тар* «эш хакы, яллау, яллану» сүзе дә шуннан.

**ТИРӘ** «окрестность» — бор. тк. *тәгрә, тагра* > бор. болгар. *тәүрә, *тәүрәсе > чув., мар. *тавра, тавраш* «тирә». Бор. *тәүер- (чув. *таврă*) < *тәгир-* «әйләндерү» фигыленнән ясалган (бор. *тәгирәг «тирәлек; әйләнә-тирә»). Сүзнең тамыры — гом. тк. *тәү* < *тәг* «әйләнә, түгәрәк» бик күп сүзләрнең төп чыганагы. К. **Тәгәрә-ү, Тәгәрмәч, Тәкмәч, Тәүлек, Тегермән, Тилгән, Түгәрәк, Чүрә** һ.б.

**ТИРӘК** «тополь; осокорь» — гом. тк. *тэрәк* «тирәк, тополь», уйг. *тэрэк, дэрэк* «бик зур агач, изге агач» — фарсы. *дэрэхт* (рус. *дерево* «агач» сүзе белән тамырдаш) «агач» сүзеннән.

**ТИРӘН** «глубоко; глубокий» — гом. тк. *тәрән, тэрэң, тэриң*, алт. диал. *төрөн*, тк. derin. Сүзнең иң борынгы фонетик вариантына ишарә чуваш телендә: *тарăн, тавăрăн* < болгар *тәүерең. Бу вариант *тирән* сүзен бор. *тәүрән, тәгрән, тәгирән* «су өермәсе» сүзеннән, *тәү* < *тәг* тамырыннан дип уйларга нигез калдыра (к. **Тирә**), эвен., эвенк. *дэрэн, дөрән* «чишмә, тирән күл, өермә».

**ТИРГӘ-Ү** «ругать, бранить» — гом. тк. *тэргэ-* «җентекләп тикшерү» сүзеннән, бор. *тэриг* «тезеп салу, тезеп күрсәтү» сүзеннән булса кирәк. К. **Тирге, Тирмә**.

**ТИРГЕ, ТӘРГЕ** *диал.* «комплект; гроздь» — чув. *тиркĕ*, мар. *теркы*, удм. *тэрки* «савыт-саба» — тат. диал. *тир-* < гом. тк. *тәр-* > тк. *дәр-* «тезү» сүзеннән.

**ТИРЕ** «кожа; шкура» — гом. тк. *тери, тәри* «тире» сүзеннән. Чаг. хакас. *тээр* «тире».

**ТИРЕС** «неприглядный → навоз» — чув. *тирĕс*, уйг. *тәрс*, бор. тк. (МК, Орхон һ.б.), алт., кк. *тэрс*, монг. *тэрс* «кире; каршы, капма-каршылык; тискәре» фарсы. *тăрса* «дошман як» сүзеннән. К. **Тискәре**. К. Әхмәтьянов, 1989: 194.

**ТИРМӘ** «юрта» — башк., кк. *тирмә*, тув. *терме, тербе*, монг., калм. *тэрм*, куман. *тэрмэ* «тирмә, хатын-кыз бүлмәсе» *тир-ү* «җыю, тезү» сүзе белән тамырдаш булса кирәк (ягъни



*тирмә йорт* «җыйма йорт»), алт. *тэр-* «җыю», *тэргэ-* «юлга җыенып, бөтен кирәк-яракны барлау» (шуннан ук тат., башк. *тиргә-ү* «әрләү; шелтәләп тикшерү»); рус. *терем*<тк. *тэр-им* «кыз тирмәсе». К. **Тирге.**

**ТИСКӘРЕ** «непослушный; изнанка» — бор. *тэрскэри* «кире якка» сүзеннән; к. уйг. *тискәри*, алт. *тэскэри* «кире якка, каршы якка, тискәрегә». Сүзнең тамыры гом. тк., монг. *тэрс*>тат. *тирес* «тискәре; дошман; төньяк». К. **Тирес**.

**ТИТАК** «хромой» — к. азәрб., кк., кырг. *тайтак* «чатан, аксак», *тайта-* «аксау», кк., кырг. *тайтакта-, тайтаңда-* «чатанлау, бот аерып басу». Мари. *титак* «хата, ялгыш» — татарчадан.

**ТИЯК** «деревянные палочки вместо пуговиц» — бор. тк. *тигәк, тик-әк* «кадама, элэктергеч» сүзеннән, *тик-* «кадау, чәнчеп кую» фигыленнән булса кирәк (к. **Тек-ү**); к. алт. *тэгэк* «кармак», тк. *тегек* «кәтүк; агач борындык», хакас. *тээк* «казык, багана», бурят. *тээг* «тияк, төймә».

**ТОБА** «омут; проток» — чув. *тăпа*, рус. *туба* «тоба, ат капчыгы», морд. *дуба* «тирән урын», кк. диал. *тыма* «тар култык» һ.б. рус. *турба*, тат., тк. *торпа, турпа* «ат капчыгы (солы салып, ат башына элә торган капчык)» сүзе белән бәйләнешле дигән фикер бар.

**ТОВАР** «товар» — бу сүз бор. тк. телләрдән. К. **Табыр, Туар.**

**ТОҖЫМ** «паутина» — *чыҗым* (к.) сүзе белән тамырдаш.

**ТОЗ** «соль» — гом. тк. *туз*, монг. *дабусу(н)* «тоз» — бор. гом. тк. *табург «тоз» сүзеннән; к. чув. *тăвар, тоар* «тоз», эвенк. *турука* «тоз». Кайбер телчеләр бор. тк. *табур* «тоз» сүзен *туар* һәм *товар* (к.) сүзе белән бердәй дип карыйлар (борынгы заманда тоз иң таралган товар — сәүдә әйбере булган).

**ТОЗАК** «силок, ловушка» — гом. тк. *тузак* «тозак» — ясалышы буенча *туз- тамырыннан; к. чыгт. *тозғақ* «тозак» (Севортян, 1980: 289).

**ТОКЫМ** «порода; потомство» — гом. тк. *тукум, тухум* «токым; йомырка» — фарсы. *тухм*, бор. фарсы. taoxman «йомырка, күкәй, орлык» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1989: 70.

**ТОЛ** «вдовый» — гом. тк. *тул* «тол хатын» сүзеннән; к. ш. ук чув. *тăлăх*, якут. *тулайах* «тол».

*Тол* сүзе беренчел мәгънәсендә «терлектән тоташ көе салдырылган тире» булган, элегрәк ул тиренең эченә салам тутырып, үлгән кешенең сынын ясап куя торган булганнар. Ире үлгән хатын, хатыны үлгән ир туксан көн буе шул толны «ашатып-эчертеп» яшәргә тиеш булган (к. иск. *тол* «буш», *тол гамәл* «файдасыз эш»). *Тол* «тоташ салдырылган тире» тамырыннан *толым, толын, толып, толык* («мех капчык»), *толыкман* («брутто; бик зур капчык») һ.б. сүзләр ясалган. *Толык* «буш тире» сүзеннән тат. диал., башк. *ток, токчай/токсай* «тире капчык» сүзе килә.

**ТОЛЫМ** «коса (*волосы*)» — ком. тк. *тулум, тулук* «толым, чәч яки йон учламы, кыркылмый калдырыла торган йон яки чәч өлеше», бор. тк. *тулуқ* «ат ялы, атның маңгай чәче; чигә»

(MK) һ.б.; мар. *тылым* «сарык тиресендә алынмаган йон толымы» — төрки телләрдән. Ниндидер *тул* тамырыннан; к. чыгт. *тулугун* «хатыннар толымы».

**ТОЛЫН** (*диал.* **толык, толк > ток**) «кожаный мешок для воды или соли» — к. төрек., үзб. *тулум*, монг. *тулум, тулам*, маньчж. *тулума*, венг. tömlö «толын». К. **Тол**.

**ТОЛЫП** «тулуп» — кк., ккк. *тулуп*, чув. *тăлăп* «толып». Ясалышы ачык түгел; чаг. бор. тат. *тулуп, тулум*, госм. *тулум*, кырг., алт. *тулуп* «хайваннан тоташ көе салдырылган тире һәм шуннан эшләгән җөйсез капчык», бурят. *тулам* «күн капчык». Рус. *тулуп* төрки телләрдән булса кирәк. К. **Тол**.

**ТОМА** «совершенно, отроду» — *тума* сүзеннән. К. **Ту-у**.

**ТОМАЛА-У** «закрыть; затыкать; окутать» — кк., алт., куман, *тумала-* id., күрәсең, *тума* «бөке, каплавыч, бөркәү» сүзеннән һәм *тома балавыз* «прополис» шуннан килә. Чаг. **Томар-у**.

**ТОМАН** «туман» — гом. тк. (> рус.) *туман* «томан» бор. ирани. dumnan «төтен, томан» сүзеннән дип уйланыла. Чаг. **Томала-у**.

**ТОМАНА** «бестолковый, глупый» — Идел-Чулман регионында: чув. *тăмана*, мар. *тымана*, мар. диал. *тумна* «томана; ябалак; байгыш» рус. диал. *темная* «сукыр ябалак, байгыш» дигәннән булса кирәк; сүзнең формалашуына иске тат. *томай* < алт., хакас. *тумай, томай, тумара* «сыңгырау, томана» сүзе дә тәэсир иткән.

**ТОМАР** *диал.* «тумар» (*футляр для молитв, оберегов, талисманов*) — иске тат. «эченә документ салынган җиз көпшә» — гом. тк., фарсы. *тумар* id.; чыгышы ачык түгел; чаг. монг., бурят. *даамари, дагу-, мари* «томар».

**ТОМАРЧЫК** *диал.* «булава; бутон цветка; тупой наконечник стрелы для охоты» — гом. тк. характердагы *тум, том* «бүлтәймә, комалак, тумпалык» тамырыннан. К.**Тумпа, Тумран, Түмәр.** Рус. *томар* «стрела с тупым наконечником» — татар теленнән.

**ТОМАУ** «насморк» — башк., кк. *тымау*, төрек. *тумағы, думағы*, бор. тк. *тумағу* «томау», бор. чыгт. *тумак* id., бор. *тума* «томалану, тын юллары ябылу» сүзеннән булса кирәк.

**ТОМРА-У** «выглядит молчаливым, но сильным, глубоким» — диал. *томыра-у* < *тома-ра-у* «капланып китү, карангылану» сүзеннән. Чаг. якут. *тумарый-* «томанлану». Ихтимал, бор. *томыр* «каплаулы» сүзе дә булгандыр; к. тат. диал. *томрай-, томырай-* «карангылану». К. **Томса**.

**ТОМСА** «хмурый (*о человеке*)» — диал. *төмсә* id., себ. тат. *томас* «болытлы», кк. *томсар-* «ачулы, кырыс булу» бор. *том // тум, тома // тума* «капланган, бөкеле» тасвирый янгырашлы тамырдан. Ихтимал, *тамра-у* «тын гына, ләкин җитди, тирән булу» сүзе белән тамырдаштыр.

**ТОМШЫК** «клюв» — госм., кк. диал. *тумшук*, алт., тув. *тумчук* бор. *тум* «тумпаеп, бүлтәеп торган нәрсә» сүзеннән. Чаг. **Тумпа**. К. ш. ук госм. *томуш-* «бер-берененң томшыгын чистарту» (димәк, *тому* «томшык чистарту» фигыле булган); иске (Троянский) *томыш* «борын сырты» ~ якут. *тумул* «тау борыны (мыс)», *тумус* < *тумуш* «томшык».

**ТОМЫР-У** «бросать, забросать» — бор. **том-* < *тум-* «кизәнеп, җилләнеп хәрәкәт итү» сүзеннән кебек, әмма бүтән төрки телләрдә *тӧмур-, тумур-* «кизәнеп бәрү, утын яру» сүзе генә очрый.

**ТОМЫРЫК** «глухой залив; тихий облачный день» — алт. *тумарык* «томан; томырык көн» — бор. *тумар-* «томанлану» фигыленнән.

**ТОН-У** «отстояться; оглохнуть» — гом. тк. *тун-* «ябылу, каплану, тону, төпкә утыру»; шуннан *тӧнык* < гом. тк. *тунуқ* бер яктан «үтә күренмәле; икенче яктан, «бераз болганчык» (*мәс, тонык тонган күз*). Әдәби телдә «бераз болганчык» мәгънәсе генә калырга тиеш.

**ТОНЧЫГ-У** «захлебнуться» — *тончыг-у* «тона төшү» фигыленең интенсивлык формасыннан.

**ТОРБА** «труба» — XIX гасырда «морҗа» мәгънәсендә кергән. Рус. *труба* латин. trumba сүзеннән килә.

**ТОРМА** «редька» — фарсы. *турп, туруп* «торма, шалкан» сүзеннән; к. диал. *торба*, кк. *туруп*, үзб. *турп*, азәрб. *турф, турпак* «ачы торма».

**ТОРНА** «журавль» — гом. тк. *турна* id. — торна торкылдавына охшатылып ясалган имитатив сүз; чаг. удм., коми. *тури*, якут. *туруйа*, монг. *туғрағун*, корей. *турум*, япон. *куру*, бор. ирани. zurana, немец. Kranich «торна».

**ТОРПЫЧА** «катушка для перематывания ниток» — рус. сөйл. *трубица* «шүре, торпыча» сүзеннән, *труба* нигезеннән; чаг. диал. *топырча, турбичә* «торпыча». К. **Торба**.

**ТОРПЫША** — К. **Торыпша**.

**ТОР-У** «стоять, встать; жить, существовать» — гом. тк. *тур-* «тору, туктау, яшәү, булу» сүзеннән. К. **Тырышу**.

**ТОРЫК** «звено; пролет» — бор. тк. *тогуруқ* «арка озынлыгы» — бор. *тоғур* «арка үзәге, меридиан» сүзеннән; к. чув. *тырых* «торык», бор. тк. *турук* «арка буе» (MK), монг. *туруг* «озынлык, буй», бор. чыгт. *тур, турк* «озынлык (киңлеккә каршы куела)»; к. ш. ук тат. *аркылы-торкылы* «вдоль и поперек», хакас. *тоғыр* «арка, аркылы, каршыда», удм. *тыбыр* «арка, умыртка», бор. тат. *тывыр, тыуыр* < **тогур* «арка үзәге». К. **Тура-у, Туры.**

**ТОРЫПША** «торбище, кошель» — рус. диал. *торпище, торбище* «зур торба (җәймә)» сүзеннән; рус. *торба* «ат капчыгы, җәймә» төрки *торба, тобра* «капчык» сүзеннән, төрки сүз, үз чиратында, бор. ирани. dubra «капчык» сүзеннән; к. госм., кырым. *торба* «капчык, сумка», алт. *торбо* «атның борынына кидерелә торган капчык», бор. чыгт. *тубра* «кәгазь өчен капчык» (Зәмәхшәри).

**ТОТЛЫГ-У** «заикаться; задерживаться» — госм. *тутлуқ-* һ.б. *тотыл-* < *тутул-* «тотылу» сүзенең интенсивлык формасы. Чаг. **Алтлыгу, Йотлыгу, Язлыгу**.

**ТОТ-У** «держать, хватать» — чув. *тыт-*, гом. тк. *тут-* «тоту» —

бор. тк. *ту- «тукталу» тамырыннан булса кирәк: *тот-* < *тут-* фигыленнән төрки телләрдә гаять күп сүзләр ясалган, мәс., тат. *тоташ, тоташу, тотка, тоткар, тотын-у, тоткыч,* пассиврак кулланышлы *тотак, тотанак, тотнак, тоткак, тотыш-у.*

**ТОЧ** «бронза» — к. чыгт., бор. тк., бор. монг. *туч* «бронза» ~ фарсы. *тунч* «бронза, каракургаш».

**ТОЯК** «копыто» — бор. тк. *туйак* «тояк, тырнак» (МК), уйг., алт. *туйғақ,* хакас. *туйқақ,* тув. *дуйуг,* якут. *туйах, тойнақ, дойнақ* «тояк», бор. чыгт. *туйнақ* «тояк» — бор. тк. *туй-, туйла-* (алт. *туйла-*) «тибү, тибенү» сүзеннән булса кирәк; чаг. ш. ук эвенк. *тука* «тибү». Монг. *турагун, тугур-аг-ун* «тояк», ихтимал, төрки *туй-* «тибү» — бор. **туңур-* «тибү» сүзеннәндер. Чаг. **Турак.**

**ТӨБӘК** «определенная местность» — диал. *түбә* «төбәк, калкулык, түбә», башк. *төбәк* «елга борылышы, төбәк, урын», *түбә* «ыру биләмәсе, ыру җире», чув. *тĕпек* «баш түбәсе, лепкә, түбә, алан» — гом. тк. *туп* «урын, нигез, үзәк, түбә» сүзеннән. К. **Төбә-ү, Төп, Түбә.**

**ТӨБӘ-Ү** «нацелиться» — *төп* сүзеннән.

**ТӨБЕТ** «волкодав» — бор. тк. *түбүт* «тибетлы, тибет эте» сүзеннән; чаг. ш. ук *тоьбет,* кк. *төбет,* кырг. *дөбөт* «төбет; иркәк бүре». К. **Дебет.**

**ТӨГӘЛ** «точно, ровно» — уйг., чыгт., куман., кар. *түгәл, түкәл* «төгәл, бөтенләй», бор. тк. (МК) *түкәл* «төгәл, тәмам» — уйг., бор. тк. *түкә-* «тәмамлану, бетү» фигыленнән (*түкә-л*); к. уйг., чыгт., көнч. тк. *түгәл-* «бетү, тәмамлану», алт. *түгэзэ,* монг. *төгүз* «төгәл, ахырынача». К. тат. *төкән-у* «бетү».

**ТӨЕН** «узел, сверток» — чыгт., бор. тк. *түйүн, түгүн* «төен» — гом. тк. *түй-, түг-* «бәйләү, төйнәү» сүзеннән; к. тат. диал. *төй-у* «чәчнең толымнарын бергә йомарлап кую», алт. *түй-* «бәйләү», үзб. *түг-,* чыгт. *түк-,* госм. *дүй-* «төйнәү», чыгт. *төг* «төен ясау», чув. *тĕвĕ* «төен, элмәк» < **төwек.* К. **Төер, Төймә, Төйнә-ү, Түл, Түлә-ү, Төр-ү.** Шул ук тамырдан *төй-ә-у.* Сүзнең тамыры *төй* < *түй* < *түг* ~ чув. *тĕв* «төен».

**ТӨЕР** «комочек» — диал. *түйүр, төйер* «төер, төен» — бор. *түгүр* «төйнәлгән нәрсә» (*түг-үр*) сүзеннән булса кирәк, к. чыгт. *түгүл* «төен, төер». К. **Төр-ү.**

**ТӨЗ** «прямой» — гом. тк. *түз, дүз* «төз, тигез, шома, унай» — бор. гом. тк. *түр, төрг* «төз, тигез» сүзеннән; к. чув. *тӳре* «төз», мар. *тӧр* «төз, дөрес». К. **Төзә-ү, Төзек, Төзе-ү.** Кб. *түз,* тат. диал. *төзәм* «түбән, уйсу җир, дала» — икенчел мәгънә. К. Әхмәтьянов, 1989: 40.

**ТӨЗЕК** «исправный» — чаг. үзб., уйг., чыгт. *түзүк* «тәртип, кагыйдә, төзек, дөрес» (*түз-* «төзү» фигыленнән) һәм чыгт. *түзәк* «төз, төзек» (*түзә* > *төзә-* фигыленнән).

**ТӨЙМӘ** «пуговица» — бор. тк. *түймә, түгмә* «төймә, төен» (элегрәк төймә ролен очы төйнәлгән каеш тасма яисә киндерә кисәге үтәгән) сүзеннән, *түг-* «төйнәү» тамырыннан (*түг-мә*); к. үзб. *тугма,* бор. чыгт. *түгмә* «төймә». К. тат. фольк. *Кызлар ефәктин төймә төяләр.*



**ТӨК** «волосок» — гом. тк. *түк* «төк, йон» сүзеннән; к. себ. тат., башк. *төлә-ү* < *төклә-ү* «ябага кою».

**ТӨКЛЕТУРА** «шмель» — чув. *теклетура,* тув. *дуктугары* «шөпшә, төклетура» — *төкле* (йонлач) *тура* (аяк) сүзеннән. Чаг. ш. ук хакас. *түктиг аар* «шөпшә», кк. *түкти ари,* үзб. *тукли ари (ари* «бал корты») «шөпшә». К. **Турак.**

**ТӨЛКЕ** «лиса, лисица» — гом. тк. *тулки, тилку, тулку* «төлке» — этимологиясе бәхәсле; *туклу* «төлке (йонлач)» дип аңлату бар. Тик безнеңчә, *тулку* тибетчә *тулку* < *трулку* «өрәк (төрле кыяфәткә керә торган җен)» сүзеннән; төлкенең кеше булып, аждаһа булып һ.б. әверелүе Көнчыгыш Азия әкиятләрендә еш очрый. «Йертөшлек» дигән татар әкиятендә **төлке** аждаһа булып әверелә.

**ТӨМӘН** «десять тысяч» (*төмән төрле* «десять тысяч сортов») — гом. тк., монг., эвенк. *түмэн,* бор. тохар. *тумане* «ун мен». Ун мең санының бик тә күп (чаг. *миллион*) мәгънәсендә йөргәнлеге *мәңге* сүзендә дә чагыла. К. **Мәңге.**

**ТӨН** «ночь» — гом. тк. *тун,* ткм. *дүйн* «төн, кич, караңгылык» сүзеннән. Шуннан ук *төнә-ү* «кунып төн уздыру».

**ТӨНӘ, ТӨНӘГЕН** (*диал.*) «вчера, вчера вечером» — халык этимологиясендә *төн* (к.) сүзенә нисбәт ителә, ләкин к. тат. *кәнә-көн* «төнәгэн», кк. *куне,* чыгт., кар., куман. *тунэ* «кичә, элегрәк»; сүзнең тамыры — фарсы. *күһнә* «элекке, үткән, иске».

**ТӨНӘ-Ү** «настояться; подвергаться испытанию» — дөресе *тенә-, тинә-,* к. себ. тат. *тинә-,* төрек., гагауз. *дэнә-* «озак сынау» бор. тк. **тәң* «егетлекне сынау (инициация)» сүзеннән.

**ТӨНЛӘ** «ночью» — уйг., чыгт. *тунлә* < *тун илә* «төн белән» дигәннән (әдәби алынма булса кирәк).

**ТӨННЕК** «дымовое отверстие» — гом. тк. *тунлук, тундук* «тәрәзә, төннек, чаңгырак (чумның яки тирмәнең түбәсендә төтен өчен тишек)», бор. тк. *түңлүк* «төньяк», эвен. *туннук* «тәрәзә» — ихтимал, бор. тк. (МК) *түң, тәңәк* «һава, күк» сүзеннәндер; к. алт., тув. *дүндүк* «зенит». Татар телендә бу сүз *төтенлек* дигәннән бик ансат кына ясала алган булыр иде.

**ТӨП** «основной; дно; пень; корень» — гом. тк. *туп* «төп, нигез, тамыр», тув. *төп* «үзәк», бурят. *түб, түбэ* «урта, үзәк».

**ТӨР** «вид; сорт» — гом. тк. *түр* «күренеш, төр, төс, бизәк» — гом. тк. *тус* «төс» кебек үк *ту* «төк, төсмер» сүзеннән санала. К. **Төс.**

**ТӨР-Ү** «свертывать» — гом. тк. *түр-* < **түгүр-* «төенләү» сүзеннән.

**ТӨРӘН** «лемех (*у плуга*)» — чув. **тĕрен,* гом. кыпчак. **түрэн,*

**ТӨРКЕМ** «группа» — монг. *төркүм* «группа», тат. диал., башк. *түркен,* кк., ккк. *дүркин,* бурят. *түркэм, түрбэл* «килененнең туган-тумачасы, аерым группа» гом. тк., гом. монг. *төрө-, төрү-* (тат. диал. *түрә-ү*) «үрчү, кардәш-ырулы булу» сүзе белән тамырдаш. *Төрек, түрек* сүзләре дә шуннан булса кирәк.

**ТӨРМӘ** «тюрьма» — чув. *тĕрме,* мар. *тӱрмӓ* id. русчадан, рус теленә исә иске төрки *түрмә, түрбә* «төрбә (өсте ябулы кабер, шунда тоткыннарны да япканнар)» сүзеннән, *түр-* «төрү» фигыленнән дип карала (Рясянен).

**ТӨРТ-Ү** «ткнуть» — гом. тк. *тұрт-* id.

**ТӨС** «цвет» — уйг., чыгт. *тус*, кк. диал. *туз* «төс, күренеш» бор. *ту* «төк, төсмер» сүзеннән (*ту-су* «төсе» дигәннән кыскарган) дип уйлыйлар. Чаг. **Төр**.

**ТӨТЕН** «дым» — гом. тк. *тутин, тутун* id., бор. тк. *тут-* «төтен, ис, төтәү» ~ бор. һинд- иран. *dud-* «төтәү», *du* «төтенләнү, булану» сүзеннән. Шул ук *тут* нигезеннән *төтәс, төтәсләү* һәм *төтрә-ү* «томанлап яву» да килә.

Утрак төрки (уйгур, татар) дәүләтләрдә IX гасырдан бирле *төтен, тутун* «йорт, хужалык; салым түләү берәмлеге».

**ТӨТКӘЗ-Ү** «запастись» — ~ чув. *тăхта-* id.; чыгышы билгесез сүз. Чаг. бор. тк. tit-, һинд. tyagad-, hanam — «даимән корбан биреп бару».

**ТӨЧЕ** «пресный; приторный» — диал. *чөче, чөчек* < чыгт. *чучук, сучук*, бор. тк. *сучиг* «төче, баллак» бор. *сут-сиг* «сөт тәме килә торган» сүзеннән (Рамстедт). *Төче-* бор. *сут-си-* «сөт кебек булу» дигәннән (чаг. *сассы-* < *сарсы-, сөрсе-* < *сурси-* *-сы //-си* аффиксы белән ясалган сүзләр бар).

**ТӨЧЕ**: **төче авыруы** «волчанка» — чув. *чĕчĕ, чӳчӳ*, мар. *чучи, чӱчӱ*, удм. *чучи*, морд. *суча, цуце* id. дә татар телендә *төче* нигезеннән ясалган булса кирәк.

**ТӨЧЛЕГӘН** «заболонь, оболонь» — диал. *сөтлегән* id. сүзләрендә *-ган / -гән* — үсемлек исемнәре ясагыч кушымча. Чаг. **Карлыган, Бөрлегән.**

**ТӨШ I** «полдень» — гом. тк. *туш* «төш; көньяк» (чаг. тат. диал. *төш, төшлек* «көньяк») сүзеннән.

**ТӨШ II** «сновидение» — гом. тк. *туш*, бор. тк. *түуш* «төш, йокы» — бор. гом. тк. **тул* «төш күрү, мәрт» сүзеннән; к. ткм. *дүйш*, якут. *түүл, тулук* «төш», чув. *тĕлĕк* «төш, йокы», мар. түлек «мәрт (летаргия)» — бор. болгар теленнән; бор. уйг. *тул* «төш». Чаг. тат. *төлер-ү*, чув. *тĕлĕр-* «йокымсырап китү».

**ТӨШ III** «место» — гом. тк. *туш, тус* «кирәкле урын; момент, чак» — бор. гом. тк. *тул* «урын; нокта; чак, момент» сүзеннән; к. чув. **тĕл* «теш, урын, очрак». Түбәндә **ТӨШ I** белән бердәй булса кирәк.

**ТӨШ IV** «ядро (*орешка*)» — фин-угор телләреннән булса кирәк; к. мар. *туш*, удм. *тысь*, коми. *тусь* «төш, орлык, бөртек, тамчы»; тат. диал. *төш* «ядро».

Омонимнардан качу принцибыннан чыгып шул вариантны активлаштыру хәерле (*төш коралы* түгел *тош коралы*).

**ТУ I** «освобожденный от работы (*о лошадях*)» — башк., алт., кк. *ту*, хакас. *туғ* «кысыр (бия), симертелә торган (елкы)», бор. монг. *табуғ* «ирекка җибәрелгән, сугымга калдырылган яки үрчемгә билгеләнгән (мал)» сүзеннән, *таба-, таби-* «үрчемгә яки сугымга калдыру» фигыленнән. К. **Тугар-у**.

**ТУ II** «знамя» — бор. гом. тк., монг., маньчж., корей. *туг, туң, тук* «байрак» — кытайча *дуң, *дук* «байрак» сүзеннән (Рамстедт, Владимирцев). *Ту* сүзе тарихта эчгәлекле эз калдырган: элекке ядкәрлекләрдә *ту киңәш* «генераль җәң (сугыш) алдыннан үткәрелгән киңәш», *ту казан* «хәрби берекнең бергә җыелып ашавы (гадәттә сугыш алдыннан)».

**ТУАР: мал-туар** «домашний скот» — диал. (мишәр.) *тавыр, тыwар*, кум., кырым. *тувар*, кк., ккк., н. *туар* «яшь мал көтүе, терлек, мал; товар» (ихтимал, гом. тк. *туғ* «туу» сүзеннән (Рясянен), кырг. *туuар* «теше терлек; кытай ефәге», бор. тк. *таwар* «мал, ярак», уйг. *табар* «ефәк, товар», бор. уйг. *тафар* «мал көтүе, мал, байлык» (МК); к. ш. ук бор. тк. *табар, табур* «байлык, олау, сәүдәгәрләр олавы, сатлык мал» (шуннан венг. tabor «чегәннәр табыры» > рус. *табор*), бор. рус. *товар* «табыр, олау; байлык, сатлык мал», *товарище* «күп сәүдәгәрләр бергәләп оештырган уртак олау», сонрак «уртакка кергән сәүдәгәрләр», шуннан хәзерге рус. *товарищ* «иптәш»; к. алт. *табар* «товар, һөҗүм, яу, атлы гаскәр». Кайбер телчеләр шушы ук нигезгә тат. диал., рус. диал. *тагар, тавар* «капчык, янчык» (чаг. *тағарак*) һәм *туғар-у* сүзен дә кайтарып калдыралар (чаг. бор. чыгт. *тубан* «капчык»). К.: Е л к и н а Н.М. Этимологические исследования по русскому языку. 2-е изд. — МГУ, 1962.

**ТУБАЛ** «круглое лукошко из коры дерева, луба» — иске тат. (мәсәлән, М.Иванов «Татарская хрестоматия»сендә) *тулаб* «цилиндрик савыт» ~ Гиганов сүзлегендә *дулап* «поставец» ~ угыз телләрендә *долаб* «түгәрәк кысага урап ясалган савыт» бор. *дол, тол* «әйләнә, чүлмәкче чыгыры; чүлмәкче чыгырында эшләнгән керамика» сүзеннән; *толаб*ны фарсыча *толи аб* «су чүлмәге» дип анлаталар (Будагов). *Тол* сүзе үзе төрки, к. **Тула, Тулма.** *Тубал* сүзе «ашлык чәчү өчен кабык савыт» мәгънәсендә татар теленнән күрше төрки һәм финугор телләренә дә кергән.

**ТУБЫК** «щиколотка» — гом. тк. *тобук*, бор. тк. *топук* «тубык, туп» (МК) — *туп* (к.) нигезеннән (*туп-ык*).

**ТУБЫЛГЫ** «таволга» — тат. диал. *тубырхан, тубылдык*, удм. *тубылгы*, мар. *товылго* «тубылгы, чыбыркы сабы», тат. диал. *тубалгы*, бор. тк. *табылку*, алт. *табалгы*, сагай. *табылкат*, чув. *тăпăлхă*, кырг. *табылга*, кк., ккк., н. *тобылгы*, кум. *тобургу*, якут. *тобулуоскай*, *тамал-* бор. гом. тк., монг. *топул-* «үтә чыгу, тишек булу» тамырыннан. Тубылгының кайбер төрләре йомшак үзәкле, туры ботаклы була. Үзәген тишеп, аннан шүре һ.б. ясала; к. фарсы. *тубурлан* «чыбыркы сабы». Икенче яктан, тубылгының чәчәкләре шарсыман була.

**ТУБЫРЧЫК** «шишка; пробка» — гом. тк. *тубырчык, топурчук*, монг. *тогурчак* «тубырчык» — тат. диал. *тубыр* ~ гом. тк. *тобур, топур* «оешма (тк. *топар* «төркем»), оерша, тупсыман яисә тупланган нәрсә» нигезеннән, *туп // топ* тамырыннан. К. ш. ук себ. тат. *тубырцык, тубырцын* «нарат күркәсе; тубык, бәкәл», хакас. *тобырчын* «очы туплы, төенле чыбыркы», алт. *тобырчық* «төен, чыбыркы очындагы йомры, шарчык», куман. *топурчук* «йомры, йомарлак».

**ТУҒАЙ** «извив реки; луг» — гом. тк. *тоғай, тоқай* «тугай, болын», төптә «елга бөгелеше, дугай» мәгънәсендә булган; к.

монг. *токой, тохой* «елга бөгелеше, дугай, терсәк» — *тохих* «бөгү, бөгелү». Рус. *тугай* — татар теленнән. К. **Тугым**.

**ТУГАР-У** «распрягать» — гом. кыпчак. *тоғар-, туғар-* id. *ту* «йөксез, буш» сүзеннән (*ту-ғар-у*; чаг. *суғар-у*; к. Әхмәтьянов, 1989: 87). К. **Ту I**.

**ТУГЫЗ** «девять» — гом. тк. *тоғыз, тоғуз, тоққуз* < бор. тк. **токкур* (к. чув. *тăхăр, тăххăр* «тугыз», төрек. диал. *докурҗин* «тугызташ уены»), безнеңчә, бор. *тōк коргу* «күзгә бәрән» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1988: 113 — 114. Бор. рус. *тахьрь* «тугызлык яки унлык» болгар теленнән.

**ТУГЫМ** «обод» — диал. *тугын, дугын*, чув. *тукун*, мар. *тугун*, кырг., үзб. *тогу*, н., кк., ккк. *тогын*, кум. *тоган*, тув. *дугуң*, монг. *дугуйн* «бөҗра» (к. **Тугай**) сүзеннән, тамыры бор. тк. монг. *тоа-* «бөгү».

**ТУЗ** «береста» — гом. тк. *тоз, тос* < бор. **торс* < *тобурс* «агач яки каен тубыры (бүлтәймәсе)» сүзеннән: каен тубыры, аның тузы кебек үк, савыт ясарга бик җайлы булган. К.**Тырыс**.

**ТУЗАН** «пыль» — гом. тк. *тозан, тозаң* «тузанлы, тузгыган нәрсә» (монда борынгы *-ан / -аң* аффиксы *-ган* белән бердәй түгел), бор. тк. *тооз* «тузан» < бор. гом. тк. **тогургь* ~ **тобургь* id., шуннан ук *тобурғақ* > *топрақ* «туфрак». К. **Туз-у, Туфрак**.

**ТУЗ-У** «подниматься (*о пыли*); изнашиваться» — чув. *тус-*, мар., удм. *тос-, туз-* гом. тк. *тоз-, тооз-* id. *тооз* «тузан» сүзенең фигыль варианты.

**ТУЙ** «свадьба; пир» — чув., мар., удм. *туй*, гом. тк. *той* бор. тк. toñ «хан оештырган тантана» сүзеннән; бу сүзне гом. тк. *туй-* < *той-* «туюю» сүзе белән дә баглыйлар.

**ТУЙРА** «дубок, дуб (*молодой*)» — чув. *туйра* «яшь имән», морд. *тояра*, удм. *туйыро* «куак» — бор. тк., уйг. *тоғрақ* «тополь» сүзеннән килә. Бу сүзнең тамыры бор. тк. *тоғ* «сумала, җилем»; к. бор. тк. toγraγu «сумала», шуннан *тоғ-ра-* «сумалалау» фигыле ясалган һәм сумала бирә торган барлык агачлар *тоғрағ* яисә *тоғрангы* диелгән; шуннан тат. *торангы*, кк. *турангы*, үзб. *турангил* «тамариск (сумалалы бер агач)».

**ТУК** «сытый» — гом. тк. *ток* «тук, тулы», бор. тк. *тозук* бор. toδ– «туюю» сүзеннән (шуннан ук чув. *тăр-, тур-* < *tod- «туюю»). Бор. toδ- фигыле үз чиратында нindидер *то-* «тулы булу» сүзеннән, к. *тулы* < *то-луг.*

**ТУКМАК** «колотушка, деревянный молоток» — чув. *тукмак*, мар., удм. *токмак, тукмак* — гом. тк. *тоқмақ* id. *тоқы-* > тат., башк. *туқы-* «суккалау, туку» фигыленнән ясалган.

**ТУКМА-У** «бить; колотить» — татар һәм башкорт телләрендә генә очрый; *тукы-у* гом. тк. *тоқы-* «постукивать; бить; взбивать; ткать» сүзенең интенсивлык формасы.

**ТУКМАЧ** «лапша» — бор. чыгт., госм. *тутмач*, алт. (куман. *тутмаш* «тукмач», бор. монг. *тусма* «тукмач» (чаг. *тасма*) — нindидер бор. *тут // тус* фигыленнән (*тут-мач*), татар телендә *тукмач* булып *тукы-у* (к.) фигыле тәэсирендә (халык этимологиясе буенча) үзгәргән.



**ТУКРАН** «дятел» — гибрид сүз: бер яктан, тат. диал. (себ. тат., мишәр.) *тумыркан*, көнч. тк. *тумуркун* «тукран» (*томыр-у* фигыленнән), икенче яктан, кк., тат., башк. диал. *тукылдык, тукылдауык* «тукра» (*тукылда-у* фигыленнән); к. диал. *тукыркан*, алт. *тоңыртка*, хакас. *тобыргы* «тукран»; чаг. якут. *тоңсоғой*, эвен. *товтокит, таптоқ* «тукран».

**ТУКСАН** «девяносто» — көнч. тк., бор. тк. *токкус он* «тугыз ун» сүзеннән. Чаг. *Сиксән*.

**ТУКТА-У** «остановиться» — чув. *тахта-*, удм. *тукталля-, дуктъ-* < гом. тк. *токта-*, монг. *тогта-* «туктау, тукталу» бор. *турукта-* «торып тору» сүзе белән баглы булса кирәк; к. тат. диал., башк. *тукра-у* «тукталу».

**ТУКЫМ** «подседельник» — гом. тк. *токум* «тукым» бор. тк. *токы-, току-*, монг. *тохо-* «иярләү, төяү, арту, аудару» сүзеннән.

**ТУКЫ-У** «ткать; многократно повторять» — гом. тк. *току-* id. Тәкълиди сүздән (*тук-тук* итү).

**ТУЛА** «сукно домашнего производства» — чув. *тăла* «тула», бор. тат. *тулак* «аякка чорный торган калын материя» (К.Насыйри), чыгт. *толағ* «ыштыр», госм., азәрб. *долақ, долағ* аякка чорнау өчен тукылган озын һәм тар сукно кисәге, аяк киемен биләп куя торган каеш (портянка) — бор. тк. *тула-, тулга-* «урау, чорнау» сүзеннән (к. азәрб., госм. *тола-*, чыгт. *тула-* «урау, чорнау»). К. **Тубал, Тулгак, Тулган-у, Тулма**.

**ТУЛАЙ(ЫМ)** «оптом; общий» — чыгт. *толай* «бөтенесе», *тулылай* сүзеннән (к. **Тул-у, Тулы**). *Тулайым* варианты *тулылайын* дигәннән.

**ТУЛГАК** «родовые схватки» — бор. тк. *тулға-* «боргалану» сүзеннән (к. **Тулган-у**); к. кк., ккк., н., кырг. *толғак* «тулгак».

**ТУЛГАН-У** «болтаться; крутиться» — гом. кыпчак. *толган-* id. гом. тк. *толға-* (> угыз. *дола-*) «әйләндерү, чолгау, сару, ишү, бору, боргалау, борып сыгу» фигыленнән. Тамыры—**тōл* булса кирәк. К. **Тула, Тулгау, Тулма**.

**ТУЛГАУ** «стих в дастане» — н., кк., ккк. *тōлғау* «тарихи җыр, поэма», *тōлға-* «речитатив белән җырлау» > тат. диал. *тулга-у* id. гом. тк. *толға-* «әйләндерү, чолгау, әйләнү-тулгану, төрлесен уйлау» сүзеннән; к. кырг. *толғон-* «үткәннәргә кайтып уйлану».

**ТУЛКА** *ист., диал.* «шлем, втулка» — морд., рус. диал. *тулка* id., удм., коми. *тул* «тулка, чөй», кк. *долқа, дулқа, долға* < монг. *долго, дулга, дагулка* > иске үзб. *дағулға* «шлем, кирәгә», азәрб. *дулғу* id.; чаг. ш. ук себ. тат. *тулға* «өчаяк, өч терәкле казан» ~ якут. *дулға*, монг. *тулға* һ.б. «терәк багана; өчаяк»; көпчәк күчәренең втулкасы шлемга охшаш булганда, монда төрле нигезләр буталырга мөмкинлек туган булса кирәк. Рус. *втулка* үзе алынма сүзләрдән санала.

**ТУЛМА** «голубцы» — төрек. *долма* id. *тул-* ~ *дол-* «тулу» сүзеннән дип уйланыла, ләкин гагауз. *долма* «тулма» бор. *дол-, тол-* «урау» сүзенә ишарә итә шикелле.

**ТУЛПАК** «старинная монета из серебра» — башк. *тōмбак* ~

төрек. *томбак* «томпак, җизнең бер төре» — рус. *томпак*, француз. tombac id., малайя. tombaga «җиз» сүзеннән таралган.

**ТУЛПА** «коренастый, кондовый» — башк. *тулпанҡы*, үзб. диал. *толпак*, чув. *тăлпам, тăлпам* «зур гәүдәле, тулпа» ~ кк. *тулпан* «бөтен гәүдә, зур гәүдә» *тул* (к. **Тол**) сүзеннән булса кирәк; к. ш. ук себ. тат. *тулман* «тулымса гәүдәле».

**ТУЛПАР, ТОЛПАР** «быстроногий конь» — кк., үзб., кырг. *тулпар* «тулпар», алт. *тулбар* «ябык ат», кб. *тулпар* «җитез, тиз», чув. *тăлпар* «зур гәүдәле, көчле» (*ат турында*), тат. диал. *тулпа* (*тау ягында*), чув. *тăлпан* «ныклы, юантык» һ.б. Борынгы заманда иң яхшы, таза гәүдәле, күндәм һәм шул ук вакытта йөгерек атларны сугыш өчен сайлап алганнар. Шуннан *тулпар* сүзенең «баһадир аты, канатлы ат» мәгънәсе килеп чыккан. Сүзнең тамыры гом. тк. *тул* «кеше үлгәч, аның истәлеге итеп саклана торган сын, курчак» (к. **Тол**) сүзеннән булса кирәк; к. чыгт., иске тат. *тул* «тулпар, сугыш аты» (Радлов). Элек сугышчыны күмгәндә төркиләр, бигрәк тә кыпчаклар аның атын да бергә күмгәннәр, кайчакта атының итен ашап, баш-аягын гына кабергә куйганнар. Сонрак кабер өстенә атның тиресе генә эленеп куелган яки ат сурәтен (балчыктан һ.б.) ясап кына күмгәннәр. Бу гадәт — ат сурәтен корбан итү — мариларда революциягә кадәр сакланган. Марича корбанлык ат сыннары аргамак дип аталган. Сугыш аты, әлбәттә, бик тиз үлә торган булган. Ул үлгәч, аның тиресеннән *тул* (к. **Тол**) ясаганнар; пар өлеше бор. тк., монг. *пар, бар* «барыс, юлбарыс» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1980: 92 — 93.

**ТУЛЫ** «полный» — гом. тк. *толу, толуг* «тулы, тулган, тулылык» сүзеннән. Тамыры — **то-, тул-у* «тулы булу». К. **Тук.**

**ТУН** «шуба» — гом. тк. *тон* «тун, өске кием», чув. *тăм* «күлмәк-ыштан», бор. тк. *тоң* «кием, күлмәк» — санскрит. thauna «кием» сүзеннән хисапланыла. *Туннан* — *туна-у* «тунын салдыру».

**ТУҢ** «мерзлый; застывший» — гом. тк. *тоң* «туңу»; «тун, нык, каты; тупас, дорфа» сүзеннән.

**ТУП** «мяч; шар; связка; пушечное ядро» — гом. тк. *туп, топ* «туп (*барлык мәгънәләрендә*)» сүзеннән, *тум // туң* тамырыннан (к. *Тумпа*), к. ш. ук диал. *тубык* «мал туплый торган урын». К. **Тубал, Тубык, Тубырчык, Тупак, Тупас.**

**ТУПА(К)** «тупой» — *тумпа* (к.) «томпа» сүзеннән; к. диал. *тупан* «тупа, тупарган (*балта һ.б.*)», кум. *томакъ*, хакас. *томбыр, топыр* «тупа», кум. *топар*, госм., чыгт. *топак* «йомры, йомгак, туп» һ.б.; чаг. венг. tompa «тупа», рус. *туп(ой)* «тупа» (төрки телләрдән булса кирәк), тат. *тупыйк*.

**ТУПАС** «грубый, невежливый» — *туп* (к.) нигезеннән; к. мар. *топас* «түгәрәк, йомры, түмәр, тупас», госм., кум., кырым. *топаз, топач* «юан, симез, бөтерчек, йомгак, башына шар утыртылган таяк», *топуз* «тубырчык» (<бор. **топург*). Тамыры — *тупа*.

**ТУПСА** «шарнир, дверная петля» — башк. *тупса* «бусага, күгән, шарнир», кк. *топса* «шарнир», чув. *тăпса, тăпăлса* «тупса, күгән». *Туп* сүзеннән: тупса капка яки ишек агачының йомры башы — тубыгы кереп утыра торган агач яки таш дигән сүз (*туп-са*; чаг. *муенса, беләксә*.

**ТУПЧЫ-У** «стегать, прошивать» — *туп* тамырыннан; ясалышы ачык түгел; к. башк. *тупсы-у* «тупчу, төенчек төйнәү», себ. тат. *топцы* «төен», кырг., алт. *топчы* «төймә» (*топ-чуг*), *топчыла-* «тупчу, бәйләү, төймәләү», кум. *тобу-* «тупчу, үтәдән-үтә тишеп тегү».

**ТУПЫЙК** «с тупым концом» — бор. *тумпай-ык* «тумпайган».

**ТУР** «сетка; сетчатка» — гом. тк., монг. *тор* «челтәр»; еш очрый.

**ТУРА-У** «кромсать» — к. **Туры**.

**ТУРА(К)** *диал.* «подошва ног; ножка» — чув. *тура* «аяк, тәпи» (*төкле тура* «йонлач аяклы байгыш, төклетура»), кырг. *тура* «тояк арты» — бор. тк. *тугур -ақ* «тояк» сүзеннән; к. монг. *турагун, тугурай* «тояк», калм. *тура* «тояк».

**ТУРА** «тура (*сорт домашнего сыра*)» — мар., удм., тат. диал. *туара*, чув. *тăвара, турах, торах*, чыгт. *торақ*, монг. *тараг*. Чаг. тат. *турта* «вытопки».

**ТУРГАЙ** «жаворонок» — гом. тк. *торғай* «тургай» — нинди-дер *тора, тура* нигезенә кошлар исеме ясагыч *-ғай* кушымчасы ялганып ясалган сүз; к. башк. *турағай*, чыгт., куман., уйг. *торғай*, бор. тк. *турига* «тургай», эвенк. *тураки*, маньчж. *туракки* «карга, чәүкә», алт. *торчық* «сандугач».

**ТУРКА** «крепкий шелк; железный шлем» — мар. *торга* «чатыр кору өчен махсус киндер» — бор. тк. *торқа, торқан, торқу*, бор. монг. *торған* «ефәк» (күп телләрдә очрый).

Бу борынгы сүздән рус. *торг, торги*, эстон. *тург*, фин. *турку* «базар, сәүдә (башта, күрәсең, ефәк белән сату итү урыны)» сүзе килеп чыккан.

**ТУРСАЙ-У** «дуться, надуться» — алт., кырг. *торсой-*, кк., ккк. *торсуй-* «турсаю, күбенү, кабару» һ.б. тат. *турыс* < гом. тк. *торс, торус* < *тобурсы* «тумпайган» нигезеннән ясалган фигыль. К. **Тубыр, Турсык, Тустаган**.

**ТУРСЫК** «бурдюк (*мешок из шкуры животных для воды*)» — тув. *дорзук* «сыйрак; турсык», алт. *торсук, торсык* «тубык, ашык» бор. *торс, торус* (к. **Тырыс**) «агач орысы, шуннан ясалган савыт, ат аягы тиресеннән ясалган савыт» сүзеннән. К. **Турсай-у**.

**ТУРЫ I** «прямой; правильный» — әд. *тугры* «туры, турылыклы», чыгт. *тоғры*, куман. *тоғру* «туры» — бор. тк. *тоғыр-* «аркылы кисеп ату» сүзеннән, бор. *тоғур-* «аркылы кисем» нигезеннән (*тоғур-уғ*); к. ш. ук башк. *тура*, көнч. тк., уйг. *тогра*, якут. *туора*, тув. *доора* «туры, аркылы». Тат. *тура-у* < гом. тк. *тоғра-* < *тоғур-а-* «аркылы кискәләү».

**ТУРЫ II** «гнедой» — гом. тк. *торуғ* «туры, көрән, җирән (*ат турында*)» сүзеннән (тамыры ачык түгел), удм. *тори* «туры, кара (ат)» — төрки телләрдән.

**ТУСНАК** «пленный раб» — башк. *туснак*, кум., н. *тоснак, туснак*, ткм. *туссак* «тоткын (төрмә)» — алт., кырг. *тос-* «каравыллап тору, аяк чалу» фигыленнән. Шуннан ук тат. диал. *тусҡын* «тоткарлык, комачау, киртә». К. Әхмәтьянов, 1989: 169 — 170.

**ТУСТАГАН** «ковшик, черпак» — диал. *дустыган, дустаган, тустак* «агач чүмеч, купы», кк. *тостаган*, чыгт. *тостакан* «тустаган», тув. *достак* «оры, бүлтәймә, агач бүлтәймәсеннән кырып ясалган чүмеч», *достай-, торсай-* «бүлтәю», бор. рус. *достокань* «стакан» төрки телләрдән (шуннан ук бор. рус. *дьстакан* «стакан»). К. **Туш**. Сүзнең тамыры *торс-* күп телләрдә билгеле сүз, ул элегрәк агачның йомры шешен — бүлтәймәсен белдергән. К. **Туз** < *торз, торс*; **Турсык** < *торсук*; **Тырыс** < *торус* һ.б.

**ТУТ** «пигментация; ржавчина» — гом. тк. сүз: кк., ккк., н., кум., бор. тк. *тот* «тут», алт. *тот* «туткыл». Тат. диал. гом. тк. *тат* «тут, тутык» (к. **Татыр**) сүзе белән бәйләнеше ачык түгел (төрки телләрдә [o>a] яки [a>o] күчеше юк).

**ТУТА(Й)** «тетя» — к. н. *тотай кыз* «аристократ кыз», *тотай хатун* «аристократка» — монг. *тоотай* «аристократ; данлы, шәрәфле», *тоо* «сан; шәрәф» сүзеннән; көнч. тк. *тутай* «туганнар» шулай ук монгол сүзе. Чаг. **Түтәй**.

**ТУТАШ** «барышня, девушка» — *тута* (к.) сүзеннән (чаг. *энекәй ~ энекәш, сеңелкәй ~ сеңелкәш: тутай ~ туташ*).

**ТУТКЫЛ** «смугловатый» — бор. *тут-кыл* яки *тутык-ыл* формасыннан. К. **Тутык**.

**ТУТЫЙ** «попугай» — фарсы. *тути* «тутый» сүзеннән.

**ТУТЫК** «ржавчина» — *тут* (к.) тамырыннан (*тут-ык*). *Тутык-* «тутыгу» икенчерәк юл белән ясалган.

**ТУТЫР-У** «наполнять, заполнять» — тат. диал., башк. *тултыр-у* id. ягъни *тул-у* сүзенең йөкләтү юнәлешеннән.

**ТУ-У** «рождаться» — гом. тк. *тоғ-, туғ-* «туу, тудыру» сүзеннән. Шуннан ук чув. *ту-* «итү, ясау».

**ТУФАН** «потоп» — гар. *туфан-ун* «туфан» сүзеннән, *таафа* «ил гизү, тирәләй әйләнеп йөрү» тамырыннан.

**ТУФРАК** «почва, земля» — гом. тк. *топрак*, *тобрак* «туфрак, жир, тузан; ил, өлкә», бор. тк. *топурағ* «туфрак» — бор. гом. тк. *тобур-, тоwур-, тоғур-* «тузан тузу» сүзеннән, *тоб // тоғ* «тузан, жир» тамырыннан (*тоб-ур-аг*); к. тув. *добурак* «жир, тузан, былчырак», монг. *тогурак*, монг. диал. *тоарай* «тузан», бор. тк. *тооз* (Габэйн), тув. *дооз-ун* «тузан» < *тоwор-ун* «тузан», чыгт. *тоғ*, бор. тк. *тоғ-* (МК) «тузан, тузан тузу»; чаг. ш. ук уйг. *топа*, монг. *доба* «жир, балчыке». К. Әхмәтьянов, 1989: 40. К. **Тузан, Туз-у**.

**ТУФРАКСА** «подволока» — бор. тат. сүзе; мар. *тувыраш, тупырас*, удм. диал. *тупъраш*, чув. *тăпрас* «туфракса» бор. болгар. **тувырас* сүзеннән, болгар сүзе исә борынгы татарчадан (болгар телендә кыпчак-татар [*к*]сы башта [*h*]гә, аннары нульгә күчкән). Бу — татар теленең нисби борынгылыгына ачык дәлил: болгарлар бу сүзне *татарчадан* алганнар булып чыга.

**ТУШ** «наледь» — алт., хакас. *тош*, бурят. *тошон* «туш», хакас. *торс* «туш, сөял, кутыр» — ниндидер **торш* сүзеннән. К. **Тустак**.

**ТҮБӘ** «крыша; вершина» — гом. тк. *төпэ, төбө* «түбә, өем» сүзеннән; чаг. *төп*. К. **Түбәтәй**. К. Әхмәтьянов, 1989: 42.

**ТҮБӘН** «низкий» — хакас., тув., бор. тк. *төбүн, түбүн* «түбән, түбәнгә» сүзеннән, *төп, түп* (к. **Төп**) тамырыннан.

**ТҮБӘТӘЙ** «тюбетейка» — монг. *түбәтәй* «түбәле, түбәсе калкып торган» сүзеннән, *түбә* (к.) нигезеннән (*түбә-тәй*), гом. тк. *төпа* «түбә» сүзенең «бүрек, капкач, кыек» мәгънәсе дә киң таралган; к. ш. ук диал. *түпи бүрек* «түбәсе калкып торган мескен бүрек» (Ф.Сәйфи-Казанлыда), үзб. *туппи*, чыгт. *түппү*, бор. уйг. (МК) *түпү* «түбәтәй, йон бүрек (малахай)».

**ТҮГӘРӘК** «круглый» — башк. *түңәрәк*, кк. *төңөрөк*, чыгт. *төгрәк* «түгәрәк» — бор. тк. *төгәрәк, төгәрәк* «кечкенә төгәр», ягъни нигездә *төгәр ~ түгәр / тәгүр* «әйләнә, тәгәрмәч» сүзеннән (к. **Тәгәрә-ү, Тегермән**); к. диал. (себ. тат.) *түгәрлән-ү* «тәгәрәү», *түгәрцәк* «бәжра»; к. ш. ук монг. *төгрөк*, бурят. *түгәриг* «тугрик (монгол тәңкәсе)». Чаг. *диал.* түгәр «бочка» — бор. *төңгүр, тәңгүр* «түгәрәкләп кискән агач».

**ТҮГЕЛ** *частица отриц.* «не» — диал. *тәгел, тигел*, гом. кыпчак. *түгүл, түгил*, угыз. *дәгил* < бор. тк. *tekol «буш ул», бор. tek, täk, монг. *тэк* «буш, тик». К. **Тик**.

**ТҮК-Ү** «пролить, лить» — гом. тк. *төк-* id.

**ТҮЛ** «яичник (*у птиц*); поправляться» — гом. тк. *төл* «түл, яшь бала, яңа токым, эмбрион» Мәхмүт Кашгарый аңлатуынча, бор. тк. *түг-ел* «күкәй төере (*ана карынындагы*)» сүзеннән, ягъни *түг-, төг-* «бәйләү, төйнәү» фигыленнән (к. **Төен**). К. Әхмәтьянов, 1989: 71.

**ТҮЛӘ-Ү** «платить» — ~ мар., чув. *тӳле-*, гом. тк. *төлэ-* < бор. тк. *төг-лэ, төгүлэ-* > чув. *тĕвĕле-* «түләү, төенләү» (борынгы гадәт буенча, истәлек киндерәсен төйнәп, эш беткәнлеген белдерү). К. Әхмәтьянов, 1989: 72.

**ТҮМӘР** «чурбан» — чув., мар. *түмәр* «имән күсәк», монг. *түймэр* «гөрзи, күсәк», тат. диал. *тумар* «түмгәк, ягулык өчен тамырлар», *тумран* «түмәр, кискә», *томар* «таяк башына утыртылган шар» — гом. тк. сүз *тум // туң* тамырыннан. К. **Түмгәк**.

**ТҮМГӘК** «кочка» — диал. *думгәк, түңгәк, түндәк* «түмгәк, төп, түмәр, бүкән»; морфологик яктан караганда, тат. диал. *дөмгәк* «түмгәклек» сүзе дөрес, чөнки сүзнең тамыры *түм ~ түң* үзе «түмгәк» дигән сүз; к. тат. диал., башк. *дүмбәскә* «зур түмгәк, тамырлары белән актарылган төп», кк. *дөңбәк, диңгәк*, тув. *дөнгәләк* «түмгәк», алт. *тоңко-* «тумпаю», *тоңкок* «тумпайган, түмгәк», эвен. *тәмбәг* «түмгәклек», якут. *төңкүр* «дүмбәскә» — барысы да бер тамырдан, тат. диал., мар. *түң* «төп, түмгәк», алт. *төң* «калкулык, түмгәк», үзб. *дуң* «калкулык», хакас. *төңәй* «түмгәк», якут., госм. *тум* «калку, тумпа, йомры». К. **Томыр-у, Томшык, Тубал, Тумпа, Туп, Тупа, Түмәр.**

**ТҮП** «выжимки» — диал. *түпрә, түбер*, н. *төп*, кырг. *топ*,

бурят. *тобог* «түп, чүбек, йомычка» — бор. гом. тк. **турп* «калдык-постык, чүп» сүзеннән (алынма сүз булса кирәк); к. үзб. *турп* «түп, кибәк, йомырка кабыгы». Чаг. **Чүп, Чүпрә, Чүпрәк, Шүр.**

**ТҮР** «передний угол; почетное место» — гом. тк. *төр*, бор. тк. *төрә* «түр» — мәгънәсе ачык түгел; к. мар. *тур* «кырый; тигез урын; кайма».

**ТҮРӘ** «начальник» — гом. тк. *төрә* «түрә, судья; суд, хөкем», бор. тк. *төр, төрә* «закон, йола, идарә». К. Әхмәтьянов, 1981: 98.

**ТҮРӘ-Ү** «родить; умножаться» — < бор. тк. törä- «тудыру, бар итү; күп итү». Күп телләрдә очрый.

**ТҮТӘ: мылтык түтәсе** «приклад винтовки» — диал. *төйтә* ~ башк. *төйҙә* ~ төрек. dögdu «түтә, коралның төя торган ягы» — *төй-* фигыленнән. *Түтә* варианты мишәр диалектыннан таралган (миш. *ту-у* «төю»).

**ТҮТӘЛ** «грядка» — бор. монг. (Ибне Муханна) *татул, татуул, тартугул, тартагул* «түтәлләр системасы, арыклар челтәре» сүзеннән (уйгур теле аркылы булса кирәк) килеп кергән; к. кум., н. *татавул*, кырг. *татаал* «канау, түтәл арасы»; хәзерге монг. *тата-* «тарту, арык казу, арык үткәрү», *татаал* «водопровод, арык, түтәл».

**ТҮТӘРӘМ** «четвертая часть (*напр., каравая*)» — *дүрт* (к.) сүзеннән (*дүрт-әр-әм*); ясалышы буенча борынгы болгар сүзе. К. Әхмәтьянов, 1989: 158.

**ТҮТЕК** «рожок, свистулька» — кк., бор. чыгт. *түтүк* «түтек, камыш, курай», чыгт. *түтә*, азәрб. *түтәк* «көтүче быргысы», чув. *тут* «быргы» — сызгыру, кычкыру авазын белдерә торган тасвирый яңгырашлы *тү* (*тү-тү*) итү сүзеннән.

**ТҮШ** «грудь» — гом. тк. *төш, төш* «түш; түбәнлек, ятак, терәк»; чаг. фарсы. *дош*, бор. фарсы. daoša id.

**ТҮШӘК** «перина, тюфяк» — чув. *тӳшек*, мар., удм. *тӳшак, тӧшак-*, гом. тк. *төшәк* id., тат., башк. *түшә-* < гом. тк. *төшә-* «түшәү» сүзеннән. Чаг. **Түш**.

**ТҮШӘМ** «потолок; настил» — *түшә-ү* сүзеннән.

**ТҮШӘ-Ү** «постилать» — гом. тк. *төшә-* id. *төш* (к. **Түш**) «түш» сүзеннән булса кирәк.

**ТЫГЫЗ** «тесный; узкий; плотный» — гом. кыпчак. *тыгыз*, үзб. *тигиз*, ткм. *дыгыз*, хакас. *тыгыс* «тыгыз», тув. *дыгыш* «тыгыз, дыңгычлап тутырылган», *дыңзы-* «тартылу, ныгу», *дыңзыг* «көчле, ныклы, көчәнешле», кк. *ныгыз* «тыгыз», бор. тк. **дыңкырг // *ныңкырг* «кысылган, дыңгычланган» сүзеннән; к. чув. *тӑкӑр* ~ *тӑпӑр* «тыгыз». К. **Тыкрык, Нык, Чын**.

**ТЫКРЫК** «переулок; тупик» — чыгт. *тыгырык*, чув. *тӑкӑрлӑк* «тар гына тыкрык» — бор. тк. *тыкыр* «тыгыз» сүзеннән. К. **Тыгыз**. К. Әхмәтьянов, 1989: 142.

**ТЫЛМАЧ** «переводчик, толмач» — гом. тк. *тылмач*, көнч. тк. *тылбас, тилбәс*, угыз. *дилмач* «тылмач» — бор. тк. *тилмәрчи* «телчән» сүзеннән булса кирәк (*тилмәч* < *тилмәрч*); к. тат. диал. *телмәр* «телчән» (*тел-мәр*), башк. *телмәр* «нотык». Рус. *толмач*, венг. tolmacs «тылмач» — төрки телләрдән. Борынгы төрки ханның хезмәт штатында *ишек агасы, сакчы, ярлыкчы, бетекче, казначы, боерчы* белән беррәттән *тылмарчы* яки *телмәрче* дә булган. Ул борынгы дастаннарны сөйләп, үгет-нәсыйхәт биреп, сугышчыларны рухландыру белән бергә тылмачлык итү белән дә шөгыльләнгән. К. **Телмәр**. К. Әхмәтьянов, 1977: 47.

**ТЫЛСЫМ** «талисман» — госм. *тылсым*, үзб. *тилисм*, гар. *талисм-ун* «тылсым» яки грек. *телесма* «тылсым, сихер» сүзеннән.

**ТЫН** «дыхание, вздох; спокойный, тихий» — гом. тк. *тын* «тын, жан», алт., куман. *тым* «тынлык, тыныч», якут. *тын* «тын, пар; рух, жан» — бор. тк. (МК), бор. гом. тк. *тың* «тын, сулыш» сүзеннән; чаг. фарсы. *дам* «тын, сулыш; момент, вакыт», бор. фарсы. tam «өрү, тын, пар, дым» (к. тат. *дым, дәм*). К. ш. ук тат. диал. *тымык, тымызык* «җилсез һәм дымлы (*көн*)», *тын-у*. К. Әхмәтьянов, 1989: 12.

**ТЫҢКЫШ** «гнусавый» — бор. тат. *тыңкы-у* «сулыш тыгылу» сүзеннән; к. башк. *тыңкау* «тынкыш», хакас. *тыңыс* «кату» — *тың* «көчәнешле» тамырыннан, к. **Дыңгыч, Тыгыз, Чын**.

**ТЫҢ** «слушание; слух» (отсюда *тыңла-у* «слушать») — госм., бор. тк. *тың* «аваз, чың (*чыңлау авазы*)» сүзеннән; к. гом. тк. *тыңла-, тыңда-*, монг. *чиңла-* «тынлау, дикъкать салу», гом. алтай. *тың, чың* «көчәнеш, тартынкы кыл, чыңлау» тәкълиди тамырыннан.

**ТЫРМА** «грабли» — чув. *тӑрма*, мар., удм. *тырма* — кк., ккк., алт. *тырма, тырмак* «тырма, тырмавыч» бор. *тырмаг* сүзеннән. К. **Тырна-у**.

**ТЫРНА-У** «царапать; чесать» (шуннан *тырнак* «коготь, ноготь») — чув. *черне-* «тырнау», *чӗрне* «тырнак» — бор. *тыр-* «тырнау, тырмау» фигыленнән (чаг. алт. *тырғақ* «тырнак») ясалган гом. тк. сүзләр *тыр/цыр, тар/цар* тәкълиди тамырыннан; чаг. рус. *царапать*.

**ТЫРЫС** «туесок, кузовок из бересты» — башк. диал. *тырыз*, чув. *тӑрӑс* (*тӑрӑс*) id., бор. тк., фин-угор. *турс* «каен бүлтәймәсе» сүзеннән. Чаг. **Турсай-у, Туш**.

**ТЫЧКАН** «мышь» — чув. *шӑшӑ, шӑши* < **чычҡай*, уйг. *чачкан*, якут. *чыңгырткан, сынгырычкан* id. гом. тк. *чыңыр* «чыелдау» сүзеннән булса кирәк. Иске тат. *сычкан* әдәбиерәк.

**ТЫШ** «внешняя, наружная сторона» — гом. тк. *тыш* < бор. *тыл, тал* > чув. *тол* > *тул* «тыш». Гом. тк. *таш* «таш» сүзе белән бәйле. К. **Чыг-у**.

# -У-

**УБЫР** «упырь; обжора» — гом. тк. *обур*, чув. *вупӑр, вупкӑн* ~ гом. тк. *оп-* (тат. *уп-*, чув. *вуп-*) «убу, йоту» сүзеннән. Рус һәм гом. славян. *упырь* бор. һун теленнән булса кирәк.

**УГРЫ** «вор» — гом. тк. *оғры* ~ хакас. *оғыр*, бор. *оғур* > тат. диал. *ур*, кум. *уру* «форсат, урлау» сүзеннән. *Урла-, угырла-* «форсатлау».

**УЕН** «игра» — тат. диал. *уй* < бор. *ой* «уйнау; бию» (шуннан ук *уй-на-у*). Чув. *вайа* «уен» < болгар. *уйғы* яки *уйығ* нигезеннән.

**УҖАУ** «половник» — кк., ккк. *ожау*, чув. *вĕҫев, уҫав*, якут. *удьаа* «озын саплы чүмеч».

**УЙ** «мысль, дума» — гом. тк. *ой*, бор. *од* «уй». Чаг. **Уян-у.**

**УК I** «стрела» — гом. тк. *ӧк* id.

**УК II** *частица* «же» — гом. тк. *оқ, оқуна* «ук, мәзкүр, күрсәтелгән», чув. *ху* < **оқу* «үзе», *хам* < **оқум* «үзем» гом. тк. *оқ, оoғ* «нәсел, зат, билгеле заттан, охшаш» дигәннән; к. тув. *уқ* «нәсел, зат; шул, күрсәтелмеш». Бу сүз *ук* «стрела» белән бердәй булырга мөмкин; чаг. монг. *сомун* «ук; төбәк; кабилә». К. ш. ук гом. тк. *ог, ӧг*, монг. *ӧг* «зат, нәсел, ана», чыгт. *оқа* «нәселдәш, эне яки сеңел», бор. чыгт. *ӧк* «өлеш, пай; ук (именно)» бурят. *уғ* «зат, нәсел-ыру, ата-баба, чыгыш, тамыр», *уғсаа* «нәселдәнлек, чыгыш», *уғлараа* «пар, охшаш». К. **Охша-у, Ул I, Үгәй, Үксез.**

**УКА** «позумент» — чув., удм., мар. *уга, ока*, кк., кб., ккк. *оқа* «ука», кырг. *оқа* «ука, бизәк» — грекча *окка* «алтын тәңкә» сүзеннән (тәнкәләр тезеп, кием бизәге ясау гадәтеннән).

**УКЛАУ** «скалка» — чыгт. *оқлағу* «уклау; цилиндр» — бор. тк. *оқла-* «җәймә җәю» сүзеннән, ниндидер *оқ* сүзеннән (борынгы заманда уклау урынына ук кулланылмадымы икән?). Чаг. ккк. *уқла-* «угалау, камыр басу».

**УКРА** «личинка овода» — чыгт. *окра*, кк., ккк. *оқыра* «лишай; оры; зыян», кум., кырг. *оқура* «укра» ~ мар. *охыра*, чув. *ыхра* «суганча, сарымсак». Тамыры ачык түгел. Чаг. чыгт. *окра* «тирән чүлмәк».

**УКСЫМ** диал. «чеснок; головка чеснока» — чув., мар. *уксым*. Тат. диал., башк. *уксын*, хакас. *ухсум*, шор. *оксум*, төрек сөйләшләрендә *эсгун, ускым, ашкын* һ.б. (күп төрки телләрдә бар) бор. грек. *оксин* «әче җимеш» (чаг. *оксид* «әчү нәтиҗәсе» — халыкара химик термин) сүзеннән, Бактрия (Урта Азия грек дәүләте) иленнән бор. төркиләргә кергән.

**УКЫ-У** «читать; учиться» — гом. тк. *оқы-* «чакыру, кычкыру, өндәү; җырлау» *оқ* «аваз; исем; дан» сүзеннән ясалган фигыль. «Кычкыру, чакыру > китап уку» мәгънә күчеше типологик характерга ия: алт. *қычқыр* — «кычкырып чакыру, уку», фарсыча *хандан* «чакыру; уку». *Укуның* «мәктәптә өйрәнү» мәгънәсе иске тат. *ӧк-* «игътибар илә тынлау; отып алу, аңлау; өйрәнү» < гом. т.к. *уқ-* id. тәэсирендә килеп чыккан.

**УЛ I** «сын» — гом. тк., бор. тк. *оғул* «ул; бала» (чыгт. *қыз оғул* «кыз бала», *эркәк оғул* «ир бала, ул») сүзеннән, бор. гом. тк. *оқ, оғ* «нәсел, зат» нигезеннән (*оғ-ул*); к. ш. ук тат. *уғлан*, чыгт., госм. *оғлан, уғлан* < *оғул-ан* «яшь бала, егет» (шуннан к. тат. **Олан**). К. **Ук II, Уылдык**.

**УЛ II** мест. «он; тот» — гом. тк. *ол* «ул» — бор. гом. тк. *о, у* «шул, теге» нигезеннән; гом. тк. *бул* (кыек килешләрдә *бун-*) һәм *шол* (кыек килешләрдә *шон-*) алмашлыкларның ясалуына да катнашкан. К. **Бу, Шау, Шул**.



**УЛАК** «желоб» — уйг. *олак*, кк., н. *олық*, госм., чыгт., бор. тк. *олук*, якут. *уолук* «улак, тагарак», чув. *валак* «улак» — бор. тк. **оғ, оқ* «эче куыш кәүсә» сүзеннән булса кирәк; к. чыгт. *оғлуқ* «улак, агачтан ясалган су юлы», чув. *вула* «көпшә», мар. *вол* «улак, тагарак».

**УМАЙ: умай-ана** «дух — покровительница родов (*языческ.*)» — гом. тк. *умай, май, пай* «умай» — фарсы *һумай* «мифик кош» сүзеннән (бор. рус. *гамаюн*). Һумай кошы һавада йомырка салып, һавада бала чыгара дигән гыйбарә бар. Шуңа күрә ул авыр шартларда да бала табып үстерүче ана символы булып киткән. К. **Май**.

**УМАРТА** «улей» — диал. *марта, мурта* «умарта», рус. диал. *бортя*? Чув. диал. *марта*, удм. *умортo*, мар., кк., уйг. *омарта* «умарта» — татарчадан булса кирәк.

Төньяк Кавказ телләрендәге *мартан* «умарта; кәрзин» сүзе бу нигезне бор. ирани *мӓрдан* «халык» сүзе белән дә бәйләргә мөмкинлек бирә. К. Әхмәтьянов, 1989: 47.

**УМАЧ** «затируха» — кк., ккк. *умаҗ*, чыгт., үзб. *умач, омоч*, госм. *омаҗ, огмаҗ* — гом. тк. *у-, оғ-* «уу» сүзеннән (*у-мач*), *ума аш* дип аңлатуга нигез юк.

**УМРАУ: умрау сөяге** «ключица» — кк. *омырау*, кырг. *омуроо*, чув. *ӑмӑр*, ӑмӑра, көнч. тк. *омыр, омру*, монг. *омруу* «умрау» — бор. гом. тк. *ом-ур-ғағ* «йомры башлы сөяк» сүзеннән; к. тк. *ом* «сөякнең йомры башы», *омур* «умыртканың бер сөяге», *омуз* «умрау». Чаг. ш. ук тат. диал. *ум* «түшкәнең алгы ягы», алт. *ӧмүр* «тун изүе», хакас. *омых*, чув. диал. *омак*, тат. диал. (себ. тат.; урал) *умгән, уңгәл*, чыгт. *ӧмгән* «ат тәненең күкрәк турысы, күкрәк турысындагы биеклек». Чаг. **Умыртка**.

**УМЫРЗАЯ** «подснежник» — диал. (урал, башк.) *гомерзайа-* «гомере зайа» сүзеннән. Н. *омирзая* «горицвет» татарчадан (?).

**УМЫРТКА** «позвоночник» — алт., кк., кырг. *омуртка, оңуртка* «умыртка». Чаг. **Умрау**.

**УН** «десять» — гом. тк. *он* «ун» сүзеннән.

**УҢ** «правый; лицевая сторона» — гом. тк. *оң*, якут. *уңа, ума*, чув. *ум, ома* «уң, уң як, алгы як, ал; көньяк, кыйбла» сүзеннән. Беренчел мәгънәсе «алгы як» булса кирәк. **Чаг. Умрау**.

**УҢАЙ** «удобный; положительный» — гом. тк. *оңай, оңкай-* «уңай, җиңел» — гом. тк. *оң* «уң» сүзенә *-кай // -гай* аффиксы ялганып ясалган (чаг. *сулагай*< *солгай*).

**УРА: ура кычкыру** «кричать «ура» — рус. теленнән; рус теленә исә бор. тк. телдән; к. гом. тк. *уран* «ярсулы кычкыру, һөҗүмгә чакыру» (тат., башк. *оран*), якут. *уоран, ура*, монг. *урага* «сөрән» сүзеннән дигән фикер бар (ләкин *оран* сүзе бөтән сүз булган!). *Ура!* сүзе татарча *ура* (*окружай!*) сүзеннән дигән фикер дә игътибарга лаек (төркиләрнең төп тактикасы — дошманны урау була).

**УРАЗ** «бог счастья у древних кипчаков» — төрле төрки телләрдә *ороз, ораз, оруз, уруз, урус*, тат. диал. *ырыс* id., бор. ирани. *роуз, руз* «көн; яктылык; бәхет» сүзеннән. К. **Рыскал, Ураза**.

**УРАЗА** «ураза, мусульманский пост» — н., кк., ккк. *ораза* «ураза», бор. тат., чыгт. *руза* «ураза көне» — фарсы. *руз* «көн» сүзеннән. К. **Ураз**.

**УРАК** «серп; жатва» — кк., ккк. *орақ*, бор. тк. *орғақ* «урак» гом. тк. *ор-* «ур-у» сүзеннән. Чаг. шумер. *ur-* (*ур-*) «уру».

**УРАМ** «улица» — кк., ккк., чыгт., кар., үзб. *орам*, гом. уйг. *урам*, алт. *ороом* «урам, квартал», бор. чыгт. *урам* «шәһәр, кальга; нығытылган зур авыл», иск. кк. *орам* «биләмә» чыгышы белән тат., башк., чув., мар., удм. *ур*, гом. тк. *ор* «канау, окоп» (тат. *урай* «кирмән, кальга тирәли казылган тирән, киң чокыр») сүзе белән бәйле. К. Әхмәтьянов, 1989: 142 — 144.

**УРДА** «орда, государство» — гом. тк. *орду*, монг. *ордо* «хан сарае, зур тирмә, ихата» сүзеннән. Бу сүз күп кенә башка мәгънәләргә күчкән — төрек. *орду* «гаскәр», мар., морд. *орта* «капка», һинд. *урду* «дәүләт теле».

*Алтын Урда* сүзе Батый ханның алтынланган зур тирмәсе булуыннан дигән фараз бар.

**УРМАН** «лес» — уйг., госм., кк., ккк., н., кум. *орман*, чув. *вырман* «урман» — бор. тк. *ора, ура* «тау яки яр буендагы урман» сүзенә *=ман* кушымчасы ялганып ясалган сүз; к. тат. диал., башк. *ур, урай* «урманлы чокыр, урман үскән тар үзән», эвенк. *урэмэ, урэмэн* «урманлы таулык», *урэ, хурэ* «текәлектә үскән урман», бурят. *урмэн, урмэдэһэн* «әрәмә, әрәмәлек». К. **Әрәмә, Әрем, Имән.**

**УРТ** «десна» — алт. *уурт* «тамак», тат. диал. (себ. тат.) *аурт*, госм. *аwурт*, якут. *омурт* «урт, авыз эче» — бор. тк. *омур-, обур-* «умырып тешләү, авыз тутырып кабу» сүзеннән (*омур-т* ~ умыр-т); к. ш. ук тат. *уртла-*, себ. тат. *аурт-, аwыртла-*, үзб. *урт*, якут. *омурт-, обурт-* «эчү, уртлау», бор. чыгт. *ауртла-* «уртлау», бор. монг. *огурчи-, огуpти-* «уртлау, эчү».

**УРТА** «середина; центр» — гом. тк. *орта* «урта, уртадагы ара» сүзеннән; чаг. уйг. *утра* «урта» ~ бор. язм. *отра* «уртадагы»; шуннан ук *утрау*. К. **Уртак**.

**УРТАК** «общий; пополам» — гом. тк. *ортак* «уртак; иптәш, компаньон» сүзеннән, *урта* нигезеннән (*урта-к*); к. ш. ук уйг. *орту*, көнч. тк. (алт., хакас., тув.) *ортун* «уртак, уртадагы»; к. үзб. *ортак* «иптәш». К. **Урта**.

**УРЫН** «место» — гом. тк. *орун, орын* «урын, утыргыч, ятак» бор. тк. *олур-ун* «утыра торган җир» сүзеннән, бор. *олур-* «утыру» фигыленнән (тат. *утыр-у* < гом. тк. *олтур-* id.) ← бор. **ол* «урын».

**УСАК** «осина» — кк., ккк. *осақ*, тат. диал. (себ. тат.) *аусақ*, *апсак* «усак» — бор. тк. **обус* «усак» сүзеннән, бу сүз исә һинд-евр. телләреннән кергән; к. алт., хакас., тув. *ос, ӧс* «усак, тополь», чув. *ăвăс, увăс, авăс* «усак», алт. диал. (шор., куманда.) *аспак, апсак* «усак», латыш. apse << лит. apuse ~ немец. Espe, бор. немец. aspa ~ рус. *осина* < **опсина* «усак».

**УСАЛ** «шалун; злой» — уйг. *осал* «усал», бор. тк., үзб. *осал*, *усал* «начар (дрянной)», кырым. *осал* «ялкау», азәрб., чыгт. *усал* «усал, вөҗдансыз», бор. чыгт., кк. *осал* «зәгыйфь; ялкау», кум. *осал* «юаш (!)», бор. тк. *осал*, монг. *осал*, чув. *усал* «зыян, ялгышлык, хата» — бор. гом. тк. *усса-, оса-, уса-* (монг., эвенк. *оса, уса-*) «ялгышлыкка юл кую, гамьсезләнү, язлыгу» сүзеннән (*оса-л*); к. ш. ук кырым. *осан-*, госм., чыгт. *усан-* «дикъкатьсезләнү, күңелсезләнү, нәфрәтләнү». Сүзнең тамыры — бор. тк. *ус, ос* «тәҗрибә, дикъкать, акыл» (к. *Ос*): *ус-са-* «тәҗрибәсезләнү». Чаг. ш. ук шумер. usalla «яшеренлек; астыртынлык».

**УТ I** «огонь» — гом. тк. *ōт* «ут» сүзеннән; чаг. һинд-евр. *ater «ут». К. **Утын, Учак**.

**УТ II** «трава» — шуннан *утла* «пастись», *утлык* «кормушка», диал. *утса* «печәнлек» — гом. тк. *от, ōт* «яфрак, үлән, яшь үлән» сүзеннән. Шуннан ук *ута-у*, бор. тат. *утачы* < уйг., куман. *отачы*, тув. *одучу* «имче».

Ихтимал, **Ут I** һәм **Ут II** сүзләре үзара бәйледер; к. шумер. utun (утун) «мич».

**УТАР** «хутор; загон» — кырым., н., кк. *отар*, якут. *отор*, монг. *отор* «утар, киртәләнеп алынган көтүлек, яшел үләнле болын, көтүчесез көтү» — гом. тк. *от* (к. **Ут II**) сүзеннән (ясалыш юлы ачык түгел); к. ш. ук бор. чыгт. *отғар-* «көтү». Рус. *отара* «ачык далада җәйләүче зур сарык көтүе» — төрки телләрдән.

**УТЫЗ** «тридцать» — гом. тк. *отуз*, көнч. тк. *оттыс*, алт., кырг., чыгт. *олтус* «утыз» — ясалышы һәм тамыры ачык түгел; чув. *вăтăр* «утыз» < бор. гом. тк. **олтургъ* «утырыш, табын» дигән фикер бар.

**УТЫН** «дрова» — гом. тк. *отун, одун, отуң* «утын» — гом. тк. *от* «ут; учак» сүзеннән; к. хакас. *одын-* «ут кабызу», *одуң* «утын», бор. тк. (МК) *ота-* «ут яну», *отуң* «утын».

**УЧ** «ладонь» — чыгт., кырым. *ауч*, госм., азәрб. *аwуҗ*, уйг. *аwуч*, алт. *уучи* «уч» — бор. тк. *абуч* «уч, учка алу, учлам», монг. *абуча* «учлау, учлам» сүзеннән (монг. *абу-* «алу, тоту», *-ча* — исем ясагыч кушымча) (Рамстедт).

**УЧАК** «очаг; костер» — гом. тк. *очақ, очағ* «учак, мич, таган; җинаятьче муенына кыздырылган хәлдә кидерелә торган кыршау (суынгач, баш аркылы чыгарып булмый)» — ясалышы ачык түгел; к. чув. *учак, вучах* «учак» (*вут* «ут»), эвен. *охог, осог* «мич», *оту* «костер». К. ш. ук уйг. *очак* «нәсел-ыру, фамилия, чыгыш» — тат. иске әд. *учак* «шахта, рудник».

**УЧАР: учарлан-у** «стоять вместе» — к. башк. *усар* «группа, ыру», кум. *очар* «җыелыш мәйданы», кк. *ошарлан-* «җыелып тору». Чаг. бор. ирани. vačar, vačara «җыелыш мәйданы».

**УЫЛДЫК** «икра» — чыгт. бор. тк. *оғул-дурук* «эмбрион саклана торган капчык; күкәй яки аналык» сүзеннән (*оғул* «угыл, эмбрион», *-дурук* «һәртөрле кидерелә торган нәрсәне белдерүче кушымта»; к. **чөелдерек**); к. тат. диал., башк. *ыуылдырык* «уылдык». К. тат. *уыл* > чув. *ăвăл* «умартада әле канатланмаган умарта корты».

**УША** «скамейка у печи» — к. башк., чув., мар., морд. *уша,*

*ужа* «мич, учак; почмак, мич тактасы, куна», чув. *улча* «уша баганасы». Бор. *ŏл* «утыру урыны» сүзеннән.

**УЮ (уй-)** «делать выемку» — гом. тк. *ой-*. Чаг. **Уйсу, Уяз.**

**УЯЗ** «долина; пологость» Кк., н. *ояз* «уйсу җир» — гом. тк. *ой* «уй, үзән, басу» сүзеннән. К. **Уйсу**.

**УЯН-У** «пробудиться, пробуждаться» — гом. тк. *уйган-, ойган-* «уяну» сүзеннән, бор. *уйға-, ойға-* «уяу булу» фигыленнән (шуннан ук *уят-у* «разбудить» < *уйгат-у*). Сүзнең тамыры — *уй* < *ой* < **od*.

**УЯУ** «бодрый; бдительный» — чыгт., бор. тк. *ойаг, ойгак* «уяу» бор. тк. *ойга-*, бор. гом. тк. *одга-* < **орга-* «уяу булу, уйга килү» фигыленнән, бор. гом. тк. **од* ~ **оргь* «уй, аеклык» сүзеннән; к. чув. *вăран-* «уяну» < **ора-н* < **ор-га-н-* «уяну». К. ш. ук уйг. *одун-* «уяну», *одуқ* «уяу», бор. тк. *одуқ-, одуғ-* «уянган».

## -Ү-

**ҮГЕЗ** «бык» — гом. тк. *öкуз, öгуз*, уйг. *һöкуз*, үзб. *хукуз, хукиз* «үгез» — бор. гом. тк. **окургь* «үгез» сүзеннән; к. чув. *вăкăр*, венг. *ökör*, монг. *укэр, ухэр* «үгез»; чаг. бурят. *урхэр* «үгез», *урхэн* «болан».

**ҮГЕТ** «наставление» — бор. тк. *öгут* «үгет-нәсыйхәт» — гом. тк. *öг-* «акыл (бирү), өйрәтү» фигыленнән ясалган сүз (*öг-ут*). К. **Үкен-ү, Өйрән-ү**.

**ҮГИ** «неродной, сводный» — кырым., үзб. *öгәй*, ткм. *öгей*, госм. *öгәй* — монг., бурят. *öггүй, үггүй* «ата-анасыз, населсез» сүзеннән; гом. тк., гом. монг. *öг, ŏг* «ата-ана, нәсел» нигезеннән (*öг-гүй: -гүй* — юклык кушымчасы). Чаг. **Үксез**.

**ҮҖӘТ** «упрямый; упорный» — себ. тат. *уцат, учат, үчәт, үчәш* «үҗәт, үчле» — *уч* (к.) сүзеннән; к. ш. ук алт. *öчöш* «үҗәт, кире, үчле», якут. *öсöс* «үҗәт» (*öс* «үч»). Ясалышы буенча бу сүз бор. тк. *öчә-* «үчләшү, үчләнү» фигыленнән булса кирәк (*öч-ә-т*); к. хакас., чыгт. *öчә-* «үч алу, кинә саклау». К. **Үч**.

**ҮЗ** *мест.* «свой» — гом. тк. *öз, öс*, бор. тк. *öδ*, госм., кырг. *öд, ŏд* «үз, үзе; төп» — бор. гом. тк. **öргь* «үз, үзәк, үзе, урта» сүзеннән; к. ш. ук тат. диал. *уз* «ин яхшы сыйфатлы, иң кирәкле», якут. *уöс* «үзәк (сердцевина)» ~ чув. *вар, вара, варă* «үзәк (середина, центр; желудок; живот)», монг. *öр, öрö* «үз», öрү «күкрәк, йөрәк, үзәк», *öрöн* «тирмәнең урта баганасы». К. **Үзәк, Үзән, Үзгә, Үзле.**

**ҮЗӘК** «центр» — гом. тк. *öзәк* «үзәк» сүзеннән; *öз* (к. **Үз**) тамырыннан. Чаг. **Үзән**.

**ҮЗӘН** «долина, низменность» — алт., кк., кырг. *öзән, öзöн* «үзән» — гом. тк. *öз* (к. **үз**) тамырыннан (*öз-ән*); к. алт. *öзöк* «елга, үзән». Чаг. **Үзәк**.

**ҮЗГӘ** «другой, иной» — гом. тк. *öзгә, öскö* «үзгә» — *öз* (к. **үз**) сүзеннән булса кирәк (чаг. *башка*); к. *үзгәр-ү* < *үзгә-р-ү*.

**ҮЗЛЕ** «вязкий, тягучий» — диал. *уз* «әйбернең иң яхшы өлеше» сүзеннән (*уз-ле*); к. уйг., үзб., кк., ккк., угыз. *öз* «әйбернең үзәге, мае», госм. *öзлу* «тулы, сутлы, майлы, җилекле». Асылда *öз* (к. **Үз**) сүзенә кайтып кала.

**ҮКСЕЗ** «сирота» — госм., кырым., чыгт. *öксуз* «үксез» — бор. тк. *оқ, оғ // öк, öг* «нәсел-нәсәп, ана, туганнар» сүзеннән (*öксиз*; чаг. **үгәй, ук II**), көнч. тк. *öксус, öгсус* «акылсыз» исә бор. тк. *ок, öг* «акыл, уй» (к. **Үгет, Үкен-ү**) сүзеннән.

**ҮКЧӘ** «пятка; каблук» — уйг., чыгт., госм. *öкчә*, кк., ккк. *öкшә* «үкчә» — чыгт., бор. тк. *öк* «терәү, казык» сүзеннән булса кирәк (*öк-чә* «кечкенә казык» ягъни биек үкчә күз алдында тотылган); к. ккк. *öкшә* «казык, үлчәү казыгы (вешка)», калм. *öг, öгег* «терәк, ястык, мендәр», бор. тк. *öң* «нигез».

**ҮЛӘКСӘ** «труп» — уйг., кк. *öлуксә* «үләксә» — уйг., бор. тк. *öләк*, гом. тк. *öлук* «үлек» сүзеннән.

**ҮЛӘН** «трава» — уйг., чыгт. *öлöң* «сусыл һәм сутлы үлән, болын», якут. *öлу, öлöң* «үлән, сазлы үләнлек», уйг. диал. *уләң*, тат. диал. (мишәр., тау ягы) *үләм* «үлән» — бор. тк. *öләң* «сазламык җир, яшел үлән», гом. тк. *öл, ŏл* «юешлек, юеш җир» сүзеннән; к. тат. диал. (тау ягы) *ул-су* «чык», алт., хакас., уйг., госм. *ол*, якут. *уол* «юеш, чи», *олэң* «күрән, саз үләне», бор. чыгт. *öл*, үзб. *һул* «юеш» һ.б. <* *öгул* (чув. *ӳхлем* «күрән») «үләнлек».

**ҮЛҖӘ** «трофей; трофейный» — тат. диал. *улҗа-*, уйг., чыгт. *олҗә, олча*, кк. *олжо* «үлҗә» — монг. *олзо, олчо* «үлҗә, табыш, казаныш» сүзеннән (монг. *ол-*, бур. *оло-* «табу, казану»).

**ҮҢӘЧ** «пищевод» — кк., ккк. *öңәш*, уйг. *әңгәч*, алт. *öң, öңöч* «үңәч», *öңәч* <* *öң-гач*; к. тув. *öк*, алт. *он, öң* «көпшә; бугаз».

**ҮПКӘ I** «легкие» — гом. тк. *öпкә, öфкә* «үпкә» сүзеннән.

**ҮПКӘ II** «обида» — гом. тк., бор. тк. *öпкә, öпкö* «үпкә; ачу, ярсу» — **Үпкә** I (к.) белән бердәй хисапланыла, ягъни *үпкә* сүзе «үпкә кабару, үпкәләй» сүзләреннән алынып ясалган, чаг. тат. диал. *йөрәкләү* «ачулану, үпкәләү»; рус. *сердиться — сердце* «йөрәк» сүзеннән.

**ҮР** «возвышенность» — гом. тк. *öр* «үр» сүзеннән. К. **Үрә, Үркәч.**

**ҮРӘ** «дыбом; торчком» — бор. тк. *öру* «үрә», алт., уйг., чыгт. һ.б. *öрә*, якут. *öрö* «үргә (вверх)» сүзеннән булса кирәк. Чаг. тк. *огü*, бор. монг. *örgü*, себ. тат. *өргә* «стена, эргә».

**ҮРӘЧӘ** «грядки (*телеги*), разводы (*саней*)» — башк. *урәсә*, чув. *ӳрече, ĕревĕч*, мар. *öрача*, удм. *öрача, ырача* «үрәчә», якут. *öрöсö* «рәшәткә, арба читәне», н., кум. *öрече* «арба карамасы» — бор. **үрә, *öрэ* «атның арт аягын алгы аягына бәйли торган тышау, аркылы-торкылы бау» сүзеннән; к. шул мәгънәдә кк. *öре*, кырг. *öрöö үр-ү* < *öр-* сүзеннәнме?

**ҮРДӘК** «утка» — тат. диал. *урзәк*, хакас. *уртәк*, чыгт., бор. тк. *öрдәк*, үзб. диал. *öвирдәк*, якут. *урдукэн* «үрдәк, кыр үрдәге (чирок)», башк. *өйрәк*, хакас. *öдрәк*, тув. *öдурэк* «үрдәк» — ясалышы буенча *-дәк* кушымчасы (чаг. *кашкалдак, бизгәлдәк*) һәм **öр* ~ *öвир* тамырыннан.

**ҮРКӘЧ** «горб (*верблюда*)» — алт., кк., ккк. *өркөш, оркэш* «үркәч, кабарынкылык», угыз. *өргүч, һөркүч* «үркәч, тау чыгынтысы», бор. тк. *өркү* «үркәч» (МК) — бор. тк. *өрүк-* «югары күтәрелү, үрә тору, ур булып тору» фигыленнән (к. **Үр**); к. ш. ук кырг. *үркүй-* «күтәрелеп тору».

**ҮРМӘКҮЧ** «паук» — чыгт. *өргәмчи, өрмүкчи,* уйг. диал. *өрмүчүк,* хакас. *өрүнмәҗәк,* госм. *өрүмҗәк* «үрмәкүч» — төрле җирдә төрле модельләр буенча, гом. тк. *өр-* (к. **Үр-ү**) фигыленнән ясалган; к. кк., ккк. *өрмөк* (тат. диал. *урмәк*) «пәрәвез», *өрмөкчи* «үрмәкүч (пәрәвезче)».

**ҮРНӘК** «пример, образец» — госм. *өрнәк,* бор. госм. *әүрнәк* «үрнәк», кырг., кк., ккк., н. телләрендә дә бар. Кум. *өрнек* «үрнәк, үсенте, ботакчык» — гом. тк. *өр-, ӧ̄р-* «үрү, үсеп чыгу» тамырыннан, ягъни *урнәк* «яфраклы ботакчык рәвешендәге бизәк» дигән сүз булган. К. тат. диал. *урнәк* «бизәк», гар. *урник-ун* «үрнәк» — төрек теленнән.

**ҮРТ** «пал, пожар» — гом. тк. *өрт* «үрт, янгын» — бор. тк. *өрүн* «янгын, пожар» сүзеннән, бор. тк. *өр,* монг. *һөр* «ут» сүзеннән (*өр-үн, һөр-үн* — Рамстедт); к. монг. *өрни-* «янып китү, кабыну», *үрсә-лән-ү* «тыелгысыз сикерену» < *урцә-лән-ү* < *уртә-лән-ү,* диал. *уртә-ү* «пожар чыгару, утта яндыру, үчекләшү» < *урт-ә; уртлә-ү* «өтү, яндыру».

**ҮР-Ү I** «плести, заплетать» — гом. тк. *өр-* «үрү, ишү» сүзеннән. Шуннан ук *үрмәләү, үрмәкүч.*

**ҮР-Ү II** «давать ростки» — чув. *ӳр-,* башк. *үрә-, үре-,* госм. *үрә-* «шыту, куе булып калкып чыгу» — бор. тк. *үрә-, үре-* «орлыктан шыту» сүзеннән; бор. тк., монг. *ур, ор, үр, өр* «орлык» нигезеннән (к. **Орлык**); к. диал. *үрек-ү, үрге-ү* «үрчү», *үре-ч-ү* (бор. *үрә-, үре-* фигыленең интенсивлык формасы) «үсентеләр чыгару», *өрет* < *үрет* «курпы, бала-чага» (*Яман булса да, өретең калсын*). К. **Үрче-ү**.

**ҮРЧЕ-Ү** «размножаться; расплодиться» — кк. *өршү-,* чув. *ӗрчӗ-,* монг. *үржи-* «үрчү» — бор. тк. *үре-, өре-* «шытып чыгу» фигыле нигезенә *-че* аффиксы ялганып ясалган (*үре-че-*); чаг. диал. *үршы-ү* «үсентеләр чыгару». К. **Үр-ү II**.

**ҮС-Ү** «расти» — гом. тк. *өс-* «үсү» сүзеннән.

**ҮТ** «желчь» — гом. тк. *өт, өд* «үт» сүзеннән.

**ҮТӘ** «прозрачный; через» — *үт-ү* «перевалить» фигыленең адвербиаль формасыннан (*үт-ә*); к. госм., бор. тк. *өтә* «аръякта, аша, үтә».

**ҮТЕЧ** «взаймы» — чыгт. *өнтүч* «үтеч» — бор. тк. *өтү-нүч* «үтенеч» сүзеннән; к. чыгт. *өтүнч,* куман. *өтүнц,* бор. уйг. (МК) *өтүнч* «үтенеч, үтеч (заем)». Тат. *үтен-ү* < гом. тк. *өтүн-* бор. *өт-* «әйтү».

**ҮТҮК** «утюг» — диал. *өте* < бор. *үтүг, өрт-үг* «өтели, өтә торган нәрсә» сүзеннән (сүзнең ясалыш нигезе *үрт* < *өрт,* к. **Үрт**). Рус. *утюг* — бор. тат. теленнән. Үтүк төркиләрдә башлыча бетләрне үтереп бетерү өчен кулланылган.

**ҮЧ** «месть» — гом. тк. *өч* «үч» сүзеннән. К. **Үҗәт**.



# -Ф-

**ФИЛТӘ** «фитиль» — фарсы. *филитә, филитэ* «филтә» сүзеннән, фарсы теленә исә гар. *фӓтилә-т-ун* «филтә» дигәннән үзгәреп кергән; к. ш. ук рус. *фитиль* < гар. *фитил-ун* «фитиль, филтә». Сүзнең тамыры — *фӓтӓлӓ* «үрү, ишү, җеп кату».

**ФӘЗА** «вселенная; пространство» — гар. *фәза* < грек. *физос, фэзо* «тирәлек» (шуннан *физика* «тирәлек турында фән»).

# -Х-

**ХАН** «хан» — гом. тк. *хан,* барлык телләргә таралган сүз — бор. тк. *кан* «хан» кытай. **куан* «идарәче» сүзеннән хисапланыла; к. ш. ук **Тархан**.

**ХАНЫМ** «ханум; дама» — гом. тк. *ханым* — *хан* (к.) сүзеннән, ягъни «хан хатыны» дип хисапланыла; к. бор. тк. *бәгим* «бәк хатыны», *тарым* «тархан хатыны» (Рамстедт); икенче яктан, к. иск. тат. *хан* «укымышлы бикә» (фарсы. *ханд* «укыган, укымышлы» сүзеннән).

**ХАНӘ** «комната» (в составе многих сложных слов: *ашханә* «столовая», *китапханә* «библиотека», *чәйханә* «чайхана» и т.д.) — фарсы-таҗ. *ханэ* «өй, бүлмә» < бор. ирани. kana, kanak «өй, торак» сүзеннән.

**ХАТЫН** «женщина; жена» — гом. тк. *хатын, хатун* «хатын», көнч. тк. *кадың* «ханбикә», монг. *хатаң* «ханча (княжна)» — төрлечә аңлатыла: берәүләр *хан* сүзе белән бәйлиләр, икенчеләр ирани телләрдән (к. согд. xwtan, xwtn «хатын-кыз») чыгаралар. *Хатын* — Идел буйларында V гасырда теркәлгән төрки сүз.

# -Һ-

**ҺӘҮКӘШ** «буренушка» — тат. диал. *әүкә* id. һинд-евр. *ghau «сыер» сүзеннән (*-кәш* < *-кәч* — иркәләү кушымтасы); шуннан ук рус. *говядина,* инглиз cow «сыер».

# -Ч-

**ЧАБАГАЧ** «цеп, молотило» — *чәп агач(ы)* сүзеннән; к. диал. *чеп* (сергач), *чәп, чип* (мишәр.), *шәп* (урал) «чабагач, чабагач таягы» — көнчыгыш Европада киң таралган сүз: фин-угор. телләрендә (мар., удм., коми.) *чап, чәп,* рус. *цеп* «чабагач» һ.б. Нигездә рус сүзе дип кистереп әйтеп булмый.

**ЧАБАК** «плотва; сорожка» — кырг. *чабак,* чув. *ҫупах,* госм., кырым. *чапак,* бор. тк. (МК) *чапак* «чабак, вак балык», тув. *шавага* «чыбык-чабык; вак балык», алт. (диал.) *чабага* «вак куаклар, чыбыклар» — нининдидер *чап* тамырыннан (*чап-ак*); к.

кырг. *чабыр* «вак балык, вак нәрсәләр (мелкота)». Рус. *чебак* «чабак, вак балык» — төрки телләрдән. К. **Чәбе**.

**ЧАБАН** «чабан, пастух» — кум., кырым., госм. *чабан, чабанчы* «чабан», үзб., ккк. *чупон* «чабан, көтүче» — фарсы. *чубан, шубан* «сарык көтүчесе», бор. фарсы. xšu pana «сарык караучы» сүзеннән; рус. *чабан* төрки телләрдән.

**ЧАБАТА** «лапти» — кк., ккк. *шабата* «чабата, башмак», тат. диал. (себ. тат.) *шыпытый* «чүәк», чув. *сăпата* «чабата», рус. диал. *чебота, чеботья* «башмак; итек» бор. ирани. cabbada «итек» сүзеннән таралган; к. ш. ук фарсы. *чабатан, чабатанд* «чабата (*каештан үрелгән*)». К. Әхмәтьянов, 1989: 33.

**ЧАБУ** «пола, фалда» — кум. *чабыв*, кырг. *чабуу, чапы* ~ хакас. *сабығ*, чыгт. *чапуқ* id. Чаг. бор. тк. *чабғут* «юрганчык». К. **Чапрак**.

**ЧАБ-У** «бить с размахом; косить; скакать» — гом. тк. *чап-* < *чалп-* id. К. **Чал-у**.

**ЧАГАН** «клен» — монг. *чагаан, цагаан* «ак» сүзеннән; к. бурят. *сагаан үлтэнэг* «чаган» («клен», *букв.* «белый луб»: *сагаан* «белый», *үлтэнэг* «луб, пакля»). К. **Чагыр, Чал**.

**ЧАҒЫЛ** «склоны гор» — диал. *чәгыл* «вак куаклык», *чағу* «калку җир», *чаука* «вак әрәмә», алт. *чаалл* «вак куак», башк. *сауыҡ, сауҡа* «вак каенлык», кырг. *чогоол* «энәле куаклык, саксавыл».

**ЧАҒЫЛ-У** «отражаться; сверкнуть» — гом. тк. *чақ-* «ялкын чыгару» фигыленең төшем юнәлеше формасыннан; к. ш. ук бурят. *сахил-*, монг. *чакин-* «ялтырап китү», якут. *чагылый-* «чаткылар чыгару», *чагылган* «яшен» (чаг. диал. *җала, җалагай* «нажагай»).

**ЧАГЫР: чагыр күзле** «пестроглазый» — тат. диал. *шагыр*, башк. *сағыр, сәгер* «чагыр, аксыл-зәңгәр», гом. тк. *чакыр* «зәңгәрсу», угыз. *сакар, саггар* «ак кашка», бурят. *сахир* «аксыл» — бор. тк., бор. монг. *чак(ы)* «ак, ап-ак, зәңгәрсу-ак» сүзеннән. К. **Чаган, Чал, Шар II**.

**ЧАГЫШТЫР-У** «сравнить» — диал. *чагыш-у* «туры килү, тәңгәл килү, тиңләшү» фигыленең йөкләтү юнәлеше формасыннан, сүзнең тамыры *чак* (к.) «тигез, таман, тиң», тк. *чагы-у* «тиң килү», хакас. *сағыстыр-* «бәрдерү, бер-берсенә бәрү». *Чагыштыру* татар сүзе дияргә мөмкин (кырг. *чагыштыр-* id. татарчадан булса кирәк); к. кырг. *чагын* «охшаш, тиң».

**ЧАДРА** «чадра» — фарсы. *чадра, чадар* «чадра» сүзеннән; сүзнең төп чыганагы бор. һинд. čattra «зонт, зонтик» (čat — šat- «күләгәләү» фигыленнән). К. **Чаршау, Чатыр**.

**ЧАЙКА-У** «качать; сполоснуть; мотать» — гом. тк. *чай-* «чайкау, дулкынлату» (тасвирый яңгырашлы фигыль) сүзеннән ясалган (*чай-ҡа* яки *чайық- а-*); к. алт. *д'айка-* «чайкау (качать)», *д'ай-* «чайкау, язу (распускать)», тув. *чай-* «чайкау, болгау, айкау», үзб. *чай-* «чайкау, су коену», башк. *сай-ын-у* «су керү, коену». К. ш. ук тат. диал. *чайпал-у, чайпыл-у* «всплеснуться», башк. *сайпыл-у*, алт. *чайбал-у* «всплескиваться», алт. *чайба-* «чайкау (полоскать)».



**ЧАК I** «пора, время; еле, чуть» — гом. диал. *чақ* «таман, тигез», *чәк* (тат.), *сәк* (мишәр.) «бераз; вакыт; таман», кк., ккк. *шақ* «чак, вакыт, үлчәм», алт. *чақ* «вакыт, чор, көч, яхшы кәеф», үзб. *чоқ* «яхшы кәефле», уйг., кырг. *чақ* «вакыт; көч; эш», чыгт., госм. *чаг* «билгеләнгән вакыт, унике еллык цикл, борынгы астрономик сәгать (хәзерге ике сәгатькә тиң)», хакас., якут. *сах* «нәкъ», бурят. *сағ* «вакыт, сәгать», монг. *чаг, цаг* «вакыт; һава торышы» — бор. гом. тк. *чақ, т'ақ* «билгеле бер чик, нокта, үлчәм, период» сүзеннән. К. **Чагыштыр-у**, **Чаклы**. К. Әхмәтьянов, 1989: 159.

**ЧАК II** *диал.* «впору, как раз» — ачык түгел, ихтимал, диал. *чақ* «ярлы, житешсез» сүзеннәндер, ул вакытта к. **Чак I**.

**ЧАКЛЫ** *послелог* «до; по» — тат. диал. бор. тк. *чақ* «билгеле бер чик» сүзеннән (*чак-лы*); к. диал. *чақла-у* «чамалау; төгәл туры китерү». К. **Чак I**.

**ЧАКМА** «огниво; кремневый» — гом. тк. *чақ-у* «очкын чыгару» сүзеннән (*чак-ма*); тат. *чак-у* «высекать огонь; кольнуть; жалить» — гом. тк. *чақ-* «тиз генә сугу, яшен яшьнәү, чагу» < бор. гом. тк. *чақ-* «тиз генә кисеп җибәрү, кадау, яшьнәү» сүзеннән; к. диал. *чак-, ча-* (мишәр.), *цак-* (себ. тат.) «яру, телү, тешләү, бәрү, утын яру, чыра телү, ут ягу», үзб. *чак-* «яру, ваклау, шакмак ваклау, шырпы сызу, чакма чагу», *чақмоқ* «чакматаш, шакмак», хакас. *сак-* «чагу, кадау», *сак-* «чагу, чакма сугу», бурят. *сак-* «чакма чагу». К. ш. ук тат. диал. *чага* «жало», үзб. *чака* «сызлавык», үзб. *чакар* «үткен, кискен», *чақир таш* «чуер таш», якут. *чакыр*, бурят. *сахур*, монг. *чаки гур* «чакматаш», монг. *чагул-* «тишү». К. **Сагызак, Чагыл-у, Чакма, Чалым, Чалын-у, Чалт, Чаткы, Чатна-у, Шакмак**.

**ЧАКЫР-У** «звать; приглашать» — гом. тк. *чақыр-* «кычкырып чакыру, аваз салу», бор. тк. *чағур-, чақур-, чарқыр-* «чакыру, кычкыру, гарыз кылу (бить челом)»; авазларны белдерә торган фигыльләр ясагыч *-кыр // -кер* аффиксы ярдәмендә *чар // җар* «чакыру, өндәү» сүзеннән ясалган. К. **Чакрым**.

**ЧАК(Ы)РЫМ** «верста» — гом. тк. *чакырым* «чакрым» — гом. тк. *чакыр-у* (*чар-кыр-у*) сүзеннән (*чакыр-ым* «аваз салып ишетерерлек ара»; чаг. тув. *кышқы* «кычкырык; чакырым», калм. *дума газар* «тавыш җир — чакрым»; белорус. *кликовище* «чакрым», *кликать* «кычкырып чакыру»; эрзя. *вайгельбе* «чакрым», *вайгель* «кычкырык» (Егоров), мар. *уштыш, оштыш* «кычкырык; чакрым»). Чаг. ш. ук тат. диал. *кычкырым*, чыгт. *кыйкырым*, төрек. *багырым* «чакрым».

**ЧАЛ** «седина, проседь» — гом. тк. *чал, чăл* «чал, аксыл, соргылт-аксыл», бор. тк. *чағыл, чақыл* «аксыл», бор. *чак* «ак, ап-ак» сүзеннән (*чаг-ыл;* чаг. *кыз-ыл, яш-ел*). К. **Чаган, Чагыр**.

**ЧАЛБАР** «шаровары; брюки» — диал. *шалбар, шалауар* «чалбар» — фарсы. *шалwар*, бор. фарсы. šaruar «чалбар» сүзеннән (рус. *шаровары* төрки телләрдән). Шуннан ук тат. диал. *сирвәлә* «хатын-кызлар чалбары».

**ЧАЛГЫ** «коса» — тат. диал., гом. тк. *чал-* «печән чабу, кисү,

кырку» сүзеннән (*чал-гы*); к. бор. тк. *чалғу* «чалгы, урак, кыллы уен коралы».

**ЧАЛКАН** «на спину» — бор. *чалакан, очалакан* «очага яткан» сүзеннән, тат. диал. *очала-у* «очага (аркага) яту» фигыленнән (*очала-*; к. *оча*); к. алт. *уча* «арка, оча», *учалан* «чалкан», мар. *вуза-ла-ш* «җәелеп утыру», чув. *вуҫа-ла-, выҫҫа-ла-* «очага утыру» (чув. *выҫҫа* «оча»). К. ш. ук диал. *чалкы* «чалкан», *чалкай-у* «чалкан яту» (болар соңрак *чалкан* сүзе нигезендә барлыкка килгән сүзләр).

**ЧАЛМА** «чалма» — *чал-у* «ыргытып урату, аягына бау уратып егу» фигыленнән, чаг. диал. *чалма* «пароходны дебаркадерга беркетә торган аркан». Рус. *чалить* (*причалить*) — тат. *чал-* фигыленнән.

**ЧАЛТ: чалт аяз** «совершенно ясный» — бор. тат. *чал-, чағыл-* «яктырту, яп-якты булу» фигыленнән булса кирәк (*чал-т, чагыл-т*); к. алт. *чал-, чалы-* «яктырту, балку». К. **Чагыл-у**.

**ЧАЛ-У** «подставить ногу; зарезать (животных)» — гом. тк. *чал-* «җилкенеп сугу, селтәнү, ташлау, мал тоту, эләктерү, корык ыргыту, арканлау, урату, урау, скрипкада уйнау (сызма белән селтәнү)», бор. тк. *чал-* id. сүзеннән (төрки телләрдә бик күп сүзләр шул нигездән ясалган, к. ш. ук *җил, салпы*). К. **Чалгы, Чалма, Чалыш, Чәл-ү, Чылгый ~ Чалгый**. *Чап-* < *чалп-*, *чалпы-* сүзе дә (к.**Чаб-у**) шул тамырдан.

**ЧАЛЫМ** «черты сходства» — диал. *чагылым* «чалым, чагылып киткән билге» сүзеннән. К. **Чагыл-у.**

**ЧАЛЫШ** «косой; кривой» — *чал-у* (к.) сүзеннән булса кирәк. К. алт. *чалый* «чалыш».

**ЧАМА** «мера; возможность» — чув., мар., удм., кырг. *чама*, н., кк., ккк. *шама, шәмә*, ткм. *чәмә* бор. кытай. *ча-ма* «чәй-ат» (чәйне атка алмашу эквиваленты) сүзеннән.

288) Бу сүз борынгы уйгурларның күчмән төркиләрдән күпләп ат алып, аны чәй шырларына (тюкларына) алмашып сәүдә иткән заманнарыннан калган. Ул чакта атларны чәйгә алмашу пунктлары *ча-ма-сы* дип, аш һәм чәй бәяләренең нисбәте *ча-ма* диелгән.

**ЧАН** «чан» — бор. тк. *чан* «чан, казан» — кытай. *чан* «казан; бассейн» сүзеннән.

**ЧАНА** «сани» — алт., чыгт. *чанақ* «чана», тув. *шанақ* «чана», якут. *сыңақ* «яңак, чана», чыгт. *чаңа* «аскы яңак», үзб., таҗ., грузин., авар. *чана, чанағ* «чана». К. **Чаңгы, Яңак** (чана табаны яңак сөягенә охшатылган).

**ЧАНДЫР** «сухопарый» — үзб. *чандир* «чандыр,ябык», кум. *чандыр*, н. *шандыр*, уйг. *чандир* «сеңер», башк. *сандыр* «чандыр, касык», кк., тув. *шандыр* «корсак асты; итсез, мускулсыз урын» монгол телләреннән; к. бурят. *шандаһар, шандааһагар* «чандыр, сөякләч», монг. *чандаа* «нигез; скелет; грунт».

**ЧАҢ** «колокол, набат» — гом. тк. *чаң* «чаң авазы» — тасвирый яңгырашлы сүз; чаг. *чың иту, даң, таң*. К. ш. ук бурят. *саң*, монг. *чаң* «кимвал (бер-берсенә сугып аваз чыгарыла торган дисклар — музыкаль инструмент)».



**ЧАҢГЫ** «лыжи» — *чана* (к.) сүзе белән бердәй диярлек; к. диал. *чаңга, чаңа* «чаңгы», бурят. *сана, чана*, монг. *цана* «чаңгы», *шанаа* «яңак» (чаг. бурят. *ургэн* «яңак, ияк, чана табаны»), эвен. *хынгак, сыңгак* «чана табаны, чаңгы». К. **Чана**.

**ЧАПАН** «чапан» — фарсы. *чаппон* «чапан, халат» сүзеннән; фарсыга гарәп диалектларыннан кергән, гарәпкә исә итальян теленнән кергән. К. **Җөббә**.

**ЧАПТАР** «игреневый» — гом. тк. *чаптар, чамдар, шабдар* «чаптар» — бор. монг. *чабидар* «җирән» < *чағаб-дар* «аксыл (кызыл)» сүзеннән. К. **Чаган, Чагыр**.

Әдәби әсәрләрдә *чаптар* сүзен «чабышкы» яисә «чапкын; кугын» мәгънәләрендә куллану еш очрый.

**ЧАПРАЗ** «прошнуровка вместо пуговиц (*на старинной военной и женской одежде*)» — фарсы. *чап-у-раст* «уң һәм сул; уңлы-суллы» сүзеннән. К. **Чапрыш**.

**ЧАПРАК** «чепрак; старая одежда, подкладываемая под седло» — к. **Чүпрәк-чапрак**. Бор. тк. *чапыр* калын аркаулы тукыма.

**ЧАПРЫШ** «наискось» — фарсы. *чап-у-раст* «унлы-суллы». К. **Чапраз**.

**ЧАПЧАК** «кадка, бочонок (*из цельного дерева*)» — гом. тк. *чапчақ*, башк. *сапсақ*, якут. *чабычақ* «агач стакан, чиләк, чапчак» — бор. тк., монг. *чапчы-, чабчи-* «агач чоку, агач ую» сүзеннән.

**ЧАР** «точило» — фарсы. *чарх* «чар, куласа» сүзеннән. К. **Чарык**.

**ЧАРА I** «средство» — фарсы. *чара* «чара» (нигездә, «нәрсәгә»).

**ЧАРА II** «широкая кухонная посуда» — алт., гом. кыпчак., бор. монг., маньчж. *чара, цара* «җәенке табак» (элегрәк «тире табак») *шәрә* (к.) сүзе белән бердәй.

Рус. *чара, чарка* «купы» татарчадан; төрки һәм монголлар шәрә — йоны коелган тиредән һәртөрле савытлар ясап килгәннәр.

**ЧАРЛАК** «чердак» — фарсы. *чартак* «чардак, дүрт терәкле манарачык» (*чар* «дүрт», *так* «дугайлы арка»). Бу сүз русчага төрки телләрдән *чердак* һәм *чертог* рәвешләрендә ике сүз булып кергән.

**ЧАРШАУ** «полог; занавес» — фарсы. *чадыршаб* «төнге чатыр» (*чадыр* «чатыр», *шаб* «төн») сүзеннән.

**ЧАРЫК** «колесо с лопастями; прялка» — фарсы. *чарх* «тәгәрмәч, көпчәк, чарык» сүзеннән. К. ш. ук **Чар, Чыгыр**.

**ЧАРЫС** «резвый, горячий (*о лошади*)» — к. диал. *җарыс* «куркак, ярсу», себ. тат. *царыс* «свирепый», чув. *чурӑс* «кире, тупас, тәкәббер», мар. *чорыш* «шәп йөрешле, ярсу», үзб. *чарс* «усал (*ат турында*)». К. **Чәрчә-, Шаш-, Ярсы-**.

**ЧАТ** «развилина; перекресток; угол» — гом. тк. *чат* «елга чаты, чат, җәп, ярык» сүзеннән. Тамыр бәйләнешләре ачык түгел. К. диал. *чата* «чатлы таяк», *чатал* «вилка»; к. **Чатак, Чатан, Чит**. К. Әхмәтьянов, 1989: 44 — 45.

**ЧАТ: чат ябышу** «вцепиться» — чаг. чыгт., госм., кырым. *чат-* «ябышу», үзб. *чат-* «ябыштырып тегү».

**ЧАТАК** «уродливый, ненормальный» — *чат* (к.) сүзеннән булса кирәк; к. үзб. *чатоқ* «буталчык», *чатиқ* «аркылы-торкылы», якут. *сатай-* «бозылу, кыйралу». К. ш. ук диал. **Ботак-чатак**.

**ЧАТАН** «хромой» — *чат* (к.) сүзеннән булса кирәк; к. үзб., чув., госм. *чатан* «чатан (*башлыча хайваннар турында*)», кк., чыгт. *чатан* «атның бот өлеше, бер-берсенә беркетелгән нәрсә», кк. *сатан* «бот, бот арасы, чат», удм. *чут*, коми. *чатны* «чатан» (төрки телләрдән).

**ЧАТКЫ** «искра, искорка» — диал. *чагылткы, чагыткы* «чаткы, очкын» — диал. *чагылт-у* «чакма чагу, чагылдыру» сүзеннән. К. **Чагыл-у**, **Чак-у**.

**ЧАТЛАМА** «трескучий» (*чатлама суык* «трескучий мороз») — *чартла-у* (*чарт итү*) фигыленнән; к. диал. *чалтлама, чартлама* «чатлама», чув. *шартлама сивĕ* «чатлама суык». Чаг. **Шартла-у**.

**ЧАТНА-У** «треснуть, потрескиваться» — диал. *чартла-у, чыртла-у* «чарт итеп ярылу» сүзеннән булса кирәк; к. чув. *чатла-* «чат-чат чабу, чатнау», госм., чыгт. *чатла-* «чатнау».

**ЧАТЫР** «шатер; палатка» — фарсы. *чадыр, чадур* «чатыр» сүзеннән. Күп телләргә таралган. Асылда, бор. һинд. сүзе; к. **Чадра**. К. Әхмәтьянов, 1989: 144 — 145.

**ЧАЧАК** «бахрома» — уйг., госм., чыгт. *сачак*, бор. тк. *сачак, сачук*, якут. *сусуох*, монг. *чачак, цацаг* «чачак» — бор. гом. тк., гом. монг. *сач, час-* «чәч, чук, сибелдерү, чәчү, тарату» тамырыннан (Рамстедт). К. ш. ук эвен. *чэчэ* «тәлкәш (клок)», удм. *чача* «чәчәк; уенчык», таж. диал. *чачча* «чачак, очкыннар көлтәсе». К. **Чәч, Чәчәк, Чәч-ү**.

**ЧАЯ** «отчаянный, бойкий» — диал. *чайан* «чая», *чайа* «шаян, шук, алдакчы», чув тк. *чейе* «чая», мар. *чая* «чая», *шайа* «сүзчел, юк-бар сүз, гайбәт, әкият, ялган» — якут. *сайагас* «булдыклы, теремек (*бала*)». Төрки мәҗүсилегендәге *җаян* < *җаяган* < *йайаган* «шәхит булган кешенең тереләр тормышына актив катнаша торган рухы» сүзеннән (тамыры *йай-* ~ бор. һинд. *йай-* «кеше корбан итү; шәһит булу»). *Чая, чаян* татар теленә Себер татарларыннан ([*җ* > *ч* ~ *ц*]) килгән, ә аның *шая* шуннан *шая-я-у, шаян* варианты (к. **Шаян**) нугайлар аша ([*ч* > *ш*]) кергән булса кирәк. *Наян* варианты татар телендәге хакас компонентыннан (бу телдә [*й* > *н*] еш очрый).

**ЧАЯН** «скорпион» — госм., чыгт. *чайан*, үзб. *чайан*, уйг., бор. тк. *чадан, чабан* «чаян», бор. тк. (МК) *җаҗан* «чаян, кыргаяк, көлтә». Чаг. иске тат. *чайбан* «чаян, меңаяк».

**ЧӘБӘ** «возглас, которым отгоняют собак» — диал. *сәбә, цәбә* «чәбә» — бор. ирани. spaka «эт, кәнтәй» сүзеннән булса кирәк; шуннан ук рус. *собака*.

**ЧӘБӘЛӘН-Ү** «бить руками и ногами» — госм. *чабала-* «чәбәләү» — *чап-у* «чабу» фигыленең интенсивлык формасыннан. К. **Чәпә-ү**.

**ЧӘБЕ** «хворост на корм скоту» — диал. *чабык* «вак чыбыклар, кисентеләр (чыбык-чабык)», чув. *çапă* «вак чыбыклар, талчыбык», көнч. тк. *чабага* «чыбык-чабык» — гом. тк. *чап-* «балта белән чапкалау, кисү, кырку» сүзеннән (Егоров); к. ш. ук удм. *чебы, чабы*, мар. *саве* «озын талчыбык; читән», венг. *syepu* (*зепу*) «чәнечкеле куаклардан торган киртә». Чаг. **Чәпе**.

**ЧӘЕР** «смола» — тат. диал. *чайыр, сайыр*, башк. *сайыр*, кырг. *чаҗыр* «чыршы чәере, агач җилеме, сагыз, гәрәбә» — бор. тк. *сағыр, çакыр* «сагыз, чәер» сүзеннән. К. **Сағыз**.

**ЧӘЙ** «чай» — кытай теленнән барлык төрки телләргә таралган сүз. Рус. *чай* — татар теленнән (XV гасырдан башлап чәйне татар сәүдәгәрләре китергән).

**ЧӘЙНӘ-Ү** «жевать» — гом. тк. *чайна-* «чәйнәү, тешләү, кыру, яньчү», бор. тк. *чагна-, чагын-а* «чәйнәү» бор. тк. *чағ, җағ* «янак (челюсть)» сүзеннән; к. бор. монг. *җагу-* «чәйнәү, тешләү», уйг. *чәкнә-* «чәйнәү, таптау».

**ЧӘКӘН I** «початок» — кырг. *чэкэн*, чув. *чакан* «чәкән» — бор. тк., монг. *чак* «башак, колак» сүзеннән булса кирәк. К. диал. *чака* «арба чәкүшкәсе, бор. тк. *чәка, чака* «башак, чәкүшкә, чәкән», монг. *чикин, чэгэн* «чәкән, колак, чәкүшкә», монг. диал. *җих, җэх* «колак, чәкүшкә». К. **Җикән, Зикән**.

**ЧӘКӘН II** «чекан; молоток с длинной рукояткой» — кк. *чакан* id. тат. *чәке-, чәкә-* (*чәкәт-*), гом. тк. *чак-* «тиз генә сугып алу» сүзе белән тамырдаш.

*Чәкән, чакан* борынгы төркиләрнең сугыш коралы булган һәм төрки телләрдән бу сүз күп телләргә таралган: фарсы. *чаукан, чауган* «атлы туп уены, атта чәкән уйнау», барлык славян телләрендә *чекан*, венгрча czakanu «чәкән».

**ЧӘЛПӘРӘМӘ** диал. *челпәрәмә* «вдребезги» — фарсы. *чилпарә* «кырык кисәк (кырык парә)» сүзенә *-мә* кушымчасы ялганып ясалган. Чаг. **Челтәр, Чылбыр**.

**ЧӘЛ-Ү** «украсть, стянуть» — чыгт., бор. тк. *чал-* (к. **Чал-у**) «малны суярга чалып егу, кеше малын урлау» сүзеннән; к. гагауз. *чал-* «урлау, чәлү», кырг. *чэл-* «мөгез белән электерү».

**ЧӘМ** «страсть» — ~ диал. *чам, цам* «чәм, үпкә, ачу», үзб. *чам* «дәрт», бор. тк. *чам* «бәхәс, судлашу», уйг., кырг. *чам* «зур адым, аяк басу», уйг. диал., тув., монг. *цам, чам* «дини бию; пантомима» — тибет. *тсам* «шаман биюе» сүзенә барып тоташа.

**ЧӘМЧӘ** «кайма, узор» — к. себ. тат. *цамца*, уйг., алт., монг. *чамча* «хатын-кыз күлмәге», монг. *цамц* «камзул» бор. гом. алт. *сам, чам* «житен» сүзеннән (Рамстедт).

**ЧӘНЧӘ, ЧӘНТИ** «мизинец» — күп телләргә таралган сүз: тат. диал. *чәнтәй, чәмкәй*, алт. *чэчэн*, госм., кырым. *чынача*, якут. *чанчык, чәгчәкәй*, таж. *чэнчиләк*, эвен. *чинчэн*, эвенк. *чимчэн*, удм. *чины, чунь, чәл*, коми. *чәл*, эстон. *цилби* «чәнчә бармак, бармак; үсенте».

**ЧӘНЕЧ-, ЧӘНЧЕ-** «воткнуть, пырнуть» — гом. тк. *санч-*, көнч. тк. *чач-, шаш-*, якут. *сус-* «чәнчү, кадау» — бор. тк. *сән-, сан-, сайн-, сак-ын-* «кадау» фигыле нигезенә *-ч (-че)* аффиксы ялганып ясалган. К. **Сәнәк**.

**ЧӘПӘ-Ү** «хлестко бить ладонью или иным плоским предметом» — төрки телләрдә төрле фонетик яңгырашларда киң

таралган *чәп- // чап-, сап-* «кинәт сугу, селтәнеп сугу» фигыленнән (*чап-а*, тат. *чап-у*); к. диал. *чәп-, чәпе-* «чәпәү», *чәпәк, чәбәк, чәбәкәй* «алкышлау» һ.б. К. **Чәпче-ү**.

**ЧӘПЧЕ-Ү, ЧАПЧЫ-У** «биться ногами в упряжке (*о лошади*); горячиться» — башк. *сапсы-у*, якут. *сап-сый-* «чәпчү, тибенү, селтәнү, очып килеп сугылу (*кошлар турында*)» ~ бурят. *сабша-* «балта чабу, селтәнү, тибенү» — бор. тк. *сап-, саба-* «сабау, селтәнеп сугу» сүзенә бор. *-чы (-ча)* аффиксы ялганып ясалган фигыль; к. ш. ук кк., башк. *сапсаң* «типкен, житез, елгыр, кошларны һавада тибеп ала торган лачын» > тат. диал., рус. *сапсан* «лачынның бер төре». Чаг. диал. *чәнче-ү* (*дулкын*) ярга бәрелеп тору».

**ЧӘПЕ, ЧӘПЕР** диал. «ткань с толстым утком; грубоватая, но прочная ткань» — к. ткм. *чәпәр* «основа ковра» < бор. тк. *чапыр, чапур, чаппар* ~ перс. *чаппара* тукыма төре.

**ЧӘРМӘ** «кожаная сумка» — тат. диал. *чирмә, ширмә, чәрем* id., *чәрми* «күн лифчик» — фарсы. *чәрмәи* «күннән ясалган», *чәрм* «күн». Тат. диал. *чәрби* «хатыннар итеге» фарсы. *чәрмпай* «күн аякчу» сүзеннән. *Чәрмә* — күннән эшләнгән әшьяларның (изделия) гомуми атамасы булган һәм чәрмә белән башлыча татарлар шөгыльләнгән. К. **Чирбек**.

**ЧӘҮКӘ** «галка» — диал. *чаука*, кб. *чаука*, удм., коми. *чавкан* (татарчадан булса кирәк) «чәүкә, карга» — чәүкәләрнең тавышыннан чыгып ясалган сүздер (К.Насыйри); к. *чәукәләр чәкелди, чәкел-чөкел итә*, фарсы. *чау-чау* «чәүкәләр тавышы», рус. диал. *чавка* «чәүкә».

**ЧӘЧ** «волос» — гом. тк. *сач, чач* «чәч, тәлкәш, чачак» сүзеннән. К. **Чәчәк, Чәч-ү**.

**ЧӘЧӘК I** «цветок» — алт., чыгт., уйг. *чәчәк, сачәк* «чәчәк, чәчкә, чәчәк II» — гом. тк. *чачак* (к. **Чачак**) сүзе белән параллель яшәп килә торган сүз; к. диал. *чичәк, чичкә* «чәчәк», монг. *сэчэг, чэчэг*, бор. монг. *сачуг* «чәчкә, чачак». К. **Чәчәк II**.

**ЧӘЧӘК II** «оспа» — гом. тк. *чәчәк*, тув. *чечке* «чәчәк (оспа); чәчкә» *чачак* (к.) сүзеннән.

**ЧӘШКӘ** «чашка; блюдце» — мар. *цäшка, чашка*, удм. *чашка*, чув. *чашăк-* рус. теленнән (*чаша* сүзенең кечерәйтү формасы).

**ЧӘШКЕ** «норка» — мар. *шашкы, шашкэ*, удм. *чашкъ*, чув. *шашкă* «чәшке» — Урта Идел өчен характерлы сүз, мари теленнән таралган булса кирәк (Рясянен, 1969: 105).

**ЧЕБЕН** «муха» — чыгт., уйг. (диал.), кырым. *чибин*, алт. *чымын, чыбын* «чебен, бал корты, шөпшә» — типологик характердагы *чәб, чиб* «очучы бөҗәк» сүзеннән; к. бор. рус. *чапы* «чебен, бал корты», шумер. zibin «бөҗәк, чебен». К. **Чыбылдык**.

**ЧЕБЕШ** «цыпки» — гом. диал. *чебеш* «чеби» сүзеннән; к. гом. диал. *чеби* «аяктагы чебеш», башк. *себешке* «чебеш»; чаг. рус. *цыпки* «чебиләр: чебеш (*аяктагы*)». К. ш. ук венг. *sebes* (*шебеш*) «канаганчы сыдырылган», *sebhely* (*шебел-*) «яра эзе».

**ЧЕБИ** «цыпленок» — диал. *чебек, чебеш* «чеби» — типологик характердагы сүз: рус. *цыпка, цып-цып* (шуннан *цыпленок, цыплята*), мар. *цеве*, венг. scibe, фин. cibi, čibi «чеби», коми. *чипан* «тавык», осетин. c'ipi «чеби, кечкенә кош» — кечкенә кошлар һәм чебиләр чыгара торган авазга охшатып ясала торган сүз. К. **Чыпчык**.

**ЧЕГӘН** «цыган» — тат. *чыйган*, башк. *сыйған*, мар. *чыган*, *чыган*, удм. *чиган* бор. тк. *чигань, чигай* «ярлы, фәкыйрь» сүзеннән; шуннан ук чув. *чухăн* < *чохын* < **чагын* «ярлы, начар: чакын» (тат. диал. *чақ* ~ чув. *чох, чух* «начар» сүзенең инструменталь килеш формасы). К. Әхмәтьянов, 1989: 115.

**ЧЕЛӘН** «цапля» — чув. *чарлан* «челән, акчарлак» сүзенә караганда тат. диал., чув. диал., ткм. *чарлақ* «акчарлак, чарылдап кычкыручы кош» сүзенең бер вариантыннан гыйбарәт (бор. **чарлаң* формасыннан булса кирәк). К. ш. ук тув. *шилэн*, хакас. *сулэн*, маньчж. *сулахун*, негидаль. *силигэн* «челән, торна, ләкләк», гом. тк. *чел* (тат. диал.), *чил, чыл* «көртлек; челән».

**ЧЕЛЕМ** «чилим (*курительная трубка*)» — гом. тк. *чилим, чылым* «челем» — фарсы теленнән (М.Рясянен, К.Юдахин). К. **Черем**.

**ЧЕЛЛӘ «горячая пора»** — үзб., таҗ., фарсы. *чилла, чэллә* «җәйге иң эссе һәм кышкы иң суык кырык көн (25 июнь — 5 август һәм 25 декабрь — 5 февраль)» — фарсы-таҗ. *чил, чэл* «кырык» сүзеннән. К. **Чәлпәрәмә, Челтәр, Чылбыр**.

**ЧЕЛТӘР** «сетка; кружево» — фарсы-таҗ. *чилтара* «челтәр» сүзеннән; төп мәгънәсе «кырык тишек»: *чал, чэл* «кырык», *тара* «тишек». К. **Челпәрәмә, Челлә, Чылбыр**.

**ЧЕРЕМ: черем итү** «подремать» — башк. *серем*, чув. *чĕрĕм*, удм. *чырым*, кк., н. *шырым*, кырг. *чырым* «черем, кыска ял». Тат. диал. (казан арты) *челем иту* «ял итү, черем итү, тәмәке тартып алу» тәгъбире бу сүзнең *челем* (к.) сүзеннән килеп чыкканлыгын дәлилли ([*л>р*]).

**ЧЕРКИ** «комар» — диал. бор. тат. *черекәй чебен, сиүрек себен* «озын борынлы, сөңгеле чебен» сүзеннән килеп чыккан (*черекәй* < *чурәкәй* «озын һәм очлы борынлы», *чебен* сүзе төшеп калган); чаг. диал. *сөйре* «озынборын (черки), арба сүрәсе, сөңге» (к. **Сүрә**), уйг. *сиwри синәк* (*синәк* «чебен»), кум. *сүйри чибин* «черки». К. тат. диал. *сурәкә, сөрәкә* «сөңге», башк. *серәкәй* «черки».

**ЧЕРЧЕТ** «орда, враждебное полчище» — к. кырг. *чурчут* «кяфер, дошман кабилә», себ. тат. *чурчут* «кытай-маньчжур халкы», бор. монг. *җурҗут* «чжурчженьнәр, маньчжурлар» (*җурҗун* «чжурчжень» сүзенең күплек формасы). VIII — XI гасырларда Амур, Керулен буйларында яшәгән татарлар *чжурчженьнәр*, ягъни «чжур кешеләре» белән каты көрәш алып барганнар. Шул заманнан *черчет* сүзенең «дошман чирүе» мәгънәсе кала, венг. scerscet «черчет, орден, община» бор. кыпчак теленнән. К. Әхмәтьянов, 1981: 45.

**ЧЕТЕРЕК** «каверзный; щекотливый» — диал. *чытырык* «четерек, куе чытырманлык» сүзеннән. К. **Чытыр**.

**ЧИ** «сырой» — гом. тк. *чиг, чығ* «чи, юеш, чыланган» сүзеннән; к. кар. *чый* «чи». К. **Чык, Чылан-у**.

**ЧИБӘР** «красивый» — алт., уйг., якут. *чәбәр*, монг. *цэбэр // цэвэр, чэбэр*, бурят. *сэбэр*, кк., тув. *шэвэр* «таза, матур, пөхтә, сылу, оста» (к. рус. диал. *чебер*, морд. *цеберь*, чув. *чипер* «чибәр» — татар теленнән), алт. *чэбэр*, хакас. *сибәр* «саклык, пөхтәлек, тазалык» монголча *чэгэ-бэр* «аклык, сафлык» сүзеннән (Будагов) — тамыры монг. *чэгэ, чага* «ак, саф».

**ЧИБЕК** «слабенький» — башк. *сибек* id. Чаг. кырг. *җилбик* id.

**ЧИГӘ** «висок» — уйг., кырг., бор. тк. *чәкә, чәгә* «чикә», үзб. *чәккә* «чикә» — бор. тк., бор. монг. *чәкә* «колак яны» сүзеннән булса кирәк; к. монг. *чикэ, җихэ* «чигә, колак», тат. диал. *чикә* «башлы кадак». К. **Чөй**.

**ЧИК** «край; граница» — тат. диал., гом. тк. *чек, чэк* «чик, чит» сүзеннән; к. ш. ук бор. тк. *чак* «чик, кырый», үзб. *чекка, чегәрә* «чик», бурят. *сэг* «чик», венг. szeg «чик (край), чит». Тибет теленнән кергән дигән фараз бар.

**ЧИКЕРТКӘ** «кузнечик; стрекоза» — алт. *чәгәртқә*, госм. *чәкиргә*, бор. тк. *чекүргэ* «чикерткә» — чикерткәләр чыгара торган авазга охшатып ясалган нигездән булса кирәк: госм. *чырт-лака, чырғып* «чикерткә», кк. диал. *чэк-чэк* «чикерткә», коми. *чирк* «чикерткә», алт. *сығырчық*, хакас. *сығырчақ*, рус. *сверчок* (> тат. *чөрчек*) «өй чикерткәсе», якут. *чыркый-, чырдырға-* «чикерткә сайрау».

**ЧИКЛӘВЕК** «орех» — гом. диал. *читләүек, чатлауык*, кырым. *чәтләүек*, башк. *сәтләүек* — гом. тк. *чәртлә-у, чартла-у* «чырт итеп ярылу» сүзеннән (*чикләүек* < *читләүек* ~ *чәтләүек* < *чәртлә-ү-ек* «чертли, чыртлый торган»); чаг. исе әд. *чатлауык* «чикләвек ваткыч», алт. *чәрт-* «чикләвек ашау», чыгт. *чәкирдәк* «җимешнен каты төше».

**ЧИКМӘН** «чекмень; зипун» — иске тат. (Троянский) *чибкән*, тат. диал. *сукмән*, себ. тат. *цәкмән* «чикмән» — гом. тк. *чэкмән, чәбкән* һәм *сәкмән, сукман* вариантлары бар. Рясянен *чэкмән*не бор. тк., төрек. *чэк-* «тарттыру, кию» сүзеннән, ди (чаг. ш. ук бор. *чэк* «өске кием өчен тукыма»). *Чәпкән* варианты бор. *чәп-* «туку» фигыленнән (к. тат. диал. *чәпе, цәпе* «гади тукыма»); чаг. фарсы. *чәкбәнд* «хәрби амуниция (*чәк* «кием» — төрки телдән, *бәнд* «каешлар, бәйләвечләр»), бурят. *җәбхүүн* «чикмән».

**ЧИЛӘК** «ведро» — госм., чыгт., үзб., кк. *чәләк* «чиләк», кырг. *чэлэк* «агач чиләк, тәгәрмәч көпчәге» (бу мәгънәләр сүзнең башта куыш агачны белдергәнлегенә ишарә ясый. Тк., фарсы. *чәлик* «корыч» сүзенең *чиләк* сүзенә багланышы шикле.

**ЧИР** «болезнь, хворь» — чув., чыгт. *чир* «чир, авыру», кырг. *чэр*, кк. *шэр, шер* «озакка киткән чир, кайгы» < бор. тк. (МК) *чэр* «чир, яра», азәрб. *чәр* «чир» бор. гом. тк. *чэр* «яра, кутыр» сүзеннән булса кирәк; к. рус. *чирей* «кутыр» — төрки телләрдән.

**ЧИРӘМ** «трава; лужайка» — чув. *çӗрем*, якут. *сирэм, сирэн* «чирәм, көпшәле үлән», бурят. *шэрэм* «язгы үлән, чирәм» — бор. гом. тк. *чэрэң* «урмансыз тугай, курпы, сусыл болын» сүзеннән, *чэр* нигезеннән; к. чув. *çаран* «болын, чабынлык» (*сәрәм чирәм* белән бердәй, ди Егоров), мар. *сирэм* «чирәм», *сәран, сәрән* «болын, алан», бурят. *сарам* «сазлы алан»; чаг. ш. ук азәрб. *чәрән* «болын көтүлеге, болын үләне», тув. *ширик* «чирәм», уйг. *ширәм* «ерак кардәш; курпы, үсенте».

**ЧИРӘП** «черепок; керамика» — куман. *чирэп*, венг. cserep «чирәп, чүлмәк» — славян телләрендәге *череп* «керамик савыт» сүзеннән («баш сөяге» ~ «чүлмәк» мәгънә күчеше киң таралган).

**ЧИРЕК** «четверть; ~ ведра (*мера емкости*), аршина (*мера длины*)» — үзб. *чорак, чойрак*, госм. *чәйрәк* «чирек, дүрттән бер» — фарсы. *чäрак, чäру йäк* «дүрттән бер (*чар* «дүрт», *йак* «бер») сүзеннән.

**ЧИРБЕК** «кожаные тапочки» — фарсы. *чäрмäк, чäрмпақ*, «кун аякчу» сүзеннән борынгы алынма. Рус. *черевики, черевички* — татар теленнән булса кирәк. К. **Чәрмә**.

**ЧИРКЕН** «отвратительный» — иске әд. *чиркин* формасыннан; сүзнең тамыры гом. тк., бор. тк. *чиг, чәг ~ йәг* «нәфрәт, шайтан, җен, начарлык» (к. **Җик**). К. ш. ук кк., ккк. *ширкин*, иске тат. әд., куман. *чиркен, чиркин* «нәфрәтләнерлек», тув. *чиир-тэн* «чиркәнеч», бор. монг. *чэгүр* «нәфрәт» (димәк, *чиркин* < *чэгүркин*).

**ЧИРКӘҮ** «церковь» — рус. теленнән борынгы заманда ук кергән; к. куман. *чирку* «чиркәү». Төптә — грек сүзе.

**ЧИРҮ** «войско; нашествие» — чыгт., уйг., алт. *чәру, чәрик* «армия», кум., кб., кар. *черив*, кырг. *черүү* «гаскәр, чирү, поход», монг. *чэриг, сэр* «чирү, гаскәр», бор. уйг. *кшетрик* «гаскәр» — скр. ksatrya «гаскәр, гаскәри» сүзеннән Баскаков), чув. *çар, çарӑ* ~ мар. *с'äр* «гаскәр» — бор. болгар теленнән, венг. sereg (шерег), рус. *шеренга* — бор. кыпч. диалектларыннан (Рамстедт); к. бор. кыпч. *шэри, шэрин* «гаскәр». К. Әхмәтьянов, 1989: 153.

**ЧИСЛА** «день месяца» — рус теленнән.

**ЧИСТА** «чистый» — рус теленнән.

**ЧИТ I** «край; чужой» — уйг., чыгт., алт., кырым. *чәт* «чит, кырый, яр, чат» — *чат* (к.) сүзе белән тамырдаш булса кирәк, чаг. **Чит II**.

**ЧИТ II** *диал.* «граница; ограждение» — госм., чыгт., бор. тк. *чэт, чит* «читән, үрелгән кәрзин, текмә, чик», тат. диал. (себ. тат.) *чыт, цыт*, уйг. *чит* «читән, тигәнәк, тигәнәкле киртә», бор. уйг. *чит* «камыш яки тигәнәк, киртә» (МК) — бор. гом. тк. *чэт* «чәнечкеле үсемлек» сүзеннән булса кирәк; к. тув. *чидиг* «үткер, чәнечкеле». К. **Читән, Читлек, Чытыр**.

**ЧИТӘН** «плетень, изгородь» — гом. тк. *чәтән, читэн*, чув. *çатан* «читән, чыбыктан үрелгән абзар, койма, ишек, арба өсте, кәрзин», кб. *четен* «кәрзин, умарта» — бор. гом. тк. *чэтәң* (чәнечкеле) чыбыктан үрелгән» сүзеннән, *чэт* (к. **Чит II**) нигезеннән. К. Әхмәтьянов, 1989: 145 — 146.

**ЧИТЕК** «ичиги» — *эч итек* (эчке итек) сүзеннән; к. бор. рус. *ичетыги* «читек», төрек. *чәдик* «читек» — татарчадан булса кирәк.

**ЧИТЕН** «трудный; трудно» — гагауз., госм., чыгт. *чәтин, чэтин*, кырг. *четин, чертин* «каты, авыр, читен» — бор. *чәрт*,

*чәрт* «каты» сүзенең борынгы инструменталь килеш формасы; чаг. хакас. *сидек* «читен, авыр», төрек. *сәрт, чәрт* «каты, катгый».

**ЧИТЛЕК** «клетка» — **чит II** (к.) сүзеннән (*читлек* «читән белән уратылган урын, читлек»).

**ЧИЧӘН, ЧӘЧӘН** «сказатель; народный певец» — чыгт., алт., кырым. *чәчән* «чәчән, матур сөйләүче», тув. *чэчэн* «чибәр, чәчән», алт. *чэчэркэ-* «матур сөйләргә тырышу», якут. *сэһэн* «нәфис сүз, хикәя», башк. *сәсән* «чәчән», иске тат. әд. *чәчән* «көяз, купшы, ыспай», чув. *çеçен* «чәчән, чачаклы, җете чуар», *чечен, черчен* «матур, чибәр, нәзек, назлы», гом. тк. *чарча-* (тат. диал. *чәрчә-*) «ярсу; ару; арып көйсезләнү», к. монг. *сэчэн* «чәчән; ыру башлыгы», чув. *шершен, шешен* «шөпшә, сагызак, кигәвен», тат. *чәрчән, сәрсән*, башк. *сәрсәңке* «кызу канлы, кочле реакцияле», тат. *чәчә-, чәрчә-* «ярсып китү», *чичәру* (Ф.Бурнаш) «телгә остару». К. Әхмәтьянов, 1981: 111.

**ЧИШМӘ** «ключ, родник» — диал. *чәшмә* «чишмә» — фарсы. *чашма* «чишмә, күзләвек» — фарсы. *чашм* «күз» сүзеннән.

**ЧИШ-Ү** «развязать; расстегнуть» — алт., чыгт., уйг. (диал.) *чәш-, чәч-*, бор. уйг., куман. *сәш-*, уйг., үзб. *йеч-, йеш-* «чишү, сүтү».

**ЧИЯ** «вишня» — чув., кырг. *чийе*, кк., ккк. *шийе*, кум. *җийе*, калм. *чи*, монг. *чий* «чия», башк. *сейә* «чия» — ачык түгел; чаг. бор. монг. *чэкэ, чэгэ* «кытай алмасы».

**ЧОКЫР** «яма, ров, рытвина» — госм., кырым., үзб. һ.б. *чукур* «чокыр, тирән», уйг. (диал.), кырг. *чуңкур* «чокыр, чоңгыл» — *чукы-у* (к.) һәм *чуң-у* (к. **Чум-у**) сүзләре нигезендә ясалган гибрид сүз булса кирәк. К. ш. ук тат. диал. *чокыр* «тирән тустаган, чынаяк өсте».

**ЧОЛАН** «чулан, сени» — тат. диал., башк. *сŏлан*, кк. *шылан* «чолан, камыш кура», алт. *чулан* «кура». Рус. *чулан* «чолан, болдыр» — татар теленнән. Чаг. монг. *чуглан, чигулган* «җыен, җыелыш; гаскәр җыелу урыны», бор. тк. *чоғлан-* «гаскәр җыелу», чоғла- «җыю». Сүзнең тамыры бор. тк., монг. *чоғ* «күп» (к. тат. **Чук-чук сәлам**). К. Әхмәтьянов, 1989: 24.

**ЧОЛЫК** «борть» — себ. тат. *цулун, чулун* «умарта», башк. *сŏлык*, чув. *çал // çăл, çăлă* «чолык, агач куышы, ырмау», алт. *чол ару* «умарта корты», төрек. *чолуқ* «нәсел, токым, үрчем», тат. диал. *чулык* «онык баласы» — тамыры бор. тк. *чоғ* «гаилә; күп» сүзе булса кирәк (*чолык* < **чоғулук*; к. тк. *чогул-* «үрчү»).

**ЧОҢГЫЛ** «омут; водоворот» — диал. *чоңгыр*, гом. тк. *чонкур, чуңкур* «чокыр, тирән», якут. *чоңолок, чоңнучах, чоңоро* «чоңгыл, тирән» — бор. гом. тк. *чуң-, чоң-* «чуму, тирәнгә төшү» фигыленнән булса кирәк; к. алт. *чоң* «чуму; тирән»; *чум-у* < гом. тк. *чом-* «тирәнгә төшү».

**ЧОР** «период, эпоха» — гом. тк. *учур*, монг. *учир*, бурят. *ушар* «очрак, булган хәл; вакыт, чор» сүзеннән (шуннан ук *очра-у*); к. ш. ук тув. *уҗур* «эш, хәл, очрак, момент, норма», удм. *учыр* «момент» иске татарчадан.



**ЧОРМА** «чердак» — диал. *очырма*, башк. *осорма, осортма* «кыекта күгәрчен очыру өчен тәрәзә» сүзеннән булса кирәк; чаг. үзб. *учирма* «очарга өйрәнүче яшь лачын». Бу сүз лачынчылыктан калган.

**ЧОРМА-У, ЧОРНА-У** «опутать; оплести» — азәрб., алт. *чырма-* id. бор. *чыр-, чур-* «урау, чолгау» фигыленнән. К. **Чырымта**.

**ЧОС** «бойкий; меткий» — башк. *сос*, н., кум. *шош* id. күп телләрдә очрый торган сүз; к. маньчж. *чос*, фарсы. *чуст* «чос, елгыр». Ихтимал, тәкълиди сүздер.

**ЧӨГӘ** «стерлядь» — чув. *сугэ*, ткм. *чӧгэ*, чыгт. *чукә*, госм. *чука* «чөгә» — ачык түгел; чаг. себ. тат. *сурех, сурәгә* «чөгә, очлы нәрсә, балык аулау сөңгесе». Чаг. **Сүрә I**.

**ЧӨГЕНДЕР** «свекла» — иске тат. әд., чыгт. *чугандар* «чөгендер» — фарсы. *чогандар* «чөгендер» сүзеннән.

**ЧӨЕЛДЕРЕК** «супонь» — диал. *сагалдырык* «чөелдерек», монг. *сэгэлдэрег, сагалдараг* «чөелдерек» — *сакал* (к.) яки *сәкәл* (к.) сүзенә кидерелә, тагыла торган әйбер исемнәрен ясагыч *-дерек* (*-дырык, -дарак*) кушымчасы ялганып ясалган (ягъни *чөйелдерек* < **сәүелдерек* < *сәгәлдэрэк* «ияк турысына тагыла торган нәрсә»).

**ЧӨЕР-Ү** «отвратить» (*йөз чөер-ү* «отвратить лицо») — азәрб., чыгт., уйг. *чәүир-, чәwир-, чәгир-* «әйләндерү, бору» ~ тат. диал. *чәвер-* >> чув. *çавăр-*, мар. *савыр-* id.

**ЧӨЙ** «клин; шпонка» — кум. *чүй*, госм. *чиwи*, кк. *шүй, шеге*, кырг. *чеге*, үзб. *чегә*, тат. диал. *чикә* «чөй, арба чәкүшкәсе (чека)» — ихтимал, бор. тк. *чикэ* «колак» сүзеннәндер (к. **Чигә**); к. ш. ук рус. *чека*, удм. *чӧг* «чөй, арба чәкүшкәсе, сүрә» — төрки телләрдән.

**ЧӨЙ-Ү** «метать, кидать» — татар-башкорт сүзе.

**ЧӨК, ЧҮК** «жертвоприношение огню (*языческая молитва*)» — чув. *чук, чӗк, чăк*, мар. *цӧк, чок, чук*, удм. *чек, чеке, чок, чук* «чөк, үлгәннәр рухына корбан», алт. *чок*, шор. *шок* «изге утка, потларга су бөркү йоласы». Чүк йолаларын борынгы төрки христианлыктан калган дип, *чукын-у* сүзе дә шуннан килә дигән караш та бар. К. **Очык**.

**ЧӨМӘК** «трубочка; кран» — ~ башк. *сөмәк, һемәк* «чөмәк», госм. *сүбәк*, кк. *шүбӧк, шүмӧк* «сидек яткан урынны чылатмасын өчен, нарасый баланың бот арасына беркетелә торган трубка», кум. *чюмек* «чөмәк», якут. *сумә* «трубка, жилек, кайбер агачларның йомшак үзәге», бурят. *сэмэгэн* «эчекуыш сөяк, күбәк, жилек» — бор. гом.тк. *суңәк* «сөяк» сүзеннән (элегрәк) һәртөрле чөмәкләр, кыска трубкалар эче куыш сөяктән ясалган).

**ЧӨНКИ** союз «потому что, так как» — бор. әд. *чөн ки* фарсы. *чун ки* сүзеннән (ике сүздән тора: фарсы. *чун* «шулай, шул очракта», иске фарсы. *чун* < *чи гуна* «шул төрле» һәм *ки*).

**ЧУАК** «погожий, ясный» — башк. *сыуаҡ*, ккк. *шууаҡ* «кояш җылысы төшә торган җир», бор. монг. *чуғақ* «эссе, кызу» — гом. тк., бор. тк. (МК), монг. *чог* «кояш эссесе, ут ялкыны» сүзеннән (*чуг-ак, чог-ак*); к. ш. ук уйг., алт., кырг. *чок* «эссе, куз, ут», чыгт. *чуг*, якут. *чок*, бурят. *сок, цок*, монг. *цог* «ут кызуы, күмер кызуы, утлы күмер». Шуннан ук *чуал* «борынгы мич төре».

**ЧУАЛ-У** «спутаться; запутаться» — диал. *чыбал-у, чобал-у*, бор. тк. (МК) *чоғул-* «бәйләнү, чуалу» — бор. тк. *чуба-, чуwа-* «сүтү» фигыленең төшем юнәлеше формасы булса кирәк; к. уйг. диал. *чуба-* «йомгак сүтү, киләп чуалту»; бу сүз исә бор. язм. *чуб* «бүлек, бүленеш, бүлгәләнү» сүзеннән булуы ихтимал (*чуб-а-*).

**ЧУАН** «чирей» — диал. *чыбан* (пенза), *чипан* (урал) «чуан, кутыр», угыз. *чибан, чыбан*, уйг., үзб., кырг. *чыпкан*, башк. *сикан*, кк., ккк. *шайкан*, алт. *чыйыкан*, бор. монг. *чыган* «чуан, шеш» — бор. гом. тк. *чыпыган, чыпыкан* «чуан» сүзеннән, ниндидер *чыпы* тамырыннан. Шул ук бор. *чыпыкан* нигезенә тат. диал. *шыйган* > рус. диал. *шихан* «тигезлектәге ялгыз тау» сүзе дә тоташа.

**ЧУАР** «пестрый» — диал. *чыбар, чобар*, алт. *чокур*, тув. *шокар*, хакас. *сохыр, чокыр*, госм. *чопур*, үзб. *чавкар*, якут. *чуогур*, бурят. *соохор*, бор. монг. *чоокур, чупакур* «чуар, таплы» — ниндидер *чупа- тамырыннан. Рус. *чубарый* «чуар (ат)» — татар теленнән булса кирәк.

**ЧУЕН** «чугун» — диал. (урал) *чөген, чөгөн* «чуен, чуен чүлмәк» — бор. тк. *чуғ, чу* «чуен» сүзеннән (*чуғ-ун*); кытай. *чой гун* «чуен савыт»; алт. *чой*, тув. *шой* «чуен, казан», рус. *чугун*, фарсы. *чудан* «чуен, казан» — төрки телләрдән.

**ЧУЕР** «галька; булыжник» — ачык түгел; к. алт., тув. *сай* «сай урын, чуер», тув. *сайыр* «чуер таш белән капланган коры елга үзәне, чуер», кк. *сайыр*, монг. *сайр, сайыр* «коры үзән, чуерташлы үзән, чуерташ» (к. **Сай**), ләкин бу сүзнең *чуйырга* әверелүе фонетик яктан аңлашылмый.

**ЧУК I** «кисть, бахрома» — киң таралган сүз: кырг., чыгт. *чок* «чук, төймә», коми., удм. *туг* «чук». Чаг. **Чукмар**.

**ЧУК II** «много, множество» — азәрб.,, госм. *чок, чох*, чыгт. *чук* «күп», монг. *чуг*, бурят. *суг* «бергә, җыелып торган» — бор. гом. тк., монг. *цог* «җыелган» сүзеннән; к. монг. *чуог-уй* «бергә җыелу», алт., кырг. *чогул-*, монг. *чугла-* «бергә җыелу». К. **Чолан, Чолык**.

**ЧУКМАР** «булава; кистень» — *чук* (к.) һәм *тукма-у* (к.) сүзләре нигезендә оешкан гибрид сүз булса кирәк; к. госм. *чокман, чокмак* «чукмар», госм., себ. тат., алт., кб., кум., мар. *чокмар* «чукмар (булава), күсәк», госм., уйг. (диал.), бор. тк. *чомақ, чоқмақ* «чукмар, башына шар утыртылган таяк», кк. *шокмар* «чукмар», тув. *токпар*, рус. диал. *чекмарь, токмар*, морд.-мокша. *цетмар* «чукмар» (төрки телләрдән). К. **Чумар**.

**ЧУКРАК** «глухой, глухонемой» — башк. *сукрак*, чув. *сухра* (*анра-сухра*), мар. *чоқрақ* «чукрак» < гом. кыпч. *чоқурақ* «пычрак, тигезсез, агышсыз күл» сүзеннән; к. тат. диал. *чуқрақ* «сазлык, пычрак», кум. *чоқрақ*, н. *шоқырақ* «тигезсез җир, сазламык, инеш, елга», кб. *шокурак* «тозлак җир, уңдырышсыз туфрак» (төрки телләрдән), кк., ккк. *шокырак* «тигезсез йөрешле ат». Сүзнең тамыры — *бор. čogra-* «ургылмак» булса кирәк.

«Агышсыз күл > чукрак» мәгънә күчеше метафорик характерда: чукракның башына берни керми (ул ишетми) һәм аннан берни дә чыкмый (ул сөйләми). Чаг. кб. *чоқурақ* «кабырчак».

**ЧУКЫН-У** «креститься» — удм. *чукин-*, мар., гом. тк. *чокын, чокун-* еш кына *чукы-у* фигыленең кайтым формасыннан дип карала, әмма чув. *сăхсăх-* «чукыну» һәм кайбер фактлар бу сүзне бор. тк. *чоғ* «утка табыну йоласы» сүзе белән бәйлыйлар. К. **Чөк**.

**ЧУКЫР** «клест» — *чукы-у* фигыленнән: башта кошны «чукыр борын, келәшчә борын» дип атаганнар, соңыннан *чукыр* калган. К. кк. *шокыр* «өтерге, келәшчә».

**ЧУКЫ-У** «клевать, выклевывать» — башк. *суқа-*, үзб. *чуқи-*, алт., госм. *чоку-* «чуку», тат. диал. *чокы-* «казу», кырг. *чок-*, хакас. *чох-*, чув. *сых-* «чуку, билгеләү», хакас. *сохла-*, тув. *сокта-* «чуку, казыну».

**ЧУЛАК** «криворукий, сухорукий» — тат. диал. *чулан*, гом. тк. *чолақ, чулақ* «гарип, чулак» — ниндидер *чол* тамырыннан (*чолак*), к. кырг. *чолтой-* «чулаксыман булу», *чолтоң* «чулак кул», эвенк. *чулугды*, эвен. *чолэкэ* «бер аяклы, бер куллы», чаг. фарсы. *чолә* «кәкрәйгән».

**ЧУЛЛЫК** «бекас» — < төрек. *чоллук* id. *чōл* «чапрак» сүзеннән.

**ЧУЛПАН** «утренняя звезда; Венера (*планета*)» — гом. тк. *чолпан, чолбон* «чулпан, якты йолдыз», монг. *чолбон* «йолдыз», бурят. *солбаң* «чулпан», якут. *чолбон* «чулпан; җете күзле, зәңгәр күзле»; чаг. эвен. *чулбан* «чулпан», *чулба, чулба-ня* «зәңгәр», *чулга-, чула-* «зәңгәрләнеп тору». Шулай итеп, *чулпан* башта «зәңгәр йолдыз» дигәнне белдергән. Икенче яктан, нигездә, бу мифологик образ — кытай. *чжу-луң-вань* «күк аждаһасы (шуның күзе)» сүзеннән килергә мөмкин. К. Әхмәтьянов, 1981: 58 — 59.

**ЧУЛПЫ** «накосник» — башк. *сулпы* «чулпы», кк., ккк., н. *шолпы*, кырг., кум., ткм. *чолпы, чолпу* «дуршлаг, сөзгеч чулпы», уйг. *чолу*, монг. *чолубу* «чулпы, талчыбыктан бөгеп орнаментлап эшләнгән сөзгеч» сүзеннән. Сүзнең чыгышы ачык түгел: С.Е.Малов фикеренчә, уйг. *чолу* «чулпы» кытайчадан (Язык желтых уйгуров. — М., 1957); К.К.Юдахин буенча, кырг. диал. *чоолу* «чулпы» — фарсы теленнән (фарсыча *чäлу, чäлипä, чäлипäвäр* «аркылы-торкылы хач, сигез нурлы йолдыз). К. ш. ук монг. *цолув, чолуба* «җидегән» (ул вакытта *чулпы — чулпан* икесе бер тамырдан). *Чулпы* сүзенең «чыбык сөзгеч» мәгънәсеннән «тәңкәле бизәк» мәгънәсенә күчүе шуның белән аңлатыла: «такталы чулпы» дигән бизәк нәкъ чыбыктан үрелгән сөзгеч шикелле орнаментлы була. Чаг. башк. *сулпы* «дүңгәләк, аел, каптырма» (ягъни шул бизәк формасындагы аел).

**ЧУМАН** «короб» — к. чув. *чуман*, мар. *чоман*, коми., удм. *чумон*, рус. *чуман* — төрки телләрдән. Сүзнең нигезе — бор. тк. *чомаң*, эвенк. *чомоко, чомо* «тире капчык, тире янчык», к. тат. диал., бор. тк. *чумак* «дегет капчыгы, дегет күнәге, зур тире капчык», кк. *шумак*, башк. *сумак* «тумпак, учлам, туп», башк. *суман* «чуман, кәрзин», венг. scomak «күн капчык» ~ рус., украин. *чумак* «олау капчыгы, олаучы» — төрки телләрдән. К. кырг. *чом* «дөягә салына торган ябу, капчык».

**ЧУМАР** «клецки» — мар. *чомар*, удм. *чумар* id., диал. *чумара* «чумар, чукмарсыман нәрсә», госм. *чомар* «чукмар» — бор. тк. *чокмар* (к. **Чукмар**) сүзеннән. *Чумар* сүзе фин-угор телләреннән дигән фикер дә бар; к. морд. *цёмара* «чумар», коми. *чомӧр* «уңыш бәйрәмендә пешерелә торган ашамлык».

**ЧУМ-У** «нырнуть, погрузиться» — гом. тк. *чом-, чӧм-* «чуму, бату, йөзү, су керү» — бор. тк. *чоң-* «суга чуму, төпкә китү» сүзеннән; к. алт. *чоң, чӧң* «тирән чуму, чумдыру», алт., кк. *суң-* «чуму». *Чум-у* сүзеннән *чумыр-у, чумгыл* сүзләре ясалган; к. **Чоңгыл**.

**ЧУПАЙ** «ребенок, который сосет пальцы; филин» — башк. *супай, супайлы* «чупай; какул, балалар башлыгының түбәсенә беркетелгән тубыр, тупалак; чаг. монг. *сибүгэ, шубүгэ* «чупай (бүрекле ябалак)» ~ рус. диал. *чуб* id., ш. ук «тырпаеп торган чәч».

**ЧУПТАР** «вышивка на ткани» — тат. диал. *чупләм* — фарсы. *җуфттар* «пар җеп» сүзеннән. Тат. диал. *чупллә-* < *җуфтлә-* «парлау, пар итү». К. **Җеп, Җефет**.

**ЧУРА** «работник; дружинник» — гом. тк. *чора*, ткм., үзб. *җора, җўра* төптә скр. *čога* «яугир, хәрби» сүзеннән; мар., морд. *цёра* «угыл, егет» мишәр диалектыннан. К. Әхмәтьянов, 1989: 170.

**ЧУРТАН** «щука» — гом. тк. *чортан*, якут. *сордоң* «чуртан» — бор. тк. **чур(а)* тамырыннан; к. тат. диал. *чурәгәй, чурагай*, башк. *сурагай*, монг., бурят. *сурхай, цурхай*, кк. *шорагатай* «кечерәк чуртан». Чаг. ш. ук тат. диал. *сурәкәй*, чув. *шӳреккей* «чөгә; очлы башлы нәрсә» (к. **Сүрә I, Шүре**).

**ЧУТ I** «топор для обтесывания (*стен сруба*)» — бор. тат. *чут*, уйг. *чот*, кк. *шот* «китмәнсыман балта, бәлҗә» сүзеннән. Шуннан *чут-ла-у* «бүрәнәне чут белән тигезләү».

**ЧУТ II** «счеты» — удм. *чот*, мар., чув. *шот* — рус теленнән. Идел-Урал телләрендә бу сүз күп дериватлар биргән: тат. *чут-ла-у, чутсыз, чутында*.

**ЧУТЫР** «корявый» — диал. *чутра, шутыр, шытыр* (себ. тат.) «шадра, кара таплы», алт. *чодра, чодур* «кара таплы, каратутлы, шадра, сипкелле» — скр., бор. ирани. čitra «билге, тамга, күренеп торган, ачык якты (*кеше йөзе турында*), чуар; йөз, бит, картина» сүзеннән. К. **Чырай**.

**ЧУЧКА** «свинья» — уйг. *чочка*, хакас. *сосха*, башк. *сусҡа*, чув. *сысна*, мар. *сосна* «чучка, дуңгыз», чыгт. *чочуқ, чочуңа* «дуңгыз баласы; бала» — ткм., тк. *çосик* «бала». Тамыры — *чоч-* «чупылдатып иму». К. Әхмәтьянов, 1989: 74.

**ЧҮ** межд. «чу!, тише» — күп телләргә билгеле булган ымлык, алт. *чо*, коми. *чов* ~ һинд. *чу* «чү!».

**ЧҮӘК** «чувяки» — диал. *чүбәк* «чүбек, чүәк» — ихтимал, «чүбектән эрләп эшләнгән» дигән сүздер. К. **Чүбек, Чүп**.

**ЧҮБЕК** «очески, вычески» — диал. *чүбәк*, башк. *сүбәк*, чув. *чупек* «чүбек» — *чүп* (к.) сүзеннән (*чүбәк, чүбек* < *чүп-әк*); к. ш. ук венг. szöbek «чүбек» (бор. тк. телләрдән).



**ЧҮГӘТӘ** «сосуд с носиком, выемкой» — диал. *чүгәтәй, чүргәт*, башк. *сүгәтә, сеүәтә*, чув. *çурхат*, мар. *чоргат*; удм. диал. *чурок* «бүрәнкә» ~ иске тат. (Будагов) *чурға*, кырг. *чорғо* «агызгыч торба, бүрәнкә». Монг. *чорға-тай* «агызгычлы, борынлы, чургалы».

**ЧҮКЕЧ** «молоток» — удм. *чекыч*, мар. *чӧкыс* id., госм. *чӧкүч*, *чәкич*, якут. *чокоччу*, бор. чыгт. *чэкүш*, монг. *чэкүк, чэкүч* «чүкеч» — тат. *чүке-ч* «чүкү» сүзеннән (татар телендә, мәсәлән, *чүкегеч* сүзеннән кыскарып килеп чыгарга мөмкин).

**ЧҮКЕ-Ү** «ковать» — башк. *суке-* id. Бүтән телләрдә юк.

**ЧҮЛ** «пустыня» — гом. тк., монг. *чӧл* «чүл, чүлле» сүзеннән. К. калм. *цӧлӧ* id.

**ЧҮЛМӘК** «глиняный горшок» — госм., кар., чыгт. *чӧлмәк*, кк., н., ккк. *шӧлмәк*, чув. *чүлмәк, чүмләк*, азәрб., куман. *чӧмләк* «чүлмәк» — ясалышы һәм тамыры ачык түгел. Чаг. **Чүмеч**.

**ЧҮМӘЛӘ** «копна» — башк. *сүмәлә*, уйг. *чӧмүлә* ~ кырг. *чӧмӧлӧ*, чув. *çӗмел* «чүмәлә» — гом. тк. характерда булган бор. *чом // чӧм* «чүмәләсыман өелгән нәрсә» сүзеннән; к. диал. *чүмә*, *чүмәкәй* «өеп тутырылган (савыт)», якут. *чомох, чомчох* «чүмәлә, өем», бурят. *сомоо* «чүмәлә, өем», *сомо-* «өю, чүмәлә салу», монг. *цомог, чомог* «чүмәлә». К. ш. ук коми. *чумали* «сослан» ~ тат., уйг. *чумали* «кырмыска оясы; кырмыска; өем».

**ЧҮМЕЧ** «половник» — уйг. *чӧмүч*, чыгт., госм. *чӧмүш* «чүмеч», н., кк., ккк. *шӧмиш*, кум., кырг., ткм. *чӧмүч, чомуч* — бик ансат кына чыгт. *чом-* «чуму, чумдыру» сүзеннән чыгарып булыр иде, ләкин сүзнең башка бер тамыры да бар: үзб., таҗ. *чумча* «чүмеч», бор. рус. *чумь, чумькъ* (төрки телләрдән) «чүмеч» бор. тк. *чум* «чүмеч» сүзе булганлыгын күрсәтәләр. К. ш. ук урду. *чаммач, чамча* «кашык».

**ЧҮП** «мусор» — гом. тк. *чӧп* «чүп, калдык, йомычка» — бор. гом. тк. *сӧп // тӧп // чӧп* «калдык, эшкәрткәннән соң торып калган нәрсә» сүзеннән; к. бор. тк. (МК) *чӧп* «аракы түбе (*йөзем суын сыккач кала торган*)», *сӧпэк* «җимеш калдыгы (каты орлыклары, кабыгы, төше)», бурят. *суб* «калдык, чүп, түп». К. **Түп, Түбек, Чүпрә, Чүпрәк**.

**ЧҮПРӘ** «дрожжи; закваска» — диал. *чүбрә* «балык кылчыгы», *чүпер* «шама (выварки)», *түбер* «чүп, калдык», башк. *түпрә* «чүпрә, калдык», чув. *çӗпре* «чүпрә», венг. sерrő «чүпрә», кк. *шӧбрӧ* «шама, чүп (осадок)», чыгт. *шәпрәк*, бурят. *сүбрэг* «эретелгән май түбе, калдык, шама», кум. *чӧпүре* «чүп, калдык, чүпрә» — бор. гом. тк. *чүпәр-эг* «чүпкә, түпкә калган нәрсә» сүзеннән, *сӧп // тӧп // чӧп* тамырыннан (к. **Чүп**). К. **Чүпрәк**.

**ЧҮПРӘК** «тряпка» — башк. *сеперәк*, тат. диал. *чеперик*, чыгт. *чиприк, чибүрә, чибәрик*, алт. *чәбәрәк*, хакас. *сүбүрәк, сүбәрәк*, кк. *тӧбӧрӧк*, бор. тк. *чупра* «чүпрәк, иске кием, кием калдыгы» — бор. гом. тк. *чүпәр-эг* «калдык нәрсә» (к. **Чүпрә**) сүзеннән; к. монг., бурят. *сүбрэг* «түп, калдык, май эреткәннән соң калган калдык». *Чүпрәк-чапрак* сүзенең икенче компоненты — *чапрақ* ~ госм. *чапрақ*, көнч. тк. *чапырақ*, якут. *чаппарақ* «ат ябуы» (шун-

нан ук, төрекчәдән булса кирәк, рус. *чепрак*) көнч. тк. *чап-* «ябу» сүзеннән, ләкин *чүпрәк* сүзенең контаминацион тәэсире белән таралган.

**ЧҮРӘ** «обратная сторона (*листа, ткани*)» — к. диал. *чөрә, чөкрә,* башк. *сөйҙә ~ чөйрә,* кб., кум. *чүйре, цүйре* «кире, тискәре, чүрә» — бор. тк. *чүгрә, чүкәрә* «арткы яктагы» *чүк* «арткы як» сүзеннән; к. тат. *чөк*, гом. тк. *чүк, чөк* «ашыкның батынкы ягы». Чаг. ш. ук чув. *çавра*, кар., азәрб. *чүврә* «тирә-як», чув. *çавăр-*, угыз. *чәвүр-* «әйләндерү» < *чөгүр-.

**ЧҮРӘК** «чебуреки, чурек; круглый хлебец» — азәрб., гагауз. *чөрәк, чөрек,* кк., ккк. *шөрек ~* азәрб. *чөбүрәк* «шишара, камыр калдыгыннан пешерелгән күмәч» сүзеннән, асылда, *чүпрәк* белән бердәй. К. **Чүпрә**.

**ЧҮРӘГӘЙ: чүрәкәй үрдәк** «нырок» — киң таралган сүз: диал. *чүрәккәй* «чүрәгәй», *чөркәнтәй, сөрхәнтәй* «ябык, арык һәм зур булмаган гәүдәле кеше», хакас. *сигэйэк*, якут. *чыркый, чырмакай, чоркой*, рус. *чирок, чир* «чүрәкәй». Ясалышы ачык түгел.

**ЧЫБЫК** «прут; лоза» — гом. тк. *чыбык, чибиқ* «чыбык-чабык, йөзем үрмәләре өчен колга, киштә, читән» — бор. тк. *чыбық, чибуқ, гып* (МК) «чыбык; озын, нечкә тал» — ниндидер *чып//чап* нигезеннән (*чып-ык*), ихтимал, көнч. тк. *чабага* «чыбык-чабык, чәбе» сүзе белән бердәйдер (к. **Чәбе**), ул вакытта сүзнең тамыры *чап-* «кискәләү, чабу»; ләкин к. уйг., кырым., бор. тк. *чубуқ* «чыбык, эче куыш таяк, озын трубка» > рус. *чубук* id.; к. ш. ук себ. тат. *чыбал, чыбыртык* «тал чыбыгы» (чаг. **Чыбыркы**). Чаг. **Чыпта**.

**ЧЫБЫЛДЫК** «занавес; полог» — башк. *сымылдық*, кк. *шымылдық*, үзб. *чимилдиқ* «чымылдык», тат. диал. (себ. тат.) *цыбынның* «кашага чымылдык», *цыбын* «чебен», госм. *җибинлик* «чебеннәрдән саклану өчен вуаль», *җибин* «чебен», чув. *шăнăлăк* (*шăнă* «чебен») — мисаллардан күренгәнчә, *чыбылдык* сүзе бор. *чыбынлык, чебенлек* сүзеннән, ягъни «чебен» нигезеннән кебек, ләкин бу соңрак халык этимологиясе нигезендә туган параллельлек булуы да ихтимал; к. кырым. *чымылдырық* «чыбылдык», үзб., таҗ. *җамолиқ* «чыбылдык» (*җамо* «озын күлмәк, баштан каплана торган плащ»).

**ЧЫБЫРКЫ** «плеть, кнут» — диал. *чыбыркы, сыбыртқы,* башк., алт., куман. *сыбыртқы* «чыбыркы, себерке», хакас. *сымыртқы* «себерке, чыбыркы» — диал., көнч. тк. *чыбыр- // сыбыр- // шыбыр-* «себерү, сыптыру» сүзеннән. К. **Себер-ү, Сыпыр-у**.

**ЧЫГТАЙ** «чагатай» (*чыгтай теле* «чагатайский язык — язык с фонетическими и отчасти морфологическими нормами староуйгурского и староузбекского языков» (Чыңгыз-ханның улы Чагатай исеменнән: Урта Азия тирәләре шуңа бирелгән булган. *Чагатай, Чәгәтай* исеме үзе монгол телендә кыргый ишәкнең бер төрен белдергән сүздән).

**ЧЫГ-У (чык-)** «выходить, выступать» — гом. тк. *чык-* id. күпчелек телчеләр фикеренчә, бор. тк. *тышык-, ташык-* «тышка таба юнәлү» фигыленнән үзгәреп килеп чыккан; бу фигыль исә



бор. *тыш-, таш-* «өйдән, киртәдән, ярдан ашып чыгу, ташу» сүзенең интенсивлык формасыннан. Бор. *тыш ~ таш < тал* сүзе тышны, ташлыкны һәм әлеге фигыльне дә белдергән синкретик тамыр булган: аның *tal' вариантыннан чув. *чул < чол < *ṭ'al* «таш», *тул < тол < *тал* «тыш» һәм *тух- < тох- <* *taq-, *talq- (~ монг. *талхи-*) «чыгу» сүзләре килә. *Таш* вариантыннан тагы *ташы-* «йөк күчерү» сүзе дә ясалган.

Тат. *тышка чыгу* идиомасы башта *ташка чыгу* яңгырашында булган. Бу тәгъбирдә бор. *таш* тамыры ике тапкыр кабатлана.

Соңрак барлыкка килгән *чык-* һәм *чыкар- > чығар-* нигезләре төрки телләрдә бик күп яңа сүзләр ясалуга китергәннәр. К. **Чыгым**.

**ЧЫГЫМ** «расход» — чув. *çăхăн*, удм., мар. *чыгын-*, гом. тк. *чыгын* id. Идел-Чулман телләренә татар теленнән таралган.

**ЧЫГЫР** «ролик; колесо (*колодца*)» — чув. *чăкăр*, мар. *чыгыр*, удм. *чыңгыр* id., гом. тк. *чығыр, чығырық* — һәртөрле гади машиналарны белдергән сүз — сугди. *čуγу* «тәгәрмәч, тәгәрчек, көпчәк» сүзеннән. К. **Чар, Чарык**.

**ЧЫГЫТ** «поджаренный творог» — чув. *чăкăт*, кар. *чыгыт* id., күп төрки телләрдә юк яисә сирәк очрый. Чаг. диал. *чығыл* «эремчек».

**ЧЫДА, ЧИДА** *уст.* «копье, пика» — уйг., чыгт. *чида*, хакас. *чыда*, госм., калм. *җида*, кум. *җыда, җыйда,* н., себ. тат. *йыда, йыта,* бор. монг. *ӡida-* бик борыңгы корал атамасы; к. кабарда. *җатэ* «кылыч, чида», *җыдэ* «балта», госм. *җида* «дротик», *йатаған* «кәкре кылыч».

**ЧЫДА-У** «терпеть» — гом. тк. *чыда-, чида- ~* монг. *чида-* «чыдау, дөрес эшләү» сүзеннән санала, ләкин бу сүзнең төрки телләрдәге кайбер формалары һәм мәгънәләре башка фикерләргә дә юл ача; к. кар. *чыда* «йогынтылы булу, түзеп тору, ирешү», чув. *чăт-* «чыда-».

**ЧЫЕЛДА-У** «взвизгивать, пищать» — тәкълиди *чый, чи* «бәләкәй кошлар, балалар чыгара торган авазларга ияртем, тәкълит» сүзеннән, күрәсең, *чый-чый килү* белән беррәттән *чыел-чыел килү* сүзе дә бар. Чаг. ш. ук *чыйкылда-у, чыйна-у, чыек-чыек килү*.

*Чый* белән бергә шул ук мәгънәдә *чыр* имитативы да киң таралган, шуннан *чырылда-у, чыркылда-у, чырык-чырык итү, чырчу* сүзләр ясалган.

**ЧЫЕРА-У** «затягиваться (*льдом*); крепнуть» *чирак* «нык бөтерелгән, нык тартылган (*җеп турында*), жегәрле, көчле, ябык һәм көчле», *тирақ* «унган, түземле, жегәрле», алт. *чыйырақ*, хакас. *сырах*, бурят. *ширағ*, монг. *чийрэг*, бор. тк. *тығрақ* «көчле, чыдамлы, нык катылган». Бор. *чың // тың* «ныклы, киеренке» тамырыннан.

**ЧЫҖЫМ** «тяжи в телеге; канат невода; телефонно-телеграфные линии» — башк. *шыҗсым*, кк. диал. *чыҗым* «тимерчыбык» ~ монг. *шижим*, төрек. *сыҗым* id. К. **Тоҗын**.

**ЧЫЙ-У** «насекать (*узоры*); писать острым предметом» —

башк. *сый-*, алт., кырг. *чый-* id. Шуннан тат. *чымай, чимай, җимай* «лекало, бизәк шаблоны». Себ. тат. *цый, чый* «чыеп язылган билге; чаг. кытай. *цзый* «хәреф».

**ЧЫК** «роса» — алт. *чык*, хакас. *сых*, якут. *сик* «юеш, юешлек», тув. *шык* «юешлек, болын», бор. тк. *чиң, сиң* «чык, юешлек» (МК), бурят. *чик* «чык» — бор. гом. тк. *чыңығ* «юешлек» (*чың* «юеш», шуннан *чың-лан-* > *чылан-у*). Чаг. **Чи**.

**ЧЫЛБЫР** «цепь; цепочка с бляхами для украшения (диал.)» — ~ алт. *чылбыр*, кк., ккк. *шылбыр*, уйг. диал., көнч. тк. *чулбур* «чылбыр, бизәкле тезген, чулпы» — фарсы. *чилбур* «кырык кисәк, кырык күзәнәк» (*чил* «кырык», *бур* «кисәкчә, өлеш») сүзеннән; к. ш. ук монг. *цилбуур* «чылбыр, тезген». Чаг. **Чәлпәрәмә, Челлә, Челтәр**.

Татар әдәби телендә яңгырашы һәм мәгънәсе буенча чылбырга охшашлы тагын ике сүз бар: *зынҗыр* (>чув. *сынчыр*, мар. *шинчыр*, мордва-мукши. *цинзер*) «богау чылбыры» шулай ук фарсы теленнән, ләкин *чылбыр* сүзенә тамырдаш түгел. Икенче сүз — *чәмбәр* (диал. *цәмбәр*) «мичкә коршавы; тимер коршау» — татар теленнән күп күрше телләргә таралган, татар теленә исә төрек теленнән кергән булса кирәк. Бу сүзнең дә *чылбырга* дәхеле юк.

**ЧЫЛГЫЙ** «маховые перья птиц» — диал. *чылғый* «чылгый, мыек очы», башк. *салгый* «итәк очы», бор. тк. *чалғай* «кош канаты очы» (МК) — бор. тк. *чалга-г* «канат җилпәзәсе» сүзеннән; *чалга-, чалгы-* «җилпенү» фигыленнән; гом. тк. *чал-* (к. *Чал-у*) фигыль нигезеннән (*чалға-*); к. кк. *шалгы* «канат кагуы», тув. *чалғын* «канат», *чалғығ* «дулкын».

**ЧЫН** «настоящий; правда» — гом. тк. *чын* «чын, чынлык, чама», госм. *чың* «чын, ныклы», гом. тк. (тат. диал.) *тың* «ныклы, көчле, бик тә, чын», тув. *дың, ның* «көчәнешле, тыгылган», бор. монг. *чиң* «каты, чын, дөрес» — барысы бер **таң, *тың* тамырыннан булса кирәк. Шул ук тамырдан (яки шуның тәэсирендә) к. *дыңгыч, нык, тык-у, тыгыз, тыкрык, чынык-у* сүзләре ясалган. Чаг. ш. ук **Чыда-у, Туң, Тың, Чыныкый**.

**ЧЫНАЯК** «фарфор» — бор. тат. *чини айак* «кытай савыты» сүзеннән (к. чыгт., бор. тк. *Чин* «кытай», *чини* «кытайдан килгән», *айак* «савыт»); к. диал. (себ. тат.) *чене табак* «фарфор тәлинкә», кырг., алт. *чыңа, чыны* «чынаяк».

**ЧЫНЫКЫЙ** «настоящий; в самом деле; ей-богу» — к. кырг. *чыныгы* «чын», якут. *чыңха, чаңка* «нәкъ, туп-туры, дөрес», бурят. *шанга* «көчле дыңгычланган», монг. *чыңга, чаңга* «дыңгычланган, көчле көчәнешле».

**ЧЫПТА** «рогожа» — уйг., үзб. *чипта*, кум. *чыпта*, н., ккк. *шыпта*, чув. *ҫăпта*, чыгт. *чифтә* «чыпта; мунчала; кап» — фарсы теленнән булса кирәк.

**ЧЫПЧЫК** «воробей» — кечкенә кошлар авазына охшатудан килеп чыккан *чип, чып* «кечкенә кош, чеби, чыпчык» сүзеннән (*чып-чык*), бор. тк. *чыпчук, чупчук,* чыгт. *чимчик* «чыпчык»; к. ш. ук кар. *чипчә* «чеби», якут. *чичаг, чычаг,* монг. *чечигэ*, маньчж. *чэчикэ* «кечкенә кош», эвен. *чибалан-дай, чибарта-дай* «чырылдау»; чаг. бор. ирани syč «чыпчык», сугди čwz'kk «чеби, чыпчык», ягноб. (таҗ. диал.) *чирда* «чыпчык».

**ЧЫР** «навар; жир на лице» — *чыр* id. Чаг. бор. тк. *чыргуй* «ярлы».

**ЧЫРА** «лучина» — *чырак* (к.) сүзеннән үзгәреп килеп чыккан.

**ЧЫРАК** «светильник; факел; костер, зажигаемый на специальной подставке на носу лодки во время ночного лова рыбы острогой» — фарсы. *чирағ, чарағ* «факел, яктырткыч чыра» сүзеннән. Күп телләргә таралган.

**ЧЫРАЙ** «лицо» — иск. әд. *чәһра* «йөз, чырай» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан (*чәһра* > *чәйра* > *чырай*), асылда, фарсы. *чәһра* «йөз, чырай», бор. ирани. čithra «якты, якты йөз» дигәннән.

**ЧЫРШЫ** «ель» — башк., н. *шыршы*, чув., мар. *чăрăш*, ккк. *шыршы*, кк. *шырыш* «чыршы», кк. *шырыш*, тат. диал., кум. *чырыш* «сумала, җилем» (*чырыш агачы* «җилем агачы, сумалалы агач») сүзеннән. Соңгысы исә фарсы теленнән санала. (А. Курышҗанов).

**ЧЫТЫК** «хмурый» — диал. *сытык* «чытык» — *сыт-у* (к.) фигыленнән һәм гом. тк. *чыт-у* «йөзне бозу» сүзеннән; к. диал. *йөз сыту* «кәефсезләнү чырае чыгару», *сытыл-у, чытыл-у* «елап җибәрү (*балалар турында*)». Шунысы кызык, уйгур, монгол телләрендә *чытуқ* «усал кыяфәтле химаяче рух; шайтан», *чәти, чиди* «иблис» (Тибет теленнән).

**ЧЫТЫР** «хворост» — вак-төяк ботаклар, чыбык-чабыклар сынгалау авазын белдерә торган *чытыр* (*чырт-ыр*) сүзеннән (*чырт-* бер генә чыбыкның сыну авазын белдерә); к. ш. ук тат. диал. *чытырман* «чытырлык, кызу холыклы, чытырдап ябышучан», хакас. *сыдырбан*, кырг. *чытырбан* «чытырлык» (чаг. **Урман**). К. **Четерек**.

## -Ш-

**ШАБАЛА** «отвал плуга» — гом. диал. *шабала* «калак, карлау, кашык», чув. *шабала, сапала*, алт. *чабала, самнак,* хакас. диал. *самалак, санмак,* тув. *шопулак, шамлак,* госм. *сапылак* «калак, кашык, озын саплы чүмеч» — үзб., бор. тк. *сапал* (үзб. *сопол*) «чүмеч» сүзеннән (*сапал-ак*), сүзнең нигезе бор. тк. *сап-, сапы-* «чүмеч яки көрәк белән ыргытып эшләү» булса кирәк.

**ШАБЫР** «холщовый плащ» — мар. *шавыр, шабыр,* удм. *шабур, шобыр,* чув. *шопăр, шупăр,* рус. диал. *шабур, шибур, шабура, шубур* ~ иске тат. («Җәмигыль-хикәят») *чабыр* «плащ, җилән» *чапрак* белән нигездәш булса кирәк. Кавказ телләрендә (кб.) *чабыр* «каеш чабата».

**ШАДРА** «рябой» — башк. *шаҙра*, чув. *шатра*, мар., удм. *шадра, шедра* «рябой», тат. диал., н. *шадра* «вафлясыман тукыма; чадра тукымасы» << азәрб., фарсы. *чадира, чатира* «вуаль, чадра; чатыр өчен тукыма» бор. һинд. čatra «зонт» сүзенә кайтып кала; к. **Чатыр**. К. Әхмәтьянов, 1989: 144.

**ШАЙТАН** «черт, сатана» — гар. *шайтан-ун* «шайтан» сүзеннән (*сатана* белән бер нигездән). Төптә семит телләрендә «суд полициясе» дигән сүз булган.

*Шайтан ашыгы* «щиколотка» — «ашык уены»на шайтан уйлап чыгарган уен дип караудан.

**ШАЙ: моңың шае** «вот столько» — диал. *шай, шәй* «кыяфәт, җиһаз; өслек» — бор. тат., себ. тат. *шай, шайман* «хәрби кием (панцирь)» сүзеннән.

**ШАККАТУ** «удивляться» — бор. *шах кату* «шаккату, таш булып кату» — фарсы. *шах шудан* «гажәпләнеп кату» сүзеннән калька (*шах, шәх* «кыя, тау, таш; каты, катып калган», *шудан* «булу, тору»); чаг. тат. диал. *шақ* «тормоз ташы, кран».

**ШАКАЛ** «шакал» — бор. тк. *чакал* «шакал» — фарсы. *чакал, шағал, шағар,* скр. *čakhar* «шакал» сүзеннән таралган (рус. *шакал* — төрки телләрдән; инглиз. jackal һинд телләреннән).

**ШАКМАК** «квадрат; куб; куски дерева для самовара» — бор. *чакмак* «ярып ясалган нәрсә» сүзеннән, *чак-* (к. **Чак-у**) «яру, яргалау» фигыленнән; к. үзб. *чақмақ* «шакмак», *чақ-* «яру, ваклау», тат. диал. (себ. тат.) *цак-* «яру, яргалау», рус. диал. *сакъ* «шляк, обрубок дерева, чурбанчик для городков» (Даль) — төрки телләрдән.

**ШАКШЫ** «грязный, зловонный» — түбәндә тире иләгәндә тирене йомшарту өчен кулланылган сеңәл — состав: аңа куйларның койрыгына ябышып каткан тизәге — *шақ, шақмара* салынган. Элекке тире эшкәртү ысулы бик сасы измәләр, сеңәлләр илә башкарылган (һ. Салиховның шуңа баглы бик гүзәл тәмсиле бар).

Шакшы *шак суы* яки *шакча* дигәннән сүз төрки телләрдән рус һәм бүтән күрше телләргә дә таралган (рус. *шакша* «шакшы сеңәле», *шакшевание* тирене шундый сеңәлдә йомшарту процессы һ.б.).

**ШАЛ** «цветная кожа для аппликации» — к. уйг., алт., үзб. *шал*, калм. *шал*, монг. *шал, сила,* кырг. *шалы,* тат., башк. *шәлйә, шәлиә* «төсле күн, сәхтиян» — фарсы *шәл, шәли, шәләи* «шал» сүзеннән.

**ШАЛАШ** «шалаш» — диал. *салаш* «агач башына корылган куыш» (Х. Госман), госм. *салаш* «сайгау (накат), вакытлы кибет, балаган», себ. тат. *сала* «ботаклар, ботаклар өстендәге тезмә», чыгт. *салача*, госм. *салаҗак* «колаша», бурят. *шала* «сайгау» — бор. тк. *сай-ла-ш* яки *сала-ча* «тезмә, сәке, сайгау» сүзеннән булса кирәк. (к. **Сал**). Рус. *шалаш*, болгар. *салаш*, чех. solaš, salas' «шалаш, будка, лапас» — төрки телләрдән. Венгр телчесе Л. Киш бу сүзне венгр теленнән дип аңлата (к.: Этимологические исследования по русскому языку. — МГУ, 1963).

**ШАЛКАН** «репа» — кк., алт. *шалкан, чалкан,* хакас. *салган,* тув. *шалган* «шалкан» — фарсы теленнән дип хисапланыла; к. фарсы, таҗ. *шалгам, шәлгәм* «шалкан»; к. ш. ук кет теленең борынгы диалектында *чалгана* «шалкан».

**ШАМА** «чайные выварки» — чыгт., үзб., бор. тк., уйг., кум., кк. *шама*, тат. диал. (пенза), кырг. *чама* «шама» — кытайча *ча ма* «чәй калдыгы» сүзеннән.

**ШАМАКАЙ** «клоун» — диал. *шамакый, шамакы* «шамакай, шәмәкә», бор. *шамахаи* «Шәмәхә шәһәреннән килгән сәүдәгәр» — барысы да фарсы «Шәмәхәдән килгән» дигәннән. Шәмәхәдән атаклы әрмән циркы безнең якларга килеп йөргән. К. **Шәмәхә**.

**ШАМБЫ** «налим» — тат. диал. *шумба*, чув. *шампă*, мар. *шомбы* «шамбы» — фин-угор телләреннән; к. фин. samppi, ханты. sopii «шамбы».

**ШАПШАК** «неряха; неряшливый» — диал. *шапа, шава* «шапшак», мар. *шапшак* «шапшак», *шапы, шопо* «әчегән, черегән»; димәк, *шапшак* < *шапы-шак*; чаг. ш. ук. чув. *лапсак, лапша, лапшака* «шапшак, сәләмә», тат. диал. *лашпыр* «сәләмә, салынкы, пычрак, шапшак». К. **Шакшы**.

**ШАР I** «шар» — рус теленнән дип хисапланыла; к. ш. ук диал. *шара* «шар (*уен шары*)» < рус. *шары.*

**ШАР II** *диал.* «побелка, краска» — себ. тат., бор. тат. *шағыр* «буяу, ак буяу» сүзеннән, бор. рус. *шаръ* «буяу», *шаръчии* «буяучы, бизәкче» бор. тат. теленнән. К. **Чагыр, Акшар**.

**ШАТ** «веселый» — фарсы. *шад* «шат» (һинд-евр. *koye-t) сүзеннән. Бор. рус. *кой* «тыныч яту, тыныч булу» сүзе белән (к. рус. *покой, кой-ка*) тамырдаш.

**ШАШ-У** «сходить с ума; буйствовать» — гом. тк. *шаш-*, тат. диал., үзб. *чаш-* id.

**ШАЯН** «шалун; шаловливый» — *шаяр-у* «шалить» сүзе *шая* варианты да булганлыгын күрсәтә; к. диал. *чай-ан* «шаян, чая» — н. теле аша конч. тк. телләрдән килә. К. **Чая**. К. Әхмәтьянов, 1981:25.

**ШАЯТЬ** «наверно, вероятно» — фарсы. *шайәд* «шаять, яхшы булу көтелгән» сүзеннән.

**ШӘЙ** «вещь, предмет» — гар. *шәй-ун* «әйбер, предмет» сүзеннән. Диал. *шәй(е), шай(ы)* «охшаш, тиң» ~ бор. тк. *чаг-ы*. К. **Чак**.

**ШӘЙШЕ** «обрешетка для кладки снопов, сена и т.п. на просушку» — диал. *шәлче, чәче, чәрче,* чув. *шăлча, шăлçа,* башк. *сәйсе* «жердь на столбах» — тат. диал. *әшәлче*, башк. *әсәнче* «каты сабаклы үлән төре», *өшәлче* «салам түбә бастырыгы» белән тамырдаш булуы ихтимал.

**ШӘКЕРТ** «шакирд, ученик» — фарсы. *шагир-д* «шәкерт, хезмәткәр» сүзеннән.

**ШӘЛ** «шаль» — күпчелек төрки телләрдә һәм барлык Европа телләрендә таралган сүз. Татар телендә ул рус теленнән дә, фарсы теленнән дә булырга мөмкин (сүзнең төп чыганагы да фарсы теле).

**ШӘЛКЕМ** «гроздь, кисть; веточка с листьями» — кырг. *чәлкем*, госм., кырым., бор. чыгт. *салқын* «асылынып торган тәлгәш» сүзеннән, бор. тк. *салкы* (к. **Салпы**).

**ШӘЛТӘУ** «чехол, скоба на ремне для ношения топора и т.п.» — бу кызыклы сүзнең чыгышы ачык түгел; к. башк. диал. *шалтау*, мар. диал. *шалтау, шалтал* «шәлтәү» — тк. *шәлтә* «бил-

бау» нигезеннән. К. ш. ук чув. *шулкеме*, мар. *шӧлкама, шалкама*, морд. *сюлгемс* «чулпы, күкрәкчә».

**ШӘЛПЕК** «отвислый» — *шәлп-, сәлп-* тәкълиди тамырыннан, шуннан ук *сәлпәй-ү, шәлпәй-ү, сәлперә-ү*, башк. *шалпай-у*, бурят. *шальпай-* «шәлперәү; шәлперәгән, сәлкәү» (шуннан — бор. монг. теленнән — рус. *шалопай* > тат. *шалапай* «юньсез; җилкуар»). К. **Салпы**.

**ШӘМ** «свеча» — гар. *шäмғ* (тат. диал. *шәмек*) «шәм, яктырткыч» сүзеннән.

**ШӘМӘЙ** «вид игры в альчики» — диал. *чәмәй, чәбәй, чабай* «ашык, кузна» ~ тув. *шаңай, шаний*, бурят. *шагай*, монг. *шага* > бор. рус. *шега* id. бор. монг. şiγaj «ашык сөяге» сүзеннән булса кирәк. Чаг. **Сака**.

**ШӘМӘХӘ** «фиолетовый» — Азәрбайҗандагы Шәмәхә шәһәре исеменнән: шәмәхә бизәкле ефәкләр элек шуннан китерелгән. К. **Шамакай**.

**ШӘМДӘЛ** «подсвечник» — фарсы. *шäмдан, шäмегдан* «шәм савыты» сүзеннән (к. диал. *шәмгәдән* «шәмдәл») киң таралган.

**ШӘП** «хорошо, замечательно» — диал., иске әд. *шәпле* ~ чув. *шеп, шеплĕ*, мар., удм. *шäп, шаплы* id. гар. *шäбб* «яшь; егетләрчә» нигезеннән шәкертләр телендә килеп чыккан.

**ШӘРАБ** «вино» — гар. *шäраб* «эчемлек» тамырыннан, шуннан ук *ширбәт* һәм *шулпа* (грек теле аша) *сироп* сүзе килә.

**ШӘРӘ** «голый» — Идел-Чулман регионында ясалган сүз; к. мар. *цäрä, чäрä*, чув. *çара, чар'а* «шәрә, тиренең (кайбер хайваннарның корсагындагы) йонсыз урыны», удм. диал. *чап-чара* «шәпшәрә», асылда, тат., кырг., кар. *чара* «ашъяулык итеп кулланылган каткан йонсыз тире, тире табак» сүзе белән бердәй булса кирәк. К. **Чара II**.

**ШӘҮЛЕГӘН** «иволга» — тат. диал. *шүлегән* «оляпка» (су астына төшеп корт чүпли ала торган кош) — тат. диал., башк. *шүлгән* «су асты патшасы», рус. *шуликун, шулейкун*, мар. *шулейкин*, якут. *сүлүүкүн* «Яңа ел төнендә су астыннан чыга торган явыз рух» << кытай. *шуй-луң-хуан* «су аждаһалары патшасы» сүзеннән булса кирәк (ул аждаһа кайчак кошка әверелеп күккә аша имеш). **Шүлгән** — башкорт эпосында еш очрый торган персонаж. «Заятүләк» дастанының бер вариантында ул — Сусылуның атасы. Шуңа охшаш әкияти каһарман Тувада **Шулугун** дип атал. Бу вариант тат. *шолган, шуылган, шыулыган* «су күсесе» сүзен дә әлеге аждаһалар патшасы исеменнән дип уйларга нигез бирә. К. Әхмәтьянов, 1981: 59 — 60.

**ШӘҮЛӘ** «облик; отражение *чего-л.*» — гар. *шуғлә-т-ун* «шәүлә, нур көлтәсе» сүзеннән таралган (күп телләрдә очрый).

**ШЕКӘ, ШӨКӘ** «гном» — бор. тат. *чәкә, чикә* «үлчәү сөяге, терсәк (үлчәме)» сүзеннән; к. чув. *чике* «үлчәү берәмлеге — пары; беләк», мар. *шика, шига* «шекә; беләк буйлыгы кеше». К. Әхмәтьянов, 1981: 48.

**ШЕЛТӘ** «выговор» — госм., бор. тк., бор. монг. *шылтак* «яла, шелтә», үзб., ткм. *силтә-* «шелтәләү, сылтау, тезген тару» бор. тк. *сылта-ғ-, салт-аг-* «башкаларга күрсәтү, сылтау, селтәү» сүзеннән. К. **Селтә-ү**.

**ШЕШ I** «стожар (*шест в середине стога*), вертел» — тат. диал. *чош* «колга», ткм. диал. *чыш*, госм., алт., тув. *шиш*, бор. тк. *шаш, чиш*, кб. *тиш* «казык, кадак» — бор. гом. тк. *шал//сал* «оч, үткен нәрсә» сүзеннән хисапланыла (Рясянен чув. *шăл* «теш» сүзе белән чагыштыра). К. ш. ук бор. тк. *шашлық* > рус. *шашлык* «шештә пешерелгән ит (шешлек)».

**ШЕШ II** «опухоль» — гом. диал. *шешек* «шеш», куман., чыгт. *шиш*, ткм. *чиш*, алт. диал. (телеут.) *тиш* «шеш» — *шеш* «кадак» белән бәйле (кадак кергәч шешү). *Шеш-ү* фигыле — конверсия.

**ШЕШБҮРӘК** «пирожок, испеченный на вертеле» — *шеш I* һәм *бүрәк* (к.) сүзләреннән. *Шешбәрәк* — борынгы болгар. **шеш буәрәк, шеш пуәрәк* вариантыннан. Чаг. себ. тат. *шеш палык* «шештә пешерелгән балык».

**ШЕШӘ** «бутылка» — диал. *шиша* «шешә», фарсы. *шиша, шуша* «шешә, стакан, пыяла» сүзеннән таралган сүз.

**ШЕШӘК** «овца (коза, реже корова) после второго окота (отела)» — тат. диал. *чешәк, тешәк*, үзб., бор. тк. *шишәк* «ике яшьлек сарык, ике тапкыр бәрәнләгән сарык» — бор. тк. *тишәг* «тешен алмаштыра торган мал» сүзеннән (сарыклар ике мәртәбә бәрәнләгәч теш алмаштыралар).

**ШИГЫРЬ** «стих, стихотворение» — гар. *шиғр-ун* «шигырь» сүзеннән (*шагыйрь, шигъри, шигърият* сүзләре дә гарәпчәдән).

**ШИК** «сомнение» — иске әд. *шәк* «шик» — гар. *шәкк-ун* «шик» сүзеннән.

**ШИКӘР** «сахар» — фарсы. *шәкәр* «шикәр» сүзеннән; сүзнең төп чыганагы — бор. һинд (пракрит.) sarkara «комлы шикәр, шикәр комы»; күп телләргә таралган (гар. *сәккар*, грек. *сакхар* > рус. *сахар*, немец. Zucker).

**ШИКЕЛЛЕ** «вроде, подобно» — гар. *шәкл-ун* «шикел (вид, образ, рисунок, схема)» сүзеннән; к. иск. әд. *шәкел* «схема, форма (металл кою эшендә)».

**ШИКМӘ** «обрешетка крыши, каркас забора» — к. чув. *шикме, чикмә* «баскыч, койма шикмәсе» — бор. тат., чув. *чик-* «багана утырту, кадау, беркетү, тегү» фигыленнән (*чик-мә*). К. **Тек-ү**. К. Әхмәтьянов, 1989: 61.

**ШИМБӘ** «суббота» — фарсы. *шәмбә, шәнбә* «шимбә» сүзеннән (асылда, «җиде көнлек атна ахыры» дигәнне белдерә) — барлык мөселманнарда, христианнарда һәм яһүдләрдә таралган уртак нигездән; к. рус. *суббота* < бор. славян. *самбата*, румын. šambata, венг. szambat, латин. sabbatum ~ грек. *саббатон*, гар. *сабтун*, бор. яһүди. *шаббат* «шимбә, шабаш, җиде көнлек атна ахыры». Сүзнең тамыры — семит. *смг* «җидедән тору» сүзе булса кирәк (к. гар. *самга-т-ун* «җиделек»). Икенче яктан, бу сүзне борынгы Вавилондагы *шаммаш* «кояш алласы» (к. гар. *шәмс* «кояш») сүзенә кайтарып калдыру да күзәтелә (*шимбә* «Кояш алласына табыну көне»).

**ШИФА** «исцеление» — гар. *шифа* «шифа» сүзеннән.

**ШОБАГА** «жребий» — удм., башк. *шыбага*, кк., ккк. *сыбага* «шобага, өлеш, пропорция», чув. *шăпа* «шобага», калм. *шавг* «шобага шакмагы» — бор. монг. *шибагай, сибагай* «өлеш, шобага» сүзеннән, сүзнең тамыры — кытай. *шо* < **шоб* «юрау шакмагы» сүзе булса кирәк. К. Әхмәтьянов, 1989: 154.

**ШОМ** «опасение» — гом. тк. *шум* «ялмавыз, явыз рух, шайтан; явызлык» ~ фарсы-таж. *шум* «явызлык иясе» сүзеннән булса кирәк.

Бу нигездән тат. *шомлан-у, шомлык* һәм *Шомбай* сүзләре ясала.

**ШОМА** «гладкий» — *шу-ма* «шуа торган» татар-башкортка гына хас *шу-у* сүзеннән. Чув. *шăма*, мар., удм. диал. *шыма* «шома» — татарчадан.

**ШОМЫРТ** «черемуха» — чув. *шăмăрта, çăмăрта, çӗмӗрт*, башк. *шӧмӧрт, шӧмӧрӧт*, алт. *йымырыт, д'ымырыт*, хакас., тув. алт. диал. *нымырт, намырт* «шомырт, муел», себ. тат. *чумурт* «кыргый чия», хакас. диал. *ымырт, йумурт* «шомырт» — бор. гом. тк. *уймуру-т* «йомыры җимеш» сүзеннән. Үзб. *шумурт*, кк. *шомырт* «шомырт» татар теленнән, татар теленә исә бу сүз шул янгыраштa борынгы болгар яки чуваш теленнән кергән (сүз башында [*й* > *ч* > *ш*]).

**ШОҢКАР** «кречет» — гом. тк. *шункар, шонкур, сонкур*, монг. *синхур* «шоңкар, ханлык кошы» < бор. хинд. čanukart «әкияти кош» булса кирәк. Тат. әкиятләрендә *Сонгур хан* «кошлар патшасы».

*Шонкар, шункар* сүзен алт. диал. *шуңу-* «аска ташлану» (кошлар турында) сүзеннән дә чыгаралар. Ләкин ул чагында сүзнең кайбер фонетик һәм мәгънәви вариантлары аңлатылмый кала.

**ШӨКЕРАНА** «в благодарность» — фарсы. *шукрана* «шөкерана, шөкерләр» сүзеннән (гар. *шукр* «шөкер» сүзенә ирани. *-ана* кушымчасы ялганып ясалган).

**ШӨЛДЕР** «колокольчик» — диал. *шөлдер, шылдыр* «шөлдер» — кечкенә кыңгырау яки чылбыр тавышын белдерә торган *шылдыр // чылдыр* тасвирый янгырашлы сүзеннән булса кирәк.

**ШӨПШӘ** «оса» — диал. *шыпша, шыпшы* (мишәр), шүпшә (башк.) «шөпшә» — болгар яки чуваш теленнән; к. чув. *сăвăса, сăпса, шăпша* «шөпшә, сагызак»; чуваш һәм болгар телендә *сагызак, сауызак* (к. **Сагызак**) закончалыклы рәвештә *сăвăса, сыуыса, сыпса* янгырашын бирә. Шулай итеп, *шөпшә* һәм *сагызак* — лексикологик дублетлар.

**ШӨҺРӘТ** «слава» — гар. *шуһрә-т-ун* «шөһрәт, дан» сүзеннән.

**ШӨШЛЕ** «кочедык» — диал. *чөшле*, чув. *шешле*, мар. *сузлӧ* «чөшле» — ясалышы һәм тамыры ачык түгел; чаг. мар. *шужсыль* «чөшле», *шуж* «тишек».

**ШУК** «озорной» — алт. *шок* «усал, усаллык», кк. *шок* «мактау *ирон.*, явыз көлү», хакас. *сох* «шук», төрекм. *шох* «шук, шаян» һ.б. фарсы-таж. *шох, шух* «шук, шаян, уйнак» сүзеннән булса кирәк.

**ШУЛ** «тот; этот; сей» — уйг., госм. *шол*, кк. *сол*, бор. тк. *ошал, ошол*, бор. чыгт. *ошул* «шул, шул үзе» — бор. тк. *уша ол* «шушы ул» кушма сүзеннән килеп чыккан (Радлов); чаг. *ӧшбу, уша бу* «шушы бу» (к. ш. ук *шау*); чаг. ш. ук чыгт., бор. тк. *ушанча* «шунча», *ушандаг* «шундый». К. **Шулай, Шушы**.

**ШУЛАЙ** «итак, так» — бор. тат. *шу* «шушы» сүзеннән (*шулай*; чаг. *теге-ләй, бӧлай* < *бу-лай*), бор. тат., госм., кар. *шу* «шушы, бу» сүзе исә бор. тк. *уша* (башк. *ӧшӧ*) «шушы» сүзеннән кыскарган. К. **Шушы**.

**ШУНДЫЙ** «такой» — диал. *шундай* < *шун-дай* «шуның кебек» сүзеннән. К. **Шул**.

**ШУЛПА** «суп, бульон» — диал. *шурпа*, гом. көнб. тк. *шорба*, госм. *чорба* «шулпа» — фарсы-таж. *шурбо* «шулпа» сүзеннән. Сүзнең тамыры — тат. диал. *шур, шур* < фарсы. *шур, шор* «тоз; тозлак».

**ШУ-У** «скользить; кататься на коньках или на лыжах, санях» — башк. *шыу-*, чув. *шу-*, тув. *со-* «шуу, шуып төшү» — бор. тк. *шоғ-* «шуу» сүзеннән.

**ШҮРӘЛЕ** «леший» — чув. диал. *шӳреллӗ* «шүрәле, рух (*название божества*)», *шӳрекей* «җен, шайтан», *шӳр* «хулиган, мошенник, җен», мар. *шурали*, удм., кырг. *шурали, урали* «урман рухы; шүрәле», кк. *сорель* «чүл рухы» (кыргыз һәм казах сүзләре татар теленнән булса кирәк).

Бу сүз турында фаразлар бик күп (шуларның берсе — рус. *чурило, чурилья* «бичура» сүзеннән дип раслау). Иң ышанычлы нигез — тат. *чүрәле* «тискәреле»: тат. *чүрә* «тискәре як», *чүрәкә* «кәшәкә, кәкре мөгез» > чув. *шурекке* «мөгезле җен». Җеннәренең аягы, йөзе һ.б. тирескә, тискәрегә караган дип уйланыла. Мар. *шурали* «аягы кирегә беткән нәмәстә»; чаг. ш. ук тат., башк. *тирес аяк, тирес бит* — сүгү сүзе һәм бу сүзләр асылда «җен, иблис» дигәннән (*җен, шайтан* сүзләрен әйтмәс өчен *тирес аяк* яисә *тирес бит* диләр).

**ШҮРЕ** «цевка» — диал. *шүре* «кечкенә трубка, папирос, кадак, шеш, кадама, орчык», себ. тат. *цүр* «шеш, шүре», чув. *шӳрӗ, шӳр* «шүре, трубка, очлы нәрсә», монг. *шүүр* «шүре»; к. мишәр. *шүр-*«җеп чорнау» (*шүрге* «шүре»); хакас. *сӧрге-* «урак», бор. тк. *йӧр* «урау, чорнау» *шүре* сүзенә контаминация тәэсире ясаган.

**ШҮРЛӘ-Ү** «испугаться» — к. диал. *шүр җибәрү*, башк. *шөр* (*шөбер*) *йебәрү* «курку, шүрләү» нindидер *шүр* сүзеннән. Чаг. ш. ук диал. *чүпрәлә-ү, чүпер-ү* «куркудан сасы ис чыгару» (*кайбер кыргый хайваннар турында*). К. **Чүпрә**.

**ШҮРЛЕК** «полка» — чув. *çӳлӗк, шӳрлӗх* «почмактагы шүрлек» (өчпочмаклы мәйданчык рәвешендә булып, почмакка беркетелә), төре шүрлеге» — чув. *шевӗрлӗк* «өчпочмаклы мәйданчык» сүзеннән (*шевер* «очлы, оч, очлы почмак» нигезеннән; к. бор. тк. *субур* «очлы нәрсә». Икенче версия буенча, *шүрелек* «шүре куела торган урын» сүзеннән. К. **Шүре**.

**ШЫГРЫМ: шыгрым тулы** «полно людей» — тат. диал., чув. *лыгрым* «шыгрым» сүзеннән (тасвирый янгырашлы *лагрым, лагыр, лагыр-, лыгыр-лыгыр, лыгыр-лагыр* сүзләре белән тамырдаш). Сүз башында [*л* >*ш*] күчеше ш. ук *лап* > *шап, лап-шак* > *шапшак* сүзләрендә дә күзәтелә.

**ШЫК** «нормальный, пригожий вид» — < тк. *шык, ышык* «нур», *ышы-* «яктыру».

**ШЫЛ-** «соскользнуть; улизнуть» — чув. *шăл-* «сөртү; шылу» сүзеннән.

**ШЫЙЛЫК** «торжественный пир на открытом воздухе» — Урта Идел регионындагы махсус сүз: чув. *шальăк, шилĕк, шăрлăк,* мар. *шелык, сэлык* «ачык һавада туй ясау өчен амфитеатр сыман корылма, сәхнә, изге потлар өчен өстәл». Бор. тк. *шыр* «хан тәхете алдындагы киез» сүзеннән булса кирәк. К. Әхмәтьянов, 1981: 100.

**ШЫРАЗ** «вид узора, который обычно применяется при расшивке вырезов» — к. тат. диал. *сыраж* «бизәк; кызыл чәчәкле үсемлек», чув. *шăрас, шăрас, шăрса* «кисточка, бисер, узор».

*Шыраз* яңгырашы бор. болгар теленнән булса кирәк; к. чув. *шăр,* рус. *ширязь* «җете ачык кызыл төс, шундый чәчәк».

*Шыраз, чыраз, сыраж, тыраз* — борынгы төрки гаскәриләрнең ранг билгесе булган, ягъни төсенә, чачагына карап (погон шикелле) төрки хәрби дәрәҗәне белдергән.

**ШЫРПЫ** «спичка; заноза» — диал. *шырпык, чырпы* «шырпы, кадалгы», чув. *шăрпăк* «шырпы, балык кылчыгы (сөяге)», кк., ккк. *шырпы* «чыбык, чабык, куак, шырпы», куман. *чирпи, цырпы* «чыбык-чабык» — бор. тк. тасвирый яңгырашлы **тырп* «тырпаеп торган» сүзеннән; к. **Тырпа**. Чаг. **Шырт**.

**ШЫРТ** «щетина» — диал. *шыт* «шырт», *шырт* «кискеч», бор. тк. *сырт* «шырт, калын кыл» (МК) — бор. тк. тасвирый яңгырашлы *тырт* «тырпайган, кадарга торган» сүзеннән, к. тат. диал., алт., шор. *тыртай-* «тырпаю, кадарга тору». Чаг. **Тырпа**.

## -Ы-

**ЫЗАН** «межа» — диал. *азан* «ызан» — бор. тк. **ыргы-* (тат. диал., көнч. тк. *ыз-*) «зигзаг ясап йөрү» сүзеннән; к. чув. *йăран,* мар. *йыраҥ* «ызан»; тат. диал. *ыз-у* «ызан яру» — *ызан* нигезендә соңрак килеп чыккан сүз булса кирәк. К. **Ызма**. К. Әхмәтьянов, 1989: 64—65.

**ЫЗБА** «изба» — рус теленнән борынгы заманда ук кергән (к. «Коман мәҗмугасында» isba «өй, йорт»).

**ЫЗМА** «шнуровка сбруи, подпруга» — тат., башк. диал. *ыз-* «шнур белән беркетү, зигзаг ясау», кк., ккк. *из-* «тоташтырып тегү» сүзеннән (к. **Изү**). К. бисермән телендә *измә* «шнурлаган сыман җөй» (Т е п л я ш к и н а Т.Н. Язык бесермян. — М.: Наука, 1970.— С.46) > чув. *исме* «изү бавы, ялау». К. **Ызан.** Сүзнең тамыры — бор. тк. **йырғ-* «тупас җеп белән зигзаг ясап юләү».

**ЫК-ЗЫК: ыгы-зыгы** «шум и суета» — *ык* һәм *зык* сүзләреннән, *ык, ыгы* өлеше гом. тк. *агы, ыгы* «елау тавышы» сүзеннән, шуннан ук *ағыла-, ағла-, йығла-* > тат. *йыла-у; зык, зыгы* өлеше исә тат. *зык* (*зык кубу* «шау-гөр килү»), башк. *ҙык, ҙыуы,* тат. диал. *суы* ~ чув. *сăвă* «хор белән җырлау; җыр сүзләре» дигәннән. К. Әхмәтьянов, 1981: 108.



**ЫКЧАМ** «аккуратный» — гар. *иқтам* сүзеннән: гар. *иқтамат* «ыкчамлык» сүзенә тат. диал. *тымат,* чув. *тăмат,* мар. *тымат* «ыкчам, җыйнак» сүзе дә кайтып кала.

**ЫЛКЫМ** «самое узкое место сапог, горловина» — < гар. *һәлкум* «бугаз».

**ЫЛЫКТЫР-у** «вовлекать, вовлечь (в движение)» — тат. диал. *ылык-у* «хәрәкәткә ияреп, кушылып китү» фигыленең йөкләтү юнәлеше; ул сүз исә *ыклык-у* «су агымы белән алып кителү» дигәннән, *ык-у* «тоташ масса булып агу» (исем коррелянты *ык* «агызып китә торган агым»). Себер-Урал регионында берничә елга *ык* дип атала (ул елгалар буйлап элек сал агызганнар).

*Ыклык-у* > *ылык-у* фигыле интенсивлык кушымчасы — *лык-* ялганып ясалган, чаг. *җиту-җитлегү, йоту-йотлыгу, өзү-өзлегү, сөрү-сөрлегү, таю-тайлыгу* һ.б.ш.

**ЫЛЫС** «хвоя» — чув. *лăс,* кк. *алыс* id., асылда, фин-угор сүзе; к. удм., коми. *лыс* «ылыс».

**ЫМ** «знак, сделанный рукой; мимика» — кк., ккк. *ым,* тув., бор. тк. *им* «кабиләдәшләр генә белә торган махсус билге». Мәхмүт Кашгарый әйтүенчә, *Им билсә эр өлмәс* мәкале күп кабиләләрнең ымын белгән кеше турында. К. **Им**.

**ЫНДЫР** «ток; гумно» — тат. диал., башк. *ырдың, йырдың,* гом. кыпчак. *ырдын, ырдаң, ындыр,* себ. тат. *иртин* «ындыр», н. *ыдан* «тирән баз», курәсең; тат. диал. (Паасонен) *идәм,* чув. *итем, йĕтем,* мар. *идым, йыдым* «ындыр, идән» сүзе белән бердәй; к. ш. ук морд. *утом* «ындыр» — алт. *үртүң* < бор. тк. *өртгүн* «ындыр, ашлык сугу», *өрт-* «балчык сылап тигез җир мәйданы ясау» фигыленнән. К. **Идән**.

**ЫҢГЫРАШ-У** «стонать» — чув. *ăнăраш-* гом. тк. *ын-кыр-а-* «ыңгырашу авазын чыгару» фигыленнән; к. якут. *ың* «мөгрәү авазы». К. **Иңрәү**.

**ЫҢГЫРЧАК** «седелка, вьючное седло» — гом. тк. *ынғырчақ, йынгырчак, йынар-чак* көнч. тк., бор. тк. *йынғар* «ияр» сүзенең кечерәйтү формасы; бу сүзләрнең палаталь вариантлары *ияр* сүзенә якынлаша; чув. *йенер* «ияр», *йенерчек* «ыңгырчак», алт. *ээр* «ияр», *ээрчик* «ыңгырчак»; бор. рус. *арчак* «ыңгырчак» << алт. диал. *аарчак*.

**ЫРАЙ** «настроение; характер» — кырг., кк. *ырай-* гар. *ра'и* «караш» сүзеннән.

**ЫРА-У** «спориться (*о работе*)» — мар., удм. *ыра-* << алт., тув., хакас. *ыра-* «ерагаю», себ. тат. *ыра-* «ераклашу». К. **Ерак**.

**ЫРГАК** «крюк» — чув. *йăрхах* «агач ыргак», тув. *ырғақ* «кәкре», бор. тк. *арғаг, ырқақ* «ыргак» — бор. тк. *ырығ* «кәкре» сүзеннән; к. алт., тув. *ырғай-* «кәкрәю». *Ыр-у* фигыленнән дә чыгаралар.

**ЫРГЫ-У** «прыгать вперед или вверх» — гом. тк. *ыргы-, ырга-* (к. Севортян, 1:662 — 663); шуннан ук тат., башк. *ыргыл-у* һәм *ыргыт-у* > удм. *ыргыт-*, миш., мар. *выргыт-*, чув. *вăркăт-* «ташлау, ыргыту» сүзләре ясалган.

**ЫР-У** «делать пазы» — башк. *ыры-*, чув., мар. *ыр-, ыра-*, тат.

диал., алт., хакас. *ар-* «бәж алу»: *ырмау- ыруның* интенсивлык формасыннан.

**ЫРУ** «род» — гом. тк., бор. тк. *уруғ* «ыру, нәсел, орлык», бор. тк. *ур, ор* «орлык, нәсел тамыры» сүзеннән; шуннан ук *орлык, үр-ү, үр-че-ү*.

**ЫРЫМ** «заклинание; колдовство» — гом. тк. *ырым* бор. тк. *ыры-, ыру-* «күрәзәләү, яхшыга юрау» сүзеннән (Севортян, 1: 665 — 667).

**ЫСПАЙ** «опрятный, аккуратный» — чув. *ăспай*, мар., удм. *испай*, тат. диал., башк. *ыспайы*, чув. *сăпай*, иске тат. *сипаhи*, тк., таҗ. *сипаhи* «атлы гаскәри, солдат; тыйнак, ыспай» — бор. фарсы. spada «атлы гаскәри» сүзеннән. К. **Сыбай**.

**ЫСУЛ** «способ» — гом. кыпчак. *усул*←гарәпчә *усл* «ысул, асыл».

**ЫЧКЫН-У** «вырваться» — гом. тк. *ычкын-* < *ыкчын-* (чаг. ш. ук тат. диал. *ычкыт-* «ычындыру»); бор. *ыкчы-* «ихтыярсыз атылу» фигыленең кайтым юнәлеше, тамыры — *ык-* «атылу, атылып агу» (чаг. себ. тат. *ык-* «агым уңаена йөзү», *ык* «көчле агым»).

**ЫЧКЫР** «очкур» — гом. тк. *учқур*, бор. тк. *ич қор* «эчке билбау» сүзеннән (*ич* «эч», *қур, қор* «билбау»; к. **Кушак**).

**ЫШ-, ЙЫШ-** «скоблить» — алт. *йыш-*, хакас. *йыс-*, н. *ыс-* id. Бу фигыльдән татар телендә *ышкы, ышкы-у, ышна* сүзләре ясалган.

**ЫШАН-** «верить» — чув. *шан-*, мар. *ишан-, ушан-*, гом. кыпчак. *ышан-*, чыгт. *ишан-, ишен-* еш кына *иш ан-* «иш (дус) дип бел» сүзеннән дип аңлатыла. К. төрек. *ан-* «искә алу».

**ЫШТАН** «штаны» — удм. *ыштань, иштон*, мар. *иштан*, чув. *аштан-* бор. тк. *ич тон* «эчке тун (кием)» сүзеннән: рус. *штаны* — төрки телләрдән: [*ч>ш*] мәсьәләсендә к. **Ыштыр**.

**ЫШТЫР** «онуча, обмотка, портянка» — тат. диал. *иштыр*, удм. *иштыр*, мар. *ыштыр, иштер* чув. *ăш тир* «эч тире, чолгау эченнән аякка урый торган тире» сүзеннән булса кирәк; к. башк. *куйтыр* «куй тиресе»; *ыштыр* сүзен фин-угор сүзе дигән караш та бар.

**ЫШЫК** «прикрытие, укрытие» — мар. *ышык, ушык, ушук*, тув. *ыжык* id.; чув. *ăшăх* «сайлык» (!), төрек. *ышық* «нур, кояш төшкән җир», *ыш* «яктылык», *ышыл-* «ялтырау; яшьнәү»; чаг. шумер. iş «тау, битләү»; сүзнең морфологиясенә карaганда, *ышы-, ыш-* «ышыклау» фигыле булган. Бу тамырны *яшен* ~ *ялтырау* белән дә бәйлиләр (*л~ш* күчеше булган).

## -Э-

**ЭЗ** «след» — гом. тк. *из, ис*, бор. гом. тк. **ирг'* > чув. *ĕр, йер;* татар телендә бу тамырдан *эзәк, эзәрлә-ү, эзлә-ү, эстәү* («теләү») сүзләре килә.

**ЭЛӘ-ТАНАГЫ** «прийти в полную негодность» — тат. диал. *элә, әлә, анә, анау* бор. тк. *анагу, аңагу* «күренеш, сурәт» сүзеннән булса кирәк; *анә* «сурәт» тамырыннан тат., башк. *әнәчә, әнәсә* «токмачлык камыр кисәге, киндераштан төрле фигуралар рәвешендә ясала торган ашамлык» (татарларда камырдан кошчык, ат һ.б.ш. *әнәчәләр* ясау гадәте булганлыгы тур. Г. Тукай да яза) ~ кк. *анаша* (< *анача*) ~ үзб., уйг. *нәшә, наша* «киндер орлыгыннан ясалган наркотик» > рус. *анаша* һ.б. ясалган. *Танак* ~ чув. *туна* «кәүсә, сабак».

**ЭЛЕК** «прежде, раньше» — гом. тк. *илк, илик*, бор. тк. *ил* «алдагы»; шуннан ук тат. *элгәр* «предшественник» < бор. тк., чыгт. *илгәр* «алдынгы отряд, авангард»; тат. *элгәре* < бор. тк. *илгәру* «алга, көнчыгышка». Чаг. ш. ук себ. тат. *әлик* «күптәнге», *эләй, әләй* «ишек төбе; ишек төбендәге урындык».

**ЭЛМӘ** «ильм» — рус теленнән (асылда һинд-евр. сүзе; к. немец. Elm, латин. ilmus, бор. рус. *илемь* «элмә»).

**ЭЛМӘК** «петля» — *эл-ү* < гом. тк. *ил-* «элү, эләктерү» сүзеннән.

**ЭЛПӘ** «эмаль; перепонка» — ~ мар. *äлпа, ы̆лпа*. Ачык түгел.

**ЭНӘ** «иголка» — диал. *инә*, чыгт., кк., ккк. *ыйнә*, куман., бор. чыгт. *игна*, госм. *игнэ*, бор. тк. *эгинэ, йигнә*, бор. монг. *җэг-ун* «энә» — бор. гом. тк. *ик-, йэк-* «тегү» тамырыннан. К. **Җөй**.

Тат. диал. (каратай) *эзнә* «энә» < уйг. *иснә* «энә». Чаг рус. *игла* ~ гом. славян. *йыгъла* < *йыгъ-ло* (?)-*йыг-* «тегү» тамырыннан.

**ЭНДӘШ-Ү** «окликать; обратиться со словами» — *өндәш-ү* сүзеннән. К. **Өн, Өндә-ү**.

**ЭНЕ** «младший брат» — гом. тк. *ини, эни* «эне, кече туган (эне һәм сеңел)» сүзеннән, *ана* (к.) белән бер төптән булса кирәк; к. бор. тк. *ини* «кече кардәш, ана, апа», тув. диал. *аныйак* «эне», алт. *ины* «эне», эвен. *эмде* «эне».

**ЭНҖЕ** «жемчуг» — гом. тк. *инчи, инчу*, бор. тк. *йинчу*, алт. *д'инд'и* «энҗе» — кытай. *чөн чу* «чын энҗе» сүзеннән. Рус. *жемчуг* — бор. тк. телләрдән.

**ЭҢГЕР** «сумерки» — диал. (себ. тат.) *эңерт, ымырт* «эңгер», көнч. тк. *әңир, иңир*, бор. тк. (МК) *иңгир* «эңгер» — чак-чак кына җемелдәп күренүне, җем-җем итүне белдерә торган бор. тк. *йем // д'ем* тасвирый янгырашлы сүзеннән; к. тув. *имиртиң* «эңгер», *имирәңнээр* «җемелдәү», кк. *имирт-* «чак кына җемелдәп күренүче», якут. *имил-җимил* «чак кына күренүче, тын, эңгер-меңгер», *им* «шәфәкъ».

**ЭРГӘ** «земляная насыпь вдоль наружных стен дома» — тат. диал. *өргә, иргә* «фундамент; нигез яны», бор. тат. *йәркә, йәркәсурәт* «закон, устав» (Туктамыш ярлыгы; Утыз-Имәни), башк. *эргә* «кыр, ян, янәшә», кырг., н., кк., ккк. *ирге* «стена; нигез; тирмә нигезе», алт. *эрге*, хакас. *иркен*, тув. *эргин* «бусага; йола; закон», кк. диал. *ерке* «киндер буйлыгы, рәт, тезем», кум. *җерге, ерге* «рәт, чират; түтәлләр», чув. *йерке* «тәртип, рәт; тезем; кагыйдә», кырг. *җерге* «рәт, тезем; биләмә, килеп утырган җир; ырулар, кабиләләр союзы», мокша *ирьгя* «көч, куәт; берлек» — бор. гом. Урал-Алтай *йәркә, нәркә* «тезмә, сайгау; нигез; стена»

сүзеннән; к. фин., эстон. järk, järkä «нигез; кагыйдә, йола», эвенк., монг. *нэргэ* «нигез; кагыйдә». К. **Ниргә**.

**ЭРГӘЗЕМБИ** «подснежник» — тат. диал. *эргәҗелбай* «кечкенә батыр», башк. *ирҙәйеп, илгәйер* «әкияттәге бармак буе батыр: кечкенә гәүдәле, ләкин бик булдыклы кеше», тат. диал. *Илкә-батыр* (М.Гафури), башк. *Ирҙәнәк* «кәрлә батыр», кк. *ергежәй, ергежейли*, н. *эргежейл* «карлик», Себ. тат. *Ирбеел, Ирбей* «Эрбет елгасы һәм шәһәре; бу елга буенда кәрлә батыр яшәгән» (К.: Географический словарь Российского государства. — М., 1804: 786), алт., тув. *эргекту* «бөтен көче баш бармагында булган батыр», *эргек* «баш бармак» — бу сүз барлык алтай телләрендә бар: уйгур. *әрңәк*, якут. *эрбэх*, монг. *эрекей, һерегей*, эвенк. *хэрбэк* «баш бармак». Борынгы төрки телләрдә: *Ирник* Атилланың бер улының исеме, «баш бармактай егет» дигән мәгънәне белдерсә кирәк.

**ЭРЕ** «крупный; гордый» — диал. *ире*, госм., азәрб., кырым. *ири*, үзб. *йирик* «эре, зур, калын, юан» — бор. тк. *эриг* «зур, көчле» сүзеннән; к. тат. диал. *ирәбә* «эре сөякле», *ирәй-ү* «тәкәбберләнү», *ирәмсе-ү* «үзен эрегә санау, масаю». Чаг. **Ир, Ирек**.

**ЭРЕМЧЕК** «творог» — *эре-ү* (< гом. тк. *ири-, эри-*) «эрү» сүзеннән (аның борынгы «өчү» мәгънәсеннән); чаг. диал. *эрек, эркет* «эремчек, әчегән катык».

**ЭРЕН** «гной» — чыгт., госм. *әрин*, алт. *ирэн*, хакас. *ирәң*, тув. *ириң* «эрен» гом. тк. *ири-* «эр-ү» сүзеннән.

**ЭРЛӘ-Ү** «прясть» — диал. *җерлә-ү, җегерлә-ү, йегерлә-ү* id. диал. *иер-ү, җегер-ү, йегер-ү* «эрләү, җеп кату» сүзенең интенсивлык формасыннан; гом. тк. *әгир-, эгир- «эрләү»* (к. Радлов, 1: 706) исә көнч. тк. бор. тк. *иг, йиг* > чув. *йĕкĕ* (*йеге*) «орчык» сүзеннән. К. **Эпә**.

**ЭСКӘНҖӘ** «пресс» — фарсы. *искăнҗă, ишкăнҗă* «эскәнҗә» сүзеннән.

**ЭСКЕРТ** «скирда» — рус. теленнән.

**ЭТ I** «собака» — гом. тк. *ит, ыт*, чув. *йытă*, ккк. *иит, ийит*, тат. диал., *эст.*, уйгы диал. *ишт*, тунгус. *инта, инда*, япон. *ину* «эт» сүзләре белән дә чагыштырыла. Ин бор. янгырашын **иньйыт* дип чамалап була.

**ЭТ II** «толкнуть» — гом. тк. *ит-, ыт-* id.

**ЭЧ** «внутренность, нутро» — гом. тк. *ич, ыч*, чув. *ыш* «эч» сүзеннән. Шул нигездән (к.) *эчәк, эч-ү* сүзләре дә ясалган. К. ш. ук бор. тат. әд. *эчрә* «эчтәге, эчендә». К. **Ычкыр, Ыштан, Читек, Эчмәк**.

**ЭЧӘК** «кишка» — гом. диал. *эчәге*, алт. *ичәгэ*, уйг. *иҗәгү*, бор. тк. *ичэгү* «эчтәге органнар, кабырга асты» (МК) сүзеннән кыскарган. Сүзнең тамыры — *ич*. К. **Эч**.

**ЭЧЕК** «мех» — иске татар сүзлекләрендә *ичек, чек* «тунның эчке ягы, йомшак мех, хатын-кыз туны» — әлбәттә, *эч* сүзеннән.

**ЭЧМӘК** «внутренняя сторона одежды; пододеяльник» — удм. *исьмек* «киез» гом. тк. *ичмэк* «эчке ябу (*ул киездән гыйбарәт булган*), эчлек» сүзеннән. Шул ук мәгънәләрдә себ. тат. *эчек*, иске тат. *ичек, чек* «тунның эчке ягы, тун эчлеге, йомшак мех, хатын-кыз туны», тат. диал. *эчерге* < гом. тк. *ичирги* «эчлек, эчке киез, чапрак» сүзләре билгеле.

**ЭШ** «работа, дело» — чув. *ĕҫ*, гом. тк. *иш, ыш* id. < бор. гом. тк. il (Севортян, 1:395 — 396). Чаг. шумер. il «күтәреп ташу».

**ЭШЕР-Ү** «задвигать; запирать» — *ишер-ү* сүзеннән (*иш-ү* фигыленең йөкләтү юнәлеше формасыннан).

# -Ю-

**ЮА** «дикий лук (чеснок)» — диал. *юа суган* «кыргый суган» дигәннән кыскарган, башк. *йыуа*, н. *юа*, кк., кырг. *җуа* «кыргый сарымсак», уйг. *йауа* «кыргый», тат. диал. *йуа, йыуа, йаwа* «кыргый» — фарсы. *йаwаи* «кыргый» сүзеннән (шуннан ук себ. тат. *йабайы* «одичалые; растущие самосевом культурные растения», кырг. *җапайы* «кыргый», башк. *йабай* «гади, садә». К. удм. *юатурын* «юа» («дикий лук»: *юа* «кыргый», *турын* «кыяклы үлән»). К. **Ябай**.

**ЮАН** «толстый» — кк., ккк. *җуан*, кырг. *җоон*, алт. *д'оон*, уйг., куман. *йоған*, угыз., бор. тк. *йоғун* «юан, зур, калын» бор. тк. *йоғ-, йоқ-* «юан, биек, югары; югарылану, үсү» сүзеннән.

**ЮАН-У** «утешаться, утешиться» — тат. диал. *йобан-, йобат-* ~ чув. *йăпан-, йăпат-*, удм. *йыван-, йыват-* < гом. тк. *йубан-, йубат-* id. бор. тк. *йуба-* «тынычлау, тыныч итү» фигыленнән. Семантик күчешләр нәтиҗәсендә бу сүзнең капма-каршы мәгънәләре дә килеп чыккан; к. тат. диал. (себ. тат., урал) *йобау* «арык, ябыккан, боек» ~ чув. *йăпас* «юаныч», *йăпар* «арык», кум. *йыбав* «күңелллелек»; кырг. *җобо-* «баш әйләндерү; кайгыру, кайгырту» ~ хакас., тув. *чобаƣ* «арыган, боек», *чоба-* «ару, тынычсызлану» ~ якут. *собо-* «арыклану, ябыгу». Бер яктан «арыклану, кайгыру, боегу», икенче яктан «юану, шатлану» мәгънәләре «тып-тыныч булу» мәгънәсеннән генә килеп чыга алалар. Шуңа күрә сүзнең борынгы тамыры **йоп//йоƣ* (~ чув. *йăп*) «тыныч, сүзсез» дигән мәгънәдә булган булса кирәк. Чаг. ш. ук мар. *юван-* «әкренәю, тынычлану»; себ. тат. *йуак* «юаныч, шатлык».

Монг. *җога-*, тув. *чоға-* «юату, сыйлау, тынычландыру; әкиятләр, кыйссалар сөйләү» (шуннан монг. *җогагул* > тув. *чогаал* «хикәя, кыйсса, әкият ~ юаткыч») сүзе дә *йоба-* фигыле белән бер булса кирәк.

Тат. диал. *юбалгы* «ялкау» сүзе дә *йоба-* фигыленнән.

**ЮАЧА** «пряженец» — Егоров буенча, чув. *йăва, йăввача* «юача, кош оясы сыман камыр ашы» — чув. *йăва* «кош оясы, оя» сүзеннән. Әмма бу этимология ясалмарак. Безнеңчә чув. *йăвача*, мар. *уяча*, удм. *юача*, башк. *йыуаса* «әчегән камырдан пешерелгән күмәч», бор. тат., болгар. **йыуа, *җыуа* «әчегән (камыр)» сүзеннән; к. чув. *ҫăвак, ҫĕвек* «әчегән, әче исле», *ҫĕве* «оеткы, оетырга куелган катык».

**ЮАШ** «смирный, тихий» — бор. тат. *йубаш*, бор. тк. *йоба-* «тынычлану» (к. ш. ук *юан-у, юат-у*) *йоп* «тыныч» сүзеннән.

**ЮГАРЫ** «верхний, верх» — чыгт. *йоққари* «югары» — бор. тк. (МК) *йоқ* «биеклек, биек җир» сүзеннән (*йок-кары* «биеккәрәк, биеккә»); к. ш. ук бор. чыгт. *йокла-* «күтәрелү, менү» (Боровков). К. **Юан**.

**ЮЕШ** «мокрый, мокрое место» — гом. диал. *җүеш*, башк. *йеүеш* — бор. тат. *җебеш, йебеш* «җебегән» сүзеннән (к. *җепшек* < *җебеш-ек*), *җебе-у* (к.) фигыленнән.

**ЮК** «нет» — гом. тк. *йоқ* «юк, ярлы» — бор. тк. *йоғук, йаwуғ* «юк, югалган» сүзеннән, госм., бор. тк. *йа-, йағ-ы* «югалу, юк булу» фигыленнән (шуннан ук к. **Җуй-у**), сүзнең тамыры — бор. тк. *йағ, җағ, д'аг* «юк» (шуннан бор. тк. *даг ол* «түгел» дигән фикер бар).

Бор. тк. *йоқ* сүзе күбрәк исем мәгънәсендә («кытлык, ярлылык») кулланылган. Шул нигездә гом. тк. *йоксул* > тат. *юксыл* сүзе килеп чыккан.

**ЮКА** «тонкий; худощавый» — гом. диал. башк. *йока*, алт., госм. *йувқа*, уйг. диал. *йупка*, бор. тк. *йуфка* «юка», кк. *җука* «ябык», тат. диал. *җокак* «какча, ябык» — ихтимал, бор. *йабук-ак* «ябык, нечкә» сүзеннәндер (к. **Ябык**); к. ш. ук бор. тк. (МК) *йувға* «катлы, катмарлы», тат. диал. *йуқа*, госм. *йуфқа* «катланган тәбикмәк, катлама». Чаг. **Юкә**.

**ЮКӘ** «липа; лыко» — кум. *йөгэ*, кк., кб. *җөкэ*, азәрб. *чөкэ*, чув. *ҫăка* «юкә», кк., ккк. *җөкэ* «юкә мунчала, сүс, кап», бор. тк. *йуфка* «катлы-катлы» (к. **Юка**) сүзеннән булса кирәк, алт. диал. (шор.) *чуға* «юка (тонкий), юкә (липа)», кк. *җөкэ киндер* «киндер», тат. диал. *юкә кабык* «юкагач яки карама кабыгы». К. **Юкәр**.

**ЮКӘР** «луб» — *юкә* (к.) сүзе белән бәйләнешле.

**ЮЛ** «дорога, путь» — гом. тк. *йол*, алт., якут., бор. гом. тк. *д'ол* «юл, бәхет» сүзеннән (к. тат. *Юлга чыккан кешегә юл булсын* дип уңыш телләү); к. ш. ук диал. (себ. тат.) *йулақ* «буй-буй», *юлла-у* «выслеживать, выискивать», *юллан-у* «направиться». Сүзнең беренчел мәгънәсе «сәфәр, берәр йомыш белән (чаг. *йомыш* «юл») йөрү» булган булса кирәк; к. якут. *суол* «юл, урам, рәт, эш, очрак, мәртәбә», бурят. *зол*, монг. *жол*, тув. *чол* «уңыш, бәхет, өлеш, чират». К. **Юлык-у**.

**ЮЛӘР** «дурак; глупый» — алт., бор. тк. *д'үүл-, йүүл-* «акылдан язу» фигыленнән (*йүл-әр, йүүл-әр*); сүзнең тамыры — **йүг-* «җенси теләк».

**ЮЛБАРЫС** «тигр» — гом. тк. *йолбарс* «юлбарыс» — *юллы барыс* «полосатый барс» сүзеннән.

**ЮМА: юма телле** «льстивый» — асылда диал. *уйма* «өч, биш җәпле яссы бау» < бор. *йаума* id.; *йау-* > чув. *яв-* «күп җәптән ишү» сүзеннән.

**ЮМАРТ** «щедрый» — иске әд. *җәванмард* < фарсы. *җәванмард* «ир-егет; юмарт» сүзеннән (*җәван* «яшь», *мард*. «ир кеше, чын ир»).



**ЮНЬ** «толк, способность; недорогой» — гом. тк., бор. тк. *йөн* «юнь; халык; чират» сүзеннән. К. Әхмәтьянов, 1989: 109 — 110.

**ЮРГА: юрга ат** «иноходец» — гом. тк. *йорға*, алт. *д'орға* «юрга» — бор. тк. *йоғур-(а)-ға* «юыртучы» сүзеннән; к. бурят. *жороо, жорого* «юрга». К. **Юырт-у**.

**ЮРГАН** «одеяло (стеганое)» — тат. диал. *юырган*, алт. *д'уур-кан*, чыгт. *йаwуркан*, бор. тк. (МК) *йоғуркан* «юрган, иләнгән тиредән торган ябынча» — бор. тк., уйг. *йоғур-* «иләү, йомшарту» сүзеннән. Чув. диал. *юркан*, мар. *йорган*, удм. диал. *ӟурган* «юрган» — татарчадан.

**ЮРИ** «нарочно» — *юра-у* фигыленең адвербиаль *юрый* формасыннан; к. диал. *йурамалы* «юри», *йурап әйтү* «сынап әйтү», *йуралата* «юри». Тат., башк. *йура-* < гом. тк. *йора-*, бор. *йор* «ырым, хикмәтле белге».

**ЮСЫК** «закон, обычай (*церемония на приеме у хана*); направление» — тат. диал. *җусық -җурык, йусын- йурын, җурын* (эчкен, урал) «рәт, юнь, тәртип», башк. *йусық, уйңсық* (!), *йурық*, н. *йосық*, алт., хакас. *йозоқ, йозақ* «тәртип, үрнәк, кагыйдә» — бор. монг. *йоз, йор* «гадәт, йола» сүзеннән. Бор. тк. *йоруқ* «закон» сүзен *йөр-у* фигыле белән дә аңлаталар, әмма бу шикле. К. ш. ук кытай. jo «закон, кагыйдә» < jon*.

**ЮТӘЛ** «кашель» — ачык түгел, кар. *өтәл* «ютәл», үзб. диал. *йүтәл-* «ютәлләү». Чаг. *йөт-кер-у*. Тамыры — *йүт*.

**ЮХА** *миф.* «многоголовая змея» — башк. *йуха*, чув. *йухха* «юха елан» ~ удм. *юхо*, мар. *юка* «юха, ялагай». *Юха, йувха* образы төрекмәннәрдә очрый. Риваять буенча, мең ел яшәгән елан аждаһага, тагын мең ел яшәгән аждаһа, һавага күтәрелеп, юхага әверелә, имеш. Нәкъ шушы риваять кытайларның «Шуцзин» китабында китерелә: мең ел яшәгән елан аждаһага, ә биш йөз ел яшәгәч, канатлы аждаһага (*л'унга*) әверелә (к.: Иванов С.В. Мамонт в искусстве народов Сибири. Сборник музея антропологии и этнографии. 16-е изд. М., 1949. — С.136 — 137). *Люнхуа* «аждаһа кыз, аждаһа гүзәл» сүзе борынгы төрки телләрдә *люха* булып, аннары *юха* яңгырашын алган булса кирәк. Кытайча *люн* һәм *люң* «аждаһа» сүзләре татар телендә *ләү* янгырашында да яши. К. **Ләү**. К. Әхмәтьянов, 1981: 56 — 57.

**ЮШ: юраган юш килү** «исполнение желаний» — кк. *җош*, ккк. *йош* «илһам», уйг. *йуш, йус* «начар юрау, начар билге» — фарсы. *җош* «кайнау, илһам, дәрт» бор. тк. *йош* «шаман юравы» сүзеннән. Чаг. **юшкын**.

**ЮШКӘ** «вьюшка» — рус теленнән.

**ЮШКЫН** «накипь; осадок» — диал. *д'ушкын* «ләм, юшкын», чув. *юшкăн* «ләм (ил), юшкын», госм., бор. тк. *җуш-, йуш-* «кайнау» бор. тк. (МК) *җуwша-, җаwуш-* «кайнап күбекләнү» фигыленнән; к. тат. диал. (себ. тат.) *йауышқын* «юшкын», үзб. *җушқын* «кайнап торган», *җуш ур-* «кайнап, пар бәреп тору», уйг., кк. *җушкун* «кайнау»; фарсы-тадж. *җош, җуш-* «кайнау» сүзе дә төрки телләрдән булса кирәк; сүзнең (бор. *җаwуш-* фигыленнән) тамыры ачык түгел. К. **Юш**.

**ЮЫРТ-У** «бежать рысью» — диал. *юыр-у, югыр-у* «юыртү» бор. тк. *йоғур-* «чабу, йөгерү» сүзеннән булса кирәк. К. **Йөгерү, Юрга**.

## -Я-

**Я I** *межд.* «о!» (*я, хода!* — «о боже!» — ~ госм., алт. *йа* «я» — *ай* (к.) кебек үк килеп чыккан булса кирәк, ләкин татар теленә гарәп-фарсы тәгъбирләре аркылы (гар., фарсы. *йа* «я!») кергән. Чаг. рус. **О**!

**Я II** *союз* «или... или» — гом. көнб. тк. *йә* (*йә... йә*) — фарсы. *йа* (*йа... йа*) теркәгеченнән.

**Я III** «ладно, хорошо» (диал. җә, алт., якут. *чә*, монг. *йа* «я (согласен, ну что, ладно)» — **Я** *I* кебек үк килеп чыккан сүз булса кирәк; чаг. гар. *ийә* «я (ну)», немец. ja «әйе».

**ЯБАГА** «шерсть-линька (*весенняя*)» — ~ башк. *йабаға*, кк., ккк. *җабағы*, госм., чыгт. *йапақ, йапағы*, бор. тк. *йабаку, йапағу* «ябага йон» — бор. тк. *йап* «ябага».

**ЯБАГАЙ** «бедняк» — монг. *йабу-ғай* «атсыз, җәяүле» дигән сүздән (монг. *йабу-* «җәяү йөрү»); чаг. алт. *йокту-йойу* «ярлы-ябагай».

**ЯБАЙ** *диал.* «дикий; одинокий; дикорастущий» — ~ себ. тат. *йабайы* «кыргый арыш», башк. *йабай* «кыргый, садә; кечкенә буйлы ат токымы», кк. *җап, җаба, җабайы, җәбә*, кум., н. *йабу, йәбә* «кечкенә ат токымы; кыргыйлашкан ат, кыргый ат». Борынгы кыпчак далаларындагы кыргый атлар, күрәсең, кечкенә буйлы, кечкенә колаклы (к. **Ябалак**), бик зур яллы, көлтә койрыклы булганнар (к. ш. ук хакас. *чаба*, бурят. *җаа* «ябык»). Чыгышы буенча *йабай, йабайы-* фарсы. *йаwаи* «кыргый» сүзеннән; к. кырг. *җапайы, җабай* «кыргый, кыргыйлашкан». К. **Юа, Япан**. К. Әхмәтьянов, 1975: 73.

**ЯБАЛАК I: ябалак кар** «снег хлопьями» — к. кк., ккк. *җапалақ, җалпалақ*, кум. *йапалақ* «ялпак, юка, йомшак (*кар турында*)», мар. *явалак* «юка, юка гөмбә», бор. тат. *ябалак, ялбалак* «юка, ялпак» сүзеннән. К. **Ялпак**.

**ЯБАЛАК II** «сова» — тат. диал. (себ. тат.) *йапқулақ, йапқылақ*, кк. *җәбә колак*, хакас. *чаба хулах*, бор. тк. (МК) *йабақулақ* «ябалак» — *йаба кулак* «ябай ат колагы шикелле колаклы» сүзеннән (к. **Ябай**). Ябалаксыман кошларның кечкенә каурый колаклары була. Бу кошларны *йаба колак* дип атау, ихтимал, «Табу» йоласыннан килеп чыгадыр.

**ЯБАЛДАШ** «крона (*дерева*)» — диал. *йабалдак, җабалдаш, йабалгы, йәбәлдәш* «таралып, җәелеп үсә торган; тәбәнәк; юан» (тау ягы, керәшен.), кырг. *чапалдаш* «тәбәнәк юан; лапакай», тув. *чарба* «ялы ике яклы (ат)», алт., монг. *сарбагал, сарбагар* «ябалдашлы». Сүзнең тамыры — тат., гом. тк. *ярпа / ялпа* «киңчә, киңәйгән»; шуннан тат. *ялпай-у, ярпай-у* «киңәю; шәпләнү; мактану».

**ЯБӘЛӘ, ЯБӘЛКӘ** «толк; роскошь» — чув. *япала*, мар. *явла, лӓвӓла, лавала* «мебель; кирәк-ярак» — чыгт. *йәбәлкәр*, кырг. *җәбилге*, монг. *җәбәлку* «сугыш атының көбәсе, парад атының бизәлү дирбиясе» сүзеннән булса кирәк; чыгышы монголчадан.

**ЯБЫК** «худой; закрытый» — бор. тк. *йабы-ғ* «ябыккан». Бу сүз төрки телләрдә сирәк очрый. Мар. *йавык*, чув. *йапӑх*, удм. *җабък* «ябык; начар» — татарчадан. Сүзнең тамыры — алт. *йабы* «начар»; чаг. ш. ук бор. тк. *йаблақ* «яман, начар, явыз». К. **Явыз**.

**ЯВЫЗ** «злобный» — уйг. *йабус* «явыз, усал», бор. тк. *йафуз* (МК), *йабыз* «начар, әшәке» — бор. тк. *йап // д'ап* «начар, усал, чирле, кечкенә» сүзеннән (к. **Ябык**, **Ябырыл-у**); к. ш. ук алт. *д'абыс* «түбән; усал, явыз», тув. *чавыс*, хакас. *чабық* «түбән, тәбәнәк, ябык», алт. *дабыза-*, тув. *чавыза-* «түбәнәю, төшү».

**ЯЗ** «весна» — гом. тк. *йаз* «яз; җәй» — бор. гом. тк. *д'аар* «язгы, җәйге мизгел» сүзеннән; к. якут. *саас* ~ чув. *ҫур* «яз». Монг. *нар* «яшь; яшеллек» сүзе белән чагыштырыла.

**ЯЗЫ** *диал.* «большое поле, долина, степь» — гом. тк. *йазы* кк., ккк. *җазык* id. бор. гом. тк. йаз-ыг «җәелгән, язылган» — гом. тк. *йаз-* «җәю, язу» (вариантлары — *йай-, йат-, йад-, йар-* (чаг. чув. *ҫыр-* < *йар-* «язу»).

**ЯЗЫК** «грех; проступок» — көнч. тк., госм., азәрб. *йазық*, хакас. *чазых*, бор. чыгт. *йазуқ*, алт. *д'азык* «язык, җинаять, ялгышлык, бәла-каза» — бор. гом. тк. *даз-* «язу, ялгышу, югалту» сүзеннән (*йаз-ығ* «ялгышлык, хата»); к. ш. ук чув. *ҫылӑх* «язык, гөнаһ» < **җар-лык ~ *йазлык* «язык, хата» ~ тат. диал. *йазлық-у* «ялгышу».

**ЯК** «сторона» — уйг., чыгт., бор. тк. *йақ* «як, кабырга, тыш, вакыт юнәлеше» — төрлечә аңлатыла. Бор. тк. *йағы* (к. **Яу**) «дошман; чит, ят» сүзе белән тамырдаш дип тә, бор. тк. *йак-, йагу-* «якынлашу» (к. **Якын**) сүзенә тамырдаш һәм тат. *йага*, гом. диал. *йақа*, алт., чыгт., үзб. *йака*, бурят. *заха*, монг. *җака* «кырый, яр, як, ян» сүзеннән дип һәм, ниһаять, *яңак* (к.) сүзеннән кыскарган дип тә аңлатыла. Чаг. ш. ук шумер. ag «як, чик; чүл».

**ЯКА** «воротник» — гом. диал. *йақа, йаға* «сторона, край, чужбина», гом. тк. *йақа, йаға* «яңа, кырый, чит, яр», хакас. *чаға* «билбау, кырый, яка», алт. *дӯака, д'аха* «яка, кырый, як, доха (*йоны тышка калдырып тегелгән тун*)», якут. *саға* «яка, як, кыр», монг. *җака*, бурят. *заха* «кырый, яр, яка».

**ЯКТЫ** «светло; светлый» — башк. *йақты*, кк., ккк. *җақты*, ткм. *йағты*, бор. чыгт. *йағту* «якты» — бор. *йағыт-ығ* «яктыртылган» сүзеннән, бор. тк. *йағыт-, йақ-ыт-* «чырага ут ягу» фигыленнән, *йак-* (к. **Як-у**) нигезеннән; к. чув. *ҫутӑ* «якты», *ҫут-* «ягу, яндырып җибәрү» (<**җағыт-*), бор. тк. *йаwды // йағды* «якты».

**ЯКЫН** «близкий» — башк., госм. *йақын* «якын», кк. *җакын* «якындагы» — гом. тк. *йаwуғ* «якындагы» нигезеннән (*йаwук-ын*); к. себ. тат. *йуық, йаwық*, мишәр. *җыwык*, чув. *ҫывӑх*, ккк. *җауық, җуук*, азәрб., чыгт., бор. тк. *йаwуқ* «якын» бор. тк. *йакуғ* «якынлашкан, якынайган» сүзеннән, бор. *йақ-, йағ-* «якынаю» (чаг. *як-у* «ошау») фигыленнән булса кирәк.

**ЯЛ I** «грива» — гом. тк. *йал*, алт. *д'ал*, тув. *чэл*, хакас. *чилен*,

якут. *сиэл* «ял, җилкә тамыры, җилкә» — бор. гом. тк. *д'ал* «ят ялы» сүзеннән, к. ш. ук монг. *дэл* «ял», уйг. диал. *йайл* «ял». К. **Җилкә**.

**ЯЛ II** «чаевые; плата» — алт. (диал.), кар. *йал*, алт. *дӯал*, тув., хакас. *чал* «түләү, ял» — бор. гом. тк. *д'ал* «ял» сүзеннән.

**ЯЛ III** «отдых» — чув. *йул* < *йал*, мар., удм., н., кум. *ял* «ял; хәл», бор. монг. *җали* id. бор. тк. **йал-* (*йа-л-*) «ял итү» сүзеннән. К. **Ялык-у**.

**ЯЛА** «клевета; донос» — гом. тк. *йала, җала* «яла», алт. (диал.), куман., тув. *йала* «гаеп, җәза», алт. *д'ала*, монг. *җала* «штраф» — бор. гом. тк. *дал-аг* «штраф, түләү, гаеп» сүзеннән. *Ялган, ялгыш* сүзләре белән тамырдаш булса кирәк.

Бу сүзләрнең тамыры **йаң* «ялгышу, ялгыш» булса, *йала* < *йаңлаг, йалған* < *йаңылгап, йалгыш* < *йаңылыш.*

**ЯЛАГАЙ** «льстивый» — башк. *йалагай*, кк., ккк. *җалагай*, алт. *йалаккай* «ялагай», монг. *залхай* «ялкау, ялагай» — *ялкау* (к.) һәм *ялын-у* (к.) сүзләре белән бәйләнгән сүз; к. ш. ук тат. диал. *җалак* «әрсез, ялагай», мар. *йолагай, йалакай* «ялкау», бурят. *чалахай* «иркә, юаш, күндәм, ялагай».

**ЯЛАН** «поле; степь; луг» — тат. диал. (себ. тат.), гом. тк. *йалаң* «ялан, ялангач; ялгыз», бор. тк. *йалың* «ялан, ялангач», чув. *йалам* «болын», алт. *д'алаң* «ялан, басу, кыр» — бор. гом. тк. *далаң* «киң бушлык, буш дала» сүзеннән; к. **Ялангач, Ялгыз**. К. Әхмәтьянов, 1989: 28.

**ЯЛАНГАЧ** «голый» — угр., кк., үзб. *йалаңач*, кырг. *талаңаш*, алт. (диал.) *д'алāш*, хакас. (диал.) *чалāс* — гом. тк. *йалаң* «ялан, ялангач» сүзенә кечерәйткеч *-ғач* элементы ялганып ясалган сүз; к. ш. ук уйг., бор. тк. *йалың*, госм., уйг. *йалан, йалын* «ялангач», эвен. *нулаки, жулакин* «ялангач». К. **Ялан, Ялгыз**.

**ЯЛАУ** «повязка; флаг; петличка для пуговиц» — чув., чыгт. *йалау* «флаг, бүреккә беркетелгән ефәк тасма», *йәләү* «сөнге очындагы байрак», тат. диал. (себ. тат.) *йалау* «байрак, флаг, байрак сабындагы чук», монг. *җалага*, бурят. *залаа* «бүрек очындагы чук (еш кына ат ялыннан эшләнә), серкә (тычинка)»; *җиле* (к.) сүзе белән тамырдаш булса кирәк; к. чув. *йӑлӑ* «ялау, җиле», алт. (диал.) *йалаға* «бүрек бавы, бантик», *йәлә* «бау, тозак, ат бәйләү арканы», бор. тк. *йалаба* «чачак, чук»; мар. *йалба* «чук» — төрки телләрдән. К. Әхмәтьянов, 1989: 146.

**ЯЛБЫР** «лохматый; мохнатый» — гом. тк. *йалп // далп* «җилфердәгән нәрсә» тасвирый янгырашлы сүздән (*йалпыр*); к. кк., ккк. *җалбыр* «ялбыр», *җалба, җалба-җолба* «ялбыр, иске-москы», алт. *дәлбәр* «ялбыр», бурят. *далбагар* «ялбыр, салпы», *далбы-* «ялбырдау» сүзенең тамыры гом. тк. *сал // тал // дал // йал* (к. **Җил**); чаг. кырг. *салбыр* «ялбыр».

**ЯЛГАН** «ложь; лживый» — бор. *яңгыл-ган* «ялгышлык булган» сүзеннән; к. диал. (мишәр.) *яңгал, яңгалан* «ялган»; к. ш. ук чыгт., уйг., бор. тк. *йалган* «ялган сүз». К. **Яла**.

**ЯЛГЫЗ** «одинокий» — чыгт. *йалғыз*, башк. *йаңгыз*, бор. чыгт. *йалгуз*, кк. *җаңгыз*, тув. *чаңгыс*, бор. тк. (МК) *йалынус, йалыңгук* «ялгыз, бер генә, гел, бердәм» (бор. **йалуң-ург* «ялгыз, берүзе») сүзеннән, гом. тк. *йалаң, йалың* «буш җир» нигезеннән; к. кырг. *чалкы* «бердәнбер, так», тув. (диал.) *д'алаң* «өйләнмәгән, ялгыз», калм. *йалың* «ялгыз», чаг., тат. диал. *йалғыз* һәм *йалан* «гел бер төрле» мәгънәсендә. Төрки фольклорда *йалғыз* «бермә-бер көрәшкә чыккан герой». К. Әхмәтьянов, 1981: 55—56.

**ЯЛКЫН** «пламя» — гом. тк. *йалқын*, алт. *д'алкын*, тув., хакас. *чалын* «ялкын, яшен» — алт., гом. тк. *йал(ы)-, йалкы-, дал(ы)-* «ялкынлану, яну, дөрләү» фигыленнән (*д'алы-кын*). К. тат. диал. *йалкы-* «ялкынлану». К. шумер. *ẓal* «ялтырау, яктыру».

**ЯЛПАК** «плоский» — диал. *җалпак* «җәенке», кк. *җалпак*, үзб. *чалпак*, хакас. *чалбах*, алт. *далпак* «ялпак, киң, җәенке, җәйгән» — бор. гом. тк. *далп* «җилферди торган, яссы» тасвирый янгырашлы сүзеннән; гом. тк. *сал // тал // дал // йал* (к. **Җил**) тамырыннан булса кирәк; к. ш. ук бурят. *җалбагар, далбагар* «ялпак, киң».

**ЯЛМАВЫЗ** «чудовище» — диал. (себ. тат.) *йалмауыз* «убыр», *йалмау-ыц* «ындыр себеркесе», алт. *чулмус* «убыр, хәйләкәр», *шулмус* «циклоп» — бор. тк. *йалмагур* «ашап туймас, убыр, өрәк» *йалма-у* «ялап кабу» сүзеннән; к. себ. тат., алт. *йалмауыр, йалмуур* «себерке», *йалма-* «себерү». К. Әхмәтьянов, 1981: 57.

**ЯЛЫГ-У (ЯЛЫК-, ЯЛК-)** «уставать *от чего-л.*» — гом. кыпчак., алт. *йалк-, җалык-* id. бор. *йал-* «ял итү» фигыленең интенсивлык формасыннан булса кирәк. Чаг. *ялкау* «лентяй» ~ кк., ккк., тат. диал. *җалкау*, кырг. *җалкоо*, тув. *чалгаа* id.

**ЯЛЫН-** «умолять» — чув. *юлан-* < *йолан-*, гом. кыпчак. *йалын-, җалын-.*

**ЯМАН** «плохой, скверный, ужасный» — диал. *җаман*, гом. тк. *йаман* «яман, әшәке». Ышандыргыч этимологиясе юк. Чаг. бор. һинд-иран. yama «җир асты алласы; шайтан».

**ЯМАУ** «пришить заплату; штопать; чинить» — гом. тк. *йама-*, алт. *д'ама-*, монг. *җама-*, эвен. *нама-* «ямау, төзәтү» — тамыр бәйләнешләре ачык түгел.

**ЯМЬ** «красота, краса» — диал. *ийәм, җәйәм* (касыйм.), башк. *эйәм*, тат. диал. *иләм, иеләм,* чув. *илем* «матурлык, ямь», кк. диал. *җам*, мар., удм. *йам* «матурлык; шатлык».

**ЯН- I** «гореть» — гом. тк. *йан-*, кырг., тат. диал. *җан-* > чув. *ҫун-*.

**ЯН II** «бок; сторона» — гом. тк. *йан* «ян, бер як, кыек», алт. *д'ан* «ян» — «ностратик» *йаң // аң* (к. **Яңак**) тамыры белән бәйләнешле булса кирәк. Төрки *йан* үзе дә бик продуктив нигез; к. тат. диал. *йанбыз* «янбаш, арт утыргыч», *йанта-у* «тигезләп юну», *йантай-у* «бер якка авышу», *йантық-* «бер як чит, кыеклык»; *янәшә* < *янаша* «рәттән» — *янаш-* «янга утыру» фигыленнән.

**ЯНЧЫК** «кошелек» — алт. *йанчык, д'анчык* «янчык, кесә», госм. *янҗык* «ат сыртына ябу, ияргә тагылган сумка», бор. тк. (МК) *йанлык* «көтүчеләр сумкасы» — гом. тк. *йāн* «ян; кесә»

сүзеннән (к. **Ян**). Удм. *янчик*, мар. *йанзык*, чув. *енчĕк* < тат. диал. *йәнчек* id.

**ЯНӘ** «снова, опять» — тат. диал. *җәнәтән*, госм., чыгт. *йәнә*, бор. тат., чыгт., куман., *йана*, бор. тк. (МК, Орхон) *йана* «янә, тагы, кирегә, кайтадан» — гом. тк., бор. тк. *йан-* «әйләнеп кайту» фигыленен адвербиаль формасыннан (*йан-а*); чаг. тат. диал., башк. *кайта* (*кайтадан*) «янә, янадан». *Янәсе* < *янә-се*.

**ЯҢА** «новый» — гом. тк. *йаңы, йаңгы*, алт. *д'аңы* ~ якут. *саңа*, чув. *çенĕ* «яңа», монг. *җаңги* «яңа хәбәр», калм. *зәңги* «яңалыклар» — чыгт., уйг., бор. тк. *йаңгу* «яңгырау (эхо)» сүзеннән булса кирәк; бу сүз исә алт., уйг., бор. тк. *йан-* «кайту, әйләнеп кайту» фигыленнән; «әйләнеп кайту → яңа булу» мәгънә күчеше төрки телләрдә еш очрый. К. **Янә**.

**ЯҢАК** «щека; косяк» — диал. *йанақ*, госм. *йанак*, гом. тк. *йаңак*, алт. *д'аак, д'аңак*, тув. *чаақ, чаңак*, тув. (диал.) *наақ*, якут. *сыңах* «яңак», уйг., ткм. *йаңак* «янак, ияк», чув. *йанах* «ияк», бор. тк. *эңгәк* «ияк», госм. *әңәк* «аскы янак», уйг. диал. *иңәк* «челюсть; подбородок», тат. диал. (мишәр.) *җәйәк* «яңак», *йайак* «ияк» (кум. *йайак* «яңак»), бурят. *шанага* «яңак; чүмеч» — күп телләрдә очрый торган *аң // йаң* «янак, урт, аскы яңак, ян, авыз» тамырыннан; к. бор. тк. *әң* «йөз, яңак», госм. *аң* «яңак», удм. *ан* «урт, янак», ханты. *аңэн* «ияк», венг. *эң* «анкау, урт», монг. *җақ*, үзб. *җағ*, кк., ккк. *җақ, җаң* «янак», бор. тк. (МК) *аң* «янак», гар. *җаниг* «ян». Чаг. **Аңкау, Аяк II, Ияк, Чана. Канат, Саңак, Ян**.

**ЯҢГЫР** «дождь» — диал., башк. *йамғыр*, уйг., куман. *йаңғур*, чыгт. *йағмур* «яңгыр, явым» — бор. тк. *йағ-* «яву» сүзеннән (*йағмур* «ява торган нәрсә, явым-төшем»). К. **Яу-у**.

**ЯҢГЫРА-У** «раздаваться (*о звуках*)» — гом. тк., гом. монг. яңгырауны белдерә торган *саң // таң // даң // йаң* тасвирый яңгырашлы тамырыннан (*йаң-ғыр-а-ғ* «звон»); к. башк. *шаң* «яңгыравык», монг. *хаңира-* «яңгырау». К. **Чаң, Кыңгырау**.

**ЯПАН** «степь; долина» — кырг. *җапам*, бор. кыпчак. *йабан* «япан» — фарсы. *йаwwайин* яки *бийабан* «кыргый дала» сүзеннән. К. **Ябай**.

**ЯПЬ** «развилка; развилина (напр., у вил)» — чув. *йупа, йуп* «япь», *йуп-* «бер якка җибәрү» — нииндидер *йап-* фигыленнән; чаг. чыгт. *йап*, кк. *җап* «каналдан тармакланган арык», бор. монг. *җаб* «ара (промежуток)»; к. ш. ук тат. *җәпләшкә* «ике япьле сәнәк; ухват», кк. *җаба*, чыгт., госм. *йапа* «ике җәпле сәнәк».

**ЯР I** «берег; обрыв» — гом. тк. *йар* «яр» сүзеннән; к. ш. ук диал. (себ. тат.) *йарлау* «бәке». Чаг. *яр-у* «разрывать».

**ЯР II** «возлюбленный; милый» — фарсы. *йар* «дус, яраткан кеше» сүзеннән; иске әд. *йаран* «сопровождающее лицо» — фарсы. *йаран* «дуслар» дигәннән (*йар* сүзенең фарсыча күплек формасы); шуннан ук тат. диал. *җәрән* «әшнә, дус».

**ЯРА** «рана» — гом. көнб. тк. *йара* «яра, җәрәхәт» — фарсы. *йара* «яра, җәрәхәт», бор. фарсы. јаrа «беләзек; богау» сүзеннән (ягъни, *йара-* «богау кискән урын»). *Яр-у* фигыленнән дә чыгаралар.

**ЯРЛЫ** «бедный» — гом. кыпчак. *йарлы* «ярлы, мескен» — бор. уйг. *йарлыг* «ярлы, мескен, ярлыканмыш кеше (МК)», кк. *җарылы*, алт. диал. *йарылығ* «ярлы» бор. тк. *йар* «чакыру, сөрән, тревога» сүзе белән бәйле; бор. тк. *йарлығ* «ярлы» — ниндидер бер закон буенча кимсетелгән кеше булган булса кирәк. Чаг. ш. ук чыгт., бор. тк. *йары* «ярдәм» яки бор. *йаргы* «суд». К. **Ярлык**.

**ЯРЛЫК** «ярлык, письменный указ» — гом. тк. *йарлық*, монг. *җарлык, зарлиг* «ярлык, игълан, белдерү» — гом. тк., монг. *йар, җар* «кычкырып әйтелгән белдерү, сөрән». Шуннан ук бор. тат. *йарғы* «суд». К. Әхмәтьянов, 1981:103.

**ЯРМА** «крупа» — чыгт. *йарма*, алт. *д'арма* «ярма» — *яр-у* (*йар-*) сүзеннән (*йар-ма*).

**ЯРТЫ** «половина» — кар. *йарты*, кк., ккк. *җарты* «ярты» — *яр-у* (*йар-*) фигыленнән (*йар-ын-ты* формасыннан булса кирәк).

**ЯРЧЫК** «осколок» — кк. *җаркын, җаркынчак, җаркынчык* «ярчык», алт. *д'арчага* «ярка, пүлән» — бор. тк. *йарын-чык* «ярылган кисәкчек» сүзеннән булса кирәк; чаг. ш. ук бор. тк. *йарту* «ярчык, йомычка» (МК). К. тат., гом. тк. *яр-у* «икегә бүлү; җәзалау».

**ЯРЫ I** «плевра, перепонка» — бор. тк. (МК) *йағры, йақры* «эч мае» сүзеннән, сүзнең тамыры — гом. тк. *йағ* «май». К. **Җау**.

**ЯРЫ II: бер яры киткәндер** «он, наверно, ушел *куда-нибудь*» — бор. *йак-кары* (к. **Як**) сүзеннән.

**ЯРЫЙ** «ладно; согласен» — тат., гом. тк. *яра-у* фигыленнән. Шуннан ук *ярат-у, яраш-у* > *йәрәш-ү*. К. Әхмәтьянов, 1981: 100 — 101.

**ЯРЫМ** «половина» — гом. тк. *йарым* «ярым», гом. тк. *яр-у* «расколоть» фигыленнән (*йар-ым*).

**ЯСМЫК** «чечевица» — чув. *йасмык*, кк., ккк., кырг. *җасмык*, н. *йасмық*, үзб. *есмик*, уйг. диал. *йесимуқ* «ясмык»; ясалышы һәм чыгышы ачык түгел, ихтимал, гом. тк. *яссы* (к.) сүзеннәндер (Егоров); к. ш. ук бор. рус. *ячьмыкъ* «арпа (ячмень)».

**ЯССЫ** «плоский» — тат. диал. *йасты, йасту, ятсы* «яссы, яссылык» (*кул йатсысы* «кул яссылыгы») — бор. тк. *йастығ, йастуғ* «җәелгән, язылган нәрсә» сүзеннән, бор. тк. *йаста-* < *йасла-* < *йаз-ығ-ла-* «җәю, язу» фигыленнән (тамыры — *йаз-*; к. **Яз-у II**). К. **Ястык**.

**ЯСТАУ** *диал.* «воспитанность» — чув. *юстав* id. — иске. тат. *яста-* «тәрбияләү» сүзеннән; шуннан ук тат. диал. *ястанлау* «әдәп белән сөйләп, үзеннекен итү» ~ якут. *сыстаң-* id. К. **Ястык**.

**ЯСТЫК** «пуховая подушка» — госм., кырым., куман. *йастық* «ястык, мендәр, колонна, тәплек» — алт. (диал.), чыгт., госм., бор. тк. *йаста-*, алт. *д'аста-* «таяну, яссы итү, җәю, кешегә якынлаша белү» фигыленнән; к. ш. ук тат. диал. (себ. тат.) *йастан-у* «терәлеп яту, нигезләнү; нигезләү (*фикерне*)»; сүзнең тамыры — гом. тк. *йаз-* «җәю; җәенке булу». К. **Яссы**.

**ЯТ** «чужой, посторонний» — гом. тк. *йат*, алт. *д'ат*, хакас.,

тув. *чат* «ят» — бор. тк. *йағы-т* «дошманнар» сүзеннән (к. **Яу**) булса кирәк.

**ЯТИМ** «сирота» — гар. *йәтим-ун* «ятим, үксез» сүзеннән.

**ЯТЛА-У** «выучить наизусть» — иске әд. *йадла-* «хәтерләү, хәтердә калдыру» — фарсы. *йад* «хәтер» (шуннан ук *ядәч, ядкарь*) нигезендә ясалган (*йад-ла-*); к. ш. ук диал. (мишәр.) *йад, йат* «хәтер», *йәтле* «хәтерле», әд. *яттан* «хәтердән».

**ЯТЬМӘ** «бредень (*сеть*)» — диал. *җәтмә* «челтәр», *йәтмә* «рәшәткә, текмә, читән, барьер», *әтмәлә-ү* «ятьмә үрү», чув. диал. *йатма* «изү, изү бавы», тат. диал. *әтмә* «баудан үрелгән әйбер»; *әтмәләү* «баудан үрү», мар. *этмә, атма* «соскы, үрелгән чүмеч, сөкә» — чуваш телчесе Н.П.Петров буенча, чув. *ат-* «үрү, чорнау» сүзеннән. Чаг. ш. ук госм., бор. чыгт. (Рабгузи) *читмә* «челтәр», гагауз. *чатма* «җөй, типчу», *чат-* «типчү, үрү». Чаг. ш. ук украин. *ять* «ятьмә».

**ЯУ** «противник; войско» — чыгт. *йау, йағы* «дошман ягы, сугыш, яу» — бор. тк. *йағы* «дошман» сүзеннән. Шуннан ук *яула-у*.

**ЯУЛЫК** «платок» — кк., ккк. *җаулык*, кырг. *җоолук*, ткм., госм., уйг. *йағлык* «яулык», кырым. *йағлык* «май сөрткеч» — гом. тк. *йаг* «май» сүзеннән булса кирәк.

**ЯУРЫН** «ширина спины, расстояние между лопатками» — иске әд., чыгт. *йағрын* «яурын» — тат. диал. *җауыр* «җилкә инե», госм., уйг. *йағыр, йағры* «атның савыры (*ат аркасында чиләнгән урын*), калак сөяге» сүзеннән. Борынгы яңгырашы *д'агыр-ын* булса кирәк. Чаг. *ҫăвăр*; к. ш. ук бор. монг. *йағура* «аралык, ара».

**ЯУ-У** «падать (*о дожде и снеге*) — гом. тк. *йағ-* id.

**ЯУЧЫ** «сват» — бор. тк. *йупчы* «яучы» ~ монг. *җабучи* сүзеннән дип уйланыла. К. Әхмәтьянов, 1981: 102.

**ЯФРАК** «лист, листок» — бор. тат. *йапрак*, кырг., кк. *җапрак*, бор. тк. *йапырғак, йабурғак* «яфрак, китап бите» (МК), кырг. *йалбырык*, алт. *йалбырак* «яфрак» — бор. тк. *йалбурғақ* «яфрак, җилфердәп торучы нәрсә» сүзеннән; к. тат. диал., башк. кк. *йалбыра-, йалбырда-* «җилдә җилфердәү, йалбыр-йалбыр килү». К. **Ялбыр**.

**ЯХШЫ** «хороший» — гом. тк. *йақшы, йағшы* «яхшы, әйбәт, ягымлы» — бор. тк. *йакыш-ығ* «ялгышлы, ягымлы» сүзеннән, *яқ-у* фигыленнән (Рамстедт).

**ЯШЕЛ** «зеленый» — гом. тк. *йәшел, йашыл* «яшел, яшь үлән төсендәге» — *йаш* (к. **Яшь**) сүзеннән (*йәш-ел*; чаг. *қыз-ыл*).

**ЯШЕЛЧӘ** «овощ» — к. кк. *ясылша*, кырг. *җашылча*, кум. *яшылча — йашыл, йәшел* сүзеннән (к. тат. *акча, карача, кызылча*).

**ЯШЕН** «молния» — чыгт., үзб. *йашин*, кк., ккк. *җасын* «яшен», бор. тк. *йасқын* «яшен, ялтырау». Сүзнең тамыры — *йаш-* < **йалч* «ялтырау, ялкын» булса кирәк. К. **Ялкын, Ялт**.

**ЯШЕР-Ү** «скрыть, скрывать» — чыгт., бор. тк. *йашыр-, йашур-* «яшерү» — бор. тк. *йаш-* «яшеренгән булу» фигыленең йөкләтү юнәлеше формасыннан (*йашыр-, йаш-тыр*) булса кирәк; к. тат. диал. *йәшен-*, чыгт., бор. тк. *йашун-* «яшеренү», уйг. *йашут* «яшеренлек», чыгт. *йаш* «тыныч, яшерен».

**ЯШЬ I** «молодой; возраст» — гом. тк. *йаш* «яшь, яшел, сутлы; яшь (год, возраст)» — бор. гом. тк. **йалъ* «яз, җәй, ел» сүзеннән (чаг. рус. *лето* «җәй» һәм *ему пять лет* «аңа биш яшь», *пять лет* «биш ел»). К. **Ел, Яшь II, Яшел**.

*Яшь* сүзенең «яшел» мәгънәсендә булуы караимча *йәш* «яшел; яшь» сүзе белән дә, тат. *яшәр-ү* «яшелләнү» һәм «яшь булып китү» дә ачык күренә. Бу сүзнең (*йаш ~ йал*) төптә «үлән» дигән мәгънәдә булуы күпсанлы изосемантик аналоглар ярдәмендә раслана. Күрәсең, борынгы төркиләрнең яшәү урыннарында яшь үлән елның билгеле бер чорында гына мул булган.

**ЯШЬ II** «слеза» — **яшь** I белән бәйле булса кирәк, чөнки һәр төрки телдә бу сүз *йәш* < *йаш* «молодой» сүзенә омоним булып килә (хәтта чувашчада да *ҫул* «ел, яшь» һәм «күз яше»).

## ТАТАР ЭТИМОЛОГИЯСЕНӘ КАРАГАН ТӨП ӘДӘБИЯТ

**(ике телле сүзлекләрдән һәм лингвистик журналлардан тыш)**


Абаев В.И. Историко-этимологический словарь осетинского языка. I.— М.; Л., 1958; II.— М., 1973.

Алатырев В.И. Именные деревационные аффиксы: этимология некоторых слов//Вопросы удмуртского языкознания. Вып. IV. — Ижевск, 1976.

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр.— Казан, 1945.

Аманжалов С. Вопросы диалектологии и истории казахского языка.— Алма-Ата, 1959.

Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков.— М., 1978.

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья.— М., 1978.

Ахметьянов Р.Г. Этимология некоторых служебных слов, распространенных в языках Среднего Поволжья. Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников.— Казань, 1983.— С.127 — 132.

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья.— М., 1989.

Ахметьянов Р.Г. Слова кузы < gorju и термины игры в альчики в татарском и русском языках // Материалы по татарской диалектологии.— Казань, 1988.

Ахметьянов Р.Г. Семантическая структура и происхождение терминов вокальной музыки в татарском языке // Традиционная музыка народов Поволжья и Приуралья.— Казань, 1982.— С.71 — 77.

Ахметьянов Р.Г. Музыкальные термины в поэме «Хусрав и Ширин» Кутба // Страницы истории татарской музыкальной культуры.— Казань, 1991.— С.109 — 115.

Ахметьянов Р.Г. О калькировании в языках Волго-Камского языкового союза // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка.— Казань, 1992.— С.31 — 39.

Ахунзянов Э. Русские заимствования в татарском языке.— Казань: изд-во КГУ, 1968.

Ашмарин Н.И. Словарь чувашского языка.— Казань—Чебоксары, 1910 — 1952.

Бартольд В.В. Избранные сочинения.— М., 1963, 1968.— Т.I.— V.

Баскаков Н.А. Русские фамилии тюркского происхождения.— М., 1971.

Бимабев Р. Монгольско-русский словарь.— Иркутск, 1914.

Будагов Л.З. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий.— Сибирь, 1869, I; Сибирь, 1871, II. (Стереотипное переиздание). М.: Изд. вост.лит., 1960.

Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах.— Сибирь, 1863.

Вәлиди Җ. Татар теленең тулы аңлатмалы сүзлеге.— Казан, 1928, 1929, I — II.

Гордлевский В.А. Избранные сочинения. 1959 — 1968.— Т.I — III.

Даль В. Толковый словарь живого великорусского языка.

Дмитриев Н.Н. Строй тюркских языков.— М., 1962.

Егоров В.Г. Этимологический словарь чувашского языка.— Чебоксары, 1964.

Историческое развитие лексики тюркских языков.— М., 1961.

Казак тiлiнiң кыскаша этимологиялылык создiгi.— Алматы, 1966.

МК — «Мәхмүт Кашгари сүзлеге»ндә.

Мусаев К. Лексика тюркских языков в сравнительном освещении.— М.: Наука, 1975.

Мухамедова З.Б. Исследования по истории туркменского языка // Этимологический (сопоставления) словарь.— Ашхабад, 1973.

Насыйри К. Ләһҗәи татари.— Казан, 1985, I; 1896, II.

Номинханов Ц.Д. Материалы к изучению истории калмыцкого языка.— М.: Наука, 1975.

Пекарский Э.К. Словарь якутского языка.— Будапешт, 1959, I — III.

Поппе Н. Монгольский словарь мукаддимат ал-адаб.— М.; Л., 1938 — 1939, I — II.

Преображенский А.Г. Этимологический словарь русского языка.— Сибирь, 1913; Харбин, 1959.

Проблема общности алтайских языков.— М.: Наука, 1971.

Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий.— Сибирь, 1888 — 1910, I — IV.

Саблуков Г.С. Очерк внутреннего состояния кыпчакского государства.— ИОАИЭ, XIII.— Казань, 1895 (Борынгы кыпчакларда үлчәүләр, календарь һәм хәрби терминнар).— 105 — 142 б.

Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе.— Казан, 1998.

Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков.— М.: Наука, 1974, т.I; М., 1978, т.II; М., 1980, т.III; М., 1989, т.IV.

Срезневский И.И. Материалы для словаря древнерусского языка по письменным памятникам.— М., 1958 — 1959.— Т.I — III.

Татары Среднего Поволжья и Приуралья.— М.: Наука, 1967.

Татар теленең диалектологик сүзлеге.— Казан, 1969, 1993.

Троянский А. Словарь татарского языка.— Л., 1833 — 1835.— Т.I — II.

Трубачев О.Н. Происхождение названий домашних животных в славянских языках.— М., 1960.

Фазылов Э. Хорезмские памятники XIV века.— Ташкент, 1969, 1971, I — II фан.

Фасмер М. Этимологический словарь русского языка.— М.: Изд-во «Прогресс», 1964, т.I; 1967, т.II; 1971, т.III; 1973, т.IV.

Федоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды.— М.: Изд-во МГУ, 1973.

Шанский Н.М. Краткий этимологический словарь русского языка.— М., 1961.

Шпилевский С.М. Древние города и другие болгарско-татарские памятники Казанской губернии.— Казань, 1877.

## СХЕМА I






## СХЕМА II



Clauson G. An etymological Dictionary of pre-thirteenth century Turkish.— Oxford, 1972
CC-Das türkische Sprachmaterial des Codex Cumanicus von W. Radloff — СПб., 1887.
Çagatay Z.Die Bezeichungen für Frau im Türkischen. UAj XXXIII, I—2.— Wieβbaden, 1961—S. 17—134.
Doerfer G. Türkische und mongolische Elemente im Neupersischen.
Bd. I. Mongolische Elemente im Neupersischen. Wieβbaden, 1963.
Bd. II—IV. Türkische Elemnte im Neupersischen. Wieβbaden, 1965,1967, 1975.
EJ-The encyclopaedia of Jslam. New Edition, V. I — 5.— Leiden — London, 1960—1986.
Horn P. Grundriss der neupersischen Etymologie. — Strassburg, 1893.
Gabain A. Die Leben im uigurischen Konigreich von Qočo. V.—II.— Wieβbaden, 1973.
Çolden P. Khazar Studies. An historico — philological inquiry into the origins of the khazars.— Buolapest, 1980.
Çombocs Z. Die bulgarisch-türkisehen Zehnwörter in der ungarisehen Sprache. MSFOu XXX.— Helsinki, 1912.
Joki A. Die Zehnwörfer des Sajansamojedisehen. MSFOu 103.— Helsinki, 1952.
Joki A. Uralier und tndogermanen. MSFOu 151.—Helsinki,1973.
Latt A.J. A dictionary of urdu, classical Hindi and English V. I—II.— M., 1949.
Pokorny J. Jndogermanisches etymologisches Wörterbuch.— Bern und München, 1951—1959.
Ramstedt G.J. Studies in Korean etymologi. MSFOu XCV.— Helsinki, 1949.
Ramstedt G.J. Kalmückisches Wörterbuchs. LSFU III.— Helsinki, 1976(1935).
Räsänen M. Die tschuwassiche Lehnwörter in Tscheremissischen MSFOu XLVIII.— Helsinki, 1920.
Räsänen M. Die tatarische Lehnwörter in Tscheremissischen MSFOu L.— Helsinki, 1923.
Räsänen M. Versuch eines etymologischen Wörterbuchs der Türks prachen.— Helsinki, 1969.
Rona-Tas A. Loan-vords of ultimate Middle mongolian origin in Chuvash. Studies in Chuvash etymology I.— Szeged, 1982. Pp66—135.
Zenker J.T. Dictionnaire turk-arabo-persan.— Leipzig, 1866—1876. T. I—II.

РИФКАТЬ
ӘХМӘТЬЯНОВ

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КЫСКАЧА
ТАРИХИ - ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ